


# Казан утлары

7. 1987



## УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИГЪТИБАРЫНА!

Илебездәге газета-журналларга киләсе ел өчен язылу башланырга аз вакыт калып бара. Шуңа бәйле рәвештә укучыларыбыздан «Казан утлары» журналына язылу тәртибе турында күпсанлы сораулар килә.

Соңгы еллардагы тәҗрибә раслаганча һәм алынган хатлардан күренгәнчә, «Казан утлары» журналына язылуның иң уңайлы вакыты — язылу башлангач беренче унбиш көн. Моны бигрәк тә Татарстаннан читтә яшәүче иптәшләрнең исенә төшерәсе килә.

Журналның Бөтенсоюз каталогындагы индексы—73210.

Бер елга язылу хакы — 10 сум 80 тиен.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

7

1987

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

БӨЕК ОКТЯБРЬНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

**А. ГЫЙЛӘҖЕВ, А. ЛИТВИН. Августның алтысыннан соң...** *Роман* . . . . . . . . . . 3

**Р. ФӘЙЗУЛЛИН. «Таулар» циклыннан.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . 73
**Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Чатта тукталу.** *Повесть* . . . 80
**И. ЮЗЕЕВ. Сез кабызган утлар.** *Поэма* . . . . . 124

ОСТАХАНӘ

**Ш. ҖИҺАНГИРОВА. Мәхәббәт бизмәне.** *Хикәя* . 131
**Г. САБИТОВ. Хикәя авторына ачык хат** . . . . 141

ӘДӘБИ МИРАС

**Г. КАНДАЛЫЙ. Шигырьләр** . . . . . . . . 143
**М. ГОСМАНОВ. Кандалый мирасын барлау юлында** . . . . . . . . . . . . . . . 150

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

**З. САФИН. Көч җитәрлек** . . . . . . . . . 152
**А. ХӘСӘНОВ. Йөк атына — солыны күбрәк!** . . . 156

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

**И. В. ГӘРӘЕВ. Үсештә, үзгәрештә** *(Зәй районы)* . . 160

БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

**Э. Г. ТАҖЕТДИНОВ. Закон сагында** . . . . . 163
**Р. ЮНЫС. Ничек, Гата, барып җитәрбезме?** . . . 167

БИБЛИОГРАФИЯ

**М. МӘҺДИЕВ. Китап һәм тарих** . . . . . . . 171

КОНКУРСКА

**Ф. ЗӨЛКАРНӘЕВ. Бөрене тамыр ыята** . . . . . 176
**Р. ШӘРИПОВ. Ачык йөз** . . . . . . . . . . 179

ОРЕНБУРГТА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

З. МӨХӘММӘТҖАНОВА. Ш. Мөхәммәдев йорты . 182
Җ. МИҢНУЛЛИН. Даладагы калада . . . . . 183

ЮБИЛЕЙЛАР

Э. ГАЛИЕВА. Абруйлы тәнкыйтьче *(Г. Нигъмәтинең туууына 90 ел)*. . . . . . . . . . . 184
Г. АХУНОВ. Аналар бәхете *(Р. Ишмуратовага 70 яшь)* . . . . . . . . . . . . . . . 187

«КАЗАН УТЛАРЫ» — 1988 ЕЛДА

Кабан күленең серләре . . . . . . . . . . . 190
Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . . 191
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Вторая книга романа А. ГИЛЯЗОВА и А. ЛИТВИНА «После шестого августа...». Повесть Р. ТУХВАТУЛЛИНА «На перекрестке». Поэма И. ЮЗЕЕВА. Стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА.
«Литературная мастерская» — рассказ молодой писательницы Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ разбирает Г. САБИТОВ.
В рубрике «Литературное наследие» стихи поэта XVIII века Г. КАНДАЛЫЙ.
«Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь!» — выступление директора завода СК им. С. М. Кирова г. Казани З. САФИНА. Статья А. ХАСАНОВА. В рубрике «Татарстан — родной мой край» — статья первого секретаря Заинского горкома КПСС И. В. ГАРЕЕВА.
«Наша мораль» — выступление министра юстиции Татарской АССР А. Г. ТАЗЕТДИНОВА.
Статья Р. ЮНУСОВА о шахматисте-юниоре Г. Камском.
В номере рецензируются книги А. Каримуллина, Р. Газизова и А. Мингазовой.
«Памятники татарской культуры в Оренбурге» — дом, где жил Ш. Мухамедов.
В номере отмечаются 90-летие Г. Нигмати и 70-летие Р. Ишмуратовой.
На первой странице обложки — образцы татарского ювелирного искусства — браслеты и перстни (XVIII-XIX вв.). На четвертой странице обложки — памятник Н. И. Лобачевскому в Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова*.

Производствога бирелде 4.05.1987 ел. Басарга кул куелды 23.06.1987 ел. ПФ 05228. Офсет ысулы белән басылд.
Кәгазь форматы 70×108 $^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 67149. Заказ М-197. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

**Аяз Гыйләҗев,**

**Алексей Литвин**

# АВГУСТНЫҢ АЛТЫСЫННАН СОҢ...

**РОМАН-ХРОНИКАНЫҢ ИКЕНЧЕ КИТАБЫ**



Капка тавышсыз-тынсыз гына ябылды, һәм мин, аяк очларыма гына басып, ишегалдына кердем. Йортта ут сүнгән, бөтен җирдә дөм караңгы, җәй эчендә тагын да куерып киткән сирень куакларына шомлы каралык кереп оялаган, тып-тын, почмакта куерып утырган кычыткан яфракларына, шыбырдап, яңгыр гына сибәли. Ишегалдының елгага таба авыш ягында элекке хуҗалардан ук калган кыйшык түбәле иске мунча бар, төнне мин шунда үткәрергә тиеш. Иртәгә көндез дә мин анда булачакмын. Гайнулла белән без кичкырын гына очрашырга тиешбез. Ул университет подвалында төн үткәрә...

Яңгыр сибәләп кенә торса да, җирне шактый җебеткән, кычытканлыкка барып җиткәнче, әллә ничә мәртәбә таеп киттем, итек үкчәсе белән тирән-тирән ызан сыздым, эз калдырырга ярамый иде, пошындым да, «иртәнгә кадәр яңгыр юар әле!» дип тынычланып, каты сабаклы кычытканнарны ике куллап аралый-аралый, явыз урманны уза башладым. Рәхмәт Таняга, ул сукмак салып үткән, алай да кычытканнар өч-дүрт тапкыр беләгемне, чалбар аша тез башымны пешереп калдылар. Юеш кычыткан җәлләмичә чага!

Аска салынган бу авыр, чалыш ишекне Таня ничек ачкандыр, иелеп, иңем белән күтәреп көчкә ачтым, кердем, ниндидер ят, авыр ис борынга килеп бәрелде... Бераз басып торгач, тонык тәрәзә турысында, авыр караңгылыкта мин сәкегә җәелгән ак нәрсә абайладым, кармаланып, шырпы табып алдым, чырт итеп үземне-үзем сискәндереп кабыздым һәм мунча эче киңәеп китте. Ләүкәгә дә ак чүпрәк җәелгән иде, анысы тастымал булып чыкты, Таня миңа ашарга-эчәргә дә китергән икән...

Калай чәйнек әле җылымса иде, Таняның монда күптән түгел генә кереп чыгуын шуннан чамаладым. «Йорттагыларның йоклап беткәнен көткәндер!» — дип, сызланып уйладым. Форсат барында ныгытып каларга кирәк иде, иртәдән бирле тамакка тәгам капкан юк, калын-калын ипи телемнәрен, шактый зур кисәк итне, биш-алты ярка тәмле бәрәңгене берочтан сыпырып та куйдым. Көне буе ачы су килеп торган ашказаным тынычланды диярлек. Хәзер әз-мәз черем итеп, талган аяк-

---

Романның беренче китабы «Августның алтысына кадәр...» дип атала. «Казан утлары»ның 1986 елгы 9, 10 саннарында басылды.

ларга ял бирергә кирәк иде. Иртәдән бирле аяк өстендә, бөтен гәүдәм кыйнап ташланган сыман сызлый, күз кабакларым йомылырга гына торалар. Тагын шырпы яндырырга кыймадым, кулларым белән стенага терәлгән эскәмияне кармаланып табып, аны уртагарак тарттым. Стена корымыннан да сак булырга кирәк, иртәгә кеше арасына, хәвефле дөньяга чыгасы бар! Эскәмиянең бер башын күтәреп куйыйм дисәм, кулым чиләккә тиеп китте, чиләк бавы котны алып шылтырады. Таня тагын берәр нәрсә калдырганмы әллә дип, эчкә тыгылсам, бармакларым салкын, түгәрәк металл арасына барып керде. Түзмәдем, ут кабыздым, иелдем һәм чытырдатып күземне йомдым — мунча эскәмиясе астындагы яньчелгән чиләк алтын тәңкәләр белән туп-тулы иде...

Бүген үзем шаһит булган хәлләр чигәмне кысып, җанымны дуылдатып талап, күңелемдә өр-яңадан калыктылар, банк ишегалдындагы ызгыз-талаш күз алдымнан йөгереп үтте, колагымда ярым кыргый авазлар яңгырады. Димәк, көндез дөрес күргәнмен, алтын талаучылар арасында Таняның әтисе дә булган. Шундый юаш, кыюсыз һәм басымчак адәм кеше талаучылар арасына ничек барып кергәндер, бусын берничек тә аңлый алырлык түгел иде. Төнге ярканат кебек көнгә чыгарга базмыйчарак, «үземнеке үзәктә, кешенеке кештәктә» диебрәк яшәгән кешене дә тартып китерә алган «сары аждаһа» комсыз-комагайларны кайлардан гына чакырып китермәгәндер!

Тар, җайсыз, какшау аяклы эскәмиягә көч-хәл белән сыеп сузылып яттым да, кулларымны баш астыма кушырып, тирән, котылгысыз авыр уйлар чоңгылына чумдым. Кулларым тыгыз кысылыбрак йомарланды, әйтерсең лә миемне дыңгычлаган ямьсез уйлар йодрыкларга ага торды. Кемнәр? Ничек? Каян?

Миңа бу сөремле кара мунчада (уйлар сөреме арасында!) көн үткәреп җибәрергә кирәк, Гайнулла белән кичен очрашабыз да, бүгенге нәтиҗәләрдән чыгып, алдагы көннең планын билгелибез. Ашыгырга да, хата җибәрергә дә ярамый! Яңа властьның чуалчык, буталышлы көннәре булса да, алар бер җәһәттә — чекистларны эзләү һәм табу юнәлешендә сынатмаслар, теш-тырнаклары белән ябышачак! Бу урынымны хәвефсез дип исәпләгән идем, менә бу сылама тулы чиләк кенә эшне бозды. Алтын банкның яшерен подвалыннан чыгып, көнгә күренгән икән — аның тирәсендәге ыгы-зыгы, кискен хәрәкәт, талаш, үлем белән тормыш арасындагы сугыш бер чакта да туктамый. Алтын — мәңгелек хәрәкәттә. Алтын куркыныч юлдаш!

Бәла килгән төннең беренче минутларында ук шундый куркыныч юлдашка юлыктым, һич шик юк ки, дәшми-тынмый утырган чиләк, вакыт аккан саен, дәһшәтлерәк була бара, минем язмышка яный иде. Йокы тәмам качты, чәбәләнгән уйларымның тотрыклы юнәлеше дә, азагы да юк иде.

Йокылы-уяулы тинтерәп ята торгач, иренеп кенә көн яктырды, мунча эченә тоник нәни тәрәзәдән сүрән, өметсез яктылык агылды. Көн ачылган саен мин үземә куркынычның ныграк янавын, аның менәменә килеп җитәчәген сиздем, алтын бер урында, ачык хәлдә тик кенә ята алмый, үзе монда булса да, әллә кемнәрне хәрәкәткә китерә, озакламый кемдер килергә, комарланып, туп-туры бәреп керергә тиеш. Күңелнең иң тирән төпкелендә зәгыйфь кенә өмет тә калкынып ала: «Бәлки алтынны Зоряның әтисе берүзе алып кайтып куйгандыр!» Шулай булса кана... Тик бу өмет яралгысы тиз үк үлә, күңелдәге караңгы үй дулкыннары алмаш-тилмәш килеп, китеп торалар. Әллә форсат барында чыгып ычкыныргамы? Әллә чиләге белән чыгарып тондырырга, кычыткан арасына күмәргәме үзен? Чыгарсың чыгуын, ә алтынны сагалаучылар булса? Алар да минем кебек мазалы төн үткәреп таң тишегеннән килеп җитсәләр? Йорт тәрәзәсеннән өйдә саклап утырсалар?

Бүтән барыр җирем әлегә юк. Танялар йорты иң ышанычлы саналганга, башка вариант каралмаган иде. Иске, кара мунча бер чиләк

алтынлы банк филиалына әверелер дип кем уйлаган?! Бәлки бүгенгә, бүгенге кичкә кадәр генә алтын караклары түзеп торырлар, килмәсләр?.. Алтын барын Таня белеп калса, нидер хәбәр салмыйча түзмәс, аннан коткаруның бер-бер җаен табар!

Шулай өметләнеп, икеләнгән боек күңелемне, шомлы уйлардан арындырып, аз гына җылытырга бик нык тырышсам да, барып чыкмады, болытлы сүрән көн генә түгел, кысан мунча эче дә шактый яктырып, эчтәге вак-төяк әйберләр, эчпошыргыч иске җиз тас, күгәргән кыршаулы чапчак, колаксыз иләмсез чиләкләр аермачык күренә башлауга, чыелдап, тирә-юньне сөмсез тавыш белән сискәндереп, капка ачылды. Хәвеф көткәндә, капка шулай дөнья сасытып ачыла икән, көт тә тор, бәла килде диган сүз! Димәк, капканы кичәге җиңүчеләр каерып ачты, күргәнегезчә, җиңелгәнне, ягъни мине, ярты төндә капка тавышсыз-тынсыз гына үткәреп җибәргән иде. Кем йөрер? Кемнәр?!

Ансат кына бирешмәскә уйлап, баш очыма куйган наганымны кулыма тоттым...

Капка тавышы сеңәргә дә өлгермәде, дөбер-дөбер ишек кагарга тотындылар. Кылыч кынысы белән төяләрме, мылтык түтәсе белән кагалармы — усалланалар, чакырылмаган таңгы кунакларның явыз нияттә икәнлегендә шик-шөбһәм калмады диярлек. Тавышларына караганда — гаскәриләр. Юк, болары алтын артыннан йөрмиләр булыр.

Кинәт сискәнеп, дерт итеп киттем: әллә берәрсе, минем эзне иснәп табып, чагып өлгердеме? Артымнан күзәтә үк килделәрме? Безнең теңкәгә тигән мөртәт җан хыянәтчеме? Кичә мин үтә сак килдем, туктаптуктап тыңладым, алда-артта беркем юк иде кебек... Минем Таня белән танышлыкны хәтерләп шикләнә калдылармы дисәң... Әллә Зоря өчен килделәрме?.. Юк, тавышларына караганда, болар — алтын хуҗалары түгел, алтын артыннан килсәләр, болай акырып-бакырып кычкырмаслар иде. Өй ишеге булса кирәк, яман шыгырдап ачылды, ир-ат, солдат тавышы колакны ярды, икенчеләр басынкы гына нидер аңлатып маташты, хатын-кыз тавышы ялварды, дөп-дөп нык басып йөрделәр, берзаман ыгы-зыгы сизелерлек көчәеп, тавышлар якынлашты, чамаладым, алар мин яшеренгән мунчага таба киләләр! Аяк тавышлары якынлашкач, пыяласы тоныкланып, зәңгәрләнеп беткән тәрәзәгә сеңдем, юньләп аерып та, күреп тә булмады, куе кычыткан урманы килүчеләрне каплады...

Ишек авыр сөйрәлеп ачылды, кызганычка каршы, мунчага мин өметләнгән кеше — Таняның әтисе түгел, юантык кына, чәбәләнгән калын кашлы, ниндидер озын чабулы, бәрхет якалы пинҗәк кигән бәндә килеп керде, ишек яктысында басып калды, йодрыгы белән чепи күзләрен уды. Почмакка артым белән чумып бетеп, иренемә бармагымны аркылы куеп: «Шым бул!» — дип боерулы ялварсам да, бәрхет якалы бераз аңгыраеп күзәтеп торгач, күзе ияләнә төштеме, мине абайлап үкереп җибәрде, шунда ук юк та булды.

— Җен бар! Пәри! — дип чинады куян җан.

Ишегалдында кыска, кискен команда яңгырады, штыкларын алга сузып, тар ишектә бер-берсенә комачаулап кысыла-кысыла, яныма ике акгвардияче солдат килеп керде. Берсенең кокардалы картузы, башыннан төшеп, минем аяк очына тәгәрәп килде. Шәһәрне алу, җиңү шаукымы белән җиңеләйгән, кан, мәет исеннән генә түгел, аракы чөмереп исәрләнгән бу ике акай күзне апрельдә урман аланында акылларын җуйган сөерләрны аткан кебек кенә чүкеп ала идем, бер нәрсә тыйды: мин Танялар мунчасында!..

Ишектән чыгуга, Иванов дигән таныш бәндә белән йөзгә-йөз очрашкач, чак авып китмәдем, мин гаҗәпләндем, миннән бигрәк ул курыкты, куян җанлы бәрхет яка салган сөреннән соң шигәеп җен-пәри күтәп торганда, адәми зат килеп чыккач, аның аксыл-тонык чырае зәңгәрләнде, юка, кан качкан иреннәре мелт-мелт калтыранды.

— Сергей Сергеевич! — диде ул бераздан һәм, нык сөенеп, юлдашларына карады.— Куянга чыгып төлкегә юлыгу шушы буладыр! Мин сезне кичә көне буе эзләдем, ә бүген сезне эзәрлекләп йөрүем түгел иде әле, без таңнан торып, кичә исәпкә алынган алтын каракларын тотып-тотып селки идек. Селкегән саен, алтын коела!.. Очрашу дисәң дә очрашу, билләһи!..

Казан университетына укырга дип, ерак Себердән үк килгән кеше иде бу Иванов. Савинков фетнәсе уңаеннан без аны кулга алдык та, әшен мин тикшердем, гаепләрлек төпле дәлилләр житмәгәч, озак та тотмыйча, без егетне азат иттек. Миңа ул бераз җиңел холыклы, вәгъдәсез, нинди власть өстенлек алса, шуңа ярақлашырга әзер торган буынсыз ялагай булып тоелды, ахыр чиктә ул күргәзгәннәр расланмады, егет «фәлән-фәләннәр фетнәгә катнашты» дип, байтак кешеләрнең исемнәрен яздырса да, алай булып чыкмады. Таһиров кызып-кызарып: «Иманым белән ант итәм, Иванов дигән бу явыз дошманны чыгармыйк, нык кына тагын бер селкеп карыйк!» — дип, кат-кат үгетләсә дә, тыңламадык, авыр чаклар, ашыгыч бүтән эшләр өелде, озын-озакка сузарга рәт юк, чыгардык та җибәрдек Ивановны!

Һәм менә, исән-сау торасыңмы, кодагый, мунча чиләгендәге алтын тәңкә кебек ялтырап, янып каршымда нәкъ үзе басып тора.

Чак егылып китмәдем...

— Әфәнделәр,— диде Иванов иптәшләренә мөрәҗәгать итеп.— Танышыгыз. Сергей Сергеевич Фролов, чеканың Мәскәүдән килгән зур кешесе! Чекада миннән җавап алды. Ә болары, Сергей Сергеевич, менә Ризван Гариф, җирле халык вәкиле, калганнары сез бик нык эзләп тә кулга алырга өлгермәгән кавемнән! Ха-ха!

Ризван Гариф дигәннәре юантык, калын бармагына иләмсез алтын балдак кигән, чуар түбәтәйле кеше, саргылт кашларын җыерды, без «кулга алырга өлгермәгән әфәнделәр»нең икесе мине ике яктан алагаемга күтәреп кысты, берсе, күнегелгән житез хәрәкәт белән, бил каешыма кыстырган җылы наганымны суырып чыгарды.

Чеканың Мәскәү вәкилен каптыру ошап китте булса кирәк, алар иннәренә суга-суга, гөр-гөр сөйләшергә тотындылар...

Кем? Минем монда булуымны көне-сәгате белән кем белгән дә, кем хәбәр иткән? Җавап эзләп, тилмереп, өметсезләнеп Таняларның йортына карадым, тәрәзә пәрдәләре төшерелгән, өйалды ишеге ачык, анда да, монда да кеше заты күренмәде. Кызы өчен Зоряның әтисе үч ала дисәм, соңгы вакытларда аның мөнәсәбәте яхшы якка күренерлек үзгәрде, без дуслаштык диярлек... Димәк, башка берәү?! Кем?!

Алай булып чыкмады. Ивановның «куянга чыгып төлкегә юлыгу» дигәне бик тиз аңлашылды.

— Ну,— диде Гариф, бәрхет якалыга карап. Божыр кебек кеше йомылып кереп тә китте, маңгае, иңбашлары корымга буялып килеп тә чыкты. Кулындагы чиләктән җиргә ике-өч алтын тәңкә төште...

— Менә! — диде ул кычкырып, һавадагы асыл кошны тоткандай сөенеп.— Күрегез! Мин сезгә «өчебезгә бер генә чиләк алтын алдык!» — дип мең кат тәкърарладым, ышанмаган идегез! Менә!..

Бәрхет яка, чиләкне ике куллап тотып, калтырана-калтырана, Иванов алдына китереп куйды да тезләнеп, изүен ачып, күзләрен күккә баглап чукынырга тотынды.

— Ходаем! Дөреслекне яклаучыбыз! Әле дә ярый син бар! Без гөнаһлы бәндәләрне саклап торучы ходаем!...

Алтынны күргәч тоташ җанланып киткән «җиңүчеләр» бер мәлгә генә мине онытып та тордылар, капка ябылмаган, әллә таеп караргамы дигән уй башыма килеп китте. Таняларның ачык ишеге янында мылтыгын иренеп кенә тоткан ак солдат басып тора, чыраена карарлык түгел, күз кабаклары салынган, бите кызарып-шешеп карабодай тәбикмәгенә әйләнгән.

Бәрхет яка укынып туйгач, тагын бер кат Ивановка эндәште:

— Бар булганы шул!

Аны шундук тибеп очырдылар, ул, чинап-улап, кычытканнар арасына барып сеңде һәм яңадан тыны да чыкмады[1].

— Кузгалдык! — дип команда бирде Иванов, тагын да җанланып, аннары елмаеп миңа карады.— Бер чиләк алтынга караганда сез безгә кыйбатрак, Сергей Сергеевич! Шулай да артыгын шүрләмәгез, үземне чека тәбесеннән кем коткарганын онытканым юк. Ярдәм итәрмен!..

Күк ат җигелгән трантаска башта чиләкне утырттылар. Гариф белән бер офицер чиләкнең ике ягына кысылыштылар, без җәяү киттек. Капка чыкканда, борылып карадым, пәрдәләр томаланган, йортта кеше барлыгы бөтенләй сизелми, бөтен җир, почмаклар, диварлар сагаеп тынып калган. Бер нәрсәне аңладым: әгәр мунчада мин табылмасам, бәрхет яка әләгеннән соң Танянын әтисенә көн күрсәтмәсләр иде! Мин коткарып калдым аны! Чуртан эләккәндә, җәтмәгә килеп кергән шыртлакага карап тормыйлар, аны суга ыргыталар!.. Хәтта бераз җиңел булып китте, һәр яманлыкның бер яхшысы да була шул, нишлисең — дөнья!

Крепостька без урау юл белән бардык, баштарак моның нилектән икәнен аңлап бетермәсәм дә, юлда күргәннәремне йомгаклап, болар минем котны алырга, өркетергә уйлыйлар, допросның «татлысы»на әзерлиләр дигән нәтиҗәгә килдем.

---

[1] Моннан ун еллар чамасы элек Татарстан Эчке эшләр министрлыгына түбәндәге хат килеп төште:

*«Казан шәһәр милициясе начальнигына кайчандыр шул шәһәрдә яшәп, хәзерендә Кытайның Циндао каласында гомер итүче Прохоров Иван Федоровичтан*

үтенеч:

Хәзер миңа житмеш биш яшь. Үләр вакыт житсә дә, жаным һаман тыныч түгел. Гомерем буе жанымны элекке күршем Сидоров Николайның явыз этлеге, комсызлыгы һәм хыянәте талады. Без аның белән күрше булып вокзалдан ерак та түгел, Посадский урамының азагында, Таш күпер янында яшәдек.

Унсигезенче елның августында, шәһәргә аклар кергәч, без Николай белән, Проломный банкында кем күпме теләсә, шул кадәр алтын чумыра ала икән, дип ишеттек. Чиләкләр тотып, Подлужный урамындагы бер танышыбызны ияртеп, банкка юнәлдек һәм үзебезгә өч чиләк алтын тутырып чыктык. Юлда явыз жаннар бер чиләген бездән талап алдылар. Алтынны өйгә алып кайтырга курыктык. Әтиләр ачуланып, тартып алырлар дип шикләндек. Бер чиләген аулакка — Подлужныйда яшәүченең мунчасына илтеп яшердек, берсен үзебезнең йортлар арасындагы бакчага күмдек. «Аяк асты тынгач, тигезләп бүлешербез»,— дип сүз куештык. Аклар мине армиягә алдылар. Николай чирләп гаскәргә эләкмәде. Кызыллар безне шәһәрдән куганда да ул бизгәк хастасы белән ята иде. Хушлашканда: «Подлужныйдагы алтынны власть вәкилләре тартып алды»,— диде. Алдагандырмы, белмим, калган бер чиләкне дөньялар тынычлангач бүләрбез дип, сүз беркетеп, без аерылыштык. Мин аңа: «Исән-аман илгә кайта алмасам, өлешемне гадел рәвештә мин атаган урынга жибәрерсең»,— дидем. Ул вәгъдә бирде. Дөнья мине байтак еллар айкап йөртте, башта Колчакта идем, аннан атаман Семеновка эләктем. Кызыллар Маньчжуриядә бик нык талкыгач, без Кытайга ук сыпырттык. «Алтынны миңа жибәр»,— дип, күршемә бер-бер артлы үтенеч язсам да, ул хатларымның берсенә дә жавап бирмәде. Бу хат белән сездән шуны сорыйм: чирлегә сабышып өйдә калган һәм хәзинәне үзләштергән явыз жанны жәзага тартыгыз.

1975 ел, 10 май».

Республиканың Эчке эшләр министрлыгында бу хатны кызыксынып укыдылар: мондый хәбәрләр көн дә килеп тормый! Бауман районы милициясенә эшне тикшереп ачыкларга кушылды. Шул районда яшәүче Вениамин Сидоровны тиз эзләп таптылар. Гаражлы, машиналы һәйбәт пулатта яшәп ята Вениамин. «Гаиләгездә алтын бар идеме?» — дигән сорауга, ул «бар иде» дип, туры җавап бирде. «Күптән вафат булган бабайдан калган мирас. Аның улы, минем әти, Ватан сугышы фронтында 1944 елны һәлак булды. Хәзиннән әле дә әз-мәз калды,— дип, Вениамин участковый милиционерга ун алтын таңка күрсәтте. Бүтәннәрен ювелир кибетенә, банкка тапшыра-тапшыра яшәдек»,— дип аңлатты.

Җинаять кылучыларның исән түгеллеген, эшнең күптән узган булуын искә алып, эш шуның белән туктатылды.

*(Исем-фамилияләр үзгәртеп алынды. Авторлар)*

Төне буе пыскаклаган яңгыр канлы мәхшәрнең эзен юып та, җуеп та бетермәгән. Рыбнорядск һәм Малый Проломный урамнары чатында, җимерелгән баррикада төбендә кулларын җәеп, тап-таза яшь моряк канга тузып ята. Карар җирен калдырмаганнар бичараның, пулялар теткәләп бетерү генә җитмәгән, гәүдәсен штыклар белән тишкәләп иләк ясаганнар, каты әйбер белән башын ярганнар. Җәзалаучыларның ләззәтләнеп мыскыллаулары күренеп тора. Анда да, монда да мәсхәрәләнгән, туралган гәүдәләр ауный, мәетләр өстенә кемнең кайсы урында совет властена хезмәт итүләре турында язулар ташланган. Ирексездән танышларымны эзли башладым һәм, Зур Проломный урамына борылганда, университет студенты, таныш чекистны таныдым. Ияге умырылып чыккан, баш чүмече чәрдәкләнгән, күзләре чокылган, кул-аяклары сынган булса да, мин аны таный алдым. Күтәрелеп карадым, Ивановның күзләре әле миңа, әле мәеткә таба сикергәли, ул, елмая төшеп, кулын минем иңбашыма салды, мин кискен хәрәкәт белән, җирәнеп, кулны алып ташладым.

— Курсташлар идек без аның белән, яши белмәде,— Иванов канәгать, тавышы чәңгелди.— Я, ничегрәк, Сергей Сергеевич, гыйбрәтләр җитәрлекме? Сезгә сабак булсын өчен әйтәм, бирелгән сорауларга туры җавап бирсәгез, белгәннәрне яшермәсәгез — яшисез.

Дәшмәдем, башым, авыраеп, түбәнрәк иелде, аклар кулына төшкән иптәшләремнең язмышы турында әрнеп уйладым... Мине дә шундый язмыш көтмимени? Без Воскресенская урамына менеп крепость капкасын үттек, бер җирдә дә сак күренмәде. Мине гарнизон гауптвахтасының үнөченче камерасына кертеп яптылар. Ивановның йөзеннән елмаю сүнмәде:

— Беразга монда торырсыз,— диде ул.— Уйланыгыз!

Әллә каян гына килеп чыккан Ризван Гариф түбәтәен селкеп:

— Кызлар юк-югын, мәгәр күңелсез түгел анда,— дип хихылдады.

Алар китеп, озак та үтмәде, ишек бикләре тагын шылтырады, камерага бик нык кыйналган ике эшчене керттеләр, чырайларына карап, мин аларның татарлар икәнен чамаладым. Дымлы, салкын таш идәндә бераз аунагач, алар, калкынып, телгә килделәр, үзара татарча сөйләшә башладылар да русчага күчтеләр.

— Эш мөшкел,— диде беренчесе шешенгән канлы кулларын кочкә кыймылдатып.— Урамга чыгар хәл калдырмадылар. Кибет хуҗалары, бүселеп чыгып, бергә төйнәлгәннәр, җиңнәренә ак бәйләгәннәр, арыбире чабалар, күзләре акайган, акыралар, кулларына кем килеп эләксә, шуны тотып яралар. Аткүз Галәви берәүне күрсәтеп: «Әнә, комиссар бара!» — дип акырган гына иде, атып та ектылар теге бичараны. Үз күз алдымда тәгәрәп җан бирде.

Икенчесе көрсенеп аны җөпләп утырды да бераздан:

— Мирза Ибраһимов булабыз без, борадәран Кәримовлар матбагасында эшлибез. Менә, агай, кибеткә кереп чыгыйм дип урамда күренүем булды, квартальный: «Әнә большевик килә, җанын җәһәннәмгә олактырыйк!» — дип илерә башлады. Акгвардиннарга шул кирәк тә, котырган эт сыман кемне тешләргә белмичә койрык чәнчеп йөриләр иде, каптырып алдылар! Кыйнап юлда ук үтерәләрме дисәм, исән-аман китереп житкерделәр тагын.

Беренче эшче «Победа» фабрикасыннан икән, иптәшенең сүзенә ялгап китте:

— Ул «ак җиңнәр» безгә дә килеп җитте. Уннан артык кеше, йөз кешедәй кычкыралар, «көнегез бетте, кабахәтләр!» — дип акыралар. «Буржуйларны җәлләмәдегезме, хәзер менә әҗерен алыгыз!» — дип, бөтенебезне стенага каратып тезделәр, байтагыбызны атып ектылар, мине типкәләп монда китерделәр.

Эшчеләр гауптвахтаның «затлы, офицерлар камерасына» ялгыш килеп эләккәннәр икән, төш алдыннан аларны бүтән камерага күчерделәр, кичкырын атарга алып чыктылар.

Алардан соң минем янымa большевиклар партиясенең Казан губерна комитеты рәисе Яков Шейнкман белән хәрби әсирләр эше буенча комиссар булып эшләгән Павел Беренсны кертеп ятпытылар. Салкын гына күрештек, хәл-әхвәл алыштык, аларны да әлегә, минем кебек үк, җәзаларга өлгермәгәннәр икән.

— Монда очрашуны көтмәдегезме? — диде Шейнкман, минем сурайган чыраема карап.— Нишлисең, мин дә көтмәгән идем, патша зинданнарын татыдык, иллә мәгәр учредиловчылар тотып ябар дигәне уема да кермәде! Үз вакытында нигә китә алмадым дигәндә, эш болай булды: дары заводы эшчеләрен үзем коралландырдым, ахыргача аерылмаска сүз бирдем, аларга тиз арада Свияжскига китәргә кирәклеген хәбәр итмичә шәһәрдән чыгып качуны хыянәт дип санадым!.. Хәбәрем барыбер соңарды... Аннары...— Ул гаепле төс белән елмайды.— Улымны күрәсем дә килде! Мондый мәхшәрдә, җитмәсә гел яңгыр, юештә хатыным баланы үзе белән алып китәргә йөрәксенмәде, аны да мин урнаштырып йөрдем...

Авыр хәбәрләрдән барыбыз да авыраеп калып, уртак бер сорауга да төпле җавап таба алмыйча утыра торгач, кичне җиткердек...

— Аннары эшләр кыекка китте! — дип дәвам итте Шейнкман, бая өзелгән уйларын ялгап.— Калдым. Госпитальгә кереп кундым, иртән яңагымны бәйләп Грузинский урамындагы госпитальгә юнәлдем. Кесәмдә доктор Аккерман исеменә паспортым бар, каушамыйча диярлек барам! Таныш врач ике-өч көн больницасында яшереп асрый алса, димен, алга таба күз күрер. Барсам, врачым больницада да, янәшәдәге өендә дә юк, эчемә пошаман тулды... Өмет аңарда иде! Улымны алып калмас микән дип тә өметләнгән идем. Больница бакчасындагы куелыкта көтеп утыра идем, янымнан үтеп баручы больница хадимнәре шәйләп алдылар. Мин дә аларны күрдем. Исәнләштек, бәйләгән яңагыма ишарәләп: «Доктор бик кирәк иде, үтереп сызлый, кайдалыгын белмисезме?» — дип сорадым. «Юк»,— диләр тегеләр, үзләре, куркынып, якъякларына каранәлар. Алар да мине таныган икән, чирек сәгать тә үтмәде, акгвардияче патруль ияртеп, әйләнеп тә килделәр... Аннан инде, юл туп-туры!.. Исән калсагыз, исемнәрен онытмагыз, патруль миңа аларның кемлеген белдерде: фельдшер Фурсов белән больница надзирателе Мокеев[1]. Ни сәбәптән алар мине дошманга тапшырды? Баксаң, гап-гади хезмәт кешеләре, совет властеннан зыян-зарар күргәннәре юк, эшләп ашаганнар. Хыянәтнең асылын да, сәбәбен дә аңлап бетерә торган түгел. Власть кешеләренә ярарга тырышалар дисәң, аннан Мокеевларга ни мәртәбә?! Көтелмәгән хәл хыянәткә этәрә дисәң, тагын юк...

— Хыянәтләрнең зурлыгы һәм төре күп,— дидем мин, Шейнкманны куәтләп,— һәр сатлыкҗан аңа үзе сайлаган юлдан урмәләп килә!

Йөнтәс яңаклы Павел Беренс, зәңгәр пыялалы күзлеген туктаусыз сөртә-сөртә, камерага аяк басканнан бирле ләм-мим сүз катмады, яңа кергән кешеләргә дә эндәшмәде, ул кая килеп эләккәнебезне, инде моннан котылып чыкмак юк икәнлеген аңлый иде булса кирәк, бер урында тик басып торды. Бәлки Шейнкманның «хыянәт» дигән куркыныч сүзенең асылына төшенергә теләгәндер? Аның сүзсезлегенең төбен аңлап бетереп җиткермәдек, аларны 9 августта, көн тәмам яктырып килгәндә, гауптвахта ишегалдына алып чыгып аттылар...

Иртән атачакларын кичтән үк белсәләр дә, алар күрер күзгә бер дә үзгәрмәделәр. Шейнкманның җилкәсе бераз бөкрәя төште дә, Беренс, күзлек пыялаларын сөртә-сөртә, кулъяулыгын юешләп бетерде. Шейнкманның ихтыяр көче бөркелеп торган йөзен гомергә онытасым юк. Башта ул улына хат язды, аннары пыяла кыйпылчыгы белән стенага шушы

[1] Фурсов С. К., 30 яшендә, Мокеев Г. Д., 54 яшендә, ревтрибунал карары белән 1918 елның 10 октябрендә атылдылар.

сүзләрне чокыды: «Мине тиздән атачаклар. Бәхил булыгыз! Улыма соңгы васыятем — әйбәт кеше бул!» Астарак кәкре-бөкре хәрефләр белән имзасын тырнагач, озак кына карап торды...

Атарга алып чыгар алдыннан Шейнкман тагын сүзчәнләнеп китте:

— Дошманның максаты һәм нияте көн кебек ачык: алар, тоташтан җан кыеп барып, эшчеләрне өркетергә, большевикларны каушатырга маташалар. Үзләре чамасыз нык курыкканга шулай кыланалар! Көче бар берәүдән дә курыкмый, бүтәннәрне куркыту исәбенә дә яшәми, яшәр өчен аңа үз көче, абруе, ышанычы җитә. Бу уңайдан Энгельсның Маркска язган сүзләрен белмисезме, Сергей Сергеевич?

— Хәтерләмим.

— Әле исемә төште: «Террор — күпчелек очракта куркаклар төркеме тарафыннан үтәлә торган шәфкатьсезлек, үзләрен тынычландыру максатыннан башкарыла торган эш»,— дигән ул.

Аларга соңгы сүз иреге бирделәр. Шейнкман язган хатын бердәнбер улына тапшыруларын үтенде. Аклар мыскыл итеп хатны аның күз алдында ук ерткалап таптадылар. Беренс тартырга сорады һәм ни өчендер зәңгәр пыялалы күзлеген чалбар кесәсенә тыкты. Пөхтәләп кульяулыгына төреп... Тартып бетергәч, Шейнкман тураеп:

— Атыгыз, җәлладлар, ерткычлар! Җан кыюдан башка эшегез дә юк сезнең! Әмма көннәрегез санаулы! — дип кычкырды.

Алар өчәү иде, һәм аларны хәзер бөтен гауптвахта белә. Яңа кергәннәргә иң әүвәл шул дәҗҗалларны сөйләп бирәләр. Җәзалау, ату йөкләнгән комендант ротасы командирларыннан өчәвесе — Мышкин, Попов һәм Иванов кансызлыклары белән ул көннәрдә дан казандылар. Аларның шәфкатьсезлегенә солдатлар да хәйран кала торган иде. Үлемгә хөкем ителгәннәрне җиргә салып таптау дисеңме, борын-колакларны кисеп алу, камерадан типкәләп алып чыгып өскә басып сикерү дисеңме,— берсе дә, берсе дә калмый иде. Студент Иванов миңа мактәпнең «яхшысын» әзерләгән!..

Алып чыгып, стенага териләр дә:

— Герман шпионнарына ут! — дип акыралар.

Көпшәләрдән ут бөркелеп чыгып, дөнья йөзенә яктылык, җылылык өстәргә килгән большевикларның гомеренә соңгы ноктаны куя, атылучыларның шпионнар түгеллеген хөкем чыгаручылар да, атучылар да бик шәп беләләр!

Камера ишеге шапылдап ябылырга да өлгерми, тавышсыз гына тагын ачыла, канга батырып, яңадан-яңа корбаннарны кертеп ыргыталар, алар күргән-белгәннәрен безгә сөйләп бетерергә дә өлгерми, ишек тагын ачыла, әлерәк кенә китергәннәрне атарга ук алып чыгып китәләр. Шәһәрдәге канлы вакыйгаларны ишеткәч, йөрәк ярсып тибә, кан суынып китә. Төн уртасында кергәннәрдән берәү Казан губерна юстиция комиссары — егерме өч яшьлек Мартин Межлаукның һәлакәтен хәбәр итсә, аның артыннан ук кергән иптәш өлкән профсоюз хезмәткәре Абрам Павлович Комлевның үлеме турында сөйләде...

Күз алдымнан күпме үлем, җәзалау үтеп торса да, мин һаман алдагы көннәр турында уйлыйм, иптәшләрнең, белгәннәремнең, белмәгәннәремнең язмышы турында сорашам, белешәм, бигрәк тә кулга алыну сәбәпләрен ачыкларга телим, кем сатканын, хыянәтчеләрнең кем булуын хәтеремә җыя барам...

Комлев квартирасына, юнкерлар ияртеп, поручик Антипин[2] килеп керә. Комлевны кулга алалар һәм кайчандыр без эшләгән Набоков йортына алып китәләр (нинди аяныч хәл — элек чека урнашкан йортта хәзер Комуч контрразведкасы!). Ишегалдына алып керүгә үк, Комлев-

[2] Антипин Г. А. 1922 елда Полтавада чекистлар тарафыннан кулга алынып, озак срокка төрмәдә утырырга Казанда хөкем ителә.

ны аталар, ул егыла, озата килгән хатыны врач эзләп таба. Антипин килеп җитеп, каты яраланган Комлевны атып үтерә.

Өч көннән соң безнең янга шактый кырыс кыяфәтле, аскы ирене салынкырак, киң калын иякле бер егетне кертеп ыргыттылар. Ул башкалар кебек идәндә ятмады, җилем туп сыман сикереп торды да конвойның үзеннән дә катырак сүгенергә кереште. Оста, тәмле итеп сүгә тегеләрне, тетмәләрен тетә, сокланырсың! Ертык изүеннән бакыр кал-кан кебек күкрәге, күкрәгендәге зәңгәр канатлы горур бөркете чәлдәеп күзгә кереп тора. Егет чирек сәгать чамасы урын таба алмыйча идән уртасында боргаланып, тилгән күзе белән берәм-берәм барыбызны капшап чыкты да минем яныма килеп кысылды, пышылдап кына:

— Сергей Сергеевич сез буласызмы? — дип сорады.

— Монда Сергейлар күп булыр,— дидем мин, шигәеп.

— Сез! — диде ул күңелле җиңеллек белән. Мин закондагы карак булырмын, атым Гитара. Мине бөтен Идел буе белә! Китергән кылычлыларга да: «Әгәр чиста якка, офицерлар арасына кертмәсәгез, кырык картагызга бозым җибәрәм, кырыкка җиткәнче кәкшәерсез!» — дип өркеттем. Берсе, картуз кигәч кенә буе метр ярымга җиткән селәгәй: «Беләбез, син — Гитара!» — дип тора... Ә сез чекист Сергей Сергеевич Фролов!

Күчеп утырып идем, камера шыплап тулган чак, «законлы карак» әллә кая түшәмгә текәлгән хәлдә һаман пышылдый:

— Гайнулла да белә мине! Бер ишегалдында яшибез. Сезгә шуны җиткерергә кушты: җавап алырга барганда ук качарга тырышыгыз! Барасы юлны сезнекеләр көн-төн күзәтә. Әгәр Набоков йортына алып барсалар, Песәй тыкрыгы башында җигүле ат торыр. Йорттан ычкыну сезнең эш, чыккач та тыкрык башына элдерегез!.. Кучерны танырсыз дип уйлыйм. Эх, үзем анда булсаммы?.. Я иртәгә, я берсекөнгә чакырмый калмаслар, диде Гайнулла. Ычкыну читен түгел, монда аларның рәтле тәртибе юк, эт баш, сыер аяк. Гайнулла шуны да әйтергә кушты.

— Ә сез?

— Һәй, миңа ни булсын? Яшен ташын кем күргән? Без, караклар, хәлдән килгән кадәр совет властен да йолыккаладык. Әзрәк тотарлар да чыгарып җибәрерләр. Гауптвахтага эләгер өчен, бер алтын сәгать әрәм китте, шул гына!..

Кыен хәлдә калганда, үзеңнең ялгыз түгеллегеңне белү көч өсти, билгесезлеккә әз генә ачык төс кушылганда да күңел күтәрелеп китә. Иртәгәгә, киләчәккә өмет белән карыйсың. Иртәгәнең язмышыңны хәл итеп куюы бар! Карак китергән хәбәр сискәндереп җибәрде, әйе, алар мине монда озак тотмаслар, качарга, качар өчен көчне сакларга кирәк. Мин онытылырга тырыштым, йокларга, хәл алырга кирәк иде. Үз-үземә: «Йокла... йокла! — дип боерам.— Алда сине көтелмәгән сынаулар көтә!»

Гәрчә ул, алтын сәгатен җәлләп, ярым сәгать ахылдаса да, каракның нинди юллар үтеп камерага эләгә алуын белә алмадым, аңысы бүгенгәчә караңгы билгесезлектә калды...

Зарыгып көткәнгәме, икенче көнне ишек ыграк дөбердәде, үткер ачкычлар тешкә тиеп шылтырады, ике култыгымнан эләктереп, авыр йозак белән җилкәмә төя-төя, мине тарантаска чыгарып утырттылар, янәшәмә ике конвой сеңде, чыбыркы чыжлады, һәм без җан-фәрманга юыртып киттек. Гоголь урамына, элек тә, хәзер дә атаклы Набоков йортына без бик тиз барып җиттек... Ольkеницкийны хәтерләдем... Без күпме көч сарыф итеп контрреволюция белән көрәшкән, йокысыз төннәр үткәргән, хәвефле таңнар каршылаган йортка хәзер мине читләр алып керәләр. Гаепләнүче сыйфатында! Күптән тимер рәшәткә артында дөмегәсе җаннар, революциянең явыз дошманнары, хыянәтчеләр хәзер бу йортта хуҗа!.. Без баш бирдек, иптәшләрне, шәһәрне саклап кала алмадык, җитмәсә, үзебез дә килеп каптык. Ваемсызлык, саксыз тәҗри-

бәсезлек аркасында, кубебезнең башына хыянәт житте... Алар бүген монда хужа икән, димәк, без житәрлек дәрәҗәдә көрәшмәгәнбез, кайдадыр йомшаклык, сүлпәнлек һәм җебегәнлек күрсәткәнбез. Григорий Шмулевич безне мактамас иде...

Керәбез. Җинүчеләргә дә, җиңелүчеләргә дә баш иеп ачыла торган шул ук ишек. Минем тәшвишле адымнарымны иртә-кичен ничә тапкыр санаган шул ук тимер баскыч араталары. Һәммәсе таныш, якын, алай да күңелем борчыла, тирә-ягымда нидер нык үзгәргәнен тоеп бәргәләнә. Баскычтан менә-менә аңладым: ис үзгәргән икән! Бөтен җирдә ят ис, тир исе, ияр каешы исе, ашыгу-кабалану исе. Лыбыр-лыбыр сөйләшеп, упыр-тупыр атлап, олы булырга тырышып, каршыма өч гимназист төшеп килә. Бала-чага, кулларына мылтык кергәч, балалар үзгәрә, өчесе дә бүре булып миңа карыйлар. Театр уйныйлармы, сызылып чыгып килгән мыеклары да корым белән генә буяп куйган кебек, юк, уйнамыйлар, болар кулына эләксәң, исемеңне дә сорап тормаслар...

Кайчандыр үзем эшләгән кабинетка төрткәләп керттеләр, мине анда ай-кояштай балкыган, чәчен бритва белән кырдырган якты башлы Иванов каршы алды. Башы озынча кабак кебек икән, нигә чәчен алдыргандыр, ахмаклыгы тагын да ачыграк күренә ләбаса хәзер... Мине кerткәндә, ул, аягүрә басып, нидер укый иде, баш кагып, миңа утырырга боерды да, арты белән борылып, тәрәзә аша урамга текәлде. Сизәм, уйный! Беләм, кылана! Аңлап бетермәгәнмен теге чакта мин бу адәм актыгын! Хаталарың белән очрашканда, үткәндәге ялгышыңны аңлаганда, йөрәк әрни, күңелсез, ирексездән куырылып, кечерәеп каласың...

— Рольләр алышынды, Сергей Сергеевич! Сезне үз катымда һәм шушы гүзәл сыйфатта күрүемә шат икәнемне яшереп тормыйм, аңлыйсыз. Тирән хөрмәт йөзеннән сезгә уйланырга вакытны мул бирдем! Берәүне дә алай озаклап иркәләмибез, ә сезгә бүләкнең зурысы эләкте — гомер! Хәзерге заманда бер көн бер чиләк алтынга алышынмый! — Ул нидер хәтерләп көлеп куйды.— Күз алдыгыздан шактый вакыйгалар үткәндер, ата большевик Шейнкманны да камерагызга минем боерык белән керттеләр. Шаярып утырырга вакыт юк, киек-җанвар эзенә төшкән сунарчы акны-караны күрми! Алга ыргыла, алга! Хәзер без җиң сызганып, изү чишеп тотындык, эзгә төштек! Язмыш җебен кулдан ычкындырмабыз, нәтиҗәдә бөтенегезне кырып бетерәчәкбез! Сез киләчәккә ышанасыз — ахмаклык! Тәрбия юлы белән кешеләрне иманга китереп була дип инанасыз — җүләрлек! Алай кәнфитләнеп утырырга акыллы кешеләргә ходай вакыт бирми. Кулдагы кылыч өскә күтәрелгән икән, ул кемнеңдер башын кыярга тиеш! Әйе, Шейнкманны кысып, әллә ниләр белеп булыр иде. Нигә?! Кирәкми! Без бүгенге көн кешеләре, безнең кулда козырь — сез бар.

— Зурлавыгыз өчен рәхмәт. Ә иртәгә? — дип сорадым мин.— Бөтенебезне кырып бетергәч, кем белән гомер итәрсез? Кем иген игәр, йортлар салыр, ниһаять, кем сезгә кабер казыр?

— Чүп-чар халыксыз яшәп булмас дисезме? — Ул биек аркалы урындыкка килеп утырды.— Русиядә катыннар житәрлек, хәттин ашкан! Тудырырлар. Статистика барын да белә диләр, аңа мөрәҗәгать итсәк, җир шарында татар белән еврей сан ягыннан кытайларны да ашып киткән!

— Иртәгә ни булыр? — дип кабатладым мин.— Сугыш бетәр, ышанам, ул безгә җиңү китерәчәк. Җирдә яңа буын туар һәм ул сезне каргап һәм каһәрләп кенә яд итәчәк. Каһәрләп, каргап кына! Бүгенге мәгънәсез мәхшәрдә, мәгънәсез җәһәннәмдә ирләрен, туганнарын, апа-сеңелләрен судсыз-нисез югалтканнар алдагы көннәрдә сезнең вәхшилекне онытырлар дисезме? «Тотрыклы демократик власть» вәгъдә итеп, илне канга йөздереп, иртәгәгә юл саласызмы?!

— Салсак ни?! Мин студент — юрист, «илдә тәртипне җәлладтан һәм руханилардан башка урнаштырып булмый», дип өйрәттеләр безне. Үтерәбез, кырабыз, без, эсерлар, террорны сәяси көрәш формасы дип кабул иттек һәм халыкны да шуңа күнектереп киләбез. Хәзер ул шулай уйлый!

— Килешәм, революцияләр законлы нигездә яралмый, чөнки революция яшәп килгән кануннарны кырып-себереп, җимереп туа! Иске законнарны яңасы алыштыра. Ә сез искене — без себереп түккәнне кире кайтарырга тырышасыз. Шул йомгаклаусыз көрәштә сез кем — җәлладмы, руханимы? Көчлеләргә сыенып, ярашып яши алырлык бөҗәкме әллә сез дисәм, сезне көчлеләр янына якын җибәрергә ярамый икән! Властьны алу — бер нәрсә, аңа хуҗа була белү авыррак.

Аның яңаклары тагын зәңгәрләнеп китте, ул үзе корырга маташкан кәмиттән ялыкты булса кирәк, чынлыгына кайтты, аяк тибеп:

— Җитәр,— дип кычкырды.— Җитәр!

— Менә хәзер мин сезне тулысынча аңлыйм.— Көлемсерәдем.

— Бәхәс чоры үтте. Сез җавап алганда, эшне коры тота идегез. Мине бер мәлгә үз шәкертегез дип уйлагыз... Идән астында күпме большевик калды? Чекистлардан шәһәрдә кемнәр бар? Сергей Сергеевич, кыланмагыз, сезне ялгызыгызны калдырмадылар! Очраклы рәвештә шәһәрдә тоткарландым дип, тәтен җибәреп маташмагыз. Барыбер ышанмыйм. Менә кәгазь, карандаш. Адресларны, исемнәрне, явкаларны, берсен дә калдырмагыз. Корал кайда саклана? Берсен дә калдырмагыз, урыннарны күрсәтегез. Максат... Максатыгыз ачык, аңа нинди юллар белән ирешүне планлаштырасыз? Кыскасы, ни уйлыйсыз, ни беләсез — һәммәсен теркәгез. Яшермим, гомерегезне саклап кала алмам, Россия алдында гаепләрегез чамасыз зур, мәгәр кыйнаулардан азат булырсыз. Ә бездә оста куллар җитәрлек, ыжгырып көтеп кенә торалар. Россия үзен Германиягә сатучылардан үч ала! Үч! Үч!

Нәкъ шул вакытта ишек ачылды (бусы да алдан килешенү беләнме?), кемдер, кул изәп, Ивановны чакырды. Ул өстәлдәге кәгазьләрне тартмасына сыпырып төшерде, бикләп алды, һәм мин кабинетта ялгызым калдым. Башымның арт чүмече сызларга тотынды...

Ул чыгып, ярты минут та үтмәде, күрше бүлмәдән бик яман акырган тавышлар ишетелә башлады. Бусы да спектакльме? Һәммәсе мине бөгәр, сындырыр өчен эшләнәме?! Спектакль икән, әйдә, без дә уйнап багыйк, чак кына көттем дә тәвәккәлләп ишеккә юнәлдем.

Ишек ачылуга күкрәгемә штыкның салкын, үткер очы килеп төртелде. Төртке-төртке сыткы битле сузан егет керфексез яшькелт күзләрен терәп:

— Кая? — дип җикеренде.

Әтәч тавышы, мөгаен, өлкән класста укучы гимназисттыр...

— Тышка чыгасым килә,— дидем мин һәм, штыкны бер якка аударып, коридор буйлап киттем. Беренче катка төшәргә һәм коридор аша узарга кирәк иде. Ул, штыгын минем калак сөягенә тидерә язып бер карыш та артта калмыйча ияреп барды. Туалетта чигәләремә салкын су тидереп алдым да чыктым, коридорның буш икәнен күз читем белән чамаладым, баягы аһ-зарлы илергән тавыш монда да ишетелеп төшеп җитә, контрразведчиклар хәзер шунда җыелган ахрысы, алар шулай, бергәләп җәзаларга яраталар, эш үземдә калды. Джиу-джитсу ысулы белән конвойның йокы артериясенә ныклап басуым булды, ул буш капчык кебек бөгелеп тә төште, аны, култык астыннан эләктереп, туалетка сөйрәп кертеп ыргыттым да, ваемсыз күренергә, кабаланмаска тырышып атлап, йорттан чыктым. Законлы карак хаклы булган, «җиңүчеләрнең» тәртибе юньләп урнашмаган икән, ишек катында кем беләндер күңелле гәпләшеп торган сакчы миңа әйләнеп тә карамады, үзе сөйләшә, үзе югарыга, тавыш ташкыны килгән якка кулын изәп күрсәтә.

Ул-бусыз гына урамга ук үтә алдым...

Өс-башын килештереп киенгән, ак алъяпкыч бәйләгән, түгәрәк бүреген каш өстенә батырып куйган, мыек-сакал ябыштырган Гайнулла кузлада көтеп утыра иде. Мин кабриолетка сикереп менгәч: «Ку әйдә!» — дип кычкырган кебек булган идем, соңыннан Гайнулла: «Син ул сүзләрне пышылдадың, Сергей Сергеевич!» — диде.

Песәй тыкрыгыннан Балык мәйданына төштек, олы урамны да ансыз-мөнсыз гына уттек, күперне чыктык һәм Кәҗә бистәсенә житкәч, Гайнулла юртып барган атны сулга, аулак тыкрыкка борды, без озакламый гел эшчеләр генә яши торган Алафузов бистәсенә барып кердек. Тәгәрмәч кыршаулары астыннан чәчрәп чыккан кара коймаклар выж да выж янымнан очып тордылар.

Шактый баргач, Гайнулла атны тыйды, ул арада сул яктагы капкадан нәкъ аның төсле үк киенгән кыска кара сакаллы бер агай чабып чыкты да Гайнулла урынына кузлага менеп утырды, без җәһәт кенә сикереп төшеп калдык. Кабриолет шылтырап үтеп китте, без ачык капкадан йортка, өйалдына кердек, кочаклаштык, шул чакта өй ишеге ачылды һәм аннан авыз читен яулык почмагы белән томалаган Сажидә апа, сөйкемле Сажидә Салиховна килеп чыкты. Без аларның танышларынамы, ерак кардәшләренәме килгәнбез икән...

— Яңалыкларым байтак, Сергей Сергеевич,— диде Гайнулла, зәңгәр чынаякка чәй ясый-ясый.— Кайсысыннан башлыйм? Яхшысыннанмы, әллә начарыннанмы?

— Яхшысыннан. Яхшылык тансык, шуларын сөйлә! Начары зиһенне тагын да чуалтып җибәрер дә, яхшысын бәяләрлек аек акыл, хәл калмас.

Сажидә Салиховна, тирән тәлинкәгә өеп, кайнар коймак кертте, шунда ук авызга су йөгерде, ашказаны сулкылдарга тотынды, баш иеп, аңа тирән рәхмәтемне белдердем, ул, сөенеч тулы ягымлы күзләре белән сөеп карый-карый, аяк очларына басып чыгып китте.

— Безнекеләр белән тотрыклы элемтә урнашып килә, Красная Горка тирәсендә урманда даими очрашу урынын оештырдык. Свияжскида безнең гаскәрләр чигенүдән туктап, оборонага күчкән. Хәбәрләр дөрес булса, анда акларның бер генералын үтергәннәр. Аклар Идел күперен ала алмадылар, аларның һөҗүме хәлсезләнеп туктады.

— Бусы бик яхшы! — дидем мин яктырып.

— Фәридә Свияжскида булып кайтты, Лацисны күргән.

— Димәк, ул исән?

— Исән генәме, безгә өеп эш җибәргән! Аңа ашыгыч рәвештә җавап әзерләргә кирәк булыр. Тагын шул: шәһәрдә аерым группалар кичәге көнгә кадәр корал ташламадылар. Себер трактында, артиллерия казармалары тирәсендә, әле атышлар бүген дә кызып-кызып китте. Анда Пальгуновның коммунистик отряд сугышчылары һәм Славен дивизиясенең калдыклары, атыша-атыша, Бисктау ягына чигенгәннәр. Безнекеләр военрук Авровның Казаннан китүен күреп калганнар. Кыскасы, шәһәр һаман бирешми, һаман көрәшә, сугыша! Гәрчә яңа хуҗалар халыкны тоташтан өркетәләр, яныйлар, куркыталар. Менә нинди дәһшәтле приказлар эләләр алар!

Гайнулла тәрәзә төбендәге гөл чүлмәкләре арасыннан бер саргылт кәгазь суырып алып миңа сузды.

«Идел буе фронтының Төньяк гаскәрләр группасы командующие капитан Степанов Казанны «хәрби хәлдә» дип игълан итә».

— Ә менә монысы «Комуч демократиясе»нең белдерүе.

Каян табып өлгергәндер боларны Гайнулла, егетнең җитезлеге бар, өлгер егет!

«Казан һәм тулаем Казан губернасы вакытлыча гына Самара шәһәренә урнашкан Учредительное собрание әгъзалары комитетына буйсына. Шәһәр һәм Земское идарәләренең соңгы сайланыш әгъзалары

агымдагы эшкә керешәләр. Барлык дәүләт һәм җәмәгать оешмалары Комучның аерым вәкаләтле Б. К. Фортунатов һәм В. М. Лебедевка буйсыналар».

Ахырдан өстәп куйганнар:

«Казанда һәм Казан губернасында совет власте мәңгегә бәреп төшерелде, большевиклар куылды. Курыкмагыз, ул бәдбәхетләрне кайда да юк итегез!»

— Менә шушы боерыкка таянып, алар шәһәрдә кемне күрсәләр, шуны суялар. Шәһәрдән китәргә өлгермәгән иптәшләрнең инде күбесе һәлак булды,— дип дәвам итте Гайнулла дулкынланып.— Смоленскиданмы, Курскиданмы эшчеләр отряды килгән булган. Без аларны белми дә калганбыз. Отряд комиссары аклар кулына эләккән. Аны ерткычларча бик озак газаплаганнар, тереләй җиргә күмгәннәр, казып чыгарганнар. «Нинди кызыл частьләр килде? Тагын киләләрме?» — дип сораганнар. Комиссар түзә алмаган: «Ике полк килде»,— дигән. «Өч полкы һәм нәфрәт полкы! Шуларны җиңә алсагыз, була, җиңмисез икән, сез хәшәрәтләргә көн юк! Кызылларны җиңә алмыйсыз!..» Атканнар батырны, исемен дә белә алмый калдык.

Газеталар белән гадәттән тыш мавыгып китүемне күргәч, Гайнулла бер мәлгә сүздән тыелды, куе ясалган кап-кайнар чәйне яңартып, чәшкәне кулым кырына ук этеп куйды.

Вакыйгаларның үзе шаһит булганнарына дөп-дөрес бәя бирә алырлык зирәк дустым каршымда утырганда, нигә мин, онытылып, газеталарга ябыштым соң?! Гайнулланың нинди хәбәрләр җиткерәсен дә, аларга ничегрәк йомгак ясыйсын да чамалый ала идем мин. Кулларына власть төшкәч, революция ясаган чын кешеләрне кырып бетерергә йөз тоткан ак ерткычларның канлы вәхшәтлеген күзаллау читен түгел! Газеталардан, стенага ябыштырылган ашыгыч боерыклардан мин бер генә нәрсә — контрреволюциянең эчтәлегендә яңалык эзләдем. Куркалар, кабаланалар, чәбәләнәләр. Шул хәлдә дә үзләренең очраклы һәм вакытлы булуларын халыктан ничек яшерә алдылар икән дә бик күпләрне кыска арада үз ягына ничек аудардылар икән? Әгәр безнекеләр күпләп-күпләп кырыла икән — димәк, аларны кемнәрдер, шушы шәһәр кешеләре тоттыра бит! Шулар сата! Ерткычлар кулына бер гаепсез татар эшчеләрен тотып бирә, Комлевны, Шейнкманны, башкаларны...

Мин, тетрәнеп, шушы сорауга җавап эзләдем...

Менә 2 нче номерлы приказ. Казанда яшәүче барлык офицерлар (барлык!) 7 августка Хәрби комиссариат бинасына җыелырга һәм «Халык армиясе» сафына язылырга тиешләр. «Офицерлар, килми калган очракларда, сугыш заманы законнары нигезендә каты җәзага тартылачак. Алардан хәрби инструкторлар һәм командирлар әзерләнәчәк».

Шулай булсын да ди!.. Офицерларны чакырулары табигый.

3 нче приказ да аңлашыла: «Казан Халык армиясенә ирекле язылу башлана. Рәхим итегез, кардәшләр!» Русча һәм татарча...

Бусы да ачык, яңа власть үз эшен армия ныгытудан башлый икән, димәк, ул яңа кан коюларга, яңа сугышка әзерләнә. Сугышның алда тагын да рәхимсезрәк җәеләчәгенә исәп тота.

Уйлардан, укудан тукталдым да текәлеп торган Гайнуллага карадым.

— Таня кайда, белмисезме?

— Белмим, Сергей Сергеевич.

— Белсәң, яшермә.

— Гафу ит, Сергей Сергеевич. Шәһәрдәге хәлне ачыкларга, сезне коткарырга кирәк иде. Ендаковның боерыгы шулай булды. Таняга күз җитмәде, вакыт та калмады. Син очрашу урынына килә алмагач, бардым, мәгәр аларның өе тирәсендә кеше-мазар күренмәде.

Арт чүмечем котырып сызларга кереште... Чыдар әмәл юк. Сызлау күкрәккә, йөрәк тирәсенә күчте. Аларга ни булды икән?.. Берәр яры китә алдылармы?..

— Әллә Сажидә апаны җибәреп кайтарабызмы? — диде Гайнулла.

Шулай уйлаштык. Сажидә Салиховнага аңлатып торасы юк, ул иске-москы киемнәрен киеп, ертык шәлен ябынып, шунда ук кыптырдап чыгып та китте.

— Зинһар, сак йөрегез, Сажидә Салиховна.

Ул чыгып китте, мин, комучларның сары кәгазьгә басылган кара боерыкларын йомарлап, дустыма карадым.

— Беләм. Шейнкман, Беренслар һәлак булды. Тагын кемнәр алар кулына төште?

— Күпләр. Иң аянычлысы — Мулланур Вахитов. Алабуга өязе советы рәисе, Сергей Гассар, эшче отрядның командирлары бертуган Егор һәм Константин Петряевлар, Казан хәрби округы командующие ярдәмчесе полковник Руанет, округ штабы начальнигы Родионов, большевик Саттаров, Кәримуллин һәм башка бик күпләр. «Җаваплы иптәшләрдән генә егермедән артык кеше алар кулында»,— диде Ендаков[3]. Төрмәләр шыгрым тулы.

— Кемне дә булса коткарып буламы?

— Тырышабыз, Сергей Сергеевич. Учредиловчылар контрразведкасына Николайны үткәрдек. Уңышлы гына сеңде шикелле. Аңа бик нык өметләнәбез. Мондый хәл булды әле, Сергей Сергеевич,— дип дәвам итте Гайнулла.— Җиденче августта мин сезне билгеләнгән урында көттем. Дошан кулына төшүегезне Николай белдерде. Югыйсә һаман-һаман көтеп тору авыр иде. Сезнең белән очрашканнан соң мин Посадский урамындагы квартирага элемтәчене каршыларга барырга тиеш идем. Киттем, элемтәчем юк! Соңрак әйләнеп киләм, һаман юк! Өченче мәртәбә барсам, шунда ята... Аркасына пычак кадаганнар. Башка җәрәхәте юк, әүмәкләшү эзләре беленми, пычак та юк — үтерүче үзе белән алып киткән. Йорт ишегалдыннан чыга башлаган идем, сизәм, артымнан күзәтеп киләләр. Барам, эз чуалтып карыйм, һаман артымнан калмый! Ольkеницкий биргән сабаклар, «подпольщикларны кисәтү»е кылт итеп исемә төште: «Кешене абайласаң — бара бир, ике тапкыр күзеңә чалынса — торып йөгер, өч тапкыр сизсәң — котылу юлын кара!» Һәм чаптым мин...

— Квартираны һәм очрашу вакытын кемнәр белә иде?

— Өчебез. Сез, мин һәм күрешергә килгән иптәш.

— Тагын кемнең белүе ихтимал? Берәрсе сине танып калмадымы?

— Баш ватам менә, очына чыга алган гына юк.

— Мин чүт кенә ял итим, Гайнулла. Бүген чыккан газеталарның һәммәсен табарга тырышыйк.

— Әзерләп куйдым, Сергей Сергеевич.

Гайнулланы кычкырып мактарга җыенган идем, күз тидерүдән курыктым. Хәзер ифрат сак булырга кирәк!

— Фәридә кайда?

— Ул шәһәрдә, Ендаковның элемтәчесе белән очрашырга тиеш.

Тәмле ис килеп торган йом-йомшак чуар мендәргә башымны куйдым, чалкан ятып, газеталарга йотылдым. «Вестник Комуча» газетасы, эсер, меньшевик басмалары...

Башымда бер генә сорау: ничек халыкны ышандыра алдылар алар, тиз арада ничек үзләренә иярттеләр? Үзем дә сизмичә йоклап киткәнмен. Әллә төш күрдем, әллә йокылы-уяулы укыштырып ятканмын, мин шәһәр уртасындагы театрда утырам икән дим...

Иске шәһәр театры бинасында, шәһәрнең абруйлы кешеләре катнашында, «җиңүчеләр»нең беренче тантаналы җыелышы бара. «Җиңүчеләр» кунакларны яңа власть вәкилләре белән таныштыралар, өннәреннән уянып чыккан шәһәрнең абруйлы гражданнары аларга тоташ мәдхия җырлый.

---

[3] Ендаков М. Е.— 1905 елдан большевик, подпольедагы чекистларның җитәкчесе, соңрак Казан губчекасының председатель урынбасары.

Самара уң эсерлары җитәкчесе Борис Фортунатов калкына.

— Канлы һәм авыр көрәштә максатыбыз ачык — без бөек Россиянең шан-шәүкәтен торгызырга телибез! Милли горурлыгыбызны кайтарырга омтылабыз. Без агымнар, партияләр, оешмалар арасындагы аерманы танымыйбыз, кем Россия мәнфәгатен үзенекеннән өстен куя ала — шул кеше безнең дус, туган. Андый кеше түгел икән, ул безнең кан дошманыбыз. Белегез, алда безне җилсез һава, тыныч көннәр сагынып тормый, безне канлы көрәш кырлары көтә. Чөнки газиз Россиябезнең һәлакәтендә без барыбыз да бердәй гаепле. Россияне сез тар-мар иттердегез, аны аякка бастыру да — сезнең бурыч!

Ул сөйләгәндә үк урынында сикергәләп утырган Владимир Лебедев атылып чыкты. Вакытлы хөкүмәт әгъзасы, Диңгез эшләре министрлыгында эшләр Идарәсе управляющие, атаклы кеше, уң эсер, Самара комучында член. Сүз түгел, ут чәчә.

— Большевикларны дәүләткә хыянәт иткән партия дип игълан итәбез. Сүземне нигезлим: хурлыклы Брест солыхына кем кул куйды? Большевиклар! Россияне кем сатты? Алар! Германиягә саттылар. Казан халкы безне искиткеч яхшы каршылады! Меньшевиклар да үзләрен әйбәт яктан күрсәттеләр. Әмма кисәтергә тиешмен: кем дә кем кызылларга ярдәм итәргә азаплана — атачакбыз! Тарихта моңарчы күрелмәгән хурлыкны тудырган большевиклар белән янәшә бастырып атачакбыз. Хәзер большевиклар Казан тирәсенә мөмкин булган барлык көчләрен тупларга азапланалар. Ә без, аларны тар-мар итеп, Мәскәүгә туры юлны ачачакбыз. Безгә башка юл юк. Без үзебезнең тугры союзникларыбызга һәм үз көчебезгә ышанабыз. Инглизләр, японнар, французлар, хәтта америкалылар да ярдәм итәчәк! Тик читләргә генә өметләнү — бөек Россия халкы өчен хурлык! Казанлылар фронт шәһәрендә яшәүләрен онытмасыннар, «Халык армиясе» сафларына бердәм язылсыннар! Безнең Армия — партиясез армия. Без каһәр суккан погоннарны йолкып аттык, честь бирүне бетердек, сафларыбыздагы һәр хәрби — кем булуына, дәрәҗәсенә карамастан, аена унбиш сум алачак. Казанда җиңгә ак тасма бәйләүгә чик куйдык, ак гвардия дә, ак армия дә түгел, без — Халык армиясе. Бер-беребезне олылап «гражданин» дип мөрәҗәгать итәбез. 1897-98 елларда туган ир-атларга гомуми мобилизация игълан итәм. Чех һәм серб гаскәрләре армый-талмый көрәшкәндә, ватандашларыбыз арасында «алма пеш, авызыма төш!» дип көтеп утыручы ахмаклар очраштыра әле! Аннары, хөрмәтле граждannar, армия ул — сәрмәя, акча. Сездән ихтыяри иганәләр күп керер дип ышанабыз.

Бүген Самарадан Комуч радиосы капитан Степановка, полковник Каппельга, поручик Швецка, майор Благотовичка Казанны алулары өчен зур рәхмәт белдерде. Мәгәр, хәтерегезгә төшерәм, сезнең вәкилләр Самарага килеп: «Һәй, Халык армиясе шәһәр тирәсендә күренсен генә, шәһәр шул минутта ук ипи-тоз күтәреп чыгачак!» — дип кат-кат сайраганнар иде, алай булып чыкмады, киресенчә, күңелдә «Казанны алып ук булыр микән?» дигән шик-шөбһә торды. АКШның генераль консулы Гаррис минем исемгә суккан телеграммасында, котлау сүзләренә өстәп, корбаннарның башка урыннарга караганда күбрәк булуын да искәрткән.

Казанны алу — Совет власте өчен үлемгә тиң удар булды. Без киләчәккә ышаныч белән карыйбыз һәм ике ай эчендә Мәскәүне азат итәчәкбез!

Казан һәм Свияжск митрополиты Иаков сүз ала.

— Изге Казан чиркәве канат астындагы оланнар! Сезгә, ходайга табынучы тугры колларыма юнәлтәм сүземне. Куркыныч бетмәгән, ул якында гына. Казаннан куылса да, дошман тәмам җиңелмәгән, ул, соңгы сулышына буылып, шәһәр диварларын шакый. Кулга корал тотарлык һәркем ходайның ышанычлы уллары тупланган Халык армия-

сенә язылсын. Икеләнмичә ходай кушкан көрәшкә чыгыгыз, изге поч-макларыбызны дәһриләрдән коткарыгыз. Шәһәребезне җимерүдән, бәндәләрне һәлакәттән саклап калыгыз.

Чехословак командиры Йозеф Швец сүз алгач, залда алкышлар яңгырады:

— Поручик идем, хәзер мин полковник. «Чехословаклар — Германиягә каршы чыгачак армиянең ышанычлы авангарды», — дидегез. «Иделдә тупланган союз армияләре составында рус социалистларын немец шпионнары — большевиклардан коткарырга булышыгыз!» — дип чакырдыгыз. Пензадан Самара, Сембер аркылы без Казанга килеп життек. Ни күрдек тә ни белдек? Учредительное собрание өчен чит ил гражданнары русларга караганда ныграк көрәшәләр. Шик төште безгә: әллә Россия өчен зарарга гына кан коябызмы? Халык үз мәнфәгатен белми икән, кем өчен тырышабыз соң без?! Ярый инде, бүген, тәүге мәртәбә сезнең якты чырайларыгызны күреп, хак юлдан баруыбызга инандым[4].

Казан меньшевиклары лидеры Рясенцев та ярсып аваз сала...

Казанны алуы өчен полковник дәрәҗәсе белән бүләкләнгән Александр Степанов та рәхәтләнеп мыркылдый...

Тагын да тәкәбберләнгән, борыны тагын да югарырак чөелгән Фортунатов йомгаклау сүзе белән чыга:

— Бүгенгә көнгә Самара, Уфа, Сембер, Оренбург губерналары, өлешчә Казан, Саратов, Пермь, һәм Вятка губерналары Комуч байрагы астында. Без бүген тантаналы рәвештә: «Капитализм яшәргә хаклы һәм тиеш!» — дип белдерәбез. Промышленность тулысынча капиталист кулында булыр. Авыл буржуазиясеннән башка безгә көн юк, без аларны да тулысынча яклыйбыз һәм аларның язмышын хәл итүне чабаталы хәерчеләр өере — комбедларга бирмәбез. Без гомумхалык властена йөз тотабыз һәм шуңа ирешәчәкбез! Хәзерендә власть түбәндәге гражданнар кулына тапшырыла:

Комучның шәһәрдә һәм губернадагы төп вәкиле Учредительное собрание әгъзасы Владимир Архангельский. Аның урынбасарлары: Учредительное собрание әгъзаларыннан Ильяс Алкин — татарлар арасында, Григорий Алюнов чувашлар арасында эш алып барачак. Административ идарә эшләре Вакытлы хөкүмәтнең Казандагы эмиссары Евгений Калининга йөкләнә. Азык-төлек ягы Михаил Пасковка тапшырыла. Шәһәрдә, советларны һәм большевикларны яклаучы газеталардан кала, бөтен басмаларга рөхсәт бирелә! Ә-ә, сул эсер басмалары да тыела! Чехословак корпусы белән генерал Шокоров, легионерларның Идел буе группасы белән Станислав Чечек, Комучның Халык армиясе белән Владимир Каппель (аңа 35 яшь!) командалык итәләр. Казан гарнизонының начальнигы итеп генерал-лейтенант В. Рычков, штаб начальнигы итеп генерал-майор Визирев билгеләнә һ. б. һ. б.

Ниһаять, Зензинов та халык каршысына чыгып баса. Трибунада ул — чуртан, йөзә дә, йота да белә! Уң эсерлар Үзәк комитеты члены. Чиннар, дәрәҗәләр өләшенгәндә базарга әйләнгән зал кинәт тынып кала.

— Үзгәрәсе нәрсә үзгәрми калмас, дигән борынгы римляннар. Хак әйткәннәр. Советларны бәреп төшереп, властька Комуч килде. Ике дөнья бәрелешенең — 1918 елның язында кабынган көрәшнең нәтиҗәсе һәммәгезнең күз алдында! Большевиклар оятсызларча куып тараткан Учредительное собрание бүген илгә хуҗа! Россия язмышы алар кулында! Без Комучны Самарадагы җирле власть итеп кенә түгел, ил башында торучы һәм торырлык ышанычлы Бөтенроссия органы дип таныйбыз. Виктор Чернов җитәкләгән уң эсерлар Үзәк комитеты Самарага күчеп килә. Бу факт турында уйланыгыз, иптәшләр. Учреди-

---

[4] Й. Швец, 1918 елның 25 октябрендә, үз полкы солдатлары буйсынудан баш тарткач, атылып үлде. Чиләбедә күмелгән.

тельное собрание рухы ил буйлап гизә, ныгый. Самарада Комуч урнашкан бина өстендә революциянең ал байрагы җилферди! Учредительное собраниенең 402 әгъзасыннан бүген безнең тарафка кырык сигезе җыйналды! Казан губернасыннан сайланган уникенең дүртесе безнең янда: өч чуваш эсеры — Алюнов, Васильев һәм Николаев, мөселман социалистларыннан Ильяс Алкин безнең сафта. Бүтәннәр кайсы якка авышырга белмичә икеләнебрәк торалар.

Урыннан Лебедев кычкыра:

— Мулланур Вахитовка уйлап-нитеп торасы юк! Ленин мандаты белән Казанга килгән большевик-комиссар килеп капты! Учредительное собраниегә хыянәте өчен без аның җанын алачакбыз! Аны исемлектән сызып ташлагыз. Үз ихтыяры белән булмаса да, ул монда!

Зензиновка бу хәбәр бик ошады:

— Бәс, алай икән, аны Учредительное собрание һәм Мөселман фракциясе хөкем итсен! Бу секция әгъзаларыннан Вәлидов, Терегулов һәм Туктаров та безнең белән. Хәзер миңа мәгълүм булган кадәресе шул: Казан тирәсенә Самара армиясенең иң ышанычлы көчләре тартыла. Армиядә 50—60 мең солдат исәпләнә, ләкин аларның 30 меңе генә коралланган[5]. Бу тарафта бөтен өмет сездә, казанлылар.

Лебедев тагын сикереп торды:

— Әгәр һәрберебез берәр кешене армиягә үгетли алса, кызылларны әллә кайчан Идел күпереннән куып җибәрә идек! Гражданин Зензинов дөрес уй йөртә: явыз дошманны Мәскәүдән куу өчен тәре походына чыгарга кирәк, ә акчасыз кая барасың? Бөтен нәрсә акчага терәлгән! Акча! Русның изге җирен дәҗҗаллардан әрчер өчен шул кирәк!

— Банктан халык кулына күчкән акчаның бөртегенә кадәр җыеп бетерик! — дип кычкырды уртадан кемдер.

Зензиновның сүзе бетмәгән икән, аның калкынуын күреп, Лебедев кабаланып, кычкырып сүзен тәмамлады:

— Безнең чакыруыбызның нәтиҗәсе бәрәкәтле булыр дип ышанам. Россиядә, шул җөмләдән Казанда да, элек-электән революцияне яклаган, алтындыр, акчадыр кертеп, уртак эшкә бик күп файда китергән изге җаннар бар иде, хәзер дә бардыр дип беләбез![6]

Зензинов аңа ялгап алып китте:

— Халык власте — Учредительное собрание кулында! Менә безнең иманыбыз. «Диктатура» идеясен, бер сыйныфның икенче сыйныф өстеннән идарә итүен без телебездән мәңгегә чыгарып ташлыйбыз. Без советлар тәмам тар-мар ителгәнче көрәшәчәкбез. Атаклы акыл иясе италияле Макиавелли әйткәндәй: «Котылгысыз икән — сугыш гаделә, аңа соңгы өмет баглана икән — хак сугыш!»

Ильяс Алкин да сүзсез калмады, кукраеп трибуна артына чыгып басты, залның тонык кына гөрләвен тыңлап торды...

— Хәтерегездәдер, быелның гыйнварында, Учредительное собраниенең беренче һәм азакгы утырышында, Мөселман социалистлар фракциясе исеменнән Әхмәтбәк Цаликов болай диде: «Бөек революциядән соңгы вакыт, Россия халыкларына туганлык һәм тынычлыкның яшел ботагын бүләк итәсе урынга, күпме җәбер-җәфа, тоташ янгыннар һәм кан ташкыны китерде». Милләтләрне сыйныфларга аергалап бербереснә каршы куюны бары тик Учредительное собрание генә туктата ала! Социалистларның мөселман фракциясе күп миллионлы мөселман хезмәт ияләрен бөек максатларны тормышка ашырырга маһир булган бердәнбер көч — Учредительное собрание тирәсенә тупланырга чакыра.

---

[5] «Халык армиясе» берчакта да 30 меңнән артып китми, күпчелеге кулаклар һәм элеккеге офицерлар иде.

[6] Казан купецлары «Халык армиясе» файдасына 2 миллион сум акча җыеп тапшыралар.

Һәм бүген без монда, милли таркаулыкка чик куеп, сарык көтүе кебек таралышкан халыкларны җылы канаты астына алган бөек Собрание исеменнән эш йөртәбез. Төрки-татар халкын берләштереп азатлыкка чыгару бары тик Идел-Урал штатларын төзегәч кенә хәл кылынырга мөмкин. Без яңа тормышка өндәүчеләр белән һаман бер сафта, Маркcның «Капитал»ына таянып түгел, коръән һәм шәригать кануннарына кайтып, гомумкешелек идеаллары өчен үз-үзен кызганмаучылар арасында! Сафларны тыгызлыйк, союзниклар белән иңне-иңгә терәп көрәшик!

Степанов, аны бүлдереп, урыныннан кычкыра: «Союзниклар төрле яктан кузгалды! Әлерәк кенә телеграмма китерделәр: японнар Читаны алган!»

Зал күтәрелеп кул чаба, төрле яктан «афәрин!», «браво!» дигән сүзләр яңгырый, әллә Алкинны мактыйлар, әллә Степанов хәбәрен шулай күтәрелеп хуплыйлар. Алкин исә һәммәсен үзенә кабул итә, бәхет диңгезендә җилкәнсез дә йөзә, күзләре, һаваланып, залны тел-гәлиләр...

— Мөселман фракциясе исеменнән белдерәм — без Вакытлы хөкүмәткә тугрылыклы! Теләкләребез тормышка ашсын өчен барыбызга да дәһшәтле көч булып дошманга каршы ташланырга кирәк! Без большевикларны җиңәчәкбез!

Уяндым да, авыр уйлар тозагында, аңыма килә алмыйча бәргәләнеп яттым. Газеталарда булган хәбәрләр театрда булып узган «тантаналы кичә»не чын итеп диярлек күз алдымнан йөгертеп үткәрде, уйланып, укып ятуым өнне төшкә илтеп ялгады. «Тантаналы кичә» дидем дә икеләнеп калдым, әйе, алар өчен «тантаналы», ә безнең өчен, Казан өчен, республика өчен шомлы очрашулар кичәсе иде бу, өрәкләр зираттан әйләнеп кайтып түргә үтәргә маташкан кичә иде...

Нигә боларны бөртекләп яздым соң әле? Яңа власть вәкилләре белән ни өчен шулай җитди рәвештә таныштырып чыктым?! Тарихи чынлыкка тугры булып каласым килде, чынбарлыкны, аяусыз, дәһшәтле чынбарлыкны күз алдыгызга тулаем китерергә тырыштым. Әйе, безгә каршы чыккан көчләрнең максаты уен-муен гына түгел иде, юк, Совет властенең язмышы ул чакта кыл өстендә торды! Нинди генә явыз көчләр берләшмәде безгә каршы! Кансыз, өметсезлектә соңгы чиккә җиткән кара көчләр! Уйнарга җыенмый иде алар, ил язмышын чынлап торып кирегә борырга маташалар иде. Максатлары бар, идеяләре, кешеләре — һәммәсе җитәрлек... Әгәр шулай булмаса, әз генә вакыт эчендә Казан халкының актив өлешен үз якларына аударып өлгерерләр идеме?! Белә идек, заманында Ленин безне бик белеп кисәтте: «Күне житкәч, буржуазия безгә каршы иң әшәке яла, ялганнарны эшкә җигәчәк. Аларның нәфрәте революциянең пролетариатка тугры хезмәт итүенең дәлиле булыр!»

Теге чакта ук, унҗиденче елда, полициянең ялланган провокаторы Ермоленко, уйдырма документка кул куеп, «германда әсирлектә чакта немец генштабының яшерен агенты булырга ризалаштым һәм шунда Ленинның да немец шпионы булуын ачыкладым»,— дип игълан итте. Моның чеп-чи ялган, уйдырма-сафсата икәнлеге көне-сәгате белән бе-ленде. Мәгәр яла, ялганнар моның белән генә чикләнмәде. 1918 елның мартында Германия белән ике арада Брест солыхына кул куелгннан соң: «Большевиклар беренче булып дөнья сугышында союзникларга хыянәт итте, немецларга сатылды!» — дип бөтен дөньяны сасытмадыларммы? Әле алда, алдагы көннәрдә Совет властенең асылы турында күпме гайбәт таратылыр? Димәк, ялаларга күнегергә, гайбәтчеләрне кичерергә ярамый, беркем аңа күнекмәсен, ялганчыларны, ялачыларны фаш итеп, ялган-ялага каршы да аяусыз көрәш алып барырга кирәк.

Әйтик, мин белгәннәрнең күпчелеге Казанның барлык халкына мәгълүм иде, алар да шушы ук боерыкларны укыдылар, шул ук газеталарны күз һәм күңелләре аша үткәрделәр, театрда яңгыраган купшы, ялган сүзләр бөтен кешегә мәгълүм! Яңа власть вәкилләре үзләренең актыккы планнарын яшереп, балга манып тормаганнар. «буржуазияне яклыйбыз»,— дигәннәр, «кулаклар да безгә таяна ала!» — дип өметләндергәннәр... Алар да: «Башка юл юк!» — диләр, үз юлларының бердәнбер һәм хак икәнлегенә ышандырырга тырышалар, армияләрен «халыкныкы» диләр, погоннарны ертып ыргыталар...

Һәм кемнәрдер йөзәрләп, меңәрләп аларга ышана...

Әллә моңарчы без эшне дөрес алып бармадыкмы? Дошман белән артык нәзакәтле кыланып, дошман ягына аварга әзерләр белән пассив булдыкмы? Кайда безнең ялгышлар?

Алдагы көрәшләргә яңа эшче-крестьяннарны да чакырыр өчен ялгышларыбызны тәгаенләргә, ялгышларны кабатламаска кирәк...

Күземне ныграк ачып карасам, өстәл янында кулларын иягенә терәп, Гайнулла утыра, бөдрә чәчләре, тирләп, маңгаена ябышкан, аз гына калынчарак иреннәре елмаялар, кулында зәңгәр чынаяк...

— Чәеңне яңартыйммы, Сергей Сергеевич?

— Булды, рәхмәт. Чәй качмас. Хәзер Казандагы хәлләр турында Лациска донесение әзерләргә кирәк булыр. Дошман белән арадашлык итүчеләрне ачыкларга, турыдан-туры хезмәт күрсәтүчеләрне кичекмәстән чекага белдерергә кирәк...

— Күпне белмәсәк тә, кулда нидер бар! Нидер бар икән, эш пешә дигән сүз! Сез югында донесениене ничек язарга белмичә аптырап йөри идем... Нәкъ шагыйребез Тукай әйткәнчә... «Тапдисәм мәүзуг, язарга аптырыйм: кай төшеннән мин моның, дим, ләктерим?»

Икәүләшеп тотынсак та, донесение язылмады, фактлар аз, бар булганнарын да бергә ялгау кыен иде, безгә тагын ике көн, ике төн тырышырга, Ендаков янына барып кайтырга, бар булган иптәшләрне күрергә, сорашырга туры килде...

Ниһаять, без эшкә тотындык...

«Шәхсән Лациска гына! Ашыгыч! Яшерен!

Шәһәрдә дошманның өч контрразведкасы эшли: Комучныкы Набоков йортына, элеккеге чека бинасына урнашкан. Чехларныкы аргы Үсиядә, «Грибоедов» пароходына урнашкан. Серблapныкы — крепостьта. Иң әшәке кыланганы — Комучныкы, аны капитан, уң эсер Калинин Евгений Павлович җитәкли. Вакытында Вакытлы хөкүмәтнең Казандагы эмиссары иде, шул сәбәпле җирле шартларны да, совет хезмәткәрләрен дә, большевикларны да танып белә. Хәтере яхшы, әзерлекле. Күптән түгел генә рәсми белдерү ясады:

«1. Большевикларны һәм сул эсерларны якын да китермичә Учредительное собраниегә сайлаулар үткәрергә. 2. Совет власте ялчыларын хөкемгә тарттыруны тизләтер өчен, Казандагы тикшерү төрмәсен ябарга, аның бар вазифаларын контрразведкага йөкләргә».

Кулга алынучыларның саны сәгатьләп арта тора, кулга алу хокукы контрразведкага гына түгел, һәр сербка, чехка, словакка, ак офицерга, хәтта урам комитетларына да бирелгән. Берәүнең күрсәтүе дә җитә. Кулга алынганнарны контрразведка ата. Офицерлардан Иванов, Мышкин, Попов аерата явызлык күрсәтәләр, атканга кадәр тоткыннарның авыз-борынын җимерәләр, колакларын йолкып чыгаралар... Бездә булган мәгълүматларга караганда, хәзерендә кулга алынып та, атылмаган иптәшләрдән Мулланур Вахитов, мәгариф хезмәткәрләре Александр Максимов, Михаил Жаков, журналист Петр Ионовлар бар. Кулга алынганнарның хәл-әхвәле ифрат авыр. Губернаның мәгариф комиссары партиясез Максимовка әтисенә хат язарга рөхсәт биргәннәр. Ул болай дип язган: «Тикшерүчедән, нигә безне хайван хәлендә тотасыз, дип сораган идем, ул елмаеп болай җавап бирде: «Революционер Кибальчичны белә-

сеңме? Күренекле кеше. Шуның уңае белән патшабыз галиҗәнабләре Александр III болай дигән: «Химик булса да асарга». Ә син химик та түгел әле! «Димәк, азатлыкка өметне өзәргә туры килә».

Тоткыннарның хәлен җиңеләйтергә тырышып карыйбыз, коткару, качу мөмкинлекләрен, бигрәк тә Мулланур Вахитовны качыру җаен эзлибез.

Николайны Комуч контрразведкасына «сендерү» уңышлы үтте.

Учредиловчылар белән кулга-кул тотынышып эшли башлаган хыянәтче совет хезмәткәрләре:

Строкин С. Ф.— дүртенче участокның милиция начальнигы.

Синявин Л. И.— элеккеге милиция хезмәткәре.

Элек кызылларда хезмәт итсәләр дә, аклар аядылар, хәзер алар Комуч контрразведкасында хезмәт итәләр, димәк, бездә чакта ук аклар ягына тырышып ятканнар.

Касаткин А. А.— Казан совет дивизиясенең 2 нче батарея командиры, подпоручик.

Яушев Ибраһим — Мөселман полкының рота командиры.

Леухин Н. Г.— банкның элекке хисапчысы, комучларга алтын тапшыруны башкарган кешеләрнең берсе, беренчесе.

Казан жандарм идарәсенең элеккеге полковнигы В. Кафаров, хезмәт комитеты швейцары В. Кочнов, «Рус халык союзы» әгъзасы М. Золотов совет хезмәткәрләрен эзәрлекләү, табу һәм сату белән шөгыльләнәләр. Элеккеге савинковчылардан К. Н. Ивановский һәм Б. И. Булаев-Горбунов Комуч контрразведкасы белән якыннан хезмәттәшлек кылалар. Савинковның һәм Ярославльдә, Рыбинскида тар-мар ителгән савинковчыларның Казанга килүе көтелә.

Генштаб Академиясенең 15 укытучысы генерал Андогский җитәкчелегендә тулысы белән Комучка хезмәткә күчтеләр.

Чехословак һәм серб офицерлары мәрхәмәтне белмиләр, бигрәк тә үз ватандашлары большевикларны кыралар, судсыз-нисез аталар, ялгыш бер сүз, ялгыш караш өчен күпме кешенең җанын алдылар.

Раславы әлегә кыен булса да, Казандагы серб батальоны командиры майор Благотовичның Антанта файдасына шпионлык итүе ачыклана төште.

Таһиров урамда чека писаре М. А. Щукинны күргән. Сез Казанда аңа эш йөкләгән идегезме? Кем файдасына эшли ул? Тиз үк хәбәр итегез».

Бара торгач, донесение шактый озын булып чыкты. Ендаковтан, башка иптәшләрдән алынган хәбәрләр дә сыйды. Язып бетергәч, Гайнулла нәни куен дәфтәрен әлерәк кенә коймак пешкән мичкә, күмерләр өстенә илтеп тыкты... Яна бирсен! Камерада утырганда, мин һәр утырган кешедән ничек камалуын, кем тарафыннан эләгүен, кулга алынуының сәбәбен, шикләнгән кешеләрен, һәммәсен җентекләп сораша барган идем, алар да ярап куйды.

— Кем илтеп кайта? — дип сорадым мин Гайнулладан.

— Иске Аракчинога кадәр Фәридә барыр. Анда элемтәче көтә, ул Красная Горкага кадәр илтәчәк. Иртәгә донесение Свияжскида булыр. Борчылмагыз, Сергей Сергеевич, иптәшләр ышанычлы. Тоташ фронт сызыгы юк, әлегә үтәргә була.

— Риза. Хәзер менә чәй эчеп юансак та була. Чәй эчкән арада төп мәсьәләгә күчик. Мулланур Вахитовка һәм башка иптәшләргә нинди ярдәм күрсәтә алабыз? Сүз арасында синең элемтәчене кем үтерүен онытып бетермик. Димәк, хыянәтче һаман безнең арада йөри! Берәүме ул, икәүме, әллә алар, күренмәс шөпшә оясы булып, безнең арада яшәп яталармы?.. Бер дә ошамады миңа аның үлеме! Пычакны да алып киткәннәр. Ни өчен? Безгә таныш пычак булгангамы?..

Таһиров, гадәтенчә, кызып сөйли генә башлаган иде, нык итеп ишек шакыдылар, без бер-беребезгә караштык. Чит кеше шакуы иде бу,

ят кеше. Безнең ят кеше белән бер дә очрашасы килми иде! Донесениене нишләтергә?.. Гайнулла миңа ым какты, үзе, чәй чынаякларын кызыл ашъяулык белән каплап, шакыган тавышка таба атлады. Мин чаршау белән бүленгән күрше бүлмәгә кердем. Гайнулла биреп калдырган наганның патроннарын барладым. Шаку тагын кабатланды.

Ачылган ишек шыгырдавына Гайнулланың соң дәрәҗәдә гаҗәпләнгән тавышы ялганды:

— Щука? Син мине ничек эзләп таптың?

— Урамда очраштык бит. Артыңнан килдем.

— Йомышың бармы?

— Бар.

— Ник аны урамда очрашканда ук әйтмәдең?

— Анда ярамый иде.

— Я, сөйлә.

— Миңа бик җәһәт рәвештә Сергей Сергеевич кирәк. Син аның кайдалыгын белергә тиеш.

— Ишетүемчә, аны кулга алганнар.

— Качкан! Хәзер бөтен контрразведка аның артыннан чаба булыр.

— Син дә шуларга ияреп эзләшергә чыктыңмы?

— Минем үз йомышым!

— Эшең ашыгыч икән, әйдә, янына алып барам!

— Чынлапмы?

— Мин уйнап сөйләшә белмим.

Тәнем буйлап кайнар дулкын йөгереп узды. Көч-хәл белән Комуч контрразведкасы кулыннан котылып ычкын да, тагын килеп кап! Рәхмәт Гайнуллага, ударны ул үзенә алды, мине коткарыр өчен шикле бәндәгә, Щукага ияреп чыгып китте! Алар ерагайдылар, тәрәзә янына килеп, башта ишегалдына күз салдым, аннан урамга карадым. Әлегә ул-бу күренми. Мин ишетсен өчен, Гайнулла юри кычкырып-кычкырып сөйләшә. Менә тавышлар да басылды. Димәк, хәзер алар бу йортны беләләр. Гайнулла булган җирдә мине табарга өметләнәчәкләр!

Ишегалдына чыгып, капкага башымны тыгуым булды, атлы патрульнең сызгыра-сызгыра җырлап килүе ишетелде:

> Все тучки, тучки понависали,
> Трещал наш пулемет...
> А красные отступали,
> Мы двигались вперед!

Патруль монда нишли? Беренче мәртәбә үтүеме? Белешергә иде, тик менә Гайнулла тиз генә кайтырмы?.. Кайта алырмы? Щука аны хәйләләп тәбегә төшермәсме? Ул югында Фәридә килеп житсә? Бу йорткурада калу минут саен куркынычрак була барса да, беренче нык каушау үтте, мин Фәридәне көтеп алырга карар иттем, өйгә кердем. Ары-бире каранып көткән арада урам тәрәзәсе турыннан хатын-кыз шәүләләре узды, һәм өйгә уйламаган, көтмәгән кеше — Таня килеп керде. Фәридә, елмаеп, бусага төбендә тукталып калды. Башта мин Таняны танымадым — өсте-башы әләм-сәләм, ул да миңа ятсынып карап тора, минем дә сакал житкән, чырай ямьсезләнгән, өс-баш таланган (сакалны Гайнулла кырдырмады!). Таня: «Сергей Сергеевич, Сережа»,— дип кочагыма атылгач кына үз күзләремә ышандым. Фәридә, Гайнулланың юклыгын абайлап, кинәт сүрәнләнде һәм җәһәт кенә өйалдына чыгып китте. Таняның кайнар күз яшьләре минем күлмәк якасын чылатты.

— Сездә ни хәлләр, Танюша?

— Эти авылда, Столбище ягында, туганнарга качты. Әни, йортжирне сагалап, өйдәрәк утыра.

— Борчымыйлармы?

— Кергән-чыккан кеше юк икән әлегә.

— Ничек монда киләсе иттең?

— Фәридә кереп алды. Ничек очраштык диген, бәхеткәдер инде, әнине сагынып, бер генә минутка кергән идем... Күршеләрнең бәрәңге базында утырабыз. Төнлә-төнлә генә чыгабыз. Гайнулла Фәридәгә: «Таняны караштыр!» — дип кушкан булган...

Эчем җылынып китте, «дустым, җан дустым!» дип күңелемнән рәхмәт укыдым.

— Сине исән-аман күрермен дип уйламаган идем, Сережа...

«Кайчандыр син миңа озын гомер юрадың!» дип әйтергә теләдем дә тыелдым, ваксыну булыр кебек тоелды, кинәт кенә:

— Сажидә Салиховна кайда? — дип сорадым.

— Өчәүләшеп йөрсәк, күзгә ташланырбыз, диде Фәридә. Сажидә Салиховна бераз арткарак калды.

— Эш тыгыз, Таня, һәр минут кадерле. Һәр адым санаулы.

— Кая да булса китәсеңме?

— Бүген кичен кайда буласымны кем белсен? Менә сине нишләтергә?

— Фәридәдән калмыйм,— диде Таня нык итеп.

— Ничек?

— Ул нишләсә, мин шуны эшлим. Кая җибәрсәгез, шунда барам.

Мин уйга калдым. Базда утырып, ни файда? Таняга да күңеленә ятышлы эш, хезмәт кирәк. Әгәр чынлап торып аны Фәридәгә иш итсәк? Икәү аларга җиңелрәк тә, күңеллерәк тә булыр... Донесение белән хәзер икесен озатам...

Фәридәгә озак сөйләп торасы юк, ул ярты сүздән эшнең асылын аңлады, Таня белән бергә барырга, дөнья танырга һәм эшкә өйрәтергә бик теләп риза булды. Сүз арасында гына: «Гайнулла кайда соң?» — дип сорады.

— Болай, кайтырга тиеш. Монда кайтмаса, безнең очрашу урыны билгеле... Шиксез, монда кайта алмаса, шунда килер...

Килерме? Килә алырмы? Бусын Фәридәгә ачыклап тормадым, хәлебезнең җитдилеген үзе дә бик яхшы аңлый...

Кызларны суык чәй, коймак белән сыйладым. Чәй эчкәндә, Таня мунчада булган хәлгә тагын бер кат әйләнеп кайтты.

— Хәзер дә акылым ирешми: юаш әти банктан чиләге белән алтын алып кайтсын инде... Котырткannar аны, Сергей Сергеевич, кеше сүзенә ышана торган беркатлы бәндә инде бичара...

Мин бәрхет якалы шома бәндәне күз алдыма китердем: очрыйнитә калса таныйм мин аны! Онытмадым, онытмам да!..

Кызларны озатырга чыкканда, урам буп-буш, анда-монда тавыклар кырлашып йөри, йөнтәс койрыгын юл пычрагына тидереп-сөйрәп шәлбер колаклы бер эт бара. Койма өстендә парлашып саесканнар утырган, димәк, тирә-як тыныч... Таня белән Фәридә тыкрык башында югалганчы, мин аларны күз белән озатып калдым. Фәридәгә артыгын сөйләргә кирәкми, ул белә, аңлый, Таняны аңа ышанып тапшырдым.

Сажидә Салиховнаны күреп киткәндә ярый иде дә, кәтәргә хәвефле. Теге этнең, Щукинның иснәнеп килеп җитүе яхшыга түгел, тыныч чакта китеп котылырга кирәк, шулай иттем, бәрәңге ызаннары аша ындыр түренә кадәр бардым да, Пороховой бистәсенә юл тоттым. Бәрәңге алынмаган, ел килеше әйбәт торганга сабагы котырып үскән, шикле кеше очрый калганда, качып калырга да мөмкин, төрле якка таралган ызаннардан теләсә кай якка үрмәләргә дә була.

Бәлки мин артык дәрәҗәдә шикчелгә әйләнгәнмендер? Гауптвахта аша узган корбаннар күз алдымнан бер минутка да китеп тормаганга, һәркемгә шигәеп, сагаеп карый башлаганмындыр? Бәлки Щукин да Лацис боерыгы буенча махсус задание үтәргә калган кешедер?! Тик нигә без белмибез бу хәлне? Лацисның без белмәгән яклары бармы? Гайнулла аны кая таба алып китте? Кем янына? Әллә Щукин Гайнулланы ияртте ме?..

Хәлләр бөтенләй көтелмәгән якка борылды...

Солдат кем ул? Асылда — кичәге эшче я крестьян. Эшчеләр арасында аз-маз көтепханәләргә йөреп, газет-китап караштырган, дус-иш арасында, курилкаларда забастовкалар, стачкалар турында сөйләшкәнне ишеткән хәбәрдар кешеләр очраштыра. Озын колактан гына булса да алар дөньяның тигезсезлеге, сыйнфый каршылыклар, бөек Француз революциясе турында да ишетеп калганнар. Крестьянга килгәндә — эш катлаулырак, ул гомере буе, тәртә арасына җигелгән арык алашасы кебек, җәен-кышын эштән бушамаган. Русы — поп ни әйтсә, шуңа табынып, татары — мөнбәреннән мулла ни сөйләсә, шуңа ышанып йөргәннәр. Юк, аңгыралыктан түгел, аларның һәммәсендә яшәү сәләте, дөньяны үзенчә танып-белү, зирәклек җитәрлек дәрәҗәдә булган. Мәгәр алар, табигать кануннарын белсәләр дә, җәмгыять законнарыннан шактый читтә торганнар. Иң артта калган, дөмеккән аңлы, изелгән, мыскылланган түбән катлауларны — эшче-крестьянны революция яңа юлга — аң юлына чыгарды. Гражданнар сугышы ук аларның аңын чарлады, зиһеннәрен ачты, уңны — сулдан, хакны ялганнан аерырга өйрәтте.

Алай да беркем дә ялгышлардан азат түгел!

Дөньяның кинәт борылышларын берәү дә алдан кисәтеп, адәм улларын маяклы юлга чыгарып куймый, андый борылышларны, фикере белән илне, тарихны аркылы-буйга гына түгел, алга, киләчәккә дә иңли ала торган юлбашчылар гына сизенгән. Ә гади халыкка борылышларда яшәү гаять кыен, авыр, четерекле. Борылыш ясап большевиклар чыга да: «Халык өчен көрәшәбез! Власть эшче-крестьяннарга!» — дип ышандыра. Инде тәмам ышанып беттек дигәндә генә офыкта аклар калка, комучлар, эсерлар, кадетлар, меньшевиклар! Һәммәсе шул ук сүзне сөйли: «Большевиклардан котылсак, җирдә оҗмах булачак!» Армияләрен «халыкныкы» дип атыйлар, күз күреп нәфрәтләнгән погоннарны каерып ташлыйлар, хезмәт хакы офицерга да, солдатка да тигез, честь бирүләр бетте, һәммәсе «гражданнар», «иптәшләр...» Кая карап сәҗдә кылырга да, кая карап чукынырга да белмәссең!

Хәзер сезнең кулга килеп эләгәчәк бүлек — вакыйгаларның аерата мөһим өлеше тупланган бүлек. Дөрес, анда мавыктыргыч мажаралар да, революцион кискен бәрелешләр дә, канлы көрәшләр дә юк. Бу бүлек тирән ялгышулар турында. Совет властен вакытлыча бәреп төшергәч, гади эшчеләр, крестьяннар гына алданмады, комучларның буш вәгъдәләренә бер алар гына ышанмады! Бик күп укыган, әзерлекле, революцияләр тарихын биш бармаклары кебек белгән акыл ияләре дә шушы утыз биш көн, утыз биш төн эчендә адашты. Кыскасы, сүз акыллы кешеләрнең ахмаклыгы, күзләренең тома сукырлыгы турында барачак. Моны искә төшереп узу бик кирәк, бик! Комуч Идел ярындагы йомшак ком өстендә генә кормады үз бинасын, Россия җирлегендә, һәр почмакта, һәр тарафта аңа таянырга тал, утырырга түр, ышанырга ачык күңелләр бар иде. Шуның белән көчле иде дошман, шул ягы белән куркыныч иде. Гәрчә, кая барсын томана крестьян? Кая карасын чак-чак укый-яза белгән яки бөтенләй белмәгән рус, татар, чуваш эшчеләре?.. Әле революция булганга ел да үтмәгән, әле җирдә унсигезенче елның августы гына...

Казан университеты профессоры могтәбәр Николай Николаевич Фирсов Малопроломный һәм университет урамнары чатындагы һәйбәт йортның иң затлы квартирасында яшәп ята иде. Бүген ул өйдә, кәефе гаҗәеп шәп, куе каймак ашап, затлы кофе эчеп, иртән хушланганнан соң, профессорның күңеле тагын да күтәрелеп китте, гәүдәсе җиңел, борын эченнән генә Глинканың «Сомнение»сен җырлап, ул язу өстәле тирәсендә очынып йөри. Төрлесе-төрле җиргә куелган кәгазьләрне барлый,

жыештыра, иелеп, бит саннарына күз төшерә. Шатлыгы өйгә сыймый, профессор тәрәзәләрне кин итеп ачып җибәрә, урамнан кергән ат тоягы тавышларын да ишетми, бөтен барлыгы, күнеле, зиһене белән китабына йотылган. Әллә кайчаннан әзерләнә башлаган китап тәмам! Әзер! Университет нәшриятында да китапны көтәләр. «Тарихи характеристикалар һәм эскизлар» дип атала китап. Исеме генә ни тора! Бу жыентыкка соңгы егерме биш елда профессор иҗат иткән иң яхшы хезмәтләр керeп, аның исемен фән дөньясында мәңгеләштерергә тиеш! Җыентык хәзерге буталыш һәм дәһшәт заманында адәм улларының гомере арзанаюын, кеше табигатендәге иң явыз сыйфатлар өстенлек итүен бәян итә. Фактлар җитәрлек, фикерләр нигезле... Ничек сөенмисең дә ничек куанмыйсың?!

Профессорның алдан күрүчәнлеген бүгенге хәлләр, Казандагы вакыйгалар тулысынча раслады! «Моннан бер ел элек кенә «Учредительное собрание һәммәсен үз урынына куяр!» — дип язган идем, — дип уйлады профессор тәмләп. — Менә, озак көттермәде, шул көн килде. Комуч вәкилләре Казанда хуҗа... Җирсез һәм аз җирле халык һәрдаим бер хакыйкатьне исендә тотсын: элеккеге социаль-экономик тәртип кался, җир, бигрәк тә урман-болыннарны бүлгән чакта тигезсезлек яшәтергә киң мөмкинлек сакланачак. Хөкүмәт һәр чакта да хөкүмәт булып кала бирәчәк, тарихи вакыйгаларның агышын дөрес чамалап, «өскә калыккан кешеләр һәм сыйныфлар» барыннан да бигрәк үзләренең җылы урынын кайгыртачак. Властьның ныклыгы капиталистларның — чит ил һәм үз капиталистларыбызның ярдәменнән чыгып билгеләнә...»

Могтәбәр тарихчы каләм сабы белән карындык төсле сары маңгаен кашып алды да яза башлады:

«Җирсез һәм аз җирле крестьян хуҗалыклары законлы өлешләрен алсыннар дисәк, алар Учредительное собраниегә үз хокукларын якларлык вәкилләр сайларга тиеш. Вәкилләр бердәм рәвештә Россиянең төп байлыгы — җир-суларны, урманнарны, казылма байлыкларны үзләштерергә маташучы комсызларга каршы чыксыннар».

Фирсов каләмен куеп, авыш аркалы йомшак көрсиенә ята төште, күзләрен кысып, татлы уйлар дәрьясында ага башлады: «Тарихны беләм, аңлыйм. XVII гасыр башында Россиядәге чуалышлар хакында күп яздым. Үзара талашлар илне зәгыйфьләндергән, чит мәмләкәтләр Россияне кисәкләргә турарга омтылганнар. Әмма Русь бирешмәгән! Наполеонның илгә басып керү тарихын мин җентекләп өйрәндем. Русь Наполеонны да куып чыгарган. Бу орыш Наполеон монархы бер илдә дә күрмәгән гадәттән тыш сугыш була! Ул бит бер тапкыр да җиңелми, ләкин ахырда тар-мар ителә. Французларның асылын җете күзе белән күзәтеп торган бөек полководец гаять тапкыр фикергә килгән: «Болар һәммәсе миннән башка да таркалачак!» Чыннан да, бөек армия, черек җеп белән теккән шикелле, сыпылып, таралып бетә. Анысы бар барысын, Кутузов галиҗәнаб Александр II нең: «Французларны җиңә алырсыңмы?» — дигән соравына картларча зирәклек белән: «Җиңә алмам, мәгәр хәйләләргә тырышырмын», — дип җавап биргән. Һәм аның акрын кыймылдавы, туктап торуы французларның башына җитәрлек хәйлә булып чыккан. Бәлки хәзерге чуалышлар да иләп кенә үз җаена төшәр? Акрын кыймылдау, ашыкмау файдалырактыр? Россия — тарихи традицияләргә бай ил, Россия үзгәрешләргә, яңарышка зур корбаннар биреп кенә ирешә. Мондый гыйфритне кузгату читен, бер кузгалса, туктатырмын димә! Русьта һәммәсе булып узган — боярлар Думасы, Земский Собор, Дәүләт Думасы, хәзер Учредительное собрание — иң демократик дәүләт формасы. Әллә каян советлар килеп чыкты да илдә парламентча идарә итү формасын юкка чыгарды, тоташ буталыш, чуалыш туды. Учредительное собрание вәкилләре властька килсә дә, илдә тынычлык юк, комучларга ияреп, чит ил кешеләре килеп тулды, алар сәяси карашлар өчен россияннарны кыралар, үтерәләр. Ямьсез дә, оят та»

Уйлары язгы ермак кебек төрле якка борылды профессорның, капма-каршы юнәлешләргә кереп китте, әмма асылда ул шат, тормышыннан бик канәгать һәм горур иде.

Фирсов ашыгып кына сәгатенә карап алды, кәҗә сакалын сыпыргалап, эчке зур тантана белән чирек гасырлык гомере киткән хезмәтенә тагын күз ташлады. «Кызып кына эшкә керешкәндә, бүленергә туры килә!» — дип мыгырданды ул. Университетның Гыйльми совет утырышына барырга вакыт. Калдырырга ярамый, гаять мөһим мәсьәлә карала — Гыйльми совет яңа власть вәкилләре белән очрашып, аларга үз мөнәсәбәтен белдерә. Тарихи көн, тарихи момент!

Күпне белгән, меңне белеп оныткан, гомереңең һәр борылышында: «Дөрес яшәдем! Дөрес бардым!» — дип инанган могтәбәр профессор татлы уйлар белән университетка ашыга. Үз мөнәсәбәтен белдерергә!..

Юридик факультетның беренче курс студенты В. И. Ленин катнашкан 1887 ел 4 декабрь сходкасы белән атаклы зал, 1905 нче елгы революцион митинглар белән атаклы зал, бөек Лобачевский үзенең дөньякүләм ачышын игълан иткән зал хәзер ниләр күрми?! Бүген шул зал, Гыйльми совет әгъзалары белән рәттән, узурпатор учредиловчы власть вәкилләрен, уң эсер һәм меньшевик оешмаларның кешеләрен кабул итә. Төрле сәяси агым вәкилләре аерым-аерым утрау булып төрле рәтләргә утырышканнар. Нигәдер тирән тынлык, килүчеләр шыпырт кына керәләр дә урыннарына сеңәләр...

Гыйльми совет утырышын университет ректоры вазифасын башкаручы профессор-физик Гольдгаммер ачып, беренче сүзне Комуч вәкиле Архангельскийга бирде.

— Әфәнделәр! Бөек Россия гражданнары! Совет изүеннән һәм көчләвеннән, большевиклар террорыннан мәңгегә котылуыгыз белән тәбриклим! Без сезгә кимсетелгән Учредительное собрание рухын яклар өчен килдек. Россия халкы сайлаган тулы хокуклы вәкилләр ил язмышын һәм аның сәяси асылын билгеләү алсын өчен кайттык. Хәзер каты сугыш бара, шик юк ки, без җиңәчәкбез, большевикларның вакытлы уңышларга гына ирешүе ихтимал. Әмма тулы өстенлек өчен безгә көчле, ныклы гаскәр кирәк. Аны булдыру, асрау бик күп чыгымнар таләп итә. Ярдәм итүегезне үтенәбез. Әфәнделәр! Без бик күп санлы оешмалардан ярдәм, теләктәшлек кабул иттек, байтаклары безгә булышырга әзер торуларын белдерәләр, вәгъдә бирәләр. Урта мәктәп укучылары союзы, врачлар, укытучылар союзы, медик-студентлар профсоюзы, укытучыларның ярдәмчеләре союзы, һәм башкалар, һәм башкалар, санитар отрядлар оештырачак, туклану пунктлары кырык кешелек күңеллеләр отряды җибәрәчәк, укытучылар үзләренең мул булмаган хезмәт хакларыннан безгә өлеш чыгарачак. Кызлар Югары курслары Халык армиясенә ярдәмгә санитар дружиналар төзи. Урта һәм түбән классларда укучыларның әти-әниләре советларның мәгариф өлкәсендә чыгарган барлык карарларын юкка чыгаруны таләп итәләр! Алар бигрәк тә мәктәпләрдә дин дәресләре бетерүгә каршы. Алар ачыктан-ачык сөйләшәләр, эшкә дә әзерләр. Менә сез ни уйлыйсыз, ил агалары? Сезне саф йөрәкле ватанпәрвәрләр, ватандарлар дип беләбез. Безнең өчен догада булуыгыз, матди һәм мәгънәви ярдәмегез өчен тагын бер мәртәбә тирән рәхмәт. Иллә мәгәр студентлар тоташтан Халык армиясенә язылсын өчен, сездән булышлык, хәер-фатиха кирәк.

Зал беразга тынып, сагаеп һәм уйланып калды, һәм, кирәк бит, уйламаганда, көтмәгәндә, урыныннан, җилләнеп, профессор Фирсов күтәрелде һәм, бик дулкынланган чакларындагы гадәтен ташлый алмыйча, кәҗә сакалын йолыккалады.

— Тарихта халык армияләре булып узган инде. Тарихтан мәгълүм, алла бәндәләре андый армияләргә, акчага, малга кызыгып түгел, ватан, халык азатлыгы хакына язылганнар. Армия тугры рухлы кешеләр-

дән оешкан. Француз революциясе вакытында да шулай булган. Минин һәм Пожарский армиясе дә шундый ватандарлардан тупланган. Бонапарт баскыннарын да халык үзе куган.

Рус халкының бүгенге бурычларына килгәндә, ул шәһәр вә авыл гражданнарының азатлыгын гына түгел, гасырлар буена дәвам иткән изелүдән дә котылуны мәңгегә беркетеп калырга тиеш! Бу изге, тиңдәшсез зур бурычны, славян кардәшләр ярдәмендә, көнләп түгел, сәгатьләп көчәя барган Халык армиясе чишәргә кереште дә инде. Бердәм һәм ирекле илне аякка бастырырга омтылган бөтен халык аны үзенеке дип таный!

(Җәяләр эчендә генә әйтеп үтик: нинди бөек сүзләр! «Халык армиясе» дип аталган канечкечләр төркеменә нинди зур ышаныч! Халыкның һәм кешелекнең мәңгелек теләкләрен тормышка ашырырга туган армия, янәсе!)

Әлбәттә, бар халык исеменнән сөйләргә профессор Фирсов кулында җитәрлек мәгълүматлар да, дәлилләр дә юк иде, әмма ул былтыр лыгырдап йөргән, китабына аерым почетлы бүлек булып кергән сүзләренең тормышка ашуын җаны-тәне белән теләп, күңелендәге бар хыялларының тормышчан булуын күреп калып куанырга омтыла иде...

Язгы су юл алса — туктатырмын димә!

Коры саламга очкын төшсә, ул шунда ук зур ялкынга әйләнә.

Кәҗә тәкәсе кай сукмакка кереп китсә, сарыклар да, мәэлдәп, аңа ияреләр. Фирсов сәнәк белән суга байтак язганнан соң, залдагы утрауларның берничәсеннән кул күтәрелде. Сүзне Дравертка бирделәр.

— Һәммәгез дә беләсез: фирка ягыннан мин эсер. 1905 елда, октябрьдә, университетның төп бинасы өстендәге тәре янына кызыл әләмне мин элдем. Хәзер «Халык армиясе» дип аталган бер көнлек газета чыгарырга тәкъдим кертәм. Шуны сатудан кергән файданы тулаем халык армиясе фондына күчерик. Хөрмәтле профессорларыбыздан Фирсов, Парфентьев, Бречкевич, Богородский һәм башкаларны шушы изге эшкә чакырам[7].

Хвостов та сүзсез кала алмый, мәгәр ул сак, юкка гына «койрык» дигән фамилия йөртми, аны болай да аңлап була, бүтәнчә дә...

— Эһем, эһем, хөрмәтле коллегалар... Минем төп эшем — тарих. Халык мәгарифен үзгәртергә кирәк дисез икән, биш куллап риза. Һәм бу эштә университет төп юнәлешне кулыннан ычкындырмас дип ышанам. Халык мәгарифен үзгәртергә дигәндә, демократик башлангычларның роле күтәрелгәндә, мин дә хезмәткә кушылырга риза...

Винокуров та университетта мәгълүм эсер, Казан шәһәр думасы президиумы әгъзасы, ертлач һәм дуамал кеше.

— Ниһаять, көн килде! Идел шәһәрләренең барчасында Казандагы кебек үк иң халыкчан идарә органнары төзелә. Бәхәсле мәсьәләләрне хәл итүдә большевиклардан кала барча төркемнәр һәм партияләр катнашачак. Һәр эш туганнарча килешү юлы белән алып барылачак. Крестьяннар, эшчеләр һәм интеллигенция вәкилләре бергә барганда гына без бар теләгебезгә ирешербез. Озакка сузылган сыйнфый көрәш тудырган каршылыкларны, аерымлыкларны, таркаулыкны ашыгыч рәвештә бетерергә кирәк. Бу уңайдан башкарасы эшләр санап бетергесез. Казанның байтак эшчеләре большевистик чир белән агуланган, алардан әлегә ни дә булса көтәргә ярамый. «Җир биләүчеләр кире кайта икән!»— дигән ялган хәбәр крестьяннарны өркетте, бездән ерагайтты. Бу — провокация! Без большевиклар белән көрәштә крестьян туганнарыбыз төп көч булыр дип өметләндек, ә алар, киребеткәннәр: «Сугыш дәвам итүен теләмибез, большевиклар белән сугышырга солдатлар бирмибез!»— дип сөрән салалар. Димәк, төп өмет хәзер интеллигентларда. Казан университеты көрәшләрнең байракчысы булыр!

---

[7] «Халык армиясе» дип аталган бер көнлек газета 1918 елның 21 августында чыга. Анда Н. Фирсов, Н. Парфентьев, М. Бречкевич, А. Богородскийларның мәкаләләре басыла. Редакторы П. Дравертт. Соңыннан алар хаталануларын таныйлар.

Күтәрелгән куллар сирәгәя, зал тына, ипләп кенә атлап, трибунага физика-математика факультеты деканы профессор Болотов күтәрелә. Энәдән-җептән генә киенгән, гәүдәсе төз, нык. Гадәттәге сүзсезлеген, вак-төяк ыгы-зыгыларга катнашырга яратмавын белгән Гыйльми совет, бераз гаҗәпсенеп, бераз сагаеп, йотылып, аның сүзен көтә. Болотов ашыкмый, кемнедер эзлиме, таныштан танымаслыкка әйләнгән коллегаларының күзен күрергә тырышамы, һаман дәшми, күзе белән рәтләрне сөзә, тикшерә.

— Мин механик. Төгәл һәм табигать фәннәр вәкиле. Тапкырлау җәдвәле теге яки бу хөкүмәтнеке генә түгел, ул бар халыкларныкы да! Уртак! Әйе, мин дә властька хезмәт итәргә әзер, хезмәт итми нишлисең, власть — көч ул. Әмма борынгылар әйтеп калдырган: Audiatur etaltera pars, ягъни карарга килердән әүвәл икенче якны тыңлау да гамәлгә керсен! Безне монда «большевиклар законга сыймыйлар!», «аларның мәете генә күзне иркәли!» дип ышандырырга тырышалар һәм аларны кырып бетерергә чакыралар... Кырылыш болай да житәрлек, шәһәрдәге хәлләрне тыңласаң, чәчең үрә торыр! Уйлашыйк, җәмәгать!

Комуч вәкилләре, кызарынып-бүртенеп, бер-берсенә караштылар. Гыйльми совет әгъзаларының да чырае агарды, профессор Фирсовны очкылык тотты, байтак башлар түбән иелде.

— Үлгәннәр дә безнең ватандашлар ич, әфәнделәр! Ничек ватандашларны рәттән кырып бармак кирәк?! Әгәр сез үзегезне «дөньяда иң-иң демократик хөкүмәт» дип исәплисез икән, нинди хокукка таянып, ватандашларны юк итәсез? Хәтерлим, сез, эсерлар, элек тә «герой һәм халык» дигән нәмәрсә турында сайраштыгыз, ә кылган гамәлләрегезне күргәч, мин болай фикер йөртәм: халык массаларының һәр кешесе сезнең мактаулы батырларыгыздан әхлакый мең өстен тора. Тәмам.

Урыннан ашыгып-кабаланып, профессор, врач-анатом Бушмакин калкына:

— Әфәнделәр, сүз артыкка киткәнче, түбәндәге резолюцияне кабул итәргә чакырам.

«Университетның Гыйльми советы, Учредительное собрание әгъзаларыннан төзелгән комитетны яңа хөкүмәт дип таный, аның тууын алкышлый. Без яңа хөкүмәт вәкилләрен барлык көчебезне, белем-байлыгыбызны, кирәк икән, җаныбызны да җәбер-җәфалардан интеккән газиз Ватаныбызны яңартуга бирербез дип ышандырабыз. Халык армиясе файдасына хәзер үк акча җыю игълан итела, теләгән кешеләр хәзер үк имзаларын сала алалар».

Гыйльми советның илле тугыз әгъзасыннан утыз бише шушы резолюцияне яклый, профессор Болотов тавыш бирүдән баш тарта...

— Таня, ә Таня!

Җәяү йөреп күнекмәгәнгә ботинкалары кыса башлагач, Таня, Фәридәгә аны-моны сиздермәскә тырышып, арткарак калып бара иде, чалыш атлавын, аксавын да күрмәсен! Фәридә чакыргач, ул адымнарын бермә-бер кызулатты, һәм алар икесе янәшә атладылар. Таня чак кына йомрырак, Фәридә буйга бераз аннан калкурак.

— Менә уйланып барам, Таня.

— Юл уйсыз булмый. Юл уйлата.

— Синең белән булгач рәхәтрәк,— диде сөенеп Фәридә.— Синең Аракчинода туганнарың яки белешләрең юкмы?

— Без анда кунабызмыни? — дип гаҗәпләнеп сорады Таня. Ул үзләрен алда ни көткәнен, эшнең ничек булачагын Фәридәдән сорарга базмый, аны борчу була дип исәпли иде.

— Кунмасак та, дөнья бит, төрле хәлнең чыгуы ихтимал.

— Юк шул, Фәридә. Без — мәскәүлеләр. Казанга күптән түгел генә килдек. Столбище ягында кемдер бар барын, ерак туганнар.

— Столбищеда аклар.

— Аракчинода да шулар инде!

— Безгә бик уяу булырга кирәк. Син — рус кызы. Аракчинода руслар. Әгәр ак патруль килеп чыгып бәйләнә башласа, иптәш кызыбызны эзләп барабыз, диярбез.

— Әгәр алар: «Кайда ул кеше? Кем?» — дип сорашсалар?

— Уенга ал да үкчәңне күтәр! «Белер идегез бугай, кыз кешенең адресын бирмим!» — диген. Өлгерлек сорала монда, Таня!

Байтак юлны сөйләшмичә диярлек үттеләр. Таня тагын арткарак калды. Фәриләнең борылып-борылып каравын күргәч, тагын кызулады. Сынатырга һич тә ярамый иде, беренче мәртәбә шундый эшкә алын да, ботинкаң кысып эшне бозсын, имеш. Ярамый! Сергей Сергеевич ни әйтер дә Гайнулла ни уйлар?..

Үсиядән Аракчинога хәтсез ара, алар шактый озак бардылар. Юлда сагаерлык хәлләр дә очраштыргалады. Түгәрәк бер күлне урап үтәләр иде, теге як ярга юрттырып өч кеше ат эчертергә төштеләр. Атларын сугарып үлән чемченергә җибәрделәр дә үзләре анадан-тума чишенеп ташлап, су керергә тотындылар. Ай-һайлап, су чәчрәтә-чәчрәтә керенделәр, ахылдап көлештеләр.

— Аклар,— диде шыпырт кына Фәридә.

— Алар,— диде агарынган Таня.

Котырып, уралышып беткән тал чыбыклары арасында кымшанмыйча утыра-утыра, кызларның аягы камашып бетте. Аклар киткәч тә, алар беравык куркып, калтыранып утырдылар.

— Иделгә төшәргә кирәк безгә,— диде Фәридә, чак-чак кузгалып.

Алар барып життек дигәндә, ярга көймә килеп туктады, аннан жилпәзә зонтиклар тотып, ак эшләпәләрендәге ефәк тасмаларны жилфердәтеп, купшы барышнялар төште. Җиңнәрен, чалбар балакларын сызганган егетләр аларга иңнәрен куеп тордылар. Егетләр кызлардан тиз генә аерыла аламы — тәтә-тәтә сөйләшеп, тагын шактый вакытны алдылар.

— Аклар,— дип ачыклады Фәридә.— Бүген алар гына шулай көлә ала!

— Алар,— дип килеште аның белән Таня.

Аракчино турына барып житкәндә, күз бәйләнә башлаган иде инде, көн тиз сүнде, көн болытлы, салынкы һәм ямьсез иде. Идел өсләп, кыйгачлап, әче жил исте, августның яман гадәте буларак, жиз иләктән вак яңгыр сибәләде, кызларны чылатты.

— Бусы яман,— диде Фәридә, күкрәкчәсенә кыстырган пакетны эчкәрәк яшереп.— Безнең кайтасы да бар ич әле!

— Берәрсенә керербез дә кунарбыз,— диде Таня, ваемсыз күренергә тырышып. Туктап-туктап ял итсәләр дә, ботинка кыскан аяк үтереп сызлый иде.

— Мондый чакта берәүгә дә керергә рөхсәт ителми.

«Яланаяк кайтырга туры килер»,— дип пошынды Таня.

— Без бүген кайтып житик инде, Таня. Башка эшләр булуы бар.

Иптәшенең шундый тәвәккәл, нык булуы Таняга көч бирде, алар, яр комын ишә-ишә, Идел яры буйлап өскә, Свияжск ягына атладылар. Элемтәче Аракчино турында, Иделдә, көймәдә көтәргә тиеш икән. «Хәзер барып житәбез!» — дип, Фәридә адымнарын ешайтты, инде ике тапкыр шулай диде, Таня, канатланып, аннан калмаска тырышты, яфракларына тоташ тут йөгергән караңгы таллыкка барып керделәр, борынга иртә шиңгән яфрак исе тулды, таллыктан соң киң булып Идел өсте ачылды. Фәридә көрсенеп куйды, монда беркем күренмәде, элемтәче дә, гадәттә ярга бәйләнеп торган яшькелт агач көймә дә юк иде. Идел бөе тыптын, ялкау дулкыннар гына әз-мәз чупырдаша, яфраклар сак кына шыбырдый, тынлык куркыныч дәрәҗәдә буш һәм күңелсез иде. Фәридәнең ашкынган күңеленнән уйлар бәргәләнеп үтте: «Ни булды? Тотып

аптыйлармы? Чирләдеме? Әллә соңга калуымы? Без дә, аклардан шүрләп, ничә урында ничаклы вакыт әрәм иттек. Ул да шулай кылә алмагандыр. Көтик.»

Таня сорашып тормады, моңарчы кыю гына килгән юлдашының боегып, сүрелеп калуыннан ул эшнең көтелмәгән якка авышуын чамалап өлгерде.

— Элек килгәннәрдә бер дә соңармый иде,— диде Фәридә, борчылуын яшерә алмыйча. Гәрчә Таняга борчылуны сиздермәскә кирәк иде... Таня исә әллә салкыннан, әллә юештән, әллә эшнең хәтәргә әйләнүеннән тагын дер-дер калтырый ук башлаган иде. Үч иткәндәй, янгыр шәбрәк ява башлады, һаман кара төс ала барган тал куаклары ныграк шыбырдады, кызлар бер-берсенә елышып, бер-берсенең татлы тән җылысыннан көч алып, бераз тыңланып тордылар. Шактый калын пакет Фәриданең күкрәген көйдерә иде.

— Нишлибез? — диде аптырап Таня. Үзе үк:— Әллә авылга менәбезме? — дип сорады.

Элемтәченең авылда, Красная Горкага чыккан очта торганын Фәридә хәтерли, мәгәр аңа: «Соң чиктә дә Елизар Ефимовның өенә бара күрмә! Инде бүтән әмәлең калмаса гына тәрәзәсен шакы!»— диелгән.

Гайнулла кат-кат кисәтте, Ендаков та: «Зинһар, бер-берегезне саклагыз!» — дип үтенгән иде...

Фәридәне элемтәченең үзеннән дә бигрәк көймәсенең юклыгы шомландырды, искереп беткән балыкчы көймәсенә кеше кызыгырлык түгел, төбендәге суын да хуҗасы юри түкми: «Сулы көймәгә утырырга куркалар!» — дип әйткәнен дә хәтерли Фәридә...

Монда төн үткәрергә ярамый, яктырганчы, Казанга кайтып өлгерәсе дә бар, җитмәсә юлдаш белән, Таняның кыеш-мыеш атлап килүе бая ук Фәридәне шикләндергән иде инде...

Бүтән чара калмады, кызлар, бер-берсенә орынып диярлек, юеш юл балчыгында тая-тая, авылга таба менделәр. Димәк, Красная Горка очында. Сирәк-мирәк кенә өйләрдә утлар яна, бик күп өйләр — әллә куркып, әллә болай гына — чепи күзләрен йомганнар, тимер юлга җитәрәк, суык нур коеп, алларыннан гына, уфылдап, паровоз үтте, машинист, корымлы тәрәзәсеннән башын тыгып, нидер кычкырды, аның ни әйткәнен Таняның бик ишетәсе килсә дә, берни дә аңлап булмады, кызлар тагын шомлы тынлыкка уралып калдылар. Тимер юл аркылы чыгып, озын авыл урамына кергәч, адымнарын тизләттеләр, ятьрәк барып җитәргә дә тизрәк бу куркыныч урыннан котылырга кирәк иде. Элемтәче югалганга, авыл да, аның тирә-ягы да кызларга ямьсез, күңелсез булып күренде. Ул да булмады, ат куган авазлар ишетелде, тыкрыктан, пычрак чәчә-чәчә, ике җайдак юртып килеп чыкты, кызлар исләренә килгәнче, атлылар алар янына туктадылар.

— Кая барасыз, чибәркәйләр! — диде калын тавыш.

«Аклар!»

— Безме? — дип сорады Фәридә, аз гына булса да вакытны сузарга теләп.— Иптәш кызыбыз янына.

— Каян киләсез?

— Каладан без, абзыкай. Анда куркыныч...

Калын тавышлының юлдашы атын каулап китә башлаган иде, әллә Фәриданең тавышыннан шикләнде, әллә сүзләре сагайтты, кире борылып килде.

— Шәһәрдә безнең дошманнарга гына куркыныч! — диде ул яшь һәм көр тавыш белән.

— Ашарга да юк,— дип еламсырады Фәридә.

— Тукта, Сысоев,— диде калын тавыш.— Иптәш кызыгыз кайда тора? Исеме кем? Кем кызы?

Фәридә ык-мык тора башлаганда Таня телгә килде һәм:

— Ушаков Терентий кызы! — дип әйтеп салды.

Якындагы йортның тәрәзәсе тавыш бирде, кемдер ут кабызмыйча гына аларның әңгәмәсен тыңлап тора икән:

— Ә-ә,— диде тәрәзә.— Красная Горка очыннан өченче йорт. Лиза янына киләсез алайса?

— Шуның янына, шуның! — диеште кызлар.

— Күренде, Лиза өйдә,— диде тавыш.— Дөрес барасыз.

Атлылар төпченеп тормадылар, борылып, юрттырып китеп тә бардылар. Олы гына балчык кисәге Таняның иңбашына килеп ябышты...

Кызлар, караңгыдан килеп, үзләрен коткарган мәрхәмәтле тавышка эчләреннән рәхмәт укый-укый, бераз бардылар да беренче очраган тыкрыктан урман ягына каерылдылар. Авыл белән урман арасы якын, аны йөгереп диярлек уздылар, куркулары элемтәче белән очрашасын да онытгырды, урманга кергәч кенә бераз тыннарын җыеп, буылып тордылар.

— Ә син Ушаков Терентийны юри әйттеңме? — дип сорады Фәридә.

— Юк.

— Аракчинода танышларым юк диден ич.

— Исемә төште! Әти берзаман балыкка барган иде, шуннан кайткач, «Аракчинода берәүләргә кердек, Ушаков Терентийларга, хатыны өреле уха белән сыйлады!» — дип сөйләгән иде.

— Молодец! — диде Фәридә, аны кочаклап.— Синнән чын чекистка чыга, онытылып беткәннәрне дә иң кирәк чакта, иң кискен мизгелдә уена китерә алгач, булдырасың!

— Ә син чекисткамы, Фәридә?

— Шулай булмыйча! — диде Фәридә бераз мактанып.

Гәрчә кызларның хәле бер дә мактанырлык, куанырлык түгел иде. Элемтәче югалды, Аракчино урамында аклар, патрульләр. Элемтәчене шулар тотып алганмы?.. Монда, урман ышыгында башта бераз җылырак кебек тоелса да, тора-бара кызларның тәнен суык ала башлады. Алар ничарадан-бичара Красная Горка ягына таба атладылар һәм, шактый юл үткәч, урман ешлыгында дөрләп янып утырган учакны күрделәр. Учак янында ниндидер шәүләләр йөри, кычкырып көлешәләр, гитара чирткән тавыш да ишетелеп калды.

— Чегәннәр! — диде Таня.

— Әйдә, шулар янына барабыз.

— Алар акларммы? — дип сорады Таня.

— Кем белгән аларны? Җылынмыйча ярамый, икебез дә чирләп егылсак, безнең егетләр рәхмәт әйтмәс!

Ялкыннарын төрле якка авыштырып янып утырган учакка курка-курка гына якынлаштылар, яктыга чыктылар, шул чакта ут тирәсендәге кешеләр төркеменнән дәү гәүдәле бер хатын аерылып алгарак чыкты, кулын маңгаена куеп бераз текәлеп торгач:

— Фәридә, бу синме? — дип эндәште.

Фәридә дә хатынны таныды, «каян минем исемне белә ул?»— дип аптырады... Әйе, бу — ул, чекага еш-еш кереп йөргәләгән, өч-дүрт тапкыр киңәшмәләрдә очрашкан атаклы Лариса Рейснер иде. Тик монда, җиде ят арасында, аңа кем дип эндәшергә, кем дип атарга, нишли ул монда карурманда, үзен кем дип таныта?

— Нишләп йөрисез монда? Рейснер Фәридәне култыклап алды да килгән сукмагы белән кире алып китте.— Эш беләнме?

— Без... Мин...— Фәридә югалып калды.

— Курыкма, чегәннәр сәясәткә катышмый. Рәхмәт аларга! Мин, аларга ияреп, монда кадәр килеп җитә алдым.

— Хәзер кая барасыз?

— Свияжскига. Казанга иремне эзләп барган идем. Ишеткәнең бардыр Федор Раскольниковны?

— Күреп тә беләм.

— Аклар эләктергән аны... Эзләдем, тапмадым... Гәүдәсен булса да ерткычлар кулыннан йолып алмакчы идем...

— Сез Свияжскига кайчан кайтасыз?

— Чәй эчәм дә кузгалам.

— Сез анда Мартин Яновичны күрәсездер?

— Туры шуның янына кайтам да!

Бусы бөтенләй көтелмәгән бәхет иде. Тик аңа ышаныргамы, юкмы. Бармы ышанырга хакы Фәриданең?..

Фәридәне төнге учак янында таныган хатын, чыннан да, Лариса Рейснер иде. Алар ире Федор Раскольников белән унсигезенче елның егерменче июлендә Казанга килеп төштеләр. Муравьевның хурлыклы хыянәтеннән соң Көнчыгыш фронтка башкомандующий итеп билгеләнгән Вацетис белән Федор Раскольников бер-берсен якыннан беләләр иде. Рейснер килеп төште дә Казанда чыга торган «Гражданская война» газетасында эшли башлады. Идел хәрби флотилиясенең разведка отрядында комиссар була. Чекага кереп йөргәләгәч, ул да Фәридәне күреп калгандыр, тик менә исемен каян хәтерли? Берәрсеннән сорашканмы? Ни өчен? Бусы гаҗәп тә, шикле дә иде...

Әмма ни кыласың, донесение ашыгыч. Фәридә, тәвәккәлләп, пакетны Рейснерга тапшырды, Лациска илтеп житкерүен үтенде. Кызлар учак янына кире кайтып күренеп тормадылар, аларга ашыгырга, мөмкин булган кадәр тизрәк иптәшләре янына кайтып житәргә кирәк иде. Болай да ут йотып көтеп торалардыр...

Хәл белән танышкач, Сергей Сергеевич кызларны мактап та куйды, «тапкырлыгыгыз өчен сөенәм!»,— дип кулларын кысты. Озакламый һәммәсе ачыкланды. Аракчинода кызларны көтеп торырга тиеш булган элемтәче Елизар Ефимовны кемдер акларга саткан, аны кулга алганнар һәм ул шул чуалчык көннәрдә бөтенләйгә эзсез югалды...

Кем акларга хәбәр житкерде? Кем ашады аның башын?

Бусы да безнең өчен билгесез иде...

Сажидә Салиховна үзен казанда кайнаган ярма бөртеге итеп сизә башлады: бер дә тик тора алмый! Моңарчы беркемнең күзенә туры карарга базмаган, телсез-тешсез диярлек яшәгән татар хатынының язмышы тәмам үзгәрде дә куйды...

Үзгәреш Мәскәүдән килгән егетнең фатирга керүеннән башланды бугай...

Әнисе дә юаш иде аның, кыз чагыннан Яңа бистә бикәләренең затлы керен юып, өен жыештырып яшәде Фатиха түти, Фәттах байда кучер булып йөрүче таза гәүдәле, сукса — тимер, басса, бакыр изә торган егеткә кияүгә чыкты. Әтисен Сажидә Салиховна белми дә диярлек, Кабан күлендә боз ныгыгач, ел да шаулап үтә торган «захват» сугышларының берсендә кемдер аның чигәсенә кургашынлы бияләй белән тондыра да, ул шуннан аңына килмичә, хатынын һәм ике кызын ятим калдырып, теге дөньяга китеп тә бара. Кызларның берсе озак яшәми, чәчәк зәхмәте сабыйны әтисе янына илтеп куя...

Сажидәләр Яңа бистәнең иң ярлы тыкрыгында, иң фәкыйрь, жиргә сеңә язган йортында өчле-тугызлы гомер иткәндә, герман сугышы чыгып, ирен фронтка алдылар да, ул шунда ятып калды, кайтмады. Озакламый ютәл чиреннән әнкәсе дә дөнья куйды. Элек тә юаш иде Сажидә, хәзер тома ятим дә калгач, бөтенләй аска инде, үзен-үзе, яшәгән бистәсен, күршеләрен, аз-маз санлы таныш-белешләрен яратмас булды. Шуның аркасында урыс ягына асрау булып ялланды, күчеп китүгә, өе жимерелеп, нигезе тузанга әйләнде. Яңа урында аны беркем белми, беркем аның үткәне белән кызыксынмый, хужалары аз сүзле, эштән гайрене белмәс саран һәм йокычан кешеләр иде.

Революция булды — Сажидә апаның исе китмәде.

Патшаны төшерделәр — жәлләп жылап та алды: «Патшасыз ничек яшәрбез дә ничек гомер итәрбез?»

Үтте, күз яшьләре кипте, патшасыз да яшәп була икән, аннан башка да тормыш алга кыймылдый, көннәр үтә, кемнәрдер кайдадыр сугышалар, кемдер кем өчендер кан түгә, җан бирә, Сәҗидә апаның сугышыр кешесе юк, ерак агай-энеләр белән елына бер дә очраша алмый, ул үз өендә шыпырт-басынкы рәвештә кайгысыз-ваемсыз гына яшәп азаплана иде. Яшәгән җире Гоголь урамында булып, яхшы, урыс ягында, шул урамында чека дигән нәмәрсә оешып, ерак кардәше Гайнулла Таһиров шунда хезмәт итәргә тотынгач, алар очраклы гына күрештеләр.

— Бәй, Сәҗидә апа, син дөньядамыни?

— Дөньядырмы, ләхеттерме, әлегә җан саклыйм,— диде апабыз кыюланып.

Гайнулла сирәк-мирәк кереп чыккалый, кабаланып керә дә капылтибел генә бер-ике чынаяк чәй йота, чәй арасына бер-ике сүз кыстырырга өлгерә...

Балалары булмады аның, нигезен ташлап күчеп китүенә баласызлыгы да сәбәпче иде, көнче күршеләр (һәйбәт егеткә чыккан иде тормышка!), таныш-белешләр аның корыган агачлыгына еш кына тупас ишарәләр ясыйлар, болай да җәрәхәтле күңеленә бу сүз бик авыр ишетелә торган иде.

Сергей Сергеевичны ул үз баласыдай яратты, карады, бакты, керен юды, юктан бар ясап ашарына юнәтте, ул кайтмыйча йокларга ятмады, иманлы авызы белән аңа саулык-сәламәтлек, иминлек теләде. Хәзер аның киләчәге якты булып күз алдына килә иде: Сережа өйләнер, йөргән кызы бар, бәбиләре булыр, бала багып, Сәҗидә аларда торыр, картлык көнендә бер кыерчык икмәген эшләп табар...

Дөнья үзгәрде дә куйды...

Акларның кем икәнен дә, кызылларның ни өчен кызыл булуын да Сәҗидә аңлап бетерми, ул бөтен нәрсәне үз фатирчысыннан чыгып кына бәяли ала иде. Сергей Сергеевич — кызыл, мөгаен кызыллар акларга караганда әйбәтрәктер... Сергей Сергеевич иң беренче көнне үк: «Сезнең этиегезнең исеме ничек?»— дип сорады. Әтисенең исеме?.. Онына да язган иде инде ул аны, бу ят кешегә ни нәрсәгә кирәк булды анысы тагын? «Салих»,— диде Сәҗидә читенсенеп кенә. «Мин сезне Сәҗидә Салиховна дип атап йөртермен»,— диде кунак... Шул көннән Сәҗидә үзендә нindidер үзгәреш сизде, бу үзгәрешне бөтен ишегалды, күршеләр күреп алды, алар да Сергей Сергеевичтан күрмәкче аны «Сәҗидә Салиховна» дип йөртә башладылар. Берәүләр мыскыллап әйтте, икенчеләре хөрмәт белән шулай эндәштеләр, Сәҗидә апа үзе моңа ифрат канәгать иде. Әллә кайчан, Кабан күленең зәңгәр бозында авызыннан-колагыннан шарлап кан агып яткан кешенең исеме, аны тудыручының исеме шушы Мәскәү урысы авызыннан олылап, хөрмәткә лаек булып яңгырады. Кабарган күркә күк йөргән бистә бикәләренең берәрсенә тәтедеме бу бәхет?..

Дөнья кинәт үзгәрде дә куйды.

Югыйсә рәхәткә чыгабыз, сугышлар бетәр, инде икмәк, керосин булыр дип, зур өметләр белән яши башлаганнар иде ләбаса!..

Сергей Сергеевич чыгып югалды, аны-моны кисәтергә дә өлгермәде. Сәҗидә Салиховнаның йорты да, күңеле дә бушап, сагышка тулышып калды. Хәзер аның күңел кыллары дөнья яңалыкларына үтә сизгерләнә ала иде. Шәһәрдә власть алышынды... Зур өермәдә үзен вак тузан бөртеге итеп санап өйрәнгән Сәҗидә Салиховнага да үзгәреш тиз килеп бәрелде. Әлек авыз эченнән генә мырылдап йөргән кайбер күршеләр әрләргә, үртәргә һәм ачыктан-ачык янарга керештеләр.

— Кая китте квартирантың? Банктан алтын талап качтымы немец шпионы?

— Илдән бәрәкәтне шулар качырып бетерде, сансызлар!

— Чәнчелде совет власте!

— Синең ишеләргә көн бетте.

Нишләп бетсен аның көне? Гомере буе эштән башы чыкмаган ятим карчыкның көнен кем бетерсен?.. Көн көтте Сәҗидә Салиховна Сергей Сергеевичны, төн көтте, курку-каушауны арттырып, фатирчысы кайтмады, шәһәрдә имеш-мимешләр ишәйде, базарга бәрәңгегә барырга чыккан Сәҗидә апа, урамда канга баткан мәетләрне күреп коты чыгып, кире чапты, «ач тамагым — тыныч колагым» дип, ике көн беркая чыкмады, кичкырынлатып, ишегалды аулак чакта аңа шыпырт кына Гайнулла килеп керде, Сергей Сергеевичны сорашты, «очрашырга тиеш идек тә!» дип уфылдап куйды. Сәҗидә Салиховна, дөнья хәбәрләренә кереп тормастан, күршеләреннән зарланды...

Шул төнне Сергей Сергеевичны эзләп, ак солдатлар килделәр, өйнең астын-өскә әйләндереп актардылар: «Кайтып күренсә, тор да безнең янга йөгер, без каршыда гына, Набоков йортында. Әгәр хәбәр итмәсәң, сул аягыңнан асып куярбыз!»— дип янадылар...

Алар чыгып киткәч, ни гаҗәп, Сәҗидә Салиховнага рәхәт булып калды. Бердән, фатирчысы исән икән, икенчедән, дөньяда Сәҗидә карчыкның да кирәге бар икән әле! Аңа да яныйлар, куркыталар, «асып куярбыз!» диләр...

Иртән ул базарга барган булып җыенып, култык астына иске кәрзин кыстырып чыгып китте дә өенә кайтмады. Качты, әйбер-караларын да алмады, «Чәнчелеп китсен, баш кыйбат, баш исән калсын!»— дип, бистәгә юл алды. «Андый-мондый куркыныч чыкса, шунда-шунда бар!» — дип, Гайнулла аңа онытылып беткән ерак туганнарының адресын биргән иде.

Шунда ул Сергей Сергеевичны да, Гайнулланы да, үтә мөлаем, озын кара толымнарын салындырган Фәридә исемле кызны да очратты...

«Таняны эзләп кайтмассыңмы?»— дип үтенгәч, ул сөенеченнән нишләргә белмәде, аның рәнҗегән күңеленә хәзер эш кирәк, ике кулына бер юаныч — шөгыль хаҗәт иде...

Аңа эш кимеде, Таняны Фәридә барып алган булып чыкты, алар башта өчәү бергә кайттылар да, Бишбалтаның таралып утырган иске-москы йортлары, черек кара бүрәнәләре кыйшайган бараклар арасына кергәч аерылыштылар, «өер булып йөрмик», диде Фәридә. Сәҗидә Салиховна уенча, Фәридә — барын да белә торган акыллы кыз. Шунда бер баракның ишегалдына кереп чак кына хәл җыйды Сәҗидә Салиховна. Кер эләргә чыккан юан балтырлы, чиләк-чиләк имиләрен асылындырган сипкелле битле марҗа белән дә сөйләшеп алды, парлашып дөньяның авырлыгыннан зарландылар. Барак тәрәзәсенә эчтән сарылып биш-алты бала карап тора иде...

«Балалы кешегә дә кыен инде!»— диде ул үз-үзен чак кына тынычландырырга теләп...

Сергей Сергеевичны калдырып чыккан йорт янына якынлашкан саен аның күңеленә шик ныграк иңде. Урам да ничектер сәер иде, буп-буш, ишегалдында да үле тынлык. Баягы капкага ике-өч йорт кала ул тукталды да ябалдашы белән ярты урамны каплап торган муртайган кәүсәле тирәк ышыгына килеп басты. Йорт хуҗалары өйдә юк та юк, ирле-хатынлы икесе дә пороховойда эшлиләр, кичке караңгысыз кайтмыйлар... Капка шар ачык. Йөрәге кинәт ярсып тибә башлады, тезелеп торган дүрт тирәкнең иң аргысында посып торган кешене шәйләде. Шикле кеше иде бу. Урамның аргы башыннан кабык арбага утырган берәү юрттырып килде дә, теге кеше поскан тирәк турына җиткәч, арбасыннан сикереп төшеп камыт бауларын рәтләгән булды. Посып торган кеше аңа карап башын чайкады...

— Юкмы?— дип сорады атлы.

— Күренмиләр,— диде тегесе... Тирәкне юкка гына тирәп тормый ул!

Атлы тагын нидер эндәште, Сәҗидә Салиховна ишетә алмады, тез буыннарының егәре китте, ул инде Сергей Сергеевич белән Гай-

нулла эләккәннәр икән дип кайгырды, бәлки кызлар да аклар кулына килеп капкандыр, я ходай, ниләр күрәселәре бар икән ару балаларның әле бу болганчык заманда?.. Аңа да бу йортка кайтып күренергә ярамый иде хәзер. Өтермәнгә илтеп тыгарлар да, башыңны юк итәрләр.

Ничек Гайнулланы кисәтергә, ничек хәбәр итәргә?

Бусын Сәҗидә белми иде. Ул бераз иңке-миңке барды да, тәрәзәләре аркылы такта белән кадакланган өйнең җил капкасын каерып ачып кереп, ишегалдында озак кына тыңланып торды. Җил чыгып вак яңгыр шәбәртергә тотынды. Ул ишекне тартып карады, ишек ачык иде. «Әллә шунда кереп кунаргамы?»— дип изаланды аның күңеле.

Ин читене — аның кунар урыны да, кагар ишеге дә калмаган иде. Монда, ят җирдә йокларга курыкты, җен-мазар булуы бар, төнлә берәрсе кайтып керсә, кая барыр тишегеңне тапмассың!

Кая барырга?

Шунда ул бик еракта яшәгән бер кешене, элегрәк елларны йомыш-югла әнисе кереп йөргән кешеләрне, Ботан бакчасы тирәсендә җәен уздыручы Фатих Әмирханны хәтеренә төшерде. Менә аларда тынычтыр, мөгаен! Матавык заманда, төн уртасында килеп чыгуны яратып бетермәсә дә, куып чыгармаслар, шуларга барырга кирәк. Яулыгын кысыбрак бәйләп, Сәҗидә Салиховна Бишбалтадан Ботан бакчасы ягына барырга чыкты, вокзал тирәсенә барып җиткәч туктады, «ары җибәрмиләр, урам чатларында гаскәр тора» дигәч, вокзалга керде, шунда почмакта чүмәшеп интегеп төнен уздырды, Әмирханнарга иртәнге чәйдән соң гына барып әлгәште.

Язучы, күренекле тәнкыйтьче, философ Фатих Әмирхан аяклары сау түгелгә әллә ни чыгып йөри алмый, күбрәк вакытын өйдә, өстәле тирәсендә я язып, я газеталар укып үткәрә. Бу хәвефле җәйне ул Ботан бакчасы якынында дачада, аргы Архангельск урамында уздырды. Байтак еллардан бирле ул җәйләрен Казаннан читкә ерак чыгып йөрми шунда, Трофим Иванович Литовченко йортына күчеп килә. Хуҗа ачык йөзле, игътибарлы һәм бәяне дә артык зур каермый торган иплe кеше.

Бүген иртәдән бирле Әмирханның кәефе кырку иде. Моның сәбәпләре, уйлый башласаң, шактыйдан булып, иң зурысы — бүгенге дөнья хәлләренә үзенең шәхси мөнәсәбәтен ачыклап бетерә алмау иде. Беренчедән, Әмирхан янына килеп китүчеләр күзгә күренеп кимеде, танышлар бер ара каядыр югалып-сеңеп беттеләр, кайчаннан тере кеше күргән юк, дөньяны фикердәшләр аша, алар белән бергәләп танып яшәргә күнеккән кеше, ялгызлыкны авыр кичерә. Үзенең көчсезлегенә гарьләнә, эченнән сабыр гына сүгенә дә иде. Очраклы адәмнәр, үткән-сүткән күршеләр килеп түгеп киткән хәбәрләргә ышану кыен, алар сару кайнатып ачуны кабарталар, күпчелек бер-берсенә капма-каршы сөйли, кемгә ни ошый төшә, ул шуны алга чыгарып, дөреслек итеп күрсәтергә җыена, һәркем үз ягына каера.

Әмирхан көндезләрен Трофим Ивановичны газеталар артыннан йөгертә, «Күзеңә ни күренсә, барын да алып кайт!»— дип үтенә. Әмма бүгенге газеталардан да хаклыкны аңлау, дөреслекне эзләп табу һич мөмкин булмаган өметсез эш иде!

Инде бүген берәрсе килеп чыкмасмы дип сызланып көтсә дә, юк, беркемнең күренгәне юк, әлерәк кенә газеталардан укып белгән чуалчык хәбәрләрне уртага салып сөйләшерлек җан иясен табармын димә...

Әй газеталар! Шайтан алгыры, ни генә язып тутырмыйлар, укый башласаң — колагың үрә торырлык!

Менә «Волжская-Камская речь» ниләр лыкылдый! «Большевиклар тираниясен байтак шәһәрләрдә алыштырып, Учредительное собрание әгъзалары йөзендә Дәүләт власте без алга куйган фикерләрне үз байрагы итеп күтәрде: бердәм Россияне өр-яңадан торгызу, дәүләт офы-

гын киң җәйгән нык, милли һәм партиясез власть! Ил язмышы турында сүз барганда, сыйнфый һәм сәяси көрәшсезлекне бүгенгә бер читтә калдырыйк!»

Укып чыкканчы кырык кат абынасың, валлаһи! «Бүгенгә калдырып торыйк!», ярый, ә иртәгә? Хәл ителмәгән бу мәсьәләләр иртәгә калкып чыгар да ни белән тәмамланыр? «Хәзергә калдырып торыйк», ә партиясез китапханәче Закир Сәетзадәне үтереп ташлаганнар! Фәкыйрьләрнең яшәү шартларын яхшырту комиссиясенең әгъзасы гына иде югыйсә! Даулы җан түгел, сабыр холыклы күркәм кеше иде. Бер Закирның гына җанын кыйдылармы?.. Бу хәлне ничек аңлатасыз, «сыйнфый көрәшсезлекне» онытырга өндәгән әфәнделәр?

Меньшевикларның «Рабочее дело»сы исә теленә ни килсә, шул сафсатаны чәчә! Имеш, Совет хөкүмәте Кронштадтка күчкән, имеш, Мәскәү урамнарында русча сөйләшкән кызылгвардеецларны сирәк очратасың, күбесе авызын йомып йөри, сөйләшкәннәре немецча пупылдыйлар. Сала мужиклары кайчан немецча өйрәнеп өлгергәннәр әле?! Кем ышансын мондый уйдырмаларга?.. Ә язалар, бастырып тараталар, кемдер, ахмак баш, ышанып та куярга мөмкиндер? Ахмакларга исәп тоталармы?

Мулланур Вахитов белән остазы Сергей Гассар язмышы бу көннәрдә Фатих Әмирханның йөрәгенә утлы ук булып кадалды. Теге чакта, 1905 нче елны, гимназиягә имтиханнар бирергә әзерләгәндә, сөйкемле Гассар университет студенты гына иде әле... Фатихның да сәламәт чагы иде. Уртак сүзләр күпме иде, уртак уйлар, уртак өметләр. «Бишенче елны без уяндык таң белән!» дип җырлаган иде Тукай, ул канатлы елларны хәтерләп... Хәзер, әнә, большевик Гассар тагын төрмәдә, бөтен урам чатларында «ирек», «демократия!» дип лаф оручылар аңа үлем әзерли![8]

Телдә һәммәсе дә юмарт, Идел буе халыкларына милли-мәдәни автономия вәгъдә итәләр, үз телләрендә сөйләшергә, мәгариф һәм мәдәният үсеше белән җитәкчелек итәргә рөхсәт бирәләр...

Сүздә җиңел, ә эштә нәрсә булачак? «Татарларның үзбилгеләнеше ничегрәк соң?» дигән сорауга, җитдиләрнең җитдие булган мәсьәләгә, эсерлар икеле-микеле мыгырдыйлар: «Җир һәм сәяси автономияягын бары тик Учредительное собрание гына хәл итәчәк, янәсе». Ә итмәсә? Булачакмы ул, юкмы,— беркем дә кистереп әйтә алмый. Юлының дәвамы кая икәнен белмәгән хәлдә халыкны шул юлга өндәп буламыни?

Вахитов һәм башка большевиклар өндәгән «Татар-башкорт республикасы» яхшыракмы, әллә Алкин, Шәрәфләр һәм аларның тарафдарлары яклаган, бары тик дин берлегенә таянып барлык мөселманнарны берләштергән «Идел-Урал штаты» гына шәбрәк булырмы? Алкин-Шәрәфләрне «Татар-башкорт җөмһүрияте» генә канәгатьләндерми, аларга киңлек кирәк, бөтен мөселман дөньясы кирәк!.. Кайсы яхшырак, кем бүген шуны кистереп аңлата ала?

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган елларымда мин, әлбәттә, соңгысын яклар идем, ә хәзер бик нык, бик тирәннән шикләнәм. Матур сүзне күп әйтәләр, вәгъдәләрне юмарт чәчәләр, ә тарих үз улларыннан эш сорый, һәркемнең гамәлен шуннан чыгып кына бәяләргә кирәк тә...»— дип уйлады Фатих.

Ә яңа властьның сүз-вәгъдәләре кылган гамәлләреннән бик нык аерыла...

Әмирханның арбасы бер урында тормый, авыр уйларына җавап эзләгәндәй, бүлмәнең әле бер почмагына, әле икенчесенә тавышсыз

---

[8] С. Н. Гассар — 1903 елдан большевик, 1918 елда төзелеш эшчеләре профсоюзының секретаре, учредиловчылар тарафыннан 1918 елның августында атыла.

гына тәгәри, кая тәгәрәсә дә уй йомгагы чәбәләнгән хәлдә, аннан калмый, бер сүтелә башлый да бер җыела... Уйлар, китмәскә тыгызланып, күңелне һаман авырайталар. Ник берәр тере кеше килеп керми инде ичмасам?! Тәшвишле уйларын чыгарып бетереп, күңелен бушатыр иде!..

Шәһәрнең һәр урамында ыгы-зыгы барган кебек, шушы аулак йортның почмакларында Әмирханны борчулар, икеле-микеле төпсез фикерләр сагалап тора. Шик-шөбһәләрне арттырып, аларга авыр юнәлеш өстәп, урамнан атлылар чабып узды. «Монда да чабышалар!»

Уйлар, уйлар... Аларның бүгенгеләре зур әдипнең аерылмас юлдашы...

«Большевиклар халыкларның тигезлеген игълан итте, «һәр халыкның, зурмы ул, кечеме, үз язмышын хәл кылырга хакы бар!»— дип белдерде. Татар телен дәүләт теле санап, безнең милли горурлыгыбыз Сөембикә манарасын хезмәт ияләренә кайтарып бирделәр... Изге урын, татар өчен хөрмәтле урын, манара өч изгенең кабере өстендә корылган, анда мәрхүм ире Сафагәрәй җеназасы өстендә Сөембикә энҗе яшьләрен түккән... Кемнәрдер моны әкият дип саный, әмма чынмы-ялганмы икәнен берәүнең дә дәлилли алганы юк...

Большевиклар «Болак арты» заманында бертуган Алкиннарны, Токумбетовны, Мозаффаров белән Баһаветдин ахунны кулга алдылар да чыгарып җибәрделәр. Ә болар кулга алынганнарны тоташтан аталар. Ни өчен — беркем аңлатып тормый! Аталар — вәссәлам!

Ярый, Самара комитеты Учредительное собрание исеменнән эш йөртсен, ди»...

Әмирхан уйларын һаман шул якка юнәлтте...

Әмма хаклары бармы аларның, чөнки бөтеннең бер өлеше — бөтен була алмый! Комитетның собрание исеменнән сөйләргә тулы хокукы булуы шикле!

Һәр халыкның, шул җөмләдән татарларның да бәхеткә хакы бар. Әмма халык бәхетенә ничек ирешергә? Сүз аерым бер шәхеснең бәхете турында гына бармый лабаса, аерым кеше бәхете һәм халык бәхете — болар икесе ике нәрсә. Хәзер әнә милли бердәмлек турында күп язалар һәм «бәхет әнә шул бердәмлектә!» дип кычкыралар. «Яңа вакыт» газетасы, мәсәлән, болай дип фикер йөртә: «Без, татарлар, большевик та, меньшевик та, социалист та түгел, без — бер имандагы мөселманнар!» Алай икән, татар большевикларын кая куясың? Алар татар милләтенең уллары түгелмени? Заманында Мирхәйдәр Фәйзи: «Авылда рәхәт эчендә йөзәм, хезмәт итәм, башкасында һич гамем юк!»— дип сөенеп язган иде, «Халык армеецлары» көтепханәсен тар-мар иткәч, тиз үк фикерен үзгәрткән, «рәхәт эчендә йөзеп хезмәт итү хокукын» сакларга да, якларга да кирәк икәнен бик тиз төшендергәннәр!

Кайберәүләр: «Милли бәхет — башка халыклардан аерылуда»,— диләр, хуш, ничек була ди инде монысы, шушы зур дөнья йөзендә, томаланып, ничек яшәмәк кирәк? Төрекләр русларга караганда һимматлерәк дип кем раслый ала? О, хәзер янымда Тукай булса! Бөек кеше, берчакта да икеләнеп тормаган, үз сүзен пәйгамбәрләрчә кистереп әйткән:

> Монда тудык, монда үстек,
> Мондадыр безнең әҗәл!

«Хак,— дип уйлады ачынып Әмирхан.— Борынгылар рас әйткән: «Иртән уянасың да сөенеп куясың,— әле ярый Рим империясенең язмышы өчен җавапны мин бирмим!» Мин дә аның язмышы өчен җавап бирмим, мәгәр үз халкымның киләчәге хәл ителгәндә, битараф кала алмыйм, юк, милләттәшләрем яу кырларында бер-берсенә ук, ут төбәгәндә кул кушырып утырырга ярамый...

Хәлләр ашыгыч алмашына, элек иртәләрне мин «Эш», «Эшче» газеталарын караштырып башлый торган идем, хәзер миңа «Корылтай»ны тәкъдим итәләр. Совет газеталары шәһәрдә тыелган. Чуваш идарәчеләре, «Канаш» газетасының редакциясен тар-мар китереп, «Хыпар» чы-

гарырга керештеләр. Марилар «Мари мут» тәкъдим итә. Чыннан да мутланалар!» «Яңа власть өчен көрәшкә» өндәп, Самарадан татарча нихәтле листовкалар, кәгазь ташыйлар.

Һәммәсе бердәмлеккә өнди, үз канаты астына дәшә! Большевиклар юксылларны, хезмәт ияләрен берләшергә чакырды. Аларга алмашка килүчеләр «милләтләр һәм тугандаш халыклар бердәмлеген» яклый. «Татарлар белән бергә булганда безгә бернинди дошман куркыныч түгел!» — дип яза «Хыпар». Казанда чуваш вәкиле Алюнов «Чуваш штаты» төзергә тәкъдим кертә, аның исәбенчә, ул Урта Идел һәм Көньяк Урал штатлары составына керергә тиеш. Икенче яктан кызыллар, совет властена каршы көрәшкән чувашларга мөрәҗәгать итеп, махсус өндәмә чыгаралар: «Акгвардияче офицерлар, инглизләрдән һәм башка союзниклардан ярдәм килә дип, сезне алдадылар! Инглиз, япон һәм башка ил байларына сезнең кан кирәк, каныгыз! Шуның ярдәмендә алар хезмәт ияләрен, шул исәптән сезне — чувашларны да буйсындырырга телиләр. Акгвардиянең русы, чувашы, сезнең җилкәгә ышыкланып, сезне бер дә юкка үлемгә таба этәрәләр!»

Хакыйкать ерак яшерелгән, гади кеше тиз генә төшенеп житәрлек тә түгел. «Мариларның үзәк союзы» житәкчеләре Казандагы мариларны «сәясәтләре ничек булуга карамастан» берләшергә кыстый. Царевококшайскида сайланган шәһәр думасы Казанга телеграмма суккан: «Ходай ярлыкаган Царевококшайск каласы, кызыллар җәфасыннан котылып, Самара хөкүмәтен тулысынча яклавын тантаналы төстә белдерә»...

Кая бара дөнья?
Кая бара халык?
Кая бара ил?..

Тыгыз һәм хәвефле уйларны бүлеп ишек ачылды, һәм аннан Фатихның энесе Ибраһим килеп керде.

— Әссәламегаләйкем, Фатих абый,— дип ягымлы гына күреште.

— Бәракалла, бәракалла, Ибраһим! — диде куанычы йөзенә чыккан Фатих.— Хуш киләсең! Әллә син минем чакыру авазын ишеттеңме? Дөнья белән арадашлыкны ныгытыр өчен миңа бер тере җан бик кирәк иде. Әгәр ул тере җан син икәнсең, икеләтә шатлык. Менә рәхмәт, хуш киләсең!..

Фатих энесе Ибраһимны ихлас ярата иде. Гомер-гомеренә яратты, хөрмәт итте. «Мөхәммәдия»дә укыганда, студент Сергей Гассарга дәрес тыңларга йөргәндә кабынган хөрмәт һәм мәхәббәт берчакта да сүрелмәде. Аларның тормыш юллары аерылгалады. Ибраһим шәһре Бәйрүттә америка колледжы тәмамлап чыкты, укытучы, солдат булды, нужага житәкләтеп язмыш аны шактый чайкады, ниһаять, 1918 елда аны Казанның 7 нче участогына судья итеп сайладылар. «Көченне хак эшкә куй, энем!» — диде абыйсы, ара ераклашса да, уртага җил кермәде. Фатих та, Ибраһим да туганлыкның берни белән алыштырмаслык кадерен аңлап торган гали затлардан иделәр. Төпле, әзерлекле, киң карашлы, рус-татар телләрен бердәй белү өстенә Ибраһим төрек, гарәп, инглиз телләрендә укый-яза һәм бик яхшы сөйләшә алырлык тирән белемле зыялы иде. Бу көннәрдә дә ул тик ятмый. Яңа бистә татарларын «Халык армиясенә» көчләп мобилизацияләүдән коткарыр өчен үзенә күрә бер «хәйлә» дә уйлап тапкан иде... Татар ирләрен «Бистәдә тәртип саклау өчен» дигән дружинага чакыртып, дружина әгъзаларын сугыштан алып калырга тырышып йөри иде.

— Тынмыйсыз, абый, укыйсыз да язасыз,— диде Ибраһим, хәлъәхвәл алышкач, өстәлдә таралып яткан рус, татар, чуваш, мари газеталарына һәм листовкаларга ишарәләп.

— Боларны әйтәсеңме? — дип көлеп алды Фатих, энесе килеп керүгә аның кәефе әйбәтләнеп киткән иде.— Болар фикер сугыштырырга

азык кына! Ә җавап бирергә хәлләреннән килми, нәтиҗә ясау читен! Утырасың чүбек чәйнәп, җенләнеп. Дөрес, һич югында алар да ярап тора, алар бүгенге көннең шаһитлары, әмма тарихны тудыручыларның хак авазы монда юк. Гаҗәп, әй, тора-тора шаккатам! Бүген капма-каршы килеп, канга-кан тузышып яткан адәмнәр әле күптәнме бергә, янәшәдә иделәр?! Бер үк түгәрәкләргә йөрделәр, бердәй китапларны укып, бер-берсенә гашыйк булып күңел серләрен алмашып яшәделәр. Ә хәзер, баксаң... Җир бер, басу-кыр да бер, ә чәчкән ашлык төрле урында төрлечә шыткан, җимеше дә, уңышы да төрлечә. Фуат Туктаровны хәтерлисеңме?

— Сез шул турыда да уйладыгызмы, абый? — Ибраһим, абыйсының гадәттән тыш уйлар чоңгылына чумуын аңлап алып, сүзен дәвам итәргә кыймыйча, аны бүлдерергә базмыйча утыра иде, бу соравы да ихтыярсыз, үзеннән-үзе килеп чыкты, чөнки Фатих абыйсы бүген бер дә көтелмәгән исемне атады.

— Казанда учительская школа һәм университетның юридик факультетын тәмамлады. Үсте. Учредительное собрание әгъзасы булды. Хәзер шул кеше үзе кебек үк Учредительное собрание әгъзасына, кан кардәше Мулланур Вахитовка үлем җәзасы сорый! Сорый гынамы, таләп итә, дәлилләр таба! Яки менә Гаяз Исхакый белән Зәки Вәлидине алыйк, икесе дә Казан мәдрәсәсе шәкертләре. Исхакый заманында «Ил » газетасының мөхәррире иде, кыен күрде, патша төрмәсендә утырды. 1917 елда Мөселманнар съездын оештыруны башлап йөрде. Хәзерендә әнә, «Идел-Урал» идеясе белән җенләнгән, төрки халыкларны бер арбага, ике тәртә арасына җигәргә чамалый. «Бергә», «бердәм»! Ә большевикларны кая куясың? Мөселманнар арасында Вахитов кебек асыл егетләр барында Исхакый көткән «бердәмлек»кә ансат кына ирешеп буламы? Туктаров Вахитов янына сыямы? Вәлидинең беренче адымнары кызыклы һәм өметле иде. Галим! Төрек-татар тарихын өйрәнеп язды. Хәзер ятса-торса күз алдында «Аерым Башкортстан»! Авызын ничә ачса да: «Башкорт, башкорт!»

Заманында барыбыз да бергә идек, яшь аермаларыбыз дүрт-биш ел, зирәк Каюм Насыйри, тиңсез галим, шәйхе-рәйс Шиһап хәзрәтнең фикерләре белән янып, ялкынланып йөргән идек. Шиһап Мәрҗанинең «Мөстафад әл-әхбәр фи әхвәли Казан вә Болгар» китабы һәммәбезнең уе, фикере, иманы иде бит. Мәрҗани шулай зирәк булган ки, хәзрәти Чыңгызның канлы урдаларын гомергә яратмаган, Кулагу, Аксак Тимерләрнең халыкка ничаклы кайгы-хәсрәт китергәнен аңлаган. Менә бүген, шул фикерләр белән авызланып үскән, ныгыган егетләр остазлары сөймәгән, нәфрәтләнгән канлы эшләрне үзләре кылалар! «Мәрҗани шәкертләре» дип атыйлар иде ич алар үзләрен!

Фатих, арбасының бер читендәге кисәгә кыстырылган кулъяулыгын тартып чыгарып, калынча иреннәрен иплән кенә сөртте, Ибраһим, абыйсының ымын аңлап, өстәлдәге тәбәнәк графиннан салкын су салып бирде. Фатих вак-вак йотымнар белән сусынын кандыргач, сүзен дәвам итте. Сөйләшергә зарыккан иде...

— Алай гынамы сиңа! — диде ул.— Вәлиди «Соры бүреләр» идеясен күккә чөя башлады. Пантюркизм символын! Күр, менә ниләр яза бит ул төлке! «Кемнәр без? Соры бүреләр без. Безнең иманыбыз ни? Соры бүреләр — төркиләр, менә безнең какшамас иман. Соры бүреләр нәрсәгә табына? Алар төрек токымының, төрек милләтенең башка расалардан вә милләтләрдән өстенлегенә ышана. Бу өстенлекнең дәлиле ни-нәрсәдә? Төрек милләте...» һәм башка чүп-чарлар китә... Расизмга чакыру түгелме бу сиңеңчә, Ибраһим? Чакыру гынамы, чеп-чи расизм! Без аның белән танышлар идек, хәл-әхвәл алмашкан чаклар булды, хәзер шуңа оялам, колакчыны астындагы соры бүре колакларын ничек күрмәгәнмен? Үз милләтеңне бүтәннәрдән өстен кую җирәнгеч хәл, туган чакта кеше милләтен дә, эти-әнисен дә сайлап ала алмый. Ни өчен адәм баласы

дөньяга яралганда ук үзенең кимлеген тоеп туарга тиеш? Хаклыкмы бу, дөреслекме? Түгел, мең мәртәбә ялгыш караш! Тарихтан бер нәрсәне дә яшереп булмый. Кемнең якты эз калдырганын, кемнеңдер хак юлны пычратып үтүен ачыклар өчен тарихка вакыт кына кирәк. Кайберәүләр, халыкка хезмәт итүне онытып, дөнья табынынннан калҗанын симезрәген эләктереп калырга омтылалар икән, алар берзаман якты көнгә чыгар. Әйе, Мисырда «Дөньяның бар хикмәте Коръәндә тупланган инде, башка китапларның хаҗәте юк!» — дип мәшһүр Искәндәрия көтепханәсен яндырырга боерган ахмак төрек вәзирен дә телгә алгалыйлар. Мәгәр ничек итеп, нинди сүзләр белән яд итәләр аны! Якты эш янәшәсендә кара эзләр дә онытылмый.

Язмыш тукмауларыннан читләшеп булмый — тарих шуны өйрәтә. Әйе, байтак милләтләр үз заманнарында, гәрчә башкаларны буйсындыру исәбенә булса да, алга чыкканнар, өскә үрләгәннәр. Бу хәл исә армияләрнең, яу башлыкларының зирәклегенә һәм көченә бәйле булган. Алыйк юнон, румнарны, иранлы һәм төрекләрне, монгол һәм татарларны, рус һәм испаннарны, гарәпне, кытайны, французны... Һәммәсе заманында данлы-шанлы, бер читеннән икенче читенә кош очып үтмәс дәүләтләр корганнар. Ахыр чиктә ни белән тәмамланган — һәммәсе үз урынына утырган. Милләтләрнең көчле яңарыш чоры үткән, алар һәммәсе гап-гади җир улларына әйләнгәннәр. Нәселдәшләре яулап алучыларны мактаса да, корбаннары һәрчак аларны каһәрләп яшәгән. Җирле ватандарлык һәм куркыныч шовинизм нәкъ шушы җирлектә туа, үсә, дөнья цивилизациясе шушы җирлектә җимерелә. Бер дәүләт эчендә, бер халык арасында сугышка өндәүчеләрне күралмыйм, нәфрәтләнәм.

— Соңгы көн газеталарыннан алган тәэсирләр шулай алайса, абый?

— Соңгы айларда, соңгы елларда, Ибраһим! Соңгы көннәр уй-фикерләргә ачыклык кына кертте. Адәм улларының асыл табигате турында без бер бүген генә уйламыйбыз лабаса! Бу арада тере кеше сагындырды! Тере җан! Ә комучлар, миңа мәет артыннан мәет тәкъдим итеп, ватанны сөяргә өйрәтмәкче булалар. Ярый, куеп торыйк. Дөньяда ниләр бар, Ибраһим? Газеталар аерым төркемнәрнең мәнфәгатен чагылдыра. Мондый кискен мизгелләрдә, власть өчен тартыш барганда, алар тормыш чынлыгыннан шактый ерак була. Сөйлә! Тукта, башта чәй кертсеннәр. Сөйләдем, сөйләдем дә, тамак яна!

Ибраһим хуҗа хатынга абыйсының үтенечен әйтеп кенә өлгерде, өстәлгә гөҗләп торган җиз самавыр килде, тәбәнәк өстәл янына килеп чәйне Фатих үзе ясады. Бүлмәгә чәйнең хуш исе таралды.

— Житеш, Ибраһим. Чәйдә йөзеп чыккач тел җитезләнә.

— Үзем дә сезнең янга ашыктым, абый. Әлерәк кенә Юныс мәйданында булдым. Шунда, Иске бистә уртасында, митинг булып узды.

— Кемнәр катнашты?

— Күпчелеге татарлар. Яңа власть вәкилләре чыгыш ясады, арада чит ил вәкилләре дә бар иде.

— Урынның кәттәсен сайлаганнар, ә? Мирза Алкиннар йорты, Шамил йорты, татар учительская школасы, Апанаевлар йорты. Чит ил вәкилләренең күзенә тузан җибәрәләр янәсе!

— Митингны Габделбари Баттал ачты.

— Ул каламы соң? Баттал каламы?

— Баттал Казан мөселманнары исеменнән большевикларга бәддога укыганнан соң, чехларны, учредиловчыларны, Халык армиясе һәм союзниклар вәкилләрен берәм-берәм тәбрикләп чыкты.

— Чит илләрдән кемнәр килгән инде безнең данлы Казанга?

— Белергә теләрсез дип, куен дәфтәремә теркәп бардым, абый — Ибраһим бармагын кәгазь өстендә йөртеп абыйсына таба иелде.— Француз капитан Борд, америкалы подполковник Рошторх, инглиз капитан Митчел.

Фатих чәен куеп торып мыскыллап көлеп җибәрде.

— Кан коярга дигәндә татарлар мәркәзенә америкалы да килеп җиткән диген, әй, дөнья! Шуннан, шуннан?

— Мылтык-кылыч тотардай һәр хак мөселманны Баттал Халык армиясенә өндәде. Матди ярдәмне дә онытмыйк, һәркем хәл кадәренчә армия казнасына акча кертсен дип кычкырды. Элгәрендә социалист-панисламист булып күренгән Мулланур Вахитов чынында большевик булып чыкты, хәзерендә килеп капты, тимер рәшәткә артында утыра, дип сөенечен белдерде.

— Мулланурга яный, ә?!

— Сүзенең азагында купшы төче сүзләр сипте, Идел күперенә ябышып яткан большевикларны себереп түгәр өчен җыелган голамәне «Мөселман эскадроны»на керергә дәртләндерде.

— Керүчеләр табылдымы?

— Алдан әзерләп куйганнар икән! Казылыкчы Абдулла Килдишев кул астындагы егерме бишләп атлы «Демократия идеяләренә тугры булырга» ант итеп эскадрон төзеделәр. Әй кул чабарга тотынды чит ил вәкилләре!

— Алай,— дип сузды Фатих.

— Аннан Габдрахман мулла Исхаков, чуваштан Учредительное собрание әһелләре Алюнов белән Васильев сөйләделәр. Подполковник Әмир Мамлеевны күптән ишеткән юк иде. Ни ди, «Мин, ди, Казанга союзниклар һәм Халык армиясе вәкилләре белән берлектә милли мөселман гаскәре төзер өчен килдем, ди. Башкортстанда бу изге эшне Зәки Вәлиди башлап җибәрде, алар башкорт халкын изеп килгән рус колонизаторларына һәм большевикларга каршы көрәшне ачтылар. Учредительное собраниедән башкортларга автономия алыр өчен хәзер башкортлар ашыгып берләшә, полклар, дивизияләр оеша, ди. Татарлар алардан үрнәк алсын»,— ди.

— Садрый Максудый бар идеме?

— Булмыйча!

— Яле, яле! III дәүләт Думасында Мөселман фракциясен җитәкләгән кеше. «Иттифак»ны җитәкләгән лидер! Соңгы елларда адвокат, хәзер шәһәр думасында гласный. Дөньяның киләчәге хакында фикере ничек?

— «Татарлар гомер-гомергә милли-мәдәни автономия турында хыялландылар, шул хыялны тормышка ашырачак Самара Комучын яклыйк. Төрки-татарның үзәге булачак Идел-Урал штаты безнең хыял иде, хәзер шуңа ирешергә җай туа. Казакъларның «Алаш-урдасы», Кырымның «Милли фиркасы», Бөтенроссия Милли Шурасы да Учредительное собраниене алкышлап каршылады»,— ди.

— Милли Шура вәкиле буларак Садрый Максудый комучлардан риза вә бәхил алайса?

— Тагын озак сөйләде әле! «Мөселманнар арасында марксистларга караганда либераллар һәм социалистлар гомергә күбрәк булды. Казанда властьны советларга руслар бирде, татарлар ул эшкә катышмады»,— диде.

— Вахитов, Якубов, Чанышевларны кая куясың дип кычкырмадылармы?

— Халык тып-тын тора. Бүгенгә җайлашам дип, тарихка күз йому ару түгел бит, абый, иеме? Ялган сүз ышанычны үтерә, абруйны киметә. Максудый да халык армиясенә чакырды һәм «Большевистик Карфаген тар-мар ителергә тиеш!»— дип сүзен тәмамлады.

— Вот позор! — дип көлде Фатих. Арба тәгәрмәчләре салмак кына уңга, сулга тәгәрәделәр.— Сүзләрең рас, күзең үткен. Үзем дә беркөн шундыйрак хәлгә тап булдым. Тукай мәйданын үтеп барам, койма артында мәетләр озата торган урында, нинди дер митинг! Туктап калдым, ярты сүзеннән аңладым, учредиловчы чыгыш ясый! «Союзникларга биргән вәгъдәбезгә тугры калып сугышны Германияне җиңгәнче алып ба-

рыйк!»— дип, армияләренә керергә кыстый. Беркем кул чапмый, бераү хупламый, ул һаман жиңү турында жилпи! Бармы аңа халык, тыңлыймы, теләктәшме — барыбер. Кушканнар — сөйли, кушсалар — туктар. Кушалар икән — атачак. Боерсалар, мәйдан уртасында асачак. Арттагы рәтләр берәм-берәм тарала башлады, инде кеше калмады диярлек, «һаман бер балык башы», «чүбек чәйниләр!» дигән зар сүзләрен үзем ишеттем. Шунда Насыйх Мөхетдинов белән күрешеп сәлам алыштык[9]. Син аны беләсең, армиядә прапорщик иде. Шуннан искә төште, яңа власть офицерларны, унтерларны тоташтан мобилизацияли икән! Син унтерофицер, саклан, күздән югалып тор!

— Яңа бистәдәге кардәшләребезне сугышка барудан кем аралап алып калыр?

— Татарлар арасында хәрби хезмәттән читләшергә тырышкан офицерларның исемлеген төзеп кемдер яңа власть әһелләренә тапшырган дигән хәбәрне Насыйх әйтте! Мөгаен, син дә шул кара исемлектә, Ибраһим! Сак бул, хәзер без сират күперен кичәбез, ожмахка үтәрбезме, әллә тәмугка тап булырбызмы, кем белсен.

— Тагын шуны белдем,— диде чынаягын каплап Ибраһим.— Учредиловчылар контрразведкасында махсус комиссия төзелгән, мөселманнарның эшен шул комиссия караячак, башында Ильяс Алкин.

Фатихның йөзеннән кара күләгә тирбәлеп үтте.

— Комиссия әгъзалары Гаяз Исхакый, Габдулла хәзрәт Апанаев, «Корылтай» мөхәррире Габделбарый Баттал. Кулга алынган Мулланур Вахитовның язмышын әнә шулар хәл итәчәк.

— Комиссарның гомере чикледер дип куркам. Батталның: «Большевиклар җәмгыятебезгә шул кадәр зыян салды, аларны кырып бетерергә генә кирәк!»— дип шашып йөргәнен бөтен кала белә!

— Баттал башсыз һәм муенсыз кеше,— дип килеште Ибраһим.

— Мулланурны беләм,— дип дәвам итте Фатих.— Искиткеч саф, чын кеше, алтын егет! Җаны-тәне белән Октябрьгә бирелгән, аның бәрәкәтле нәтиҗәләрен безгә, Көнчыгыш халыкларына сеңдерергә күпме тырышты! Алкиннар гына аны сындыра алмас. Мәгәр алар кабак башлы фанатиклар! Хәзер Алкинга егерме өч яшь, унҗиденче елда, Бөтенроссия мөселманнары Хәрби Шурасы рәисе булып сайланганнан бирле Мулланурны үзенең төп көндәше итеп санады һәм, татарлар арасында гына түгел, Россия мөселманнары арасында да үзен бердәнбер юлбашчы итеп күрергә тырышты. Дөрес, энем, хак әйтәсең, Баттал кебекләргә большевикның әйбәте — үлгән большевик. Алкин үзеннән йөз мәртәбә талантлырак, мең мәртәбә төплерәк, максаты тайпылусыз һәрчак ап-ачык булган Вахитовтан гомер бакый үлеп көнләште. Үлеп! Вахитов үз тормышы, иманы, гамәлләре белән аңа гел комачаулап килде. Сәяси көнчелек һәрчак кан белән генә хәл ителә. Унҗиденче елның көзендә Учредительное собраниегә тугызынчы исемлектә бергә сайланганнар иде югыйсә. Яшәгән саен аларның юллары ерагайды, менә хәзер дә, акыллысы — тоткын, шыр тилесе — хөкемдар!

Алдагысын алла белә диләр, мәгәр күңелем курка, нидер кылырга, Мулланурны коткарыр өчен нидер эшләргә кирәк. Кичекмәстән. Туры Тукай нәрсә дигән:

Әйдә, халыкка хезмәткә,
Хезмәт эчендә йөзмәккә!

— Без нишли алабыз соң, абый?

Фатих бераз уйланып алды.

— Татар халкының алдынгы улларыннан имзалар җыеп демократ булып кылanучы комучлардан Мулланурны порукага бирүләрен үтеник. Бирмәсәләр, алар мәңгелек каргыш алачак!

[9] Насыйх Мөхетдинов (1892—1937) — 1918—20 елларда Казан губернасы халык мәгарифенең бүлек мөдире урынбасары. 1920—22 елларда мөселман пехота курслары комиссары, соңра укытучы.

— Ай-һай, абый.

— Күнмәсләр дисеңме?

— Имзаларны кем җыя? Казанда хәрби хәл игълан ителгән. Миңа чыгып йөрмәскә, күренмәскә үзегез кушасыз. Сез...— Ибраһимның карашы бер генә мизгелгә абыйсының тәгәрмәчләрендә тукталып алды.— Монда нык уйларга кирәк.

Татар халкының зур әдибе, Тукайның якын дусты, атаклы тәнкыйтьче, философ Фатих Әмирханның горур башы түбән иелде дә шунда ук югары күтәрелде.

— Садрый Максудыйлар татар халкы исеменнән сүз сөйли ала! Миңа ярамыймы? Мин халкым исеменнән Мулланурны порукага бирүләрен таләп итә аламмы?!

— Аласыз, абый. Моңа сезнең генә хакыгыз бар да!

Шул чагында иплəп кенə ишек ачылды һәм Сажидә апа килеп керде.

— Менә үтенечне Ильяс Алкин комиссиясенә Сажидә апа илтеп тапшырыр. Барасызмы, Сажидә апа?

— Сез кушкач нигә бармаска ди, Фатих улым?!

•

Бүген унсигезенче елның унсигезенче августы...

Юк, өстәлдә ачылып яткан календарьга ике унсигез бергә туры килгәнгә генә игътибар итмәде Мартин Янович Лацис, түгел, бүген беренче мәртәбә аның башы ачылып китте, чигәләрдә гел сызланып торган авырту кимеде, ул аякларын сузып, башын урындык аркасына куеп күзен йомды, йокымсырады. Күптәннән йокы тынычлыгы татыганы юк, Казанны акларга калдырып чыккан көннән бирле... Бүген унике көн... Унике көн буена, күзен йомса күз алдына шәһәр урамнары, вокзал, пристань тирәләрендәге атышлар, хурлыклы качу күренешләре тоташ кара болыт булып агылып килә дә йокыны кысрыклый, качыра...

Бүген нигәдер ул тынычланып калды...

«Вакыт ашыга, кабалана, без әнә шул агымга ияреп агабыз. Әллә агымны үзебез тудырабызмы? — дип уйлады ул.— Кичә баш житә алмаслык фаҗига булып тоелган хәлләрне бүген яшь аралаш көлемсерәп кенә искә алырга була! Үткәннәргә мөнәсәбәт үзгәрә икән!» Унбер көн элек кенә ул хурлыклы качу минутларын гарьләнеп, ярсып-шашып күз алдына китерә иде, бүген минутлар аның тыныч гомерен саный. Шәһәрне кире кайтарачак алар! Һәлак булганнарны гына кайтарып булмый... Әлерәк кенә Красная Горка өчен көрәшкәндә батыр башын салган комбриг Ян Юдинны Свияжскида җирләделәр... Янны кайтарып булмый! Гүзәл кеше иде...

Күңеленең нилектән тынычланып, акылының үз урынына утыруын Мартин Янович беркемгә дә аңлатып бирә алмас иде, мөгаен...

Кинәт ачылган ишектән кабаланып кына ярдәмчесе керде һәм:

— Вацетис кайтты! — дип белдерде.

Лацис кинәт айнып китте: «Вацетис?! Казанны калдырганда хәбәрсез югалганнар исеменә кертелгән командующий!?»

Ул атылып ишегалдына чыкты, баһадир гәүдәле Иоаким Иоакимович былчыракка буялган күнитекләрен чыбык белән чистарткалап тора иде, Мартин Яновичны күргәч чыбыгын атып бәрде. Кочакларын җәеп бер-берсенә каршы киттеләр.

— Мартин Янович!

— Дустым!

Лацис ярдәмчесенә тиз арада кабарга берәр нәрсә хәстәрләргә кушты.

— Кайнар чәй, бик кайнары, авыз пешәрлек булсын,— диде Вацетис, җилдә яргаланган иреннәрен ялап.

Гадәттә ифрат каты күңелле, бер чакта да йомшап төшми торган Лацистан «дустым!» дигән сүз ычкынып җылыттымы, кайтып керү

сөенече артык зур идеме. Вацетис бер мәлгә онытылып, юаш, гади кешегә әйләнеп калды. Казанны калдырган армиянең башкомандующие белән Казан чекасының хуҗасы шулай итеп Свияжскида очраштылар:

— Ничек? Кайда? Ниләр булды? — дип сорады бик тиз җитдиләнеп Лацис.

— Монда ни хәлләр? Мин исән-сау кайтып җиттем...

— Юк, башта син аңлат. Кайда югалдың?

Вацетисның йөзе кызарып китте, ул күзләрен күтәреп Мартин Яновичка сынаулы караш ташлады. Аның карашының мәгънәсе ни аңлатканны белү кыен түгел иде...

— Без шәһәрдән алтау чыгып ычкындык,— дип башлады Вацетис сүзен.— Алтау гына идек, ә котылу барыбер җиңел булмады! Көч бәләкәй, дошман белән очрашуга караганда очрашмау хәерлерәк... Безнең бәхеткә көн яңгырлы иде, караңгы тиз төште, котылсак хәзер котыла алабыз, дип куаныштык... Шыпырт кына, казлар кебек тезелешеп барабыз. Кинәт тар тыкрыкта, бездән илле адымнар булыр, кычкырган тавыш ишетелде. «Тукта! Туктагыз! Сез кемнәр? Әйтегез! Пропуск!»— дип акыралар. Арада хатын-кыз тавышы да бар сыман. Без барабыз да барабыз, беткән баш беткән, караңгы төшсә дә кычкыручыларның җиңнәрендәге ак тасмаларын абайладык. Кулларында корал да бар! Дошманнар! Иптәшләргә шыпырт кына: «Тукталмагыз, барган шәпкә атлагыз!»— дип боердым. Атлыйбыз, алар да килә, ара егерме метрлап кына калды. «Тукта! Туктагыз! Сез кемнәр? Әйтегез!»— дип тамак ярып кычкыралар болар. Ә без ләм-мим дәшмибез, аркага салкын тир бәреп чыкса да, төбәлгән револьверларга чекерәеп карап алга барабыз. Иптәшләр түзмәде, берсе мылтыгын иңеннән алды, икенчесе гранатага тотынды. Кирәкми, димен, сабырлык саклагыз! «Сез кемнәр? Туктыйсызмы, юкмы?»— дип ирләре дә, хатын-кызлары да бакыра тегеләрнең. Ара ун адым калды. Ачуымнан шартлый язып сүгендем дә: «Олагыгыз күз алдымнан!»— дип мин дә кычкырып салдым! Тегеләр бер мәлгә тынды. «Нигә сүгенәсез? Әллә кыргыйлар арасында дип беләсезме үзегезне? Кемнәр сез? Кая барасыз?»— дип тынычрак сораштыралар. Мин тагын яман акырып сүгенеп җибәрдем. Якынлаштык, күзләр күздә, куллар коралда. Алар байтак, җиде ир һәм дүрт хатын-кыз булып чыкты, һәммәсе кулында безгә төбәлгән корал. Колак төбендә җикеренәләр: «Сез кемнәр? Нигә әйтмисез? Туктагыз!» Тар басмада очрашкан кәҗә тәкәләре сыман тыкрык уртасында торабыз. Беркая борылыр да, читкә сугылыр җай да юк. Чак кына алгарак чыктым, тегеләрнең берсе, командирлары булдымы, бер-ике адым алга атлады.

— Сез кемнәр? Нигә сүгенеп йөрисез? — ди бу наганын болгап.

Бүтәннәре дә коралларын селкиләр, «күрегез!» янәсе. Безнекеләр гранаталарга ябышты... Кискен мизгел! Хәзер бары да хәл кылыначак. Без аларны, алар безне... Әмма мин сабыр, ни хәлдер, кыл бөртегем дә селкенми, иңемдәге винтовканы ипләбрәк куйдым да тагын бер адым алгарак үттем. Баш иеп ханымнардан гафу үтендем, «Ялгышканбыз, караңгы, акмы, кызылмы сезнең кемлекне дә, арада ханымнар барлыгын да шәйләмәдек. Без чехлар»,— димен. Ханымнар бик үк ышанып та бетмиләр, ирләр тоташтан шикләнә, сораштырырга тотындылар. Ә безнекеләр, күбебез латыш, русчаны ватып-җимереп: «Чехлар без, чехлар!»— дип тәкрарлыйлар. Ханымнар йомшагач, ирләрнең дә шигәюе кимеде. Ханымнар бөтенләй эреп төште, елмаялар, безгә рәхмәт яудыралар. «Безне большевиклардан коткардыгыз, төрмәләрнең ишеген ачтыгыз, рәхмәт сезгә!»— диләр. Ирләр: «Безнекеләр кайда?»— дип сорашалар. «Крепостьта!»— дибез.

Ханымнар моны ишетүгә кыбырсый-ашыга башлады, ирләрнең икесе аларга кушылды, каш астыннан сөзеп карап бишесе яныбызда калды. Кораллар һаман безгә төбәлгән! Мин һаман тып-тыныч, сабыр, нәзакәт

белән картузымны күтәрдем дә: «Сау булыгыз, әфәнделәр!»— дип тегеләрне үтеп киттем. Алар безгә юл сапты, без аларга. Аерылыштык... Театр мәйданына җиттек, йөрәк урынына утырырга да өлгермәде, театр артыннан гүләп-гөжләп автомобиль килеп чыкты, безне күреп туктады. Шофер кырында бер генә кеше бар. Мин иптәшләргә ым кактым, ә дигәнче барыбыз да автомобильгә кереп тулдык. Теге бәндәчек чинапмычиный, беребез аның авызын каплады, мин шоферга Казанка ягына ашыгырга боердым. Чинаганны ишетепме, яныбызга ике яктан да патруль килеп җитте. «Тукта да тукта!» дип сөрән салалар, кая ул, шоферның касыгына наган терәлгән, очабыз гына, арттан аталар, яннан аталар, бар дип тә белмибез. Исән-аман күпергә кердек, Кәҗә бистәсенә илтә торган олы юлга төштек, бистәне дә үттек, урман авызына җитәрәк, утызлап атлының кыеклап безгә таба чабышуын абайладык. Караңгы тәмам куерган иде инде, тиз-тиз машинадан төштек тә урманга кереп сибелдек. Атлылар сызгыра, ата, ләкин кырда җилне, урманда качкынны тотып кара син! Бераздан бергә җыйналдык, аякларга ял бирдек, коралларны барладык... Уравыч юллар аша, көндезләрен урманда качып ятып, Биектау тирәсеннән узып Вятские Полянага барып чыктык. Аннан Арзамасны үтеп, ниһаять, мең бәла белән сезнең янга кайтып төштек.

Лацисның озын, нык бармаклары өстәлдә биешеп алдылар.

— Әйе,— дип сузды ул, тәрәзә аша каядыр еракка, билгесезлеккә карап.— Без дә Казаннан чак-чак чыгып ычкындык! «Беттек! Эләктек!»— дигән чаклар да булгалады. Вокзалга төшеп җитәр хәл юк, ыгы-зыгы, барча халыкның коты очкан, эт чаба дип бет чаба, кая карама янгын, ут, төтен. Баш очыннан снарядлар сызгырып үтә. Бөтен җирдән аталар. Мең бәла белән поездга кердек, аклар килеп җитте дигәндә генә кузгалдык... Моңарчы гел җиңеп килгәнгәме, кәеф бик каты кырылды. Күңелсез мизгелләр! Красная Горкага җитәбез дигәндә генә поездыбыз каршыга килүче паровоз белән маңгайга-маңгай бәрелде. Әллә диверсия, әллә бездәге гадәти хаталык, белмәссең, ярый әле, акрын бара иде, паровозлар сафтан чыкса да, үзебез исән калдык... Аннары Валерий Межлаук, Бакинский, тагын берничә иптәш Свияжскига кадәр элдердек.

Чигенү, шәһәрне калдыруның күңелсез маҗараларын искә алу һәр икесендә авыр кичерешләр кузгатса да, артык җебеп, хисләргә бирелеп утырыр чак түгел иде. Көч бар, бер мәлгә таралып киткән көчне тупларга да явыз дошманга ябырылырга гына кирәк!

— Монда хәлләр ничек?

Лацисның ярдәмчесе кырлы стаканнар белән чәй кертте, чәй тәлинкәсенә салып ике-өч телем ипи, вак-вак ватылган шикәр шакмаклары китереп куйды. Сүзсез генә бер-ике йотым чәй эчтеләр.

— Свияжск хәзер төрле якка тамыр җибәргән нык агачны хәтерләтә! Казан тирәсендәге иң өметле лагерьга әйләнеп бара. Үзәктән тотрыклы ярдәм килә башлады. Казан большевиклары Камил Якубов, Лев Милх нык ук ярдәмләшәләр. Чаңны вакытында кагып өлгердек, хәзер эш көйләнүгә таба бара.

Пешенә-пешенә чәй эчеп утырган элеккеге командармга шушы сүзләрне әйтте дә тыелып калды, «мактана» диюе бар... Вацетис нигәдер гафу үтенде.

— Кичер, тамак яна... Мин дә су төбендә түгел идем, мәгәр белгәннәрем өзек-өзек...

— Әйе, башта үтә кыен иде,— дип дәвам итте Лацис, ниһаять, үзенә хас ныклык белән.— Идел күперен саклап алып калырга кирәк, Свияжскиның үзенә дошманны якын китермәскә кирәк, бер үк вакытта тәмам таркалган гаскәрләрне тупларга, ашыгыч рәвештә өр-яңадан оештырырга кирәк иде! Эшләр кирегә сүтелеп китте, Казанны калдыру күпләрнең котын очырды. Ижевск белән Воткинскида контррево-

люционерлар фетнә күтәреп «Вакытлы Кама буе Комучы» игълан иттеләр. Тиз арада большевикларны турап барырлык ун меңкешелек гаскәр укмаштырдылар. Эсерлар коткысына бирелгән Ижевск һәм Воткинск заводы эшчеләре, Кызыл байрак тотып, Учредительное собраниене яклап, безгә каршы сугышка чыктылар![10] Гаҗәп тә, кызганыч та!

Мин моны бүген сиңа аңлата алмыйм, бәлки тарихчылар киләчәктә моның сәбәпләрен табарлар... Азык-төлек отряды командиры Степанов хыянәтче булып чыкты! Хыянәтченең дә явызы, комсызы, Малмыжның казнасын үзләштергәч, Уржумны һәм Нолинскины талап, һәммәсен кара җаяүгә калдырды, хезмәт хакы түләргә акча юк! Шундый ук саботажниклар аркасында Казан губернасының Курмыш һәм Ядрин өязләрендә контрреволюция дөрләп кабынды... Казанны калдыру көтелмәгән хәл иде, болары аңа ялганып китте. Болары шулай, мәгәр олы дөреслек шунда: без таркалмадык, күрерсез, Свияжскида гаскәр бар, алар монда очраклы гына тупланмады, көчләп тә җыймадык гаскәрне, алар дошманнан үч алырга атлыгып торалар! Бу хакта үзешчән шагыйрь үзенең «Казан» дигән поэмасында тапкыр фикер әйткән! Әдәби ягына кереп тормыйм, шагыйрь дөреслекне бик оста тотып алган! Кая куйдым соң әле...

Лацисның сөйләгәндә шигырь куплетлары, мәкальләр, фәлсәфи тәгъбирләр кыстырып җибәрергә яратканын белгән Вацетис, гәрчә мондагы шартларны тагын да киңрәк һәм тизрәк белергә ярсыса да, Мартин Яновичны бүлдермәде, аның Свияжскида чыга торган «Гражданская война» дип аталган газета номерларын анда-монда таратып тиз-тиз эзләвен сабыр гына көтеп торды. Лацис эзләгәнен тапмады, өзекне куен дәфтәреннән укып бирде. Шигырьне куен дәфтәренә үк теркәп куюын бүтәннәргә күрсәтергә теләми идеме әллә?

— Менә, тыңла!

> Нам неведом робость и страх:
> Мы кровью победу купили.
> Родившись в казанских боях,
> Стали мы мощной силой!

Зур көчкә әвереллек, Иоаким Иоакимович, хәзергә 5 нче Армиядә ун меңгә якын сугышчы, ике йөздән артык хәрби белгеч бар.

— Командующий кем?

Лацис кыска гына бер исемне яңгыратып «Славен» дип әйтеп салгач, Вацетисның көрсенүе сөенеч белән алышынды:

— Булдыра алырлык егет! — дип куйды.

— Данишевский Мәскәүдә булып, анда Ленин белән очрашкан.

Кая карама, иске танышлар, Карл Данишевский,— латыш, латыш дивизиясенең комиссары, Вацетисның җан дусты, алар Казанга бергә килделәр, Данишевский белән Вацетис ул чакта Көнчыгыш фронтының Реввоенсовет членнары иделәр.

— Ул да исән икән! — диде ул, тагын бер кат сөенеп.

— Ленин Казанны калдыруның бөтен ваклыкларын, шәһәрдәге хәлне бик җентекләп сорашкан. Казанны бирмәс өчен без ниләр эшләгәнбез, нәрсәне күреп житкермәгәнбез, татар авылларында уй-фикерләр кай тирәдә йөри, рус крестьяны кай якка авыша — берсен дә калдырмаган. Армия составы эшчеләр белән тиешле дәрәҗәдә тулыландырылганмы, алар Казанга ярдәмгә килергә нилектән соңга калганнар, Хәрби эшләр комиссариаты Казанга ярдәмне ник кирәгенчә биреп житкермәгән, кыскасы, Ленин барысын да белергә, ачыкларга һәм бергәләп нәтиҗә ясарга теләгән. Без капчыкта ятмый, Данишевский яшереп тормаган, Казан заводларында партия эше йомшак иде, фронт белән

[10] 1919 елда Ижевск дивизиясе Колчакның иң көчле гаскәри берәмлеге булып саналды. Колчак аны Георгий байрагы белән бүләкли.

партоешмалар арасында элемтә тиешенчә булмады, мәгълүм мәсәлдәгечә, кысла бер якка тартса, аккош кире якка талпынды, дигән Акгвардиячеләрнең Казандагы фетнәсен анализлап биргән. Татар авыллары аша үткәндә кулаклар кызыл отрядларга бик нык каршылык күрсәттеләр дип, аны күп санлы фактлар белән раслаган. Җыеп әйткәндә, армиядә таркаулык өстенлек алды, аерым группалар, эшче отрядлар, латыш укчылары гына актык сулышларына кадәр корал ташламадылар, актык сулышларына чаклы антларына тугры калдылар дигән.

Көнчыгыш фронттагы хәлләрне белешеп, аның язмышын Ленин үз карамагына алгач, хәлебез кискен үзгәрде. Яхшы якка үзгәрде! Иң кыйммәтлесе — фронт фронт булып калды! Димәк, безгә ышандылар. Һәм кискен бурыч та куелды. Казанны калдырган 5 нче Армия үзе үк аны азат итәргә тиеш!

Вацетис дулкынлануын яшереп тә тормады. Лацисның берүзенә күп кеше алдында чыгыш ясагандай пафос белән, күтәренке рух белән сөйләве дә ошады. Димәк, ул аңа ышана, кадерен белә...

Өстәлгә төрле төстәге уклар белән чуарланган, таушалган карта җәелеп ятты, икесе дә аның өстенә иелделәр. Лацис Вацетисның чуеннан коелгандай таза иңенә кагылып киткәч, елмаймый түзә алмады.

— Баһадир син, Иоаким Иоакимович!

Вацетис дәшмәде, тәҗрибәле күзләре белән картага йотылды.

— Иделнең ике ягыннан да аз-азлап акларны кысрыклый башладык. Менә бүген штабтан алынган мәгълүматлар. Безнең уңъяк ярда мең ярым штыгыбыз, дүрт җиңел һәм ике авыр орудиебез бар. Акларда мең ике йөз штык һәм дүрт авыр орудие! Сулъяк ярда исә безнең ике мең штык өстенә ике йөз житмеш кылыч, тугыз орудие һәм бер бронепоезд әзер тора! Акларда да бар бронепоезд. Аларда тугыз йөз штык, ике орудие. Сан ягына килгәндә, күрәсең, өстенлек бездә. Әлегә без күзгә бәрелерлек дәрәҗәдә таркау. Җиңелгән армияне яңадан кору — яңаны төзүгә караганда күп тапкыр кыенрак икән! 5 нче Армия белән берлектә Арча группасы — Владимир Азин житәкләгән 2 нче Армия сугыша. Идел флотилиясе көч җыеп килә, моряклар шактый активлашты, Балтыйк диңгезеннән миноносецлар килеп житте. Командирлары шәп, комиссарлары исә Николай Маркин.

— Егетне беләм. Казан белән элемтә ничек?

— Элемтә начар булса, акларның көче хакында шундый тулы мәгълүматлар бирә алыр идекме? Ендаков, Фролов һәм Таһировлар көткәнгә караганда да нәтиҗәле эш җәелдерделәр. Тик менә Красная Горка аша элемтә чуалып тора...

Вацетисның карашы картадагы Красная Горка ноктасында туктalып калды. Кыска арага урнашкан тынлыкны бозып, ишектән хатынкыз тавышы ишетелде һәм бүлмәгә Лариса Рейснер килеп керде.

— Бүген иртән сезнең хакта уйладым,— диде Лацис.— Мең яшәрсез.

— Нигә меңне генә? Мин мең дә берне яшәргә телим!

— Бер елы нәрсәгә багышланачак аның? — дип сорады Вацетис керүче белән кул биреп күрешкәч.

— Дошманнар ишәйде! Алардан үч алырга мең ел гына житмәс кебек... Җәһәннәмнән котылдым әле мин...

Аның шулай әйтүе дә, өчесенең Свияжскида очрашуы да үтә житди, үтә мөһим иде, әмма Лацис белән Вацетис — ике сәламәт ир бер генә мизгелгә дөньяларын онытып бу сылу, гүзәл һәм көчле рухлы хатынга сокланып карап тордылар. Һәркемне үтәли күрә алган коңгырт-яшькелт күз почмакларында ут уйный, коңгырт куе чәчләре тарасаң-тарамасаң күз явын алып елкылдый; ап-ак йомры беләкле куллар иркәләп туймаска яралган кебек тоелалар, әллә кайларга дәшәләр, әллә ниләр вәгъдә итәләр...

— Сөйләгез,— диде Вацетис елмая төшеп.— Җәһәннәмнән котылучылар арада бер сез генә түгел түгелен! Сезнең җәһәннәмдәниләр бар иде?

— Офицер хатыны булып киенеп Казанга барып кердем. Контрразведкадан җыландай шуып ычкындым. Свияжскиның ярты юлын чигән хатыны булып үттем.

— Утырыгыз,— диде Лацис. Рейснер утырмады, күңелендәге кайнауны туктата алмады:

— Казанга кайту белән бөтен шымчыларны, доносчыларны кырып бетерегез, Мартин Янович! Аеруча берсе, мине һәм бик күп башкаларны комучлар контрразведкасына тоттырган кеше — пристав Алексеев ычкына күрмәсен! Берүк! Адресын ачыкладым — Бишбалтада, Елга училищесыннан ерак та түгел, үз йорты белән яшәп ята хәшәрәт! Карагруһ, эшче иптәшләрне сата, барлык контрреволюцион оешмаларның эшенә бик теләп катнаша![11]

Лацис бу тарихны Рейснер авызыннан элегрәк ишеткән иде, сүзнең Вацетиска юнәлгәнен ул яхшы аңлады, әмма кыю һәм чая хатынның Алексеев турында әйтүе аның өчен дә яңалык иде. Ул сикереп торды:

— Андыйлар бездән котыла алмас! — дип кычкырды ул.— Үч сусап түгел, бөтәннәргә гыйбрәт өчен дә түгел, безнең кискенлектән дошманнар шәфкатьле булып уйнау заманы үткәнен ачык белсеннәр! Яхшылыкны яманлык белән чагыштырып үлчәп була! Алар икесе дә бер яссылыкта, бер тигезлектә була алмыйлар. Яманлык азрак булса да, аның тамыры тирәнгә китә, артык азынганчы аны йолкып ыргытыйк. Юкса намуслы чын кешеләрнең гомерен кыскартып, бәгырьләрен кимереп ятачак ул! Свияжск тирәсендә акларны туктаттык, хәзер кирегә кысрыклыйбыз. Батырлык монда романтик дәрәҗәгә менеп житте. Нәкъ безнең җырда әйтелгәнчә:

Вы — все в этом мире купили,
Мы — все в этом мире возьмем!

Килешү, килешенү юк. Безгә иң көчле усаллык та куркыныч түгел!

Рейснер утырмады, Вацетис тәкъдим иткән чәйгә дә үрелмәде. Лацис җыр өзеген укыганда аның күзләре шашкын ут, тыелгысыз ут белән тулып-тулышып янды, ул аркасы белән ишек яңагына сөялде дә, рухланып үзе шигырь укый башлады. Үз шигырен. Үзәккә үтәрлек итеп тәэсирләнеп укыды:

Ты зовешь, разорванный на части
Умирающий финляндский стяг.
Нальется на снега вино причастий
И на встречу обнаженной пасти
Гневно улыбается босяк.

Ул кинәт чыгып та югалды.

Вацетис белән Лацис Рейснер чыгып киткәч кенә кул чабарга өлгерделәр...

Лацис кызылларның бар булган көчләрен санаганда 5 нче Армиянең очучыларын санга-исәпкә кертмәде. Гәрчә очучылар гаҗәп дәрәҗәдә файдалы эш башкаралар, разведка ясыйлар, Азин отрядлары белән элемтә тоталар, дошман батареяларына бомба ыргыталар, листовкалар таратала. Командирлары революциягә җаны-тәне белән бирелгән кыю, батыр йөрәкле фанатиклар Константин Акашев белән Иван Павлов. Искереп, пуля тиеп кырык ямалган самолетларда һаман очалар,

[11] Алексеев А. А., 56 яшендә, 1918 елның октябрендә хөкем ителеп, 5 нче Армиянең хәрби-кыр трибуналы карары белән атылган.

әгәр Лацисның элекке командармга отчет ясаганда үзләрен онытып калдырганны белсәләр, алар бик каты үпкәләрләр иде. «Без аллалар, чөнки без күктә!»— дип кабатларга ярата Акашев.

Самолетлар шактый кыйммәтле информация биргәләп торсалар да, Лацис тулысынча канәгать түгел иде. Юк, очучылардан түгел, информация җитеп бетми иде аңа! Аның очасы, фронт сызыгын, юллардагы хәрәкәтне, Казан тирәсен үз күзләре белән күрәсе килә иде. Ул бу турыда ике-өч тапкыр сүз кузгатса да, Свияжск аэродромына урнашкан 23 нче авиаотряд командиры М. В. Сатунин озак карышты.

— Зенитчылар көннән-көн тәзрәк ата, Мартин Янович, аэропланнар таушалган, сезне очыртырга ярамас...

Тора-бара «латыш кирелеге» җиңде, бүген төштән соң, көн ачылса, Лацис самолетта очарга тиеш... Ул бу хакта штабта да, Вацетиска да белдереп тормады. «Кайткач белдерермен»,— дип уйлады.

Бәхеткә каршы, көн аязды, вак-төяк болытлар әллә кайда, Казан тирәсендә генә, тирбәләләр, ул машинага утырып аэродромга барырга чыкты, үтеп барышлый бер урында матросларның митингысына игътибар итеп, шоферга тукталырга кушты. Матрослар арасында басып торган Лариса Рейснерны күреп машинасыннан ук төште. Мәйдан өстендә Ларисаның яңгыравыклы тавышы чыңлап тора иде.

— Братва! — дип яратып эндәште Рейснер.— Күрәм, шәп һәм батыр егетләр сез! Берегездән берегез шәбрәк сайланган. Табигать сездән берсен дә кызганмаган! Миңа Казанда булырга һәм акгвардиянең безнең туганнарны, кардәшләрне ничек кыруларын үз күзләрем белән күрергә туры килде. Моны бер чакта да онытырга ярамый! Беркемгә дә! Мин котылып фронт сызыгын кичеп чыга алдым. Мин тагын сезнең арада! Үз иптәшләрем арасында... Сезнең белән очрашу, моряк дуслар арасында булу — чын сугышчан рухны кабат тою ул! Бәхетлемен! Идел-йорттан дошманны куарга кирәк. Яңадан баш калкытмаслык итеп дөмбәсләргә кирәк аны! Җитәр! Явызланган, котырынган дошманнан үчебезне алыйк! Сезгә сугышчан уңыш телим! Мин сезнең янда, алгы сызыкта да янәшәгездә булырмын.

Гөлт итеп кул чабулар кабынды да сүнде, кемдер ачы итеп сүгенеп җибәрде. Лацис уртага кереп морякларны оялтырга җыенган иде, мәйдан өстен тагын яңгыравыклы ачык тавыш күмеп китте.

— Сүгенү безнең батыр әнкәләребезнең исеменә пычрак ату булып яңгырады. Сүгенергә телисез икән, рәхәтләнеп, авыз тутырып, кинәнеп кан эчүче ак хәшәрәтләрне сүгегез!

Бу юлы мәйдан өсте кул чабулардан тетрәп китте, матрослар язын араннан болынга чыккан яшь тайлар кебек кешни-кешни, бөгеләбөгелә кул чабалар иде.

Самолетны стартка дүрт кеше тәгәрәтеп чыгардылар. «Суык тимәсен!»— дип Лациска күн куртка киерттеләр, башына махсус очкыч каскасы чәпәп куйдылар. Ул «Форман-30»ның гондоласындагы алгы урынга көчкә сыеп утырды һәм, башын астагы иптәшләргә борып, салкын, коры тавыш белән:

— Ә бомбалар? — дип сорады.

— Нинди бомбалар?

— Аклар өстеннән очканда мин аларга кылыч айкап күрсәтимме?

«Бомба ташлау өчен күнегүләр кирәк, хәвефле эш ул!»— дип аңлатып карады Сатунин, Лацис белән якыннан аралашмаса да, аның кирелеге, үзсүзле булуы турында күп тапкырлар ишеткән кеше буларак, кулын гына селекте. Тиз арада китереп тә җиткерделәр. Лацис бомбаларны утыргычның ике ягына да куелган чиләкләргә тутырды. Моторны кабызып, эшләтеп карагач, самолетны як-яктан тотып торган кешеләр төрле җиргә сибелделәр, тыр-пыр килеп ике-өч мәртәбә алга талпынгач, ул кузгалып китте һәм пөҗегән үләнле алан өстеннән җитез генә йөгерә башлады.

Күз алдында иң әүвәл Идел ачылды.

Сулда — Идел күпере. Зеленый Дол, Красная Горка станцияләре. Красная Горкага житәрәк, урман авызыннан акларның зениткалары ата башлауга очучы самолетны Идел ягынарак күчерде. Станциядән аткан зениткалар да тидерә алмады. Менә Казан пристане. Шул тирәгә ашкына иде Лацис, шул бәхетсез ярларны күрәсе килгән иде. Оборонаны юньләп оештыра алмадылар!..

Пароходлар ярдан шактый ерактa якорь салып тукталганнар. Самолет якынлашкач, баржалардан нидер бушатучы ак солдатлар ярга чаба башладылар. Тыр-тыр, абына-сөртенә йөгерәләр, егылалар. Лацис бер бомбаны йөгерешчеләр өстенә, икенчесен пароходка турылап ташлады. Ярда ут, төтен, әмма пароходка тидерә алмады, «тәҗрибә юк!» дип уфтанды Мартин Янович, көрсенеп. Пристань өстен урап чыкканнан соң алар Югары Ослан аша үтеп аэродромга борылдылар. «Вакыт»,— дип аңлатты очучы, нидер хәбәр итәргә тырышып. Ягулык аздыр, дип аңлады Лацис һәм Югары Ослан ярында торган хәрби катерларга соңгы бомбаларын ыргытты.

Моңарчы кәгазьләрдән күреп, телдән сөйләнгән ярларны, дошман пароходларын үз күзләре белән күрде. Сергей Сергеевич, Ендаков, Таһиров һәм башка тугры иптәшләрдән килгән, килеп торган донесениеләр, Казанда акларның кылган эшләре, Лариса Рейснерның үз гомерен куркыныч астына куеп комучларның явызлыгын күреп кайтуы, ниһаять, аэропланнан күзәтүләр, акларның хуҗа булып Иделдә рәхәтләнеп йөзә алулары, Казанга баржа-баржа корал ташулары — һәммәсе-һәммәсе Лацисның кызган күңелен тагын да ярсытып җибәрде. Ул шул көнне үк чекистларны, контрразведка хезмәткәрләрен, командирларын җыеп әйтәсе сүзен батырып әйтте:

— Контрреволюционерларны мөртәт дип исәпләп, җәлләмичә кырырга кирәк. Ниһаять, озакка сузылган бәхәсләрдән соң, ВЦИК илне хәрби лагерьга әйләндерергә карар бирде! Ишетәсезме, озакка сузылган бәхәсләрдән соң! Алай озакка сузмаска да була иде! Карар нигезендә бөтен гражданнар ил сагына басарга тиеш. Дзержинский тәкъдиме белән Халык комиссарлары советы акгвардиячеләргә, фетнәчеләргә һәм заговорчыларга каршы кызыл террор игълан итә! Вакыт, дошманнар белсен: һәр түземлелекнең чиге бар, безгә каршы һәр кузгалышның тамырына балта чабарга, кайчаннан бирле корал тотып безне тинтерәткән контраның башын изеп узарга! Көне килде! — Лацис кесәсеннән куен дәфтәрен тартып чыгарды, тиз-тиз актарды, сул кулының юантык имән бармагы белән кисәтә-кисәтә, һәрбер сүзгә, һәрбер тынышка аерым басым ясап язганнарын укып чыкты:— «Дошманнан, советларга корал яки сүз белән каршы чыкканмы, дип төпченеп маташмагыз, кирәкми. Иң әүвәл сез дошманнан кайсы сыйныф вәкиле икәнен белешегез, атаанасы кем, белеме һәм һөнәре нинди? Шулар җиткән. Шушы сорауларга җаваплар гаепләнүченең язмышын хәл итәргә бик җиткән! Кызыл террорның эчтәлеге шунда!»[12]

Иске тәртипләрне кабат кайтарырга маташкан буржуаны да, Казандагы учредиловчыларның һәм легионерларның табанын ялаучы кабәхәт меньшевикларны да көл итәчәкбез! Көл! Сөремнәре генә күккә күтәрелер! Әйе, элек тә, хәзер дә без эсерлар куәтләгән «ялгыз террор» актларына каршы, мәгәр уйлашыйк: тарихта берәр революция үлемсез-кансыз үткәнме? Тарихта чәчәкле гражданнар сугышы бармы? Дошманнар безнең шаярып маташмаганны аңлагач, хәл бераз яхшыруга ук, без бу чараны туктатырбыз. Электә римлеләр консулларына: «Дәүләт үзе утырган ботакны кисмәсен!»— дип аң бирә торган булганнар. Без кызыл террорны илдәге эшче-крестьяннар хакына башкарырбыз!

---

[12] В. И. Ленин Лацисның бу тезисын «мәгънәсезлек» дип атады. «Кызыл террор үз властьларын расларга тырышкан изүчеләрне көчләп бастыру икән, аларны гаепләр өчен дәлилләр кирәк»,— дип язды Ленин.

Лацис туктады, тып-тын, ни өчендер ул Фаустның Мефистофельгә җавабын хәтерләп, шуны яттан укып бирде:

> Великое разрушить ты не мог,
> Тогда по мелочам ты начал разрушение.

— Юк, юк, без вакланып тормабыз, монда сүз кыска, сүз бер генә: я алай, я болай — башка юл юк! Без яңа тормыш кора башладык, яңалыкны кертү һәр очракта да авыр, җимерү ансатрак, «корабыз» дибез икән, бу искиткеч бай эчтәлекле чакыру, сүз революциянең язмышы, пролетар дәүләтнең киләчәге турында бара! Аң булыгыз — революция куркыныч астында. Гадәттән тыш көрәш — гражданнар сугышы кызып кына бара, газета-журналларга күз ташлагыз, алар яшәүсөенеч, мәхәббәт, җаныңны урап алып кереп китәрлек кайнар хисле әсәрләр басасы урынга, үлем, үтереш, террор хәбәрләре белән тулып чыгалар. Бер-беребезгә бары тик мәхәббәтле күз белән генә карарга иде дә, ул көн еракмыр шул әле! Тик без аны якынайтырга тырышачакбыз!

Чека кыска гына арада Свияжскида үзенең көчләрен туплады, ныгытты, революциягә бирелгән куркусыз кешеләрне җыйды. Тылны контрреволюционерлардан арчу буенча 5 нче Армиянең контрразведкасы нәтиҗәле эшли башлады. Аны Иван Петрович Павлуновский җитәкләде. 1905 елдан большевик, дөнья сугышында поручик, дары исен иснәгән, окоп хакыйкатен татыган кеше, хәзер тәҗрибәле контрразведчик. Арча-Казан-Свияжск сызыгында элемтә ныгыды, тотрыклы һәм ышанычлыга әйләнде. Азин разведкасына аерата хезмәт күрсәткән иптәшләрдән Казан тукучысы Евдокия Леонтьеваны, мәзин улы, 1907 елдан большевик Мәхмүт Дулат-Алины күрсәтеп узарга кирәк.

Павлуновский Хәбибулла Вәлиуллин белән Илдар Насыйровның эшен аерата югары бәяләп, рәхмәт әйтеп Лацис янына махсус кереп чыкты. Бу кыю чекистлар тырышлыгы аркасында Свияжскидагы шпионнар оясы ачылды һәм 5 нче Армиянең хәрби-кыр суды ояның төп җитәкчеләрен атарга хөкем итте. Арада исправник ярдәмчесе, монархист Пульхеровский, элеккеге офицер монархист Мухоротов, управа хезмәткәре монархист Васильев, Свияжскида почта бүлеге начальнигы Попов һәм башкалар бар иде. Шактый эш майтарган бу кара йөзләр, шәһәрдә контрреволюцион чыгыш әзерләп ятканнар, Каппельгә туктаусыз шифрлы телеграммалар яудырып, җыйган разведка мәгълүматларын комучларга озатканнар.

Илдар Насыйров Лацис боерыгы белән Буа өязенең Турган-кассы авылына барып кайтты. Анда мондый канлы фаҗига булып узган. Атлы тугыз кызылармеец авылда кунарга туктаган. Васильев фамилияле крестьянда чәй эчеп болар йокларга ятканнар. Иртән, унбишенче августта, авылга аклар керә. Алар башта дневальныйны, аннары бүтәннәрне аталар. Берәү авыр яраланып исән кала, тагын бер кызылармеец тәрәзәдән чыгып кача. Аклар киткәч, крестьяннар кызылармеецларны күмәргә җыеналар. Качып котылган кызылармеец та урманнан кайтып керә. Шунда, һич уйламаганда, йорт хуҗасы Васильев урманнан кайткан кызылармеецны искәрмәстән, яралыны халык күз алдында атып үтерә. Үзе Сембергә чыгып кача. Насыйров эшне ачыклый, кулакның мал-мөлкәтен конфисковать итеп, гаиләсен төяп Свияжскига алып кайта. Хәзер түземсезлек белән явыз дошманның эзе беленгәнне сагалап йөри, «Тавышы гына чыксын, мин аны җәһәннәмнән барып булса да табам!»— дип кабатлый...

Казаннан килгән даими донесениеләр белән Казанда чакта ук шактый күренекле эшләр башкарган чекист Вәлиуллин да таныша барды, комучларга һәм акгвардиячеләргә турыдан-туры хезмәткә ялланган хыянәтчеләрнең шактый булуын күреп, йөрәге әрнегәч, ул Лацис янына бер тәкъдим белән керде.

— Мартин Янович, бер киңәш бар иде миндә,— диде ул.
— Әйт, Вәлиуллин.
— Менә без соңгы атнада гына чекага байтак кеше алдык.
— Шулай.
— Озаклап, ижекләп тикшереп торыр вакыт түгел. Һәрбер чекист эшкә алыныр алдыннан ант кабул итсен.
— Бар андый ант, тексты да әзер,— дип аңлатты Лацис Вәлиуллинга бик җентекләп карап.
— Кайда ул?
— Антта Дзержинскийның «чекист намуслы, саф һәм нык булырга тиеш», дигән таләпләре язылган.
Вәлиуллин антны күчереп алды да бераздан янадан Лацис янына кереп, өстәленә эре-эре хәрефләр белән язылган кәгазь китереп салды.
«Мин, Вәлиуллин Хәбибулла Вәлиуллович, 1897 елда Екатеринбургта туган татар, 1917 елдан большевиклар партиясе әгъзасы, үз өстемә түбәндәге бурычларны алам һәм шул хакта имзамны беркетәм:
1. Көнчыгыш фронтның чека хезмәткәре буларак намуслы һәм таләп ителгән дәрәҗәдә эш итәчәкмен.
2. Совет властен нык яклаучы җитәкчеләремнең бар кушканнарын һәм боерыкларын үз вакытында җиренә җиткереп үтәрмен.
3. Ныклы тәртип саклармын.
4. Дәрәҗәмә лаек дип кушылган һәр эшне ахырынача төгәл башкарырмын.
5. Контрреволюционерларның һәр төрлесе белән аяусыз көрәшермен.
6. Үз хезмәтемнең абруен саклармын, телемне тыеп, чеканың миңа мәгълүм операцияләре турында беркемгә авыз ачмам.
7. Кушылган һәм тәкъдим ителгән урыннарда гына урнашырмын.
8. Намуслы, әдәпле, аек, эшлекле, хезмәтемдә һәм аннан тыш илтифатлы булырмын.
9. Хезмәт урынымны һәм исемемне беркемгә дә ачмам.
10. Югарыда саналганнарның бер генә сызыгын бозсам да закон нигезендә суд һәм иптәшләрем алдында җавап тотачакмын».
Аста Вәлиуллинның имзасы куелган иде.
Лацис бу риясыз, сабыр акыллы, төгәл һәм пөхтә, батырлыкка һәрчак әзер торуы күренеп торган кешенең ихлас сүзләрен укып чыкканнан соң аның кулын ирләрчә, нык итеп кысты.
— Мартин Янович,— диде Вәлиуллин бераз тынычлангач.— Казандагы иптәшләр байтак донесениеләрдә Щукинның шәһәрдә калуына аерым игътибар иткәннәр. Таһиров аны юк итәргә дә ниятләгән. Аны Казанда сезнең боерык белән калдырдылармы?
— Аны махсус мин үзем калдырдым...

Вәлиуллинга шактый җиңел генә җавап бирсә дә, Лацисның күңеле бу уңайдан бер дә тыныч түгел иде. Казанда калган чекистлар арасында хыянәтче кысылуы хәзер сер түгел, беренче көнне үк. Таһиров очрашырга барган элемтәченең билгесез үлеме. Иске Аракчинода балыкчы-элемтәченең эзсез югалуы, тагын бик күп, берсенә берсе өстәлгән тәшвишле вакыйгалар шуны раслыйлар! Свияжскидан торып хыянәтченең эзенә төшү авыр, ә шәһәрдә калган иптәшләргә хыянәтче барын белеп яшәү тагын да кыенрак. Алар искиткеч катлаулы, күнегелмәгән шартларда дошманның күңеленә үтеп керә белергә тиешләр. Шул чакта пычагын әзерләп артыңнан сатлык җан барсын әле!
Чекистларны шулай алдый алган бәндә кем ул? Кем?
Фролов белән Таһиров, дәлилләргә таянып, «Хыянәтче — Щукин!» — дип раслап баралар. Дөресме бу фикер?!
Щукин Михаил Александрович. Лацис Казанга килеп төшеп, җирле чекистлар белән танышканда ук бу кешегә игътибар иткән иде. Озын

төз буй, хәрбиләрчә күркәм, солтанатлы чибәр егет чекада писарь хезмәтен башкара икән. Мартин Янович аның фамилиясенә һәм күперэп торган купшы мыекларына игътибар итте: «Кырып ташлагыз, чекистның мондый билгеләре булырга тиеш түгел»,— диде.

— Офицермы? — дип сорады ул аннан.

— Унтер.

— Казанда күптәнме?

— Унжиденең көзеннән, иптәш Лацис.

— Ничек килеп чыктыгыз?

— Яраланып госпитальгә монда эләктем.

Аның ачык сүзгә керешеп китәргә ашыкмавы беленеп китте, сорауларга Щукин теләр-теләмәсрәк, кыска-кыска җавап бирде. Шунысы ошамадымы әүвәл Лациска, әллә купшы, хушбуй исе аңкыган мыекларымы?! Тормыш юлында алай шикләнерлек нәрсә юк, сүзгә саран, телгә коры, болар чекист өчен кирәк сыйфатлар. Шулай уйласа да, Щукинның кай ягыдыр аңа бер дә ошамады...

— Каян килдегез? Әти-әниегез кем?

— Полтава ягыннан, украин мин, әтием тегермәнче.

— Партиядәме?

— Унжиденче елның көзеннән большевиклар партиясендә торам.

— Исем-фамилиягез, әтиегезнең исеме русныкы. Моны ничек аңларга?

— Чын фамилиям Щука, Михась Олексович. Россиядә кулайрак булсын дип рус фамилиясе алдым. «Щука» шундук игътибарны җәлеп итә.

Беренче очрашу шулай булды. Лацис белән бүтән очрашуларда Щукин нинди юллар белән булса да күләгәдәрәк калырга омтыла иде. Моны да сизде Мартин Янович.

Ничек килеп капты соң әле бу чуртан балыгы?!

Лацисның хәтеренә тагын бер сәер очрашу килеп төште.

Казанда чакта кабул итүне бик үтенеп чекага бер бәндә килеп керде, үзен Украина Үзәк Радасы вәкиле итеп танытты һәм илгә кайтырга теләгән милләттәшләренә Казаннан китәргә ярдәм итүне сорады. «Украина Халык республикасы дип игълан ителде, бәйсез дәүләт һәм көчле Украина төзер өчен гетман Скоропадский милләттәшләрен өйгә дәшә!» диде.

Бу чәрәшеп каткан «самостийник»ны ярты сүзеннән куып чыгарып була иде, мәгәр, һәр кешедән нидер эзләгән, еш кына таба алган Лацис бу кешене дә иренмичә тыңлады. Ни сөйләшенгәндер ул чакта, хәтердә калмаган, Лацис бер нәрсәгә игътибар итте: теге кош Казан чекасының эшен шактый ук яхшы белә булып чыкты, белү генә түгел, сүз дәвамында җаваплы чекистларны исеме, әткәсенең исеме белән дә атап җибәрде.

— Сез алар белән яхшы таныш ахрысы?— дип сорады Лацис, гадәтенчә кинәт һәм көтелмәгәндә.

— Юк.— Кыю бәндә беренче тапкыр кызарынып, югалып калды.

— Исемнәрен дөрес атыйсыз. Инде шәхсән таныш түгел икән, кемдер сезгә аларны атаган. Сез алар турында күп сөйләшкәнсез һәм сөйләшәсез. Шулаймы?

Пан-милләтче куырылып төште, әмма ачылмады, аңа сугыш заманы икәнен искәртергә, әгәр дөрес җавабын кызганса, Казаннан түгел, чека бинасыннан да чыгып китә алмаячагын аңлатырга туры килде. Ниһаять, «самостийник» мәлҗерәп төште, тезләнеп ялварды, күз яшьләре елга булып акты, Лацисҡа: «Бу исемнәрне миңа Щука әйтте, ул!»— дип язып бирде.

Щукин-Щука нык бикләнгән йозак булып чыкты, милләттәше сыман эреп акмады, карышты, карулашты, боргаланды, акланырга мең сәбәп эзләде. Әмма җеп Лацис кулында иде, якташы язып калдырган, имза,

дәлилләр белән көчәйтелгән бер битлек кәгазь хәйләкәр чуртанның кәфене икәнен ул яхшы аңлады.

— Сайла! — диде Лацис көл чырае кергән Щуканы каршысына бастырып.— Хыянәтең өчен ата алам! Казандагы украин милләтчеләренең яшереп эшен фаш итәргә боера алам! Оператив максатларымны тормышка ашыручы агентым итү хокукым да бар. Күрәм, син таш астыннан чыккан балык, сайла!

Лацисның ике төрле сөйләшмәвен яхшы үзләштергән Щука аның соңгы тәкъдимен сайлады, «гомерем буе тугры һәм файдалы хезмәт итәрмен», дип ант эчте. Алдагы хезмәттәшлек турында Лацис аннан расписка алды һәм чигенер алдыннан шәһәрдә калырга боерды. «Комучларга хезмәткә кер, урнаш, кирәкле мәгълүматларны көне-сәгате белән безгә житкер!»

Мартин Яновичның актыкка боерыгы шул иде.

Щукин исән калуына бер сөенсә, комучларга якынай дигән тәкъдимгә ике сөенде, ул актив эш җәелдереп җибәрде: шәһәрдән киткән чекистлардан берничәсенең гаиләсен сатып тиз арада комуч контрразведкасының ышанычын казанды, сеңде. Лациска шактый мөһим хәбәрләр җибәргәләде. Бу мәгълүматлар Николай аша тикшерелде һәм расланды. Полковник Каппельның кызыллар тупланган һәм вакытлыча ныгыган Свияжскига һөҗүм-рейд әзерләве турындагы куркынычлы хәбәр иң башлап Щукиннан килгән иде.

Вахитовны һәм кайбер башка революционерларны коткару операциясенең барып чыкмавы, аларның бер-берсенә охшаш шартларда уңышсызлыкка дучар булуы, шәһәрдә тәҗрибәле провокатор бар дигән шикне бермә-бер көчәйтте, бу хакта Сергей Сергеевич Фролов Лацисны гел кисәтә килде. Вахитовны һәм бүтән иптәшләрне коткару операциясе планнары бик аз санлы, үтә ышанычлы кешеләргә генә мәгълүм иде, табигый буларак, шик тагын Щукинга барып житеп тукталды.

Каппельның һөҗүм рейды хакында алдан ук белеп торсалар да, анда да кызыллар чак кына оттырмады. Ничек алай булды, нигә? Кызыллар белгән кебек үк, Каппель да аларның йомшак якларын, ваемсызлыгын белеп торганмы? Бу мәсьәләнең азагы да артык дәрәҗәдә серле, шикле һәм караңгы иде...

Хәлиулла Вәлиуллин сүзләре Лациста менә нинди уйлар кузгатты...

«Революция куркыныч эчендә!» «Революциягә куркыныч яный!» Бу сүз, юк, сүз генә түгел, җан авазы, кисәтү, дәһшәтле чакыру теллә дән-телләргә күчеп һаман яши, һаман хәвефлерәк төс ала бара. Казан — акгвардиячеләрнең, комуч гаскәрләренең һәм чит ил легионерларының бердәнбер өмете булып кала бирде. «Революциягә куркыныч яный!» икән, аны коткарырга кирәк. Революциягә кабер казучылар төрле фикердәге, төрле җирдән җыелган чуар төркемнәрдән тора иде. Революциянең кан дошманнары Борис Савинков, Ильяс Алкин белән ахун хәзрәт, күпчелек очракта бер-берсен күреп белмәсәләр дә, кулга мылтык эләккәч бер мишеньгә — революциянең йөрәгенә төбәп аталар иде. Революция сакчылары чекист Лацис белән Сергей Сергеевич Фролов, Хәбибулла Вәлиуллин белән Гайнулла Таһировлар да әзерлекләре, белемнәре, тормыш тәҗрибәләре ягыннан бер-берсеннән шактый ерак торсалар да, аларны да төп нәрсә — революциягә мөнәсәбәт ныклыгы берләштерә иде. Савинковлар, Ильяс Алкиннар шашып, ашкынып революцияне буарга маташканда, Мулланур Вахитов аркылы алдынгы татар зыялылары дөньяны яхшыртырга, аны нәҗес контрреволюционерлардан арчырга омтылалар иде. Әйе, Савинковлар, Каппельләр, генераллар, полковниклар дөньяда Фатих Әмирхан барлыгын, бәлки, белмәгәннәрдер дә, ярлы карчык Сәҗидә Салиховнаның үзе аңлап бетермәгән хәлдә дә революциягә файда китерергә тырышканын уйлап та карамаганнардыр, мәгәр алар бар иде. Фатих Әмирхан да, аның энесе Ибраһим да,

Сажидә Салиховна да дөньяда барлар, тереләр, аңлылар, якты күңеллеләр иде. Дошманнарны да, аларның дошманнары булган кызылларны да бер нәрсә уртак мәйданга берләштерде: революция. Революция — халыклар язмышында авыр чор, сыналу чоры, кыенлыклар аша чыныгу чоры.

Иң хәтәре август азагында, утызынчы числода, эсерлар Ленинга аткан көн булды. Свердлов сүзләре белән әйткәндә, «революциянең йөрәгенә аткан көннәр». Ул көннәрнең хатирәсе истәлекләрдә, телеграммаларда, шаһитларның язмаларында сакланып калган.

Көнчыгыш фронттан телеграмма: «Владимир Ильичның ярасы — безнең яра. Аның авыртулары безнең йөрәкләрне дошман ядрәләренә караганда ныграк яндыра».

5 нче Армиянең политбүлегеннән: «Почмактан торып мәкерле атуга безнең җавап штыкка штык булачак! Кискен көрәштә дошманны пыр туздырып, акгвардиячеләрнең соңгы өмете булган Казанны шушы көннәрдә үз кулыбызга алачакбыз! Дошманга рәхим-шәфкать күрсәтмәбез!»

«Гражданская война» газетасыннан: «Иптәш Ленинга ату акгвардияче бандаларның һәлакәте булыр! Юлбашчыбызга хыянәтчел атуга Казанны алу белән җавап бирәчәкбез!»

5 нче Армиянең политбүлек начальнигы урынбасары В. Каюровның митингта чыгышыннан:

«Ленин яраланганнан соң армия тыгызлана төште, тәртип күзгә күренеп ныгыды, без чын регуляр гаскәргә әверелеп барабыз. Бәлки, революцион армиянең мондый уңай үзгәрешләре башка бер сәбәпләр белән аңлатыладыр? Бәлки, тәртип ныгу очраклы бер хәлдер? Бәлки шулайдыр да. Әмма мин бер нәрсәгә ышанам: Ленинга ясалган һөҗүмнең бик күпләргә рухи тәэсирен бәяләп бетерү мөмкин түгел. Гаскәр арасында болганыбрак йөргән эшчеләрнең дә күзе ачылды, эсер-меньшевикларның революцион өндәмәләренең ни хак торганын, ниһаять, алар ап-ачык күрделәр. Икеләнүчеләрнең күзеннән пәрдә төште! Ленинга уң эсер Каплан атты. Чекада җавап алганда ул Петерска Учредительное собрание яклы икәнен, Самара Комучына тартылуын икърар итте[13]. Ленинның каты яралануын, Петроград чекасы председателе Урицкийның үтерелүен Казан эсер-меньшевиклары алкышлап каршыладылар. Меньшевистик газета «Рабочее дело»: «Кылыч күтәргән — кылычтан үләр» дип куанып язып чыкты. Эсерлар, кадетлар бу җөмләне һау-һаулап теллөрдән телләргә тапшырдылар».

Кайнап торган дөньяда Борис Савинков та бар бит әле, онытмадыгызмы? Мондый чакта, Казан тирәсендәге болганчык суда балыкны мул тотарга форсат ачылганда, андый кеше Казанны читләтеп узамы соң?! Фикеребез ышанычлы, сүзебез рас булсынга сүзне Савинковның үзенә бирик әле. Дөньяга мөнәсәбәттән, августның ул көннәрендә ниләр кичерүен, әйдә, үзе бәян итсен!

«Ярославльдә һәм Муромда безнең восстание тәмам тузгытып бастырылгач, мин, алдан билгеләнгән җыелу үзәге Казан каласына юл алдым. Мәскәү оешмасының бер өлеше элегрәк үк Казанга эвакуацияләнгән иде, гомумән, әгәр восстание барып чыкмаса, исән калганнар шунда тартылсын дип килешенгән иде. Мин дә шул сәбәпле Казанга сәфәр чыктым, авыр, мәшәкатьле һәм уравыч юл иде бу, чыны шулай! Әйтик, юлда мине берничә тапкыр кулга алдылар, сораштылар, ләкин танымадылар, җибәрделәр һәм мин теләгемә ирешеп Казанга барып та җиттем. Үзем әзерләгән документлар ярдәм итте, сораганнарга шул кәгазьләрне күрсәттем. Совет властеның җаваплы вәкилләре белән очрашкаларга да туры килде, мәсәлән, Ядринск авыл советы рәисе белән рәхәтләнеп,

---

[13] 1918 елның 4 сентябрендә «Известия ВЦИК» газетасы хәбәр итә: «Кичә ВЧК карары белән иптәш Ленинга аткан уң эсер Фанни Ройд (Каплан) атылды».

күзне күзгә терәп сөйләштек. Мине тоткарлау аның башына да килмәде. Хәтта миңа чын документлар әзерләп бирде, өстәвенә акча да тәкъдим итте. Бар бит безнең бәхеткә беркатлы адәмнәр! Мин күрер күзгә гади, әмма бик ышанычлы документ белән йөрдем. Анда мин Наркомпроста хезмәт итүче, Вятка һәм Уфа губерналарына ятим калган пролетариат балаларына колонияләр оештырырга баручы булып күренә идем! Балалар дигәндә совет власте юлда тоткарлап тормас дип уйладым һәм ялгышмадым. Ядринскида сак астында бер кич кунгач, иртән үк «Кайда советыгыз, мине шунда озатыгыз!»— дип үтендем, алып баручы кызылармеецтан юлда барын сорашып белдем, совет рәисенең исем-фамилиясен хәтеремә сеңдердем, кыю гына барып кердем, фәлән-фәләнечнең исемен атап, «Шәһәрегездә мондый ныклы тәртип булуына куанам һәм котлыйм»,— дидем, рәиснең кулын кыстым. «Нинди тәртип?»— дип сорады ул, гөнаһсыз күзләрен тутырып карап. «Кичкә кырын чит кеше урамга килеп керүгә, аны кулга алалар. Мәскәүгә яки Петроградка кайткач, мин бу хакта югарыда хәбәр итәрмен!». Кем яратмый мактаганны?! Ул шунда ук эреп төште, мин күрсәткән документларны өйрәнә башлады. Документта: «Наркомпрос бу иптәшкә һәр төрле ярдәм итүегезне үтенә»— дип язган идем. Шул урынга житкәч, ул такыр башын калкытып: «Ә без нинди ярдәм күрсәтә алабыз?»— дип кызыксынды. Әз-мәз уйлап тордым да: «Күрәсез ич, мин Петроград документлары белән йөрим, аны һәркем аңлап бетерми, бар жирдә дә сезнең кебек зирәк житәкчеләр юк, әгәр сез миңа жирле документ бирсәгез, миңа юл йөрү һәм ватан алдындагы изге бурычымны үтәү бермә-бер жиңеләячәк. Мәскәүдә яки Петроградта бу хакта да хәбәр итми калмам!»— дидем. Ул секретарен чакырып миңа «бик яхшы документ» әзерләргә кушты, юлга акча кирәкмиме, дип сорады. Мин: «Кирәкми, рәхмәт»,— дидем. Соңыннан фронт аша ничек үтеп чыгарга мөмкинлеген белештем, кирәге чыгар дип, аның ярдәме белән ат сатып алдым, шул атка бик һәйбәтләп менеп, яхшы документны түш кесәмә тыгып киткәндә мин такыр башлы рәиснең кайнар кулын иптәшләрчә кыстым...

Казанда эсерлар. Учредительное собрание комитеты хужа булып утыра. Килүемә, беренче нәүбәттә, мин үз кешеләремне, оешманың исән калган әгъзаларын жыйнап алдым. Алар алдында чыгыш ясап, оешманы таратуымны белдердем. Бу хакта рәсми рәвештә эсерларга да житкердем. «Мин бары тик большевиклар белән генә сугышам; әгәр кем дә булса Россиядә иске тәртипләрне кайтара ала икән, миннән хәерфатиха, кулыгыздан килсә, әйдә, тырышып карагыз»,— дидем. Эсерлар юморны аңламады, алар миңа шикләнеп һәм куркып карадылар. Гомуми тәэсирләргә килгәндә, Керенский заманында илдә ни булса, Казанда нәкъ шул хәл икән, кая барма, оборона турында гәпләшәләр, белгәнебелмәгәне хәрби стратегиягә барып тыгыла, ялкынлы речьләр сибәләр, шайтан түе...

Хәрбиләрдән дә, сугыш эшеннән ерак торганнардан да акыллы фикерләр ишетергә туры килгәләде. Армия таркау, солдатлар кача, беркем дә юньләп сугышырга теләми. Эсерлар крестьяннарны үзләренә каршы куя торган чаралар күрде, дип зарланучылар очрады, чаралары нинди булгандыр, тәгаен белмим, мәгәр ишеткән кадәресе саруымны нык кайнатты. «Сугыш, фронт!» дип шапырынгач, мин халык армиясе дигәннәре оешкан, көчле гаскәри берләшмә дип күз алдына китергән идем, һәммәсе коры куаныч икән, сугыш кырында Халык армиясе вәкилләре юк диярлек, бары тик ирекле язылганнар һәм безнең оешма офицерлары гына әз-мәз көч куеп, сугышып маташалар. Менә шундый хәлләр!»

Сергей Сергеевич Фроловтан Лациска донесение.

«Яшерен!

22 августта Казанга Борис Савинков килеп төште. Ялгыз түгел. Кайда очрашып, ничек тупланганнардыр, аның белән бергә «Ватанны

һәм ирекне саклау союзы»ның тышкы эшләр начальнигы журналист Дикгоф-Деренталь, Ярославль палачы полковник Перхуров, аның ярдәмчеләре Ивановский, Березовский, барлыгы илле кешелек отряд килде. Муромнан доктор Григорьев отряды килеп аларга кушылды. Гарнизон начальнигы генерал Рычковка визит ясадылар, бүләкләр тапшырдылар. Нәтиҗәдә, Казан фронтының җиде участогын берләштереп (начальникларының дүртесе Савинков «Союзы» әгъзалары) полковник Перхуров Казан укчылар бригадасы оештырырга кереште. Чека тарафыннан байтактан эзләнә торган Пинку Казанда калган латыш укчыларыннан учредиловчыларга турылыклы «Латыш батальоны» төзи. Рычковның адъютанты Флегонт Клепиков.

Полиция полковнигы Деммерт тирәсендә шәһәр монархистлары җанланып маташа.

Француз хәрби миссиясе члены капитан Мариус союзникларның Казандагы тулы вәкаләтле вәкиле булып санала һәм сугыш эшләрендә житәкчелектә катнаша.

Алтын төяп китәргә Самарадан Казанга ике пароход килде.

Николай һәм Щукин, икесе аерым-аерым рәвештә, шушы көннәрдә Каппельның Свияжскига һөҗүм-десант ясау ихтималы турында хәбәр итәләр. Максатлары: Свияжскидагы кызыл житәкчеләрне юк итү, Наркомвоенморның штабын һәм поездын яулап алу, Идел күперен кулга төшерү. Үз чиратында, мөмкин булган кадәр, ваклыкларны хәбәр итәрбез.

Безнең кулга төшкән телеграммалар:

Самарадан. Комуч председателе Вольский. 10 август. 15 сәг. 45 мин. Телеграмма. Ашыгыч! Яшерен! Хәрби ведомство управляющие урынбасары Лебедевка.

«Комитет сезнең карамакта булган барлык йөзмә средстволарны файдаланып, бар булган алтын запасын ашыгыч рәвештә Самарага күчерүне тәкъдим итә».

Казаннан. Лебедев Вольскийга. Телеграмма. Үтә ашыгыч.

«Алтын озата алмыйм. Большевиклар Иделгә җиңел генә үтеп керә ала, ахыр чиккә житсә, пароходларны батырырлар дип куркам».

Шушы телеграммалар нигезендә Вацетис приказ чыгарды. Иоаким Иоакимович, Ленин тәкъдиме белән, республиканың барлык кораллы көчләре белән житәкчелек итә башлаган иде...

«Вацетис. 1 нче командарм Тухачевскийга, 2 нче командарм Блохинга. Ашыгыч. Оператив приказ.

Дошман пароходлары түбән якка чигенәләр. 5 нче Армия частьларының Казаннан түбәндә Идел ярларына якынаю мөмкинлеге әлегә юк. Нәтиҗәдә, түбән якта дошман пароходлары бер каршылыксыз дәүләт байлыгын төяп китә алалар. Дәүләтебезнең барлык интересларыннан чыгып, 2 нче Армия командующиеннан кул астындагы судноларны, баржаларны Кама Тамагына кадәр төшереп Идел буйлап чигенүче дошман пароходларын үткәрмәүне тәэмин итүне сорыйм. 1 нче Армия командующиеннан шундый ук киртәне Сембердән түбәндәрәк булдыруны үтенәм»[14].

16 август. Вольский Лебедевка. Ифрат ашыгыч!

«Комуч булган металл хәзинәне һәм акча кәгазьләрен ашыгыч рәвештә пароходларга төяп Самарага озатырга боера. Көндәлек кирәк-яраклар-га үзегездә 3 миллион сум кәгазь акча калдырыгыз, әгәр шул сумма житәрлек тоелмаса, үз чиратыгызда комитетка өстәмә сорап мөрәҗәгать итегез. Алтынны озатырга махсус конвой оештырып, аны Генераль штаб офицерлары, сыналган, ышанычлы кешеләр белән тулыландырыгыз».

21 нче август Лебедев Вольскийга. Ифрат ашыгыч!

«Бик яхшы сак астында ике пароходка төяп Казаннан Самарага Россиянең алтын запасы озатылды. Алтын запасы 657 миллион сум

[14] Киртәләр соңга калып корылды, алтынны кайтарып алып булмады

саналып, бүгенгечә бәяләгәндә 6,5 миллиард сумлык булды, шуның өстенә 100 миллион сумлык кәгазь акча, ак алтын, көмеш һәм башка кыйммәтләр төялде».

Комучның финанс ведомствосы управляющие Н. М. Брушвитның йомгаклау сүзе:

«Казаннан килгән алтын запасының бәһасен банк хезмәткәрләре 1 миллиард 100 мең сум дип куйдылар»[15].

Казан хәрби округының командующие яшәгән зиннәтле пулатта бүген хуҗалар яңа — генерал Рычков, шәһәрнең гарнизон начальнигы кунак кабул итә! Кунак дисәң кунак, димәсәң дә ярый, әйдә кунаклар дип атыйк, алай дисәң, затлы-купшы киемнәр киенгән ханымнар юк, музыка тавышы да ишетелми, ара-тирә шпорлар чыңлап куя да, итек табаннары паркетны ялый; кысылган иреннәрдән шыпырт-шыпырт кына чыккан сүзләр яңгырый да сүнә, тәрәзәләрдәге калын бәрхет пәрдәләр ярым-ябык. Алай да авыш аркалы саргылт бәрхет көрсиләрне, җыелганнарның кырыс чырайларын күрсәтергә яктылык җитә. Генерал Рычковның бүгенге утырдашлары аз санлы булса да, исемнәре-чиннары яңгыравыклы, һәрберсе шәһәрдә шан-шөһрәт казанган абруйлы затлар: Каппель үзе генә ни тора! Савинков, Перхуров, Григорьев, Степанов, Швец, эсер Каллистов белән меньшевик Рясенцев. Болары «безнең кояш чыкты!» дигән кебек Рычковның авызына ук кереп утырганнар. Комуч вәкилләре Лебедев, Фортунатов һәм Архангельский кабарынган тук күркәләр сыман башларын артка чөеп, корсакларын киереп бер читкәрәк елышканнар. Баш артка чөелгәндә койрык тырая, билләһи, комуччыларны чишендереп карасаң, койрыклары туп-туры булгандыр!

Рычков түш кесәсеннән алтын сәгатен чыгарып караганда уң кулындагы калын, кашлы йөзектә сүрән август кояшы майлы таба кебек елтырады. Ул йодрыгына бер-ике йөткереп алды да шактый калын бас белән сүз башлады:

— Әфәнделәр, без бүген якындагы хәрби һәм сәяси бурычларыбызны ачыклар өчен җыйналдык. Кызыллар ныгый, алар Казан тирәсенә иң көчле гаскәрләрен тарталар. Свияжскига наркомвоенмор Троцкий килеп урнашкан. Ул шунда яши һәм алар, көч туплап, Казанны алырга әзерләнәләр. Өметләнәләр дә. Комуч байрагы үз тирәсенә халыкны җыя алмый. Әйе, әйе, әфәнделәр! Йөз меңлек шәһәр ватан файдасына меңләгән күңелләләр бирер дип өметләнсәк тә казанлылар мобилизациягә буйсынмады, нибарысы 570 үсмер туплый алдык, аларның

---

[15] Алтын запасының алдагы язмышы болай булды: 1918 елның сентябрендә алтынны Самарадан Уфага, аннан Омскига күчерделәр. Юлда барганда алтынны сакчылар, комучлар, легионерлар — кем иренмәсә, шул талады. Бигрәк тә чехословак легионерлары узынды. 20 еллар башында Праганың иң гүзәл урамнарының берсендә яңа, зур банк бинасы корылды: «Легионбанк». Бинаның да, банк байлыгының да «Казан алтыны»ның бер өлеше икәнен бөтен кеше белә иде.

Мейснер Д. С. «Миражи и действительность».
Записки эмигранта. М., 1966, стр. 135.

Омскида алтын запасы адмирал Колчак кулына күчә, ул АКШтан, Англиядән, Франциядән һәм Япониядән алган коралларына шушы алтын белән түли, Советлар Россиясендә күтәрелгән һәр фетнәгә акча белән булыша. Омскига җиткәндә алтын 651 532 117 сум 86 тиенлек кала.

Кызыл Армиянең һөҗүме нәтиҗәсендә аклар Омскидан качалар һәм алтын запасы алар белән Иркутскига кадәр «сәяхәт итә». Хәзер аны озата баручы аkгвардиячеләр, атаман Семенов, семеновчылар талыйлар, хәзинәне чит илгә алып чыгарга тырышалар.

1920 елның 4 октябрендә Иркутскида алтын запасы яңадан Совет властена кайтарыла. Әмма ул шактый «юкарган» була — 409 625 870 сум 23 тиенгә кала. Алтынның 241 906 247 сум 63 тиенен урлыйлар, талыйлар, үзләштерәләр. Калган алтынны махсус эшелон белән 1920 елның 3 маенда Казан банкысының кладовойларына кайтаралар. Бу эшне 5 нче Армия каршындагы ВЧКның особый бүлек вәкиле Александр Косухин җитәкли.

Кладт А., Кондратьев В. «Быль о золотом эшелоне». М., 1966 г.

да күбесе ямь-яшел, гимназистлар, өлкән класс укучылары. Алардан сөт тә юк, ит тә! Ата чекист Фролов көпә-көндез контрразведкадан чыгып ычкына, сакка куелган гимназист туалетта үксеп җылап кала. Аларның берсен дә сугышка кертергә ярарлык түгел, мылтык тавышын ишетүгә ыштаннарына җибәрәләр...

Иманым белән мин монархист, шулай булып калырмын да, «әллә илдә сәяси хәл үзгәрерме?» дигән өмет белән комучларга кушылдым. Хәзер чүт кенә икеләнә калдым. Моңа генерал Деникинның хаты сәбәпче булды дисәм дә ялган түгел.

Моңарчы төрле яккарак тартылган башлар, бу хәбәрне ишеткәч, Рычков ягына таба авыштылар. Фортунатовның пенснэсы караңгыда гы елан күзе кебек ялтырап алды.

— Генерал Деникин эшнең асылын безгә караганда яхшырак аңлаган. «Легионерлар штыгына аркаланып властька килгән Учредительное собрание комитетының совет властеннан бер аерымлыгы да юк. Шул ук совет властеның шәүләсе алар! Төссез, зәгыйфь шәүләсе» Ишетәсезме, әфәнделәр, генерал Деникин, дөньяны аңлый торган гали зат, нинди бәһа биргән! Хак әйтә, чөнки бүгенгә алар арасында халыкка дәрт бирерлек, өмет уятырлык, рухландырырлык кеше юк. Элегрәк большевиклар таркау иде, без аларны артык көч түкмичә дә җиңә ала идек, хәзер хәл чамасыз үзгәрде. Әгәр бүгеннән нәтиҗәле чаралар кулланмасак, безнең хәл тагы да мөшкелләнәчәк. Сездән сүз көтәм.

Савинков Каппель, Перхуровлар сүз алыр дип көткән иде, алар авызларына су кабып утыргач, ярсып диярлек сөйләргә тотынды.

— Эш тотмаган гына ялгышмый,— диләр итальяннар. Ялгышлар бездә дә күптер, бәхәсләшмик. Төп хатабыз шунда ки, без, эсер һәм меньшевиклар, унҗиденче елда властьта чакта иске армияне һәлакәткә китердек, таркаттык, аны большевиклар кулына бирдек. Ә алар ни эшләде? Армияне демобилизацияләделәр дә корал складларына, интендант хезмәте кирәк-яракларына тулы хуҗа булып алдылар. Бар байлык аларга күчте. Большевикларга каршы торырлык көч илдә бармы хәзер? Бар. Бердәнбер көч — шанлы-шәүкәтле рус офицерлары. Офицерсыз армия юк, димәк, әгәр без аларга таянырга теләсәк, тиз арада аларның абруен ныгытырга тиеш. Большевикларга каршы торуның бердәнбер юлы шул. Идел ярларында кан коеп без хәрабә хәленә төшкән Россиягә җан өрәбез, терелтергә тырышабыз. Хәзер төп мәсьәлә большевикларның көче күпме булуда түгел, көнбатыш фронтта Германия хәлсезләнгәнме, аның да әһәмияте калмады, бүген иң мөһиме шул — хәзер без ахырга кадәр көрәшә алабызмы?! Бармы безнең әзерлек?!

Россия җиренә яңа буын килде, шул буын революция ясады. Ахыр чиктә алар, илдә коммунистик дәүләт төзеп, бөтендөнья революциясенең йолдызын кабызырлармы-юкмы, анысы миңа караңгы, мәгәр яңа буын иске заманга кайтачак түгел. Иске заманны ефәктәй яңа сүзләргә төрә-төрә мактасагыз да кайтачак түгел! Россияне коткару өчен конструктив программа һәм көчле, абруйлы юлбашчы кирәк. Бүгенге таркалган төркемнәрне, чуалышкан партияләрне, оешмаларны һәм шанлы рус офицерларын бары тик шундый олы зат кына туплый алыр. Чит ил штыклары, акчалары, ахыр чиктә акчалары гына булсын, берсе дә безне коткармаячак. Русның чын ватандар асыл ирләре үз язмышларын чит ил акчасы бәрабәренә таянып хәл итәргә теләмиләр. Акча бүгенгә генә түгел, акчаның иртәгесе дә бар, шуны бик яхшы белә алар! Мин халыкны яраттым. Халык язмышы өчен гомеремне бирергә әзер тордым, мәгәр бу хәлдә халкымның ни теләвен аңлап бетермим. Җиңәр өчен нык-лы оешма зарурлыгын гына беләм! Оешырга! Берләшергә! «Ирек агачын вакыт-вакыт патриотлар һәм тираннар каны белән сугаргалап торырга кирәк»,— дигән бөек американнарның берсе. Без исә ирек агачын дошманнарыбыз каны белән, ирекле Россияне терелтергә комачаулаучылар каны белән генә сугара алабыз!

Савинковның пеләше алсуланганнан алсулана барды, тирләп чыкты, чыраена тимгел-тимгел кызыллык йөгерде, ул, бармакларын бер-берсенә ышкып, кулының калтыравын залдагыларга сиздермәскә тырышты.

Чират Каппельгә житкәнлеге һәркемгә ачык иде, комуч гаскәрен ул житәкли, әйтсен үз сүзен: эш ни хәлдәрәк тора? Каппель, калкынса да, сөйләргә ашыкмады, күзен тасрайтып комуч вәкилләренә карап алды, тегеләр, бер-берсенә карашып, үзара мыгырдаштылар.

Каппель, утырдашларының күңел авазын ишеткән кебек, сүзне болай дип башлады:

— Әйе, мин комуч гаскәрен житәклим. Әйе, аның йомшак якларын мин барыгызга караганда да яхшырак беләм. Оешкан, көчле һәм сугышчан әзерлекле армия миңа кирәкмиме? Әфәнделәр, әфәнделәр! Алдан сөйләүчеләргә кушылам, Кызыл Армия иманы белән көчле. Ә бездә алар берничә: эсер иманы бар, монархистлар иманы, тагын, шайтан белсен, әллә кемнәр иманы! Кая карап чукынырга да белмәссең! Көчле, хәрби бердәмлек имансыз булмый, була да алмый. Мин дә конструктив программа яклы. Ягез, әйтегез, Россия улларын бердәм итә торган программа кайсыгызда бар?

Савинков урыныннан кычкырды:

— Кайсыбызда бар дип сора!

Каппель залдагыларны берәм-берәм бораулап күз йөгертеп чыкты.

— Хуш, без бердәм һәм бергә булырга тиеш. Мәскәүгә ерак калмады, хак, аңа барып житәр өчен әле байтак кан коярга кирәк. Генерал Алексеев Иркле армия белән кайчан безгә ярдәмгә килеп житәргә тиеш иде? Июньдә! Хәзергәчә күзгә-башка күренгәне юк. Кайда ул? Кубаньда! Затлы шәрап эчеп, яшь казачкаларны ура! Союзниклар Вологдадан туп-туры көньякка төшәргә, немецларга һәм аларның ялланган агентларына каршы Идел ягасында оешкан төп көч — Көнчыгыш фронтка ярдәм итәргә тиешләр иде. Алар кайда? Вәгъдәләргә без юмарт, кесәгә кереп тормыйбыз, уңлы-суллы сибәбез! Идел буйлап өскә, Мәскәүгә күтәреләсе урынга, без җилдән хәбәр көтеп утырабыз, кайчан килерләр, килерләр микән, юкмы дип күрәзәлек итәбез. Киләләр пычагым! Большевиклар һаман көчәя, фронт-тылларын ныгыталар, без исә ачык кырда җил куабыз да тамырда килеш череп таркалабыз. Социалистик партияләрнең тәгълиматын, ни яклауларын биш башлы дию парие дә аңларлык түгел, биш баш йөртсә дә! Тоташ төтен, сыек томан. Бүгенгә Русь җирендә күпме автоном хөкүмәтләр төзелде, аларны кем берләштерер? Ничек итеп? Әле шушында, Идел регионында, үзара килешенә алмыйча, бердәм командование юклыктан иза чигәбез. Үзара килешә алмаган мәлдә без солдатларны большевикларга каршы өнди алабызмы! Юк. Казан янында гына канлы-аяусыз бәрелешләр бара, ә шәһәр гражданнары крепость стенасына җыйналалар да гайбәт саталар, соңыннан урам-йортларына кайтып ишеткәннәрен тараталар. Юк-бар белән халыкны өркетәләр, куркыталар.

Рычков сәгатендә тагын нур уйнатып алды, учына йөткергәләп:

— Сез ни тәкъдим итәсез? Сүз һәммәбездә мул,— диде.

Каппель киң күкрәгенә мул итеп һава тутырды да йодрыгы белән күзгә күренмәгән дошманны тукмады, алга иелгән Фортунатовның күзлеге төшеп китте.

— Бердәмлекне сүз белән түгел, эш белән ныгытырга кирәк!

— Сез асла ни тәкъдим итәсез, сез?! — дип чинады Фортунатов, пенснэсын борынына элә алмыйча азапланып.

— Көчле, иң ышанычлы отрядларны туплап, Свияжскига — большевиклар оялаган төп өнгә искәрмәс рейд ясарга! Кызылларның йонын туздырырга, рухи инициативаны үзебезгә кайтарырга! Тәкъдимем менә шул.

— Күптән вакыт,— дип пышылдады меньшевик Рясенцев, үзе генә ишетерлек итеп. Каппель аны ишетмәде, ул инде җиңгән кыяфәт белән планнарын бәян итәргә тотынды.

— Бер селтәнүдә большевикларны башсыз калдырырга! 5 нче Армия штабын һәм командованиесен кулга төшерергә. Наркомвоенмор поездын яулап алырга. Идел күпереннән большевикларны алып ыргытып Мәскәүгә юл ачарга!.. Күперне чыгуга инициатива тулаем безнең кулга күчә, күрерсез. Планның нечкәлекләрен полковник Петров игълан итәр.

Залга хуш ис таратып, Каппельның ак маңгаенда зәңгәр читле ак яулык йөреп алды. Петров хәрбиләрчә житез генә аягүрә басты, шпорлары чыңлап куйды, ул моңарчы тезендә тоткан папканы тирләгән бармаклары белән ачты.

— Ашыгыч һәм искәрмәс операцияне тормышка ашыру өчен ике мең пехота билгеләнә. 340 кавалерист, ундүрт орудие, ике дистәгә якын пулемет. Рейдка катнашучыларның күпчелеге офицерлар һәм эсер боевиклары, атап әйткәндә, кулыбызда бар иң ышанычлы частьләр. Без кинәтлеккә йөз тотабыз, рейдның кайчан һәм ничек башланасын берәүгә дә белдермибез. Шуны өстәп әйтәм, полковник Каппель тәкъдиме белән ат дагалары чүпрәк белән уралачак, шалтырый, чылтырый торган корал-яраклар чехолларга төреләчәк. Безнең удар кызыллар өчен һич көтелмәгән һәм дәһшәтле булырга тиеш!

Папка эченнән карта килеп чыкты, Петров шак-шок басып Рычков янына узды, төрле уклар, саннар белән бизәлгән кәгазьне өстәлгә очыртты. Каппельдән бүтәннәр өстәлне урап алдылар, пенснесын һаман көйләп куя алмаган Фортунатовка гына урын житмәде, ул кемнеңдер култык астыннан башын тыгарга ниятләгән иде, пенснесы идәнгә үк төшеп китте, пыяла чартлаган тавыш ишетелде.

— Менә сезне, әфәндем,— диде һаваланып Петров,— рейдка алып барып булмый инде.

Тирә-яктагылар тыенкы гына көлеп җибәрделәр.

— Менә Свияжск. Менә станция,— дип күрсәтте Петров.— Ике колонна булып һөҗүм итү күздә тотыла. Беренче колонна Идел күперенә юнәлә. Аның төп бурычы болай: Красная Горка тирәсендәге кызылларны кырып бетереп Обсерватория станциясенә үтә, Атлашкиноны ала һәм күпергә бәреп керә. Беренче колоннада атлылар эскадроны, биш орудие, сигез пулемет һәм бер батальон пехота. Аңа ярдәмче роль тапшырыла, димәк, беренче колонна сулъяк ярдагы кызыл гаскәрне үзенә җәлеп итә, кызыллар һөҗүмнең төп юнәлеше шушы икән дип белеп алданалар, Свияжскидагы отрядларына ярдәмгә килә алмыйлар. Фортунатов белән Савинков житәкләгән беренче колонна кызылларның көчен үзенә каратып, тоткарлап торырга тиеш!

Каппель тагын бер мәртәбә Фортунатовка җирәнеп кенә күз ташлады, баягы көлеш тагын кабатланды.

— Полковник Каппель һәм Лебедев житәкләгән икенче колоннага төп авырлык төшә, аерата мөһим бурыч йөкләнә. Алар паромнарга, көймәләргә төялеп Иделне кичәләр, кырлар аша үтеп, яшертен генә Түрләмә станциясенә якынлашалар, андагы корал һәм азык-төлек төялгән эшелоннарны шартлаталар, паника тудыралар, шау-шу, буталыш арасында шәһәрне һәм Свияжск станциясен кулга төшерәләр. Рейд уңышлы чыккан очракта кызыллар камалышта кала, командование юкка чыгарыла. Кызылларны тәмам бетерер өчен Свияжскиның үзеннән, якындагы авыллардан безнең кешеләр күтәрелеп чыга, алар алдан ук корал белән тәэмин ителәчәк.

— Дошман безгә каршы нинди көчләр куя ала? — дип сорады моңарчы тып-тын утырган эсер Каллистов. Ул үзенә сугышчан бурыч такмауларына сөенә иде. Петров бу сорауга төгәл җавап бирде, папкасыннан юка кәгазь алса да, аңа карамады диярлек.

—Хәрби һәм агентура разведкасы мәгълүматларына караганда шул билгеле: сулъяк ярда безгә каршы кызылларның элеккеге полковник Алексеев группасы куелган. Боларга 3 нче Курск полкы, 2 нче

Брянск совет полкының 3 нче батальоны, 5 нче Петроград кавалерия полкы, «Свободная Россия» бронепоезды керә. Уңъяк ярда элеккеге полковник Вахрамеев группасы. Аларга 4 нче латыш, 2 нче Мәскәү полклары, 1 нче Петроград революцион отряды, кавалерия отряды, авыр һәм җиңел артиллерия батареяларының латыш взводы бирелгән.

Болардан тыш Свияжск станциясендә комендант взводы, әле дары исен бер дә иснәмәгән 2 нче Петроград полкы, интендантлык хезмәтләре урнашкан. Станциянең оборона начальнигы — элеккеге прапорщик Хаханьян. Төп житәкчелек наркомвоенмор Троцкий кулында. — Петров авыр көлемсерәп куйды. — Тәртип урнаштырырга маташа нарком! Тәртип ягы сыек!

Полковникның тавышы көчәйде, кырыс хәрби чыраена сүрән елмаю чаткылары чәчелде.

— Тыңлагыз, Троцкий күптән түгел генә мондый боерык чыгарган: «Кисәтеп куям, әгәр кайсы булса да часть, югарыдан боерыксыз чигенә икән, беренче булып отряд комиссары, икенче чиратта командиры атылачак. Батыр һәм гаярь солдатлар хезмәтләре дәрәҗәсендә бүләкләнәчәк һәм командный постларга куелачак. Куркаклар, җебегәннәр һәм хыянәтчеләр пулядан котыла алмаслар! Мин моны бөтен Кызыл Армия алдында белдерәм». Приказның асылы шул, янәсе большевиклар армиясендә тәртип ягы какшаган, Троцкий каты һәм кискен чаралар белән аны ныгытырга маташа. Троцкий заложниклар мәсьәләсен дә читләтмәгән, куркакларның һәм хыянәтчеләрнең гаилә әгъзалары, кулга алынып, җәзага тартылачак дигән. Әгәр Халык армиясенең командир гаиләсе яшәгән урын совет Россиясе составында икән, алар да хыянәтчеләр исәпләнеп кулга алыначак. Бу хакта Халык армиясе офицерларына кичекмәстән җиткерегез. Тагын шуны белдерәм, наркомвоенмор поезды белән кинопередвижка һәм шагыйрь Демьян Бедный килгән. Аның шигырьләрен большевиклар листовкалар итеп Казан өстендә тараталар, мондагы подпольщиклар исә аларны стеналарга ябыштырып йөри. Большевиклар кәгазь өндәмәләргә зур игътибар бирә, «кем дә булса бу плакатны ертып алса яки өстән томаласа — ул кеше контрреволюциягә ярдәм итә!» дип җибәрәләр. Шушы соңгы белдерү белән сүземне тәмамлыйм.

Бер минут киеренке тынлыктан соң кояш нуры соңгы мәртәбә Рычковның алтын сәгатенә кунып алды.

— Әфәнделәр һәм гражданнар! — диде ул. — Киңәшмәдә катнашуыгыз өчен рәхмәт белдерәм. Безнең егетләргә уңыш телик. Сезгә табынучылар теле белән әйтсәк, хөрмәтле Владимир Оскарович, «Алла һәм полковник Каппель безнең белән!» Алга, Свияжскига! Мәскәү юлындагы большевикларның соңгы киртәсе җимерелсен!

Лацистан Троцкийга, Славенга, Хаханьянга!
Аерата мөһим!
«Разведка агентурасының ышанычлы чыганакларына таянып шуны белдерәм: якын көннәрдә гаскәр туплап Каппель Свияжскига һөҗүм әзерли. Казанга һөҗүмне өзеп, Кызыл Армия частьләрен, югары командованиене һәлак итеп, Идел күперен яулап алуны планлаштыра».

Славен. Троцкийга, Хаханьянга.

«Армия һәм һава разведкалары Югары Осланда акларның гаскәр туплавын һәм Идел кичәргә ашыгып әзерлек алып баруларын хәбәр итте».

Троцкий, 5 нче Армия командующие Славенга, станция оборонасы начальнигы Хаханьянга.

«Свияжскины саклап калырлык бөтен көчләрне барларга. Фронттан гаскәр кузгатмаска. «Свободная Россия» бронепоездын Түрләмә станциясенә күчерергә. 2 нче Петроград полкын кисәтергә. Минем бер

очракта да Свияжскидан китәргә җыенмавым күренеп торсын өчен, наркомвоенмор поездыннан паровозны алып, вагоннарны иң аулак юлга күчерергә. Күпер тирәсенә, командующий белән мәслихәтләшеп, Идел флотилиясеннән берничә судно китертергә».

Свияжскига һөҗүм әзерләнә... Яшертен, искәрмәс һөҗүм...

Свияжск һөҗүм буласын белә, әзерләнә, дошманның мәкерле планын өзәргә җыена...

Савинков күрсәтүләреннән:

«Пулеметлар белән коралланган йөз кылычлы идек. Обсерватория янындагы бер авылга тукталдык. Карасак, ачык платформаларына туплар тезеп каршыбызга поезд чаба! Станциягә килеп туктауга кызылармеецлар коралларын бушатырга керештеләр. Безнең яшеренеп торганны белепме, белмичәме, тәртипсез рәвештә атарга тотындылар. Без яшеренеп торабыз, атуларына игътибар итмибез. Шуннан кызылармеецлар бер таучыкка җыелдылар да митинг башлап җибәрделәр. Кызылларның митингысы шәбәеп барганда гына без бар булган пулеметлардан ут ачтык. Берничә минуттан тауччык мәетләр белән капланды. Исән калганнар, ашык-пошык поездга төялеп, китеп барды, коралларын ташлап качтылар. Шуннан безнең капитан: «Атларга менегез!» — дип боерык бирде, тауччыкка барып карадык... Төнлә суытты, шинелем юк иде, берне сайлап алдым, кигәч карыйм, итәге кан гына...»

Каппельчылар һөҗүменнән соң ук матрослар отряды белән Түрләмә станциясенә килеп кергән комиссар Лариса Рейснер донесениесеннән:

«Аклар станцияне көчле утка тотканнар, корал төялгән ике эшелонны шартлатканнар, сакта торган кызыл сакчыларны тоташтан суеп чыкканнар. Күзгә күренгән җан ияләреннән берсен дә аямаганнар. Бөтен җирдә суеш, кырылыш, һәлакәт. Бу әфәнделәрнең бүтән җиңүләрендәге кебек үк монда да чамасыз кансызлык, мәгънәсез шәфкатьсезлек күрсәтүе күзгә ташлана. Үзләренең монда озакка килмәүләрен белгән кебек, алар ни күрсәләр шуны кырганнар, җимергәннәр. Ишегелдында мәгънәсезгә атылган (әйе, атылган!) сыер ята. Тавык кетәгендә башлары өзелгән тавыклар ауный. Кое, бакчалар, водокачка бинасы, йортлар — аларны да большевиклар дип белгәнме әллә бу шашканнар! — һәммәсе кырып, җимереп ташланган. Мал-туарларның эчәгеләре чыккан. Туралган, чабылган дуңгызлар канга манчылып төрле җирдә ауныйлар. Мал-туар белән шулай кыланганны, искәрмәс һөҗүмне абайламый калган аз санлы кызылармеецлар һәм тимер юл хадимнәренең ни хәлдә булуын күз алдына китерү кыен түгел.

Түрләмәне яндыргач, Каппель сау калган платформаларга тизрәк төяләргә боерган, паровозларны, машинистларны офицерлар карамагына тапшырган.

— Тизрәк, тизрәк Свияжскига! Шәһәрне алуга ук станция дә безнеке булачак! — дип кабатлаган ул.

Свияжскидан аларга каршы «Свободная Россия» бронепоезды чыккан һәм алар каппельчыларны Түрләмәгә җитәрәк үк абайлаганнар. Офицерлар ул арада тупларны ачык платформаларга беркетеп өлгергәннәр, бер-ике уңышлы залптан соң ук бронепоездны сафтан чыгарганнар. Команда каушап калган. Бронепоезд командиры, кискен чаралар күрәсе урынга, җебеп төшкән, дрезина куеп Свияжскига «күрсәтмәләр алырга» китеп барган. Комиссар бронепоездны ташлап калдырырга һәм шартлатырга боерган. Бронепоездның «кара сөякләре» юлда таралып калган. Свияжскига юл ачылган...

Станциядә паника башлана. Караңгы. Пычрак. Сибәләп кенә вак яңгыр ява. Бөтен җирдә буталыш, кырылыш, ыгы-зыгы, таркаулык. Мондый хәлнең азагы бары тик үлем, һәлакәт булып тоелган».

Аклар төрле яктан кыса башлауга, иң әүвәл, пристань ягына штаб һәм армиянең политбүлек хезмәткәрләре чаба башлады. Моннан ике атна элек кенә кулларына беренче мәртәбә корал тоткан 2 нче Петроград эшчеләре берән-сәрән качарга тотындылар. Алар сугыш тәҗрибәсе туплаган, өйрәтелгән, ярсулы үч белән янган офицерларга каршы тора алмыйлар иде, бераздан бөтенесе, бер-берсен узып, дәррәү чабарга керештеләр.

Славен, Хаханьян, Лацис, Якубов корал тота алырлык ир-атларны дәшеп-чакырып станция урамнарында арлы-бирле тулганган отрядларны ашык-пошык җыештырдылар, аз-маз оешуга ук отрядлар туптуры сугышка керә торды. Каппельчылар станцияне майга кергән үткер пычак сыман икегә телеп үттеләр. Аз санлы, таркау отрядларны алар бар дип тә белмәделәр. Дөнья кан исе, ыңгырашулар, җан авазлары белән тулды.

«Ходай һәм Каппель безнең белән!»

— Соңыннан, соңыннан! — дип ашыктырды Каппель. — Иң әүвәл станция! Штаб һәм кызылларның командованиесе. Аннары күпер! Без Романов күпере дип, большевиклар Кызыл күпер дип атаган күпер! Мәскәүгә юл.

Станциянең бөтен почмакларыннан аталар, дошманны күреп, төбәп түгел, — теләсә кая, шәүлә күренсә аңа да аталар. Атыш аз гына басылып тора да тагын котырып кузгалып китә. Урам, ишегаллары мәетләр белән тулы. Кем-кемне!..

Беркем йокламый, һәр урам чатына, һәр йортка, почмакка, ярыкка короллы кешеләр кереп тулган...

Иртән яктыра башлауга, аэропланнар күтәрелеп каппельчыларны бомбага тоттылар. Станциядән бераз читкә китеп өлгергән, тимер юл платформасына урнашкан латыш батареясы да, ниһаять, телгә килде һәм каппельчыларга шрапнель арты шрапнель яудырды. Унөч сәгать барган аяусыз көрәштә арган каппельчылар түзмәделәр, кул сугышына күтәрелделәр һәм ике дулкын капма-каршы бәрелеште.

---

Военком Витовта Путны донесениесеннән:

«Кызыллар, чигенергә юл калмаган кебек, арысланнарча сугыштылар. Ослан ягыннан, фронттан, бер генә солдатны да алмыйча сугыштылар. Свияжск өчен генә түгел, ил язмышы хәл ителә икәнен аңлап сугыштылар. Ярсыган дошманнар әллә ничә тапкыр штыкка-штык очраштылар. Бер чакта да әле мондый ук кыен хәлдә калмаган Кызыл Армия кинәт һөҗүм ясый алуы өстенә, ныклы оборона тота белүен дә раслады. Акларның кызган тәненә утлы штыклар чыжлап керде!

Кызыл Армия Идел ярындагы шушы нәни станциядән бөек көрәш юлына чыкты!»

Бу — гадәти булмаган бәрелеш иде, кинәт кабынып киткән, ике якның да уңышын тизлек һәм кыюлык кына хәл итә торган хәтәр сугыш иде. Яклар тигез түгел иде, авырлыкка чыдый алмыйча, хуҗалык взводы солдатлары, күпчелеге өлкән һәм сәламәт булмаган кешеләр, сугыш кырын ташлап качтылар һәм санитар пароходы «Одесса»га шашып-бәреп кerделәр. Бер үк вакытта Идел күперен саклаучы матросларга ярдәмгә Паратск заводыннан эшчеләр килеп өлгерде, һәм алар ярсып күпергә үрмәләгән дошманны артка каерып ыргыттылар. «Ваня-коммунист» һәм «Добрый» ут ата-ата күпергә якынлаштылар. Латышларның ике эскадроны килеп җиткәч хәл бераз җиңеләйде, кавалерия каппельчыларны качарга мәҗбүр итте.

Көнчыгыш фронтның политбүлегеннән алынган донесение:

«Явыз дошманны качарга мәҗбүр иттек. Төнлә, куып бара торгач, без аларның эзен югалттык, кая качканнарын белә алмадык. Көне буе эзәрлекләп, хәлдән тайгач кына, аларның Свияжскидан утыз чакрымга

сыпырткannарын аңладык. Шушы көннән бишенче сентябрьгә кадәр дошман үзенең барлыгын сиздермәде, тыны чыкмады явызларның!»

Таркалган, тар-мар ителгән, зиһене чуалып һушы киткән дошманны куа барып тәмам дөмектерергә кирәк иде дә, Троцкий эшне бүтәнчә хәл итте.

Беренче эше итеп ул үч алырга уйлады, җәзаларга! «Төрле сәбәпләр тапкан булып сугыш кырыннан качкан үз гаскәренне җәзаларга!» Ул үзе качмады бит, түзде, каушамады, китәргә нияте юклыгын раслап, поездын паровозсыз калдырды. Дәһшәтле бәрелеш барганда ярыкка посмады, вагонында булды, сугыш белән җитәкчелек итә алды.

«Аны, революциянең һәм армиянең җитәкчеләрен, (үзен һәм якыннарын ул шундыйлар дип саный иде!) дошманга калдырып качтылар, у-у, кабахәтләр. Армия юлбашчыга буйсынырга тиеш, солдатлар командирларына. Бигрәк тә сугыш барышында ике сүз, икеләнү була алмый! Митинглар, үгетләүләр, инандырулар чоры үтте, үтте!»

Ул, монысын беркемгә сиздермәсә дә, куркуның ни икәнен татыды, бүген төнлә ул әҗәле белән күзгә-күз очраша язып калды, һәм аның шартларга җиткән күңеле хәзер, дөнья тынычлангач үч сорады. Үч! Качкан солдатларны, командирларны үз кулы белән бугазлап ташлардай булды!

«Куркаклыктан куркытып кына котылып була, кискен чаралар гына каушаган кешеләрне айныта, уйландыра! Әгәр без хәзерге минуттан куркуның тамырын чабып өзсәк, алдагы көннәргә сабак, гыйбрәт булачак. Бу яман хәл белән без алда очрашмый башларбыз!»

Ул чактагы наркомвоенмор шулай фикер йөртте.

Үч ярсуын тормышка ашырырга һәм аңа нигез, аклау, дәлилләү табарга җыенды... Хәрби-революцион трибунал утырышына ул үзе килде һәм чыгыш ясады:

— Кызыл Армиянең Казан янындагы тиңсез батырлыгы бөтен дөньяның игътибар үзәгендә тора. Дошман моннан төньякка да, көнбатышка да, төньяк-көнчыгышка да узарга маташты. Вяткага, Ярославльгә, Архангельскига үтеп, чехословак фронтын инглиз десанты төшкән төньяк белән ялгарга бик теләде. Үткәрмәдек, кушылдырмадык, җиңә килдек. Без хәзер көрәшнең үзәгендә торабыз һәм алда да дошманны җиңү өчен көчебезне кызганмабыз. Казан өчен сугыш актыккы бер сорауга җавап бирәчәк: кем көчлерәк? Киләчәк кем кулында булачак?

Шикләнмибез, без көчлерәк, киләчәк безнеке булыр. Дошманны һичшиксез тар-мар итәр өчен, тагын да көчлерәк булыр өчен, без төрле төстәге контрреволюция белән генә түгел, үз арабыздагы бер иш куркаклардан, башбаштаклыктан арынырга мәҗбүрбез. Куркаклардан, куркаклыктан котылырга кирәк! Мин ВЧК гаскәрләренең штаб начальнигы һәм Мәскәү-Казан тимер юлы оборонасы начальнигы Каменщиковка Муром, Арзамас, Свияжск районнарында концлагерьлар корырга боерык җиткердем, без анда буржуа калдыкларын, куркакларны һәм заложникларны утыртып куячакбыз! Гражданнар сугышының актыгына хәтле утырсыннар әйдә! Башкаларга сабак рәвешендә Свияжскины каппельчыларга бирә язган куркакларны, паникерларны, дезертирларны каты җәзалаячакбыз, без алардан арынырга, чистарырга, сафларыбызны тыгызларга, бер йодрык булып тупланып якын араларда Казанны гына түгел, Идел буеның бар шәһәрләрен азат итәргә тиеш. Итәрбез дә.

Ихлас пропаганда да һәрчак диярлек тенденциоз була, әйтик, ул кайбер фактларны дәшми, яшереп калдыра. Әмма безгә ярым-йорты түгел, тулы хакыйкать зарур. Безнең яшерен эшебез юк, без дошманнар белән аяусыз булачакбыз, үз арабыздагы куркакларга мәрхәмәтсез икәнлегебезне дөньяга ап-ачык итеп белдерәбез. Бу безнең альфа һәм омегабыз. Гимназия елларыннан хәтерлим, борынгы Римда гаскәр-

дә буйсынуны һәм тәртипне ныгытыр өчен полководецлар еш кына децимациягә мөрәҗәгать иткәннәр, гаепле хәрби берләшмәләрне рәткә тезгәннәр дә, һәр унынчы солдатны җәзалаганнар. Мин трибунал карамагына 2 нче Петроград полкының командирын, комиссарын һәм кичәге сугыш кырыннан куркак куян кебек качкан кызылармеецларның һәр унынчысын атарга тәкъдим кертәм. Әлбәттә, хәл авыр, болар революция хакына авыр корбаннар булачак, мәгәр бу аяусыз хөкем тырт иткән саен качарга әзер торган солдат массаларын уйландырыр, революцион кагыйдәнең һәркем өчен бер икәнен күрсәтер! Без регуляр армия туплыйбыз һәм үен-муен белән маташырга җыенмыйбыз! Дус та, дошман да моны ачык аңласын!

Трибунал әгъзалары бер кавымга телсез калдылар, трибунал утырышына чакырылган 2 нче Петроград полкының командиры белән комиссары агарынып каттылар. Андый-мондый гына кеше чыгыш ясамый бит, тәкъдим наркомвоенмор авызыннан чыкты, димәк, ул җиренә җиткерелергә тиеш!

Хәрби трибунал рәисе, 1898 елдан большевиклар партиясе члены Петр Гермогенович Смидовичның халык комиссарына каршы төшәргә кыюлыгы җитте.

— Сез тәкъдим иткән чара, иптәш нарком, кот очарлык. Бер буталчык мизгелдә, бер гаепсезгә куркып-каушап калган иптәшләрне ату, иң бөек максатлардан чыгып булса да, акланмаслык, аклана алмаслык фаҗигага булачак. Аңлыйм, бәлки бу кискен чара куркакларга сабак булыр, партизанчылыкка, башбаштаклыкка чик тә куяр. Әмма мондый юл белән тәртип урнаштыруга мин каршы. Әйе, каршы. Уйлашыйк. Беренче мәртәбә дошман белән күзгә-күз очрашкан, сугышта чирканчык алган эшче полк. Ә аңа каршы каппельчылар килә, кулларын ничәмә-ничә тапкыр кан белән юган итчеләр! Монда куркып калырсың да... Юк, мин аларны акламыйм, ләкин андый шәфкатьсезлеккә бармаска иде. Гимназия дәресләре дисәгез, ягъни мәсәлән, мин дә хәтерлим! Децимацияне яклаучы претор Марк Лициний Красс булган! Халыкның бөек улы Спартак восстаниесен буган кеше. Без Красс юлын сайларга тиешме? Без, минемчә, нииндидер бер дәрәҗәдә Спартак юлыннан барабыз, хокуксызларны, кимсетелгәннәрне азат итәр өчен кан түгәбез. Мин дә җәзалау ягында, мәгәр мондый дәрәҗәдә түгел...

Уртада сүнәр-сүнмәс кенә учак яна. Шунда ук ярка-ярка туралган утын, чабылган ботак-сатаклар аунап, тәгәрәп ятса да, беркем дә калкынып учакка көч өстәми, инде сүндем, беттем, юк булдым дигәндә генә кемдер бөкшәеп калкына да елтыр-елтыр килеп яткан күмерләр өстенә бераз утын ташлый. Ярка пыскып, чыжлап бик озак яткач кына ялкын телләре, терелеп, югарыга үрмәли башлыйлар, ниһаять, муртаеп беткән утынны ялкын чорнап ала. Учак тирәсен сарган кызылармеецларның көл төсенә кергән чырайлары барыбер ачылмый, ияклэр очланып калган, яңаклар суырылып эчкә кергән, борыннар салынган, кашлар җимерелгән. Кемнеңдер шинель итәгенә күмер чәчрәп төшеп пыскый башлый, әмма ул аны сүндерергә ашыкмый, кабаланмый, юан, кыска тәмәке төпчеге иреннәренә кушылып чожлап яна башласа да, һаман төпчеген имә. Янына чүмәшкән иптәшләре дә шинель итәгеннән бөркелеп чыга башлаган сасы искә игътибар итмиләр, һәркемнең күзе сүнәр-сүнмәс янган учакта... Учак тирәсенә тончыгырлык зәһәр ис таралгач кына кемдер кыска, усал итеп сүгенеп алды.

Янган шинель хуҗасы учактан бераз читтәрәк моңаеп утырган калай чәйнектән итәгенә чырылдатып су агыза башлады. Чәйнектә чәй иде югыйсә, аңа да бераү дә кагылмады. Ашау, эчү, һәммәсе онытылды, кирәксез һәм вак бер эш булып калды...

Полк командиры белән комиссарны трибунал утырышына чакырып алдылар. Кызылармеецлар әле трибунал карарын белмиләр, карарның

бер канаты үзләренә килеп кагылачагын әле уйламыйлар да, алар командир белән комиссар өчен генә борчылалар. Боерыкны беләләр: «Качкан хәрби частьларның командиры белән комиссарын атарга!»

Ничек алай булды?

Нигә шулай җебеп төштеләр алар?!

Беренче мәртәбә кулларына корал килеп кергәч, гайрәтләнеп: «Сугышта, ут арасында ничек йөрәксенеп йөриләр икән дип уйлый идем, кулына корал кергәч ир кеше бөтенләй үзгәрә икән, ул сугышчыга әверелә, аның җаны башка, каны бүтән, ихтыяры нык, беләге көчле!» — дип сөйләшкәннәр иде бит алар...

Кечкенә тимерчеләр, слесарьлар, токарьлар. Данлы Питер эшчеләре. Аларны эшләреннән, гаиләләреннән, күнеккән гадәтләреннән революция аерды. Алар Кызыл Армиягә үзләре теләп язылдылар, үз ихтыярлары белән «хәвеф эчендә калган революцияне» яклап калырга Казанга килделәр. Командирлары сабыр, мәгәр ифрат акыллы, комиссарлары кайнар, мәгәр кирәк чакта тыныч та була белгән кешеләр иде. Алары да кечкенә эшчеләр... Иптәшләр...

Ник шулай булды?

Нигә шулай?

Кулларындагы коралларны кайсын-кая ташлап нигә качтылар алар? Кулдан корал киткәч, ир егет сугышчы булудан туктый, ул үзгәрә, ул куркакка, буйсынучы хайванга әверелә икән! Аның җаны башка, каны бүтән, ихтыяры юк, беләге зәгыйфь... Шуны татыр өчен качтылармы?

Ул чакта уйлап торырга вакыт юк иде, яшенле яңгырга эләгеп көтүчесез калган сарык көтүе сыман ишелеп Идел ярына төшә башлаганда аларга каршы матрослар йөгереп менде. Алар нидер кычкырдылар, янадылар, командир белән комиссар: «Туганнар, туганнар! Бирешмәгез!» — дип үгетләп тамаксыз калдылар, авызларыннан, канлы ирен араларыннан сүзләр түгел, хырылдау авазлары гына чыга башлады. Әмма барысы да беләләр иде: шул авазлар да барыбер кирегә борылырга өндәде, дошманга каршы ташланырга чакырды, бирешмәскә, бирелмәскә боерды. Ә алар тыңламадылар, бераздан полк юк, кайсыкая таралган коралсыз эшчеләрне каппельчылар мырлый-мырлый турыйлар, штык белән эчәгеләрен актарып чыгаралар иде...

Полкның күпмесе генә исән калды икән?

Монда бер учак, тегендәрәк тагын берәү, арырак тагын бер...

Җыелдылар, әмма бер була алмадылар. Бер була алмыйлар иде инде. Батырлык берләштерә, куркаклык аера, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне аерып ташлый, солдатлар бер-берсеннән ерагаялар, кечкенә иптәшләр, дуслар бер-берсенә бүре булып карыйлар. Трибунал утырышына киткән командир белән комиссар турында сөйләшәсе иде, уртага салып, кызып-кызып бәхәсләшәсе иде, әмма бүген учаклар аерым, җаннар бер-берсеннән кача гына ала, кызылармеецлар, кечкенә Питер эшчеләре таркалган. Командир белән комиссарны атачаклар... Ни өчен? Аларны үлемгә әнә шул учак тирәсендәгеләр илтеп житкермәдемени?.. Ничек аларны йолып алырга, дигән сорау полкташларның уена да килеп карамады. Алар таркау, сүнгән учаклар төсле сүрән, җансызлар иде. Кысылган иреннәрдә тәмәке төпчекләре чожлады, август күгенә тонык кына булып ай калыкты. Учак яктысы белән ай нуры кушылып, аларның үлек төсле чырайларын тагын да өметсезрәк, тагын да җансызрак итеп күрсәтте...

Командир белән комиссарны полкка кайтармадылар. Иртәнгә чаклы трибуналның хөкемен полкта белергә тиеш түгел иделәр. Нарком шулай боерды, трибунал шулай карар итте... Командир белән комиссарны Троцкий вагоныннан ерак та түгел бер сарайга илтеп яптылар.

Сарай эчендә дөм караңгы иде. Бәлки аның шулай булуы яхшырак та булгандыр? Алар бер-берсен болай да бик әйбәт күрәләр, сүз сөйләш-

мәсәләр дә, бер-берсенә ни әйтәчәкләрен, ни әйтә алачакларын беләләр. Тәмәке тартырга уйладылар, шырпылары беткән икән, сарай алдында сакчы йөреп торса да, алар аңа эндәшмәделәр, шырпы сорамадылар, казакълар насбай салган төсле тәмәкене тел асларына гына салдылар. Нидер эшләргә, ичмасам тәмәке яндырып булса да, вакыт уздырырга кирәк иде, әмма шырпылары юк. Юк икән, башка әмәлен таптылар, ачы су авызны, аңкауларны яндырып тамакка ук йөгереп үтте.

Командир комиссарны кызганды: яшь, кайнар, акыллы егет!

Комиссар командирны җәлләде: хатыны, ике баласы бар, улы белән кызы! Командирның френч кесәсендә фото бар, дүртәү төшкәннәр, хатыны елмаеп-көлеп карап утыра... Балалар алга, киләчәккә карап йотылганнар...

Комиссар полк турында уйлады...

Командир полк турында уйларга базмады. Уйлары соң дәрәҗәдә томанлы, башы авырта, аяк буыннарының хәле киткән иде.

Атарга хөкем ителгән кызыл командир белән комиссарның хәле начар, ә полкның...

Әле алар берни белмичә, үз уйлары белән төнне кыскартып сүнәрсүнмәс янган учаклар янында таралып утыралар. Һәр унынчы кызыл армеецның үләчәге турында әле белмиләр...

Ай бераз күтәрелгәч, сарай ишеге ярыгыннан эчкә нәзек кенә нур кылычы сузылды. Тик ул нурдан җылынып та, тәмәке кабызып та булмый иде.

Свияжскида таң атты, тик әтәчләр кычкырмады, сыер мөгрәмәде, каппельчылар бар җан иясен турап, кырып бетереп киттеләр. Дөнья бүген тып-тын, Идел ягыннан гына тавышлар килеп киткәли, сузып кына пароходлар кычкырта, тик пароходлар да ямьле таң атканын хәбәр итми, аларның үз вакытлары, үз мәшәкатьләре. Салкынча. Командир белән комиссар аркага-арка терәшеп арган аякларын сузып утырганнар. Ай кылычы югала, ишек шыгырдап ачыла, ишек тирәсен авыр аяк тавышлары күмә...

Полкны Иделгә каратып калкулыкта тезделәр.

Командир белән комиссар — революциягә кадәр үк партиягә кергән большевиклар уңда, уң флангта. Коралсызландырылган, рухы сынган полк, аз санлы булса да, бер генә рәткә тезелгәч шактый ишле булып күренә. Гаеплеләрне пулеметлар, карабиннар белән коралланган «Ваня-коммунист» матрослары чолгап алды. Иртәнге җил Идел өсләп килеп матросларның фуражка тасмаларын җилфердәтә, матрослар тасмалар белән моңлы күзләрен яшерергә тырышалар да кебек...

Трибунал коменданты саф алдына чыгып приговорны игълан итте һәм кәгазен кулында тотып саф буйлап санап бара башлады, һәр унынчыга ике адым алга чыгарга боерды. Командир һәм комиссар белән барлыгы егерме җиде кеше алга чыгып басты.

Егерме җиде кеше.

Кичә алар егерме җиде сугышчы иде. Бүген кулына зур власть тапшырылган кешенең шәхси капризы корбаннары, аның дуамал хөкеменә буйсынып алар хәзер һәлак булачаклар.

Атарга хөкем ителгәннәрне калган иптәшләр сафына йөз белән бордылар, «күрегез, янәсе, куркакларны, хыянәтчеләрне!» Күрегез һәм хәтерләп калыгыз: куркаклык кая китереп җиткерә!

Ике ара зур түгел, нибарысы ике адым, мәгәр бу үлем сызыгы, соңгы сызык. Хөкем ителгәннәр агарып каттылар, алар ике адым аша гына каршыларында басып торган иптәшләренә исләре китеп, аңышмыйча аңгыраланып, калтыранып карап каттылар. Нигә? Ни өчен без үләргә тиеш?!

Хәсрәт кешеләрне берләштерә, кичә куркудан тәмам сүтелеп киткән полк бүген уртак хәсрәттән соң үзен бер итеп, бер язмыш ачысын татучы

итеп сизде. Арадан юаш кына тавышлар ишетелгәләде: «Нигә без генә? Нигә алай?!» «Аңлатыгыз!» «Бергә идек ич без!» «Юк, бу гаделлек түгел!»

Исән калырга тиешләрнең сафы дәшмәде, хөкем ителгәннәр аларның сүзсезлеген, җансызлыгын күреп тындылар, йөзләр тагын да сүрәнләнде, күзләргә дым йөгерде...

Ике як та язмыш иркенә бирелде. Командир белән комиссар нинди яхшылык, кыюлык, теләктәшлек көтеп каршы яктагы полкташларына ымсынып карасалар да, беркемнең дә җылы карашын, теләктәшлеген таба алмадылар, барлык күзләрдә курку-каушау һәм сүзсез буйсыну гына чагыла иде...

Юк, алар берсе дә куркак түгел иде, алар сугыш кырыннан ни өчен һәм ничек качып китүләрен хәзер дә аңлап бетерә алмадылар, алар элек тыныч тормышка иялөнеп, карышусыз эшләргә күнеккәннәр, басынкы яшәргә гадәтләнгәннәр иде. Моңарчы аларны беркем дә сугыш эшенә өйрәтмәде, сугышның кыен, яңа сабакларын алар үзләштерергә өлгермәде.

Командир белән комиссар подпольеда кыю эш алып бардылар, шуннан торып көрәштеләр, төрмә-сөргеннәрне татыдылар, богау тагып йөргәндә дә рухлары сынмады, ләкин сугыш кырында, кирәк чагында алар качып баручы полкны туктата алмадылар, хәлләреннән килмәде, хәзер үзләре аңламаган рәхимсез, борынгы законның корбаннары булып калдылар, җаннары кычкырып җыласа да, үзләрен яклап сүз әйтә алмадылар.

Сафта калганнарның хәле яхшырак иде, алар әлегә язмышның усал камчысы үзләрен читләтеп үтүен, очраклы гына «унынчы» булмый калуларын аңлыйлар һәм урыннан кымшанырга да куркып эчтән генә зарланалар иде.

Матрослар егерме җиде кешене чокыр янына әйдәп китерделәр һәм команда көтеп калдылар. Алар арасында полк солдатларының күз тондырып качканын күргән шаһитлар да бар иде. Сугыш кырында чакта ачулары килеп аларга ләгънәт укысалар да, хәзер, тыныч иртәдә, егерме җиде кешенең үлемгә хөкем ителүен алар аңламый да, кабул итә дә алмый иде... Әле беркем дә приговорга ышанып бетми, һәммәсе дә ниндидер үзгәрешкә өметләнәләр, кемдер килеп чыгар да: «Булды, шаярдык!» — дип әйтер кебек иде. Трибунал коменданты да һаман өметләнә, нарком урнашкан салон-вагон ягына карап-карап ала, хөкемне җиренә җиткерүне һаман суза иде.

Ниһаять, йөрәк яргыч команда тавышы яңгырады. Карабиннар иңнән кулга күчте, залп тавышы һаваны ярды. Беркем дә һавага атмады, пулялар үз корбаннарын эзләп тапты, әлерәк кенә тауЧыкта басып торган кайнар канлы, эссе җанлы кешеләр, хакыйкать тантанасын көткән, җиңүне китерергә омтылган кешеләр авыр ыңгырашып чокырга тәгәрәде. Беркем дә кымшанмады.

Гайнулла Таһиров һаман төрмәдә утыра.

Мин Фәридәнең күзләренә туры карый алмыйм...

Ничә карасам да, аның күзләрендә шул ук җавапсыз сорау: «Ничек, Сергей Сергеевич? Яңалыклар юкмы, үзгәрешләр?»

Соңгы көннәр, атналар мине тәмам эздән чыгарды. Нервылар шулкадәр таушалды, һич нәрсәгә карамыйча больницага кер дә ят, валлаһи! Вакыйгалар бер-берсенә ялганып тоташ агалар, бер-берсен яңартып яки бетереп, изеп ташлыйлар, күпчелегенең асылында һич көтмәгән, уйламаган фаҗига ята. Һәркайсын табарга, аңларга, үсеш юлларын чамаларга, кайберләренең юлына аркылы төшәргә дә кирәк. Күңелемә еш кына: «Кеше күпмегә кадәр түзә ала, аның җаны кайчанга хәтле чыдый?» — дигән сәер уй килеп китә.

Свияжскидагы децимация хәбәре йокыны бөтенләй качырды...

Кешелек дөньясы бик борынгыдан үләләргә һәм тереләргә бүленә. Күпчелек очракта үләләр тереләргә караганда куркынычрак санала. Тереләр аларны хәтердә саклый, үлгәннәр адәм балаларының шәфкатьсезлеге, кансызлыгы турында бик еш искә төшереп торалар.

«Әгәр теге яки бу фикерне тормышка ашырганда, ни теләсәң шул рөхсәт ителеп, гамәлләреңнең һәммәсе дә аклана икән — бу фикердән читтәрәк йөрергә тырыш. Хаксыз чаралар белән максатыңа ирешсәң — бу хак максат түгел диган сүз». Маркс шулай ди. Адәм балалары хак максат куеп, тоташ гаделлек турында хыялланып революция юлына чыктылар. Хаклык сөйгән җаннарга гаделлек тулаем, үзгәрмичә, бөтен килеш кирәк иде!

Бүген исә, бөтен дөнья күз алдында, аны-моны абайларга күнекмәгән, революцияне яклаудан бүтән максатлары булмаган, көтелмәгән шартларда каушаган гаепсезләрне революция исеменнән тоталар да аталар. Мондый адым гаделлекнең кайсы төренә керә икән?! Гомумән, гаделлек төрләргә бүленә аламыни? Чигенгәннәр икән, чарасын тап, нигә урта гасыр кыргыйларына әверелеп вәхшиләрчә кыланырга?!

Бисмарк үз вакытында әйтеп калдырган: «Революцияне даһилар уйлап чыгара, фанатиклар тормышка ашыра, аның җимешләре бушбугазларга аш була» — диган. Әмма бу раслау һәр революциягә ябышып бетмидер, ләкин явыз Бисмарк бер нәрсәдә хаклы — революция агымына бик күп җилкуарлар, авантюристлар һәм мошенниклар ияри, халыкларның иң изге хисләре өстенлек алганда, алар үзләренең шакшы кулларын җылытып калырга тырышалар.

Нарком Троцкий вәкаләтен күпкә арттырып җибәргән, аңа аклау һәм аклану булмас, тик аннан хәзер ни файда? Аның тилемсәр боерыгы белән һәлак ителгәннәр терелеп тормас...

Ә бүтәннәр? Исән калганнар?!

Бергә Питердан килеп, бергә утка кергән сугышчан иптәшләре? Бер минут элек кенә сафта янәшә басып торган эшчеләр?! Алар нигә дәшмәгәннәр? Командир белән комиссарны, иптәшләрен яклап ник тавыш күтәрмәгәннәр?! Асылда алар да шәфкатьсез хөкем карарына кул куйганнар булып чыга лабаса! Ризалашырга аларны кем мәҗбүр иткән? Нишләп алар шулай үзгәргәннәр анда, Свияжскида, Идел ярында?!

Бәхәс юк, Троцкий үзен зур бер диктатор итеп күрсәтергә теләгән. Шуны да искәрик, тәхетеннән чәнчелеп төшмәгән диктаторны тарих хәтерләми, белми. Хәзер революция, сугыш бара. Сугыш уен түгел, ул сүзсез буйсынуны, тәртипне сорый, тик тәртип һәм буйсыну акыллы, хак принципларга корылсын. Гаепсезләрне тиктомалга юлдан алып ташлауны ничек тә аклап булмый. Һәркем кылган гамәлләре өчен үз язмышы белән җавап бирә. Кеше үлә, әмма аның эше, кылган гамәлләре дөньяда — тереләр арасында кала, яхшысы-яманы җирдә кала. Саклана. Тора-бара алар калкып чыгып караңгыда яткан тарих битләрен яктырталар, иртәме, соңмы, яңадан яши башлыйлар, хәтта яңа буыннар үз сәясәтләрен, үз кылмышларын аклар өчен тарихны «төзәтеп», «үзгәртеп» язарга тырышсалар да, дөреслек өскә чыкмый калмый.

Революцион җиңүләрне үз туганнарының, җирдәшләренең каны белән сугарып яшәп булмый. «Беркемгә дә болай яшәргә рөхсәт юк! Рөхсәт итәргә ярамый да!» — дип кисәтә тарих.

Күземне ачсам, янымда Таня басып тора.

Таня, Таня!.. Аның йомшак бармаклары җыерылган кашларымны җылыта, йомшак учлары яңагымны иркәли, сыйпый...

Алар Фәридә белән Иске Аракчинога барып кайтканнан соң байтак җаваплы эш башкардылар, тәмам дуслаштылар, берсе өчен берсе үлеп торалар. Хәзер Таняның ялгызын да йөртәбез. Лациска диган

донесениеләрне алмаш-тилмәш илтәләр, шәһәрара элемтәгә йөриләр, сизгер, сак һәм бик акыллы кызлар...

Бүген Таняга карадым да тагын Зоряны искә төшердем...

Ул да революция корбаны...

Яшьли, әле чын бәхетне татырга да өлгермәгән килеш дөньядан китеп барган җан. Гүзәл җан!

Саҗидә Салиховнага һаман өенә кайтырга ярамый әле, ара-тирә аның йортын һаман иснәштереп торулары безгә мәгълүм иде. Таня да, әнисенең ялгыз калуына бик борчылса да, һаман үз йортын читләтеп үтә. Уйлаштык-уйлаштык та, без Саҗидә Салиховнаны Таняның әнкәсе янына күчереп куйдык. Тыныч көннәргә кадәр бергә яшәсеннәр! Берсенә куаныч, икенчесенә юаныч...

— Янасыз, Сергей Сергеевич, маңгаегыз кап-кайнар, — диде Таня. — Яныгызда күпме басып торам, күзегез ябылыр-ябылмас, саташтыгызмы, әллә кемнедер каргадыгызмы, ирennәрегез кыймылдады.

— Таһиров ни хәлдә?

— Фәридә «исән» ди. Ә Вахитовны атканнар.

Торып утырдым, утыруыма башым әйләнеп китте. Әллә чынлап торып чирләргә маташам инде? Бәхетсезгә — вакытсыз чир...

— Ишеттем. Анысы мәгълүм. Аны коткару планы барып чыкмады. Барып чыкмады, Вахитов вафат. Аны коткарырга барган Гайнулла төрмәдә утыра. Аны да үлем көтә!

— Сезгә артыгын борчылырга ярамый, Сергей Сергеевич!

— Борчылырга кирәк, Таня. Һәммәсен, булганын һәм буласын борчылган күңел генә хәтергә сеңдерә ала. Борчылмаган хәтер сай, андый кеше ярты гомерен йоклап үткәрә! Сөйлә, сораш, төпчен, җанымны ал! Уйлый, эзләнә торгач, бәлки уңышсызлыкларның очына барып чыгарбыз. Сора, Таня, вакчылланып тинтерәтеп бетер!

— Капкада кеше!

Бер минутка сагаеп, тынып калдык.

— Ишек кагуын таныйм, безнең кеше!

— Ач!

Сабы һәрвакыт диярлек җылы наганымны мендәр астына шудырдым, ишек артында: «Фәридә, җаным, сагындым сине!» — дигән сүзләрне ишеткәч кенә җиңел сулап куйдым.

Йөзе сулып, суырылып калган Фәридә керә-керешкә миңа кәгазь кисәге сузды.

— Сергей Сергеевич! Төрмәдән, Гайнулладан!

Күзләрем таушалган кәгазь юллары буйлап йөгерде.

«Әлегә исән-сау... Допроска йөрүләре бик авыр... «Вахитов исән!» дигән сүз таралды. Алар Алкин белән очрашканнар, ул аны Самарага озаттырган. Бәлки Мулланурны коткарып та булыр. Рычковның адъютанты Клепиков һәр нәрсәне беләдер, мөгаен. Очрашып сөйләшә алсагыз икән! Әлегә сау булыгыз. Гайнулла».

Фәридә белән Таня пәрдә артына аулакка кереп утырдылар.

Димәк, Вахитов исән? Аны коткару чарасына өр-яңадан керешергә кирәк. Флегонт Клепиков, Флегоша! Кем аңа чыга ала, кем?

Кылт итеп гауптвахтада бергә утырган «законлы карак» исемә төште. Беркөн кичкырын мин аны вокзал тирәсендә күреп калдым. Эндәшергә базмадым, яхшысынмадым. Иректә икән, яхшы. Бәлки хак юлга төшәр?! Эндәшәсе калганмы әллә? Бәлки ул бер юлын табар? Клепиков законсыз карак, бәлки уртак тел таба алырлар иде.

*Ахыры бар.*

## Равил Фәйзуллин

## «ТАУЛАР» ЦИКЛЫННАН

### Саумы, таулар!

Саумы, таулар!
Тәпи басмасам да сезне күреп,
яшьтән үк сез йөрәктә инде!
Әллә ерак бабамнарның каны
кыяларга береккән инде.

Саумы, таулар!
Озын сәфәр үтеп,
сәлам әйтәм Биекстанга!
(Минем дә бит үземә «станым» бар,
гаҗәпләнмә шулай кушканга).

Саумы, таулар!
Сезгә ятмы, үзмедер мин, белмим,
гашыйк булгач, шиктә юк гамем.
Күземә генә түгел, рухым өчен,
үземә генә түгел, халкым өчен
биеклекләр барлап килгәнмен.

Саумы, таулар!
— Сау-у-м-ы-ы...
Кабатлыйсыз?
Ишеткәнсез икән ләбаса!
Тау һәм Кеше биегәя бары,
бер-берләрен әгәр аңласа.

### Кайсын пигы итәгендә

Ватаныңа килеп, тауларыңда йөрим.
Үзең исән чакта соңладым.
Бер юаныч: исемең йөрткән пикны
үз күзләрем белән күрә алдым.

Монда булып киткән зур шагыйрьләр
данлап язсалар да тауларны,
таулар җанын йөрткән халык рухын
килгән-киткән сәях аңлармы?

---

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН *(1943)— шагыйрь, татар һәм рус телләрендә басылган егермедән артык шигырь китабы авторы. Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, РСФСРның атказанган культура хезмәткәре, Казанда яши.*

Таулар матур. Әмма кырыс та алар.
Ташны тирең тишсә — син ашлы...
Әйтә идең: тауларымның минем
күләгәләре дә кояшлы!

Киртләч-киртләч икән тау очлары —
гүя кардиограмма сурәте!
Ничек түздең икән, йөрәгеңә
ишелгәндә халкың хәсрәте?

Синдәй ирләр барда, аз халык та
ишле, бөек булып таныла.
Әйтелгән сүз, күкрәү-яшен булып,
әверелә дөнья данына.

...«Ах! тау юклыклар...» дип язган идем
күптән инде — үсмер чагымда.
Гомер тавын төшеп кабатлыймын,
таулар юк! дип, тагын, тагын да.

Казаннарга килеп чыга идең,
күңелләргә шатлык өләшеп.
Егет булып калдың күңелләрдә,
бер символы булып көрәшнең.

Син бер ныклы тере күпере идең
болгар иле белән балкарның.
Җәрәхәтле таш та җанланадыр,
канат тисә — синдәй шонкарның!

...Кайсын пигы. Биек. Итәгендә
яшь бөркетләр канатланалар.
Таулар биеклекне югалта алмый —
алар күккә кадакланганнар!

## Тау — шул ук җир...

Тау — шул ук җир. Тик аңарга
башны чөеп карар җир.
Тау — шул ук җир. Туарга да,
күмелергә дә ярар җир.

Тау — шул ук җир. Тик һәркемнең
табанына ятмас җир.
Тау — шул ук җир. Биеклекне
бер югалтсаң, тапмас җир.

## Тау өстеннән йолдызлар да якын...

Тау өстеннән йолдызлар да якын,
егылсаң да, кеше күзендә...
Таулар — гадел. Ни дип кычкырсаң да,
кайтавазы кайта үзеңә.

Кара төн дә караңгылата алмый
түбәдәге карлар аклыгын.
Биекләргә менеп кою кирәк
җанны сарган тормышваклыгын!

## Эльбруста исем турында уйлану

Ошхамахуа дип аны
адыгей халкы әйтә.
Грузинча Ял-буз булыр,
Куска-мафь ул — чиркәстә.
Осетиннарда — Ура-хох,
балкарларда — Мәңге тау...
Һәркайсы җирле халыкның
тауны зурлап атавы.
Мәгънәләре бер диярлек —
Олы тау, Мәңгелек тау,
Изге тау, Бәхет тавы...
Ничек кенә әйтмәсеннәр,
бар шул әйтерлекләре —
Туган җирләре символы,
изге биеклекләре!
Тауга якын бу илләрнең
язмышлары да текә!

Һәрбер ташка халыкларның
тарихлары береккән.

Кемнәр генә үрелмәгән
бу тауның ияренә![1]
Ышанып, биек тәхетнең
үзенә тияренә...

Аш-гамахо, стыр-хох...
Һәрбер исем изге лә!
Ә менә ерак халыкның
исеме калган үзендә:
Эльбрус дип танылган ул.
Эль-борыс — фарсычасы.
...Белмим, ни дип атый аны
бөркет — кошлар патшасы?

## Биеклектә

Кыя — текә. Җилләр йолка.
Кузгала таш... Кая басыйм?

Колакта өн: менгәнсеңме —
«Егылам!»...— дип,
ярдәм сорап кычкырма син!

## Иң биек тау

Кояшларга якын түбәләр бар!

Кешеләр,
бәхетле җыр җырлый-җырлый,
менеп-төшеп йөри алса —
кечкенә үр дә
иң биек тау минем өчен.

## Ышаныч

Күп илләр бар, күп җирләр бар, күп телләр бар...
Ә гомерләр — һәркемнең дә берәү генә!
Җырым әйтсен: халык өчен җан аямый
яшәүчеләр ирешсеннәр теләгенә!

Гөл-чәчәкле, алсу таңлы бу дөньяга
туа кеше бәхет өчен, шатлык өчен.
Ил язмышы кыл өстендә калса әгәр,
Көрәшчеләр башын сала хаклык өчен.

---

[1] Эльбрус тавының түбә өлеше ияр сыман ике өркәчле сырттан тора. Автор.

Җир йөзендә күпме ана бала бага,
өметләнеп тыныч көнгә, якты көнгә!
Һәммә кеше шат яшәсен, бәхет җырын
җырлый-җырлый туган җирдә, туган телдә!

## Гел генә иман яңартып дөньяны каргаучыга

«Дөнья — усал-фәлән...»— диеп,
кан елау яхшы түгел!
Бөтен искән җилләр дә бит
гел генә каршы түгел.

Төп кыйблаң булмый торып,
гел-гел иман яңартсаң,—
гаҗәп түгел, Язмыш ханым
борыныңны канатса...

Иман ул үзгәрә алмый,
иман ул — ныгый гына!
Дөньяны — кыйный! — димик,
дөнья — сыный гына!

## Борчылуда туган ышаныч

*Кеше ник дип өзә икән*
*үзенең иң газиз кылын?*

Безнең замана кешесе
бик күп нәрсәгә ия...
Бер җан башына фәләнчә
шартлаткыч кына тия!

Шундый авыр йөк тагылгач,
нишләсен мескен Адәм...
Ышаныч-максат күрмәгәч,
хәйраны... була әрәм.

Әйтик, Европа илләрендә
бала туу аз хәзер.
Аның каравы, ишәеп,
ракеталар тора әзер.

Әкият булып яңгырамый
хәзер «ахыр заман»ы.
Мифта түгел, чынлыкта шул
бандиты, наркоманы...

Нурланып туа һәр кеше.
Була якты хыяллы!
Яши-яши күңеленә
иблис кереп оялый.

Каян килә имансызлык?
Вату-җимерү уе?
Шәхси «мин»нән — дәүләткәчә
үзеңне өстен кую?
Нигә күп көч сала кеше
һәлакәт уенына?
Нигә дип аркылы төшми
чын афәтләр юлына —
әмәл тапмый яман шешкә,
вакытсыз картаюга?..

Ник карамый киләчәккә
баласы күзе белән?
Кем ни алып китә ала
туфракка үзе белән?
Кала барсы... һәр киткәннән —
үзгә кала ил йөзе.
Ныгытып китә — я яхшылык,
я яманлык нигезен.

Нигә таянып үсмибез
хәкимнәр мирасына?
Тарих битендә күбрәк
иң әүвәл тиран чыга!..
Җиһангирлар, каләм алып,
халык канына манып,
язалар җиңү турында,
рухланып һәм мактанып.
Гел тукыгач, әйткәннәре —
чынлыкка охшап китә,
елъязма булып кала да
байтак буынга җитә!
Дәһшәт булып, көч калыкса,
Тынычлыкка бетә рәт...
Аптырап һәм мәэюсләнеп,
Акыл кала читтәрәк.
Ни мәгънә ачышлардан,
афәт китерер булса,
Табигатьнең ямен көчләп,
асылы — үтерү булса?
Сугыш юлы — билгеле юл —
һәлакәткә туп-туры...
Күз нуры түгел икән шул
радиация нуры!

Моңарчы Адәм шикләнмәгән
һәр даим җиңәренә,
хәзер үзе аптырашта
матдә-атом җегәреннән.

Гүя аткан угы кире
үзенә төшеп килә.
Төзәтелмәс ялгышлары
исенә төшеп килә.
Тиккәмени күпме җаннар
чаң сугалар айнырга!
Ашкынып коралланырга
каршы коралланырга!

Җир — уртак өй. Бу яшәүнең
белик кадерен генә...
Белик чикләр шартлылыгын
җилләр кадәрле генә!

Кояш — Зәңгәр йомгагына,
бәлки, карыйдыр көлеп;
Җирдә тереклекнең мәңге
бетмәячәген белеп.
Ә безгә дә белү кирәк
алда ниләр буласын.
Яңа туганнар иң әүвәл
синнән-миннән сорасы.
...Бүген бездә — үзгәрештә,
Яңарышта һәр күңел!
Гасыр ахыры булса да,
Заман ахыры түгел!

## Яшәү бит үзе бер бәйрәм лә!

*Боекма! Елмай, көл!*
*Күңелеңә*
*ясын гел шифалы ләйсәннәр!*
*Хыяллар күгеңдә*
*җилфердәт әләмнәр!*
*дөньяда яшәүләр —*
*аңлаган кешегә*
*үзе бер бәйрәм лә!*

Тагын көннәр аяз! Кояш көлә!
Туган якка кайткан сыерчык!
Ничек моңа сөенмәскә кирәк —
быел язга тагын сау чыктык!

Әти-әни исән. Ярым янда.
Сөйгән эшем — җанга бер дәва.

Ихлас әйткән гадел сүзебездән
яңа яхшылыклар ярала.

Дөньялар имин. Хыяллар сау.
Җыр туарлык муллык табында.
Заманалар меңгә әйләнсә дә,
фидакарьләр һәрчак табыла...

## СИГЕЗЬЮЛЛЫКЛАР

Вакыт өчен нәрсә Адәм гаме!
Һәр үзгәреш аңа — дөреслек!
Гаҗәпмени Атлантида хәлен
аңлый алмый икән Эверест...

Кайчак сыйпап сөйгән гөлләрең дә
белми-тоймый синең шатлыкны.
...Кем ишетсен, галәмгә дип тебәп,
җиң эченә әйткән хаклыкны.

## Чормада

Ярыктан кергән дә шуып,
әйләнә җил,
тулгана җил!
Эх-ма!

Тузан белән бөтерелә!
...Чөйдән салынып карап тора
заманында ил алдында
аю биеткән гармун.

Яшәү ул — һәр күзәнәкнең
иркен, рәхәт сулавы.
Тәннең Кояш каршында
көч тоеп уйнаклавы.

Бәхет ул — һаман яшь калып,
максатка ирешә алу.
Рух бүлешер җандаш табып,
сөенә-сөешә алу.

## Алма һәм корт

Орлыкка елышкан кортка
алма әйләнгән йортка!
Алма үзе, я яман корт
чыгарга тиеш юкка...

Юк шул. Алма эленеп калды.
Дөрес, бозылган эчтән...
Корт та исән. Инде әнә
бүтән алмага күчкән!

❁

Ашыгып әйтмә: «Һай, гамьсез ул!»— дип,
гел елмаеп йөргән кешегә.
Елмаюы битлек кенә булып,
ут сулыйдыр, бәлки, эченнән...

Җанын талкып, артык йөдәтмә син
уйчан калган ялгыз кешене.
Җиңәр өчен күпләрне ул, бәлки,
ялгызлыгы белән көчледер?..

# ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

## Үз-үзеңне...

Үз-үзеңне кыйнау яхшы —
мунчада чабынганда.
Үз-үзеңне мактау ярый...
Эшкә рухландырганда.

## Тегермән урынында

Бер-ике учма арыш башы...
Калган үлән — алабута.

...Зур ипи кыерчыгы күк
җиргә батып, ташы ята.

❁

Киштәләрдә арта китапларым.
Маңгаемда — җыерчыкларым...
Башта — чәчләр сирәкләнә бара...
Күңел дә зирәкләнә бара!

## Каян чыга бу сугышлар?..

«Аек бул»мы? Бар да аек түгел, җаный!
«Юләр бул»мы? Бар да юләр түгел, җаный!

...Айный да тилерә, тилерә дә айный!
Кешелек үз хәлен юньләп аңлый алмый...

## Бер карт сүзе

Картайдым: өем тулды —
җиһазны җиһаз тартты...

Баедым: ишек төбендә
юлдашым — таяк артты!..

❁

Олы шатлык килсә, сагаямын.
Китәчәге авыр буласы...

«Алтын алма!» диеп үрелгәндә,
карыйм аска: кая егыласын...

## Рәхмәт!

Алда язмыш ни күрсәтер...
Үткәненә — мең рәхмәт!

...Моңарчы гел юлдаш булды
Саулык белән Мәхәббәт!

❁

Кош бит мин! Шуңа егылмыйм.
Имгәнми генә авам...

Кеше шул мин. Күккә генә
сыймаслык йөрәк ярам.

## Вакыт үткәч, иясе киткәч...

Әй килә соң тапкыр сүзләр бәхәс тынгач!..
Кайчак ачыграк дөнья — күзне йомгач...
Күпме сөю уты каба җанга яшьлек үткәч!..
Күпме дан йөри артта — иясе киткәч!..

## Рафаил Төхфәтуллин

# ЧАТТА ТУКТАЛУ

ПОВЕСТЬ

I



Көз якынлашып килгән көннәр. Күк йөзе чалт аяз булса да, кояш инде алай кыздырмый, битеңне рәхәт җылыта гына. Басу юлы, авыл урамы буйлап үтсәң, һавада кара болыттай карга көтүләре, җыйнак-тату сыерчык өерләре очып үткәнлегенә игътибар итми калмас идең; битеңә көмештәй тоҗым җепселләре йомшак кына килеп сыланыр, колак турыңнан пырылдап соңгы күбәләкләр соңгы сулышларын өреп узар иде.

Ләкин Салих басу юлы, авыл урамы буйлап үтми, зур булмаган бер шәһәр урамыннан атлый, һәм ул, һәр шәһәр кешесе кебек, һаваларга күз йөртеп, җай гына баруларны күптән инде оныткан. Карашын алга гына төбәгән дә җәһәт-җәһәт атлавын белә. Адымнары җиңел булса да, яшь кеше түгел инде үзе. Коңгырт эшләпәсе астыннан бөселеп чыккан аз гына бөдрәрәк купшы чәчләренә бәсләр шактый мул кунган, яңак, авыз кырые җыерчыклары, җир башындагы дугай буразнадай, бер карауда ук күзгә ташлана.

Әледән-әле каршы очраучылар белән сәламләшеп үтүе бу шәһәрдә аның абруйлы кеше икәнлеген күрсәтә, ә беләгенә аскан күк плащы һәм әле бер, әле икенче кулына күчереп күтәреп барган кызгылт сумкасы исә аның юл кешесе икәнлеген дә сиздереп тора.

Урам чатына җиткәч, Салих халык агымы белән бергә тукталып калды. Машиналар үткәреп басып торганда, Салихны һәрвакыт тыенкы гына эчке бер ярсу биләп ала. «Тор инде менә хәзер! Машинага утырып алганнарның барысы да — бик кирәккә, бик хаклыга утыручылар да, бүксәләрен кырын салган көйгә кукыраеп кына килеп салырга яратучылар да, җыен бушбугаз да, бер-берсенең иреннәренә сөлектәй ябышкан пумала башлар да, ягъни, дүрт көпчәккә ия «эте дә, бете дә» үтеп киткәнче,— тик басып тор. Никадәр генә ашыксаң да, бик кирәкле эш белән йөрсәң дә... иң элек үткәреп җибәр әнә шулай дүрт көпчәккә ияләрнең барысын да, аннары гына сиңа да юлыңны дәвам итәргә чират җитәр. Аннары гына син дә үзеңнең җир өстеннән йөрү хокукыңнан файдалана аласың.

---

РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИН *(1924) — прозаик, Татарстанның атказанган культура эшлеклесе, «Йолдызым», «Җиләкле аланнар», «Акбүз ат» һәм башка повестьлар, хикәя китаплары авторы. Әсәрләре күп кенә совет һәм чит ил телләренә тәрҗемә ителгән. Әлмәттә яши.*

Кайчан башлангандыр мондый ярсулы хис, Салих моны үзе дә хәтерләми. Студент чагында, лекциягә соңармагаем дип бик ашыкканда мы, әллә аякларын көчкә сөйрәп, авылга кайтышлый, кулыңны күтәрсәң дә, туктамый торган машинага, былчыракка чыгып, юл биреп калгандамы? Әллә сабый чакта ук: «Таптап, сытып үтә күрмәсен тагын бу тырылдык нәмәрсә»,— дип шүрләү белән үкчә ялтыраткандамы?

Ни генә булмасын, һәр чат саен уяна мондый ярсулы хис Салихта. Уяна һәм чатны үтеп китүгә онытыла да. Шулай, дөнья мәшәкате безнең көнелләрдә һәртөрле фәлсәфәдән һәрчак тизрәк өскә калкучан.

Бу юлы да шушы ярсулы уй-хис күңелдә уянып өлгерде.

Үтә дә үтә машиналар. Әллә светофор ватык инде, яшел ут һаман янмый. Салих сәгатенә күз төшерде: Казан автобусы китәргә ун минут кына калып бара. «Ах, япты башмак!» — дип, юлчы үзенең бердәнбер сүгенү сүзен пышылдады, шуңа ялгап, теленә бабасыннан күчеп калган әлеге «эте-бете» дигәне килде. Шул сүз тел очына килүе булды, ниндидер «Запорожец» тәрәзәсеннән тупыйк танаулы кыяфәтсез бер эт анын битенә генә иләмсез өреп тә үтте. Салих тагын «ах, япты башмак!»ны кабатлады, машиналар агымының очын күрергә теләп, сулга текәлде. Кәефне җибәрергә машиналарның гадәттәгедән дә озаграк агып торуы, тупыйк танаулы этнең аны мыскыллагандай һаулап узуы бик җиткән иде инде. Шулчак якынлашып килүче бер машинада шофер белән янәшә утырган таныш йөзне күреп алды ул. Бик таныш, бутарга һич мөмкин булмаслык артык таныш йөз иде бу. Зиннур Дибаев. Калын гына кара кашлары, шакмакланыбрак килгән нык ияге, матур гына зуррак коңгырт күзләренең үтә җитди карашы — бөтен кыяфәте белән: «Мин барында һәммәгез дә читтәрәк торып торыгыз әле» — дип әйтеп торган Зиннур Дибаев килә иде ялтыр кара «Волга»да.

«Тагын юлыма аркылы төшәсеңме?!» — дип, гасабилы уйлап куйды Салих. Шунда ук үз-үзенә җавабын да бирде: әлбәттә, төшә. Менә ул чаттан тоткарсыз гына үтеп китәр, машинасында кырын ятып кына Казанга ук барып җитәр. Ә син, аңа юл биреп, шушында басып кал, аннары да кырык мәртәбә туктала-туктала, автобуста тыркылдап бар, аннары троллейбусны көт... Әлбәттә, тагын ул алдан өлгерә.

Күңел күз алдыннан үткән мондый күренеш белән һич килешә алмый иде. «Юк инде, бәгырь кисәгем, бу юлы Салих моңа юл куймас! Хәзер үк аэропортка, самолеттан төшүгә — такси эләктерергә. Ә син хәзергә тыныч кына машинаңда бара бир. Әйе, хәзер үк аэропортка! Юл кагыйдәләре, имеш. Студент чакта, бик ашыкканда, яшел утны гына көтеп тормый идек бит әле. Әйдә, Салих, күрсәт өлгерлегеңне!

Уйлар елдамлыгы аякларга җитезлек бирде. Чираттагы машина үтүгә, Салих алга ыргылды. Бик ачы гудок яңгыраса яңгырады, бу машинаны үтте. Аннары тагын гудок, бот турысы бик каты авыртып китте, шулай да — алга... Ләкин ни булды соң әле? Абындымы, әллә машина бәрдеме? Нигә дөнья болай караңгыланды?

Көпчәкләр шыштырдавы, чылтырау, чыңлау, кешеләр кычкыруы... Барысы да караңгылык эченнән генә ишетелә иде инде. Караңгылык куерганнан-куерды, тавышлар тынганнан-тынды... «Әнием!.. Беттем!» Монысы инде уйларның да бетүе иде.

Машинаның кинәт туктавыннан Зиннур Дибаев бөтен гәүдәсе белән алга сөрлекте, аяклар да идәннән купты. Ләкин бер җире дә бәрелмәде — куллар алдагы тоткага нык ябышып өлгерде.

— Ни булды? — диде ул, шап итеп кире утыруга. Шофер егет сүзсез генә иңнәрен җыерып куйды да машинадан чыкты. Бик тиз әйләнеп тә килде.

— Бер тилесе машина астына ташланган анда. Бездән алдагы шофер, «күзләремә карап, юлга үзе атты»,— ди.

— Хәл-ләәр! — дип, уфылдаулы сузды Зиннур һәм үз ягындагы ишекне бик кискен кытырдатып ачты да алдагы кешеләр төр-

кеменә таба атлады. Төркем артык шаулашмый, сөйләшүләр тыенкы, уйчан.

— Барып житте мужик...

— Милиция килгәнче, кагылма! Шулай тиеш.

— Ничек инде? Бәлки һуштан гына язгандыр?

— Белмим, малай. Ай-һай...

Зиннур күз алдына кан эчендә яткан гәүдәне китерде дә тукталып калды. Олы буе алга-артка чайкалып куйды. «Юк, күрмәвең хәерле. Әллә нигә кадәр күз алдыңнан китмәс... Һәрвакыт шулай — ашыккан юлга таш ишелә».

Ул арада, тәшвишле кычкыртып, «Ашыгыч ярдәм», аның артыннан ук милиция машиналары килеп житте. Зиннур тагын алдагы төркем ягына китте. «Тик мәеткә карамаска! Күз дә төшермәскә! — дип, күңеленә беркетә барды ул.— Юкса, бүгенге көн бетте диген сүз. Бүгене генә үтсә әле... Кайдан чыкты соң әле бу афәте? Тизрәк барып житәсе иде бит».

Аяклар атлый бирде. Төркем сүзсез генә икегә аерылып, аңа юл бирде. Аны танулары булдымы бу, әллә нык иякле, нык адымлы, олы гына гәүдәле бу кешегә шулай тиешле дип санадылармы — ни арада Зиннур ак халатлар, зәңгәр фуражкалар янына килеп басты. Хәзер инде карамый мөмкин түгел, хәзер инде күз алдында иде: юк, алай кан эчендә ятмый икән, йөзтүбән барып төшкәнгәме, канаган, имгәнгән жире дә күренми, әмма шунда ук Зиннурның бөтен тәне буйлап көчле ток үткәндәй булды. Ул түгелме соң бу?

— Ничек? Исәнме ул? — диде Зиннур, янәшәсендәге ак халат жиңен бик кискен тартып.

Ак халат җавап бирмәде. Һәлакәткә очраучыны носилкага әйләндереп салуга, Зиннур үзе ике кулын алгарак суза төшеп, үзе ярымйорты адымлап арткарак чигә башлады. Ул! Кисәк борылып, машинасына таба ыргылды. Төркем бу юлы аңа бик юл биреп тормады, этәтөртә, аны ерып узарга туры килде. Машинасы ишеген ачуга, гадәттәгечә салмак-таләпчән әйтте:

— «Скорый» артыннан калма. Киттек. Тизрәк!

## 2

Ничек иркен, ничек киң һәм никадәр тар, никадәр кысан да бу дөнья дигәнең.

Күреп ятасың, өстеңдә генә бик матур, ихтимал, бик тәмледер дә нәрсә ялтырый. Кулларыңны, аякларыңны сузасың, бар көчеңә селтисең — барыбер тотып, авызыңа кабып булмый. Өстәрәк тагы да матуррак, тагы да тәмлерәк әйберләр бар бугай. Кул-аякларыңны тагы да, тагы да көчлерәк селтәсәң, житеп булмасмы?

Житеп булмый. Шунда дөнья кинәт тап-тар булып кала. Тап-тар, ләкин ифрат йомшак, ифрат рәхәт, ифрат тәмле бу тар дөнья. Борыныңа төртелгәне дә, арканнан кочканы да йомшак, иреннәрең белән суырганы шундый тәмле.

Аннары тагын киң дөньяга чыгасың. Өстеңдә, як-ягыңда тагын бик матур әйберләр ялтырый, ләкин хәзер инде аларны суырасың, авызыңа кабасың килми. Карап кына ятуы да рәхәт. Рәхәтен рәхәт, ләкин нәрсәдер житми. Баягы тап-тар дөньядагы кебек, түп-түгәрәк түгел бу рәхәтлек. Нидер житми. Һәм син, шулай нидер житмәгәнен белдерү өчен, бар көчеңә кычкырасың.

Шунда, бая сине тап-тар дөньяга алып киткән рәхәт йомшаклык тагын кочып ала. Син югарыдагы шул матур әйберләргә табарак очып китәсең. Ләкин очып житмисең, борыныңны ифрат тәмле рәхәт ис тутыра да, анда таба очып житәсең дә килми. Бая гына нидер житми ке-

бек иде, менә шушы тәмле ис житмәгән булган икән. Тәмле ис гел килеп тора, суырмасаң да тәмлелеге сизелеп торган ифрат йомшак әйбер иреннәрең янында гына, кая карама, матур-матур ялтыравыклар... Иркен-киң дөньяда да бик рәхәт икән.

Бу киң рәхәтлектә күпмедер назлангач, сиңа тагын нидер житми. Һәм син инде беләсең: шулай нидер житмәгәнен белдерү өчен, бөтен көчеңә кычкырырга кирәк. Кычкырасың. Һәм тагын үзе тап-тар, үзе рәхәт-йомшак дөньяда каласың. Иреннәрең ифрат тәмле нәрсәне хәзер инде үзе табып ала. Суырасың, суырасы килми башлаганчы суырасың. Инде берни дә кирәкми. Кулларыңны, аякларыңны тагы да житезрәк селтәп булганын гына сизәсең. Кулларың, аякларың белән генә түгел, башың белән дә омтыласың, өстәге шул матур әйберләргә таба житеп булмасмы? Була түгелме? Тагы да, тагы да өскәрәк башны!

Шулчак әллә ни була. Бик тәмле исле жылы йомшаклыкның сине тагын кочып алуына куанырга да өлгермисең, тагын да кысанрак дөньяда каласың. Аягыңны-кулыңны да, башыңны да селкетерлек түгел бу тагы да кысанрак дөньяда, хәтта кычкырып та булмый. Шушындый ифрат кысынкылыкта үзеңнең каядыр очып барганыңны сизәсең. Очып баруы күңелле, ә аяк-кулыңны, башыңны селкетеп булмау бер дә әйбәт түгел. Бик тәмле исле рәхәт йомшаклык та әллә кая китте. Якында гына да кебек, каядыр еракта да. Кычкырсаң, килер иде дә... Кычкырып булмый. Инде кычкырырга, аяк-кулларыңны селтәргә кирәклеген дә онытып бетергәндә, көтмәгәндә тәмле исле бу йомшак рәхәтлек битеңнән сыйпап ала. Шунда ук дөнья яктырып китә. Биектә-биектә бик матур әйберләр дә ялтырый. Шундый да ялтырый, озаграк карап та булмый. Иге дә, чиге дә юк бугай бу якты, киң дөньяның.

Бу киң яктылыкның иге-чиге булмаса да, синең тагын тап-тар, ләкин ифрат жылы-йомшак, ифрат тәмле дөньяга кайтасың килә. Кайтасың килә икән, кычкырырга кирәк. Кычкырасың, тагы да катырак кычкырасың һәм менә бит ифрат тәмле исле рәхәт йомшаклык килеп тә житте. Суыр, суырганың бөтен тәнеңә тәмле-рәхәт жылылык биреп, йөгереп кенә тора.

Шулай әле тап-тар, әле чиксез киң рәхәтлек кичә-кичә генә алдыңдагы матур әйберләрне тотып ала белә башлыйсың. Тотып аласың да авызыңа кабасың. Юк икән, бөтен әйбер дә алай тәмле түгел икән. Тәмлесен ифрат тәмле исле жылы йомшаклык кына бирә икән.

Хәзер инде син бу ифрат тәмле исле жылы йомшаклыкның «әннәәннә» икәнен беләсең. «Әннә-әннә»нең ифрат тәмле «мәм-мәм» бирә икәнен беләсең. «Мәм-мәм» генә бирми «әннә-әннә», тыңлаган саен тыңлыйсы килә торган бик матур гөр-гөр итә, үзенә караган саен карыйсы гына килеп тора аның. Боларны ничек белеп алганыңны үзең дә сизми каласың. Шулай үзең дә сизмәстән, кулың житмәгән матур әйберләрне тәпиләреңә бассаң тотып буласын белеп аласың. Белеп аласың да, әннә-әннәгә тотынып, бар көчеңә өскәрәк калкынасың. И-и, әннә-әннә янда булганда, берни куркыныч түгел! Менә бит, әннә-әннә янда булгач, тәпиләреңә торып та бастың. Торып бассаң да, алдагы матур әйберләргә житеп булмады. Кулларыңны гына түгел, тәпиләреңне дә алгарак сузсаң, житеп булмасмы? Иң элек берсен, аннары икенче тәпиеңне алгарак сузасың. Аннары, алмаш-тилмәш, тагын, тагын. Алдагы матур әйбер якыная төшә. Әйдә, тәпиләр, кулларга ярдәм итегез. Була бит, була. Әннә-әннә янда гына, бик матур әйберләргә таба!

Ишет, дөнья! Кеше жир йөзе буйлап беренче адымнарын атлап китте. Туп-туп! Туп-туп...

Хәтереңдәме болар? Син: «Бу нинди ахмак сорау?» — дигәндәй, елмаеп куясың. Алайса нигә бая, караңгылык дөньясына чумып барганда, хәтереңдә соңгы очкын булып, «әнием!» сүзе кабынып узды? Шулшул. Сүз белән әйтеп, сөйләп була торган хатирәләр түгел болар. Болар —

сиңа ана сөте белән бөтен барлыгына сеңгәннәр дә, үзең булып калганнар. Сүзләр булып түгел, хисләр дулкыны булып кына уяна алар хәтердә.

Сүзләр белән сөйләп була торган хатирәләр телең ачылгач башлана.

Андый хатирәләргә инде әни генә түгел, әти дә катнаша. Еш кына әнигә караганда да күбрәк катнаша әле әти кеше.

— Әти, карале, әнә нинди зур печени! Син күрәсеңме?

— Кайда ул?

— Әнә бит, биектә-биектә. Янында кечкенә печениләр дә бар.

Әти көлә.

— Печенье түгел, ай ул, нәнием. Янында йолдызлар.

— Синең буең җитәме анда? Минем ашыйсым килә. Күп кирәкми-и... Бераү генә.

— Минем дә буем җитми шул, улым. Әйдә, тизрәк кайтып җитик тә, әниең безгә я печенье, я бүтән берәр тәмле әйбер бирер.

Бик күңелсез булып кала. Күп нәрсәләрне булдыра ала әти, ә менә югарыдагы шул бик тә тәмле булырга тиеш зур печеньены алып бирә алмый. Кайткач, әниең бирер, ди. Ә югарыдагысы аның, ихтимал, әни биргәнгә караганда да тәмлерәктер? Андый зур печенье ашагач, бәлки, бик тиз дәү үсеп тә китеп буладыр әле!

— Белдем! Без, кайткач, баскычка менәрбез. Баскычка менгәч, буең җитәр.

— Белмим шул, улым. Анда кадәр менәр өчен бик тә, бик тә озын баскыч кирәк.

— Мин өй баскычын әйтмим. Лапаста бар бит әле баскыч? Бик озын. Шунда менәрбез.

— Юк шул, улым, печәнлек баскычы да айга кадәр менәргә җитми. Андый озын баскычны әле бөтенләй ясамаганнар.

— Ә син яса.

— Мин дә ясый алмыйм шул хәзергә, улым.

Аннары алар сөйләшми генә атлыйлар. Айга кадәр менә торган баскычның булмавы белән дә, андый баскычны хәтта әтинең ясый алмавы белән дә һич килешәсе килми.

Бервакыт, һич көтмәгәндә, Салих дөньяда андый баскыч барын үз күзләре белән күрде.

Үз капкаларыннан чыгып, икенче капкага керсәң, Зиннурларның өе. Аларга керсәң, һәрвакыт күңелле. Кергән саен Зиннурның әнисе: «У-у, син тагы да дәү үскәнсең бүген, Салих»,— ди. Шуны белү күңелле. Зиннур белән бик озак уйнап, бик озак сөйләшеп була. Күңелле. Уйнап туйгач, Зиннурның әнисе икесенә дә ипи кисеп бирә. Салихның әнисе кебек, май ягып түгел, май якмыйча гына бирә. Болай тагы да тәмлерәк икән, ашап бетергәнеңне сизми дә каласың.

Бервакыт, бик озак уйнагач, бик тәмле ипи ашаганнан соң тагын бик озак уйнагач, Зиннурның әнисе: «Салих, бар кайт инде, әниең көтәдер»,— диде. Бер дә кайтасы килмәсә дә, Зиннур: «Мин озата чыгам»,— дип киенә башлагач, тыңламый булмады. Тышта бик караңгы да түгел, бик якты да түгел иде. Капкага җиткәч, Салих күреп алды: тәмле печеньега охшаган ай бөтенләй түбәндә генә, өй түбәсе өстендә генә эленеп тора иде. Тизрәк кире йөгерде. Өй янына җиткәч, бер сүз дә әйтә алмый торды. Ай да өй түбәсе өстендә генә, түбәгә кадәр менәргә баскычы да бар! «Ясамаганнар әле андый баскычны»,— дигән иде бит әтисе. Инде менә ясаганнар! Менеп кит тә, зур печенине, сындырып-сындырып алып, аша». Әнә шуны әйтәсе килә, нигәдер әйтеп җибәреп булмый иде.

— Зиннур!.. Әйдә менәбез... Печени ашарга...— дип, бераздан гына әйтеп булды.

— Нәрсә, нәрсә?

Салих бер басмага, аннары икенчесенә менеп тә өлгергән иде инде. Өченче басмага менүе кыенрак булды. Тырышасың-тырышасың, тәпи житеп бетми.

— Зиннур! Син арттан эт. Шулай итсәң, була.

Беразга Зиннурның мыш-мыш килгәне, борын тартканы гына ишетелеп торды.

— Этмим,— диде аннары.— Анда менәргә ярамый. Эти әйтә, анда зурлар гына менә, ди. Моржа төзәтергә.

— Без моржа төзәтмибез. Без печени ашыйбыз.

— Нәрсә, нәрсә?

— Печени... Бик зур ул. Миңа да житә, сиңа да. Эт инде!

Үзе бик тырыштымы, әллә арттан Зиннур бик көчле эттеме, тагын бер басманы менеп булды. Аннары тагын бер басманы. Тагын ничәнчедер басманы менәргә бик тырышып маташканда, артта бик куркыныч тавыш ишетелде:

— Кая үрмәлисез инде, шайтаннар! Төшегез хәзер үк!

Ничек төшкәннәре һич хәтердә юк. Шунысы гына хәтердә: Зиннур бик ачу китергеч итеп, телен чыгарып күрсәтте.

— Әйттем мин сиңа! Ярамый дидем.

— Нигә ярамый? Зур печени дәү үстерә ул.

— Нәрсә, нәрсә?

Тагын шул бик истә: кычкырып-кычкырып елыйсы килә, ләкин елап булмый, керфекләр тулы яшь, ләкин сөртәсе килми иде.

*— Доктор, зинһар ирләрчә сөйләшик. Бик куркынычмы аның хәле?*

*— Медицина һәр авыруга оптимистик күзлектән карый, иптәш Дибаев.*

*— Бәлки, бездән ярдәм кирәктер? Ниндидер дарулар табарга? Ниндидер азыклар?*

*— Хәзергә берни дә кирәкми, иптәш Дибаев.*

*— Шулай да, мин калдырыйм әле... Монда барысы да язылган. Эш телефоны, өйнеке. Ах, туктагыз, гараж телефонын язып куйыйм. алай-болай кирәксә, һич тарсынусыз шалтыратыгыз. Любой вакытта. Мин әйтеп куярмын анда.*

*— Рәхмәт, Зиннур Галимович.*

## 3

...Әллә нәрсә булды бу Зиннурга. Тәнәфескә чыгуга, бар белгәне — кызлар белән уйнау. Әле бер кызга төртеп киткән була, әле икенчесенең чәч бавыннан тартып үтә. Икенче карасаң, кызлар белән житәкләнешеп, әйлән-бәйлән уйнап йөри. Уртада калса, әй кыланып, әй боргаланып биегән була. Кызларга нәрсә, чырык та чырык көлешәләр.

Баштарак Салихның моңа аз гына да исе китмәде. Үзенә шулай кызык икән, кылана бирсен. Малайлар белән уйнауга ни житә. «Әйдә, Илгиз, кое чыгарабыз!» Аркага арканы терәп, бер-берегнең кулларын терсәк тиңентен эләктерешәсең дә, иң элек син аны аркаңа күтәрәсең, аннары ул сине. «Әйдә, Илгиз, тиз-тиз!..» Монысын уйнап туйгач, «Кул аударыш». Аннары, «Аксак төлке» булып, титак-титак йөгерүләр китә. Боларны тышта, ишегалдында уйнавы күңелле. Аннары көзге яңгырлар китте, аяк асты лач былчырады. Кыңгырау шалтырауга, бер дә тышка йөгерәсе килми. Коридорда гына «кое чыгарасың». Укытучылар күрмәгәндә — ярый, монда да күңелле. Укытучылар күрсә, ачуланалар, «тузан кубармагыз, әнә Дибаев кебек, тәртипле уеннар уйнагыз»,— диләр. Юк инде, Дибаев кебек, кызлар белән житәкләнешеп, авыз күтәреп, жырлап йөргәнче, әйдә, Илгиз, «Кул аударыш»тан. Кулыңны гел аударып торсалар, әлбәттә, бер дә кызык түгел. Еш кына үзең дә аударасың.

Илгиз кулын — күпме генә көчән, бүртен — барыбер аударып булмый булуын, башка малайларныкын булгалый. Шулчак никадәр күнелле булып киткәнен укытучылар белми дә белми инде, ихтимал. Зиннур бичара да белмидер. Бичарасын бичара инде ул Зиннур, шул бичараны укытучылар нигә мактыйдыр?

Ул мактаулы Зиннур белән мәктәптән дә бергә кайтмыйлар хәзер. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга: Салих белән Илгиз җыен кызыклар сөйләшеп кайтучы малайлар арасында, Зиннур карашын әллә кая, Чагыл тавы ягына төбәгән дә (әйтерсен, анда бик кызык нәрсә күргән) артта берүзе атлый.

Мәктәпкә бергә барып, бергә кайтмасалар да, һаман бер партада утыралар. Бергә утырмаслар иде, сере бар. Салих сулагай, Зиннур, башкалар кебек, уңагай; язганда терсәкләр терсәккә тия дә еш кына каләм дәфтәр битенә һич кирәкмәс сызыклар сызып куя. Әлбәттә, ачуланышып аласың, аннары онытыла. Дүрт ел бергә утырып, моңа иялә-нешеп беттеләр инде. Терсәккә терсәк тиюгә дә, ачуланышуга да. Башкалар белән утырсаң, иялэнешеп булырмы-юкмы? Менә сер нәрсәдә.

Быел, бишенчедә укый башлагач, Салих үз-үзенә сүз бирде: терсәккә терсәк терәп утырганчы, бүтәннәр кебек, уң кул белән язарга өйрәнергә кирәк. Җитәр! Күп түзде.

Тырышсаң, уң кул белән дә язып була икән бит. Дөрес, бик акрын языла. Болай мыштырдап утырганчы, сул кул белән тиз-тиз сырлап китәсе килә. Юк инде, әйткән сүз — аткан ук, барыбер сул кулны парта астыннан чыгармый Салих.

Баскан саен аягыңны лычкылт тартып ала торган былчырак урамнар, хәзер инде эреле-ваклы таш таратып салгандай, туңып, катып калды. Ничәмә көннәр шулай, эреле-ваклы ташларга баскандай, шак-шок атлап йөргәч, җир өстен ап-ак, тип-тигез кар каплады. Аякларга бөтенләй җиңел хәзер, йоп-йомшак кар өстеннән йөгер генә! Колак яфракларын салкын чеметеп-чеметеп ала алуын. Әни кушканча, бүрек колакчыннарын төшереп йөрсәң, бәлки, чеметмәс тә иде. Ләкин алай итәсе килми, бөтен малай: «Әй, авызыңа сүски да кап!» — дип шарык та шорык көләр иде бугай.

Көлми торсыннар әле! Инде менә, терсәккә терсәк бәрелгән саен Зиннур да: «Әй, сулагай!» — дип, кашларын җыермый башлады. Башка малайлар да, җае чыкса-чыкмаса: «Сулагай-кыегагай», — дип, авызын ера алмый хәзер. Уң кул белән һаман да акрын языла әле язылуын, шулай да ручканы сул кулга тотып та караган юк. Кайчак укытучы әйткәннәрне язып өлгереп булмый да, үрелә-үрелә Зиннурдан күчерергә туры килә — шунысы гына җайсыз.

Беркөнне математикадан контроль эш ясадылар. Алай авыр мәсьәлә түгел иде. Тик менә уйлаганны тиз-тиз язмыйча булмый, сул кулга күчерергә туры килде. Шулай сул кул белән тиз-тиз мәсьәләне чишеп бетергәч, Салих, иркен сулап, ашыкмый гына чишелешне акламага күчерә башлады. Зиннурга җайлы, алай мыштырдыйсы юк, контроль эшен, класста беренче булып, укытучыга тапшырып та өлгерде. Салих үз эшен барысыннан да соңлап, кыңгырау шалтырагач кына тапшыра алды.

Иртәгәсен дәфтәрләрне таратканда, укытучы иң беренче Зиннурны мактады. «Молодец, Дибаев, иң дөрес чишелеш тапкансың, бишле», — диде. Салихның дәфтәрен нигәдер бирми дә бирми. Ах, әнә иң аста калган икән.

— Син, Мәрдәнов, Дибаевтан күчергәнсең. Моннан ары алай итмә. Икеле, — диде укытучы.

Салихның өстенә, әйтерсең, кинәт чиләге белән кайнар су ордылар. Башка килгән беренче уй да гадәттән тыш кайнар иде, миләрне яндыра иде: «Кем кемнән күчергәндер бит әле! Син нәрсә беләсең соң?»

Әйе, яңа укытучы әле белми. Ә менә моңарчы аларны дүрт ел буе укыткан Шакир абый белә иде. Класска математикадан мәсьәлә биргән

саен әйтә иде: «Син, Мәрданов, монысын, ихтимал, тиз чишәрсең. Менә боларын да чишеп кара»,— дип, үзенә генә әллә ничә мәсьәлә бирә иде. Салих боларын да чишкәнен, нәкъ китап артындагы җавап килеп чыкканын үзе дә сизми кала, һәр мәсьәләне чишкән саен, күңеле әйтеп аңлатып булмый торган куаныч белән тула иде.

Инде менә ишет: «Син Дибаевтан күчергәнсең...»

Шакир абыйсы Дибаевка математикадан бер вакытта да «биш»ле куйганы булмады. Өчле дә өчле. Ә сөйләү дәресләре буенча бишлеләр күп алды Зиннур. Сөйли башласа, укытучы: «Ярар, аңлашылды»,— дигәнче туктый да алмый, яттан шигырь сөйләсә, бөтен класс тының кала, әйтерсең, Казан артисты килгән!

Бөтен дөньясын болыт баскандай, караңгы иде ул көн, кара болыт хәтта күзләргә, борын тишекләренә кереп тулган кебек иде. Мәктәптән кайтышлый малайлар тагын нindидер кызыклар сөйләштеләр бугай, көлештеләр дә көлештеләр. Салих иптәшләренең ни сөйләгәннәрен дә ишетми, аның аз гына да көләсе килми иде. Көләсе килмәгәч, артка борылып карады да, Зиннурны күреп алды. Гадәтенчә, Чагыл тавына карап атлый, нигәдер елмайган була. Күңелледер шул, бишле алды бит.

Салих, малайлардан артта калып, Зиннурны көтеп алды.

— Ни күрдең анда... һавада?

— Нәрсә, нәрсә?

— Авызыңа карга аэай итмәсен, дим. Җиргә дә кара.

— Нәрсә, нәрсә?

Калганы Зиннур да, Салих үзе дә һич көтмәгәнчә килеп чыкты.

— Менә, нәрсә-нәрсә! — диде Салих, сумкасын ялт читкә атты да, мәче житезлеге белән ташланып, Зиннурны җиргә егып та салды.

— Җиргә кара дим, җиргә. «Нәрсә-нәрсә»!

Шулай дия-дия Салих Зиннурның башын җиргә бәрә, кызарып бүртенеп чыккан баш аз гына күтәрелүгә, тагын бәрә, тагын. Зиннур да аста тик ятмый, куллары, аяклары белән касыкка, күкрәккә, тагын әллә кай җирләргә тондырып өлгерде. Салихның исә бар омтылганы — карга әвәләнгән аклы-каралы бу башка аз гына да калкырга ирек бирмәскә!

Шунда Салих арт якадан ике куллап йолкыганнарын сизеп алды.

— Нишлисең син, хулиган!.. Туктагыз хәзер үк!.. Әтигә әйтсәм әле.

Күтәрелеп караса, Рәйсә икән. Шакир абый кызы. Дүртенчедә укый. Салих сикереп торганын сизми дә калды.

— Әйтмәгәең... Әйт! — дип, мыгырдана-мыгырдана, сумкасына үрелде.— Әләкче!

— Әләкче дигәч, инде барыбер әйтәм.

Салих кызга күтәрелеп карады. Күтәрелеп карауга, йомарланган йодрыклары акрын гына язылды, тел очына үрелеп килгән бик усал сүзләр тамак төбендә укмашып калды. «Күкнең үзе кебек... Юк, зәңгәр чәчәк кебек икән моның күзләре,— дип, уенда чагылды Салихның.— Кыңгырау чәчәк кебек».

— Әләкче димәсәң, әйтмәс идем. Әләкче дигәч...— Кыз тотлыгып калды. Кыңгырау чәчәк кебек күзләр, нәкъ кыңгырау чәчәк кебек, сизелер-сизелмәс тибрәнәләр иде бугай. Үзе бик усал да карый иде бу кыңгырау чәчәктәй күзләр, керфек очларыннан менә-менә яшь тә тамып төшәр кебек иде. Салих, белмим күпмегәдер, аягын да кыймылдата алмыйча басып торды. Бик тирән итеп сулыйсы килә, анысын да булдырып булмый иде.

Шулчак кар йомарламына әверелеп калган Зиннур җирдән сикереп торды, тора-торышка Салихка ыргылган иде, әллә кайдан гына килеп чыккан Илгиз араларына килеп басты.

— Икегезне тиңентен әнә шул көртка башыгыз белән тыгып куярмын... Яшь әтәчләр!

Илгизнең йодрыкларына ышанмыйча булмый иде.

*— Доктор. Мәрдәновның хәле ничек?*

*— Бик җитди, Зиннур Галимович, бик җитди. Тиздән Казаннан самолет килеп җитәргә тиеш. Баш врач Мусина үзе килә.*

*— Кем? Мусина?.. Рәйсә Шакировна түгелме?*

*— Әйе, Рәйсә Шакировна үзе килергә чыкты.*

## 4

Шулайдыр ул... Узган гомер хатирәләре бик кирәген белеп кенә, нәкъ кирәк чакта һәм нәкъ кирәкләре генә күңелдә кабатланадыр. Әни искә төшкән чаклар кебек.

Баштарак Салих моны үзе дә абайламый йөрде. Армиядә беренче генә айлары иде. Әле марш, әле строй адымнары белән атлап, әле йөгереп кенә көннең үткәне сизелми дә кала, баш мендәргә тиюгә йоклап та китәсең, «подъем!» кычкыруга сикереп тор да тагын йөгерә башла. Төш күрдеме ул төнен, юкмы — онытыла да. Шулай ук марш атлап кына төшлекне ашап кайткач, почта килә. Сиңа да хат бар! Әни күренгән иде бит төштә, тикмәгә булмаган икән. Хат еш кына өйдән дә түгел, я Рәйсәдән, я Илгиздән була. Ләкин нәкъ менә әни төшкә кергән көнне килә хат. Әй, әни, әни!..

Илгиз белән алар армиягә алынганнан бирле хат алыша башладылар. Комиссияне бергә үтсәләр дә, икесе ике якка китте. Сагынулар, армия тормышына ияләнүләр — икесенең дә бер чама. Аннары, Илгизнең хатында Рәйсә турында да сүз булмый калмый, шуңа күрә бу язышуны һич сузарга ярамый иде. Иптәшенең хатында Рәйсә турында сүз булмый калмауның сере шунда: Илгизгә хатларны өйдән сеңлесе Илсөяр язып тора, Рәйсә белән бик дуслар алар. Илгиз һәр хатында: өйдән хат алдым, Рәйсә синең турыда, хатыңда нилар язуың турында бик төпченеп сорашкан, ди.

Салихка да өйдән хатларны күбесенчә Зәйтүнә сеңелесе яза. Ләкин Зәйтүнә хатларында Рәйсә турында бер сүз дә булмый. Алар алай Рәйсә белән дус түгел, яшькә яшьрәк шул әле Зәйтүнә.

Зиннурның армиягә алынмавы (ниндидер авыру тапканнар), хәзер Казанда, КХТИда укуы турында да Салих Илгиз хаты аша белде. Тагын бер елдан Рәйсәнең дә медицина институтына керүе турында хәбәр иреште. Илгиз хатларында Рәйсә турында соңгы хәбәр булды бу. Илсөярнең, ахирәтен Казанга озаткач, бу турыда язар сүзләре дә калмады бугай.

Хәбәре ирешми, ә Салих уйларында Рәйсә нәкъ менә шуннан соң аеруча еш кабатлана башлады. Шунысы кызык, студентка булып та түгел, аларны армиягә озату кичәсендәге кебек, ак алъяпкычтан, шоколад төсендәге күлмәктән дә түгел, ә бөтенләй балачактагыча... сизелер-сизелмәс тибрәнүче кыңгырау чәчәктәй булып күз алдына килә Рәйсә. Ниндирәк икән син хәзер? Ниләр уйлыйсың икән? Бу дөньяда Салих исемле солдат та барлыгы исеңә кереп чыга микән?

Казарма тып-тын, караңгы. Лампочка аның янында, дневальный тумбочкасы өстендә генә яна. Салих, йоклап китмәс өчен, акрын гына йөренә. Дүрт адым бире, дүрт адым кире. Адымнар салмак, уйлар житез. Житез булсалар да, әллә нинди буталчык, катлы-катлы уйлар. Шунда кинәт Шакир абый сүзләре искә төшә: «Даһи фикер гаять гади була». Житди итеп тә, кайчак шаяртып та кабатларга ярата иде Шакир абый бу сүзләрне.

Салих, тумбочкага ике куллап таянып, туктап калды. Гади... әлбәттә, бик гади. Менә хәзер үк Рәйсәгә хат язарга! Илсөярнең Илгизгә Рәйсә турында ни язганын, аннары Илгизнең бу турыда кайчан хәбәр иткәнен көтеп йөр имеш... Никадәр ахмаклык!

Рәйсәгә беренче хат әнә шулай юлланды. Җавап әллә ни көттермәде. Ничектер, уйларның дәвамы кебегрәк булып килеп төште хат.

«Мин синең турыда еш уйлыйм, Салих. Шул уйларымны нигә үзеңә дә белдермәскә? Әти әйткәнчә, бик гади бит бу. Моннан соң да бер-беребез турында ниләр уйлавыбыз турында, һичнәрсәне яшермичә, язышып торыйк без. Хәзер генә түгел, мәктәптә укыганда да гел уйлый идем синең турыда. Бөтен малайлар арасында син иң батыры, иң матуры идең минем өчен. Ләкин нигәдер бу уйларымнан үзем үк ояла да идем. Еллар үтәр, синнән дә батырракны, синнән дә матурракны очратыр кебек идем. Каядыр еракта, еракта йөридер кебек иде әле ул минем иң яраткан егетем. Инде менә... ул ерактагы егет әллә син микән, Салих?»

Бик күңелле булды мондый сүзләрне укулары. Укыган саен укыйсы гына килеп тора. Аз гына ислемай исе аңкып торгандай гап-гади бу дәфтәр битен Салих еш кына ут яктысына тотып карый иде: нинди сихри көчләр яшерелгән икән соң хатка? Шуны укыдыңмы, ни шыксыз яңгырлы-җилле көзге көн, мул кояшлы җәйдәгедәй, якты-җылы нурга чума: ару-талуның ни икәнен дә онытасың. Әгәр: «Бар, егет, әнә шул тауны актарып ташла да, җир белән тигезләп куй әле»,— дисәләр, Салих, ике дә уйламастан, кулына көрәк алып, шундый эшкә тотыныр иде.

Бер хатында Рәйсә болай дип язды: «Хәтереңдәме, Салих, сезне армиягә озату кичәсендә, истәлек бүләкләр тапшыргач, уеннар башланды. Без бер буш класска кереп утырдык. Син, мин, Илгиз. Бераз утыргач, Илгиз: «Карап керим әле, нишлиләр икән анда»,— дип, чыгып китте. «Рәйсә, син бит кыңгырау чәчәк. Шуны үзең беләсеңме?» — дидең син. «Чәчәк икәнемне беләм, кызларны гел чәчәккә охшаталар. Ә ни өчен кыңгырау? Анысын белмим»,— дидем. Үзем көләм дә көләм. Гел көләсем генә килеп тора иде минем ул кичтә. Шулай гел көлеп-чыңлап торган өчен әйтүеңдер инде, дип уйлап куйдым эчтән. «Белмисең шул»,— дидең дә мине кочаклап алдың. Башка берәү кочакласа, бар көчемә карышыр идем, сугышыр идем, барыбер моңа юл куймас идем. Ә син кочаклагач, китапларда язганча, «эредем дә киттем». «Әйт инде, нигә кыңгырау мин?» — дим. «Нигәме? Әйдә, колагыңа гына әйтәм»,— дидең. Колагымны сузуга, шул турыдан үптең дә алдың. Үбүең булды, кинәт ишек ачылды. Илгиз кердеме, дисәм, Зиннур икән. Шунда яңагыңа берне чәпәдем. Бик ачуың чыкты. Әйтеп яз әле, Салих, миңамы, әллә вакытсыз килеп кергән Зиннургамы ачуландың шул чакта?»

«Берәүгә дә түгел, үз-үземә бик ачуым чыкты минем ул кичне, Рәйсә,— дип язды Салих.— Нигә шулайдыр инде, минем күп кенә кыланышларым, әйткән сүзләрем һич тә үземчә килеп чыкмый да, аннары бик ачуым килә. Ачуым килә дә,сөйләшәсем дә килми башлый. Теге кичне дә шулай булды. Залга уенга чыкканда, минем инде сөйләшәсем дә, шаярасым да килми иде. Шуңадыр, син гел Зиннур белән танцевать иттең. Ә Зиннурның күңелләре бик шат иде, гадәттәгедән дә остарак такылдый, шаяра, бөтен кыланышлары килешеп тә тора иде тагын үзенә. Шулай Зиннур белән көлә-көлә биегәндә, ничәмә тапкырлар миңа карап-карап куйдың. «Менә, Салих, Зиннурдан үрнәк ал, син дә шулай матур һәм тапкыр сөйләшергә өйрән»,— дия кебек тоелды миңа бу карашың. Рәйсә, син дә әйтеп яз әле, бу карашларыңның мәгънәсен мин дөрес аңлаганмынмы?»

«Дөп-дөрес сизенгәнсең син уйларымны, Салих. Беләсеңме, бу бит бик тә әйбәт! Коточкыч әйбәт! Димәк, без бер-беребезнең уйларын сүзсез дә, күз карашыбыздан ук аңлап алабыз икән, бу инде... Беләсеңме, нәрсә? Бу инде мәхәббәт дип аталмый микән? Ничек уйлыйсың, Салих?»

«Син дә нәкъ мин уйлаганча уйлыйсың икән, Рәйсә,— дип язды Салих.— Бу дөньяда бөтен уйларыңны уртаклашып була торган Рәйсә барлыгын белеп яшәү нинди күңелле, нинди рәхәт! Ләкин хатка бөтен уйларны да язып бетереп булмый. Очрашкач, туйганчы сөйләшербез, сөйләшмәгәннәрне сүзсез дә аңлашырбыз. Шулай бит?»

Рәйсә:

«Төшемдә без үбештек. Озату кичәсендәге кебек, бер кат кына түгел, кабат-кабат, озак-озак итеп үбештек. Нигә андый төш керә икән, Салих?»

Салих:

«Очрашкач үбешәчәкләребез төшеңә керәдер синең, Рәйсә. Бер төнне мин дә сине төшемдә күрә башлаган идем, «подъем» кычкырдылар да, сикереп тормыйча булмады».

Рәйсә:

«Теге хатымда язып бетермәгән идем. Уянгач, төшемне кабат күз алдыма китереп яттым. Бик рәхәт иде аны күз алдына китерүләре. Ләкин, шунысы гаҗәп, нәкъ сине күргән кебек идем үзе, шул ук вакытта, сине дә түгел кебек. Өнемдә бервакытта да күрмәгән бүтән берәү кебек тә. Нигә алай икән, Салих?»

Салих:

«Төшләребез турында түгел, уйларыбыз турында күбрәк язышыйк без, Рәйсә. Шулай күңеллерәк ич».

Рәйсә:

«Кайчак сине үземнең ирем итеп күз алдыма китереп карыйм. Ләкин дөресен әйтим, андый күренешне, ягъни үзебезне ир белән хатын итеп һич күз алдыма китерә алмыйм. Киресенчә, мәктәптә укыганда, малай белән кызчыкның үртәшә-үртәшә уйнап йөргән күренешләре генә күз алдымнан үтә. Синең ничек, Салих, бу турыда хыялланып караганың юкмы?»

Салих:

«Син тагын очрашкач кына сөйләшәчәк сүзләрне язгансың, Рәйсә. Инде моңа күп калмады. Ихтимал, безне октябрьда кайтарып та җибәрерләр. Хәбәрләр шулайрак йөри».

Алай октябрьны ук көтәргә туры килмәде.

Зәйтүнә сеңлесе бер хатында: «Әни авырыбрак тора. Без әти белән аңа, больницага барып күрен, дибез. Ул кулын гына селти, үтәр әле, ди. Менә бүген әйбәт кенә йөри тагын. Әллә сер генә бирми, әллә дөрестән дә хәле әйбәтләндеме, белмибез»,— дип язды.

Хатның бу юлларындагы һәр сүз Салихның йөрәгенә генә барып-барып кадалгандай булды. Нәрсә әле бу? Төшкә бик матур кергән иде ич әни. Имеш, Салих каяндыр кайтып килә. Әллә шулай армиядән кайтуы, әллә биләмнән генә әйләнүе. Өй ишегеннән каршыга әни килеп чыкты. Тулы чиләк күтәргән. Чиләгендә яңа гына бәрәңге пешереп алган тозлы су, ахры, сыек кына пар күтәрелеп тора, бүртеп, аксылланып киткән ипи кыерылары йөзеп йөри. Акмангайны сыйларга чыгышы инде әнинең, ә үзе бөтенләй бәйрәмчә киенгән. Өстендә — эре-эре чәчәкле ефәк күлмәге, аягында — яшел-кызыл чигүле читеге. Бөтен йөзе, бөтен киемнәре белән нурлы елмая, балкый әни. «Кайттыңмы, улым?» — ди.

Күп төшләр уянуга ук онытылучан. Монысы — көне буе күз алдыннан китмәде. Күз алдына килә дә тагын күкрәк турысында чәнчеп-чәнчеп ала. «Тазара гына күр, әнием җаным!»

Иртәгәсен Рәйсәдән дә хат килде. «Авылга кайтып килдем. Кибеткә барышлый, Фатыйма апа очрады. Бергә-бергә, күңелле генә сөйләшеп бардык. Үзем әниеңнең сорауларына җавап бирәм, үзем йөзеңә күтәрелеп карарга да оялам. Оялсам да, бик тә рәхәт булды миңа әниең белән янәшә атлап барулары, Салих».

Хат күңелгә бик мул итеп, кушучлап-кушучлап җылы салгандай булды. «Шулай Рәйсәне оялта-оялта күңелле йөре, әнием, авырып ята күрмә».

Көннәр сизелми дә үтә башлады. Иртән сикереп торулары да, атарга бару-кайтулары да һич авыр түгел хәзер. Тупны әзерләү-төзәү командалары үзеннән-үзе, кашык белән ботка капкандай гына, үтәлә.

Үтәлгән саен бер карыш үсеп киткәндәй буласың. Бер хәрби күнегүне аеруча житез, аеруча төгәл үтәгәне өчен, командир саф алдына бастырып рәхмәт белдерде. Казармага кайткач, часть байрагы янында фотога төшереп алдылар. «Шушы фотоны эти-әниләрегезгә дә жибәрегез»,— диде өлкән лейтенант.

Ул сурәт өйгә барып житкәндерме-юкмы, бер иртәне, каядыр барырга сафка тезелергә команда булгач, өлкән лейтенант Салихны үз янына чакырып алды. «Ә син, Мәрдәнов, юлга әзерлән,— диде,— яхшы хезмәт иткәнең өчен, командование сиңа бер атналык ял бирә».

Үзләренең станцияләренә кадәр юлны ничегрәк үтте икән? Вагон тәгәрмәчләре юл буе «тизрәк, тиз-рәк» дип тыркылдый иде — бары тик шунысы гына истә.

Станциядә вагоннан чыгуга, юлчылар бик ашыга-ашыга рельслар өстеннән салынган биек күпер баскычыннан менеп киттеләр. Ул киткәндә мондый күпер юк иде әле монда, шуңа бик гажәпләнеп, акрын гына атлаганда, күпләр аны узып киттеләр. Төшлек яңа авышуга карамастан, эңгере дә иңә башлаган соры көн иде. Вак кына яңгыр да сибәләп тора икән, монысын Салих вокзал алдындагы автобуслар тукталышына житкәч кенә абайлады. Яңгыр элекке көннәрдә дә яуган, ахры, тездән былчырак иде монда. Кешеләр йөгереп килә-килешкә, автобус ишекләре, билет кассасы төбендәге этеш-төртешле төркемнәргә ыргылдылар. Салих нишләргә, бу төркемнәрнең кайсысына кушылырга да белми торган арада, шыгрым тулы автобуслар берәм-берәм кузгалып та киттеләр. Юлаучыларның калганнары чатта күренгән йөк машиналары артыннан йөгерде.

Касса яны бушап калгач кына Салих килеп белеште. Алар авылы аша үтә торган автобуслар инде китеп беткән, чираттагысы иртәгә иртән генә булачак икән.

Салих юл капчыгын әле бер, әле икенче иңбашына күчереп, шунда бераз көтеп торгач, былчыракның күзенә үк басып, нык-нык атлап китте. Солдат өчен утыз чакырым нәрсә ул! Таныш станциягә килеп төшкәннән бирле ул үзен кайтып житкән диярлек саный, өйдәгеләр аны һич көтмиләр, бу көтелмәгән шатлыкны бераз сузганда да ярый ич... Юк, сузмыйсы иде, арттан берәр машина куып житсен иде дә утыртып китсен иде. Әнә, килә дә түгелме соң? Юк икән, жил тавышы гына булды бугай.

Яңгыр инде сибәләүдән туктаганмы дисәң... Битеңне сөртеп бетергүгә, тамчылар тагын уяккә таба агып төшә башлый. Шинель авырайганнанавырая бара. Аяклар ешрак тая, уйларны үртәгәндәй, гел артка таба тая — колак төбендә һаман да «тиз-рәк, тиз-рәк».— дип, вагон тәгәрмәчләре тыркылдый кебек юкса.

Кешеләрнең вокзал күпере баскычыннан, ашыга-ашыга, аны узып китүләре автобус ишеге төбендәге этеш-төртешләр күз алдыннан үтә дә, күңел әллә нишли — кайный, ачыта, бик ачу чыга. Берәүгә дә түгел, үз-үзенә ачу бу. Шулай мөмкин булса, изә-таптый кыйнап, дөмбәсләп ташлар иде дә үзен, икенче бер «үзе»нә жиңел булып калыр, очып кына кайтып та житәр кебек иде.

Ачу дигәннәре ул чыннан да эчтә шулай дөбер-дөбер кайный, дөрдөр яна ахры — бөтен тән кайнарланып, эссе булып китте. Салих шинель каптырмаларын чишеп жибәрде. Жилфер-жилфер бераз атлагач, шинель итәкләрен өскә кайтарып, каешына кыстырып куйды. Старшина шулай өйрәткән иде, дөрес икән карт солдатның киңәше. Адымнар жиңеләеп китте.

Артта тагын машина тавышы ишетелгәндәй булды. Салих, үҗәтләнеп, артына борылып карамады. «Юктыр, тагын жил ыжгыруы гынадыр». Шулай уйлавы булды, колак төбендә генә бик кискен-таләпчән гудок яңгырады. Салих, сискәнеп китеп, юл читендәге былчыракка чигенеп, тубыктан кереп батты. Шул мизгелдә үк, выжлап, машина үтте, биткә сасы исле жиле генә бәрелеп калды. Күтәрелеп карауга, бугаз

турысыннан аска таба бик кайнар бер төер ярып узгандай булды. Нидер төялгән машина әрҗәсендә, арт кырыйга ябышып, икәү бара! Бу гадәти күренешнең гаҗәбе шунда: Рәйсә белән Зиннур бит болар! Әнә машина, аны узуга, сикереп алды да, Рәйсә Зиннур кочагына ауды. Егет, кызны ике куллап кочаклаган көйгә, туп-туры Салихка карады, үзе, карашын һаман да солдатка текәгән килеш, Рәйсәгә иелеп, нидер әйтте. Ул арада машина юл уйсуына чумып, күздән дә югалды.

Чыннан да булдымы бу? Әллә күз алдына гына килдеме мондый күренеш?

Колаклар шаулый, тагын вагоннар тыкылдаганы ишетелә кебек иде: «Тиз-рәк, тиз-рәк». Юк, бөтенләй бүтәнчә тыкылдый хәзер: «Бул-дык-сыз син. Бул-ма-ган җан!»

Ә күңелнең әллә кай җирләрендә бик ягымлы бер аваз да яңгырый... яңгырамый, аермачык булып хәтерендә кабатлана иде:

— Дөньяга матур итеп карый белергә, гомер буе шуңа өйрәнергә кирәк, балалар. Ничек итеп дисезме? Бу бик гади. Күңеленә күңелсез уйлар килергә тотындымы, син башыңны бер селкеп җибәр дә, иң күңелле нәрсәләрне генә исеңә төшерергә тырыш. Әйтик, әниеңнең бик шатланып елмайганын күз алдыңа китер. Нәрсәгә шулай бик матур елмайган иде әле ул? Әһә, син математикадан «биш»ле алып кайткач, шулай елмайган иде. Ул эштән кайтуга, кушып калдырмаса да, идәннәрне юып куюыңа бик шатланган иде. Тагын ничек шатландырырга икән әнине? Тагын бер башыңны селкеп куй да шул турыда гына уйларга тотын. Дөньяга матур карарга өйрәнүнең бер сере менә шул. Калган серләрне үзегез дә өйрәнеп алырсыз әле, балалар.

Шакир абый сүзләре ич бу...

Салих бик кискен башын чайкап алды. Шул мәлдә, инде үзеннән үтеп, алдагы үргә күтәрелеп килүче машина күренде. Юк икән, күзгә генә күренмәгән икән. Әнә Рәйсә белән Зиннур һаман да кочаклашып баралар...

Салих күзләрен йомды, чайкалып китте дә тагын ачты, тагын йомды.

Әнә, капкадан керүгә, каршыга әни килеп чыга. Тулы чиләк күтәргән. Үзе ничек шатланып көлә. Матур чәчәкле ефәк күлмәге дә, чигүле читеге дә нур чәчә. Чиләгеннән сыек кына пар күтәрелә, чиләгендә бүртеп киткән ипи катысы йөзеп йөри. «Әни, кая, үзем генә сугарыймчы Акмаңгайны. Үлеп тә ярата ул бәрәңге суын, чиләкне ук ялап куя». «Ярый, ярый, улым, бар. Ә мин самавыр куеп җибәрим».

Мең рәхмәтләр сиңа, Шакир абый, акыллы киңәшең өчен! Әнә бит, аяк атлаулары җиңеләеп китте. Безгә, класс малайларына әйтә идең син шулай дип. Белергә иде, ул кызыңа да әйткәнең булдымы икән бу турыда?.. Әй, кирәкми Рәйсә турында уйларга. Зиннур белән кочаклашып бара бирсен.

«Ничекләр кайта белдең, улым? Кая, сал шинелеңне тизрәк, лачма су! Кара, кара, ничек тагы да үсеп киткәнсең. Пәлтәңә сыярсың микән инде, киеп кара әле».

...Авыл урамыннан ул дөм караңгыда үтте. Тәрәзәләрдә дә утлар сирәгәйгән иде. Капкадан керүгә, алай әнисе каршыга килеп чыкмады. Ярты гына сәгать элек, Фатыйматтәйне район больницасына алып киткәннәр иде.

«Салих! Мин сиңа инде дүртенче хатымны язам, синнән бер җавап та юк. Нәрсә булды? Ник язмыйсың? Без бит бер-беребез турында нәрсә уйлауларыбызны һичнәрсәне яшермичә язышып торырга булган идек. Әллә оныттыңмы? Онытсаң, үзеңнең беренче хатыңны исеңә төшер дә минем җавабымны яңадан укып кара. Әллә хатларымны ертып ташладыңмы? Әгәр ертып ташласаң... Мин тагын дөп-дөресен язам: әгәр ертып ташласаң, ихтимал, син, мин уйлаганча, иң әйбәт, иң батыр егет түгелсеңдер».

## 5

«Ах, бу юллар! Очраштыра да, аера да торган юллар! Бәхеткә дә илтә, һәлакәт упкынына да алып китү ихтималы булган юллар!»

Кайчан, кайсы китаптан укыды соң әле Салих мондый сүзләрне? Анысы истә калмаган, шулай да бик еш хәтергә килә алар. Һәрвакыт шулай, шушы сүзләр хәтергә килә дә, үткән юллар күз алдыннан кичә башлый. Ни гаҗәптер, очрашуга түгел, аеруга илтә торган истәлекләр үтә күнелдән.

Әнисе янына көн саен барып йөрде, әлбәттә. Килгән саен хәле әйбәтләнә бара иде авыруның. «Рәйсә килгән иде, озак кына утырып китте. Һай, ул бала докторлыкка укырга бигрәкләр дә белеп барып кергән. Куллары ук, сүзләре ук шифалы җанашымның»,— дия иде әнисе. Бер үк юлдан килә, кайта Рәйсә, ә Салих белән бер генә тапкыр да очрашмадылар. Әнисе Рәйсә турында сөйли башласа, кызның Зиннур белән кочаклашып машинада үтеп китүләре күз алдына килә дә, бу турыда ишетәсе дә килми иде. Күңелдә — ачу дисәң ачу түгел, ачыну да түгел бугай, әллә нинди нечкә генә бер сызлану уяна...

Шушы нечкә сызлау Рәйсәгә хат язарга утырган саен уяна. Уяна да кулдан каләмне төшереп җибәрә иде.

Армия хезмәтен тәмам тутырып, ул бик салкын җилле февраль көнендә кайтып төште. Өйдә шатлыклы очрашу чәе эчкәннән соң, урамга чыгуга, күрше капкада Зиннур да күренде. Исәнләшү-күрешү сүзләре ничегрәк булды соң әле? Алары һич истә калмаган. Хәтергә Зиннурның әллә нинди уртаүле-тәкәббер, олысымакланып елмаюлары бик сеңеп калган.

— Син, сабакташ, һаман да шулай соңлабрак йөрергә яратасың икән,— диде ул, һавалырак тавыш белән.— Кичә генә бөтен сабакташлар диярлек авылда иде. Нинди күңелле очрашу кичәсе үткәрдек. Таралышып беткәч кенә, син кайтып төшкәнсең. Үкенеч. Рәйсә белән Илгизне әле бүген генә озаттык. Мин иртәгә китәм. Каникул бетте. Декан әйткән иде әйтүен, берәр көн соңлабрак килсәң дә ярар, эш белән тоткарладык бит үзеңне дигән иде дә... Лекцияләр калдырып йөрисе килми.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Зиннур кесәсеннән матур каплы сигарет чыгарды, бик хасиятләп кенә ялтыравык кәгазьле кап авызын сыйпаштырып-шомартып куйгач, Салихка сузды. Салих: «Тартмыйм бит мин»,— дигәч, кап авызын шулай ук бик пөхтәләп кенә ябып, кесәсенә кире тыкты.

— Мин үзем дә алай үпкәләрне төтен белән агулап йөрүчеләрдән түгел. Кичә очрашуда сабакташ малайларны сыйлармынмы дип алган идем дә... Молодцы егетләр, алай бик сыйланып тормадылар. Ә син солдат киемнәрен бигрәк тиз салып ташлагансың әле. Илгиз кичә хәтта погоннарын да салмаган иде. Сержант булган. Әллә ничә значогы бар, бер медале дә. Отличник та заслуженный, вообщем.

— Кая китте соң ул? Кайчан кайтты?

— Өченче көн кайтты, бүген гаиләсе династиясен дәвам итәргә чыгып та китте. Усад механизаторлар мәктәбенә керергә исәбе. Кесәсендә тракторчы таныклыгы бар, армиядән кайтучыны сразы икенче курска алулары да ихтимал. Синең перспектив планнар ничегрәк соң?

— Китәм. Ихтимал иртәгә ук.

Зиннур елык-елык йонлач бүреген (ихтимал, шактый кыйммәтледер) ике бармагы белән өскәрәк күтәреп җибәрде дә, сабакташын беренче күргәндәй, башыннан аягынача күзләп алды.

— Кай тарафларга инде сәфәр? Әгәр сер булмаса?

— Хәзергә сер дияргә була.

Зиннур нәкъ баягыча олысымак-тәкәббер елмаеп, Салихның уңынчыда ук киеп йөргән, инде кыскарып калган сукно бишмәте җиңеннән култыклап алды.

— Диясе юк. Аңлашыла сереӊ. Бераз шабашничать итеп, өс-башны рәтләбрәк кайтырга исәбеӊ. Һәм бик дөрес итәсеӊ. Хәзерге заманда кешегә бәяне, иӊ элек, башындагы бүрегенә, өстендәге туныӊа карап бирәләр. Между прочим, быел миӊа бу яктан бик повезло. Җәйге каникулда стройотряд белән целинада эшләдек. Акча әйбәт кенә төште. Менә шушы бүрекне, шушы тунны алып кайттым. Бирედә мондыйларны акчаӊны кулыӊда учлап йөреп тә таба алмыйсыӊ, анда — пажалысты... Кара, нишләп монда басып торабыз соӊ әле без? Әйдә, безгә. Чәй эчеп сөйләшеп утырырбыз, кирәксә, мәен дә табарга була. Кругом повезло миӊа быел. Целинадан кайтышка, повышенный стипендия билгеләп куйганнар. Әти-әни җилкәсеннән төштем диярге була. Әйдәле, очрашу кичәсенә кайтып җитә алмавыӊныӊ үчен кайтарыйк бер.

«Китәргә! Әйе, иртәгә үк»,— дип күӊеленнән кабатлады Салих.

Китәргә... Туган-үскән авылны, әти-әнине калдырып...

Юк, һич тә мондый ният белән кайтып төшмәгән иде ул.

Бераз шүрләтебрәк тә көтеп алынган армия еллары, башта кыенгарак килсә дә, ахырга таба күӊелле генә, хәтта мактаулар белән дә әле, үтте дә китте. Алда, әлбәттә, студентлык еллары. Анысы да — балачактан ук күӊелне кытыклый башлаган нәрсә. Әлбәттә, Казанда үтәр бу еллар. Әнә Рәйсәләр, Зиннурлар белән. Алар алданрак башлады башлавын. Аныӊ каравы, Салих армия чыныгуы үтеп, әтисе әйтмешли, акыл утыртып башлар бу дәверне. Дөрес, керү имтиханнары бирү авыргарак килер, әмма бу киртәне узу үзеннән тора ич. Кыш үтеп, язы бар, җәе бар, көз җитәсе бар. Әти-әнисе янында, аларга йорт эшләрендә булышып, көчтән килгәнчә колхозда эшләп, кичләрен акрын-акрын онытылганнарны яӊарта барырга була. Ышанычлы, нык адымнар белән барып керер Салих гомеренеӊ студентлык көннәренә.

Ниятләр әнә шундый иде. Нәкъ шулай булырга тиеш, бүтәнчә булуы мөмкин дә түгел кебек иде.

Инде менә кинәт кенә нәрсә булды соӊ әле бу күӊелгә?

Кичә генә бөтен сабакташлар диярлек бергә җыелганнар. Рәйсә дә булган. Зиннур әнә шулай тәкәббер генә елмаеп, әйбәт бүреген, әйбәт тунын киеп килеп кергән ул кичәгә. Салих исә... Менә шушы җиӊнәре кыскарып калган постау бишмәтеннән, гап-гади солдат бүреге-нән... Рәйсәнеӊ карашлары бик ачык күз алдына килә. «Әй, Салих, син һаман да шул йолкыш малай икәнсеӊ». Шулай дип Салихка бер генә күз сала да Рәйсә, Зиннур белән елмаеша-елмаеша биеп китәләр... Уф, ярый әле кайтып җитмәгән!

Китәргә. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән әллә кай якларга! Баштан меӊ кыенлыклар, кырык михнәтләр кичсен. Барысын да батырларча үтеп, авылга җиӊүче булып, данлы-шанлы булып кайтып төшәргә!

Уйлап баксаӊ, мондый хыял балачактан ук күӊелен айкап-чайкап ала иде инде аныӊ. Булмады түгел, төн урталарында торып, шундый маҗаралы-хикмәтле юлга чыгып китәр дәрәҗәләргә җиткән чаклар булды. «Олы максатлар, канатлы хыяллар белән яшәгез, балалар. Үз алдына олы максат куеп, шуӊа омтылмаган кеше, үзе дә сизмәстән, вакланып, кечерәеп кала,— ди иде бит Шакир абыйсы да.

— Сүзеӊне кәтәм, кордаш. Безгә булмаса, әйдә, сезгә керәбез. Очрашуны билгеләп үтү тиешле. Йоласы шулай бит.

— Шулайдыр да... Ә без, моннан ике генә ай элек, очрашкан идек бугай инде.

«Мин сине, бер караганда, бик яхшы аӊлыйм да кебек, икенче уйласам, һич аӊламый башлыйм, Салих. Романтика! Күӊелеӊне яшьләр арасында хәзер бик модада булган әнә шул нәрсә биләп алган синеӊ. Мин һаман да дөп-дөресен язам: андый нәрсә еш кына мине дә җинә язып куя. Аннары, иртәгә тапшырырга тиеш экзамен искә төшә дә тизрәк конспектларымны, дәреслекләрне кулыма алам. Мин врач булырга

карар кылганмын икән, чын врач булырга тиеш. Диплом өчен генә укымыйм ич. Күңелем тарткан, кулымнан да килердәй профессия сайлый алуым белән үземне бик бәхетле саныйм. Моны газета сүзләрен, укытучылар сүзен генә кабатлап әйтүем түгел. Дөресе шулай. Син анда, ерак төньякта, электросварщик булып эшләвеңне әйткәнсең. Дөп-дөресен генә яз әле: яратасыңмы һөнәреңне? Гомерлек профессияңме бу?»

Салих:

«Син, Рәйсә:— Мин газета сүзләрен, укытучылар әйткәнне генә кабатламыйм,— дигәнсең. Уйлап баксаң, мин бит газетада язганча, укытучылар әйткәнчә яшим. Авырлыкларга карамый, ерак төньякка китеп бардым, монда бик кирәкле электросварщик һөнәрен үзләштердем. Илгә бик кирәкле, сирәк металл табышам. Күрәсең, барысы да, син әйтмешли, газетча. Ләкин, Рәйсә, мин үземне һич тә чын бәхетле санамыйм. Күңелем урынында түгел. Кайтып кына китәр идем... Ярамый. Бу бит, дөп-дөресен әйтсәк, куркаклык булачак. Әйе, куркак һәм дезертир булачакмын мин аннары. Минем ике елга хезмәт килешүем бар, аннан да бигрәк, иптәшләрдән оят. Күңелем читлектәге кош кебек минем: ярсып-ярсып талпына, ә тимер рәшәткәләр җибәрми.

Яратасыңмы һөнәреңне, гомерлек профессияңме бу дигәнсең. Утлы һөнәремне яратмаска мөмкин түгел. Гомерлек профессиям булып китәрме ул?— анысын хәзергә әле үзем дә белмим. Их, Рәйсә! Кайчак үзем дә сизмәстән, сузып-сузып җырлап җибәрәм:

Агыла болыт җилләр искәндә,
Өзелә үзәк искә төшкәндә...

Мәрдән бабам җыры бу. Яшьлегендә бабам да ерак-еракларда бик озак читтә йөргән. Кайчак: «миндә дә бабам каны уйныйдыр инде»,— дип уйлап куям. Мондый моңлы озын көйне минем башка берәүдән дә, радиодан да ишеткәнем юк. Синең ишеткәнең бармы, Рәйсә? Әгәр шушы көйне ишетсәң, күңелемне аңлар идең кебек».

*— Алло! Доктор! Самолет килеп җитте шикелле. Мин биредә тәрәзәдән күреп утырдым. Чыннан да Рәйсә Шакировна килгәнме?*

*— Үзе. Рәйсә Шакировна үзе килде, Зиннур Галимович.*

## 6

Агыла болыт җилләр искәндә... Кара инде, тагын шул җыр, шушы моңлы озын көй колак төбендә генә яңгырый кебек. Нәкъ бабай үзе җырлаган шикелле яңгырый. Ә хәтердә әллә кайчангы хат юллары төптөгәл булып кабатлана.

«Уянгач, төшемне кабат күз алдыма китереп яттым. Бик рәхәт иде аны күз алдына китерүләре. Ләкин шунысы гаҗәп, нәкъ сине күргән кебек иде үзе, шул ук вакытта, син дә түгел кебек...»

«Кайчак сине үземнең ирем итеп күз алдына китереп карыйм. Ләкин, дөресен әйтим, андый күренешне, ягъни үзебезне ирле-хатынлы итеп, һичничек күз алдыма китерә алмыйм...»

Күптән ертып ташланган хатлар инде болар, ә сүзләре, ул сүзләрнең ничек язылышына кадәр хәтергә уелган. Әнә «ирле-хатынлы» дигән сүздә, башта хәрефләр бик ачык чыкмаганмы, кабат каләм йөртеп чыгылган... Шуларына кадәр күз алдына килә.

Агыла болыт җилләр искәндә,
Өзелә үзәк искә төшкәндә...

Шушы җырын да кушып язган хатка Рәйсәдән җавап килмәде. Аннан соңгы хатлар да җавапсыз калдылар.

Аһ, үз башыңа төшкәч кенә беләсең икән ул әнә шулай. Чехов әйткәнчә, «хатыңа җавап бирмәсәләр, бу — күрешергә сузган кулыңны алмау белән бер» икәнен.

Ә күрешүләр тиз генә насыйп булмады.

Кайтып төшүләре болай ук булыр дип күз алдына да китерә алмый иде Салих.

— Күпме алсаң да ал, кайтарып куй!— дип, ул станциядә беренче очраган «Москвич»ны туктатты да, шоферның җавабын да көтмичә, хуҗаларча ишекне ачып кереп утырды. Бер сәгать тә үтмәгәндер, машина аларның капка төбенә килеп тә туктады.

— Әти, әллә кибеткә барып кайтасыңмы?— дип, күрешү ыгы-зыгысы тынып та өлгермәстән, өстәлгә бәйләм-бәйләм акча ыргытты.

Болары — кызык та булып, кызарта-оялта торган да булып истә калган.

Шуннан соңгылары кызык та түгел, кызартмый да. Теге җырдагыча:

Өзелә үзәк искә төшкәндә...

Әтисе кибеткә чыгып йөгермәде. Җайлап кына, иплән кенә өстәлдәге пачкаларны өч өемгә бүлде.

— Менә монысы — үзеңә институт бетергәнче укырга, монысына әниеңне санаторий-фәләнгә җибәрербез, монысына — өйне ремонтлыйсы, иркен-якты веранда корып җибәрәсе булыр.

Шуннан соң гына беренче өемнән бер ун сумлык суырып алды да кибеткә китте.

— Синең сабакташлардан кем генә өйдә икән соң хәзер,— дип сөйләп китте әнисе.— Илгиз басудадыр инде ул, урак өсте бит. Бик тырыш егет булып чыкты ул, узган ел да районда беренче урынны — Урак Батыры исемен алды. Төсле телевизор белән бүләкләделәр үзен. Бик зурдан тотынып, өй салып йөри. Зиннур, һәр елдагыча, целинада бугай. Равил — шофер, гел юлда. Рәйсә, укуын тәгәлләргә, Ленинградка китеп барган. Нигә алай уйлагандыр, балакаем...

Тагын ниләрдер сөйләде әнисе, ләкин Салих берни ишетми иде инде. «Менә нигә хат язмый башлаган Рәйсә. Ленинградка киткән... Масаюымы әллә? Юк, Рәйсә андый түгел. Монда бүтән сәбәп. Күңел сизә, бөтенләй, бөтенләй башка сәбәп... Илсөяр! Менә кем белсә белергә тиеш. Балачактан ук аерылгысыз дуслар иде бит алар».

Күрше Зирекле егетенә кияүгә чыккан Илсөяр, Салих килеп кергәндә, ялгызы гына бала имезеп утыра иде. Ничек табып барып керде Салих бу өйгә?— анысы аз гына да хәтердә юк.

— Әйт, әле, Илсөяр, нигә китте ул Ленинградка?

— Кем ул? Нинди Ленинград?

— Кыланган булма, кем турында сүз барганын бик яхшы беләсең.

Илсөяр йоклап киткән нәниен, иркә сүзләр пышылдый-пышылдый, иплән кенә арбасына илтеп салды.

— Тсс... әйдә,— диде дә ишеккә юнәлде.

Ишектән чыгуга, аны оя-оя чебиләр, үрдәк, каз бәбкәләре чорнап алды. Илсөяр: «И җанашларым, ачыгып та өлгердегезмени әле»,— дип сөйләнә-сөйләнә, аларга җим сибеп йөрде, аннары койма баганасындагы юынгычта озаклап кул юды. Шуннан соң гына Салих янына баскыч төбенә килеп утырды.

— Син, нәрсә, үзең зимагурлыкта йөргәндә, биредә тормыш туктап торган дип беләсеңме әллә? Әнә Илгиз абыйлар өченче балаларын көтәләр хәзер. Равилләрнең икәү. Үзең өйләнмәдеңме соң әле?

— Син, Илсөяр, сораганга җавап бир!

— Хәер, зимагурның хатыны була димени! Кочкан да җилгә очкан... Шуныңише генә.

— Илсөяр!..

— Рәйсә кияүгә чыкты, бик бәләсен килсә.

— Ә?.. Кемгә?

— Кемгә булсын, Зиннурга. Ленинградта хирургиягә особый сәләтләрне җыеп, махсус укыталар икән. Шуңа китте. Туйлары көзгә булачак... Шулай ул тормыш. Син генә зимагурлыкта йөргәч тә... Кичкә эштән кайтуына Илгиз абыйны күр. Аңлатып бирер ул сиңа.

Илгиз абый аңлатып бирер... Илсөярнең нигә болай әйтүе булды икән?

Илгиз, башка чыгып, инеш аръягында үз нигезен корып җибәргән икән. Салих яхшы хәтерли: алар балачакта монда, өем-өем яткан тиреслек өстендә, карурман күк шайтан таягы, тигәнәк, алабута, кыргый киндер котырып үсә, аннан да бигрәк, шул карурман төбе тулы күгәргән тимер-томыры, шешә ватыклары, котыңны алырдай хайван сөякләре белән янына бармастай урын иде бу. Ләкин килгәләми дә булмый, монда казып алынган симез селәүчәннәргә, ялтыр мөгезле буынтык-буынтык ак кортларга балык аеруча шәп каба иде.

Инеш аръягындагы бу ялгыз йортка Салих караңгы төшкәч кенә барды, хуҗасы шунсыз кайтмый диделәр. Өстә күзләреңне чагылдырырдай лампочка янып торган капкага җиткәч, тукталып калды. Әллә ничек, әкияттәге кебегрәк бит әле бу... Балачакның әрем исле, сукыр кычыткан исле, шушыннан казып алынган ак кортларга каптырган зур бәртәсләр исле дөньясыннан ул менә хәзер челтәр-челтәр сихри биек капка аша икенче бер дөньяга барып керә. Ниләр көтә икән аны бу шулай ук әкият сыман сарайда?

Капкадан керүгә, борынга йомычка исе, печән исе, бик мул терлек-туар исе килеп бәрелде. Монысы инде бигүк әкияттәге кебек түгел иде. Капка-койманы бик ныгытса да, эчтә әле эш җитәрлек икән. Дүрт почмаклы өйнең түбәсе ябылса да, шуңа терәлеп тагын өч стена күтәрелеп килә, каралты-кура, вакытлыча диптер, сырт такталардан гына әмәлләнгән, киң ишегалдын бүрәнә, такта өемнәре, тоташ йомычка тутырган иде. Хуҗа, майкадан гына килеш, салмак, әмма бик саллы селтәнеп, бүрәнә юна, капка тавышын да ишетмәде. Балтасын бер чапкан саен, бүрәнәгә ике яклап баскан аякларын шудырып кына артка чигенә, бүрәнә буе сузылган йомычкасы, өзелми-нитми бик күндәм дугайланып ятып кала бара иде. Салих дәшми генә бүрәнәнең бу башына килеп басты. Илгиз, аеруча нык селтәнеп, озын йомычканы чабып төшерүгә, билен язды. Салих шунда ук аны арттан кочып алды. Юк, кочмады — бу баһадир гәүдә кочакка сыешлы түгел иде,— дустының дымлы иңбашларыннан, үрелә төшеп, тотып алды. Илгиз акрын гына борылып карады да иелми-нитми кулындагы балтасын читкә атты, балта шундагы бүкәнгә бик иплә килеп кадалды.

— Эх син, котып аюы!— диде, бөтен битен дугай-дугай нурлы елмаю каплады. Шунда ук Салих дустының үзе кайнар һәм нигәдер сөт исе дә килгән кочагында калды.— Кайтып җиттең, значит, туган туфракка?

— Ташларга уйлаган да юк туган туфракны,— диде Салих һәм бүрәнә өстенә утырырга чүгәли башлаган иде... кинәт һавага очып китте. Илгиз аны култык асларыннан гына бик җиңел күтәреп, якындагы тәбәнәк эскәмия янына китереп бастырды.— Чәергә ябышып каласың бит хәзер, шүрәле. Кайтып җиттем дигәч кенә... Әйдә, шул хөрмәткә берәрне күтәрәбез!— диде һәм шунда ук иелеп, йомычка арасыннан зур гына кастрюль казып чыгарды.— Тот, әйдә!

Кастрюльдә әйрән иде, май суын, каймагын кушып ясалган, ускиткеч тәмле әйрән иде.

— Ә без менә монда гына төпләнәбез... Чүплек башында, значит,— диде Илгиз һәм әллә кайларга ишетелердәй итеп, шаркылдап көлеп җибәрде. Кесәсеннән зур яулыгын чыгарып, битен, муенын озаклап сөртте. Яулыгын кесәсенә кире тыкканда, чырае да бик җитди иде инде, гүя шулай елмаю-көлүләрен дә сөртеп алды.

— Чүплек башы дигәннән, тәмам бәла булды ул... бу җирләрнең шундый яманаты. Кем-кем, иң беренче, әти кырт кисеп каршы төште. «Өеңне чүплек башына илтеп салмасаң, беткәндер синә авыл эчендә пуста яткан йорт урыннары»,— ди. Андый урыннар урам саен анысы. Ләкин, мин әйтәм, алай ата-баба нигезенә кул селтәгән адәмнәр нигезенә якын да бармыйм дим. Шулай дигәч, әти дә ризалашты, әмма кешеләр күңелендә бу урыннарның яманаты һаман яши бит! Шунысыннан ничек котылырга? Менә иң кыены кайда! Башта, кайбер санитария чаралары үткәрдем. Теге, химикатлар кулланып түгел, иң беренче, табигатьнең үзен ярдәмгә чакырдым. Башта, резин перчаткалар киеп алып, мондагы тимер-томыр, сөяк-санак, иң күбе — төрле этилен да плассмас әйберләре калдыкларын җыеп яндырдым. Көле-күмере генә дә өч машина булды. Шуннан соң, көлне, күмерне таратып, тирән итеп сөрдем дә клевер чәчтем. Утарны әйләндереп алып, рәшәткә буйларына сәрби, канәфер куаклары утырттым. Болар инде иң ышанычлы санитар чара. Әй, уңып та карады соң клевер! Эскерт-эскерт печән җыеп алдым, куакларым да бик әйбәт китте. Шуларга куанып кына йөргәндә, һич көтелмәгән яктан удар. Берзаман хатын тәртәгә тибеп маташа, значит. «Ул чүплек башы печәнен малларга ашатасы булма». значит. Бер башмак тана, кыш чыккан үгез бозау, дүрт сарыктан үземә аерым төркем булдырдым. Эпидстанция кешеләрен чакыртып, ул чүплек башы җирен ныклап тикшерттем. Кыш чыккач, тагын тикшертми булмады. Үземнең бернинди шик-шөбһәм юк-югын, монысы — юри хатынның күңелен тынычландыру өчен. Тикшерү тәгәлләнгәч, шушы җир печәнен ашатып симерткән бер сарыкны суеп, анысын да хатынның үзеннән сайлатып, бәлеш пешердек. Пешердек дим, итен үзем турадым, үзем эчлеккә салдым. Хатын бәлешкә якын да бармый, эпидстанция кешеләре ашап туя алмый, мин сыңайтим. Бу җирләрнең яманатын әнә шулай юмыйча булмады, значит. Шуннан соң гына Ризидә апагызның да фикере үзгәрде. «Үз эргәндә оя корырга рөхсәт итче»,— дип, яшьләрдән үтенечләр дә ява башлады. Менә шулай, малай, без дә монда яңа җирләр, яткын хәзинәләр үзләштереп ятабыз.

Илгиз тагын шаулатып көлеп җибәрде. Шунда ук кинәт җитдиләнеп, Салихның бер як иңбашын зур учына алды.

— Әйдә, малай, үз ояңны шушында корып җибәр. Бергә-бергә, значит. Һөнәрең дә бик әйбәт икән. Колхозга да бик кирәк электросварщиклар. Әйдә!

Салихның күз алдыннан әтисе өч өемгә бүлгән пачкалар чагылып узды.

— Белмим шул, малай... Мин бит әле, теге... Арты белән күлгә чумган үрдәк хәлендәрәк. Башта укырга иде ният.

— Кая керергә инде исәп?

— Кереп булса, университетка иде. Геологическийга.

Ишегалдын тагын шаркылдап көлү яңгыратты.

— Тәмам җелегеңә сеңгән икән чит-ят җирләр җиле. Геолог булып, яңа байлыклар ачарга, значит. Ярый, бик әйбәт. Укырга кирәк, малай. Үзем дә быел сельхозга, заочныйга барып кердем. Әйдә, шул хөрмәткә тагын берне тотыйк әле.

Шулай әйрән эчә-эчә, алар бик озак сөйләшеп утырдылар. Хуҗаның иртә-таңнан эшкә китәрен искәртеп, Салих әллә ничә урыныннан кузгалды, әмма бетмәс көч-куәт бөркелеп торган сабакташы яныннан һич кенә дә китәсе килми иде.

*— Алло! Зиннур! Илгиз әле бу. Нәрсә булды анда безнең Салихка?*

*— Хәле әйбәттән түгел егетнең. Язмышы, беләсеңме, хәзер кем кулында? Казаннан Рәйсә Шакировна очып килеп җитте. Операция ясаячак. Син каян, үзеңнәнме шалтыратасың?*

*— Ярты сәгатьтән мин дә килеп җитәрмен. Менә бит, әй! Ярый, кузгалыйм әле.*

## 7

Әй син, Хәтер, гомер юлларыннан
Яшьлекләрне безнең чакырып ал!

Кара инде, тагын күңелгә җыр килә. Әйтерсең, гомер-гомергә җырчы малай булган. Җырлаучыларга кушылып, борын төбеннән генә мыгрәп утырудан башка, аеруча күңел нечкәреп киткән чакларда өзек-өзек куплетлар сузып җибәрүдән башка, җырлап-моңаеп утырганы да булмады аның. Гомумән, берәр җырны башыннан ахырынача белми дә бугай ул. Монысы нинди җыр булды соң әле?

Безнең гомерләрдә,
Безнең бу көйләрдә,
кайтмый калганнарның хакы бар!

Ах, әйе, «Ветераннар җыры» бу. Безнең татар көйләренә бер дә хас булмаганча, гитара чиертә-чиертә җырлыйлар бу җырны. Шулай гитара чыңлатып та, нинди матур-тәэсирле яңгырый икән ич безнең көйләр. Ерак төньякта эшләгәндә, шулай гитара яңгыратып моңаеп утыра иде егетләр. Руслар, молдаваннар. Шуны искә төшерүе белән дә күңелгә якындыр инде. Юк, барыннан да бигрәк, әтиләрнең өлеге белән дер. Безнең әтиләр җыры бит бу. Соңгы елларда гына яңгырый башлады. Димәк, әти ишетми дә калган бу җырны. Ишетмәсә дә, күңелендә йөрткән. Үзенең сугыш юлларын искә төшереп утыра башласа, бик тирән көрсенеп куяр иде дә: «Их, менә шулай, кайтмый калганнар өчен дә яшәп ятабыз инде без»,— дияр иде.

Бигрәк кинәт, бигрәк көтмәгәндә дөнья куйды карт солдат. Әнине санаторийга озаткач, өйне ремонтларга бүрәнәләр, такталар кайтартып йөрде. Салихны бу мәшәкатьләргә аз гына да катнаштырмады. «Син, улым, бар, имтиханыңа әйбәтләнебрәк хәзерлән. Махы бирерлек булмасын!»— дип, үзенең дугай тырма тешедәй баш бармагын өскә чөеп күрсәтер иде.

Әни санаторий срогын тутырмый кайтып төште. «Миңа шушысы да бик житкән. Рәхмәтләр яусын сезгә. Инде менә әтиең дә Кырым коя-шында карт сөякләрен җылытып кайтсын иде. Шуны юллыйсы иде, улым»,— диде.

Юллап өлгерә алмый калдылар.

— Кырымда булмаса, кырык өченче елны Кавказ кояшында бик әйбәт кызынып кайткан солдат бу,— дип, мөлаем гына елмаеп утырган әтисе, тагын өч көн үтүгә, урын өстенә ятты.

Күпмедер вакытлар үткәч, карт солдатның орден кенәгәләрен, медаль таныклыкларын, рәхмәт язуларын актарып утырганда, арада бер гаҗәп кәгазь дә килеп чыкты. Әтисенең Салих хезмәт иткән часть политругына язган хаты, дөресрәге, шул хатның караламасы иде бу. Русча бик авырлык белән оештырган, бик күп төзәткән-бозган, шуңа яңадан күчереп җибәргәндер инде. Хатта әтисе кыскача гына үзенең сугышчан юлын язып үткән дә, әнисе җеназасына кайтып житә алмавы гомерлек үкенеч булып калуын әйткән; инде менә Салихның әнисе сәламәтлеге турында бик борчылуын язган һәм, әгәр мөмкин булса, улын ике-өч кенә көнгә өйгә кайтарырга мөмкин булмасмы, дип үтенгән иде.

И әти, әти! Әнә ни өчен теге вакытта Салихка, демобилизациягә ике генә ай калып баруга карамастан, отпуск биргәннәр икән. Моңа ротада барысы да ничек гаҗәпләнеп калганнар иде аны.

Уйлап баксаң, әнисенең дә дөнья куюы бик гыйбрәтле.

Салих университет бетергән елны бу өйдә бер-бер артлы ике туй үтте. Үзенең туе әллә ни истәлекле булмады. Финанс-экономика институты студенткасы Җәмилә белән алар инде өч ел буе дуслар, буш вакытларын гел бергә үткәрәләр, чәчләрне-чәчкә бәйләү турында зурдан кубып сөйләшмәсәләр дә, бу үзеннән-үзе шулай булырга тиеш кебек иде. Яшьтәш-

ләре арасында Салих инде берүзе буйдак. Җәмиләнең дә чәчәк чаклары үтеп бара, моны икесе дә сүзсез дә бик яхшы аңлый, икесе дә алай «төшеп калганнардан» түгел. Җәмилә институтка кадәр берничә ел колхозда хисапчы булып эшләгән. Салих та — «дөнья күргән» егет, әйтерсең, язмыш аларны үзе очраштырган да инде бу дуслыкны рәсмиләштерәсе генә калган — туй әнә шул йола-вазифаны үтәү кебегрәк кенә узды.

Ике айдан соң Салихның сеңлесе Зәйтүнә кияүгә чыкты.

Бу туйда хәтергә уелырдай истәлекләр булды.

Зәйтүнә унны бетерүгә, фермада эшли башлады. Кияү — колхозда шофер. Илгизнең яңарак кына председатель булып сайланган чаклары, яшь кадрларны авылда төпләндереп калдыруга җиң сызганып кереште. Илгизнең ялгыз йорты буйлап, күптән инде Яшьләр урамы үсеп чыкты, бакчаларга төренгән шул матур урамда колхоз хисабына да йортлар салына башлады. Илгиз туйда яшьләргә беренче өлгергән шул йортның ачкычын тапшырды.

— Бу ачкыч яңа өйнең ишекләрен ачсын, ә күңел кошларыгызны мәңгегә бу читлеккә бикләп куйсын, значит,— диде яшь председатель, үзенең сабый елмаюлары белән балкып. Бу сүзләрне әйткәндә, шул мөлдерәмә елмаюлы күзләре Салихка таба төбәлгән иде. Шул бик истә калган.

Кияү Зиннурга туган тиешле иде. Туйга ул да кайтты. Мәҗлеснең бик оста тамадасы булды ул. Институт бетергәч, Зиннур республиканың нефть якларына эшкә китте, өч ел эчендә нефть Идарәсендә җитәкче эшкә күтәрелеп өлгерде. Салих та хәзер — шул якларда геолог. Университетка кергәндәге яшьлек хыялларына — яңа җирләрдә яңа байлыклар ачу романтикасына тормыш үз төзәтмәсен кертте — Җәмилә тиздән ана булачак иде...

Туй кызганнан-кызды. Ишегалдына чыгып, дөп-дөп биюләр китте. Тамадалык вазифасыннан бушаган арада Зиннур Салих белән Җәмилә янына килде.

— Бу котып аюын ничек авызлыклый алдың син, Җәмилә?— диде ул бөтенләй исермәгәндәй кыланып.— Шулай да, чылбырны ныграк тота күр. Мин ул егетне бераз беләм, тагын төньяккамы, көньяккамы оча күрмәсен.

— Очса, бергә очарбыз. Мин очудан курыкмыйм,— диде Җәмилә, үзенә генә хас сабыр-тыйнак елмаеп.

— Ну, малай, сиңа үпкә зур,— диде Зиннур, кинәт житди турсаеп.— Бу якларда кунакларга ниятең булгач, нигә үземә ым какмаска иде? Безнең Идарәгә дә бик кирәк геологлар.

— Геологиянең эш мәйданы бик киң...— дип кенә әйтә башлаган иде Салих, капка төбенә, пыфылдап, машина килеп туктаганы ишетелде.

Шушы мизгелләр гомерлеккә хәтергә уелып калган.

Машинадан мәһабәт гәүдәле бер ир житез генә сикереп чыкты да кочагы тулы чәчәкләр күтәргән ханымга төшәргә ярдәм итте. Ханым килеп чыгуга, барысы да тынып калдылар, әйтерсең, каршыларында нур балкышы пәйда булды: күзләре, энҗедәй тигез тешләре, җирәнсу чәчләре, күкрәгенә кочкан чәчәкләр бәйләме — барысы да нурлы елмая иде ханымның. Мәһабәт гәүдәле ир дә елмая, анысының елмаюы: «Күрдегезме, менә мин кемне алып килдем!»— дигәндәй эчке бер горурлык белән балкый иде.

Тантаналы тынлык шунда ук шат авазлар ташкынына күмелде:

— Рәисә Шакировна!

— Исәнмесез, Рәисә апа!

— Хуш килдегез, Рәисә Шакировна!

— Төкле аягың белән, Рәисә сеңлем!

Тагын шул бик истә. Машинадан Рәисә килеп чыгуга, Зиннур кырт борылды да өй ишегеннән күренгән хатынына таба кызу-кызу

атлады. Бик затлы-килешле киенгән, зифа буйлы, зур коңгырт күзләре: «сүзеңне үлчәбрәк сөйләш минем белән»— дигәндәй үткен-горур карашлы ханым иде Зиннурның җәмәгате. Ир, хатынын машинадан килеп чыккан нур балкышыннан ышыклагандай, аны олы гәүдәсе белән каплап алды, нәзакәтле генә култыклап, өйгә таба борды.

Илсөярнең: «Рәйсә Зиннурга кияүгә чыга»,— дигәне расланмады. Рәйсә, институт бетергәч, ике ел район больницасында эшләде. Аннары, ординатура тәмамлап, республика поликлиникасында эшли башлады, медицина фәннәре кандидаты булды. Әле студент чагында ук авылда аны «үзебезнең доктор» дип, «Рәйсә биргән дарулар бик килешә» дип, чын хөрмәт итәләр. Салихның әнисе исә: «Рәйсәнең шифалы куллары гына чирдән арындырды мине»,— дип, җае чыккан саен әйтә иде. Быел гына: «Рәйсә кияүгә чыккан, ире зур галим икән»,— дигән хәбәр дә иреште.

Хәбәрләрен ишетеп торса да, Салихның ерак төньяктан кайтканнан бирле Рәйсәне очратканы булмады. Салих өчен Рәйсә — егет чакның кайтарып алып булмый торган иң якты хатирәсе... ирешергә мөмкин дә кебек булган үкенечле бәхете... мәңге төзәлмәс йөрәк ярасы иде. Хәер, дөнья булгач, бер дә очрашмадылар дию дөрескә килеп бетмәс. Булгалады очрашканнары. Ләкин бу очрашулар... бары тик тылсымлы сирәк төшләрдә генә була торган, бәхетнең иң яктысы, иң олысы, әмма бик тә кыска мизгелләр генә иде. Казанда, авыл урамнарында очрашкаладылар. Рәйсә, битләре алсулана төшеп, елмая-елмая, хәл-әхвәл сораша да ни арада күздән дә югала иде. Салих Рәйсәнең сорауларына ни дип җавап биргәннәрен аз гына да хәтерләми. Мондый очрашу мизгелләреннән соң күңелдә кайчандыр ишеткән җыр сүзләре генә кабатлануы хәтердә:

Сине күрсәм,
Сине очратсам,
Җир әйләнә кирегә.
Җир әйләнсә дә кирегә,
Килче, иркәм, бирегә.

Җыр, бигрәк тә аның күңелдә генә яңгыраганы, язмышка аваздаш булмаска да мөмкин икән. Рәйсәнең алай кабат килгәне, хәтта әйләнеп бер күз салганы да булмады.

Инде менә күңелне гел сызлаткан исем генә түгел, җисем тагын аның каршында. Рәйсә, һаман да шулай бөтен барлыгы белән нурлы елмаеп, үзен сәламләүчеләргә баш ия-ия, алга атлады, менә ул Салих белән Җәмиләгә дә нәкъ бер чамада баш иеп, үтеп китте. Салих та баш идеме?— хәтердә калмаган. Ул чын-чынлап тораташтай катып калган иде. Җәмиләсе җылы-йомшак итеп яңагыннан сыйпап куйгач кына аңына килде.

Туй иртәгесен Фатыйматтәй урыныннан тора алмады. Аның: «Рәйсәне чакырыгыз»,— дигәнен көчкә генә аңлый алдылар. Рәйсә йөгереп килеп җиткәндә, ананың йөрәге тибүдән туктаган иде инде.

*— Изге юлыгыз уң булсын, Рәйсә Шакировна!*

*Рәйсәнең алдына гына караган килеш, операционныйга үтеп барышы иде, тукталып калды, бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкты.*

*— Уһу, монда бөтен сабакташлар диярлек җыелган,— диде һәм башта Җәмилә, аннары Илгиз, Равил, Зиннур белән кул биреп күреште. Ишек катында боек кына тезелешеп басып торган өч үсмер янына җиткәч, тукталып калды.*

*— Яшь Мәрдәновлар дип беләм. Рәйсә апагыз булам,— диде дә үсмерләр белән дә берәм-берәм кул биреп күреште.*

*— Әйе, улларыбыз,— диде Җәмилә.*

Зиннур: «Безнең Идарәгә дә бик кирәк геологлар, нигә үземә ым какмаска иде»,— дип, тикмәгә генә түрсаеп маташмаган икән. Ике ай да үтмәде, Салих Зиннурлар Идарәсенә эшкә күчерелде.

Салих башта билгеләнгән районда нефть ятмалары мәйданы инде «картайган», нефть чыгу үсүгә бармый, шунлыктан поселокта торак төзелеше колачы да бик тарайган. Салихларга шактый кысан бер бүлмә генә биргәннәр иде.

Салихны «яучылауны» Зиннур нәкъ шушы мәсьәләдән башлады. Нефтьчеләрнең үзәк шәһәренә җыелышка килгән иде Салих, экономист Җәмиләнең дә йомышы чыгып, ул да ияргән иде. Зиннур, ир белән хатынны машинасына утыртып, аларга бер-бер артлы өч квартира күрсәтте. Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле квартира. Элеккерәк проект буенча, түшәме бик биек, икенче катта, балконы юк. Эшкә йөрергә бик якын булса да, балалар бакчасы шактый ерак икән. (Монысына Җәмилә игътибар итте). Аннары, микрорайондагы тугыз катлы йорт янына килеп туктадылар. Лифт эшләми иде, тугызынчы катка җәяү менеп киттеләр. Өч бүлмәле, балконы булса да, әллә ни иркенлек сизелми. Ул арада Җәмилә күршеләрдән: «Өске катларда еш кына су булмый, басым җитми», дигән хәбәр дә ишетеп өлгергән.

— Син кашыңны җыерырга ашыкма әле, кордаш,— диде Зиннур һәм машина өченче микрорайонга юл тотты.

Биш катлы йортның өченче катындагы квартира ишеген ачып җибәрүгә, битләргә мул булып кояш нуры бөркелде. Ике бүлмәле, өченчегә иркен, матур итеп эшләнгән лоджия. Җәмилә теләгән балалар бакчасы ишегалдында ук. Монысы ирнең дә, хатынның да күңелләренә хуш килде.

Күченгән көннең иртәгесен үк өй туе үткәрделәр. Мәрдәновлар үзләре бу турыда уйламый да, дөресрәге, мондый бәйрәмне «бераз баш-күз алгач»ка ниятләп куйганнар иде. Дибаевлар авыз ачарга да ирек бирмәде.

— Өй туеның бөтен кызыгы шунда инде аның, идәнгә тезелешеп утырып, кайсың җамаяктан, кайсың ташаяктан тәгам җыюда да, өй мебельләр белән тулганчы, иркенләп бер дөбердәтеп биюдә,— диде Диләфрүз.

— Коллектив белән якыннан танышып, аралашып китүнең иң шәп ысулы,— дип өстәде Зиннур.

Диләфрүз — Зиннурның хатыны — Зәйтүнәләр туенда беренче күрешүдә үз матурлыгына үзе сокланган адәмдәй, бик горур-һавалы кебек күренсә дә, чынлыкта һич тә андый зат түгел икән. Ул өй туе мәҗлесенең җаны булды. Шаян-мәзәк сүзләр белән таныш булмаганнарны җаена китереп кенә таныштырды, җиңел сөяктән бөтен кунакларны биюгә тартты.

Ике гаилә бик якын дустанә аралашып, бәйрәмнәрдә, туган көннәрдә бер-берләренә кунакка йөрешеп, күңелле генә яшәп киттеләр. Мәрдәновлар яңа өйләнешеп, үз ояларын яңа коручылар буларак, аларга өй җиһазларыннан, тегесе-бусыннан кирәк-яракның иге-чиге юк иде. Диләфрүз ханым мондый мәсьәләләрдә Җәмиләгә иң беренче оста киңәшче булды, Зиннур исә андыйларны табуда, өйгә кайтартуда алыштыргысыз ярдәмче иде. Шәһәр житәкчеләреннән булсын, тәэминат бүлеге башлыкларыннанмы — бер дә белмәгән, дусларча мөнәсәбәттә булмаган кешесе юк иде. Шуңа да андый мәшәкатьләрне Зиннур һич кыенсынусыз, эш арасында, уйнап кына дигәндәй башкара иде.

Эшендә дә Зиннур Салихның иң беренче киңәшчесе, ярдәмчесе булды. Ни генә әйтмә, Зиннур инде стажлы белгеч, Идарәдә, шәһәрдә абруйлы кеше. Шундый сабакташың, гаилә дустың булу — тормышта ай-һай зур терәк икән ул. Поселокта мондый «терәксез» генә ярты

елдан артык яшәп карамаса. Салих, ихтимал, моны аңлап та бетермәс иде. Бәхетсезлек бәхет китерде, дигән сыманрак...

Зиннур житәкләгән бүлекнең Салих эшенә әллә ни катнашы юк, шуңлыктан алар хезмәттә бер-беренә бәйсез диярлек иде. Эштә алар начальник кабинетында үтә торган планерка, киңәшмәләрдә генә бергә булалар. Шунда Салих Зиннурның бөтен идарә эшенә кагылышлы акыллы чыгышларын ишетә; сөйләү рәвешендә, үз-үзен тотышында ук «начальникларча» мәһабәтлек бөркелеп тора моның. Сабакташының мондый чыгышларыннан соң Салих еш кына: «Ерак китәр бу»,— дип уйлап куя иде. Үзендә исә мондый сыйфатны аз гына да сизми Салих. Үз эшеңнен теләсә кайсы коллегаң белән ярышырдай остасы бул, бәһале белгеч бул — әнә шундый максат, китапчалап әйтсәк, шундый принцип белән яши Салих.

Ике гаилә дуслыгы якынайганнан-якыная барды. Аеруча, Жәмилә белән Диләфрүз аерылгысыз ахирәтләр булып киттеләр. Озакламый Жәмилә бер дә аһ-уһ килми генә, гадәти бер хәл кебек кенә, тагын бер малай алып кайтты. Дибаевларның бердәнбер кызлары инде мәктәпкә йөри, шуңадыр Диләфрүз Мәрдәновларның нәниләренә үз улларына тугандай шатланды, өйгә килсә, баланы сөеп туя алмый, һәр килүендә, кайгыртучан әбидәй, бик кирәген белеп кенә, берәр нәни кием-салым, уенчык-фәлән дә кыстыра килә иде.

Салих та Дибаевларның үтә сизгер ярдәмчеллегенә рәхмәтле иде, әлбәттә. Ә шулай да... Шулай да еш кына Зиннур белән Рәйсәнең машинада кочаклашып җәяүле солдатны узып китүләре күз алдына килә дә күңелләр әллә нишли... «Рәйсә Зиннурга кияүгә чыга» дигән хәбәр тагы. Мондый чакларда: «Кеше ни сөйләмәс, аларның машинада бергә кайтулары очраклы хәл генә ич»,— дип, үз-үзен тынычландырырга тырыша Салих. «Нигә төймәдән дөя үстерәм соң әле мин, вак җан!»— дип үз-үзен битәрләп тә ташлый иде. Үзенең шул рәвешчә «вак җанлылыгы» турында берәүгә дә сөйләгәне-сиздергәне булмады аның.

...Ә күңел юшкынын юардай чара-дәва, белмим, бар микән соң ул тормышта?

*— Гафу итегез, ничегрәк монда хәлләр?*
*— Тсс, Диләфрүз Бариевна... Операция бара.*

## 9

Сөенечләрдә чәчәк атабыз,
Көенечләргә керен янабыз,
Үкенечләрдән акыл алабыз...

Тагын күңел кылларын җил тибрәтә башлады. Нинди җыр соң әле монысы? Юк, җыр түгел, кайчандыр укыган шигырь юллары ич бу. Әй, бар иде заманнар... Армия елларында, аеруча ерак төньякта эшләгәндә, үлеп тә җыр, шигырь ярата торган булып китте ул. Башта әнә, күңел түрендә бабасының әлеге балачактан бирле йоклап яткан моңлы җыры күңелләрне айкап алды. Аннары, якташлары очрап, туган якларын сагынуга түзә алмый җыр сузып җибәрсәләр, күзләрдән яшьләр килә иде. Ерак төньякта якташлар алай еш очрап тормый. Ә күңел гел җыр тели. Шулай җыр эзләптер инде, кулына төшкән һәр шигырь китабын йотлыгып укый торган булып китте. Җыр гына түгел, шигырьләр дә нәкъ күңелдәгеңне әйтеп бирә ала икән ич! Һәрбер шигырь түгел, әлбәттә. Газета укыгандагы кебек, акмы — ак, карамы — кара дигәндәй, мең кат ишеткәннәрне матурлабрак кына кабатлый торганнары да бар. Бар шундыйлары... Күптәннән күңелеңне тынычсызлап, кытыклап йөри, ә сүзләр белән шуны һичничек әйтеп бирә алмыйсың. Шигырь

дигәнең, болытлар арасыннан кинәт калкыган кояштай, көтмәгәндә күңелеңне балкыта да җибәрә.

Исемдә исемең! Көнозын
Кабатлыйм кабынып мин,
Ә бәлки, табынып, дим.

Монысы — Рәйсә искә төшкәндә күңелдә кабатлана торган юллар. Кайсы китапта, кайчан укыды ул мондый шигырьне?— анысы һич истә юк. Туган яклардан еракларда уянган шигъриятькә тартылу гомерлеккә калды. Өлкәнәя төшкәч тә, эш, тормыш мәшәкатьләренә колакларына кадәр чумган көннәрендә дә ул еш кына кулына берәр шигырь китабы ала, андый китаплар өстәл тартмасында (эшендә дә, өендә дә) һич өзелеп тормый, китап кибетенә керсә, кулына берәр шигырь китабы эләктерми чыкмый иде.

Елмай, син, язмыш, ач миңа колач,
Михнәт булмасын, дан булсын эшем.

Бу юлларны эшкә барышлый еш кабатлый ул. Шушы юллар кәефләрне күтәреп, аяк атлауларны җиңеләйтеп җибәрә.

Күңел дөрес сизенгән икән: бергә эшли башлауларына ике еллап вакыт үтүгә, Зиннур Идарәнең башлыгы булып күтәрелде. Шулай буласын күңел сизенгәнгәме, Салих сабакташының болай үсеп китүенә аз гына да гаҗәпләнмәде, үзендә чеметем дә көнләшү дигән нәрсә сизмәде. Идарә эшендә нәкъ шулай булырга тиеш кебек кенә бер вакыйга булды бу.

Зиннур, башлык булгач та, үз-үзен тотышында әллә ни үзгәреш сиздермәде. Планерка, киңәшмәләрдә шул ук эшлекле, төгәл, өздереп әйтә торган чыгышлар. Хезмәттәшләре фикеренә сизгер колак сала, бәхәсләр чыкса, тыныч-сабыр гына тыңлап утыра да, нәкъ уртак фикерне тотып алып, соңгы ноктаны куя белә. Сабакташының мондый сәләтенә Салих соклана гына иде. Кара инде, бишектәге бишкә тәрләнер дигәндәй, балачактан бергә аунап үскән, бер партада утырып укыган малай әнә нинди талантка ия икән ләбаса!

Бервакыт, Зиннур кабинетында чираттагы планлаштыру бара иде. Кинәт телефон шалтырады. Гадәттә, планерка, киңәшмәләр вакытында башлык өстәлендәге яшел, ак, зәңгәр телефоннар барысы да тынып тора, күрше бүлмәдәге секретарь кыз аларны ялгамый иде. Бу юлы озынча кызыл телефон шалтырады. Монысы — Мәскәү белән турыдан-туры элемтә телефоны. Зиннур, сөйләвеннән туктап, ашыкмый гына трубканы алды. Башта «Исәнмесез, Геннадий Борисович!»— дип, бик гади-якын итеп исәнләшү, кыска гына хәл-әхвәл сорашулар. Аннары Мәскәү эш турында сорашуга күчте бугай, Зиннур: «Тырышабыз мөмкин булганның барысын да»,— дип, кыска-кыска җаваплады. Ул арада сөйләшү конкрет саннар белән бара башлады. Зиннур күп саннарны күңеленнән генә әйтә, алдындагы кәгазьләргә күз сала, ул арада трубканы иңбашы белән колагына кыстыра да, куллары белән арифметик линейка шудырмасын күчергәли-күчергәли исәпләп ала, бик тиз арада кирәкле санны әйтеп тә өлгерә иде.

Салих сабакташының Мәскәү кадәр Мәскәү белән шушы кадәр иркен-тыныч сөйләшүенә сокланып карап утырды. Үз бүлмәсенә чыккач, кинәт мәктәп еллары, Зиннурның математикадан гел өчле алулары хәтердән үтте. «Ничек шулай математик сәләтләре дә ачылып киткән моның?»— дип, бик гаҗәпсенүле уйлап куйды. Зиннурның тиз-тиз исәпләп, башкалага нинди саннар хәбәр итүен Салих яхшы аңлый иде. Әле ай урталары гына булса да, план үтәлешенең ни дәрәҗәдә икәне белән кызыксына Мәскәү.

Салих, бүлмәсенә сыеша алмагандай, ишекле-түрле йөренә башлады. Бик кисәк ишекне ачып, план бүлегенә кереп китте. Анда, янәсе, үз эшемә кирәк дип, скважиналардан килгән оператив тас-

маларны сорап алды. Мондый тасмаларны автомат аппаратлар язып бара, алдашу мөмкин түгел иде. Салих бөтен эшен куеп, шуларны исәпләп-йомгаклап утырды. Ниһаять, бүгенге көнгә нефть чыгару күләмен күрсәткән сан аның алдында. Чынбарлык саны Зиннур Мәскәүгә хәбәр иткән саннан бик күпкә ким иде. Әйе, әйе, Салих үз зиһененә нык ышана, Зиннур авызыннан яңгыраган сан чынбарлык белән аз гына да туры килми иде.

Диләфрүзнең туган көне икән бүген, эштән кайтуга, Җәмилә шул турыда искә төшерде. Салих, ябылганчы дип, абына-сөртенә «Бүләкләр» кибетенә йөгерде.

Дибаевларның шәһәр төзелә башлаганда ук салынып калган «финский» дип йөртелгән, бакча эченә күмелеп утырган йорт-квартиралары бу юлы да Мәрдәновларны бик ягымлы каршы алды. Башка кунаклар да житәрлек иде, күбесенчә берләшмә кешеләре. Өстәлдә, кем әйтмешли, күгәрчен сөте генә юк (шул исемдәге матур тартмалы кыйммәтле конфетларны искә алмаганда). Салих, барыннан да бигрәк, бакчадан гына өзеп алып кергән кыяр салатына ябышты. Шул бик истә.

Утыра торгач, кунаклар төнге гөлләр исе аңкып торган ишегалдына, бакчага сибелделәр. Шунда Салих, Зиннурны җиңелчә генә култыклап читкәрәк алып китте дә бүген иртән үзе исәпләгән сан турында сөйләп алды. «Син, ашыгыбрак китеп, ялгышкансың бит, малай, ә чынбарлыкта хәл менә шулай тора»,— дип. Идарә житәкчесенең ялгышын искәртү төсендә генә әйткән иде Салих бу турыда. Зиннур, Салихны тагын да шаккатырып, тын гына кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Саннар ул, дускай, аерым кешенең генә түгел, бөтен бер коллективның язмышын хәл итә хәзерге заманда,— диде ул һәм «һаман да сабыйлыктан чыга алмыйсың әле син», дигәндәй, кайгыртучан ата сыманрак, Салихның кулбашыннан сыйпап куйды.

Салих, тәненә ток йөгергәндәй, кисәк кулбашын читкә тартты.

*— Сестра, әйтегезче...*

*Авыз-борынына марля-япма бәйләгән сестра, операционный ишегеннән чыгуга, бүлмәдәгеләрнең сүзле һәм сүзсез сорауларына уң кулын күтәрә төшеп кенә җавап бирде дә, ашыгып чыгып китте. Шунда ук зур гына ялтыравык ак әрҗәдәй аппарат күтәреп, операционныйга кереп китте. Керешли берәүгә дә күтәрелеп карамады.*

*Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Зиннур сәгатенә карап алды, Диләфрүзнең колагына ук иелеп, нидер пышылдады. Бу пышылдау, аннары Зиннурның аяк очларына гына басып, тышкы ишеккә юнәлүе, ишекнең ачып-ябылуы — берсе дә тынлыкны аз гына да бозмады.*

## 10

Төрлесе булды тормышта,
Сугышып жаным арса...

Калган юллары ничек иде соң әле бу җырның, әллә шигырьнеңме? Бик яхшы белә иде бит. Авылына кайтканда, юл буе эчтән генә гел кабатлый, көйли иде.

Бәлки, һәркемнең дә шулайдыр, үткән гомер юлың турында уйлана башладыңмы, күңелдә һәрчак моңлы бер көй, җыр яңгырый башлый. Өлкәнәя башлагач, аеруча.

Балачактан ук күңел каядыр ерак-еракларга ашкына. Кемдә ничектер, Салихта мондый ашкыну һәрчак канәгатьсезлек, язмышыннан ризасызлык белән бергә үрелеп барды. Солдатка алынгач, юллар аны әллә кайларга, әйтик, дус-тугандаш илләрнең берсенә алып китәр кебек иде. Язмыш дигәнең бүтәнчәрәк елмайды. Бер дә әллә кайларда ту-

гел, күрше Пермь өлкәсендә генә хезмәт итте. Җире-суы, җәе-кышы туган яклардан бер дә әллә ни үзгә түгел.

Ерак төньякка юл тотканда да, күңел ашкыну белән тулы иде. Монда, әлбәттә, барысы да бүтәнчәрәк. Озын, суык кышлары, айлар буе караңгы төннәре, искиткеч матур төньяк балкышы. Шул суык караңгылыкта үзенең утлы һөнәр иясе булып китүе дә күңелгә бик хуш килде. Очсыз-кырыйсыз караңгылыкта ул очкын чәчрәтә-уйната, тимер кадәр тимерне сыга-бөгә... Яшь күңелгә бик хозур, бик горур иде бу. Аннары, шул ук ут-очкыннар күңел түрендәге бабасы моң-җырын уятты.

Институт еллары да ашкынулы үтте. Курсташлары арасында ул иң өлкәне иде. Төркемдә барысы да мәктәп партасыннан гына килгән егетләр-кызлар, ә ул — ил-җирләр гизгән солдат. Ашкынулы хыяллар исә барысыныкы да уртак. Алай гынамы, Салих бу яктан яшь сабакташларыннан да уздыра иде бугай. Шуңа да, төркемдә барысы да аңа тартылалар иде. Аннары әле, төркемдәшләр барысы да әти-әниләре җилкәсеннән төшмәгән, еш кына кесәләрендә тиене дә шалтырамаган көннәре була. Мондый чакларда Салихның яшь дуслары аеруча күбәеп китә, студентлар ашханәсендә Салих абыйлары заказ бирүче-түләүче булып кына утыра, ашын, тегесен-бусын ташып йөгерүчеләр житәрлек.

Җәмилә белән дә алар шушы студентлар ашханәсендә танышып киттеләр. Ифрат сабыр, шулай ук иптәш кызлары арасында өлкәнрәк бу студенткага Салих байтактан игътибар итә, «күз атып» йөри иде инде. Беркөнне Салих тирәсендәге күңелле төркемгә кетмәгәндә шушы «апа-студентка» да килеп кушылды. Көлемсерәвен бик мөлаем яшереп кенә:

— Бай абзый! Минем дә тамакны туйдырыгызчы,— диде.

— Зинһар, табыныбызны ямьләндерегез.

Иртәгәсен Җәмилә, подносын күтәреп, тагын Салих каршысына килеп утырды. Өстәлгә кичәге әҗәтен куйды.

— Ә шулай да, бай абзый, сез бик алай иркенәймәгез. Кулыгызга диплом алганчы, тагын мең дә бер йөз туксан биш көн яшисегез бар,— диде шул ук мөлаем елмаю белән.

— Кайдан мондый төгәллек?

— Әгәр бер иксны чишә алсам, мин сезгә көнгә күпме туздырырга кирәген дә бик төгәл әйтеп бирер идем.

— Нинди икс икән ул?

— Әнә, үң кесәгездәге кенәгәгә язылган сан.

— Кенәгә уң кесәдә түгел, әмма анда язылган сан сер итеп саклана.

Танышып киткәч, Җәмилә, үзе сайлаган һөнәренә хас, тормышка шулай төгәл исәп-хисап күзлеге аша каравын моннан соң да күп тапкырлар күрсәтте.

Кулына диплом алгач, Салихның бер дә алай ерак-ерак җирләргә түгел, үзебезнең якларга ук эшкә билгеләнүенә һич карышусыз риза булуында да, аннары, Зиннурлар Идарәсенә эшкә күчүендә дә Җәмиләнең практик акылы аз роль уйнамады.

Озак та үтмәде, Салихны Идарәнең баш геологы итеп күтәрделәр. Хәзер инде ул Идарәдә бүтән «Баш»лар белән бергә, эшне төпкә җигелеп тартучы, алай гына да түгел, Зиннурның уң кулы иде. Начальнигының: «Саннар ул, дускай, аерым кешенең генә түгел, бөтен бер коллективның язмышын хәл итә хәзергесе көндә»— дигән сүзләрен дә еш искә төшерергә туры килә иде. Искә төшә дә, нихәл итәсең, шулай кирәктер инде ул... Шунсыз булмыйдыр дип, мондый хәлгә күңеле ачыну белән күнегеп тә килә иде бугай.

Күнегеп килә, әмма әлеге үз-үзеңнән канәгатьсезлек хисе һич йокламый, ул хисне җиңү, ихтимал, мөмкин дә түгелдер.

Геолог!.. Бу сүз үзе үк күңелдә балачактан ук романтик алсу-зәңгәрсу төсләргә төренеп балкый иде. Эшли башлавының беренче

көннәреннән үк бу алсу-зәңгәрлек бик тиз соп-соры төскә керә башлады.

Татарстанда төп нефть ятмалары гасырлар буе килгән тарихы белән инде күптән ачылган, аркаңа биштәр асып, яңа сукмаклар салып йөрисе юк. Моны, әлбәттә, Салих яхшы белә иде. Яңа ятмалар ачасы юк, яңа чыганаклар ачасы бар әле. Монысы да Салихка яхшы мәгълүм иде. Дөрес, кулыңа геолог чүкече тотып, яңа сукмаклар салып түгел. Яңадан-яңа приборлар ярдәмендә.

Ләкин эшендә Салих мондый хозурлыктан да мәхрүм булып чыкты. Яңа чыганаклар ачу, кара алтынга кайсы урындарак җир бораулап төшү ноктaларын билгеләү белән бөтенләй башка оешма — геофизик трест шөгыльләнә иде. Салихлар Идарәсенең бурычы исә — бораулаучылар кулыннан әзер скважиналар кабул итеп алу да шул коелардан җае-әмәле белән генә җир маен суыру иде.

Җае-әмәле белән генә... Монда инде Салихның университетта алган белеме кирәк, фәнни-тикшеренү нефть институты шул «җае-әмәле» дигәннең кырык төрле яңадан-яңа ысулын тәкъдим итеп тора. Шуларга үз профессиональ сизгерлегеңне, тәҗрибәңне дә кушып, сайлап ал, тикшер дә куллан.

Шулай итеп, Салихның эш көннәре геологик карта-схемаларга, исәп-хисап диаграммаларына, башка кәгазьләргә күмелеп, бер дә геологларга охшамаганча, башлыча кабинетта гына үтә иде.

Җаен-әмәлен белеп кенә... Әйтергә генә ансат шул бу. Кырыкмаса-кырык ысулның иң кулай дигәнен сайлап алу турында көн-төн уйланасың, җаныңны кат-кат айкыйсың, «менә таптым» дигәч кенә скважинаның режим-планына имзаңны куясың.

Баштарак, чыннан да, «җае-әмәле» дөрес табылган кебек була. Скважиналар, иплe генә, түкми-чәчми генә җир маен суырып утыра. План да әйбәт кенә үтәлә. Һәм менә, һич көтмәгәндә, Девон бабай үз көйсезлеген күрсәтә дә куя. Каядыр гектарлап җиргә нефть түгелгән, кайсыдыр чишмә, дегеттәй май, нефтьне кысрыклап чыгару өчен катламга кудырылган химик матдәләр белән катнашып, янына бармастай сасып ага башлаган... Тагын яңа ысул, яңа режим кирәк. Тагын төн йокылары кача. Мондый көннәр, мондый эзләнү-тикшерүләр үз чиратында план үтәлешенә китереп суга.

Шушы нигездә Зиннур белән дә бәхәскә кереп бетәләр. Хәер, бәхәс дигәне алай якага-яка килешүгә барып җитми. Салихның табигатьне, әйләнә-тирә мохитне саклау турында кызып-кызып сөйләгәннәрен, башлык, әйтергә була, Сократларча бер тынычлык белән тыңлап утыра да шулай ук философларча могтәбәрлек белән әйтә:

— Синең, кордаш, әниеңнең он иләгәнен күп мәртәбәләр күргәнең бардыр инде. Никадәр сак, никадәр бәрәкәтле итәргә тырыша ул, әмма никадәр генә тырышмасын, кашларына барыбер ап-ак он куна. Кашына гынамы соң! Бөтен келәт, җилпуч, куна тактасы ап-ак булып кала. Тегермәнчене алыйк. Ап-ак онга батмаган тегермәнчене кайда, кайчан күргәнең бар? Борын-борыннан шулай. Су, җил тегермәннәре заманыннан башлап, хәзерге электр тегермәненә кадәр ап-ак онга батып беткән булыр тегермәнче. Безнең эштә дә шундый хәл инде ул, малай.

Яңа җай-әмәл, яңа геологик режим эзләү озаккарак сузыла башласа, начальникның тавышы шактый кырыс яңгырый башлый:

— Дәүләт дисциплинасы дигән нәрсәне онытмыйк, кордаш. Нефтьнең ил экономикасы, илнең халыкара хәле икәнлеген сиңа аңлатып торасы юк.

Бервакыт Салих кабинетына, гомердә булмаганча, ифрат җитди талчыгулы кыяфәттә Илгиз килеп керде. Җүнләп исәнләшеп тә тормастан, Салих каршына шап итеп килеп утырды да:

— Сез, кордаш, безнең басуларны да харап итә башлыйсыз икән инде, значит,— диде.

— Ничек... харап итәбез?

— Белми янәсе... Инеш буена, Яшьләр урамы артына ук вышка китертеп утыртмакчылар анда. Безнең ужым басуларын, сугарулы болыннарны таптатып, вышкаларын сөйрәп кенә китермәкчеләр, значит.

— Анысы әйбәт түгел, әлбәттә. Ләкин бит, кордаш, бу эш безнең Идарәгә бәйләнмәгән.

— Ничек бәйләнмәгән? Барыгыз да нефтьчеләр ләбаса! Үзара килешеп тә эшли белмәгәч... Нинди заман кешеләре соң сез? Кайсы илнекеләр?

— Илгиз, зинһар, тынычлан әле. Андыйга китсә, мин дә сиңа нәкъ шундый ук сорауны бирә алам. Нефтьчеләр белән игенчеләр дуслыгы турында, мәсәлән.

— Дуслык! Син тир түгеп иген үстер, икенчең, шуны таптап, изеп үтсен дә, дусларча үбеш!

— Дөресен генә әйткәндә, минем менә хәзер сине, чыннан да, кысып-кысып үбәсем килә.

— Ә минем сине тотып дөмбәслисем килә, значит.

— Синең ул йозрыкларга эләккәнче, шуны гына сорап калыйм: ни хәлләрдә яшәп ятасыз? Тагын ишәймәдегезме әле?

Илгизнең ачу-ярсулы йөзе шунда гына нәкъ Илгизчә итеп, сабыйларча елмаю белән яктырып китте.

— Җиденчене көтәбез. Бу темплар белән барганда, Ризидә апагызның герой-ана булу ихтималы да юк түгел, значит.

Яңа нефть мәйданының алар авылын да биләгәнен Салих, әлбәттә, яхшы белә иде. Яңа мәйданнан нефть чыгару нәкъ менә алар Идарәсенә тапшырылачагы да мәгълүм иде. Салих туган төбәгенең мондый киләчәгенә бары куана гына иде. Бу хәбәрне беренче ишеткәндә, Салихның күз алдына, иң әүвәл, көзге былчыракта җәяү кайтып килүче солдат күз алдыннан чагылып үтте. Нефть чыга башлау, барысына да өстәп, яңа асфальт юллар да дигән сүз бит инде ул!.. Шулай да, Зиннур әйтмешли, иләгәндә, он тузаны очмый калмый. Дөрес, хәзер илленче, алтмышынчы еллар түгел инде.

Моңарчы Салих, яңа скважиналар кабул иткәч, вазифасы таләп иткәнчә, алардан нефть чыгару режимын фәнни-тикшеренү институты тәкъдимнәре арасыннан гына сайлап ала иде. Илгиз белән сөйләшү күңелгә чын-чынлап тынычсызлык очкыны кабызды. Юк, андый «он тузанын» бөтенләй дә очырмыйсы иде!

Күңелдәге очкын дөрләгәннән-дөрли барды. Йокысыз төннәр, фәннитикшеренү институты, Казан галимнәре белән кайнар бәхәсләр тулы көннәр башланды.

...Илгиз, Илгиз! Рәхәт тә, газаплы да мондый очкынны син кабызып җибәрдең бит күңелдә. Күптәннән пыскыса да, чынлап торып дөрләтүчесе син!

*Бүлмәдән Зиннур чыгып китүгә, Илгиз дә Җәмилә колагына пышылдады. Аның пышылдавы исә барысына да ишетелерлек иде:*

*— Минем дә барып киләсе бар иде бит, тегее... бәбәй алып кайта торган җиргә.*

*Һәм бөтен чырае белән якты елмайды. Шушы елмаю бүлмәдәгеләрнең уңайсыз-җитди йөзләренә дә кунып өлгерде.*

## II

Сибелә чәчәк — күңел чәчәкләре,
Йолдыз булып сибелә төннәрдә...

Шуның шикеллерәк иде ул төннәр. Илгиз килеп киткән көнне Салих төне буе йоклый алмады. Вышка күчереп утыртасы урын, әлбәттә, ба-

лачактан ук аңа яхшы таныш иде. Чыннан да, нигә ужым басуы, болын буйлап үтәргә соң әле? Әллә ни ерак та түгел, станция юлы бар. Нигә шуннан үтмәскә?

Салих төн уртасында торып утырып, таныш җирләр буйлап юл сызып карады. Әллә ни урагыч та түгел, була бит, ужым, болынны бөтенләй диярлек таптамый үтәргә була. Бәлки, вышкачыларны инеш аркылы чыгу куркыткандыр? Салих яхшы хәтерли, Илгизнең әтисе колхозда иң оста механизатор Мәрди ага, язгы чәчү вакытында аргы басуга әллә кайдан, станция юлыннан әйләнгәнче, тирә-юньдә иң зур тракторы белән гел инеш аркылы гына чыга иде. Бервакыт Мәрди аганың председатель белән сөйләшкәннәре дә хәтердә:

— Синең аннан-моннан гына балчыклы таш җәйгән станция юлыннан да ышанычлырак ул инеш төбе, энекәшкәем. Табигать мең-мең еллар буе, иң нык чуерташлар белән күптән ныгытып куйган инде ул инеш төбен,— дигән иде карт механизатор.

Әйе, бик ихтимал, вышкачыларны нәкъ шушы инеш өркеткәнгә охшый. Ярлары да, кайчандыр елга төбе булгангадыр, бик нык. Дөрес, биек булмаган таулар. Ләкин, Салих яхшы хәтерли, Мәрди ага үтеп йөргән урында бернинди тау юк, сөзәк, ипле.

Иртәгәсен эшкә килүгә, Салих, юл сызымын күтәреп, иң беренче, Зиннур янына керде.

— Матур идея бу! Чыннан да, Илгиз әйтмешли, туган басуларны харап итүгә юл куймаска иде шул,— диде башлык, папкасына ниндидер кәгазьләр сала-сала, аннары папкасының ялтыр каптырмасын шартлатып япты да урыныннан торды.

— Мин хәзер берләшмәгә киттем. Бу турыда мин анда сүз кузгатырмын. Хәзер син вышкачылар конторасына үзең белеп килсәң икән.

Бергәләп коридорга чыккач, Зиннур җиңелчә генә Салихның терсәгеннән алып, сөйләп барды.

— Беләм мин Иван Кузьмичны, бик үзсүзле кеше. Син инде иплебрәк сөйләшә күр. Һәр үзсүзлеләр кебек, салпы ягына салам кыстырганны бик ярата. Хәтерлисеңдер, алар конторасы вышкачылар ярышында бөтен Союз күләмендә җиңеп чыктылар бит. Сүзне, мәсәлән, шуннан башларга була.

Иван Кузьмичның алай үзсүзлеге сизелмәде. Салихның юл сызымына бик җентекләп карап торганнан соң, алдындагы өстәл календаре битләрен актарып алды.

— Сроклар бик кысан кысанын. Шулай да сезнең фикерне исәпкә алырбыз. Табигатьне саклаучылар белән конфликтка кермәскә дә бик әйбәт фикер бу, рәхмәт сезгә,— диде, һәм урыныннан торып, Салихның кулын каты итеп кысты.

Ике көннән соң Салих, радиодан иртәнге соңгы хәбәрләрне тыңлый-тыңлый, кырынып утыра иде, безопаска тоткан кулы туктап калды. Радио алар вышка конторасының вышкалар төзү буенча яңа бөтенсоюз рекорды куюы турында хәбәр итә иде.

Эшкә килүгә, Иван Кузьмичка шалтыратты. Уңышлары белән котлау сүзләреннән соң, сорады:

— Нинди маршрут белән үттегез?

Трубкада тавышы бик тантаналы-күтәренке иде:

— Рекордның асылы — тәвәккәллектә, иптәш Мәрдәнов! Гомумән, һәр җиңү тәвәккәллек белән яулап алына.

— Тәвәккәллек плюс төпле акыл. Бу хакыйкатьне дә онытмыйк, Иван Кузьмич.

Шунда бүлмәгә Зиннур килеп керде.

— Җиңүчеләрне хөкем итмиләр, кордаш. Тизлек заманы!— диде һәм «бу турыда сүз бетте»,— дигәнне аңлатып, шунда ук әңгәмәне көндәлек эшләргә борып җибәрде.

Зиннур чыгып киткәч, Салих, ике кулы белән башын учлап, хәрәкәтсез калды. Гүя уйлар агышы бөялеп калган да, инде ничек ерганак ера алмыйча, чигәләргә ыргыла, дулый, чәбәләнә иде.

Уйлар агышы бөялеп калган, ә агым бөтергеләре мең төрле сорау белән тулы иде.

Нәрсә соң әле бу? Башта бит барысы да аның яклы кебекләр иде. «Матур идея бу!», «Сезнең фикерне һичшиксез искә алырбыз, рәхмәт!» Инде менә, үзләре әйткәнчә, шул «матур идеяне» таптап, изеп үттеләр дә тагын шоп-шома, бик матур һәм дөп-дөрес сүзләр: «Һәр җиңү тәвәккәллек белән яулап алына», «тизлек заманы!»

Тизлек заманы... Нәрсә, әллә аның, Салихның, инде заман тизлегенә иярә алмыйча, артта сөйрәлә башлавымы бу? Иртәрәк бит. Бишенче дистәне әле түгәрәкләп кенә кила. Зиннур белән яшьтәшләр, Иван Кузьмич та шул чама. Юк, юк, картаерга, артта сөйрәлә башларга иртә. Бик иртә. «Матур идея! Рәхмәт, фикерегезне искә алырбыз». Бу инде артта сөйрәлү дигән сүз түгел. Киресенчә, аның фикеренә малайсытып кына карау түгелме соң? Картаю түгел, ә малайлык...

Сораулы уйлар бөтергәләнә, ярсый, ә күңел сыкрый, көчәйгәннән-көчәя барып сызлый иде.

Башын кискен генә чайкап алды да кызу-кызу телефоннан номер җыя башлады (бу вакытта хәтердә Шакир абыйсының акыллы-уйчан йөзе, шуның артыннан ук Рәйсәнең нурлы елмаюы бик тә ачык чагылып үтте).

Трубка бик тиз, яшь, дәртле тавыш белән җавап бирде:

— Гараж тыңлый.

— Әә, гафу итегез... Мин номерны ялгышканмын...

Дөресе, чыннан да, гаражга шалтыратуы иде аның. Хәзер үк машина чакыртырга да, авылга китәргә иде исәбе. Трубкадагы тавыш Илгиз тавышына бик охшаш иде. Куәтле тракторлар белән таптап үтелгән уҗым басуы, таныш булып күз алдына килде дә, бөтен тәне буйлап суык дерелдәү узды, шунда ук Илгизнең рәнҗүүпкәле карашы белән очрашкандай булды. Берәүгә дә түгел, бары аңа, Салихка шулай рәнҗеп карый иде кебек Илгиз.

Ашыгып, эшләпәсен башына чәпәде дә секретарь кызга, «мин объектларга барам», дип, урамга чыгып китте.

Аз гына җиләс, кояшлы көн иде. Бина буендагы чәчәк түтәлләренә яңа гына су сиптереп киткәннәр, хәтфәдәй яшел үлән, аллы-гөлле чәчәкләр рәхәт елмая, борынга булып исе килеп бәрелә. Чәчәк түтәлләре булып исе аңкыта, бераз киткәч... Тузанлы бензин исеннән сулышларны туктатып торасы килә иде.

Салих адымнарын кызулатты.

Тукталыш турысына житүгә, шыштырдап дүртенче номерлы автобус килеп туктады. Шушы автобус күңелдә матур хатирәләр кузгатып җибәргәч, Салих, ашыга-ашыга, аңа кереп тә утырды.

Кайчандыр, моннан жиде-сигез еллар элек бугай инде, шушы автобуска утырып китеп, нинди җан рәхәтлеге кичергән иде бит ул. Шактый озын маршрут бу. Юл шәһәр читенә үк алып китә, умарта оясыдай җыйнак-матур дача өйләре тезелешеп утырган бакчалар буйлап үтеп, Миңлебай урманы авызына ук килеп җитеп туктый. Бервакыт, менә бүгенгедәй, Салихның җанына урын таба алмыйча гасабиланып йөргән көне иде, тотты да шушы автобуска утырып китте. Соңгы тукталышта төшкәч, җәяүләп урман эченә юнәлде. Йөри торгач, урман сукмагы аны чишмә буена китереп чыгарды. Дөресрәге, сукмак түгел, көмештәй агым челтерәве китереп чыгарды аны монда. Сукмак, бара-бара, куе үлән арасына кереп югалды, урман тынлыгында, кошлар сайравына кушылып, кайдадыр көмеш челтерәү ишетелеп тора иде. Салих, куактай әрекмән, андыз, чукмарбаш яфрак-сабакларын аралап, авышлык буйлап әчкәрәк үтте. Менә челтерәү янәшәдә үк.

Әйе, кайчандыр улагы, сукмагы да булган, кешеләргә бик хаҗәт чишмә булган бу. Улак инде череп бетеп, җир төсенә кергән, сукмакны үлән баскан, ә чишмә улактан түгел, үзенә яңа юл ярып, һаман да челтерәп агып ята. Салих куак чыбыкларына тотынып тезләнде дә, иелеп, су эчте. Салкынча-саф иде, искиткеч тәмле иде чишмә суы. Кемнәндер ишеткән: «Бетерде инде ул нефть бу якларның чишмәләрен»,— дигән сүзләрен искә төшерде дә рәхәт елмайды. Юк бит, бетмәгән әле саф чишмәләр, әнә, яшеренеп кенә, яңа юл ярган да ага бирә!

Менә хәзер Салих шул наян чишмәне эзләп бара. Бик таныш та, бөтенләй чит-ят та икән хәзер бу урыннар. Теге вакытта беленер-беленмәс бер генә сукмак иде ул якка таба. Хәзер, күр, әллә ничә сукмак, хәтта машина юлы да бар. Кайсыннан китәргә дә белмәссен. Бераз баргач, кап-кара учак урыннары да очрый башлады. Газета кәгазь чүбе, күгәргән консерв савытлары, шешә ватыклары... Һай, ниләр кыланабыз без!

Чү! Чишмә чылтыравы. Исән икән ич әле, җанашкаем!

Хәзер инде, теге чактагы кебек, куаклар, биек үләннәр арасыннан үтәсе дә юк, әнә ул, күз алдында. Авышлык буйлап, киң генә баскыч киртләп төшкәннәр, чишмә, теге вакыттагыча, яшеренеп кенә акмый, озын гына тимер торба буйлап ага.

Салих, кабалана-ашыга баскычтан төшеп, торба авызына иелде. Карачы, тимер аша акса да, һаман тәмле икән ич әле чишмә суы.

Инде кабаланмый гына баскычтан кире менеп, куе үлән эченә сузылып ятты.

Тирә-ягында — ак каеннар. Яфракларын да лепелдәтми, тып-тын калганнар. Әллә нинди, әйтеп-аңлатып булмастай, мәгънәле тынлык бу.

Бөдрә ботакларын түбән иеп,
Тирән уйга калган каеннар...

Нәрсә уйлыйлар икән алар, каенкайлар? Моны, ихтимал, шагыйрьләр генә әйтеп бирә аладыр. Ничек әле?

Йөз кабат кимсенәм, алданам,
Йөз кабат ышанам кешегә.

Уйлый китсәң, күп инде алар, кимсенүләр, алданулар. Шуның артыннан ук ышанулар да...

Шунда Салих ямь-яшел каен ботаклары арасында сарылы-аклы бер нәрсә күреп алды. Нәрсә икән бу? Сикереп торып, алып караса, каен тузы белән юкә каерысын аралаштырып, бик матурлап үрелгән чүмеч. Һич иренмичә, шундый да матур итеп үргәннәр.

Салих, баскычтан тиз-тиз төшеп, янадан су эчәргә тотынды. Аз гына саркый саркуын, әмма бу чүмечтән эчкәч, чишмә суы тагын да тәмлерәк икән.

Табигать тә алай тып-тын түгел икән. Нәрсәләрдер кыштырдый, пышылдый, лепелди. Әле кайдадыр еракта, әле якында гына кошлар чутылдый, сайраша. Шуларга гел көч-куәт биргәндәй, өзлексез чишмә челтери.

Салих янә яшел үләнгә күмелеп сузылып ятты. Бөтен тәнендә рәхәт талчыгу иде. Уйлар да алай чәбәләнми, сабыр-талгын гына агалар хәзер. Ничек ди әле шагыйрь?

Чишмәләр сафлыгын тыңлап,
Чистара кеше үзе.

*Операционный ишегеннән тагын сестра килеп чыкты. Бик тиз, әмма һич кабаланмый гына аргы ишеккә үтте, шунда ук нидер күтәреп, кире операционныйга кереп тә китте.*

*Бу юлы аңа берәү дә бер сүз дәшмәде. Тыенкы уфтанып кына, кул сәгатьләренә карашып куйдылар.*

Инде хәзер кайда ята соң ул? Әллә тагын чишмә буена килеп чыктымы? Сумкасы кайда икән? Югала күрмәсен тагын. Ярамый, һич югалтырга ярамый ул сумканы. Анда — гади катыргы папка. Папкада — геологик карталар, исәп-хисап кәгазьләре. Күпме уйланулар, күпме йокысыз төннәр нәтиҗәсе...

Үтә гаҗәп иде бу. Авылга кайткач, Салих, башта күз алдына китергәнчә, Илгизнең рәнҗү-үпкәле карашы белән очрашмады. Аз гына да сизелми иде Илгиздә андый рәнҗү-үпкә.

— Бер караганда, шәп булып китте әле бу,— диде Илгиз элеккечә, Илгизчә елмаеп.— Тагын берәр яңгыр установкасы алып җибәрергә, кесә ягы саерак иде, значит. Вышкачылар акчасын турыдан-туры Сельхозснабка күчерттем. Культуралы көтүлектә торбалар бик тузган иде, каердым үзләреннән. Инде таптаган болыннарын да үзләреннән ипкә китертәм. Аларда техника житәрлек. Бер рекорд куйдылар, хәзергә җитәр! Инде менә, шуның даны белән җылынып кына, җир-анакай куенына да маңгай тирләрен тамызсыннар. Шулай ул дөнья!

Илгизнең хәлгә шушы кадәр дә оптимистик каравы — ни гаҗәп — Салих күңеленә аз гына да тынычлык китермәде.

Сәеррәк иде «бу дөнья»... Сүз дә юк, бар да — кирәк эшләр, бар да олы максаттан чыгып эшләнә. Эш эшләгәч, тиешле хакы түләнә. Ә күпмедер хак... Бер кесәдән икенче кесәгә әвеш тә тәвеш, әвеш тә тәвеш. Ничек аңларга соң моны?

Аннары алар болынга киттеләр.

Әнә, ул, радио, газеталар шаулатып килеп утырган вышка инеш буенда ук кукыраеп утыра. Данына масаеп, алай тын-һавалы гына утырмый. Гөрли, чыңлый, доңкылдый да башлаган. Бораулаучылар да вышкачылардан калышмаска телиләр, күрәсең. Девон хәзинәсенә юлны шулай ук рекордлы тизлектә бораулап төшмәкчеләр. Тизлек заманы!

Тизлек заманы, ә менә тапталган, актарылган болын, басуны алай тиз генә ипләргә бик ашыкмыйлар икән әле. Вышка килгән юл, әллә ничә канау-ерма булып, актарылып-каралып, күз күреме җиргә сузыла да офык артында югала.

Илгиз ашык-пошык ыргытылган, сүтелгән сугару торбалары өстенә килеп утырды. Һәм башы белән кискен генә уңга-еска ымлап:

— Иртәгә үк килеп җитмәсәләр, арт сабакларын укытам әле мин аларның! — диде.— Рекордыгыз шау-шуын бик тиз басарлык күтәрермен тавышны, значит. Менә бу жимерелгән көтүлек аркасында, күпме сөт алмый калуыбыз бәясен дә, көнлекләп-сәгатьләп икеләтә түләтәм.

Ул кара ерымлы офыкка текәлеп, беразга тынып калды, аннары салмак кына башын түбән иде, кушырылган зур куллары ике тез арасыннан түбән салынып төште.

— И, мала-ай... Жир ярасы да нәкъ йөрәк ярасы шикелле инде ул. Никадәр генә дәвалама син аны, яра эчтән генә сыкрый бирә...

«Сыкрый» сүзе Салихның да күңелен нечкә-үткен сызып үткәндәй булды.

Илгизнең бу кадәр оптимист-шат елмаюлары яшь аралаш көлү икәнлеген Салих шунда гына сизеп алды.

...Кайлардан шушы кадәр көч-куәт килде икән дә, акыл-зиһене ничек шулай галимнәрчә җитезлек, тирәнлек белән эшли алды икән аның ул көннәрдә? Максат шул ук: эшли башлавының беренче көннәреннән үк омтылган биеклек — нефтьне алай «он тузаны» туздырмый гына алу. Хәер, күңел түрендә мондый максатына үзе үк ышанып та бетми иде әле ул моңарчы. «Иләгәндә, он тузаны очмый калмый»... Бигрәк ышандырырлык, бигрәк күз алдындагы хәл иде шул бу. Күпләр, алай гына да түгел, бар нефтьчеләр шул фикердә, күңел тынычлыгы өчен «он тузанын» мөмкин кадәр азрак очыртырга гына омтыла иде. Шушы

ышаныч-омтылыш Салих күңелен дә биләп алган иде бугай инде. Ньютонның бакчада алма өзелеп төшүен күрүдән нинди зур фәнни ачышка килүе кебегрәк булды бугай бу. Тирә-як чишмәләре инде барысы да күпмедер дәрәҗәдә «җир мае» исе аңкытып акканда, урман тынлыгында яшеренеп кенә челтерәп утырган ифрат саф чишмәгә юлыгуы Салих өчен әнә шундый «Ньютон алмасы» булды шикелле.

Нефть фәнни-тикшеренү институтының исәпсез-хисапсыз тәҗрибәләре мәгълүматларын, үз күзәтүләре язмаларын актара-актара, шулар турында уйланып, кат-кат исәп-хисап белән утыра торгач, ул таң атканын да сизми кала иде. Атналар буена сузылган мондый йокысыз төннәр эзсез калмады, әлбәттә. Эшендә аны әледән-әле изрәтеп йокы баса, хезмәттәшләренең сорауларына әллә ничек аңгыраеп калгандай җавап бирә иде. Моны Зиннур да шәйләми калмады.

— Синең, кордаш, сәламәтлек бик шәптән түгел ахры? Әллә санаторийга барып кайтасыңмы? Кырымда үзебезнең база санаторие бар бит безнең, путевканы момент көйләргә була.

— Санаторий соңыннан, малай,— диде Салих.— Яңа мәйданга яңача геологик режим белән утырам мин. Тизрәк шуны тәгәллисем бар.

— Анысы дөрес, кордаш. Буровиклар бик житез маташа анда. Скважиналарны срогыннан элек тапшырмагайлары. Безгә дә эзер булырга кирәк моңа. Тизлек заманы бит!

Бер таңны, йомшак халатына уралып, мыштым гына аның янына Җәмилә килеп утырды.

— Йокларга вакыт, таң сандугачы. Эш сәгате башланырга да күп калмаган, прогулчы иптәш,— диде, пышылдап та түгел, балаларны уятмастай ифрат йомшак тавыш белән.

—Әә... Әйе, вакыт икән шул. Ә нигә прогулчы дисең әле син мине? Эшкә вакытында килеп житәм шикелле.

— Син генә сәгатькә карамагач та... Кайчан, күпмегә соңга калуларың барысы да исәптә анда.

— Әй, алай гына... Секундлар, минутлар. Вак мәсьәлә.

Инде урын өстенә яткач, Җәмилә әйтеп куйды:

— Бишьеллык алдынгылары дип, күпләрне хөкүмәт бүләгенә тәкъдим иткәннәр анда. Син юк. Зиннур — иң югары бүләккә. Монысы да вак мәсьәләме?

— Вактырмы, эредерме, хәзергә иң мөһиме — йоклап алу,— диде Салих, юрганына тагын да тирәнрәк төшеп.

— И Салих... Нигәдер күңелем сизә, Зиннур белән арагызда конфликт чыгар кебек сезнең. Ул — заслуженный да иң югары бүләк иясе, ә син — бернинди дәрәҗәсез прогулчы гына. Кем сүзе өстен булачак инде шунда?

Боларны Салих йокы аралаш кына ишетте.

Кара инде, ул чакта Җәмиләнең сүзләрен шулай йокы аралаш илтифатсыз гына ишетсә дә, менә хәзер аермачык хәтергә төшә.

Ә теге иртәне ул туп-туры Зиннур кабинетына килеп керде. Ул тели́гән, күпме уйланган геологик режим инде, нигездә, табылды кебек, ләкин дөрес юлдан барамы ул? Эшкә барышлый, күңелгә шундый шик килеп төште дә, Казанның таныш галиме белән киңәш итәсе килү тыелгысыз булып уянды. Зиннур белән әнә шул турыда сөйләшергә, үзен кичекмәстән Фәннәр академиясенең Казан филиалына командировкага җибәрүләрен сорарга керде ул.

— Бик хуп, кордаш, әйдә! Буровиклар соңгы метрларны бораулый анда,— диде Зиннур һәм шунда ук секретарьга командировка кәгазе язарга, гаражга шалтыратып, Салихка машина хәзерләргә кушты.

Салих план-экономика бүлегендә утырган Җәмилә янына кереп китте, хатынына үзенең Казанга китүен белдерде. Җәмилә өстәл артыннан кубып, нидер әйтә башлауга, ашыгып чыгып та китте.

Бәхеткә каршы, Казан галиме кабинетында иде, аны тиз кабул итте.

— Син хәзер юлдан соң бераз ял итеп ал, аннары иркенләп сөйләшербез,— диде чал галим, Салихның кәгазьләренә ашыкмый гына күз йөртеп чыккач.— Парикмахерскийга кереп чыксаң да ярап китәр,— дип өстәде Салих, яңакларын ышкып куеп, үзенең ничәнче көн инде кырынмавын шунда гына исенә төшерде.

Галим бу юлы аны лабораториянең тын бер бүлмәсендә каршылады.

— Сезгә, коллега,— диде ул, алдындагы Салих папкасын акрын гына сыйпый-сыйпый,—практиканы куеп торып, безгә фәнни эшкә күчәргә вакыт түгел микән?

Әйе, «коллега» диде чал галим. Ул үзе дә күп еллар буе нәкъ Салих баш ваткан мәсьәлә буенча шөгыльләнә — шуңа ишарәләве булды бугай галимнең.

— Шуннан әйтүем аны, туганкай,— диде галим. Бу юлы «туганкай» дию дә җанга сары май булып ятты.— Сез бирегә бер генә чыганакның геологик режимы турында фикер йөртәсез. Әйтергә була, гаять оригиналь хәл иткәнсез. Кайбер нәрсәләрне ачыклыйсы бар, әлбәттә. Шулай да, беләсезме, нәрсә?

— Тыңлыйм, Николай Семенович.

— Әле монысын әйтергә иртәрәк, әлбәттә. Ләкин мин Сезне азмы-күпме беләм дип уйлыйм... Та-ак. Монысы минем үз фикерем генә...

— Сезнең фикерегезне белү миңа бик тә кыйммәт, Николай Семенович.

— Эш менә нәрсәдә. Бу ачышыгыз нефтьчеләр гасыр буе баш ваткан мәсьәләне хәл итәргә киң юл ача, минемчә.

— Гафу итегез, төшенеп җитмим, Николай Семенович.

— Әйе, бәлки, Сез үзегез дә мондый максат куймагансыздыр. Сезнең ачыш, коллега, нефтьне җир куеныннан моңарчы булганча, яртылаш кына алу түгел, шактый артык алуны хәл итәргә турыдан-туры юл ача, минемчә.

— Сез миңа, әйтерсең, тылсымлы канатлар куясыз, Николай Семенович.

Чал галим якты елмаеп җибәрде.

— Фән һәрвакыт нәкъ менә шундый канатлы кешеләргә бик мохтаҗ, коллега. Әйтегез әле, Сезнең эш хакы күпме анда?.. Шулай. Күпмедер вакыт бераз матди яктан зыян күрәчәксез икән. Ләкин, ышанычыгыз, вакытлыча гына. Бу хезмәтегез — әзер диссертация. Фәнни дәрәҗә алганнан соң, әлеге зыян капланачак. Уйлагыз әле бу турыда, Салих Шәяхмәтович.

Салихның йөрәге аңгәмә башланганнан бирле рәхәт лепелди иде.

— Беләсезме, Николай Семенович, бу яңа мәйдан — минем туган төбәгем. Туган ягымда нефть чыгаруны табигатьне һич рәнҗетми алуга ирешү — ул минем вөҗдан эшем.

Бу вакыт бүлмәгә шомырт кара күзле, кыйгач кашлы, бик шома таралган кара чәчле, татар кызы икәнлеген бер карауда ук чамалап була торган лаборантка-фәлән бугай, тавышсыз гына кереп, өстәлгә ике чынаяк чәй, бизәкле тәлинкә белән тәм-томын куеп чыгып китте. Николай Семенович кызны аталарча назлы-рәхмәтле карашы белән озатып калды.

— Туган як дисез, алайса. Аңлыйм, бик яхшы аңлыйм мин Сезне, Салих Шәяхмәтович. Алайса, бу турыда конкрет сөйләшүне күпмедер вакытка кичектереп торабыз. Ә хәзер мәсьәләгә конкрет килик,— дип, галим папканы кулына алды.

Салих бу сәяхәтеннән чын-чыннан канатланып кайтты. Гадәттә, ул самолетта очарга яратмый, күңеле болганучан иде. Бу юлы «Як» нәкъ вакытында очып китеп, бишектә рәхәт тибрәткәндәй генә алып кайтты, очкычтан төшүгә, аны үзләренең идарә шоферы, ягымлы елмаеп, каршы алды.

Проектта Николай Семенович әйткән искәрмәләр, фикерләр турында уйланып, аларны ачыклавына тыелгысыз шатлык та кичереп, тагын ике көн, ике төн утыргач, Салих кадерле папканы башлыгы өстәленә китереп салды.

— Менә, кордаш, без дә заман тизлегеннән калышучылардан түгел. Яңа скважиналарны яңача геологик режим белән эшләтәчәкбез. Карап чыгуны да сузмассың дип уйлыйм.



## 13

Сузмады Зиннур. Шул төнне үк Салих папкасы кәгазьләренә кереп чумды.

Сабакташының зирәк акылына еш шаклар катa иде Зиннур. Шаккатa да эчтән генә соклана. Соклана да... Күңел түрендә көнләшү дигәне дә уянып өлгерә иде. Ләкин Зиннур мондый яшерен кара хисен аз гына да тышка чыгармады. Чыгаруның кирәге дә юк иде. Еш кына, икәүдән-икәү генә уйнаганда, Салих көтмәгәндә шундый зирәк-үткен сүз әйтеп куя, Зиннур, бер дә исе китмәгәнгә салышып, бу сүзне күңеленә салып куя да, малайлар җыелгач кына, моны үз сүзләре итеп кабатлый. Бар малай таң кала, Салих исә, «Ник минем сүзне кабатлыйсың», дип, ник кенә бер ычкындырсын, киресенчә, моны беренче Зиннур авызыннан ишеткәндәй, күзләрен шардай ачып, тик тора.

Мәктәп елларында да күп файда күрде Зиннур сабакташының мондый сәер, бик тә сәер гадәтеннән. Контроль эшләрне аннан күчереп, күчереп булмаганда аннан эшләтеп алулар (берсүзсез, күз ачып йомганчы эшли дә бирә!) дисеңме, укытучы дәрестә сөйләгәннәрдән аңламый калганнарны уен арасында гына Салихтан сорасаң, моның шундый да гади итеп, уен уйнауның дәвамы кебек кенә итеп, төшендереп бирүләре дисеңме...

Салихның армиядән соң ерак төньякка китеп баруы Зиннур өчен тәмам бер табышмак булды. Шул акылы, шул зиһене белән нәрсә эзләп китте икән ул анда? Сабакташының киләчәген бөтенләй бүтәнчәрәк күз алдына китерә иде Зиннур. Үзе балачакта ук әйткәнчә, университетка барып керер, җиңел укыр, укып бетергәч, ихтимал, шунда аспирантурада калыр, зур галим булыр... Сабакташының киләчәге әнә шулайрак күз алдына килә һәм нәкъ шулай булачагына шик тә юк кебек иде. Ә Салих, һич көтмәгәндә-уйламаганда, төн-буран ягына китеп олакты да, анда гади сварщик булып эшләп йөри. Сәер иде бу, аңлашылмый иде.

Үзе дә көтмәгәнчә, сабакташының мондый сәерлеге Зиннурга һич уйламаган бәхет-ләззәт китерде. Мәктәптә укыганда ук, күп малайлар кебек, Зиннурның да күзе Шакир абыйның чибәр кызы Рәйсәгә төшеп йөри иде. Ләкин Рәйсә — һич аңламассың бу кызларны — үзе алдында чәчләре белән җир себерергә әзер нинди егетләр барында, һәммәсен читкә тибәреп, әнә шул йомыкый Салихны артыграк күрә иде. Салихы да, моның кадерен белеп, бик исе китеп торса икән, ичмасам. Юк бит, әллә бар Рәйсә кадәр фәрештәдәй кыз Салих өчен, әллә юк — күрми дә иде бугай ул аны.

Үсә төшкәч, Рәйсәнең дә бик гаҗәп бер сәерлеген төшенеп алды Зиннур. Гадәттә синең белән бер авыз сүз сөйләшүне дә кирәк тапмаган горур Рәйсә, әгәр сүзеңне Салих турында берәр хәбәр янсә мактаудан башласаң, кашкарый гөледәй ачыла да китә иде. Сөйләшеп, сүзләре бетми, әгәр аңгәмә берәр кичә-мазарда барса, синең белән һич ялындырмастан, көлә-елмая биеп тә китә.

Студент чакта әле, яңгырлы бер көзге көндә Зиннурның ниндидер йомыш белән авылга кайтып киләсе булды. Бик уңайсыз вакытлы поездга утырган, станциягә килеп төшкәндә, инде бар автобуслар да китеп беткән

иде. Шунда, тәмам аптырап, яңгырга чыланып басып торган Рәйсәне очратты. Аның да авылга кайтышы, ул да автобуска өлгерә алмый калган икән.

— Хәзер җаен табабыз аның, Рәйсә, бер дә аптырама,— диде Зиннур, көтелмәгән очрашуга бик шатланып.— Син бар, вокзалга кереп утыр, җылын, мин хәзер! — диде һәм пакгауз янына йөгерде. Бәхеткә каршы, пакгауз янында алар сельпосы машинасы товар төйи иде. Шофер башта: «Йөгем бик уңайсыз, кабинам буш түгел», — дип кырт киссә дә, егеткә тагын бер карап куйгач (бу шома егетнең бригадир этисенә нинди генә йомышың төшмәс!), ризалашты:

— Поселок башына, юлга чыга торыгыз,— диде.

Шактый юл үткәч, алар бер җәяүле солдатны узып киттеләр.

— Һай, Салих ич бу! Туктат тизрәк машинаны,— диде Рәйсә; ике куллап Зиннурга ябышты.

— Син, нәрсә? Салихның кайтырына ярты ел вакыт бар әле,— диде Зиннур.— Һәр солдат Салих булып күренә башлаган ахры, сиңа.

Шушы кайтудан соң алар Рәйсә белән еш очраша башладылар. Рәйсәнең сүзе, гадәттәгечә, Салих турында сорашудан («сиңа хаты юкмы, миңа нигәдер күптәннән язмый») башлана иде. Ләкин кыз шуннан соң да тиз генә чыгып китми, күңелле генә бергә-бергә булалар иде. Аерылышканда, Рәйсә тагын сорый:

— Зиннур, сез бит дуслар, Салихка хат язып сорап кара әле, нигә миңа хат язмый икән ул?

«Дуслар» диюе Зиннурны үсендереп җибәрү өчен генә әйтүе иде бугай. Сабакташ ике күршенең бер-берсен өнәп бетермәүләрен Рәйсә сизә иде шикелле.

Шулай да, бер кичне, Рәйсәнең күз алдында Салихка бик җылы хат язды. Рәйсә чыгып китүгә, хатны ертып ташлады ташлавын, ләкин шәп булып китте бу. «Салихтан җавап килмәдеме?» — дип, Рәйсә шуннан соң көн саен диярлек килеп йөри башлады.

Ә бер көнне, Зиннур бүлмәдә ялгызы гына иде, Рәйсә үзен бигрәкләр сәер тотты. Гел елмая-көлә, моңарчы булмаганча шуклана, тыпырдап биеп тә ала һәм — монысы турында Зиннур башына да китерми, хәтта хыялланырга да базмый иде — кыз бүлмәдә куна да калды. Шуннан соң... Шуннан соңгыларын хәтерли башласаң, хәзер дә башлар әйләнеп китә.

— Әйдә, язылышабыз,— диде Рәйсә күпмедер вакыттан соң, ифрат җитди тавыш белән.— Балабыз әтисез үсәргә тиеш түгел.

Зиннурның аяз көнне шартлап яшен яшьнәгәндәй яңгыраган мондый хәбәргә ни дип җавап биргәне — үтер — хәтердә юк инде хәзер. Соңгы вакытларда Рәйсә бар сыйлардан артык күреп, тозлы кыяр кетердәтергә бик ярата башлаган иде; Зиннур, кыз килешкә, базарда бик озаклап сайлый-сайлый, авызыңнан сулар китерердәй Рәйсәнең шул яраткан ризыгын алып куя иде. Аяз көнне яшен яшьнәмәде, пар кыяр салынган тәлинкә идәнгә чәлпәрәмә килеп төште. Шунысы гына бик истә.

Шуннан соң Рәйсә күзгә күренмәс булды. Тагын күпмедер вакыт үткәч, Рәйсәнең Ленинград медицина институтына күчеп китүе хәбәрен ишетте. Анда хирургия буенча махсус төркем җыялар икән диделәр дә диюен... Хәер, ни генә булмасын, бу хәбәр Зиннурның сулышларын иркенәйтеп җибәрде.

Салихның ерак төньяктан кайтып, университетка, геология факультетына барып керүен ишеткәч, Зиннур үзенең күрәзәчелек сәләтенә тагын бер кат ышанды. Әһә, әнә нинди юл сайлаган икән егеткәй. Ерак төньякта сирәк металлар табуда эшләп йөрүе дә һич тикмәгә түгел икән моның. Инде менә, практикасын ныклы белемгә нигезләп, фән юлыннан ышанычлы адымнар белән атлап китәчәк бу.

Юк, кордашы табышмак җан булуын дәвам итте. Университетны бетерүгә, перспективасыз иске бер промыселга гади геолог булып эшкә китте.

Алай фән юлы белән китмәгәч, нигә әле моның зирәк акылын практикада, төгәлрәге — үз янында файдаланмаска? Бик кирәк булып куюы бар бит бу зирәк акыллы сәер егетнең.

Салихны үзе эшләгән Идарәгә күчерү — шома эш йөртергә инде тәмам остарып житкән Зиннурга бер дә алай кыенга килмәде.

Бу юлы Зиннурның көрәшләгәсе бер дә ялгышмады шикелле. Идарә эшендә, бигрәк тә түрә булып алгач, Салихның төпле белеме, нигезле киңәшләре бик тә ярап куйды. Диләфрүз белән Җәмиләнең ахирәт дуслар булып китүенә дә Зиннур куанып туя алмый иде. Тормышта хатыннар сүзенең таулар актара торган әллә нинди тылсымлы көче бар бит! — күпләр мона бәһа биреп житкерә генә белми. Салих кадәр үҗәтне үз куәнда биетә алуында хатыннарның роле аз булмады.

...Менә хәзер Зиннур алдында бигрәк вакытында өлгергән, бик кирәкле папка. Ай, молодец, кордаш! Тырышкан, нәкъ кирәкле чакта өлгерткән. Вышкачылар, заман таләп иткәнчә, рекордлы срокларда буровойлар төзеп куйдылар. Бораулаучылар да алардан калышмый — Девон бабайга тау токымнары тишеп үтүне планда каралганнан күп алда башкарып киләләр. Инде нигә алар Идарәсенә генә калышып торырга? Салих моны бик яхшы аңлый, әлбәттә. Шулай ук заман таләп иткәнчә геологик режим эшләгәндер. Яңа чыганак үңае белән нефть чыгару планы күпкә арта — моны да баш геологка аңлатып торасы юк.

Зиннур Салих эшләгән геологик режим белән танышып чыккач, папканы бик каты шапылдатып япты да, бүлмә буйлап әрле-бирле йөренә башлады. Нәрсә бу? Әллә акылы авыша башлаганмы бу тинтәкнең? Бөтен бер мәйданны моңарчы ишетмәгән-сыналмаган яңача геологик режимда эшләтмәкче була бу. Әллә фәнни-тәҗрибә базасы дип уйлыймы ул производство мәйданын? Мондый юл белән бара башласаң, нефть чыгару планнарының чәлпәрәмә киләчәген көт тә тор. Планнар да чәлпәрәмә киләчәк... үзеңнең дә урыныңнан ничек очып төшкәнеңне сизми дә калырсың.

Бераз тынычланып, урынына кереп утыргач, Зиннур кордашын аңлый башлагандай булды. Ю-ук, акылы, һәрвакыттагыча, бик шәп эшли кордашның. Тикмәгә генә Казан галиме янына барып йөрмәде бит ул. Димәк, зур галим дә проектны хуп күргән, акыллы киңәшләрен дә биргәндер. Әгәр бу яңача геологик режим уңышлы барып чыкса, бик тә матур киләчәк көтә бит кордашны. Зур бүләкләргә лаек булыр, лауреат исеме дә алмагае әле. Аннары сөйләшеп кара син үз кул астыңдагы шул даңлы тинтәк белән...

...Уйлар гаҗәп бер җитезлек белән ерак-еракләрдан айкап йөри башлады. Моннан өч ел элек, Мәскәүгә командировкага баргач, үзенең күптәнге танышы Геннадий Борисович белән ял көнен бергә үткәрделәр. Кайчандыр бирегә, Зиннурлар Идарәсенең начальнигы иде Геннадий, аннары аны Мәскәүгә, министрлыкка эшкә алдылар. Үзенең варисын бик якын күрә иде Геннадий Борисович. Гаҗәп матур кояшлы җылы көн иде. Геннадий Борисовичның үз «Волга»сына утырып, шәһәр яны урманындагы дачасына киттеләр. Зиннур биредә үзен көтмәгәндә гүя җир оҗмахына эләккәндәй тойды. Әкият сараедай бизәп-матурлап эшләнгән дача өе, салкын душы, эссе фин мунчасы, агач күләгәсендәге рәхәт бишектәй тибрәтүче гамаклары. Хәтта җыйнак кына бассейны да бар — рәхәтләнеп чум, йөз.

Шунда Геннадий Борисович, гамакта җай гына тирбәлә-тирбәлә, әйтеп куйды:

— Уйлаганың бардыр инде... Сизми дә калырсың, безгә дә лаеклы ялга чыгар вакыт килеп җитәр. Хәзер менә кулда көч һәм мөмкинлек барында, тыныч картлыгың турында кайгыртмасаң, йөрерсең аннары профсоюз бусагасын таптап. Уйлаганың бардыр инде.

Аннары Геннадий Борисович уйчан гына әйтте:

— Буыннар алмашына тора. Киләчәк буыннар өчен бу мәсьәлә бер дә катлаулы булмас, әлбәттә. Ә безнең буын өчен... Шулайрак. Тарих

бик елмаймады безгә. Уйламыйча булмый бу хакта... Кстати, буыннар алмашы дигәннән, Зиннур Галимович, министрлык Сезнең кебек энергияле, җирле шартларда чыныгу үткән кадрларга бик мохтаҗ.

Уйламады түгел, Зиннурның да уйлаганы бар иде бу турыда.

Ләкин ул үзенең тыныч картлыгын бөтенләй башкача күз алдына китерә иде. Шәһәрдә уңайлы квартира, ә җәйләрен — авыл.

Геннадий Борисовичның сүзләре Зиннурның күңеленә якты нур өстәгәндәй булды. Никадәр мескен, никадәр фәкыйрь итеп күз алдына китергән икән ич ул үзенең киләчәген моңарчы. Уңайлы квартира, имеш. Әнә, хәзерге пенсионерлар кебек, йокыдан торуга, сумкаңны күтәреп, кибетләргә йөгер (хәзерге кебек, телефон шалтыратып кына, бер кило колбаса да суыткычыңа кереп утырмас). Җәйләрен авылда... Бакчада казын, терлек-туар артыннан чап, чалгы селтән. Шунсыз, бер стакан сөткә дә тилмереп утырырсың хәзер авылда.

Геннадий Борисович җай гына сүзен дәвам итте:

— Мөмкинлек һәм көч барында, Кырымда, я Кавказда үз ял базаңны булдыру турында кайгыртырга вакыт безгә. Кстати, моны кайгырту хәзер әле сезгә уңайлырак. Идарә исеменнән, мәсәлән...

Әнә бит, Геннадий Борисович киләчәк турында ничек колачлы итеп уйлый бөлә! Һәрхәлдә, синең кебек, сыермы, кәҗәме койрыгына ябышу түгел инде бу.

Уйларына чумып, тагын күпмедер хәрәкәтсез утыргач, тиз-тиз телефон номерлары җыя башлады. Ярамый болай. Тизлек заманы, ә ул, кул кушырып, хәрәкәтсез утыра. Кичекмәстән чарасына керешергә кирәк. Шәһәр башлыгына, Берләшмәгә, Геннадий Борисовичка да хәбәрне — оеткыны сала тору хәерле.

Телефончының эшлекле ягымлы тавышын ишетүгә, трубканы тын гына кире куйды. Болай да ярамый. Бары тик дорфалык, акылсызлык кына булачак бу хәзергә.

Ул арада Диләфрүз дә торды. Кухня якта нидер чыжлата, Зиннур елмаеп җибәрде. Менә иң дөрес юл кайда! Сыналган ысул — хатыннарның ахирәт дуслыгын эшкә җигәргә! Җайлап кына сүз башларга җеп очын эләктердем дигәндә генә, Диләфрүз, рәхмәт яугыры, бүлмәгә үзе килеп керде. Бик пөхтә-килешле киенгән, йөзендә эшлекле җитдилек.

— Мин киттем әле, Зиннур. Безнең бакчада шәһәр күләмендә семинар үтә бүген. Балада кече яшьтән үк хезмәткә хөрмәт тәрбиясе мәсьәләсендә бакчабызны үрнәк итеп тапканнар. Мин анда колбаса кыздырдым, калганын үзең карарсың. Киттем мин.


Горур гына шак-шок басып чыгып та китте.

Зиннур, хатынына бер сүз әйтә алмый калуыннан үрсәләнеп, кулындагы карандашын ачу белән өстәлгә атып бәрде.

Менә бит заманнар!.. Тизлек җиле хәтта балалар бакчасына кадәр үтеп кергән.

...Кабинетына кереп утыруга, бик кыю-таләпчән ишек шакыдылар. Зиннур «Әйе, әйе» дигәнен сизми дә калды. Ишектән, нык-нык атлап, Салих килеп керде. Зиннур баш геологны беренче күргәндәй, гаҗәпләнүен һич яшермичә, аңа башыннан аягынача күз йөртеп алды. Чыннан да, бик үзгәргән иде бүген Салих. Ишек шакулары ук элеккечә тыйнак-йомшак кына түгел моның, адымнары ук үзенекенә охшамаган; аннан да бигрәк, кыяфәте... Менә күпме көннәр инде Салих арганталчыккан хәлдә йөри, өс-башы да йончылган, сөйләшүләре дә... я җавап бирә иде ул сиңа, я юк — әйтерсең, бу дөнья кешесе түгел.

Бүген, күр, кияү егетемени кордашың! Бәйрәм костюмыннан, чытыр ак күлмәктән, галстук тагулары да ничек пөхтә-килешле... «Димәк, Җәмилә дә белә бүген иренең нинди җаваплы көне икәнен. Салих үзе гомер-гомергә өс-башына игътибарлырак була белмәде». Зиннур үзенә шундый нәтиҗә ясап куйды. Шунда ук Диләфрүзнең горур гына шык-шык атлап чыгып китүләре күз алдыннан үтте. Янәсе, аларның детса-



*А. Тимергалина рәсеме*

ды шәһәр күләмендә үрнәк... Бик исе китә иренең уй-борчуларына. Димәк, ахирәт хатыннарның сыналган тәэсир-ярдәме дә Зиннур файдасына түгел хәзергә.

Зиннур Салихны аягүрә басып, булдыра алганча яктырак елмаеп каршылады.

— Хәерле иртә, кордаш! Уңышлы проектың белән котлыйм.

Кул кысышканнан соң, «нигездә уңышлы» — дип өстәүне дә кирәк тапты.

Салих Зиннур янына җайлап кына килеп утырды.

— Нигездә уңышлы булгач, минем белән килешеп бетмәгән нәрсәләр дә бар? Сүзне шулардан башлыйк инде без. Минем өчен шулары бик кыйммәт.

Зиннур һич ашыкмыйча, алдындагы папка кәгазьләрен актарырга тотынды.

— Беләсезме, кордаш... Проект, әйткәнемчә, нигездә уңышлы. Бик оригиналь. Ләкин...

Зиннур кесәсеннән матур каплы сигарет чыгарып, өстәлгә куйды. Салих, моны күргәч, күп еллар элек, бөтенләй яшь чакларда очрашуны хәтерләп алды. Сигаретка берсе дә үрелмәде.

— Ләкин, кордаш, үзең дә яхшы аңлыйсың, безнең Идарә фәнни-тикшеренү институты түгел бит.

— Түгел. Проект нәкъ менә фәнни-тикшеренү институтының күп еллык тикшеренүләренә нигезләп төзелде.

— Анысы шулайдыр. Ләкин, һәр фәнни ачышны дип әйтик, практикага кертүдә үтә саклык таләп ителә.

Салих, урындыгы астына нидер эләккәндәй, уңайсыз кыбырсып куйды.

— Без инде чирек гасыр буе сак кыланабыз. «Иләгәндә он тузаны тузмый булмый», фәлсәфәсен нормага әверелдереп бетердек.

— Әйе, Россиядә йөз елдан артык туза инде ул он тузаны.

— Һәм моңа чик куярга вакыт! Табигатьне саклау мәсьәләсе, барыбызга яхшы мәгълүм, кешелек дөньясы алдына бөтен кискенлеге белән килеп басты.

— Кордаш! Әйдәле, конкрет сөйләшик. Без гомум фикер йөртү юлы белән киттек.

— Тыңлыйм.

— Хәзергә син тәкъдим иткән режим белән берничә скважинаны гына эшләтеп карыйк. Уңышлы чыкса, безнең бәхеткә.

— Минем проект аерым скважиналарга түгел, бөтен мәйданны тулаем эксплуатацияләүгә исәпләнгән.

— Шулай да... Саклык бервакытта да зыян итми.

— Бу Сезнең соңгы сүзегезме?

Салихның кордашына «сез» дип эндәшүе беренче мәртәбә иде. Зиннур моны күңеленә салып куйды. «Чын-чынлап, ныклап торып үҗәтләнергә моның исәбе. Күрәсең, академик Николай Семеновичка таянуыдыр. Карап карыйк! Галимнәрнең дә властька буйсынмый хәле юк».

— Әйе, дәүләт мәнфәгатьләрен беренче чиратка куеп әйткән сүзем бу.

Салих өстәлдәге папканы җитез генә үрелеп алды да кырт борылып чыгып та китте.

Шапылдап ишек ябылуга, Зиннур телефон трубкасын кулына алды. Салих туп-туры Җәмиләләр бүлмәсенә кереп китте.

— Әнисе! Миңа бик тиз Казанга барып кайтмыйча булмый.

— Һай! Шулай булыр дип күңелләрем сизгән иде аны...— Җәмилә сабыр гына урыныннан торды.— Карале, анда кибетләргә дә сугылырга вакытың булмас микән? Балаларга кроссовкамы, футболкамы, трикомы очрамасмы? Нинди размер булса да ал, берсенә ярамаса, икенчесе кияр. Янында акчаң бармы?

— Син заказларыңны язып бир, энисе. Онытуым бар.

— Хэзер, хэзер. Мин тиз генэ буфетка төшеп меним. Бер тамчы ризыксыз юлга чыгалар димени...

Бүлмэдэш хатыннар берэм-берэм Җэмилэгэ жыйнак кына төргэклэр суздылар.

— Буфет бу вакытта ябыктыр ул. Менэ алыгыз эле.

Җэмилэ төргэклэрне, һэрвакыт үзе белэн йөртэ торган кызгылт сумкага тутырып, иренэ сузды.

— Юлың уң була гына күрсен инде, Салих.

Салих бүлмэдэге телефоннан гаражга шалтыратты. Автовокзалга кадэр генэ булса да машина сорамакчы иде.

— Зиннур Галимович бер машинаны да юлга чыгармаска кушты бүген. Ниндидер делегация килэчэк бугай,— дип җавап бирде кэефсез генэ тавыш.

Тагын биш минуттан кара «Волга»га утырып, Зиннур да юлга кузгалды. Башында һаман бер уй кабатлана иде: «Академиклар акылыннан да көчлерэк нэрсэ бар эле бу дөньяда...»

Ике сэфэрченең чатта кисешэчэк юллары энэ шулай башланды.



## 14

Зиннур, бая больница залыннан шыпырт кына чыгып киткэч, кызу-кызу идарэгэ китте. Кемнэрдер аның белэн исэнлэшеп үтте, кемнэрдер нидер дэште. Зиннур аларга уйсыз гына баш кагып үтте. Үзе берни ишетми, күзенэ берни анык кына чагылмый иде.

Больница бүлмэсеннэн чыгып барышлый, Зиннур үзенэ төбэлгэн күз карашларын тоеп, ирексездэн башын күтэрде. Салихның өч улы, сузылып үсеп киткэн өч үсмер, барысы да маңгай асларыннан гына аңа төбэлгэннэр иде. Зиннур бу карашлар белэн очрашуга, үзендэ кинэт эчке бер тетрэнү сизде. Эллэ нинди яшерен көчлэр сиземлэнэ иде бу карашларда. Тирэн рэнҗү, дошманлык, шөбһэлэнү, ниһаять, чиксез нэфрэт...— барысы да берьюлы чагыла иде кебек.

Юл буе шушы өч пар күз карашы Зиннурны туктаусыз үтэли бораулагандай булды. «Геннадий Борисович эйткэн буыннар алмашының энэ нинди яклары да бар бит эле бу дөньяда...»

Бүлмэсенэ керүгэ, ул партком секретаре белэн профком председателен үз янына чакырды. Тегелэр көттерми генэ кереп тэ җиттелэр.

— Барыгызга да мэгълүмдер, иптэшлэр,— диде ул, алдына гына караган килеш,— безнең Салих Шэяхмэтовичның хэле бик җитди. Бишенче сэгать инде операция бара. Ярый, медикларның фидакарь хезмэтенэ уңышлар телик. Амин. Безгэ шул арада бик мөһим бер мэсьэлэне хэл итэргэ кирэк.

Зиннур, кулындагы карандашына текэлгэн килеш, беразга тынып калды. Күңелендэ тагын үсмерлэрнең маңгай астыннан үзенэ текэлгэн күз карашлары чагылып үтте.

— Хэтерегездэдер, моннан бер ай элек, бишьеллык алдынгыларын хөкүмэт бүлэклэренэ тэкъдим иткэндэ, без иптэш Мэрданов фамилиясен хэзергэ сызып торырга булган идек.— Зиннур, бу сүзлэрне эйткэндэ, башын күтэреп, туп-туры партоешма секретарена карады. «Турыдан-туры нефть чыгаруда эшлэүче алдынгыларыбызны күбрэк тэкъдим итик эле. Монда җитэкчелэр күбрэк шикелле»,— дигэн иде секретарь. Исемлек аның энэ шул тэкъдиме буенча яңадан карап чыгылды. Ул чакта секретарьның мондый фикер эйтүенэ Зиннур эчке бер куаныч кына кичергэн иде. Хэзер секретарьга үпкэле-ачулы текэлде. Секретарь үзенэ төбэлгэн бу караштан һич уңайсызланмый иде бугай, һэрхэлдэ, тыныч-кыю күзлэрен аз гына да читкэ алмады.

— Әйе, әйе. Тиешле оешмалар белән сөйләшүне мин үз өстемә алам,— диде ул, гадәттәгечә тыныч-йомшак тавыш белән.

— Документларны оформить итүне миңа ышаныгыз,— диде профком председателе.

— Рәхмәт, иптәшләр,— диде Зиннур, урыныннан торып.— Мин больницага киттем. Кордашлар, авылдашлар, сабакташлар бит без. Аңлыйсыздыр инде?..

Бүлмәдәгеләр чыгып киткәч, Зиннур акрын гына тәрәзә янына килеп басты. Больницада чакта ук уена килгән карарының шулай тиз хәл ителүенә ул аз гына да күңел канәгатьләнүе кичерми иде. Коридорда кайсыныңдыр (хатын-кыз, әлбәттә) шык-шык атлап узганы ишетелде. Шунда ук Зиннурның күз алдыннан бүген иртән Диләфрүзнең горур-шат кыяфәте чагылып үтте. «Безнең балалар бакчасы хезмәткә хөрмәт тәрбияләүдә шәһәр күләмендә үрнәк»...

Шунда ук моннан шактый еллар элек булып узган бер вакыйга, күңелдә экрандагыдай аермачык төсмерләнеп узды.

Мәрдәновларга ниндидер бәйрәм кичәсенә җыелганнар иде. Салихларның әле олы уллары гына мәктәпкә йөри, калган ике улының яңа телләре ачылып, армас-талмас күңелле тәтелди торган чаклары. Сабыйлар, ишектән Дибаевлар килеп керүгә, үзләренең яраткан «Дияфүз апа»ларын сырып алдылар, сөйләшеп-сайрашып сүзләре бетмәде. Анныры гына, бу очрашудан бик шат-канәгать булып, изрәп койкаларына тәгәрәштеләр.

Мәҗлес күңелле генә дәвам итте.

Бәйрәм кәефләре иң күтәрелеп кенә житкән бер мәлдә һич көтелмәгән хәл булып алды.

Стенада Мәрдәновларның өч улы бергә төшкән фотолары тора иде. Диләфрүз, балалар йокыга талгач, әнә шул фотога озак кына карап торды да кинәт, тыела алмастан, үкси-үкси елап җибәрде. Хуҗалары да, кунаклар да, дәррәү урыннарыннан кубып: «Ни булды? Зинһар, тынычланыгыз, әйтегез, борчуларыгызны уртаклашыйк»,— дия-дия, ханымны әйләндереп алдылар. Диләфрүз үксүен һич тыя алмый, сүз дәшәрлек тә хәлдә түгел иде.

Бераздан соң гына урынына килеп утырды, күз яшьләрен сөртеп тә тормастан, иренең йөзенә ук туп-туры үпкәле — хәтта каһәрле дияргә була — сүзләрен сулкылдау аша өзлексез сибә башлады:

— Син генә... Синең аркаңда гына өзелде сабыйларымның гомерләре карында ук... Синең аркаңда гына... нинди олы бәхеттән мәхрүм мин. У-у, җан кыючы мөртәт! Күз яшьләрем эгоист башыңа таш булып яусын!..

Зиннур ни әйтергә дә гаҗиз калып, уңайсыз-кыек елмаеп утыра бирде.

Кара инде, һич аңламассың бу хатыннарны. Күпме кеше алдында ирен әнә ничек мәсхәрә итте бит. Вакытында үзе ук ире кинәше белән тулысынча килеште кебек! «Әйе, синең дә хезмәт перспективаңа комачау гына булыр. Минем дә институт бетерәсем бар»,— диде. Институтын да бетерде, эшендә дә, әнә, үзе әйтмешли, детсадлары шәһәр күләмендә үрнәк. Зиннурның да эше республикада гына түгел, бөтен министрлыкта мактаулы. Балалар дип ул кадәр... Әнә, кызлары үсеп җитте. Акыллы, чибәр. Югары белем дә алды, музыка мәктәбен дә уңышлы тәмамлады. Чәчәк күк чагын бик үздырмый гына менә диган кияү дә таба белде. Озак көттермәс, оныклар туар. Тагын ни җитми бу хатынга? Боларга өстәп, Мәскәүгә эшкә чакырылу, оҗмахтай дача, көньяк кояшында үзеңнең ял базаң кебек матур ният-планнар да тормышка ашып куйса!.. Иреннең кем икәнлеген белер көннәрең алда әле, җүләр хатын...

Зиннур, җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй, инде бөтен гәүдәсендә җиңеллек сизеп, тагын бер кат ишекле-түрле әйләнеп килде дә, җитез генә бүлмәсеннән чыкты, кызу-кызу больницага таба атлады.

Зиннур больница залына килеп кергәч, операция бүлмәсеннән Рәйсә дә килеп чыкты. Ул инде марля-маскасын, ак халатын салып ташлаган, үзенә бик килешле карасу-зәңгәр күлмәктән генә иде. Йөзендә ару-талчыгу бик сизелми, әллә сиздермәскә тырышамы?.. Ул, ишектән чыгуга, азга гына тукталып, залдагыларга күз йөртеп алды, аннары туп-туры яшь Мәрдәновлар тезелешеп басып торган почмакка житез-житез атлады. Үсмерләрнең өчесен берьюлы кочагына алды.

— Егетләр... әтиегез тиздән тазарачак.

Залдагылар да алар янына жыелды.

— Операция уңышлы үтте, алайса?

— Рәхмәт, Рәйсә Шакировна!

Рәйсә үсмерләр янындагы урындыкка килеп утырды. Тегеләр, һаман аягүрә баскан килеш, кыюсыз гына сорадылар:

— Янына керергә мөмкин булмасмы?

— Озак ятыр микән монда?

Жәмилә Рәйсәнең кулын кушучлап кысып алды.

— Рәхмәтләребезнең иге-чиге юк сиңа, Рәйсә жаным!

Рәйсәнең кинәт бар ару-талулары чыктымы, күзләрен йомды. Ул тәрәзәгә арты белән утыра иде, шуңа берәү дә шәйләмәде — керфекләре дымлы иде аның...

Шулчак ишекне төбенә кадәр ачып жибәреп, бусагадан очып кына диярлек атлап, бүлмәгә Илгиз килеп керде. Аның «теге, бәбәй алып кайта торган жирдән» нинди хәбәр белән әйләнеп килүе йөзенә үк ап-ачык язылган иде.

— Сигезенчесе белән котлый аласыз Ризидә апагызны! Малай! Энисенең кәефләре — менә!

Рәйсә, урыныннан торып, аңа каршы атлады.

— Котлыйм, котлыйм, Илгиз! Яңа бәхетегез түгәрәк булсын!

Ул, акрын гына чигенеп, урынына килеп утырды. Кинәт жиңелчә генә башы әйләнеп китте аның. Күптән көтелгән, әмма һичкайчан өметен өзмәгән бәхете-шатлыгы хәбәр сала иде ахры.

## Илдар Юзеев

# СЕЗ КАБЫЗГАН УТЛАР

ПОЭМА

Хәбәр килде туган авылымнан.—
Үз-үземне ничек тыярга?—
«Ниятлиләр әткәң-әнкәң йортын
Зират йорты итеп куярга...»
...Кайту белән, мин зиратка килдем.
Әткәй-әнкәй яткан кабердә
Чәчәк-гөлләр... Димәк, авылдашлар
Өзелмәгән икән хәзер дә.
Җиңел түгел шул ул ятим калу
Өлкән яшендә дә ир-атка...
Әткәм дә юк хәзер, әнкәм дә юк.
Туган өем, синме чиратта?
Хәлсезләнеп, тирән хәсрәтләнеп,
Башың түбән игән шикелле
Торасың син: «Әлегә исән әле...
Кайттыңмыни?»— дигән шикелле.
Әле генә кебек әткәемнең
Яңа йортны корган чаклары,
Тәрәзәдән — киләчәккә карап,
Хыялланып торган чаклары,
Әнкәемнең, тәрәзәне ачып,
Толымнарын сүткән чаклары,
Мандолина кылларында, ярсып,
«Сүнмәс дәрт»не чирткән чаклары...
Ник соң еллар сизелмичә калды,
Гомерегез үтте дә мени,
Чорыгызның матча-бүрәнәсен
Еллар кулы сүтте дә мени?
...Мине күршем көтеп тора иде,
Ачкыч тотып, капка төбендә:
«Бик вакытлы кайттың. Иртән — өмә!
Уяу булыйк! Саклыйк төнен дә!
Каршы тору өчен дәлил көчле:
Искерүе җиткән чигенә,
Тормыш, имеш, үзгәрүне сорый —
Бозып тора шушы өй генә!..»
Туган йортым, саумы?
Кыймый торам:
Нинди сүзләр табып дәшәргә?

ИЛДАР ЮЗЕЕВ *(1933)— шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән утызга якын китап авторы, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты. Казанда яши.*

Кайттым соңгы юлга озатырга,
Башым иеп бәхилләшергә,
Балалыгым һәм яшьлегем үткән
Җанга якын өйнең йозагын
Ачамын да түргә узамын...

— Саумы, әнкәй,әткәй?—
Беркем дә юк.
Салкын. Караңгы.
Танымыйсың мәллә, туган өем,
Озатырга кайткан балаңны?
Истәлекләр мине җылытырлар,
Суынса да кайнар кочагың.
Төн үткәрим әле, терелтим дә
Әткәемнең сүнгән учагын.
Ахыр сәгатьләре якынлаша:
Шуңадыр ул тын да, боек та...
Соңгы поэмамны язып калыйм
Тәүге җырым туган бу йортта.
Күңелем күпме
Әнкәй җырлый торган
Таныш көйне эзләп ымсынды.
Табалмады...
Ни булды соң әле?
Әллә инде миндә моң сүнде?

Поэмамның көен табу өчен,
Нәрсә җитми?
Сизәм:
күңелне
нидер борчый...
Язма, тын кал, каләм...
Моң, хыялдан биздем түгелме?
Поэмамның керешен дә таптым,
Юллары да тигез-тигезен.
Ничек дәвам итим? Ни югалттым?
Куя алмыйм нигә, нигезен...

Шомлы уйларыма тынгылык бир,
Өйнең йөрәгедәй ян, учак,
Узганнарны, бәлки, яктыртырбыз,
Әткәм төсе булып балкысак.
Һәрбер бүрәнәсе — үзе бер җыр,
Һәрбер рәсеменә табынам,
Өебезнең әткәй тирәсендә
Шаулап торган чагын сагынам.
Ян, учагым, яктырт дивардагы
Әткәй җыйган серле тарихны,
Кайтар миңа, хыял, тик бик азга
Укытучы Муллин Гарифны.

...«Таһир-Зөһрә», «Йосыф-Зөләйха»лар...
Исән калган кайбер битләре,
Дәү әбием көйләп укый иде,—
Ул чагында исем китмәде.
«Дини кулъязмалар саклый»— диеп,
Берәү әләк язган.
Соңыннан,
Хаклык өскә чыккач,
Сөйләп йөргән:
Имеш, Муллин белән дус булган.
Котылалмый һаман гөнаһыннан:
«Ялачы» дип яман дан чыккан.
«Изге эш»кә халык җыйнап йөргән,

«Өмәгә!» дип башлап чаң суккан.
...Комсомолка Җәннәт истәлеге —
Мандолина... калган үлемнән.
Үзе ачлык елны гел нахакка
Тере килеш җиргә күмелгән.
Күмүченең берсе исән әле.

Мандолина — тере шаһиты...
Ул беренче булып калкып чыккан:
«Зиратка өй куяр чак җитте!»
Мандолина...
Әнкәй бу кылларда
Көй уйнарга мине өйрәтте,
Ул чор минем нәни йөрәгемне
Сүнмәс дәрте белән тетрәтте.
Һәр җаннарның күтәрелгән чагы,
Моңның — Яңарышка тиң чоры.
Җырда — Сәйдәш: «Без кабызган утлар»...
Сәхнәләрдә — Кәрим Тинчурин.
Кубыз, курай, скрипка, гөслә...
Яңгыраган бердәм көч булып,
«Сәйдәш маршы», әйдәп, алдан барган,
Халык тавышы белән кушылып.
Заман дошманнары «зав. избач»тан —
Муллиннардан шәфкать көтмәгән...
Чәнечкеле уклар туры тигән...
Тел ярасы, димәк, бетмәгән.

...Тәүге артисткабыз — Галиябану
Кигән калфак... таккан чулпысы...
Егетләрне яуга озатып калган
Җиз кыңгырау... Соңгы юл төсе.
Сугыш чоры. Әткәй — дус һәм туган
Белоруслар, чехлар өендә.
Менә шушы немец гармунында
Сыздырды рус, татар көен дә.
Гомер буйларына бер генә дә
Үзе көйле тормыш күрмәгән.
Әткәй юлы — Наратлының юлы...
Ян, учагым, яктырт, үрлә, ян!
Күпләр хаклык һәм дөреслек эзләп,
Шушы йортка килеп туктады:
«Гариза яз!» «Коткар!» «Ярдәм итче!»—
Өзелмәде халык сукмагы.
Чәйләр эчә-эчә танышалар,
Дуслашалар иде бу йортта
Тарих өчен нидер алып килгән
Башкорт кардәш, чуваш, удмурт та...
«Колый кантон», «Кай-кай, Ивана»ны,
«Әллүки»не җырлап алырлар,
Кайгылары, шатлыклары — бер үк,
Уртак хисләр, уртак шагыйрьләр.
Истә һаман Казан, Уфалардан
«Тукай», «Такташ» алып кайтканы,
«Ике кала икесе дә миңа
Туган йорттай» диеп әйткәне.

Ян, учагым, дөрлә, кабызучы
Хуҗаңнан син ятим калып та...
Соңгы сулышында әйтте әткәй:
«Йортым... калсын...— диде,— халыкка...»
Зәһәр уйдан кемдер сөенгәндер:
Ишеген, дип, мәңге яптылар...
Өй җанланды:

Йортсыз һәм үксезләр,
Яшәп, җан җылысы таптылар.
Өй искерде, тузды, бушап калды,
Тегеләр тик юкка сөенгән:
Күпләр хөрмәт белән баш иделәр
Узган чакта Муллин өennән.
«Зират өстендә бер йорт коралар»...
Имеш, кыла алар изгелек...
Яманлыкка берәү набат сукса,
Калкып чыга алар иң элек.
Берәү, икәү, өчәү... күп тә түгел...
Ә артыннан кемнәр иярә?
«Изге эш кылабыз» дип ышанган
Гамьсез һәм уйсызлар өере.
Әгәр бүген кайтып җитәлмәсәм,
Талар иде әрнү-үкенеч.
Мин үзем дә уйсыз шул өергә
Бер көч булып килэм икән ич!
Без кемнәр соң, дәшми карап торып,
Рухи алтыннарны күмдерсәк,
Әткәйләрнең нигезендә туган
Хыялны һәм моңны сүндерсәк?
Рухи шәҗәрәне барлый-барлый,
Киләчәккә юллар сузганда,
Һәр заманда калкып кына тора
Ясинчылар — данлы узганга.
Корбаннары булып, халкыбызның
Күпме мәрҗәннәре күмелгән,
«Яңа тормыш өчен кирәкми!» дип,
Мәрҗаниләр «себереп түгелгән».
Туган йортым — татар шигърияте
Сигез гасыр буе төзелгән.
Бик еш барам Тукай йортына мин,
Атлый-атлый серле эзеннән.
Халкыбызның туган дәверләрен
Күмсәләр дә тарих юлларында,
Югалмаслык эзебезне раслап,
Калкып чыкты шагыйрь Кол Гали дә!
Тукай торган кырыгынчы бүлмә.
«Болгар номерлары»...
Болгар-йорт...
Тукай хәзинәсе әле тагын
Сигез йөз елларга юллардык!
Пәйгамбәрнең чыны, иң реале,
Шигъри Гайсәбез ул, Нухыбыз,
Күктән җиргә килеп төшкән түгел,
Җирдән күккә менгән рухыбыз!
Төзи-төзи, алга бара-бара,
Заман, сорыйм: җитез адымда —
Әткәм өе сыман бик кадерле
Тукай торган йортка кагылма!
Такташ йортын сүтеп ыргыттылар...
Кала ямьләү иде исәбең,
Нишләдең син, Казан? Шигъри йортның
Җимерделәр сыман кисәген.
Искә төшергәндә ояласың,
Кызарасың...
Казан, әйт әле:
Кайда әткәм зурлап сөйли торган
Мәшһүр «Бакыр бабай» һәйкәле? [1]
Киләчәккә китеп барган чакта,

[1] 30 нчы еллар башында Г. Р. Державинга куелган һәйкәлне җимерәләр.

Замананың «кораб бортыннан
Пушкин, Тукайларны ыргыттылар»
Иске-контр буржуй артыннан,—
Әмма халык рухи остазларын
Саклады Ил-туган йортында.
Кемдер һаман шөбһә белән карый
Дәрдмәнднең уйчан сазына,
Кабат-кабат күммәкчеләр моңны
Капиталның алтын базына.
Рух җәллады икейөзле хаин —
Җәлилләрне сатты палачка,
Әмма горур җаннар бирелмәде
Гильотинага башны салгач та!
Хәмер-хулиганлык сазлыгына
Атмакчылар иде Есенинны,
Беркайда да яшереп, күмеп булмый
Шагыйранә дәртне, ярсу моңны!
Ничек аңлатырга «Алар чоры
Булган-узган» дигән кешеләргә?
Хыялымда кат-кат сиңа киләм:
Сиңа киләм, Ильич, нишләргә?
Туган телне яклап чыксаң, кайчак
«Милләтче!» дип тамга сугалар,
Һәр милләтне бөек, тигез күргән
Интернациональ җанга сугалар.
Башка телләргә дә ачкыч таптым
Бу сүзләрне әйткән телемдә,
Шагыйрьләрен зур дөньяга илткән
Әнкәем һәм әткәм телендә.
Әткәй сыман, кайчак сәяхәтем
Чехка, белоруска туктала,
Бөгелмәдә — Гашек, Печищеда [1]
Каршы ала Янка Купала.
Туган өйгә килеп кергән кебек,
Түргә узам — Ленин йортына.
Барысы шуннан — җанда дөрләп янган
Әткәемнең учак уты да...
Әйтә Ильич: «Тукай рухы саумы?
Шушы биеклектән төшмәгез!»
Ибраһимов аша безгә карап,
Өстәп куя тагын: «Эшләгез!»
Тинчуринсыз, Шамил Усмановсыз,
Туфаннарсыз калган чорларда
Ул яшәгән йортка килгән әткәй:
«Нишләргә?» дип киңәш сорарга.
Ильич рухы нигезендә генә
Хаклык яшәвенә инандык.
Хаклык, югалса да, барыбер кайта,
Аның рухы барда — иман нык!

...Узган гасырларны бүгенгегә
Кушып, якынайтып, учак, ян!
Борынгым да, бүгенгем дә минем
Киләчәгем белән тоташкан.
Көйли-көйли, әнкәй кылларыннан
Таныш көйне эзлим...
Тоямын:
Поэмама тигез ритм белән
Ярсу бер көй ага...
туа моң...
Әткәй кебек,
Кайнар маңгаемны

---

[1] Я. Гашекның Бөгелмәдәге, Я. Купаланың Печищедагы музей-йортлары күз алдында тотыла.

Салкын тәрәзәгә куям да
Уйлар канатында очып китәм
Киләчәккә, ерак хыялга...
Шәҗәрәмнең башы, дәвамы да
Шушы нигез, шушы тамырда.
Киләчәгем куша, таләп итә
Әткәм рухын саклап калырга!
Йорт сүтеләр,
Иске өйгә ябышып,
Яшь агызып ятар чор түгел...
Туган нигезеңне күңелеңнән
Сүтеп атсаң,
жырың — чын түгел!

...Бүген — өмә.
Кемнәр? Нигә килер?
Хәтеремдә бик күп өмәләр...
Шулай укмы әткәемнең рухын
Кара өмә ясап кумәрләр?!
Явызлыкка, уйсыз-гамьсезлеккә
Нәфрәт чәчеп ян син, учагым,
Тәрәзәдән төшкән таң нурына
Учагымның нурын кушамын.
Әткәй өе әле җимерелмәгән...
Рухи бер йорт төзим күңелдә,
Изге учак чаткылары янар
Йолдыз булып аның күгендә!
Күреп торам, тоям: өй терелә,
Тирән сулыш ала, җанлана,
Әткәй йортын сөенеп котлагандай,
Учак сыман дөрләп, таң яна.
Әткәм учагыннан җылы алып,
Җиһан йорты төзим күңелдә,
Изге учак чаткылары янар
Йолдыз булып аның күгендә!
Әмма йортны күтәрүе авыр...
Тын кысыла... туңам... сыгылам...
Таң нурлары салкын... бер ялгызым...
Хәлем бетә... хәзер егылам...
Туган йортым,
Очып кайткан идем
Башым иеп бәхилләшергә...
Гомереңне йөрәгемә ялгап:
«Исән бул!»— дип телим дәшәргә!
Кемнәр уйлый: «Ул учаклар сүнәр,
Заман өчен алар кечкенә...»
Бүгенгедән киләчәккә күчәр:
Сүнә торган түгел һич кенә!—
Мин җылынам, үсәм, күтәреләм,
Таңга-җанга куәт-көч кирә!
Кемнәр уйсыз йоклый? Уяныгыз!
Ачылсыннар йозак-келәләр...
Кулларында лом-балталар ялтырый,
Өйгә якынлашып киләләр!
Җирнең барлык явыз көчләренә
Юнәлтәм мин ярсу рух-утны...
Әнә алар яндырырга килә
Дөнья дигән гүзәл бер йортны!
Аталардан факел алучылар,
Без аларга нәфрәт-ут атыйк,
Җиһан-йортны җимерергә килгән
Өмәчеләр явын туктатыйк!
Рәвеш башка — балта урынына
Атом белән янап киләләр...

Каршы чыгыйк бердәм сафлар булып,
Чигенсеннәр кара өмәләр!
Шундый өмә ясыйк: Ил чистарсын,
Җир сафлансын, дөнья яшәрсен,
Һәркем бер-берсенә хөрмәт белән
«Дус» һәм «Иптәш» диеп дәшәлсен!
Туктаталмас мине бернинди көч
Әткәм уты исән булганда!
...Балталарга каршы кемнәр анда
Кулга-кул тотышкан урамда?
Әткәй шәкертләре!..
Рухташларым,
Илдәшләрем минем, Җирдәшләр!
Алар безнең аша үтәлмәсләр,
Мондый көчкә каршы килмәсләр!
Димәк, күпләр,
Әткәй йортын уйлап,
Төне буе керфек какмаган...
Уйда — минем белән җиһан буйлап,
Утны сүндермичә саклаган!
Илне яңартырга, үзгәртергә
Чыккан зур өмәдә — көрәштә
Артка чигенү — юк!
Картаю — юк!
Үзган, Бүгенге дә — бер яшьтә!

...Тәрәзәдән киләчәккә карыйм,
Хыялыма кушып таң нурын.
Ян син, ян син, әткәм рухы булып,
Туган йортта туган җан җырым!
Янар ул ут көнен, төннәрен дә;
Газапланма, күңелем, боекма:
Поэмамның нигезләре — ныклы,—
Соңгы җырым түгел бу Йортта!..

1986

## Шәмсия Җиһангирова

# МӘХӘББӘТ БИЗМӘНЕ

**хикәя**



Быелгы җәйнең узуын сизми дә калдым. Гел шулай инде мин: кыш буе җәй көтәм. Көнен генә түгел, сәгатен минутлап санардай булам. Баксаң, әйләнеп карарга да өлгермисең, җәй инде үтеп тә киткән. Менә быел да яңа гына яз иде, бүген исә — август. Йөрәгемнең әллә кай жиреннән сизелми узган көннәр өчен ачы үкенү хисе сызылып үтте. Шушы зур хатамны бер көндә төзәтергә жыенгандай, тәвәккәл генә Горький паркы ягына атладым. Бүген иртән үк юк кына сәбәп аркасында ирем белән кычкырышып китүебезне исемә төшермәскә тырышып, эчтән генә бер күңелле җыр көйли-көйли, зират янынннан туры Казанка буена алып төшүче юлга борылдым. Бинһая матур, гүзәл яшәештән соң безне бөтенләй башка, дөм карангы дөнья көтеп торганын исемә төшермәс өчен, гадәттә, парк үзәгендәге әйләнеч юлдан йөри идем, бүген исә, үзем дә ник икәнен сизмәстән, зират буеннан барырга булдым. Һәм гүя миңа таныш булмаган дөньяга килеп кердем. Килеп керүем булды, ирекә омтылган кош кебек, күкрәк читлегемә бәрә-бәрә, йөрәгем талпынырга тотынды. «Яшәргә, яшәп калырга ашык, бу якты дөньяда һәр минутыңның кадерен бел»,— дип кисәтә иде ул мине гүя. Рәт-рәт тезелеп киткән калку каберләргә карап уйлана-уйлана, юлымны дәвам иттем. Бигрәк кызык инде бу кеше дигәнең: һаман каядыр ашкына, һаман аңа нидер житми. Туктат та әйт әле син аңа беркөнне: «Туганкаем, фәлән көннең фәлән сәгатендә якты дөньяны ташлап китәчәксең»,— диген. Кулыннан бөтен эше төшәчәк, ул кинәт туктап уйга калачак. Җирдә яшәү дигән олы бәхетнең һәр минутын, минутын гына түгел, һәр секундын тоеп, кадерен белеп калырга тырышачак. Кадерен белми шул адәм баласы яшәү дигән бәһасез нәрсәнең. Гомере чикләнмәгән, күпме яшәсә дә, бетмәячәк дип инана.

Кинәт кенә башыма килеп кергән бу уйларны куарга тырышып, зәңгәр күк йөзенә күтәрелеп карадым. Күк йөзе гаҗәеп чиста, саф. Тик иксез-чиксез зәңгәрлекнең бер почмагында чәч бөдрәләре кебек өрфия болытлар дулкынланып тора. Кояш та гадәттәгедән нурлырак, жылырак булып китте. Баягы хәсрәтләрем онытылды, кәефем, алда ниндидер зур шатлык көтеп торгандагы шикелле, күтәренке, иләс.

Ләкин... Агачлар арасыннан боргалана-боргалана Казанкага алып төшүче асфальт бетеп, елга буена килеп чыккач, үземнен иртәрәк шат-

ланганымны бик тиз аңладым. Я, хода! Каян жыелып беткән бу халык. Яр буенда да, хәтта су эчендә дә алма төшәр урын юк.

Шулай күпме басып торган булыр идем, кинәт халык төркеме аша мине үзе янына әйдәп кул болгаучы бер ханымны күреп алдым. Шатлана-кабалана атлый башлаган җиремнән кинәт шып туктадым. Ханым миңа таныш түгел иде. Бер күргән кешенең йөз чалымнарын оныта торган гадәтем юк минем. Ханым, икеләнеп калуымны күргәч, тагы да үҗәтләнебрәк кул изәргә керешә. Янына килеп җитәр-җитмәс кыюсыз гына:

— Исәнмесез, хәерле көн,— дидем.

Ханым, мине уңайсыз хәлдән чыгару өчен мәсьәләне тизрәк төшендереп бирергә теләгәндәй, кызу-кызу сөйләп китте:

— Аптырап басып торганыгызны күрдем дә... Иртәрәк килү хәерлерәк шул монда, бигрәк тә бүген — ял көнендә...— Аннары, нигә сүз озайтып торам соң әле бу турыда, сез бит моны үзегез дә яхшы белергә тиеш дигәндәй, җиңел генә кул селтәде дә сүзен башкачарак дәвам итте: — Әйдәгез, әйдә, тартынмагыз, менә монда утырыгыз, барыбызга да урын җитәр. Минекеләрнең килгәннән бирле судан чыкканнары юк. Алар чыкса, без керербез. Җәймәгез булмаса, менә монда безнекенә ятып кызынырсыз. Әйдәгез, танышыйк: Шәрига. Ямьсез исем, әйеме? Мин аны Казанга килгәч алыштырырга да теләгән идем, әни риза булмады.

Мин дә исемемне әйттем. Үзем Шәриганең йөзенә текәлдем. Гашыйк күзләр белән. Әйе-әйе бу бәлки бик көлке дә тоела торгандыр, ләкин нишлим, мин аңа бер күрүдә гашыйк булдым! Искиткеч камил иде аның йөз төзелеше. Сүз белән әйтеп аңлата алмаслык әллә нинди эчке нур белән балкый иде күзләре. Һәр сүзендә, үзенә килешеп тора торган һәр хәрәкәтендә тормышыннан чиксез канәгатьлек чалымнары. Язмыш рәхимсез давылларын беркайчан да тидермәгәндер бу ханымга, ул да, минем кебек, бер күрүдә үз иткәндер Шәригане, аңа бирәсе сагыш-моңнарны башка берәүгә өстәгәндер. Шуңа күрә дә кирәгеннән артык эчкерсез, мөлаемдер бу ханым, башкаларның күңелен сагыш-моң тарайткан, күз нурларын рәхимсез язмыш җиле ундырган булу мөмкинлеге аның башына килеп тә карамыйдыр. Бар иде минем дә Шәрига кебек бөтен эч серемне кешеләр белән бүлешә, һәр шатлыгымны уртаклаша торган көннәрем. Ләкин ул чакта мин яшь, артык яшь идем. Кеше күңеленең еллар узган саен һаман тараеп, үз эченә йомыла баруын, тирә-юнендәгеләрнең шатлыгына көенә, кайгыларына сөенә алу мөмкинлекләрен белми торган яшьтә идем. Хәзер исә үземне әзме-күпме тормыш тәҗрибәсе туплаган кешегә санарга, эчемдәге серләремне чит кешеләрдән, хәтта иремнән дә яшерергә өйрәнгән идем. Шәригане тормыш андый тәҗрибәләргә өйрәтмәгән иде, күрәсең. Минем белән, моңарчы бөтенләй таныш булмаган бер кеше белән, әнә ничек эчкерсез сөйләшә ала бит ул.

— Абау,— дидем мин, сүзсез генә аңа текәлеп торганнан соң, соклануымны яшерә алмыйча.— Бигрәк матур икән сез. Күз тиярлек. Гашыйк булып йөрүчеләр дә күптер үзегезгә?

Шәрига ягымлы гына көлеп куйды:

— Белмим, бәлки эчтән генә янып-көеп йөрүчеләр бардыр, ләкин берсенең дә үземә килеп әйткәне юк. Кемнедер үзенә гашыйк иттерәсе, кемнендер үзеңә кызыгып йөргәнен сизеп, битараф кына елмаеп йөрисе килә бит хатын-кызның. Миндә дә бар андый теләк. Ләкин Рифкатьтән башка беркемнең дә миңа гашыйк булганын, өзелеп яратканын белмим. Ә менә үземнең үлеп гашыйк булганым бар иде. Бар иде дип үткән заман белән сөйләү дөрес тә түгелдер. Мин аны хәзер дә яратам. Ләкин...

Шушы җирдә сүзебез өзелде. Тәннәре бронза кебек матур булып кояшта каралган, берсе икенчесеннән әз генә калкурак ике малай, алар артыннан ук саргылт чәчле бер ир кеше куыша-куыша безнең янга килеп бастылар. Мине күргәч, өчесе беравыздан:

— Исәнмесез,— дип дәштеләр.

Шәрига безне таныштырырга ашыкты:

— Бу — Гөлия. Ирем Рифкать, улларыбыз Алмаз, Айваз.

Ир-егетләр квас кына эчтеләр дә тагын су буена йөгерделәр.

— Рифкать минем тормыш иптәшем, гомер юлдашым. Ике баламның газиз әтисе,— диде Шәрига бераздан.— Мин аны бик-бик хөрмәт итәм. Ул минем башка кешене яратуымны белә иде. Иң авыр вакытта яныма килде дә ялгыш адым ясаудан коткарып калды. Ә хәзер дә яратам дигәнем... Ул бөтенләй башка семья кешесе. Үз юлы, үз мәшәкате. Әй! Сез минем бу өзек-өзек сүзләрдән бернәрсә дә төшенә алмассыз. Баштан ук, аның белән ничек һәм кайчан танышканнан ук сөйлим инде алайса.

Авыл мәктәбендә унны бетереп, университетка укырга кердем. Беренче курсны бетергәндә безне Татарстанның илле еллыгын каршылауга әзерли башладылар. Моның өчен төрле вузлардан әллә никадәр кешене бергә җыеп, Горький паркының Сабан туе була торган аланында төрлетөрле күнегүләр өйрәтә башладылар. Бер сафка кызлар, икенчесенә егетләрне аралаштырып бастыралар. Мин, гөнаһ шомлыгына каршы, әллә нинди бер бәндә белән туры килдем. Бу егеткә шулкадәр ачуым килә, әгәр булдыра алсам, ике дә уйламый кыйнап ташлар идем үзен. Бөтен кеше тырышып-тырышып күнегүләр ясаганда, бу, бер генә дә исе китмәгәндәй, рәхәтләнеп тәмәке тарта. Кайбер көннәрне килми кала бу. Андый чакта мин, кош тоткандай, сөенәм. Иптәшләрем исә, миннән көлеп:

— Шәрига, егетеңә ни булды икән, кызыксынмадыңмы? — диләр.

— Куегыз әле, кызлар, яңадан гомергә күрмәсәм дә үкенмәс идем.

Ләкин бу башта гына шулай булды. Соңыннан, ул килми калган көннәрдә, мин никтер боегып калам, хәтта күңелемне аның ник килми калганын белә алмавым өчен борчылу да тырный иде.

Бераз күнегүләр ясаганнан соң, безгә унбиш-егерме минут ял бирәләр, андый чакта я шундагы чирәмгә утырып ял итәбез, я су коенырга йөгерә идек.

Беркөнне исә, теге тәмәкече егет:

— Матур кызлар, янытызга утырырга рөхсәтме? — диде.

— Рәхим итегез.

Дус кызларым аның белән бик тиз гәпкә дә керештеләр. Инде шактый вакыт юк-бар сүз сөйләшеп утырганнан соң:

— Матур кызларның исемен белү ярап куяр иде,— дигән булды бу.

— Мин — Һәнүзә.

— Мин — Рәбига.

— Ә минем исемем юк,— дидем мин киреләнеп.

— Ай-һай, шундый кызны таба белсеннәр, исем генә тапмаганнар, имеш!

— Ә үзегезнеке ничек?

— Әхсән.

Сабакташ кызларым Әхсәннең һаман минем белән генә сөйләшүенә эчләре пошып:

— Кыланган булма инде, әйт,— диделәр.

— Ә син, әгәр тартынсаң, җиргә язып күрсәт,— дип Әхсән миңа ширпы сузды. Үзе һәр хәрефемне укый барды: — Ш-ә-р-и-г-а. Шәрига. Бер дә ямьсез түгел, миңа ошый...

Шунда мин аңа күтәрелеп карадым. Матур иде Әхсән. Яшькелт күз, җыйнак кына борын. Тыңлаучан коңгырт чәчен бер якка матур гына яткырып тараган. Гел елмаерга торучы уртача гына калынлыктагы иреннәр. Урта бер җиреннән чокыраеп торучы ияк. Моның йөз төзелешен бозып ташламагаем дип, кечерәеп кенә үз урынына килеп урнашкан колаклар... Ул без яши торган тулай торакта, өченче катта гына яши икән. Гаҗәп, ел буена аны бер дә күрмәгәнмен. Бәлки, күрсәм дә, игътибар итмәгәнмендер? Хәер, алар беренче сменада укыган, ә без — икенчедә.

Танцы дисәң, кызыл почмакка бер мәртәбә дә төшкәнем булмады. Тәләгем дә, танцыга йөрерлек юньле киемем дә юк иде.

Шул көннән соң мин Әхсәнгә чын-чынлап ияләштем. Иртән ул мине тулай торак ишеге төбендә көтеп тора, һәм без бергәләп әлеге күнегүләрне өйрәнергә юл тотабыз. Икәүдән-икәү генә дисәм, дөрес булмас, чөнки миннән бер адым да калмыйча тагылып йөрүче дус кызларым Һәнүзә белән Рәбига дә безгә пара. Әхсән, шул ныклап танышкан көннән соң, элекке кебек юкка чыкмый башлады. Күнегүләр арасында без чирәмдә утырсак, ул да утыра, без су коенырга йөгерсәк, ул да артыбыздан калмый. Мин, бик эсселәсәм дә, аның янында ярым шәрә килеш су коенып йөрергә оялганлыктан, сер бирмим, никтер коенасым килми лә дигән булып, комлыкта гына утырып торам. Әхсән дә кызу-кызу чишенә башлаган җиреннән туктап:

— Онытып җибәрә язганмын, йөзгечем өйдә калган икән бит! — дип шып туктый.

Ул гомумән күп сөйләргә, кычкырып көләргә яратмый иде бугай. Шул ук вакытта аны шаяруны сөйми торган кеше дип тә булмый. Шулкадәр ышандырырлык итеп сөйли, үзең дә көләргәме, гаҗәпләнергәме икәнен белмичә, аптырап каласың. Мәсәлән, Әхсәннең кулында тырналган урын күреп: «Ни булды?» — дип сорыйсың. Андый нәрсәләрне Рәбига бик тиз күреп ала һәм сорауларны да ул бирергә ярата иде. Ә Әхсән тыныч кына: «Үгез сөзде»,— ди. Яки аяк очындагы чокырның кайдан килгәнен аңлатып: «Кечкенә чакта машина тәгәрмәче үткән аннан»,— ди. Хәер, ул миңа ничек сөйләшсә дә, ни кыланса да, барыбер, ә менә Рәбига белән Һәнүзә аны ничек тә күбрәк сөйләштерергә, үзләренә игътибар иттерергә тырышалар. Беркөнне тулай торакка кайтып барганда, Рәбига ни өчендер Әхсән белән бәхәсләшеп китте. Түбәннән поездлар үтеп йөри торган чокырга якынлашып килгәндә, Рәбига кинәт кенә:

— Әхсән, син мине чокыр ярыннан үлсәң дә күтәреп менә алмыйсың,— дип куйды.

Рәбига тәнгә таза, авыр гәүдәле кыз. Чокыр да шактый тирән. Бәхәсчынга китсә, әлбәттә, Әхсән Рәбиганы күтәреп менә алмаячак иде.

Ләкин Әхсән дә аптырап калмады, Рәбигага карап, кинаяле генә елмайды да бәхәсне бөтенләй башка юнәлешкә борып җибәрде:

— Дөрес әйтәсең, ә менә Шәригане чокырдан алып менү генә түгел, тулай торакка кадәр күтәреп бара алам! — диде дә, мин «юк!» дияргә өлгергәнче, ялт кына күтәреп алып, түбән төшеп тә китте. Мин, «җибәр, җибәр!» дип чәбәләнә барсам да, тулай торакка җиткәнче, кулыннан төшермәде...

Татарстанның илле еллыгына Үзәк стадионда бик зур бәйрәм булды. Безнең дә җәй буена тырышып әзерләнеп йөрүебез бушка китмәде, уңышлы гына чыгыш ясадык. Аннары инде, бер-ике көн киноларга барыштырып ял иткәннән соң, кайсыбыз кая җәйге ялга таралдык. Сүз арасында Әхсәннең каядыр Ерак Көнчыгышка төзүчеләр отряды белән китәргә җыенуын ишеткән идем. Мин аны стадионда чыгыш ясаган көннән соң бүтән күрмәдем. Хат язышу турында да сүз булмады. Адресымны да бирмәдем. Ни өчен дисәң, ул чакта үземнең аңа мөнәсәбәтемнең чынлыгын, зурлыгын бизмәнләмәгән идем. Алай гына да түгел, аның үземә ошыймы-юкмы икәнен дә белми идем. Ошамый да иде бугай ул миңа...

Ә авылга кайтып, балачак сукмакларыма кабат аяк баскач, мин аның бу дөньяда барлыгын бөтенләй оныттым. Болын җиләкләре тәменә, печән исләренә исереп күпме гомер үткәндер, беркөнне миңа таныш түгел кул белән язылган юка гына хат алдым. Әхсәннән! Аптырадым да калдым: менә сиңа кирәк булса, адресны да, фамилияне дә тапкан бит!

Хат кыска, ләкин оста гына язылган иде. Бер артык сүзе дә юк. Тик хатның «Әхсәнең» дип тәмамлануы гаҗәпләндерде дә, ачуымны да китер-

де. Вәгъдәләшкән кешемени, «Әхсәнең» имеш! Бирим әле кирәгенне бу мәгънәсез сүз өчен! Тик адресны укып карагач, бөтен ачуым дәррәү юкка чыкты. Камчаткадагы Петропавловск дигән. Унбишенче почта бүлеге. «Сорап алганчы» дигән сүзне дә онытмаган. Фамилиясе генә юк. Бераз аптырап тордым да, бер дә исем китмичә, хатны китаплар арасына кыстырып куйдым. Фамилиясе булмаса соң! Җавап язарга торган кеше дә юк әле монда! Тик ни өчендер үземнең шушы кирелегем өчен оялу да тырный иде эчемне. «Алай ярамый, кеше сиңа кызу эш арасында да язарга вакыт тапкан икән, аңа, һичшиксез, җавап язарга тиешсең. Җавап көтәчәк бит инде ул». Хатны бер алдым, бер куйдым. Ниһаять, бу чарасыз хәлдән чыгу юлын таптым: Петропавловскиның унбишенче почта бүлегенә ике хат яздым. Берсен — Әхсәнгә, икенчесен почта хезмәткәрләренә адресладым. Элемтәчеләргә язган хатымда «Әхсәнгә» диелгән хатны озын буйлы, коңгырт чәчле, ияк очы чокыраеп торган чибәр егеткә тапшыруларын үтендем. «Сез аны күзләреннән танырсыз, мөлә-мөлә чайпалып түгелергә торган диңгез кебек булыр аның күзләре. Моңлы булыр», дип өстәдем.

Көлгәндерме алар минем ул хаттан, юктырмы, күрә алгандырмы күзләрендәге әйтеп кенә аңлата алмаслык моңлылыкны, белмим — тик бераздан Царева Татьяна Ивановнадан хат алдым. Хатымның тиешле адресатка, ягъни, Рәхимов Әхсән Солтановичка тапшырылуы турында хәбәр иткән, безгә бәхет теләгән иде. Шушы хәлдән соң без берничә еллар Татьяна Ивановна белән язышып тордык. Ул, бертуган сеңлесе язмышын кайгырткан кебек, безнең хәлләр белән даими кызыксынып торды. Бәйрәм открыткаларын гел Әхсән белән икебез исеменә сала, уртак бәхет тели. Мин моңа әйтеп бетергесез шатлана идем...

Сузебез өзелде. Шәриганең ире белән балалары, су салкынлыгыннан рәхәт пошкыра-пошкыра, җәймәгә килеп яттылар.

— Комачауладык, ахры,— диде Рифкать, кинәт кенә сүзсез калуыбызны күреп.

— Сездән яшерен нәрсә сөйләшми идек лә,— диде Шәрига, әүвәлгечә матур елмаеп,— яңа дустыма Әхсән турында гына.

Шәрига бу сүзләрен берниндн тартыну-куркуларсыз шундый җиңел генә әйтеп куйды ки, мин кинәт сискәнеп киттем. Мөлә-мөлә берәр күңелсез хәл булырга тиеш дип куркынып, Рифкатькә күтәрелеп карадым. Ләкин аның йөзендә берниндн ачулану билгесе дә күрмәдем. Шәрига белән су коенырга йөгердек. Су эчендә баягы хәлгә артык гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча:

— Ай-һай, Шәрига, ирегез гаҗәеп тә тыныч кеше икән! Белмәгән кешенә теләсә нәрсә сөйлисең дип, ник битәрләсен. Әхсән турында сөйләшәсезмени аның белән? Беләмени ул аның турында?

— Белә дию генә аз. Ул бит Әхсән белән бер бүлмәдә яшәгән кеше. Заманында көн саен диярлек безне карточкага төшереп йөрүче дә ул. Әхсән белән мәхәббәтебезгә кер тидермәскә, сакларга тырышып нилләр генә эшләмәде ул. Бүлмәбезгә тере чәчәкләр кертеп куючыны Әхсән дип уйлап, шулай мине шатландырасы килә икән инде, дип, дәшми генә сөенеп йөри идем. Ләкин беркөнне бу сер чишелде. Грипп белән авырып өйдә ятып калган идем, йокымсырап киткәнмен. Әкрен генә ишек шыгырдап ачылганга күзләремне ачсам, кулына кызыл розалар тотып, Рифкать кереп килә. Ишек буендагы тумбочкага чәчәкләрне урелеп куймакчы гына иде, күзләремнең ачыклыгын күреп, аптырашка төште. Тик үзен бик тиз кулга алды.

— Менә, Әхсән сиңа чәчәкләр кертергә кушкан иде.

— Ә-ә, шулаймыни, рәхмәт инде. Үзе кертә алмый идемени?

— Лекциягә ашыкты.

— Ә син ашыкмыйсыңмыни?

— Мин ни-и, мин өлгерәм әле...

— Башка чакта да чәчәкләрне Әхсән кушуы буенча син кертә иденме?

— Ю-у-к. Минем әле беренче генә...

Кичен хәл белергә кергән Әхсәнгә чәчәкләр өчен рәхмәт әйтә башлаган идем, аптырап китте. Бернинди дә чәчәкләр кертергә кушмаган булып чыкты ул.

Менә шундый иде Рифкать. Ә бит розалар — иң яраткан чәчәкләрем. Шулай икән, уйлап карагыз инде: яшерергә хакым бармы Рифкатьтән серләремне?!

Ят кешегә, Әхсән дигән кешене һаман яратам бит әле, дип әйтеп кенә кара, иртәгә үк бөтен дөньяга, үз ире бар өстенә, чит ирләр белән чуала, дигән гайбәт таралачак.

— Ә миңа?

— Сез бөтенләй башка. Мин сезне нишләптер бер күрүдә ошаттым. Кайвакыт берәүне ник бер күрүдә үк якын итүеңне, икенче берәүне күралмавыңны үзең дә аңламыйсың бит. Теләсә кемне бик тиз генә якын итә, теләсә кем белән сер бүлешә торган гадәтем юк минем. Ә менә сезнең кызыныр урын табалмый нәүмиз басып торуыгызны үк яраттым. Үзем дә белмим, ни өчендер нәкъ менә сезгә сөйлисем килде барысын да... Житмәсә әле җанымны кая куярга белми йөргән чагым. Мин бит әле өченче көн генә а н ы кабат күрдем. Унике елдан соң!

Шәрига бер минут кына тынып торды. Мин аның очкын күзләре яшь пәрдәсе белән өртелгәнен күреп алдым. Бер сүз дә дәшмәдем. Бераздан ул үзен кулга алды.

— Менә шулай инде мин,— диде ул, бу вакытсыз күз яшьләре өчен акланырга теләгәндәй,— Әхсән турында тыныч кына сөйли дә, уйлый да алмыйм. Болай елак кеше түгел бугай да үзем...

Аннары, бөтенләй диярлек тынычланып, сүзен дәвам итте:

— Укуны бетергәч, Казанда калдым. Аның да Казанда икәнен белә идем. Ул бит миннән бер ел алда укып бетерде. Ләкин бер мәртәбә дә очратканым, күз кырые белән генә булса да күреп калганым булмады. Яшермим, бик күрәсем килә иде. Мин, гомумән, аның алдында үземне бик зур бурычлы саныйм. Чөнки аның аркасында гына ярату хисенең тирәнлеген, сафлыгын, илаһилыгын белдем. Ул булмаса, бәлки, бу хистән бөтенләй мәхрүм калыр идем. Уйлап карагыз әле, бәхет түгелмени ул ярата алу? Чиксез зур бәхет! Шушы изге хиснең ни икәнен танытканы өчен гел күрәсем килеп тора иде аны. Ничекләр генә итеп күз алдына китерми идем мин аның белән очрашуны, аңа нинди сүзләр әйтеремне! Ә менә өченче көн көтмәгәндә юлымда очрады...

Ул көнне нигәдер йөрәгем сикергәләп, бер сәбәпсез гел елыйсым гына килеп торды. Яңгыр да яварга җыена иде, эштән соң тизрәк өйгә кайтып житим дип, тиз-тиз урамга чыктым. Нидер уйланып барган җиремнән, машина кычкырткanga сискәнеп, ялт борылып карадым. Артымнан әкрен тизлектә ниндидер кара «Волга» килә иде. «Машина йөри торган җирдән бармыйм лабаса, ник кычкырта икән бу бәндә?» дип уйлап алдым да атлавымда булдым. Машина тагы кычкыртты, руль артындагы кеше, сузылып ишеген ачты да: «Утырасыңмы?» — диде. Бу гадәттән тыш әрсез бәндәгә усал сүз тондырыйм әле дип ачылган авызым артык гаҗәпләнүдән ябылмый да калды бугай. Бу — Әхсән иде!

«Утырасыңмы?» — дип кабатлады ул әүвәлге соравын. Мин, җавапмазар биреп тормыйча, машина эченә чумдым һәм ничә еллар күрергә зар булган йөзгә текәлдем. Артык үзгәрмәгән. Бик текәлеп карасаң гына, бераз олыгаю, сабырлану чалымнарын сиземләргә була. Ә менә күзләре, мин үлеп яраткан моңсу күзләре, тагы да моңлана төшкән, саксыз кагылсаң, менә-менә чайпалып түгелергә тора... Алар түгелгәнче мин түгелим әле, дигәндәй, коеп яңгыр яварга тотынды. Чиләкләп кенә түгел, мичкәләп койды бит ул көнне. Хәтта машиналар туктап торды. Без дә машина эчендә утырдык. Чытырдап сызылып киткән яшеннән соң көчле күкрәү

тавышыннан сискәнеп, үзем дә сизмәстән, Әхсәнгә сыендым. Ләкин бик тиз аңыма килеп, ярамаган эш эшләгән кеше шикелле, гафу үтенергә тотындым.

— Без шулай ук бер-беребезгә ят булдыкмыни? Барысы да үткәннәрдә калдымыни?

— Белмим, Әхсән, белмим. Андый авыр сорауларга җавап бирә алмыйм мин,— дигән булдым, шаяртырга тырышып.

— Син бер дә үзгәрмәгәнсең бит, Шәрига. Һаман шулай шат, чибәр. Язмыш җилләре сындырмаган сине. Рифкать синең белән бик бәхетледер.

— Бәлки мин аның белән бәхетледер...

— Яратмыйча да бәхетле булырга мөмкинмени? Син бит аны түгел, мине ярата идең!

— Яратудан өстенрәк нәрсәләр дә бар шул дөньяда, Әхсән! К е ш е л е к л е л е к дип атала ул. Минем бөтәнне яратуым үземне яратучыга газап китерергә тиешмени? Аның минем алда ни гаебе бар?

— Рифкать яхшы егет. Ихтирамга лаек кеше. Бик ярата иде бит ул сине, Шәрига. Миңа сиздермәскә тырыша иде үзе. Сизелмимени инде ул. Төн йокламый карточкаларны ясый. Иртән күзне ачып җибәрәсең, бүлмә синең белән тулган була. Дөрес, карточкаларны ул миңа дип ясый иде. Көнләшә идем аннан. Ул мин күрә белмәгән әллә нинди сыйфатларыңны күрә иде. Соклана белә иде. Гади генә нәрсәдән бөеклек таба белә. Гадилеккә табына белә иде... Ә мин...

— Нәрсә син? Алай авыр сулама әле, Әхсән? Сөйлә әле үзең турында. Ничек яшисең? Кайчан өйләндең? Бәхетлесеңме?

— Бәхетле мин дияр өчен, бәхетне аңлый белергә кирәктер ул. Мин нәрсә! Ашар өчен яшим, яшәр өчен ашыйм. Таң ата да кич була. Җырдагыча...

Ул ара яңгыр туктады. Ялтырап кояш чыкты. Мин моны табигатьнең безнең күңелләр шикелле чишелеп, бушанып алуына юрадым. Аерылганда Әхсәнне үземчә тынычландырдым:

— Үткәннәр өчен үзеңне газаплама, Әхсән. Кеше бүгенгесе белән бәхетле була белергә, киләчәккә ышанырга тиеш. Уйлама үткәннәр турында! — дидем.

Ә үзем газап утында дөрли-дөрли атладым. Менә хәзер ул миңа әйдә дисә, барын ташлап җир читенә китәргә әзер идем. Адымнарым аннан ерагайган саен, күңелкәем өзелә барды, өзелә барды...

Шәрига йөзен куллары белән каплап, читкә борылды.

Без тагы кызынырга яттык. Ир-егетләр коенырга йөгерде.

Мин әле һаман баягы халәтемнән айный алмыйча:

— Нигә соң бергә була алмадыгыз сез? Нәрсә комачаулады? — дидем.

Шәрига кайдан башласам аңлашылыр икән дигәндәй, бер генә секунд уйланып торды да сүзен дәвам итте:

— Теге җәйдә аны гына уйлап яшәдем дисәм, алдау булыр иде. Уйламадым. Яратып китәргә дә җыенмый идем шикелле. Хат языштык. Бары шул гына. Җәй үтеп, икенче курста укулар башлангач та, кайтты микән Камчаткасыннан, дип уйламаганмын. Гадәттәгечә, иртәгәге көн өчен дәресләр хәзерләп, соң гына йокларга яткан идек. Ныклап оерга да өлгермәдем, кемдер итагатьле генә ишек шакыды. Йокы аралаш: «Кем ул?» — дип сорап та тормастан, ишекне ачып җибәрдем. Әхсән! Буй-буй диңгезчеләр киеменнән. Кояшта янып каралган тәнендә әлеге кием шундый килешеп тора! Ул мине шундый бер җылылык белән кочып алды, әллә нишләп киттем. Әйтерсең, аннан миңа ярату күчте. Менә шул минуттан бик нык ярата башладым...

Аңа кызыгучылар күп иде. Мин, аңа нярәп, сирәк-мирәк кызыл почмакка танцыга төшәм. Ул, беркемгә дә бирә күрмә дигәндәй, гел минем кулымнан тотып тора. Тулай торак күп балалы семья кебек бит инде ул. Анда нәрсә эшләгәнең, кем белән йөргәнеңне бөтенесе белеп яши. Шуңа

да карамастан, кайбер әрсез кызлар, музыка уйный башлауга, тиз-тиз килеп Әхсәнне танцыга чакыра. Әхсән исә, нишлим, дигәндәй, миңа текәлә. Кулымнан ычкындырам да: «Бар».— дим. Әле кызлары да бит нинди, мин аны яратып йөреп тә шулай булдыра алганым юк, муенына асылынып танцевать итәләр.

Икебез бер тулай торакта яшәгәч, салкын көннәрдә урамга чыгып йөрмибез, ул безнең дүртенче катка менә дә, ишек шакып, мине чакырып чыгара. Бүлмәбезгә кереп беркайчан озаклап сөйләшеп утырганы булмады. Коридорда миңа якынрак елышса: «Кирәкми, алай итмә, гел кеше үтеп йөри, яхшы түгел»,— дия идем. «Үтсә соң, безнең бер-беребезгә мөнәсәбәтне бөтен кеше белә, үземнең йөргән кызыма якын килеп сөйләшмәскә дә тиешмени мин ди, шулай да читкәрәк китеп баса иде. Сиңа өйләнергә дә куркыныч, болай булгач. Кеше күрә, кеше сизә, диеп, гомер буе раскладушкада йоклатырсың».

Ләкин эш өйләнешүгә барып җитмәде. Дөресрәге, барып җиткәч, барысы да бер селтәнүдә юкка чыкты...

Безнең авылдан бер кыз культура институтында укып йөри иде. Без аның белән элек тә дус түгел идек, Казанда да аралашмадык. Әни дә каникулга кайткан саен гел колакка киртли тора: «Берүк аралашма. Килсә, куып чыгарма, үзең янына барма». Чөнки аның турында авылда ук әллә нинди колакка ятышсыз сүзләр сөйлиләр, «сигезенче класстан бирле дөрес юлда түгел икән», дигән чыш-пышлар йөри иде. Мин исә акылым белән моның дөреслегенә һич ышана алмыйм, ничек инде кияүгә чыкмаган кыз шулай була алсын. Артык әрсез, кыюлыгын исә аның укытучы баласы булуыннан һәм иркен тормышта үсүеннән күрә идем. Бик яхшы: безнең кебек йоклап йөрми, үз сүзен чатнатып әйтә, үзенә кирәкне ничек тә ала. «Танцыга килгән идем, соң дип кайтып тормадым, сездә генә йоклап китим әле»,— дип, бервакыт бүлмәбездә кунган иде. Шуннан соң килгәне булмады. Бүлмә кызлары гына кайвакытта, аны исеме белән әйтмичә: «Теге безнең тулай торакта йөри, егетләр ауларга килгәндер инде»,— дип көләләр иде.

Әхсән бишенче, мин дүртенче курста укып йөрибез. Май аенда өйләнешергә сүз куештык. Кышкы имтиханнарны биргәч, алар ягына да, безнең якка да кайтып әти-әниләр белән танышып килергә булдык. Әхсән диплом яза, без дә әзерләнәбез.

Бервакыт дүртебез дә бүлмәдә укып утырган чакта, кичен соң гына ишегебезне шакыдылар. Бертавыштан: «Әйе»,— дип кычкырган идек, авылдашым килеп керде.

— О! — диде ул бер дә тартынмыйча,— мулла кызларына сәлам! Мин әле безнең Шәрига гына шундыймы дигән идем, бүлмәгез белән бер калыптан сөрелгәнсез икән: тәмәке тартмыйсыз, шәрап эчмисез, егетләр белән йөрмисез. Абыстай булырга хәзерләнәсез.

Без көлгән булдык.

— Танцыга килгән идем дә,— диде ул,— бер юньле егет тә юк икән бүген. Сезгә менгәндә ничава гына берәү коридорда тәмәке тартып калды-калуын. Мыеклы. Кылын тартып карау ярар иде. Шуның кайсы бүлмәдә торганын әйтегез әле, кызлар. Сез белергә тиеш бит инде, мыеклы егетләрегез күп түгелдер.

Без узышып мыеклы егетләрне санарга тотындык. Кунакны бик күрәсебез килеп тормый, тизрәк чыгып китүен тели идек.

— Шәрига, тиз генә бер матур күлмәгеңне биреп тор әле,— диде авылдашым тәмам түземсезләнеп,— табарбыз, ничего!

— Минем матуры юк шул. Кешелеккә киеп йөри торган менә шушы берәү генә. Өстеңдәге күлмәгең дә бик затлы бит.

— Әй, матур түгел лә, үзебездәге бер кызныкын кигән идем, биле югарырак.

Күлмәгемне тиз-тиз киеп төзәткәләгәндәй итенде дә йөгерә-йөгерә чыгып та китте...

Ул бүлмәбезгә иртән генә кайтты. Шунда гына күреп алдым: күз ләрендә сафлык, нәфислек юк иде аның. Кәефе шәп күрәсең, эше пешкән, үз дигәнен булдырган. Күлмәгемнең алдын артка киеп куйганлыгын күреп, без пырхылдашып көлеп җибәрдек. Эшнең нидә икәнен үзе дә аңлады бугай:

— Ярар ла, күлмәк ничек булса да ярамыймыни, егет элоккач,— диде.— Таптым мин аны. Сез әйткән беренчә бүлмәгә кергән идем, сорашып таптым үземә кирәкле мыекны. Әхсән исемле икән.

Өстемә һич көтмәгәндә бер чиләк кайнар су китереп сиптеләрмени, кинәт сискәнеп киттем, әллә нишләдем. Ярый әле сизмәде, миндә кайгысы юк, һаман сөйләнә дә сөйләнә. Күлмәгемне салып караватка куйды, үзенекен киде дә китәргә җыенды:

— Күлмәгеңне тагы биреп торырсың әле, бәхетле кием булып чыкты ул. Бүген кич тагы киләм, башын-күзен тизрәк әйләндерергә кирәк егетнең.

— Синең экзаменнарың юкмыни? — диде бүлмәдәшләремнең берсе.

— Иртәгә тарих. Бернәрсә укымаган. Укытучысы шәп кеше аның, бер күз кыссам, өчле куяр әле.— Ишекне ачкач, безгә кул болгады: — Чао, мулла кызлары!

Артыннан ишек ябылуга, кычкырып елап җибәрдем. Әхсәннең быел гына үстергән, безне харап иткән кара мыегын, күлмәгемә кадәр кидергән үземне, гомумән, бөтен дөньяны тирги-тирги еладым. Янымда мине ничек тынычландырырга белми хафаланган кызлардан бер генә нәрсә үтендем:

— Үтерегез, кызлар мине! Үтерегез!

Берсе аптыраганнан Әхсәнгә чапкан булган, ишек шакып егетем килеп керде. Кызлар берәм-берәм бүлмәдән чыгып сыздылар.

Әхсәнне күрүгә, йөземне ике кулым белән каплап, бераз дәшми тордым. Аннары авылдашым салып калдырган киемне алып алдына ыргыттым.

— Миннән оялмасаң, күлмәгемнән оялыр идең...

Ул әллә нишләп, югалып китте. Аннары тыныч булырга тырышып:

— Шуңа ышандыңмы... Ул бит үзе... Үзе эзләп килеп керде. Хатын-кызны кыйнап чыгарырга идемени... Син бит мине беләсең... Бернәрсә дә булмады...— диде.

— Ялгышасың, мин сине белмәдем дә, белергә теләмәдем дә... Безнең арада бернәрсә дә булмады дип уйла... Мин сине яратмадым да, яратмыйм да... Гомумән, мин мәхәббәтнең мондый төре бар дип белми идем...

Авылдашым пычраткан, кешелеккә генә кия торган бердәнбер күлмәгем белән бергә, Әхсән исеме белән бәйләнгән, аны хәтерләтүе мөмкин булган бөтен нәрсәләрне ут төртеп яндырдым да көлен җилләргә сибеп тараттым. Әхсәнгә булган бөтен хисләрем шул көл бөртекләре белән бергә тузгып бетмәсме дигән идем дә, ялгышканмын. Гомергә, мәңгегә үзем белән калдылар. Үзен күрмәсәм дә, мин аның дөньяда барлыгын белеп торам. Аның белән сөйләшәм, хәлләрен сорашам. Иртәләрен «Хәерле иртә!» — дип дәшәм, кичләрен «Тыныч йокы!» телим. Аннан бер серемне дә яшермим. Үзен яратуымны да кычкырып әйтә алам. Җанымны кая куярга белмәгән иң авыр минутларда аны уйлап үземә көч алам. Шатлык-бәхеттән җиде кат күктә йөргәндә аның да, үзем кебек, шатбәхетле булуын телим. Беренче балабыз бик елак булды. Көйсез баламны багып төннәремне йокысыз җәфаланып үткәргәндә дә мин аның турында уйларга вакыт таба идем. Аның турында уйлау миңа дөньяда яшәргә көч бирә ала икән, моның өчен шатланырга гына кирәк. Әхсән турында уйлавым миңа Рифкать белән матур яшәргә дә комачау итмәде. Рифкатьне хөрмәт итмәү, аның турында кайгыртмау үзе зур гөнаһ булыр иде. Теге чакта Әхсәнне кичерә алмаган иң авыр минутларда Рифкать гел янымда булды. Мине тынычландырыр өчен, әллә нинди матур сүзләр, «үләсем килә!» дип кычкырганда, дөньяда яшәү үзе иң зур бәхет икәнен ә

ышандырырлык көч таба алды ул. Чыннан да, мин үземне бик бәхетлегә саныйм. Әхсәннең дә минем кебек бәхетле булуын телим. Бәлки сез, юләрләр бу, яраткан кешең белән бергә булмагач, ничек бәхетле буласың инде, дип уйлыйсыздыр. Яраткан кешең белән бергә булып та, бәхетле булмаска мөмкин бит әле. Бәхет дигәнең бик киң төшенчә бит ул. Бу дөньяда сине ярты сүздән аңлаучы яхшы кешеләр белән яшәү, яраткан эшең, семьяң, балаларың булу, һәр көн кояшны, якты дөньяны күрү, яңгырларга чылану, буранга уралу зур бәхет түгелмени?

Әгәр кодрәтемнән килә торган булса, мин шундый бер бизмән уйлап табар идем — Мәхәббәт бизмәне! Шунда салып мәхәббәтнең зурлыгын, көчен үлчәр идем. Әйтик, берәүне ике кеше яратып йөри. Миңа да миңа диләр. Берсе: аны мин сиңа караганда ныграк яратам, ди, тегесенең дә бирешәсе килми. Менә шунда тотасың да боларның мәхәббәтләрен бизмәнлисең. Синең мәхәббәт моныкыннан көчсезрәк, рәхим итеп китүеңне үтенәм, дисең...

— Менә шундый бизмәнгә салып үлчәп карасаң,— дип дәвам итте ул бүленеп калган сүзен,— Әхсәнне яратуым аны яратучы бөтен кешеләрнекеннән дә көчлерәк булыр иде...

Сүзебез шунда өзелде. Рифкать миннән итагатьле генә гафу үтенде дә:

— Китик, Шәрига, киногә барасыбыз бар бит,— дип хатынының исенә төшерде.

— Сау бул, дустым. Без әле очрашырбыз. Шунсыз мөмкин булмас,— диде миңа Шәрига.

Саубуллашып ашыга-ашыга китеп бардылар. Адресын яки эш телефонын булса да сорарга өлгерә алмый калдым.

Өйгә кайтып кергәч, альбом алып, тиешле битен ачтым да, бер фоторәсемгә текәлдем. Әйе-әйе! Шәриганең йөз чалымнарын кайдадыр күргәнем бар бугай дип ялгышмаганмын, парк каршындагы һәйкәл янында төшкән бу рәсемнән миңа ике кеше: ирем Әхсән белән аңа сыеныбрак, ягымлы елмаеп басып торучы, хәзер инде миңа шундый таныш һәм бер күрүдә үзен яраттырып өлгергән Шәрига карап тора иде...

Бу ике шат, бәхетле йөзне бик озак күздән кичергәннән соң, үзем дә сизмәстән, кычкырып елап җибәрдем. Ярсый-ярсый, әрни-әрни, рәнҗи-рәнҗи еладым. Ни өчен елый, кемгә рәнҗи идем — үзем дә белмим. Шәригага ачуым килә, аңа рәнҗи идемме? Юк! Ни өчен? Мин бит аны бер күрүдә яраттым. Чын-чынлап үз иттем. Төс-бите генә түгел, күңеле, хисләре шулай матур була алуыннан, Әхсәнне нечә ел ел үзе эчкерсез, саф ярата алуыннан көнләшеп елый идем бугай. Ничек яратып, җылы итеп сөйли бит ул Әхсән турында. Ә мин? Әхсән белән тугыз ел бергә яшәп, һәр көнемне, һәр көнемне генә түгел, һәр төнемне аның белән иңгә-иң үткәргән кеше. Сөйли алыр идемме Әхсән турында шулай матур итеп? Юк. Сөйли алмас идем. Киресенчә. Мин аны ярата да, яраттыра да белми торган, үзен генә сөюче бер кеше дип белә идем. Хәер, белә идем дию менә хәзер, Шәриганe тыңлаганнан соң, дөрес тә булмас. Белмәгәнмен мин Әхсәнне. Белергә теләмәгәнмен дә. Менә шуның өчен ярсый-ярсый елый идем мин хәзер. Баксаң, әнә нинди зур бурыч йөкләнгән икән бит миңа! Берәүнең өзелеп яраткан, күз карасыдай кадерле кешесе белән гомер итү, аны кадерләү, саклау бурычы. Ә мин бу бурычны бар дип тә, булырга тиеш дип тә белмәгәнмен. Бары тик үзем белән генә мәшгуль булганмын, үземнең бәхетсез мәхәббәтемне генә уйлаганмын. Егерме җиденче яшендә тормыш юлын минем белән бәйләгән бу кешенең тирән күңел яралары булырга мөмкинлеген дә, өзелеп сөйгән ярыннан аерылган булырга мөмкинлеген дә уйламаганмын. Күңел яраларын төзәтергә, үткәннәрдән калган сагышын оныттырырга, аны аңлавым, белергә тырышуым белән бәхетле итәргә дә тырышмаганмын. Оят иде миңа бүген. Үз-үземнән оят иде. Менә шуның өчен ярсый-ярсый елый идем мин хәзер...

# ХИКӘЯ АВТОРЫНА АЧЫК ХАТ

Шәмсия сеңелем!

Бөтенләй таныш булмаган килеш, «син» дип дәшүем өчен хәтереӊ калмасын. Күп еллар редакцияләрдә эшләү дәвереннән гадәтемә кереп калган: әдәби иҗат юлына аяк баскан яшь каләмдәшләремә башкача дәшә алмыйм.

Мин синеӊ «Мәхәббәт бизмәне» исемле хикәяӊне кулъязма нөсхәсеннән, журналга бастыру өчен редакцияләнгән хәлендә укып чыктым.

Заманында барыбыз да кичергән халәт: инде күӊелеӊдә тәмам әзер дип санаган бер-бер әсәреӊне язарга утырдыӊмы, әллә артык дулкынланудан, әллә тәҗрибә җитмәүдән, каләмеӊ бозга баскан бозау кебек тая башлый, тел очында торган фикереӊне җыеп әйтә алмыйча гаҗиз буласыӊ. Әмма бу — узгынчы халәт кенә. Җөмлә төзелеше, стилистика, сүзләрнеӊ дөрес кулланылышы — барысы да теләгеӊ булганда, тиз арада үз урынына утыра. Ләкин әдәби әсәр язу өчен дөрес төзелгән шома җөмлә генә җитәме соӊ?

Кайда гына җае чыкмасын, мин әнә шул сорауга ачыклык кертергә тырышам. Чөнки язучының төп хезмәт коралы — образлы әдәби тел. Басым ясап әйтәм: **образлы.**

Әйтик, Шәриф Камалның «Акчарлаклар» повестенда «диӊгез көлә», «акчарлаклар үксеп елый», балыкчылар яши торган иске барак «хәлдән таеп җиргә яткан арык сыер кебек». М. Горький әсәрләрендә ташлар гыйбадәт кыла, агачлар хәрәкәт итә, тау елгалары тылсымлы әкият сөйли. Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» әсәре исә бу яктан яшьләр өчен чын мәгънәсендә дәреслек хезмәтен үти алыр иде.

Образлы сөйләм бер укуга хәтереӊә сеӊеп, күз алдыӊда уелып кала. Болар кызык ясау өчен кертелгән бизәкләр генә түгел, әлбәттә. Язучы бар табигатьне, бөтен материаль дөньяны җанлы итеп күрә, образлы әдәби тел аша шуны укучы күӊеленә ирештерә.

Әгәр «ходайдан бирелгән» әнә шул сәләт юк икән — бетте, вәссәлам, әдәби иҗат тирәсеннән ерак йөрүеӊ, үзеӊә башка шөгыль сайлавыӊ хәер.

Куанычыма каршы, синеӊ хикәяӊдә очраттым мин андый шигъри бизәкләрне. Әйтик: «... иксез-чиксез зәӊгәрлекнеӊ бер почмагында, чәч бөдрәләре кебек, әрфия болытлар бөдрәләнеп тора»... Әйбәт! Чәч бөдрәләре кебек әрфия болытлар!.. Әмма «чиксез зәӊгәрлекнеӊ почмагы» шиклерәк. Бәлки, «почмагы» түгел, «чите»дер?

Күӊелгә рәхәт булып ишетелгән тагын бер деталь: «Иртән күзне ачып җибәрәсеӊ, бүлмә синеӊ белән тулган була...»

Тексттан аерып алганда, сәер кебек. Ә карасаӊ, егет, төн йокламыйча, сөйгән кызының фотоларын ясый икән.

Кемгә ничектер, мине чын-чыннан дулкынландырды бу деталь. Әһә, өмет бар бу кызыйда дигән нәтиҗәгә килдем.

Әдәби тел мәсьәләсенә, бәлки, артыграк әһәмият бирәмдер. Ләкин бу — минем теӊкәмә тигән, редакциядә эшләгән чактан ук тәмам үзәгемә үткән мәсьәлә. Күпме генә сөйләмә, тәссез, иссез, хиссез шоп-шома җөмләләр белән язылган әйберләр бербер артлы дөньяга чыгып тора. Алар халыкның зәвыгын боза, безнеӊ өчен бик изге, бик кадерле булган темаларны юкка чыгара, әйтик, һәлак булган корбаннар истәлеген мәсхәрәли. Шуӊа рәнҗим. Кызым, сиӊа әйтәм, киленем, син тыӊла, дигәндәй, әдәбиятка омтылучы башка яшьләрнеӊ дә колагына чалынмасмы, дип тәкърарлавым бу фикеремне.

Болардан тыш, миӊа синеӊ хикәяӊнеӊ сюжеты ошады.

Сюжет дигәнебезне хикәяләү тәртибе һәм алымы дип карасак, синеӊ хикәяӊ, Шәмсия сеӊелем, ул яктан шактый үзенчәлекле. Гөлия үз ире турында бөтенләй чит хатын авызыннан ишетә. Сюжетны шул рәвешле кору хикәяне бермә-бер мавыктыргыч иткән. Ничек кенә булмасын, бу әсәреӊ укучы күӊеленә хуш килер, дип уйлыйм. Болай уйларга тагын бер нигез — хикәянеӊ төп темасы. Мәхәббәт — мәӊгелек тема, ул — тереклек чыганагы, тормыш дәвамы.

Ләкин шунысын да әйтик, минем бурыч хикәянеӊ уӊай якларын күрсәтү белән генә чикләнми. Редакция «Остаханә» рубрикасын ачканда, яшьләргә аларның җитешмәгән якларын да күрсәтүне, ягъни бераз сабак бирүне дә максат итеп куйган. Берәү дә хатадан хали түгел. һәм менә синеӊ хикәяӊдә дә, дөресен әйтик, кимчелекләр бар әле.

Аеруча күзгә ташланганы — синдә логика җитенкерәми, геройларыӊ күп очракта артык дуамал, хәрәкәтләре, үз-үзләрен тотышлары берничек тә нигезләнми, тормыш дөреслегенә туры килеп бетми.

Әйтик, Шәрига, сафта янәшә туры килгәч, «тәмәкече» егетне өнәми. Хәтта ул аны кыйнап ташларга әзер. Ләкин килми калган көннәрдә юксына, сагына башлый.

Нишләп әле? Ни сәбәпле?

Дөрес, мәхәббәт хисләреннән ниндидер логика эзләү һич тә дөрес булмас иде. Ничек дигән әле шагыйрь? «Булмый яшьлек хисләренең күзе дә, колагы да...»

Шәп әйтелгән. Дөрес әйтелгән. Ләкин бит авторның күзе дә, колагы да бар. Ул үзе әйткәнне үзе ишетергә, геройларның нишләгәнен, кая басканын күреп торырга тиеш. Кыскасы, әдәби әсәрнең ныклы эчке логикасы, вакыйгаларның сәбәбе һәм нәтиҗәсе булу зарури гына түгел, мәҗбүри. Һәр хәрәкәт өчен ниндидер сәбәп, күңелдәге һәр хисси үзгәреш өчен этәргеч кирәк.

Нәрсәне юксына башлады соң әле Шәрига? Тәмәке исенме? Юкса бит ул Әхсәнгә күтәрелеп тә карамаган иде. Ул аны соңыннан, юксына башлагач кына күрде, килеш-кыяфәтенә дә шактый соң игътибар итте. Менә бусы инде логика киртәсенә һич тә сыймый. Гап-гади әйткәндә, ышандырмый.

Саный китсәң, очы очка ялганмый торган урыннар хикәядә шактый күп.

Елга буенда Шәригане күргәч, Гөлия нәрсә ди? «Ханым миңа таныш түгел иде. Бер күргән кешенең йөз чалымнарын онытa торган гадәтем юк минем».

Ә соңыннан, хикәя ахырында? «Әйе-әйе! Шәриганең йөз чалымнарын кайдадыр күргәнем бар бугай дип ялгышмаганмын...» Я, кайда биредә авторның күзе, колагы? Кайда логика?

Гаилә альбомында рәсеме булган ханымны ничек ул башта ук танымый? Танымаса, бәлки, төсмерләр иде.

Ул гына да түгел. Ниндидер ят ханым аның ире турында, үз исеме белән «Әхсән» дип сөйли. Хәтта төсен-кыяфәтен тасвирлап бирә. Ә тегесе?.. Гөлиянең күңелендә ник бер шөбһә тусын! Менә сиңа торҗагун! Бусы инде, Шәмсия сеңелем, бөтенләй адәм ышанмаслык уйдырмага әверелә түгелме соң?

Менә тагын шундый бер гыйбрәтле мисал. Атаклы язучылардан кем әйткән әле? «Пәрдә ачылганда стенада мылтык эленеп тора икән, ахырда ул, һичшиксез, атарга тиеш...»

Синең хикәядә дә бар андый мылтык. Берәү генә түгел, хәтта икәү — һәнүзә белән Рәбига. Алар икесе дә Әхсәнгә күз атып йөриләр. Ләкин Әхсән аларга игътибар итми, чокыр төбеннән Рәбиганы түгел, Шәригане күтәреп менә (уңышлы деталь!). Әһә, мылтык корылды. Бу кызларның Шәригадән көнләшергә, үчләшергә сылтаулары бар. Һәм логика шуны таләп итә. Юкса, нигә кирәк алар бу хикәягә?

Әмма шундый уңышлы корылган мылтык атылмый калды. Авторга кирәк булгач, әллә каян гына, һичбер эзерлексез-нисез ниндидер шәүлә килеп керде. Геройларның бөтен язмышын җимереп ташлаган «авылдаш кыз», «азгын кыз» дигәнебез биредә әнә шундый бер кара шәүлә генә булып кала. Аның төсе-кыяфәте дә, характеры да юк. Инде эзерләнеп беткән Рәбига белән һәнүзә барында, аны китереп кертү яңадан әдәби әсәр логикасына сыймый. Андый очраклы хәлләр психологик пландагы әсәрне беркайчан да көчәйтми. Ә бит Шәрига белән Гөлиянең очрашуы шулай ук ясалма, шулай ук очраклы вакыйга.

Бәя бирү, фикер әйтү максаты белән әсәр укыганда, һәрвакыт башыма шундый уй килә: бу хикәяне мин язсам, ничегрәк эшләр идем?

Менә синең хикәяңне укыгач та күңелдә шундыйрак вәсвәсә

Ничек эшләр идем?

Ихтимал, болайрак.

Гөлия Әхсән белән начар яши (монысына басым ясап әйтер идем). Менә бүген дә ачуланышканнар. Зират яныннан узганда, уйланулар да шуңа бәйләнергә тиеш. Гөлия белән Шәриганең очрашуы очраклы түгел. Шәрига кайчандыр аны Әхсән белән күргән. Ә машинада Әхсәннең үз авызыннан рәтле яшәмәүләре турында ишеткән. Су буенда очраткач, Әхсән турында сөйләве дә юкка түгел. Гөлиядә матур хисләр уяту нияте белән сөйли. Ләкин үз исемен телгә алмый. Иптәш кызларым аны Саша дип йөртәләр иде дисә?.. Ә иң соңыннан, аерылып киткәндә, бәлки: «Чын исеме Әхсән иде аның»,— дип әйтеп куйса...

Әлбәттә, болар — минем хыялда туган нәрсәләр генә. Мәхәббәт безмәне булмаган кебек, биредә дә безмән юк. Әмма әдәби иҗатның үз закончалыгы, һәр әсәрнең үз логикасы бар.

Күзгә күренеп торган әнә шундый кимчелекләре булгач, хикәяне журналга бастырып, халык хөкеменә тапшыру дөрес булганмы соң?

Минемчә, бик дөрес. Тулаем алганда, бөтен кимчелекләренә карамастан, яшь язучы өчен бу — шактый уңышлы хикәя.

Ә инде киләчәк иҗатың өчен мөмкинлекләрең бар. Хәерле юл телим сиңа, Шәмсия сеңелем!

Габделхәй **САБИТОВ**

# Габделҗаббар Кандалый

1797—1860

●

Бу хатымны кабул итеп аласың,
Кабул итсәң, читен өзеп каласың.

Сәнең өчен аһе-ваһ органнарым,
Бер күрергә тилмереп торганнарым!

Каным, сәүгән йөрәгем парәсе сән,
Тәнем рухы, күземнең карасы сән.

Хода язсын мөкъәддәр каләмендә:
Кавыштырсын бу дөнья галәмендә.

Кыяфәтең, сыйфатың суда кондыз,
Үзең былбыл, күзең мисалда йолдыз.

Сәнең дәрдең беләң даим йөримен,
Сәне күргәч, сары май тик эримен!

Сәнең дәрдең билә булдым гирифтар,
Хода кыйлса иде сәне гүзәл йар.

Сәнең буең Ак Иделнең камышы,
Сөләгән сүзләрең былбыл тавышы.

Сәнең өчен агыздым күздә яшем,
Бу хәсрәтдин чыгар микән бу башым?!

---

Сүзлек: Мөкъәддәр — тәкъдир, язмыш
Гирифтар — дучар

●

Җөмлә гөлнең нуры китә
Сачәк вакытлары үткәч;
Матур кызның кадре китә,
Егерме йәшенә йиткәч.

Җиһан багълары ки нурлана,
Җөмлә гөлләр сачәк аткач;
Бәнем күңлем тынычланыр
Сәнең куйн гынаңа яткач!

●

Башыңдадыр мамык калпак,
Аягыңда читек-башмак,
Бәнем күңлем сәңа моштак,—
Мәхрүм кыйлмасәнә, җаный!

Йөзең рәушан, телең сөчек,
Буең зифа, билең нәзек,
Кулыңдадыр көмеш йөзек,
Гаҗәп һиммәт ирер, җаный.

Колагыңда көмеш алка,
Дәхи артыңдадыр тәңкә;
Морадыңдыр сәнең кемдә? —
Серең белдерсәнә, җаный!

Тәмам әгъзаларың төзек,
Кулларыңда һәм беләзек,
Авазыңдыр дәхи нәзек,
Чү былбыл авазы, җаный!

Яратыптыр сәне алла,
Сүзем юкдыр сәңа әмма,
Безне һәм күңелдин салма,—
Бәйан әйлә әхвалең, җаный.

Беләкләрең сәнең аппак,
Өстеңдәдер йәшел күлмәк,
Морадымдыр сәне алмак,—
Бәйан әйлә, әхвалең, җаный!

Морадымдыр ирешмәккә,
Сәнең илә күрешмәккә,
Дәхи әхваль сорашмакка,
Хода насыйб әйләсен, җаный!

Йөзең рәушан, билең нәзек,
Бәнем гарзым үзең күрмәк,
Күреп ничеклегең белмәк,—
Бәйан ит әхвалең, җаный...

---

Сүзлек: Моштак — омтылучы, атылып, тартылып торучы
Сөчек — тәмле
Гарз — үтенеч, теләк

●

Мәхәббәт ширбәтен эчкән онытмас,
Ярындин гайре нәрсә дәва булмас.

Әйа җаный, салдың гыйшык мәҗазын,—
Сәне күрмәй табалмаймын дәвасын.

Әйа җаный, багъладың бәгъремә таш,
Күзем нәргисләренә тултырдың йәш.

Сәнең өчен кыйлыпмын налә бисйар,
Тәмам гомреми кыйлдың заре әфгяр.

Ике күземгә йәш тулды, и җаный,
Караңгы әйләдең ошбу җиһанный.

Билең кочарга тилмереп үләрмен,
Ләбләреңдин кайчан суырып үбәрмен?!

---

Сүзлек: Мәҗаз — хәл
Кыйлыпмын налә бисйар — күп елаганмын
Гомреми — гомеремне
Заре әфгяр — зар белән җәрәхәтләнү, яралы күңел
Ләб — ирен

●

Бер тамаша: бу гашыйклык берлә күңел азмасын,—
Авыр икән, хәсрәте чук — дошманыңа язмасын.

Бу гашыйклык тоткан икән, нинди түзем исә дә,
Бән түзәрмен дисә дә кем, үлчәшергә базмасын.

Ул Зөләйхә түзмәде лә, бер өмитен өзмәде,
Бер тоташ им эзләде лә бетереп мал-казнасын!..

---

Сүзлек: Чук — күп

❋

Үсеп бара ла бер җаный,
Чыгып бара матур даный.
Мәдехли һәр кеше ани —
Яр итсә кемгә дә ярый!

Үзе яңа үсеп бара,
Йөзе мисле маһа пара,
Күзе — нәргис, кашы кара,—
Ниндәй булыр бара-бара?

Мәкәрҗә калфагы сәнең,
Башыңда сачагы (уйный),
Кулыңдадыр беләзегең,
Йөрәгем өзелә, җан(ый)!

Колагыңда көмеш алка,
Дәхи артыңдадыр таңкә;
Морадыңдыр сәнең кемдә? —
Йөрәгем өзелә, җаный!

Беләзегең кулыңдадыр,
Яка-башың буйныңдадыр,
Ике нәрсәң куйныңдадыр,—
Алар ни нәрсәләр, җаный?

Бән әгәр күршәен дисәм,
Шайәт әллә ояласың,
Оялмагың чын булса гәр,
Зәһи инсафлы баласың!

Икеләнгән булып күңлең
Ары һәм бире чабасың.
Бәнем кебек сәне сәүгән,
Күп эзләсәң дә, тапмассың.

Төшемдә күрешеп, җаный,
Сөйләштек каты сер сүзләр;
Болай ук сүзләшә алмаслар
Ни кадәр үз булып үзләр.

Әйа җаным, күзем нуры,
Карасам гәр саңа туры,
Китәдер күзләрем нуры
Ки сәнсең (чын!) оҗмах хуры!

Бигүк садә баламысың?
Бәне искә саламысың?
Иә онытып каламысың
Зифалыгың горурында?

Языйм микән, йитәр микән,
Сәнең мәдхең бетәр микән?
Күңелләрдин китәр микән
Сәнең дәрдең белән, җаный?!

---

Сүзлек: Мәдехли — мактый
Маһа пара — маһ — ай: айга пар, айга тиң
Сачагы — чачагы
Морадың — теләгең, теләгәнең; омтылган кешең
Күршәен — күрешәен: күрешик
Зәһи — яхшы, шәп; бик
Үз булып үзләр — үз булып беткән кешеләр
Дәрдең — кайгың, хәсрәтең

❋

Ки бән алдым каләмемне
Язаем дип сәләмемне,
Яза белмим кәлямемне,—
Кем илткәй бу сәләмемне?

Кызыл гөлдер сәнең йөзең,
Кызыл йакут сәнең ирнең,
Төшемдә агъзыма тирдең,—
Кем илткәй бу сәламемне?

Атаң улдыр фәлән атлы,
Сүзеңдер шикәрдин татлы,
Ничек тугъмыш бу сыйфатлы? —
Кем илткәй бу сәламемне?

Әйа җаным, нечкә билем,
Үзең зирәк, үзең гыйлем,
Үзен үткен дә бик дилем,—
Кем илткәй бу сәламемне?

Буш сүзләргә колак салма,
Бәнем күз йәшемә калма,
Гомергә хур булып калма,—
Кем илткәй бу сәламемне?

Әгәр калсам сәне алмай,
Кулымны буйныңа салмай,
Гомерлеккә булыр ай-вай,—
Кем илткәй бу сәламемне?

---

Сүзлек: Кәлям — сүз; сөйләм
Тирдең — тиердең, тидердең
Бик дилем (бик тәлим) — бик күп.

*

Кечекдин сәүдем, әй күңлем зыйасы,
Йөрәгем бәгъре, күзем тутыйасы,

Үзеңне күрмәин күңелемне алган,—
Көйдереп тә яңдырып утка салган.

Морадым, мәкъсудым, күрер күзем сән,
Ничә елдин бирле сүләр сүзем сән.

Ничә елдин бирле җәһдеңдә әфгяр,
Гамең берлә гъәриблыкда герифтар.

Сәне ничә сыйфат кыйлсам төгәнмәс,
Вәли күрмәй кеше һәргиз ышанмас.

Ләбең — йакут, тешең энҗе тезелмеш,
Йөрәк бәгърем сәнең өчен өзелмеш.

Гыйшыклыкдин берәүгә ут чагылса,—
Гаҗәб улмаз җиһан утка ягылса!

Гыйшык хале маризъдыр каты, ачы,—
Кочаклашып үбешмәкдер гыйляҗы.

---

Сүзлек: Күңлем зыйасы — күңлем нуры, яктылыгы
Тутыйа — күз дарсы
Күрмәин — күрмичә
Җәһдеңдә әфгяр — яныңда җәфаланучы
Гъәриблыкда герифтар — өлешсезлеккә дучар, тоткын, әсир
Вәли — вә ләкин
Ләбең — иренең
Маризъ — чир, авыру
Гыйляҗы — чарасы (дәвасы)

# «Сәхибҗамал»дан өзекләр

## I

Төшемдә Парау илендә
Ки тайран иттем — очмакта,
Барып, анда сәнең илән
Ки сәйран иттем оҗмахта.

Ки бер түшәктә, күлмәктә,
Һәм уйнамакта, көлмәктә,
Кысып сөймәктә, үпмәктә,
Булып тотмакта, кочмакта.

Сәнең лә җәннәт эчендә,
Гата һәм миннәт эчендә,—
Күп әлуан нигъмәт эчендә —
Ки сәйран иттем оҗмахта!

Йөзең гаркъ улубән нура,
Имеш сән охшамыш хура,
Мәгъә әһиллә мәсрура,
Ки хәйран иттем оҗмахта.

Билең нечкә, буең төзгә,
Күрер күзгә сөйләр сүзгә,
Матуррак тапмыйча үзгә,
Ки сәйран иттем оҗмахта!

Кереп торганда куйныңда,
Биһуш әйләдең уйныңда,
Кулымның берсе муйныңда,
Бере билеңне кочмакта.

Имиләрең икән зурлар,
Кояштик бирәдер нурлар,
Тамаша калдылар хурлар
Бу халемезгә оҗмахта.

Шу дәклү гыйше нуш иттем,
Сафа вә зәукый җуш иттем,
Сәнеңлә күңлемне хуш иттем,—
Ки сәйран иттем оҗмахта!

Йөзеңә йөземи сөрдем
Сәнеңлә күп сафа сөрдем...
Уяндым үземи күрдем:
Ятамын өйдә почмакта!

Бу җәннәт, гъәрше көрси дә,
Ки калмамыш ла берси дә!..
Җәмалем күңле-күкси дә,
Бу хурлар, дәхи оҗмах та!...

## II

Дигел, җаный; кичәләрдә
Ни сагышлап ятыр кызлар?
Кияү дәрде белән әллә
Ятыр микән матур кызлар?

Муен куеп беләгенә,
Кулын куеп күкрәгенә,
Түзә алмай йөрәгенә,
Ятыр микән батыр кызлар?

Болай кичен таң атканчы,
Сагышлап юкны ятканчы,
Сөешеп күңле кайтканчы,
Тик уйнайур матур кызлар.

Кияүне өстенә куеп,
Уен зәукъен, тәмен тоеп,
Ки кургашын кеби эреп,
И мимылдап ятыр кызлар.

Ки хур кызыдай мимылдап,
Һәм аккош кеби гыйгылдап,
Кысып, кочып, алып чолгап,
Ничек табар хатер кызлар?!

«Сагындым, җанкәем!» — диеп,
Үбеп, кочып, кысып, сөеп,
Тиешне тиешә тиеп,
Абе залял татыр кызлар.

«Ки бакма, абзый, төсемә,
Кулың куйганда өстемә,
Килә әллә ни исемә»,—
Диеп уйнар матур кызлар...

---

Сүзлек: Тайран итү — очу, очып йөрү
Гата һәм миннәт эчендә — бүләкләү һәм юмартлык эчендә
Күп әлуан нигъмәт — күп төрле ризык
Сәйран итү — тамаша итү, хозур алып йөрү
Гаркъ улубән нура — нурга чумган
Охшамыш хура — хурга охшаган
Мәгъә әһиллә мәсрура — айлар буена шатлыкта
Биһуш әйләдең — һушсыз иттең
Шу дәклү гыйше нуш иттем — шул хәтле мәхәббәт ләззәтен татыдым
Сафа вә зәукый җуш иттем — рәхәт вә зәвыклануны хирыс иттем (шашынып теләдем)
Йөзеңә йөземи сөрдем — йөзеңә йөземне сөрттем (тигездем, каплादым)

Үземи — үземне
Гъәрши көрси — күк тәхете; монда: рәхәтлек урыны
Калмамыш — калмаган
Җәмалым күңле-күкси дә — гүзәлемнең күңеле дә, күкрәкләре дә.
Кияү дәрде — кияү кайгысы
Табар хатер — хәтерне күрү, күңелне аулау
Абе залял — пакь су (ихлас үбешү күздә тотыла).

⁂

Тулган айдай нурлы йөзгә төште гыйшкым чарасыз,—
Җыр гына хәстә күңелнең булыр микән дәвасы?
Былбыл затлы, сүзе татлы, иртәнге нур күзләре;
Ул нәкъ кояш: карап булмас — талдырадыр күзләрне.

Гүзәллекнең аңардагы күзалла меңнән берен:
Өстенлекнең галәмдәге алган җыеп һәрберен!

Дөньяның иң чибәрләре булмас аның тиңдәше,
Бары тик җәннәт хурлары булса булыр тиң-ише.

Йөргән чакта җай гына бер кинәт үзен очраттым,
Бер күрүдә гашыйк булдым, шундук һушым югалттым.

Сокланып әйттем үземә: бу ходаның сәнгате!
Ник тыйыйм нәфсем? — сөю бит пәйгамбәрләр сөннәте...

Бу гыйшыклык богавында йөримен гел миңгерәп;
Диванадай белмим үзем — миңа кемнән ни кирәк?..

Һәр теләктәш, очратсам гәр, кайгымны уртак итте,
Тик бу элгәргедән чирем мең кабат артык итте.

Батты дөнья караңгыга, кояш та юк, ут та юк;
Калган идем караңгыда — чиргә дәва юк та юк.

Калган идем караңгыда, уй-хыялларга батып,
Бәгырьгә кадап уятты, керфек укларын атып.

Күзләрем ачып күрдем дә, әйттем: «И Сәхибҗамал,
Шәфкъәт ит, үтермә мине — хәзер үк куйныңа ал!»

Үзе — гел наз, күзе — нәргис, йөзе — гүзәллек шаһы,—
Исеменә җисемнәрен тиң яраткан иляһи!..

⁂

И гүзәлем, барма картка,
И җанымның кисәге!
Карт кешенең мисле шулдыр:
Артка чыгар терсәге.

Карт куйнында ятыр булсаң
Һич тә булмас ләззәте:
Бер сүзене әйтә алмас,
Һич тә булмас гайрәте.

Саба йилләр кеби исәр
Йәш кешенең сулуы,
Йәшлегеңдин белмәйәсән
Йәш гомернең узуын.

И гүзәлем, бакмайәсән
Карт кешенең малына,—
Та гомерлек хәсрәт алма
Сән үзеңнең җаныңа.

Карт кешегә гашыйк улсаң,
Йөргәнен күр бөкрәеп;
Сәңа хаҗәт карар ирсә,
Күзе торыр чикрәеп!

Гәрчә аны кабул итсәң,
Инанып сән сүзенә;
Гашыйк улып, малы өчен
Барыр кызлар үзенә.

И гүзәлем, заигъ итмә,
Карт кешилә гомреңи,
Йәшлегеңне заигъ итмә
Үз-үзеңдән кадреңи.

Нәфсеңә әүүарә булып
Бакма аның малына,
Бу сүзләрдин аңлайәсән —
Кара үзең халеңә!

Карт кешегә гашыйк улсаң,
Гәрчә булса ул надан,
Йәшлегеңнең кадре китеп,
Барчасы булыр яман!

---

Сүзлек: Мисле — мисалы, үрнәге
Сиңа хаҗәт карар ирсә — сиңа карау хаҗәте булса
Заигъ итмә — әрәм итмә
Кешилә — кеше илә, кеше белән
Гомреңи — гомреңне
Нәфсеңә әүүарә булып — нәфесеңә бирелеп, ияреп.

Сәлам яздым сәңа, җаным, гөзидә,
Сәнең кебек ки тугмаз йир йөзидә.

•

Сәлам яздым сәңа, җаным, тиң итеп,
Сәламемне ки кайтарма ким итеп.

•

Сәлам яздым сиңа, җаным, үзеңә,
Күзем дөшде сәнең күркәм йөзеңә.

•

Сәлам яздым сәңа, җаным, асылный,
Сәне күрмәй бәнем күңлем басылмый.

•

Сәлам яздым сәңа, җаным, гүзәлем,
Сәне күрми, җаным, һич [дә] түзәлмим.

•

Сәлам яздым сәңа, җаным, хәкыйкъәт,
Йосыф-Зөләйхәдин алгыл нәсыйхәт.

•

Сәлам яздым сиңа, җаным, йитәрмү,
Бу хат берлә арада сүз бетәрмү?

•

Сәлам яздым сәңа — кабул аласән,
Ике читенә бер билге саласән.

•

Сәлам яздым сәңа, җаным, кичә көн,
Кабул итмәз исәң ватма пичәтен.

•

Сәлам яздым сәңа, җаным, бу микдар,
Бәлки булмас микән диеп бәңа җар.

•

Сәлам яздым сәңа, җаным, үзеңә,
Яман күз дөшмәсен күркәм йөзеңә.

•

Сәлам яздым сәңа, җаным, ике күз,
Сәнең хәсрәтдин саргайды нурлы йөз.

•

Сәлам улсын сәңа, җаным, кара каш,
Бу серемне әйләмә һичкемгә фаш.

•

Сәламдин соң кабул булса, җанашым,
Кичә-көндез сәнең берлә сагышым.

•

Сәламдин соң кәлям яздым үзеңә,—
Җөфетлеккә өмид идәм үзеңне.

•

Сәламдин соң дәхи сәңа кәлямем;
Кабул иткәй идең бәнем сәламем.

•

Сәлам язмак пәйгамбәр сөннәтедер,
Сәлам алмак матур кыз хөрмәтедер.

•

Сәлам язмак галим шәкерт эшедер,
Кабул күргән дәхи изге кешедер.

---

Сүзлек: Гөзидә — сайланган, сайлап алынган **[бердәнбер]**
Җар — хәбәр, белдерү; игълан; кычкырып дәшү
Зыйасы — яктысы, нуры
Кәлям — сүз
Сөннәт — пәйгамбәр эшләргә кушкан эш.

# КАНДАЛЫЙ МИРАСЫН БАРЛАУ ЮЛЫНДА

Быел классик әдибебез Габделҗаббар Кандалыйның тууына 190 ел тула. Шушы уңайдан редакция берничә сорау белән тарих фәннәре докторы, профессор **Миркасыйм Госмановка** мөрәҗәгать итте.

Сорау:

— Мәгълүм булганча, шагыйрьнең мирасы әлегә тәгәл барланмаган. Бу юнәлештә нинди табышлар һәм, әйтергә яраса, нинди ачышлар бар?

Җавап:

— Әйе, Кандалыйның бай мирасын моңарчы тәгәл белмәгән кебек, без әле бу гаҗәеп һәм олы иҗатның әһәмиятен дә җитәрлек дәрәҗәдә аңламаган икәнбез. Фикерем ачыграк булсын өчен сорауда куелган мәсьәләне икегә бүлеп карыйк. Иң элек күләм һәм табышлар хакында. Моңарчы гыйльми җәмәгатьчелеккә шагыйрьнең әсәрләреннән өч мең юл чамасы текст мәгълүм иде. Бу санга Каюм Насыйри публикациясе дә, 1960 елда Хатип ага Госман һәм Җәвад Алмазлар бастырган китаптагы материаллар да, Кандалыйныкы булып та, һаман аноним әсәрләр сыйфатында кала килеп дөньяга чыккан әсәрләр дә керәләр. Хәзер исә өстәлебездә яткан әсәрләрнең гомум күләме тугыз мең юлдан арта язды... Алар арасында, дистәләгән өр-яңа шигырьләр булган шикелле, зур, күләмле поэмалар да бар. Аерым цикллы вариантлар тәшкил итә. Кандалыйныкы булуы тәгәл ачыкланып җитмәгән текстларның да күләме шактый...

Ачышларга килсәк, аларны хәзергә бары үзем өчен генә булган ачышлар дип бәяләр идем. Мәсәлән, моңарчы Кандалый бик күп яр тоткан җилбәзәгрәк шагыйрь, заманында бер автор әйтмешли, «татар Дон Жуаны» кыяфәтендәрәк күз алдына китерелә иде. Дөреслектә исә Габделҗаббар бары ике генә кызга (әлбәттә, төрле елларда)

гыйшык тоткан, бары шуларны, төгәлрәк әйтсәк, Фәрхи белән Сәхибҗамалны гына яратып, бары шуларга гына үзенең ихлас шигырьләрен багышлаган. Ә теге Әминә, Җәмиләкәй, Фатыйма, Бәдига, Гөлбостаннар исә очраклы рәвештә генә шигырь объектына әверелгәннәр икән. Кайбер исемнәрнең шагыйрь текстларына соңрак кереп утырган булулары да ихтималга якын, мәсәлән, Фатыйма. Ә Бәдигага килсәк, бу инде соңгы заман галимнәребезнең «иҗаты» гына...

Икенче ачыш катлаулырак. Гадәттә зур язучылар, шагыйрьләр, нигездә, бер тенденциягә, ягъни бер заман һәм бер чор өчен хас хәрәкәткә, идеягә вакаләтлек итәләр. Әйтик, иҗатларында искене яки яңаны гәүдәләндерәләр. Кандалый исә үз иҗатында ике чорга хас стильне «бергә» кушкан — Урта гасырларга хас консерватив романтизм һәм идеалистик дидактизм традицияләре белән башлап, аннары халыкчанлык нигезенә күчкән, яңа дәвер мәгърифәтчелеге идеяләренә корылган демократик принципларны алга сөргән, шул принципларга бәйле рәвештә реализм методын үзләштерә башлау югарылыгына күтәрелә язган. Бер гомер һәм бер иҗат өчен бу — сирәк насыйп була торган хәл. Шуңа күрә хәзер яза торган хезмәтемә — шагыйрь иҗатына багышланган махсус мәкаләгә — «Габделҗаббар Кандалый: бер гомердә ике чор» дип исем куярга ниятлим...

Шулай ук «Сәхибҗамал» һәм «Мәгъшукнамә» китапларының беренче редакцияләре табылу, авторның бу әсәрләр өстендә кат-кат эшләү фактлары ачылу да филология, бигрәк тә текстология фәнебез өчен гаять зур әһәмияткә ия дип уйлыйм. Алар ярдәмендә шагыйрьнең иҗат лабораториясенә керү мөмкинлегенә ирешәбез...

Ниһаять, үзем өчен генә ясалган тагын бер яңалык, ул — «Сәхибҗамал» әсәренең жанры һәм төп герое мәсьәләләре. Әсәрне поэма дип атап булмый, гадәти шигырь дә түгел ул. Аның жанрын билгеләүдәге моңарчы яшәп килгән төрлелекнең сәбәбе, минемчә, төп геройны, төп проблеманы төгәл билгеләмәү белән бәйле. Төп герой Сәхибҗамал һәм аның язмышы түгел, күрәсең... Ләкин бу хакта тәфсилләп сөйләүне икенче урынга — махсус мәкаләгә — калдырып торыйк...

Сорау:

— Әле әйткән фикерләрегезнең кайберләрен дәлилләрлек конкрет фактлар китермәссез микән?

Җавап:

— Башта китерелгән җиде шигырь яңа табылган, ягъни моңарчы бер җирдә дә басылмаган Кандалый әсәрләренә үрнәк сыйфатында тәкъдим ителә. Аннан соң килә торган «Сәлам яздым сәңа...» дип башланган парчалар циклыннан (алар да әле басылмаган) шагыйрьнең бер мотивка багышланган текст өстендә ничек төпченеп эшләвен күрәбез.» ...Бер тамаша: бу гашыйклык...» дигән парча яңа укылышта тәкъдим ителә, анда Кандалыйның «ачы мәхәббәт» хакындагы уйлануы, көрсенүе гәүдәләнә...

«Сәхибҗамал»дан алынган ике өзекнең беренчесе яңа күчермәләр нигезендә моңарчы күптән мәгълүм истәлекнең фактик яктан баюын күрсәтә. Мәсәлән, моңарчы андагы ун строфаның алтысы гына (1, 6—10) К. Насыйри публикациясе буенча мәгълүм булган булса, шуларның бары дүрт строфасы гына (1, 8—10) 1960 елгы җыентыкка кергән. Калганнары исә хәзер филология фәннәре кандидаты Ш. Абиловта саклана торган күчермәдә теркәлгән (форсаттан файдаланып, аңа үземнең рәхмәтләремне белдерәм). Икенче өзек тә шул ук дәфтәрдән алынды. Уйлавымча, аны шагыйрь билгеле бер сәбәпләр аркасында әсәрнең соңгы редакциясеннән үзе төшереп калдырган. Бу өзекләр, Кандалый иҗатының тел-стиль җәһәтеннән ни дәрәҗәдә халыклашуын, димәк, иске стильдән ни дәрәҗәдә ераклашуын күрсәтә торган кыйммәтле фактлар. Шул ук Сәхибҗамалга багышланган «...Бәдре-ләмигъ дилбәрә...» дип башлана торган газәлдән без шагыйрьнең, борынгылыктан аерылуны принцип дәрәҗәсенә күтәрә алганы хәлдә, иске стиль традицияләренә кабат мөрәҗәгать итүен күрәбез. Шигырь борынгы поэзиябезнең классик үрнәкләреннән санала алырлык югары әдәби сыйфатка ия (максималь аңлаешлылык тәэмин ителсен өчен аның хәзерге телгә тәрҗемәсе тәкъдим ителә)... Менә шундый фактларның һәммәсе (ә андыйлар шактый) югарыда әйтелгән «бер гомердә ике чор» тезисын артыгы белән раслаца кирәк...

Татарстан китап нәшриятында басмага әзерләнгән китапта Кандалыйныкы «булуы ихтимал» дигән бүлек тә бар. «...И гүзәлем, барма картка» дип башланган соңгы шигырь шул бүлеккә кертелгән әсәрләргә үрнәк була ала.

Ниһаять, журналга тәкъдим ителгән текстларның орфографик һәм әйтелеш ягыннан бераз адаптацияләнеп (җиңеләйтелеп, унификацияләнеп) бирелүен искәртергә кирәк. Китапта исә бу тарихи истәлекләр документаль төгәллек һәм тиешле фәнни аппараты белән басылачак.

*КПССның XXVII съезды карарларын — тормышка!*

**Зәкәрия Сафин,**

*Казанның С. М. Киров исемендәге синтетик каучук заводы директоры, Социалистик Хезмәт Герое*

# КӨЧ ҖИТӘРЛЕК

Илебезнең соңгы елларда алга куйган бурычлары берсеннән-берсе катлаулы. Партия промышленность һәм авыл хуҗалыгының да, тормыш-көнкүрешнең дә кискен борылышын, кызу темплар белән үсешен мәҗбүри таләп дип белдерде. Аңлашыла: инде дә көтәргә ярамый, болай да, йокымсырап, шактый форсатны ычкындырганбыз.

Безнең завод коллективына килгәндә, башка завод-фабрикаларга караганда, үзгәртеп коруларны партия таләп иткән югарылыкта алып бару җиңелрәк булачак. Чөнки без, әле ил күләмендә сүз кузгалганчы ук, моңа тотынган идек инде. Эшли торган цехларны яңартып кору, өр-яңаларын булдыру заводның киләчәген ныклы нигезгә бастырачак иде. КПСС Үзәк Комитетының 1985 елгы май Пленумыннан соң ук башланган бу эш безнең завод кешеләрен рухландырып җибәрде, күрсәткечләребез яхшырды. План үтәлеп кенә калмый, арттырып та үтәлә иде инде.

Әмма тордәш предприятиеләрнең җитәкчеләре һәм белгечләре җыела торган киңәшмәләрдә без үз хәлебезне ачыграк күрә башладык, шактый артта сөйрәләнебезне сизә килдек. Моның бик объектив сәбәпләре дә бар: завод Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан салынган. Ул Ярославль, Воронеж, Ефремов шәһәрләрендәге үрнәккә нигезләнеп көйләнгән. Заманында иң киң колачлы, техник-технологик яктан иң алдынгы предприятие булган. Сугыш чорында һәм аннан соңгы бишьеллыкларда бу төр продукцияне бирүче бердәнбер чыганактан саналган.

Без илгә синтетик каучукны мөмкин кадәр күбрәк бирү турында гына кайгыртып эшләп ятканда, өр-яңа фәнни-техник нигезгә көйләнгән башка завод һәм комбинатлар корыла башлады. Аларның технологиясе нефть һәм газ кебек арзанлы чималга җайланып эшләнде. Безгә исә әле алтмышынчы елларда да азык-төлектән алына торган чимал кирәк иде.

Җитди мәсьәлә туды: заводны яки ябарга, яки... Икенче юл хәтта күренми дә кебек иде. Ул чакта коллективлар фикере белән санашып торулар юк. Барысы да «өстән» күрсәтелә, без шул өйрәтмәләрне көтеп утырырга мәҗбүр идек. Әмма безнең завод әле шул вакытта ук, житмешенче еллар башында, бөтен җаваплылыкны үз өстенә алырга җөрьәт итте. Үзгәртеп коруларны без шунда ук башлап җибәрдек. Сүз дә юк, ул үзгәртүләрнең максатын КПССның XXVII съезды һәм аннан соңгы документлары алга сөргән революцион олы максат белән үк чагыштырып булмый. Шулай да без бу бөек башлангычка әзерлекле килдек дип әйтә алам. Һәм шул ук вакытта безгә кыен да. Завод коллективының тырышлыгы югары бәяләнде. КПССның XXVII съезды көннәрендә заводка Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, ә миңа, директор буларак, Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Бу бит — бик зур ышаныч, аны аклау да җиңелләрдән түгел. Барыннан да бигрәк үзгәртүләр җәелдереп җибәрү, кешеләрнең фикерләвенә бәйле борылышка ирешүләр кыен булачак. Хәтта җаваплылыкны тулысынча тою, үзгәртүләрнең кирәклеген аңлау гына да җитми — җиң сызганып эшләргә кирәк. Алда, катып калган ысулларга, еллар буе ияреп килүче кимчелекләргә каршы, оештыру эшләрен тамырдан үзгәртеп кору өчен, кискен көрәш көтә.

Мин боларны якын киләчәктә, иртәгәдән башланырга тиешле эшләр рәтенә кертәм. Әмма бүгенгесенә ирешү өчен дә коллективка шактый тырышырга туры килде бит — сынатмады. Шул тәҗрибәгә таянып, кирәк чакта безнең завод эшкә тагын да гайрәтләнебрәк алыначак. «Кирәк. Шунсыз булмый!» Әнә шул төшенчәләр — безнең төп этәргеч. Мин аларны һәрчак ишетеп торам: башта туган йортта, мәктәптә, институтта, аннары эштә, заводта, министрлыкта... Башта, ихтыярсыздан, аны-моны уйлап тормастан буйсынасың. Соңрак тирәннән аңлау килә. «Кирәк!» дигән нәрсә алга баруыңны, үсүеңне тәэмин итүче серле көчкә әйләнә. Мин һөнәр сайлавымда да шул «кирәк»легенең тәэсирен нык тойдым бугай. Елга техникумына укырга китәргә җыенгач, әтием дә каршы төшмәде:

— Бар алайса... Капитан бул! — диде.

Үзе минем омтылышны хупламый. Әллә каян күренеп тора. Аның, әлбәттә, мине үз яныннан, җир, икмәк тирәсеннән еракка җибәрәсе килми иде. Шулай да кырт кисеп, кирегә үгетләп маташмады.

Мин аның фикерен чамалый идем инде: «Бел, улым, безнең нәселнең төп һөнәре — кулындагы эше. Өмет тә, таяныч та шул безнең...» Минем исә кулга гына ышанып каласы килми, белем дә тупларга кызыгам. Җиденче классны бетерүгә техникум турында хыялланыуым шул теләгем нәтиҗәсе булгандыр инде.

Аннан соң күп еллар узды. Инде үзем дә әти генә түгел, «бабай» булдым. Барыбер әтием, аның зирәк киңәшләре сагындыра. Үзлегеннән механика серләренә өйрәнеп, авылда Оста Зөфәр дигән даны чыккан кеше иде ул. Герой исеме бирелгән көннәремдә аеруча юксындым мин аны. Бүген дә бик кирәк булыр иде ул миңа. Заводыбыз өр-яңа үсеш чорын кичерә. Әтиемнең бер файдалы киңәше мең алтынга алыштыргысыз булыр иде дә бит...

Үткәндәгеләрне уйлый башласаң, өлкәннәрнең урынлы күрсәтмәләрен тагын да зуррак бәялисең икән ул. Мине 1965 елда директор итеп билгеләделәр. Инде тәҗрибәм дә җитәрлек кебек. Шулай да бөтен җаваплылык үз өстемә төшкәч, эшкә яңа гына тотынган кебек хис итә башладым. Җыелышларда кешеләрне ихлас күңелдән сөйләштерә алмый интектем. Югыйсә моңа кадәр мастер, смена җитәкчесе, завод парткомы секретаре булып эшләдем бит инде. Ә менә коллективның активлыгына ирешә алмыйм гына бит! Нишләргә дип баш ватам, ник болай бу?

Элекке җитәкчелеккә генә гаеп ташлыйсым килми. Бөтен кимчелекләрне заводның үткәненнән генә эзләү бөтен эш алымын ялгыш юлга кертеп җибәрергә мөмкин. Киресенчә, безнең завод бервакытта да начарлар исәбендә йөрмәде. Мине директор итеп билгеләгәндә исә аның икенче яшьлеге башланып китте кебек. Цехлар үзгәртелә, җиһазларның яңалары урнаштырыла иде. Кешеләрем генә, барысына битараф карап, уэкка үтте. Берсендә түзмәдем:

— Сез ник авызыгызга су капкан кебек утырасыз соң? — дип, баш белгечләремә аерым мөрәҗәгать иттем.

Кемдер:

— Нигә? — дип, үзалдына сорап куйды. — Барыбыз өчен дә сез сөйлисез бит. Каршы төшәргә ярамый. Ни кушсагыз, шуны үтәрбез.

Аның сүзләренә бәйләнер урын юк. Кешеләр шуңа өйрәтелгән иделәр инде. Мин үзем дә шундыйга әйләнгәнмен түгелме? Үзем кешеләр белән, чыннан да, ихлас күңелдән сөйләшәмме? Үзгәрешне, һичшиксез, үземнән башларга!

Миннән алда эшләгән директор — заводны Бөек Ватан сугышы елларында җитәкләгән кеше. Аңа җиңелрәк булгандыр дияргә тел әйләнми. Алтмышынчы елларның мәшәкате исә икенче төрле кыенлыкларга бәйле иде. Экономикада торгынлык. Үзгәртеп корулар өчен «югары»дан рөхсәт кирәк. Белгечләр тегеләй дә, болай да иткәләп карыйлар, төрле тәкъдимнәр белән дә күтәрелеп чыгалар, дәррәү хуплау булмагач, күп башлангычлар ярты юлда кала иде. Әле хәзер дә, үзгәреш, кискен борылыш, тизләнеш кебек яңалыклар көн тәртибенең үзәгенә куелгач та, бик күп мәсьәләләрне иске эзеннән чыгару шактый кыен. Әйтик, хуҗалык җитәкчеләренә хезмәткә түләү өлкәсендә киң мөмкинлекләр бирелә. Шул ук вакытта әлеге мөмкинлектән файдалану юлында мең төрле киртәгә очрыйсың. Җай эзләп, күпме вакыт әрәмгә китә. Күп очракта, Мәскәүгә бармыйча хәл итә дә алмый каласың. Бусы әле хәзер шулай. Ә теге чакта?!

Дөресен генә әйткәндә, без ул елларда экономиканың нечкәлекләренә төшенүне кирәксенми дә идек. Җитештерү мөнәсәбәтләре шул дәрәҗәдә торгынлыкка килеп терәлгән иде ки, без инде аңа тәмам ияләнгән, ниндидер мәсьәләне мөстәкыйль рәвештә хәл итү турында уйлый да белми башладык. «Бәлки ул елларда белгечләрнең фикерләү дәрәҗәсе сай булгандыр?» — диярсез. Юк, сугыштан соң хезмәт юлына баскан беренче буын белгечләрне омтылыш, якты хыял — теләсә кемне көнләштерерлек иде ул! Алар янында иңгә-иң торып Совет властен үз көчләре белән яулап алган, илне фашистлардан коткарган өлкән буын да эшли иде әле. Шунлыктан без һәр адымыбыз-

ның хаклыгына, һәр күрсәтмәнең изгелегенә тирәннән ышандык. «Совет иленеке — димәк, бик яхшы!», «Куып тотабыз һәм узып китәбез!», «Бишьеллыкны — дүрт елда!», «Күбрәк, тизрәк, арырак!» кебек өндәмәләр безне, чыннан да, югары җитештерүчән эшкә рухландыра иде.

1902 елда туган, завод салу эшен җитәкләгән, соңыннан шунда директор булган коммунист Федор Васильевич Егоровның һәр адымы яшьләргә менә дигән үрнәк иде. Революцион көрәш юлы узган, Татарстанның җаваплы эшләрен җитәкләгән кеше ул. Егерменче еллар коммунисты.

Заводның нигезен салуда ук катнашкан икенче фидакарь кешебез — Александр Кричевец. Ул 1916 елда ук, хәрби хезмәттә чакта, империалистик сугышка каршы пропаганда алып бара, большевиклар партиясе сафына кабул ителә. Безнең заводны салудагы каһарманлыгын искә алып, аңа радиоалгыч, велосипед, хәтта җиңел автомашина бүләк итәләр. Чорына күрә гаҗәп зур бүләкләр болар. ТАССРның 15 еллыгында Александр Кричевец Татарстан Үзәк Башкарма Комитетының Юбилей сессиясенә делегат итеп сайлана.

Заводта мондый ветераннар күп иде әле ул чакта. Алар белән бер сафта хезмәт итү яшьләргә үзе бер бәхет булып тоела һәм ялкауланып ятарга һичничек тә юл калдырмый.

«Күбрәк булсын!» — ди-ди, ашыгып эшләгәндә, без, кызганычка каршы, хаталарны да байтак ычкындырганбыз. Илне индустрияләштерүне тизләтү өчен, мәсәлән, һичнинди исәбен-фәләнен алып тормастан, яңарту хакында уйламастан, күпме урманнарны кырганбыз. Аны завод-фабрикалар салуга гына түгел, валюта табу өчен, чит илгә сатарга да бихисап кискәнбез. Профессор Лебедев ысулы белән синтетик каучук ясау да шуңа охшаш. Шул чакта ук каучукны нефть-химия чималыннан ясау алымы да билгеле иде бит. Кызганычка каршы, безнең илдә андый чимал бирүче комбинат булмаган. Элекке Россиядән безгә нинди мирас калганлыгы мәгълүм — йөзләрчә аракы заводлары...

Мин үзем һәрчак «гайре табигый» хезмәт турында хыяллана идем. Шул хыял мине техникумнан соң химия-технология институтына китерде. Химиянең серле дөньясы «гайре табигый» булып тоела иде. Әмма институтны тәмамлап, әлеге заводыбызның ремонт-механика цехына мастер булып килгәч, бер мәлгә аптырый калдым. Цехтагы барлык җиһазлар тәмам искереп беткән. Һәм нәкъ шул, бер караганда, кара кайгыга салырга тиешле хәл безгә... дан-шөһрәт китерде. Без цехны өр-яңадан төзәтергә тотындык, бу башлангыч коллективны үзеннән-үзе бөтен заводның игътибар үзәгенә алып керде. Директорыбыз Михаил Поздняков хәтта кайбер участоклардагы эшне туктатып торырга, тулысынча реконструкцияләргә мөмкинлек тудырды. Ул елларда мондый тәвәккәллек бик сирәк җитәкчеләргә хас сыйфат иде. Минем өчен, яңа гына эшкә тотынган яшь инженер өчен, моннан да шәбрәк мәйданны кайдан табар идең?! Мине инде төзәтүләр генә түгел, заводның эш ысулы да борчый башлады. Ни өчен без, ил азыктөлеккә шулкадәр мохтаҗ чакта, икмәк, бәрәңге, чөгендер спиртыннан файдаланабыз? Берничек тә бу бөлдергеч ысулдан котылып булмый микәнни? Китапларга, фәнни эзләнүләргә кереп чумуымны тоймый да калдым.

Безгә химикларның яңа буыны, үз республикабызда әзерләнгәннәре килде. Арадан Вениамин Григорьевны (ул соңыннан «Резинотехника» берләшмәсенең генераль директоры булды, аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде), Рафаэль Абдрахманович Каргинны (хәзер ул — Казандагы көнкүреш химиясе заводы директоры), Олег Островны (озак еллар «Оргсинтез»ның баш инженеры булып эшләде) күрсәтергә мөмкин. Институттан инженерлык дипломын алып чыксак та, бу һөнәрнең чын осталары итеп безне завод тәрбияләде. Без моңа бик шат идек, әмма күп тә үтмәде, инженерлыкның кыйммәте кими башлады.

Ник? Ничек болай булды соң ул? Без хәзер, хезмәттә тизләнеш, үзгәреш таләп ителә торган яңарыш чорында бу сорауларга җавап табарга тиешбез. Шул җәһәттән вузларда да үзгәртеп корулар көтелә. Миңа калса, үз эшен яратып, аны ослылап башкаручы инженерның бәясе бервакытта да кимемәячәк. Абруе төшкән инженер гаепне үзеннән эзләсә, мөгаен, нәтиҗәсе бик тиз сизелер иде. Бәхеткә, эшли башлаган чорда заводның өлкәннәре безгә бик нык ярдәм итте. Яшь белгечләрнең баш инженер раслаган махсус план белән эшләүче советы бар иде. Белгечнең формалашуында, аның нигә сәләтле икәнен ачыклауда бу советларның роле бик мөһим иде. Кызганычка каршы, соңгы вакытта бу роль кечерәеп калды кебек.

Безнең заводта һәр хезмәткәрнең ниндирәк перспективаны күздә тотып иҗат итүе искә алына. Әгәр ул политик һәм фәнни-техник яктан өлгергәнлеген раслый икән, үзе теләп, җаваплы эшкә куелырга мөмкин. Андыйларның аерым исемлеге булдырыла һәм, кирәк чакта, күчерелә дә куела. Бүген заводтагы цех начальнигы һәм аннан да югарырак урыннарда эшләүче җитәкчеләрнең барысы да диярлек — коллективның күз алдын-

да үсеп, өлгереп җиткән хезмәткәрләр. Минемчә, бездәге бу тәртип бүгенге көн таләпләренә бигрәк тә кулай.

Икенчедән, тизләнеш юнәлешендәге адымнарыбызны кызулату өчен без һәр кешенең эшкә уңай өлеш кертердәй тәкъдименә юлларны ачтык. Фәнни-техник алга китү башкача була да алмый. Һәр яңа уйлап табу яки ачыш мөмкин кадәр тизрәк эштә дә кулланылырга тиеш. Узган бишьеллыкта без уйлап табучыларга карата булган шундый игътибарлы мөнәсәбәте аркасында 20 миллион оттык.

Завод илленче еллар азагында башланган үзгәртеп коруларны җитмешенче еллар да тәгәлләүгә якынлашты. Әмма җитештереләчәк каучукның барыбер шактый кыйммәткә төшәчәге, сыйфатның да, хезмәт җитештерүчәнлегенең дә сизелерлек үсмәве билгеле иде. Чимал өчен әле һаман азык-төлек спиртының да байтак кулланылуыннан котыла алмадык. Дөрес, планнарыбыз үтәлә, әмма отышлырак эшләргә дә мөмкинлекләр барын тоеп тору коллективка тынгылык бирми иде.

Монда инде үзгәртеп корының нәкъ менә КПСС Үзәк Комитетында күтәрелгән чараларына таянырга туры килә. Төзелешендә, технология-фәләнендә генә түгел, кешеләр аңында да, үзара мөнәсәбәтләрендә дә, хезмәткә карашта да үзгәрергә!

Татарстан — Зур химия республикасы. Алдыңны-артыңны карамыйрак торсаң, хәзер үкчәңә басалар. Соңгы елларда киң колачлап иҗат итүче Түбән Кама нефтехимикларын әйткән дә юк. «Тасма» производство берләшмәсе дә, Менделеевскидагы завод та, башкалар да, төп җиһазларын яңартып, кызу адымнар белән алга киттеләр. Кадрлар мәсьәләсе тагын да четерекләнеп калды. Бу хәлләрнең барысы да, партия өйрәткәнчә, киңлеккә түгел, тирәнлеккә йөз тотканда гына хезмәтне интенсификацияләү барабәренә генә чишелергә мөмкин. Моңа ирешү өчен без бөтен коллективны уйландырырга, һәркемнең гомуми эш өчен янып-көеп иҗат итүен булдырырга тиешбез. Димәк, заводның яхшы һәм яман яклары барысы да коллективка ап-ачык күренеп торачак. Элек болай түгел иде. Күп нәрсәне матур сүз белән каплабрак калдырырга тырыштык. Мин директорлыгымның беренче елларында бик пассив үтә торган киңәшмәләрнең дә хикмәтенә хәзер генә төшенәм кебек. Үзем ачылып бетмәгәнмен икән бит. Ачыктан-ачык сөйләшү берьяклы гына була аламыни?! Кешеләргә дөресен әйтеп бирү кирәк, уңышны да күреп торсыннар, җитенкерәмәгән яклардан да хәбәрдар булсыннар.

Җиңел промышленность предприятиеләреннән аермалы буларак, безнең эштә заказчының таләпләрен «өйрәнү» бик хикмәтле, чөнки безнең төп заказчының шәхси йөзен күрү мөмкин түгел. Ул — фәнни-техник прогресс. Өзлексез үсеп, үзгәреп тора ул. Эш дәвамында исә безгә ун меңнәрчә оешмалар, предприятиеләр белән элемтәгә керергә туры килә. Хәзер, шөкер, бу мөнәсәбәтләргә кагылышлы барлык килешү-планнарыбыз да тулысынча үтәлеп бара. Хуҗалык кешеләре моның ни икәнен яхшы аңлый. Бары тик килешү-планнарын тәгәл үтәгәндә генә без экономик мөстәкыйльлеккә ирешә алабыз һәм алдагы бурычларны җиңүгә ышаныч белән карыйбыз.

Эштә сизелерлек алга китүне тәэмин итү өчен, без планлаштырудагы һәм производство үсешен экономик стимуллаштырудагы кимчелекләребезне бетерергә алындык. Хуҗалыктагы механизмны җайга салуда, хуҗалык исәбендәге мөнәсәбәтләрне ачыклауда бөтен ресурсларның тәгәл хисабын булдыру зур роль уйнады. Исәп-хисаплар һәр цехта, һәр бүлекчәдә ясалды. Моның белән без үзкыйммәтнең төшүенә ирештек. Әмма сыйфат ягы аксый иде әле, техник яктан алга китү дә әллә ни сизелмәде. Болары бездән төрледән-төрле техник-оештыру чаралары үткәрүне, фән яңалыкларын кыю үзләштерә баруны, технологиядә һәм чимал мәсьәләсендә үзгәрешләр кертүне таләп итә иде. Бу — нигездә, комплекслы төстә һәм өзлексез алып барылырга тиешле эш. Моңа бары тик ныклы дисциплина, максатлар берлеге, гомуми омтылыш белән генә ирешеп була. Соңгы тырышлыгыбыз нәтиҗәсендә безгә СССРның һәм ВЦСПСның Дәүләт стандарты Дипломы бирелде. Ул диплом тәрдәш предприятиеләр арасында сыйфат ягыннан иң күркәм җиңүләр өчен генә тапшырыла. Еллар буе көтеп алынган бу җиңүдән соң завод кешеләренең ничек сөенгәнен белсәгез иде!

Мондый адымнар кешеләрнең күңелен күтәрә, ә күңеле күтәренке хезмәткәр белән нинди эшне дә башкарырга була. Җиңүләрдә аның да өлеше барын күрсәтеп бирергә генә онытма!

Берсендә кызыклы тәҗрибә үткәрдек. Яңа төр каучук чыгаруны үзләштерергә тиеш идек. Эшне тизләтүдә төсле телевизор ярдәм итте. Ничек дисезме? Эшчеләргә ике төрле телевизор карарга тәкъдим ясалды. Берсе шәп күрсәтә, икенчесе — тонык. Белгечебез:

— Шәп күрсәтә торган телевизорда, — дип аңлатып бирде, — герметизация материалы итеп без ясарга тиешле яңа төр каучук файдаланылган.

Тәэсире искиткеч шәп булды. Соңгы вакытта кешеләргә уңай йогынты ясардай чаралардан отышлы файдалана башладык без. Бригада подряды да кызыклы яңалык булды дияргә мөмкин. Хәзер бу ысул планлаштыру системасын, түләү тәртибен, социалистик ярышлар алымын да үзгәртеп коруны таләп итә. Аның тәрбияви әһәмияте дә

бик зур, кешеләрдә коллективизм рухы, җаваплылык тою артты. Бу ысул белән эшләүчеләр арасында хезмәттә катнашу коэффициенты тирәсендә бәхәсләр булып алды. Дөрес, бәхәсле яклары бар аның. Әмма без бригадаларның хезмәт хакын «тигезләү» юлына баса алмыйбыз. Шулай да уйланасы нәрсәләр күп әле. Бригада подрядында эшләсә дә, ялкауланып йөрүчеләр җитәрлек. Ул үзенең уртача хезмәт хакын алачагына ышанган. Ялкаулыгын каплар өчен: «Миңа артыгы кирәкми лә!» — дигән була ул. Бригаданың бик тырыш эшчесе дә аннан әллә ни артык ала алмый, аерма 20-30 сум чамасы гына. Бу хәлнең яхшы эшчегә дә кире йогынты ясавы ихтимал. Шуңа күрә бригада подрядында эшләүче тырыш кешеләрне башка яктан да хупларга тиеш булабыз. Эзләнергә, уйланырга кирәк.

Менә шулай. Мин үземнең беренче эшли башлаган цехымдагы төзәтү, үзгәртеп коруларга кереп чумган идем, бүгенге зур борылыш агымына килеп җиткәнемне сизми дә калдым кебек. Цехлар да яңартылды, юыну бүлмәләре, ял итү мәйданнары, вахта автобуслары булдырылды. Хәзер ярдәмчел авыл хуҗалыгы бүлекчәбез дә бар. Монысы эшчеләрне ит, сөт, май кебек ризыклар белән сыйларга ярап куйды. Санаторий-профилакториебыз, Идел буенда һәм Мәскәү янында ял итү урыннарыбыз бар. Заводта көнкүреш хезмәте күрсәтү йорты ачтык. Янында гына кибет, аптека, «Союзпечать» бүлекчәсе, саклык кассасы, элемтә бүлеге эшли. Балалар учреждениеләре, тулай тораклар, квартиралар белән тәэмин итү дә, акрынлап булса да, хәл ителеп килә. Барысы да кешеләребез хакына, ил өчен башкарыла. Мин ышанам: безнең коллектив моңа бик шат һәм ул алга куелган барлык бурычларны уңышлы башкарып чыгарга үзендә көч табачак.

**Альберт Хәсәнов**

# ЙӨК АТЫНА — СОЛЫНЫ КҮБРӘК!..

Берәр дәүләтнең экономик хәле турында төпле бер мәгълүмат булдырасың килсә, син аның елына күпме корыч коюын гына белеш. Шуның белән бары да аңлашыла. Бу сан сиңа чиксез күп нәрсәләр турында сөйләр: әлеге ил елына күпме трактор чыгара, суга ничә кораб төшерә, культура сарайларын, музейларны, стадионнарны ни кадәр төзи — барысы турында да әйтеп бирер. Аңлашылса кирәк, корычны күп койган ил алга киткәннәрдән санала, аз койганы, димәк, бичара, тормышның очын-очка ялгап, чак-чак көн күрә. Заманның таләпләре шундый. Ә менә корыч коярга, башка матдәләр белән беррәттән, табигатьтә сирәк очрый торган металларның берсе — ванадий да кирәк. Әгәр ванадий кушмасаң, ул корыч инде корыч түгел, ә арыш камыры, чалгың — үләнгә, пәкең чәчкә капмый. Ә башка эш коралларының, станокларның, экскаватор-тракторларның ныклыгы турында сөйләп торасы да юк. Ванадийны аз гына кушу да искерүне, күгәрүне белмәс корыч китереп чыгара. Кибетләрдән без ятатып ала торган лезвиеләрнең составында да ванадий бар. Алар белән кырыну ир-егеткә аерым бер ләззәт бирә. Сакалыңны ялап кына ала, ун яшькә яшәреп киткәндәй буласың. Хикмәт — әлеге шул ванадийда. Ванадийның үзен исә битум составыннан алырга мөмкин икән. Нигә соң әле мин ванадий һәм битум турында сүз куертам? Эшнең сере менә нәрсәдә. «Кара алтын» дип зурлап йөртелә торган нефтьнең бик күп төрле матдәләргә бай булуын, алардан әллә ничә төрле чимал алынуын барыбыз да беләбез. Әмма киләчәктә нефтьнең төрле металлар алу өчен дә төп чыганак булачагы сәеррәк яңгырый.

Хәер, нефть составында төрле металларның булуын галимнәр моннан йөз еллар элек үк белгәннәр. Алар арасыннан аеруча А. Лидов, В. Марковников, В. Оглобин бу өлкәдә төпле тикшеренүләр алып барып, Әзербайҗан промыселларында чыгарылган

нефтьне кат-кат яндырып карагач, аның көләндә байтак микъдарда тимер, натрий, алюминий, бакыр, көмеш булуын күргәннәр. Фәнни хезмәтләрендә шушы ачышны раслаганнар. Ә безнең гасырның егерменче еллары башыннан галимнәр бу металларны нефтьтән аерып алу мөмкинлекләре турында уйланырга тотынганнар. Галимнәрдән А. Виноградова һәм Г. Бергман әле 1935 нче елда ук «СССР нефтендә һәм битумында ванадий» дигән кызыклы хезмәт бастырганнар. Әле сугыш елларында ук Л. Гуляева «Урал-Идел буе нефтендә ванадий, никель һәм бакыр» дигән гаять зур фәнни әһәмияткә ия хезмәтен чыгара. Ләкин гомер-гомергә фәнни ачышлар белән аларны халык хуҗалыгы максатларында куллана башлау арасында озын юл сузыла. Элек тә шулай булган, кызганычка каршы, еш кына безнең көннәрдә дә шулай. Әйтик, Мәскәүдәге уйлап табулар һәм рационализаторлар комитетында кабул итеп алынган һәм өстенә «дөрес» дип мөһер сугылган тау-тау ачышлар тормышта файдалану чиратын көтә. Аларның тиз генә тормышка ашмавына гадәттә ике нәрсә сәбәпче: җәмгыять галимнең фантастик дәрәҗәдәге ачышын бәяләрлек дәрәҗәгә күтәрелмәгән булуы мөмкин. Яки җәмгыятьнең чамасы чикле, ачышны гамәлгә ашырырга көче-куәте җитеп бетми. Битум составындагы сирәк очрый торган металларны аерып алу да шушы мәсьәләләргә барып терәлә. Башта бу эшкә «алты биреп, бишне алу» дип карыйлар. Хәзер исә бу мөмкинлекләрне башкачарак бәяләргә туры килә. Шуны әйтик, Америка Кушма Штатлары ике меңенче елда, ванадийга ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен, бу металлны коточкыч кыйммәткә төшереп, чит илләрдән сатып алырга мәҗбүр булачак. Әгәр дә аның инженерлары, технологлары ванадийны нефтьтән аерып алуны үзләштерсәләр, ул чакта АКШ бу металлны хәтта бөтен дөньяга җитәрлек күләмдә чыгарачак.

Нефть составында, ванадийдан тыш никель, хром, алтын, тимер, марганец һәм башка полиметаллар бар. Шулаен шулай. Ләкин, кызганычка каршы, бу металлар нефтьне яндырганнан соң коела торган көл-корым белән я чүплеккә төшә, я һавага оча. Дөрес, бу металларны әрәм-шәрәм итмәү өлкәсендә эзләнүләр бара. Канада, АКШ, Швециянең нефть продуктларын ягучы станцияләрендә бу металларны аерып торучы махсус җайланмалар куела башлады. Бездә дә беренче адымнар ясалды. Горький өлкәсенең Дзержинский шәһәр электростанциясендә шушындый махсус блок сафка бастырылды. Бу блок нефтьне яндырганда калган ванадийны җыеп, туплап, чистартып тора.

Әмма болар барысы да беренче адымнар гына. Егерме беренче гасырда битум составындагы практик әһәмияткә ия булган бу металларны аерып ала башлаячаклар.

Ярар, болары шулай да булсын, ди. Ә соң битумның үз запаслары ничегрәк? Промышленностьның аңа баглаган өметләрен канәгатьләндерә алырмы? Дөресен әйтсәң, моңарчы аның запаслары турында ныклап торып уйланган кеше дә булмады. Беренчедән, аның промышленность өчен шулай кирәклеге исәпкә алынмады. Икенчедән, битум үзе гаять «кире беткән» нәрсә, җир өстенә чыкмаска теш-тырнагы белән карыша, шул сәбәптән аңа моңарчы гел кул селкиләр иде.

Инде минем битум белән кызыксынуымның сәбәбенә килик. Сәбәбе аның бик гади. Битумның, ягъни, кашык белән каерып, балта белән китеп ала алмастай куе шушы «кире беткән», әмма бик кирәкле массага Татарстан җире дә бик бай. Девон нефте төсле алай тирәндә дә ятмый ул. Битум катламнары туксан, йөз метрлар тирәнлектән үк башлана. Хәтта нибары кырык-илле метрлар гына аста яткан җирләре дә бар. Татарстанда күп тә ул. Галимнәр тарафыннан төзелгән белешмәләрнең берсендә аның запаслары бездә җиде миллиард тонна дип билгеләнә. Икенчесендә, унбиш миллиард диелә. Өченчесендә, безнең төбәккә Ульяновск һәм Куйбышев өлкәләрен дә кертеп, битум запаслары егерме бер миллиард тонна дип билгеләнә. Җир куенындагы хәзинәнең күләмен билгеләү — җиңел эш түгел. Бер тоннага кимрәк, яисә артыграк күрсәтүдән әллә ни зур зыян юк, була гына күрсен! Эш башка нәрсәдә: аны җир өстенә ничек чыгарырга? Галимнәр күп еллар рәттән менә шул мәсьәлә өстендә баш ваталар. Нефтьнең җиргә, катламга, нефть үткәргеч торбаларга сыланыш көчен, каршылыгын билгели торган махсус бер берәмлек бар. Ул берәмлек сантипуаз дип атала. Әйтик, Ромашкино ятмасыннан чыгарыла торган нефтьнең сыланыш көче ике-өч сантипуазга тигез. Ә менә Лениногорск районы Мордва-Карамалка ятмасындагы битумның кирелек-үҗәтлеге ике-өч мең сантипуаз. Лениногорск районы Юлтимер авылы тирәсендәге битумның, өскә чыкмыйм, күнеккән җиремнән бер адым да кузгалмыйм, дип карышуы бер миллион сантипуаздан артып килә. Имәндә икән чикләвек, дигәндәй, бөтен мәсьәлә дә менә шунда. Битумның шулай карышуын җиңәргә, аны «алдарга», ай-һай, нинди серле әмәлләр, хәйләләр кирәктер?! Алай да геологлар, технологлар өметләрен җуймыйлар...

КПСС Үзәк Комитеты секретаре Егор Кузьмич Лигачев безнең якларда булган чагында Бөгелмәнең ТатНИПИ коллективы белән дә очрашты. Институт галимнә-

ренең битум ятмаларын үзләштерү өлкәсендә башкарган конкрет эшләрен, эзләнүләрен аеруча хуплады.

Безнең Бөгелмәдәге нефть галимнәре институтында «Җир астыннан кыенлыклар белән чыгарыла торган углеводород ятмаларының гидротермодинамикасы бүлеге» әле 1962 елны ук оеша. 1972 елда «Битумнар бүлеге» төзелә. Башта аңа геология фәннәре кандидаты Айрат Фаткуллин җитәкчелек итә. Шул чорда ук, геологик яктан перспективалы саналган Мордва-Карамалка битум ятмасында тәҗрибә участогы булдырылып, беренче дистә скважиналар бораулана. Айрат Хикмәтович хәзер мәрхүм инде. Ул башлап җибәргән фәнни эзләнүләрне аның шәкерте һәм фикердәше фәннәр кандидаты Мөгамбәр Мусин дәвам итә. Галимнәрнең алга куйган бурычлары кыеннарның берсе. Өскә чыкмыйм дип миллион ярым берәмлек көч-куәт белән тартышкан битумны ничек хәрәкәткә китерәсең? Аның белән ничек уртак тел табарга? Әйтик, Канадада битумны җирнең өске катламын ачып ташлап, ягъни ачык ысул белән, табалар. Канада — үзегез беләсез, нык алга киткән капиталистик ил. Үз кырларында, үз басуларында үскән бодай, кукуруз белән кайбер башка илләрне дә туендырып тора. Әлбәттә, җир бик кадерле һәм кыйммәтле монда. Битумлы җирнең туфрагын алар башта бер читкә өеп торалар. Катламның битумын алып бетергәч, туфракны кире үз урынына салып, тигезләп, өстенә агач утыртып, парк ясап баралар. Хөкүмәт участокларны тик шундый шартларда гына бирә. Бездә атаклы Чупай ташыннан үз вакытында Әлмәт, Лениногорск, Җәлил шәһәрләрен салдылар, күпме күперләр, йөзләрчә һәм йөзләрчә километр юллар төзелде. Ә хәзер Чупай таш карьерын күрсәгез иде. Заманында төз имәннәр, миләш, балан, чикләвек куаклары үскән матур тау битләре коточкыч гарасат узган хәрабәләрне хәтерләтә. Карьерны күмеп, урман утырту берәүнең дә башына килгәне юк. Кызганыч бу, бик кызганыч.

Битумны бу ысул белән алу гаять кыйбатка төшәчәк. Әмма чималы да бик кадерле бит. Кирәгең, хаҗәтең шуңа барып терәлсә, бер хәлең юк, ачык ысул белән дә чыгарырсың. Битум өстәрәк ятканда бу мөмкин әле. Ә менә дүрт йөз метрларга яки аннан да тирәндә булса, бу ысулны куллануны күз алдына да китерү мөмкин түгел. Сүз гади кое турында гына бармый бит. Дүрт йөз метр тирәнлегендәге күл, диңгез дигән сүз бу. Аны казу өчен нинди техника, нинди экскаваторлар кирәк булачак?!

Мәсьәләне уңай хәл итүдә Бөгелмә галимнәре өч юнәлеш сайлап алдылар. Беренчесе, катламга нинди дә булса актив сыекча, кислота кудырып битумны хәрәкәткә китерү. Сүз, әлбәттә, шушы ысулны сынап карау турында гына бара. Ягъни бу күп төрле тәҗрибәләрнең берсе генә. Аны практикада куллану четерекле. Катламнан бер тонна битумны чыгару өчен анда ничәмә тонна кислота, я башка төр актив сыекча кудырырга туры киләчәк. Ярар, битумның миллион берәмлеккә тигез үҗәтлеген җиңеп, аны скважиналардан өскә таба агарга күндердең дә, ди. Ә аска кудырган кислота әйләнә-тирә мохиткә, инеш-чишмәләргә зыян китермәсме, аларны да агуламасмы соң? Битум катламнары, әйткәнемчә, җир өстеннән әллә ни тирәндә ятмыйлар. Биредә бик сак эш итәргә кирәк. Каш ясыйм дип, күз чыгару очраклары нефтьчеләр арасында моңа чаклы да булгалады. Ниндидер бер булдыксыз, мәгънәсез бораулау мастерының нефть скважинасын бораулаганда тиешле технологик режимны тәгәл үтәмәве, скважинага төшерелгән колонна артындагы бушлыкны цементламавы аркасында Кислинка авылы янындагы барлык чишмәләрдән керосин тәме килә башлаган иде. Юынырга да, чәй эчәргә дә суны күрше авылдан машина белән ташып дүрт-биш ел азаплангач, халык туган-үскән җирен ташлап китәргә мәҗбүр булды.

Бөгелмә галимнәренең эзләнүләр алып бара торган тагын бер юнәлеше — катламны җылыту, ягъни битум катламына ут төртү. Шул рәвешчә катламда температура күтәрелергә тиеш, битум да скважина торбасы буенча өскә агарлык дәрәҗәдә сыегаерга мөмкин. Идея бар, яши. Галимнәр тәҗрибәләрен дәвам итәләр.

Өченче юнәлеш — забойга өстән кайнар һава һәм кислород кудыру. Бу ысул аеруча киң кулланыш тапты. Бөгелмә галимнәре, геология фәннәре кандидаты Роберт Фазлыев, техник фәннәр кандидаты Владимир Кондрашин, Казан авиация институты инженерлары белән берлектә, битум өчен бораулаган скважина авызына көчле авиадвигатель китереп урнаштырдылар. Бер баштан чак кына көйрәтеп җибәрелгән битум катламына әлеге куәтле двигатель ярдәмендә кайнар һава агымы һәм кислород кудыра башладылар. Нәтиҗәдә катламдагы температура биш-алты йөз градусларга кадәр күтәрелә. Катламдагы бер кубометр җирдә унбиш-унсигез процентлар чамасы битум бар дип исәпләнелә. Бу инде бай ятмадан санала. Температураны шул дәрәҗәгә күтәргәч, битум мәңгелек йокысыннан, ниһаять, уяна һәм скважина тамагына таба ашыга. Шушы ысул белән 1979 елдан башлап, әлеге участоктан уналты мең өч йөз тонна чамасы битум чыгардылар инде. Димәк, битумны мәңгелек йокысыннан уятырга мөмкин! КПСС Үзәк Комитеты секретаре Егор Кузьмич

Лигачев безнең якларда булганда Бөгелмә галимнәренә нәкъ менә шушы җиңүләре, уңышлары өчен зур рәхмәт белдерде.

Киң тармаклы халык хуҗалыгының әлеге битум дигән хикмәтле чималга ихтыяҗы елдан-ел, көннән-көн үсә бара. Әллә ни ерак киләчәккә күчермичә, бүгенге көн мәнфәгатьләреннән чыгып карагандa да, битум ул — бер дигән ягулык, торбалар өчен яхшы изолятор, төзек юллар салу өчен, бер дигән асфальт. Шушыларны истә тотып, узган елны Лениногорскида нефть-газ чыгару буенча «Татнефтебитум» тәҗрибә идарәсе төзелде. Мордва-Карамалка битум ятмасында хәзер барлыгы йөздән артык скважина борауланды. Яңа оешкан идарә коллективы әнә шул скважиналарга хезмәт күрсәтә. Идарә начальнигы Николай Ефимов, баш инженер Михаил Потемкин, баш геолог Васил Хөсәенов белән берлектә битум промыселында мин берничә мәртәбә булдым. Һәр килүдә бу яңа һөнәргә үз өсләрендә зур җаваплылык сизеп һәм дәрт белән алынган яңадан-яңа кешеләр белән таныштым. Скважиналарга хезмәт күрсәтүче Галия Гарифуллина биредә җиденче елын эшли. Аңа карап торуы үзенә бер ләззәт, уңганбикәнең кулы кулга йокмый. Аның тормыш иптәше Миңлебай Гарифуллин да биредә бораулаучы булып эшли икән. Ирле-хатынлы Гарифуллиннарның исемнәре промыселның Мактау тактасында. Мондый гаиләләр монда байтак. Мөдәррис Сафин — оператор, аның хатыны Сәгыйдә — лаборант.

— Бу гаиләне дә без бәйрәм саен я Мактау грамотасы, я кыйммәтле бүләк белән зурлап торабыз,— дип сөйләде промысел мөдире Миргазиян Шакиров. Ул үзе дә шушы яңа һөнәрнең энтузиасты. «Лениногорскнефть» промыселында яхшы гына эшләгән җиреннән, шәһәрдән җитмеш-сиксән километрлар ераклыктагы битум промыселына җитәкче булып күчә. Промысел, гомумән, тапшырылган эшне җиренә җиткереп башкаручы уңган-булган энтузиастлардан тора дисәм дә ялгышмам кебек. Хисамиев Тәлгать, Әхмәтов Минсалих, Сөнгатуллин Самат, Звонарев Михаил нәкъ менә шундый энтузиастлар. Мондый егетләрсез биредәге кыенлыкларны җиңәрмен димә. Яңа өйгә генә күченсәң дә, беренче кышыңны мәшәкатьле кышлыйсың: я тәрәзәңнән җил өрә, я ишегең ябылып бетми. Промыселда да шул ук хәл. Эшче куллар җитешми, техника искергән. Битумчылар тәэминатның начарлыгыннан бигрәк изалананалар. Чөнки яңа оешкан идарә, яңа промысел хәзергәчә үги бала сымаграк. «Татнефтебитум» идарәсе башта «Татнефть» берләшмәсенә буйсына иде. Бу берләшмәнең, мәгълүм ки, үз мәшәкатьләре дә — муеннан. Аның скважиналары, промыселлары хәзер Себергә үк таралды. Шунлыктан ул яңа йөктән баш тартты. Әле оешу чоры гына кичергән «Татнефтебитум» бөтенләй ятим калды. Ятимлек — тәэминат өлешеннән коры калу, беркаян бер метр торба, бер тотам кабельсез калу дигән сүз. Башка вак-төяк кирәк-яракларны әйткән дә юк. Шактый гына вакыт этеп-төртеп йөрткәннән соң «Татнефтебитум» идарәсен Мәскәүдәге «Нефтеотдача» комплексы карамагына тапшырдылар. Мәсьәлә моның белән генә хәл ителсә иде! Бер метр торба, бер метр кабель табу яңа оешкан идарәдә бүген дә зур проблема. Хәл ителмәгән мәсьәләләрнең очына-кырыена чыгышлы түгел. Әйтик, гади бер эш көне өчен идарәгә кимендә төрле-төрле утыз бер машина кирәк. Идарәгә исә шәһәр автоколонналары тарафыннан нибары унбиш-уналты машина бирелә. Уңган-булган оператор егетләрнең җир куеныннан зур тырышлыклар белән чыгарган битумын да куяр урын юк. Аны әлегә Шөгер битум заводына көннекен-көнгә дүрт «КамАЗ» белән ташып торалар. Нефтьүткәргеч салсалар, бик уңай буласы да... Аралары да әллә ни ерак түгел. Ләкин аның өчен торба табарга кирәк. Анысын каян аласың? Асрамага алган малай хәлендә яшәп, әллә ни югары сикереп булмый. Югыйсә, әүвәл-әүвәлдән акыллы агайлар авыр йөк тартучы атка солыны да күбрәк биргәннәр. «Татнефтебитум» идарәсе коллективы исә, алда торган зур кыенлыкларны җиңә килеп, дәүләт планын айдан-айга арттырып үтәп бара. 1986 елда алар 224 тонна битум чыгарырга дип күтәренке йөкләмә алганнар иде. Лениногорск битумчылары, үз сүзләрендә нык торып, узган елда 260 тонна чимал җитештерделәр.

Битум чыгаруга алынган егетләрнең фидакарьлеге нәтиҗәсе бу. Промыселда катkat булып, мин тик көн авышсынга, кояш батсынга гына йөрүче бер ялкауны да күрмәдем. Ләкин коры энтузиазм белән генә әллә ни ерак китеп булмый. Иөккә, төп тартәгә җигелгән атка солыны күбрәк бирә башларга вакыт. Республикабызда, кыенлыкларны, каршылыкларны җиңеп, индустриянең яңа төре — битум промышленносте туып килә. Аның киләчәге зур һәм өметле. Аңа кичекмәстән тиешле игътибарны юнәлтеп, хезмәт кешесенең эшкә булган дәртен дүрткуллап якларга кирәк!



**И. В. Гәрәев,**
КПССның Зәй шәһәр комитеты
беренче секретаре

# ҮСЕШТӘ, ҮЗГӘРЕШТӘ

Районыбыз тарихы бик ерак гасырларга барып тоташа. Урманы-суы да, иген игәр җире дә булган гүзәл табигатьле бу якларны кешеләр бик күптәннән үз иткәннәр. Биредәге җирләр әле Болгар дәүләте чорларында ук үзләштерелә. Казан ханлыгы чорларында исә шушы җирләр аша Нугай юлы уза, далаларда яшәгән күчмә халыклар белән тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләре алып барыла.

Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, хәзерге Зәй районы җирләренә яңа власть белән, сәүдәгәрләр һәм хәрби башлыклар белән, посад кешеләре һәм рус крестьяннары белән бергә православие дине дә килгән. Ул колониаль эксплуатациягә эләккән рус булмаган халыкны идеология ягыннан «эшкәртү», җирле халыкларны руслаштыру максаты белән христиан динен тарату хезмәтен үтәгән. Православие Россиягә кушылган халыкны патша хөкүмәтенә һәм хаким сыйныфка буйсындыру чарасы, коллыкка, кабалага төшерү чарасы булган.

Шәһәрләр төзү хөкүмәтнең иң мөһим чараларыннан берсе булган. Аларның күбесе крайдагы җирле халык өстеннән рус хакимлегенең хәрби пунктлары буларак төзелгән. Ә кайберләре Кырым һәм Нугай татарлары һөҗүменнән саклану өчен булдырылган. Зәй шәһәренә дә нәкъ шул чакларда, 1653—1656 елларда нигез салынган.

Ул Кама аръягының көнчыгышында, Иделдән башланып, Агыйделгә кадәр сузылган хәрби сак сызыгында крепость итеп торгызылган. Шундый крепостьларга «ышыкланып», Идел буе җирләренә рус кешеләре, «пашенные люди», ягъни игенчеләр күченә башлый. Крепостной изүдән качып, крестьяннар агыла, патша хөкүмәте дәүләт чиген саклау өчен гаскәриләрне күчереп утырта. Иң яхшы җирләрне алпавытлар биләп алган. Аларга Үзәк Россиядән үз крепостнойларын бу якка китерергә рөхсәт бирелгән Зәйгә күчеп килүчеләр казаклар дип аталып, күп кенә ташламалардан файдаланганнар.

1655 елда патша хөкүмәте, «мәңге яшәргә» дип, Смоленск һәм Полоцк шляхталарыннан хәрби әсирләрне Зәй ягына китерә.

1676 елда, башкортлар восстаниесе вакытында, шушы күчеп килгән әсирләр фетнәчеләрне бастыралар. Моның өчен аларга җирдән файдалануда ташламалар һәм өстенлекләр бирелә, ә Зәй бистә дип йөртелә башлый.

Гади халык исә патша властьларының җәбер-золымына түзә алмый, азатлык, ирек турында, җир турында хыялланып яши. 1773 елда Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы әнә шул хыялларны тормышка ашыруда якты өметләр уята.

Ул чорда Көнбатыш Кама аръягында төп административ үзәкләр булып Биләр һәм Зәй исәпләнә. Гасыр урталарына Зәйдә 512 хуҗалык һәм отставкага чыгарылган 932 күчереп утыртылган гаскәри була. Калкулык башына урнашкан крепость агач стена белән әйләндереп алынган. Анда манаралар һәм ату өчен тәрәзчекләр уелган. Баш күтәрүчеләр һөҗүм итеп килгәндә, Зәйдә мең кешелек гарнизон була, аңа капитаннар Мертвецов, Савинич һәм секунд-майор Лопатин җитәкчелек итә.

Зәй янындагы беренче бәрелеш крестьяннарның җиңелүе белән тәмамлана. Ләкин ул Зәйнең алынуын кичектереп тору гына булып чыга. Минзәлә белән Зәй арасындагы барлык авыллар баш күтәрүчеләргә кушылган. Пугачевчылар отрядлары Алек-

сандровка, Аксар, Югары Налим, Ләке, Сухарево һәм башка авылларда. Баш күтәрүчеләргә ясаклы татарлар старшинасы Нагайбәк Әсәнов һәм Аренкул Асеев җитәкчелек итә. Ә Зәйнең үзендә отставкадагы подпрапорщик Богдан Буткевич хәрәкәт итә.

1774 елның 15 январенда баш күтәрүчеләр Зәйгә килеп керә. Гарнизон Нагайбәк Әсәнов һәм Аренкул Асеевка кушыла.

Крестьян сугышының нәрсә белән тәгалләнгәне һәркемгә мәгълүм — патша власте баш күтәрүчеләрдән канлы үч ала. Әмма халык аңында азатлык өчен көрәш уты сүнми дә, сүрелми дә.

Шул ут Бөек Октябрь революциясе елларында куәтле ялкын булып кабына, революция һәм Гражданнар сугышы елларында Татарстанның бу төбәгеннән күп батырлар үсеп чыкты. Коммунистик җыелма батальон политкомиссары, Зәй шәһәрендә совет властен урнаштыруда катнашучы, партия ячейкасын оештыручы И. Я. Горбунов — шуларның берсе. Зәй шәһәрендә совет власте 1918 елның 5 январенда урнаштырыла. Йөз егерме кешедән торган волость Советы, башкарма комитет, президиум сайлана. Президиумдагы алты кешенең дүртесе большевик һәм икесе сул эсер була.

1920 елда волостьта эсерларның «Кара бөркет» оешмасы әзерләгән «сәнәкчеләр фетнәсе» кабынып китә. Партиянең Зәй оешмасы һәм башкарма комитеты членнары, беренче комсомоллар, Брянск, Мәскәү, Петроградтан килгән продотряд һәм Минзәлә өязенең ВЧК отряды сугышчылары «сәнәкчеләр» кулыннан һәлак була.

Бөек Ватан сугышы башлангач, меңнәрчә зәйлеләр фронтларга китә, кулына корал тотып, ил сагына баса. Аларның 4 мең 380 е туган якларына кире әйләнеп кайта алмады, азатлык өчен сугыш кырларында ятып калды. Тыл хезмәтчәннәре фронтка 3 миллион пот икмәк, меңнәрчә пот ит, 3 миллион литр сөт, бик күп күләмдә йон, бал, 400 баш ат бирә. Танк колоннасы төзүгә зәйлеләр 14 миллион 299 мең сум, самолетлар эскадрильясе төзүгә 3 миллион 500 мең сум акча җыялар. Сугышчан батырлыклары өчен районыбыздан ике меңнән артык кеше орден һәм медальләр белән бүләкләнә, Зәй җирендә туып-үскән Г. Ф. Ларионов һәм Н. Н. Майков Советлар Союзы Герое исеменә лаек булалар.

Сугыштан соң районда авыл хуҗалыгы киң үсеш алды. 1956 елда Европада иң зурлардан саналган Зәй ГРЭСы төзелә башлады, 1963 елның 20 январенда ул энергия бирә башлады. Аңа кирәкле җиһазларны Ленинград, Мәскәү, Харьков, Свердловск, Подольск, Казан шәһәрләре предприятиеләре ясады. Зәй ГРЭСындагы җиһазлар, илдә беренче буларак, блоклап монтажланды һәм ягулыкның яңа төре — Оренбургта чыга торган күкертле газ кулланыла башлады.

Кама аръягындагы моңарчы күрелмәгән үсеш-үзгәрешләр — КамАЗ һәм Түбән Кама нефтехимия предприятиеләре корылу — административ бүленештә дә үзгәрешләр тудырды. 1972 елның 1 ноябрендә РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән элекке Чаллы районыннан мөстәкыйль Зәй районы бүленеп чыкты. Ә инде 1978 елның апрелендә РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән район үзәге — Яңа Зәй эшчеләр поселогына Зәй шәһәре дигән исем бирелде. Шәһәребез 3745 гектар мәйдан били. Ул Зәй елгасы ярында урнашкан. Район җире аша Зәйне Бөгелмә һәм Круглое Поле станцияләре белән тоташтыручы Куйбышев тимер юлы үтә. Аңа параллель салынган автомобиль юлы Әлмәт һәм Брежнев шәһәрләренә илтә.

Районда 55 800 кеше. Төп халык — татарлар — 59 процент, руслар 40 процент тәшкил итә.

Районда төп тармаклар — энергетика һәм машина төзелеше. Шәһәрнең иң зур промышленность предприятиесе итеп автоагрегатлар заводын саныйбыз. КамАЗның «кече туганы» дип йөртелүче бу предприятие куәтле «КамАЗ» машиналары өчен идарә итү аппаратлары, май насослары, автомобильләр һәм авыл хуҗалыгы машиналары өчен тәгәрмәчләр эшләп чыгара. Проектта каралган куәтендә эшли башлагач, ул елына 100 миллион сумлык продукция җитештерәчәк.

СССРның 50 еллыгы исемендәге Зәй ГРЭСы — коммунистик хезмәт предприятиесе. Биредә елына 17 миллиард киловатт-сәгатьтән артык электр энергиясе алына. Бу — Татарстанда җитештерелә торган барлык электр энергиясенең яртысы дигән сүз.

Зәй шикәр заводы — Идел буенда һәм республикабызда азык-төлек промышленносте предприятиеләренең иң эреләреннән санала. Ул елына 18 мең тонна шикәр комы җитештерә.

«Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең тимер-бетон конструкцияләр заводы 5 миллион чамасы сумлык продукция җитештерә. «Татагропромстрой» берләшмәсенең тимер-бетон заводы авыл хуҗалыгы төзелеше өчен җыелма тимер-бетон конструкцияләр бирә. Аның да тулаем җитештерүчәнлеге 5 миллион сумнан арта.

Шәһәрдә «Сельстрой», «Спецмонтаж» һәм 22 нче төзү-монтаж идарәләре кебек эре төзелеш оешмалары эшли. Болардан тыш кондитер фабрикасы, икмәк заводы, сөт заводы, леспромхоз, комбиазык заводы, ашлык кабул итү предприятиесе һәм тагын башка оешмалар бар. Алар барысы бергә елына 380 миллион сумлык продукция җитештерә.

Бездә хезмәте белән дан һәм хөрмәт казанган кешеләр яши һәм эшли. Алар арасында Социалистик Хезмәт Герое М. Н. Хөснетдинова, автоагрегатлар заводында слесарь-ремонтчы, «Почет Билгесе» ордены кавалеры Н. А. Бочкарев, сөт комбинаты машинисты, II һәм III дәрәҗә Дан орденнары кавалеры А. С. Лазарев, Зәй ГРЭСы машинисты, ТАССР Верховный Советы депутаты И. В. Шишкин, 4 нче мәктәп укытучысы, «Почет Билгесе» ордены кавалеры А. И. Әхмәтова һәм башкалар бар.

Районда 117 мең гектар авыл хуҗалыгы җирләре булып, шуның 96,3 мең гектары — сөрү җирләре. 17 колхоз, 3 совхоз һәм мөгезле эре терлек үрчетә торган бер махсус хуҗалыгыбыз бар. Алар көче белән ел саен дәүләткә уртача 4,8 мең тонна ит, 30 мең тонна ашлык, 24 мең тонна сөт, 75 мең тонна шикәр чөгендере тапшырыла.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының тәҗрибәсен, фән казанышларын, интенсив технологияне куллану хезмәттә яңа уңышларга юл ача. Ә тәҗрибә уртаклашырдай, маяк булырдай кешеләр күп бездә. СССР Дәүләт премиясе лауреаты, ТАССР Верховный Советы депутаты, XXI партсъезд исемендәге колхозның шикәр чөгендерен механикалаштырылган игү звеносы җитәкчесе Ф. Н. Миңлебаев, «Алга» колхозының баш белгече, Татарстанның атказанган агрономы Р. Г. Вәлиев, сыер савучылар А. В. Тарышкина, Р. Н. Курская, З. И. Богомазова, РАПО механизаторы, Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры, Татарстанның атказанган механизаторы М. Ф. Вәлиев әнә шундыйлардан. Тукай исемендәге колхозны аеруча мактап телгә аласы килә. Хуҗалыкка 27 ел буена җирнең чын хуҗасы, РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Ленин ордены кавалеры, КПССның XXVII съезды делегаты И. А. Сәгытдинов җитәкчелек итә. Соңгы елларда бу колхоз игенчеләре районда иң югары уңыш үстерәләр. Узган җәйдә, мәсәлән, һәр гектардан 31 әр центнер бөртек җыелды. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет Билгесе» орденнары кавалеры коммунист Н. М. Моратов җитәкчелегендәге Кушъелга бригадасында исә уңыш 40 центнерга җитте. Хезмәт Даны орденнарының тулы кавалеры, Татарстанның атказанган механизаторы М. Х. Гыйлфанов звеносы чын батырлык, осталык күрсәтеп эшли.

Шәһәрдә һәм районда 53 мәктәп, шул исәптән 21 урта, 12 сигезьеллык, бер интернат-мәктәп, бер ярдәмче мәктәп бар. Аларда 645 укытучы һәм тәрбияче эшли, шуларның кырыгы «Халык мәгарифе отличнигы». Шәһәрдә Брежнев автомеханика техникумы филиалы, ике профессиональ-техник училище эшли. Алар промышленность предприятиеләре, төзелеш һәм сәүдә оешмалары өчен белгечләр һәм шулай ук авыл хуҗалыгында эшләү өчен механизаторлар әзерли. Гомуми урта белем бирү мәктәпләрендә һәм профессиональ-техник училищеларда 8 мең укучы белем ала.

Халыкка 4 больница, 31 фельдшерлык-акушерлык пункты, 12 сәламәтлек саклау пункты медицина ярдәме күрсәтә, ашыгыч ярдәм күрсәтү станциясе эшли. Медицина работникларының унысына «Сәламәтлек саклау отличнигы», бишесенә «Татарстанның атказанган врачы» исемнәре бирелде, алтысы СССРның төрле орден һәм медальләре белән бүләкләнде.

«Октябрь» культура сарае, «Космос» кинотеатры, яшьләр дискоклубы, район культура йорты, 61 авыл клубы һәм культура йорты халыкка культура хезмәте күрсәтә, 62 кино җайланмасы эшли. Шәһәр һәм район китапханәләрендә 170 мең китап бар. 1985 елның маенда — Ватан сугышында Бөек Җиңүнең 40 еллыгы алдыннан — шәһәрдә тарих һәм төбәкне өйрәнү музее ачылды.

Без талантлы якташларыбыз белән бик горурланабыз. Язучылар Сөббух Рафиков, Аяз Гыйләҗев, Роберт Батуллин, шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Наил Дунаев Зәй җирендә туып-үскәннәр.

Шәһәрдә һәм районда уналты меңнән артык физкультурачы 78 коллективка берләшкән. Алар карамагына күп санлы спорт заллары, стадионнар, шугалаклар, тирлар, ишкәкчеләр базасы, шахмат клублары бирелгән. Югары Баграҗ авылында туып-үскән татар егете Ф. П. Симашов чаңгы ярышлары буенча 15 тапкыр СССР чемпионы, 3 тапкыр дөнья чемпионы, Олимпия уеннары чемпионы булды. Хәзер районда ел саен Ф. Симашов призына чаңгыда узышу буенча республика ярышлары үткәрелә.

Районыбыз эшчәннәре КПССның XXVII съезды һәм Үзәк Комитетының аннан соңгы Пленумнары карарларын бик тырышып үтиләр, бөек борылышка зур күтәренкелек белән керештеләр.

**Ә. Г. Таҗетдинов,**
Татарстан АССР юстиция министры

# ЗАКОН САГЫНДА

Торыгыз, суд килә!

Менә икенче көн инде Казанның Киров районы халык судында хөкем бара. Гаепләнүчеләр эскәмиясендә уналты яшүсмер — мәктәп һәм һөнәр училищесы укучылары, сәүдә техникумы студентлары, «Тасма» һәм вертолет берләшмәләре эшчеләре. Әле тормыш юлын башлап кына җибәргән, гүзәл яшьлекнең әле бөреләнеп кенә килгән чорында юридик җаваплылыкка тартылырга нәрсә мәҗбүр иткән соң аларны?

Бер-бер артлы шаһитлар, зыян күрүчеләр чакырыла. Судьялар һәм халык утырышчылары алдында җәйге эссе көннәрдә шушы төркем ясаган җинаятьнең төсмерләре ачыла бара.

Ташлар, тимер таяклар белән коралланган ике төркемнең үзара сугышуы кызганнанкыза, күзләрен кан баскан яшьләр инде бер-берсенә түгел, үткән-сүткән кешеләргә дә ташланалар. Аларның рәхимсез хулиганлыгын бары тик милиция хезмәткәрләре генә туктата ала.

Шушы күренешне күз алдыма китергән саен, күңелемне борчу баса. Хәзерге яшьләрне начар дип әйтергә телем әйләнми. Юк! Алар да егерменче, утызынчы, кырыгынчы еллар яшьләре кебек үк фидакарь һәм куркусыз, батыр һәм кыю да була белә. КамАЗ заводлары, Байкал — Амур магистрале шуның ачык мисалы түгелмени?! Әфганстанда интернациональ бурычын үтәгәндә утка-суга кергән егетләребез һәм, ниһаять, Чернобыль фаҗигасенең нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан яшьләребез шуны сөйли. Ә менә аерым очракларда шушы мәгънәсез кансызлык, рәхимсезлек, бер-береңә карата мәрхәмәтсезлекнең тамырлары кайдан башлана? Бер Киров районындагы хәл генә булса, болай зурдан сүз кубарып язып торуның кирәге дә калмас иде. Кызганычка каршы, шушылай ук төркем-төркем булып, урам белән урам, микрорайон белән микрорайон сугышу шәһәрнең башка төбәкләрендә дә, республиканың башка районнарында да бар.

Озак еллар юрист булып эшләү дәверендә күп нәрсә күрергә, аяныч язмышлар белән очрашырга туры килде. Әмма мондый да мәгънәсезен ай-һай күргән булдымы икән?! Дөресен әйтим: малайларның үзара сугышуы, көч сынашуы, ниндидер мәсьәләдә көндәшлеге без яшь чакта ук бар иде. Бала чагында сугышмаган, көрәшмәгән, көч сынашмаган ир-егет юктыр да. Ләкин ул чакларда кемнеңдер борыны канау, күлмәге ертылу — бәрелешне һичшиксез туктата торган олы сәбәп була иде. Егылганны кыйнамыйлар! Бу безнең төп закон, язылмаган канун иде. Ә өлкәннәргә кул күтәрү — бусы инде вәхшилекнең чиге. Чордашларым минем белән килешер дип уйлыйм.

Бүгенге шәһәр малайларының үзара сугышуындагы кансызлык гаҗәпләндерә дә, тәрбиядәге җитешсезлекләр турында җитди уйланырга да мәҗбүр итә. Үткән ел Казанда әнә шулай берничә яшүсмернең гомере киселде. Дөрес, хулиганнарга чара күрелде, алар төрле срокларга ирекләреннән мәхрүм ителде. Закон гадел. Чөнки ул халык исеменнән, дәүләт исеменнән эш йөртә.

Бу язмада әхлак һәм закон турында, тәрбиядәге җаваплылык турында кайбер фикерләремне уртаклашасым килгән иде.

Социалистик җәмгыять кешегә туган көненнән үк күп төрле юридик хокуклар бирә. Шул ук вакытта аңа, ил гражданины буларак, җитди бурычлар, иң элек әхлакый, ә аннан соң юридик бурычлар да йөкли.

Шунысы да ачык, бер генә җәмгыять тә, хәтта социализм да автоматик рәвештә кешеләрне әдәпле, намуслы һәм бәхетле, югары әхлаклы һәм законга буйсынучан итә алмый. Болар — кешегә бирелгән мөмкинлекләр, һәм, әйтер идем, өстенлекләр. Шәхесне төрле яктан үстерү өчен социализм биргән мөмкинлекләрне акыллы файдалануга да бәйле ул.

Әйе, кеше дөньяга әхлакый җаваплы булып килми, ә бары тик шәхес булып формалашу процессында гына шундый сыйфатларга ия була бара. Үз вакытында күренекле педагог А. С. Макаренко, ата-аналарга мөрәҗәгать итеп, болай дип язган иде: «Сөйләшкәндә, өйрәткәндә яки боерык биргәндә генә балабызны тәрбиялибез дип уйламагыз. Сез аны тормышыгызның һәр мизгелендә, хәтта үзегез өйдә булмаганда да тәрбиялисез». Әхлак тәрбиясе бала туганнан соң ук башлана. Гаиләдәге үзара мөнәсәбәтләр, ата-аналарның үз-үзен тотышы һәм мөгамәләсе, кыскасы, өйдәге һәр сүз, һәр адым бала күңеленә уелып кала, аның әхлагына нигез ташлары булып ята. Табигый ки, биредә коммунистик әхлакның принципларын, нормаларын, кагыйдәләрен һәм идеалларын халык арасында киң тарату гаять зур әһәмияткә ия. Бу очракта сүз шәхесне реаль әхлакый мөнәсәбәтләргә тарту, моның өчен социалистик һәм дөнья культурасының кешегә тәэсир итү көче зур булган сәнгати мөмкинлекләреннән дөрес файдалану турында бара. Әхлак культурасы тудыруда рухи культура — төп этәргечләрнең берсе.

Тулаем алганда, кешенең әхлакый яктан өлгерүе тормыш эшчәнлегенең барлык сфераларында — производствода, дәүләт эшендә, иҗтимагый-политик һәм социаль-культура өлкәләрендә, һәм әлбәттә, гаиләдә һәм көнкүрештә кылган һәр гамәлең өчен җаваплылык хисе формалашудан тора. Ләкин мораль нормаларының тәэсир көче никадәр генә киң булмасын, алар җәмгыятьтәге барлык мөнәсәбәтләрне һәрьяклап җайга салу өчен җитәрлек түгел. Менә шушында инде хокук нормаларын кулланырга туры килә. Мисал өчен хезмәткә намуслы мөнәсәбәтне генә алыйк. Меңнәр, миллионнар өчен ул әхлак нормасы булып тора, алар хезмәттән башка яшәүне күз алдына да китермиләр. Ләкин шул ук вакытта күпме ялкаулар, әрәмтамаклар, хезмәт дисциплинасын бозучылар бар. Аларга эшкә урнашырга ярдәм итела. Шул кайгыртуларга карамастан, ул һаман намуслы хезмәт юлына басмаса, мондый кеше РСФСР Җинаятьләр кодексының 209 статьясы нигезендә җаваплылыкка тартыла. Үткән ел, мәсәлән, 1985 ел белән чагыштырганда, җавапка тартылучылар арта төште. Картайган ата-аналарга балаларның кадер-хөрмәт күрсәтүе дә әхлагыбызның асыл сыйфатларыннан санала. Әмма кайчагында әти-әниләренә матди ярдәм күрсәтүдән баш тарткан кешеләргә карата закон көче белән тәэсир итәргә туры килә. Күптән түгел Казанның Совет районы халык судында шундый гыйбрәтле эшләрнең берсе каралды. Чиләбедә яшәүче В. А. Абзалова моң-зарлары белән хөкем органнарына мөрәҗәгать иткән иде. Һәрбер ана кебек, ул да үзенең улын үстерү, аякка бастыру өчен бөтен көчен куйган, төн йокыларын йокламыйча баккан, тәрбияләгән. Ә инде ул гаилә коргач, аңа мебель, кием-салым алып биргән, башкача ярдәм күрсәткән. Хәзер үзе авыр хәлдә калган. Авыру сәбәпле эштән китәргә мәҗбүр булган. Улына һәм килененә, ярдәм күрсәтүләрен сорап, берничә мәртәбә мөрәҗәгать иткән ул. Әмма юкка. Хәзер Казанда, Совет районында яшәүче улы белән килене аналарының аһ-зарын ишетмәмешкә салынганнар. Ә киленнең җавабы бер: «Судка бир!»

Халык суды гадел хөкем чыгарды, әлбәттә. Әнисе файдасына Александр Абзаловтан алимент тотып барылачак. Биредә күпне күргән юристларны да гаҗәпләндергән тагын бер нәрсәне әйтеп үтәсе килә. Суд утырышыннан соң күп тә үтмәде, республика Юстиция министрлыгына әнә шул анасын оныткан адәмнән шикаять килеп төште: «Алиментны тиешеннән сигез сумга күбрәк тотып калалар, шул акчаны кире кайтарыгызны сорыйм»,— диелгән иде анда.

Әхлак һәм хокук җаваплылыгының аермалары турында сөйләгәндә, аларның соңгысының төгәл билгеләнгән булуын һәм, кеше билгеле бер яшькә җиткәч кенә, кулланыла башлавын истән чыгармаска кирәк. Чикләнгән күләмдәге җинаять җаваплылыгы, мәсәлән, 14 яшьтән башлана. Ә хезмәткә хокук 16 яшьтән гамәлгә ашырыла. Шушы ук яшьтән егет һәм кызларга төп гражданлык хокуклары, шуларны раслаучы документ-паспорт бирелә. Политик хокуклардан исә яшь кеше (сайлау һәм сайлану хокукы һ. б.) 18 яшьтән файдалана башлый.

Җәмгыятьтә яшәгән һәрбер кешегә мораль җаваплылык йөкләнгән, ә закон алдында җавап тоту исә, аны бозган кешеләргә генә йөкләнә. Гадәттә җитәрлек дәрәҗәдә әхлакый тәрбия алмаган, рухи җаваплылык тоймаган кешеләр юридик җаваплылыкка ешрак тартылалар. Менә шунлыктан, тәрбия процессында коммунистик әхлак нормаларын ныгытуны алга сөрергә кирәк. Ә хәзергә аяныч күренешләргә тап буласың. 1984 елда СССР Педагогия Фәннәре Академиясенең тәрбиянең гомуми проблемалары фәнни-тикшерену институты хезмәткәрләре сигезенче класста укучы 500 укучының мораль җаваплылык турындагы фикерләрен өйрәнгән иде. Аларның дүрттән өч өлеше тәртип бозган өчен кем алдында мораль җаваплы икәнлеген әйтә алмады.

Беркемнән дә сер түгел, әле хәзергә җәмгыятебездәге барлык кешеләр дә коммунистик әхлак принципларын һәм нормаларын үзләштерде дип әйтә алмыйбыз. Ул гына да түгел, әхлакый үсештә мәгълүм дәрәҗәдә артка калу тенденциясе яшәп килү киң җәмәгатьчелектә борчылу уята.

Ихтыяҗларны канәгатьләндерү өлкәсен генә алыйк. Хәзер матди һәм рухи тормышның баерак булуын һәркем сизә. Көндәлек ихтыяҗларны канәгатьләндерүнең көн саен яңа мөмкинлекләре туып торган чорда, аерым кешеләр, бигрәк тә яшьләр аңында «рөхсәт ителгән» һәм «тыелган» төшенчәләр юыла бара. Нәтиҗәдә кешенең социаль өмете белән җәмгыять үсешенә ул керткән өлеш арасында каршылыклар туа. Яшьләрдән бик күпләр, мәсәлән, үз мөмкинлекләрен исәпләп тормыйча, кыйммәтле магнитофон, автомашина алырга тырышалар, дача яки бакча булдырырга телиләр. Бер сүз белән әйткәндә, таләпләр артык күбәя башлый. Ә нәфес туктала белми. Бер ихтыяҗ үтәлүгә, ул икенчесен тудыра. Әнә шул үзләре тудырган «стандарт»ка ирешү өчен аерым кешеләр социалистик милекне, кеше әйберен, автомобиль яки мотоцикл урлау, талау юлына басалар.

Казанның Вахитов районы халык судында хөкем бара. Гаепләнүчеләр эскәмиясендә — өй басучы Константинов. Аның менә дигән квартиры, эшләү һәм яшәү өчен бөтен уңайлыклары бар. Хезмәт хакы да яхшы гына.

— Ничек мондый хурлыклы юлга бастыгыз? — дип сорый судья.

Гаепләнүченең җавабы таң калдырырлык дәрәҗәдә беркатлы. Ул ирексездән нәфрәт һәм ачу уята.

— «Жигули» алырга уйлаган идем. 500 сум акча җитмәде,— ди ул.

Яки менә тагын бер мисал. Түбән Камада өйләр баскан вакытта ирле-хатынлы М. һәм Р. Әхмәтҗановлар кулга алына. Беркайда да эшләмәүче яшь гаилә шушы кәсепкә кереп киткән. Бу аларның унбишенче өйне басулары була. Кеше исәбенә яхшы яшәү, матур киенү, рестораннарда типтерүне тормыш максаты итеп куйган җинаятьчеләр 5 мең 500 сумлык әйбер урлаганнар. Аларны халык суды озак срокка ирекләреннән мәхрүм итте. Уйланырга вакытлары булачак.

Казанда яшәүче Токмаков, Хисаметдинов һәм Семенов белән бергә, төнге сәгать икедә Карбышев урамыннан ВАЗ-2106 автомашинасын урлап китә. Аның иң кирәкле, кыйммәтле детальләрен алып, үзенең ватык машинасын төзәтә, аны Кавказ якларыннан килгән берәүгә кыйммәтле бәягә сатып җибәрә. Урланган машинаның калдыкларын шәһәр читенә алып чыгып ут төртәләр. Җинаятьчеләр Совет районы халык суды тарафыннан төрле срокларга хөкем ителделәр.

1986 елда урлау, талау, разбой һәм мошенниклык өчен хөкем ителүчеләр барлык җинаятьчеләрнең 18 процент чамасын тәшкил итте. Урлашу өчен җавапка тартылганнар аеруча күп. Квартир басулар белән көрәш хәзергә артык нәтиҗәле түгел. Шунлыктан СССР Верховный суды пленумы — 1986 елның 5 сентябрендә гражданнарның шәхси милкенә каршы җинаятьләрне тикшерү практикасын карады һәм бу өлкәдә көрәшне көчәйтү, суд эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү турында карар кабул итте.

Җинаятьләрне булдырмауда эчүчелек белән көрәшнең әһәмияте зур. Шунысын гына әйтү дә җитә: хулиганлык очракларының 95 проценты диярлек исерекләр өлешенә туры килә. Үтерү, көчләү һәм башка авыр җинаятьләр дә күп очракта исерек килеш эшләнә. Иң аянычлысы — яшүсмерләр һәм хатын-кызларның эчкечелеккә бирелүе. Бу инде бернинди әхлак кагыйдәләренә дә сыймый. Белгечләрнең раславынча, хатын-кызлар алкоголизмы әле күптән түгел генә ирләрнекенә караганда 1,5—2 тапкыр кызурак темплар белән үсә иде.

Гаиләләрнең тотрыклылыгы кимүдә дә шушы яман чир гаепле. Суд практикасы күрсәткәнчә, һәр ике аерылышуның берсенә ир яки хатынның эчкечелеге сәбәп була. Илебездә хәзер яңа төзелгән һәр өч гаиләнең берсе таркалып бара. Безнең республикада исә шәһәр җирендә 100 никахка — 40, авыл җирендә 10 аерылышу туры килә. Аерылулар, кагыйдә буларак, яшь гаиләдә, бергә яшәүнең беренче унъеллыгында була.

Эш, әлбәттә, эчкечелектә генә дә түгел. Аерылышучылар күп очракта уртак мәнфәгатьләр булмауны, ата-аналарның яшь гаилә эшенә тыкшынуын, ирнең — хатынга, яки хатынның иргә хыянәт итүен, холыклар туры килмәвен дә сәбәп итеп күрсәтәләр. Соңгысын аерылуның төп сәбәпләрен интеллигентларча яшерергә омтылу дип тә бәяләргә мөмкин.

Гаеп ике якка да төшә. Хатын ирен эчүдә, власть сөюдә, тупаслыкта һәм эгоизмда, өй эшләрендә һәм бала тәрбияләүдә катнашмауда, ялны оештыра белмәүдә гаепли. Хатын-кызга, гадәттә, иренә хыянәт итү, йорт эшләрен белмәү, мәгънәсез әйбер җыючылык, көнчелек, талашу, вакчыллык кебек гаепләр белдерелә.

Чынлыкта исә төп сәбәп — ир белән хатынның ихтыяр көче булмау, тормыштагы көндәлек мәшәкатьләрне җиңә белмәү, гаиләне саклауда җавапсызлык, аралашу культурасы җитмәү.

Гаиләне саклауда һәм ныгытуда уңайлы социаль-экономик шартлар тудыруның мөһимлеген кире какмаган хәлдә никахлашкан яшьләрнең гаилә өчен, балалар тәрбияләү өчен җаваплылыгын истән чыгармаска тиешбез. Ахыр исәптә һәр никахны саклап калу — ул иң беренче чиратта ир белән хатынның шәхси эше. Менә шунлыктан гаилә тор-

мышының интеллектуаль һәм культура дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән тәрбия эшенең әһәмияте арта бара. Яшьләрне никахка җитди һәм җаваплы карарга, тормыштагы кыенлыкларны җиңә белергә, гаилә белән яшәүнең күңелле һәм матур якларына өйрәтергә кирәк.

Партиянең XXVII съездында кеше факторына, совет кешеләрен социаль һәм хезмәт активлыгын үстерүгә, әхлак һәм хокук тәрбиясен көчәйтүгә гаять зур әһәмият бирелде. Бу күп төрле нәрсәгә: эшнең формасы һәм ысулларына, кешеләргә тәэсир итүнең күп төрле чараларын файдалануга бәйле. Шуның белән бергә, көндәлек тормыштагы чынбарлык та шәхес тәрбияләүгә көчле йогынты ясый. Хезмәт кешесенең активлыгына бар нәрсәнең дә гадел эшләнүенә ышанудан да яхшырак тәэсир итүче нәрсә юк.

Табигый ки, хәзер тәрбия эшендә конкретлыкны көчәйтү, һәр кешегә индивидуаль якын килү таләп ителә. Тормышыбыздагы тискәре күренешләр турында ачыктан-ачык сөйләү шулай ук тәрбия эшендә яхшы нәтиҗә бирәчәк.

Әйтик, яшьләрнең аерым бер өлеше эшләмичә генә җиңел тормыш алып барырга, кәеф-сафа корып яшәргә омтыла. Бу омтылыш исерткеч эчемлекләргә, наркотик матдәләргә алып килә. Соңгы вакытта матбугатта наркоманнар турында күп языла. Дөресен әйтик, безнең илебездә наркомания — Көнбатыштагы (АКШта 30 миллион наркоман исәпләнә) шикелле киң таралыш алган күренеш түгел. Ләкин аның аз гына чагылышына каршы да көрәш кискен һәм аяусыз. Безнең тормышта мондый тискәре күренеш бөтенләй булмаска тиеш. Әмма, кызганычка каршы, республикабызда наркотик матдәләр куллануның билгеле дәрәҗәдә артуы сизелә. Мәсәлән, Апас районы больницасы врачы А. Чибриков һәм аптека мөдире Р. Вәлиуллин ел ярым дәвамында наркотиклар урлау белән шөгыльләнгәннәр. Алар 4600 ампула дару урлаганнар. Тәүлек буе миңгерәйткеч сөрем эчендә йөзгән бу врачлардан нәрсә көтәргә мөмкин соң? Утыз яшьләр тирәсендәге чагыштырмача яшь бу егетләрнең бөтен максаты чираттагы дозаны кабул итүгә юнәлә. Чынлыкта инде алар икесе дә нормаль кеше булмый. Башка больница һәм аптекаларда да наркотиклы даруларның тиешсез кешеләргә эләгү очраклары ачыкланды.

Наркомания — яшьләр проблемасы. Исәпкә алынган барлык наркоманнарның биштән дүрт өлеше — әле утызга да җитмәгән кешеләр. Менә шунлыктан егетләр һәм кызлар арасында тәрбия эшен көчәйтү аеруча мөһим. Наркомания рухи ярлылык, тормышта анык максатлар булмау, буш вакытны оештыра белмәүдән килә һәм мораль яктан гына түгел, хәтта физик яктан үз-үзеңне һәлак итүгә китерә.

Соңгы елларда әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре тәрбия мәсьәләләренә игътибарны моңарчы булмаганча көчәйттеләр, вөҗданлылыкка, намуслылыкка чакыра башладылар. Валентин Распутинның «Янгын» повестеның төп герое Иван Петрович болай дип фикер йөртә: «Үзеңә генә кагылган барлык нәрсәдә, әлбәттә, син үзеңә үзең әфәнде. Синең үзеңдәге хуҗалык өчен башка беркемнән дә сорап булмый. Хәлбуки, ул бик күп тышкы сәбәпләр һәм башлангычларга бәйле булып тоелса да, синнән тыштагы серле һәм гаҗәеп дөньяга чыкканчы, бу сәбәпләр һәм башлангычлар синең югары властеңны читләтеп үтә алмыйлар. Димәк, бу очракта да бары тик үзеңнән генә сорарга туры килә».

СССР Верховный Советы депутатлары булып сайланган язучылар һәм Мәскәү әдипләре белән очрашу вакытында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре М. С. Горбачев фикерләү һәм кеше психологиясен үзгәртеп кору турында сөйләгәндә: «Психологик һәм әхлакый үзгәртеп коруны тормышка ашырганда тискәре күренешләр белән көрәштә әдипләр мөһим роль уйный алалар»,— диган иде.

Үзенең тәртибе, тормыш рәвеше һәм эшчәнлеге белән башкаларга үрнәк булырдай кешеләр һәрбер коллективта бар. Намуслы, вөҗданлы, үз-үзләренә таләпчән булулары белән алар һәркемнең ихтирамын казаналар. Әмма яшьләрдән кайберәүләр чын шәхес булып җитешүнең әнә шундый һәркемгә яраклы тәҗрибәсен игътибардан читтә калдыралар. Күршеңне яхшырак белергә, өйрәнергә иде! Гомумкешелекне ярату җиңел, ә конкрет кешене, үзенең батырлыгы, матурлыгы белән генә түгел, ә кайбер кимчелекләре дә булган янәшәңдәге кешене ярату авыррак шул.

Соңгы вакытта массаларга әхлак һәм хокук тәрбиясе бирүдә социаль-педагогик комплекслар үзләрен яхшы яктан күрсәтте. Аларның советлары торак микрорайоннарындагы халык арасында көндәлек эшне оештыралар һәм координацияләләр, уку йортлары, культура-спорт оешмалары, хокук саклау органнары, предприятиеләр, торак идарәләре һәм башка оешмаларның тырышлыгын туплыйлар. Түбән Кама, Әлмәт, Брежнев һәм башка шәһәрләрдәге социаль-педагогик комплекслар тәҗрибәсе күрсәткәнчә, халык белән әнә шулай кызыксынып һәм мавыгып эшләү, мәнфәгатьләр берлегенә ирешү эзсез үтми, әлбәттә. Аларда эчкечелек сизелерлек кимеде, җинаять очраклары сирәгәйде, эш вакытын югалтулар азая башлады. Болар барысы да кешеләр психологиясендә булган үзгәрешләр, көнкүрештә һәм производствода үз-үзләрен тотышлары өчен җаваплылык хисе арта бару турында сөйли.

Рәфикъ Юныс

# НИЧЕК, ГАТА, БАРЫП ҖИТӘРБЕЗМЕ?..



*«Шахмат белгечләре аның сирәк очрый торган талант булуына шикләнмиләр. Өлкәннәр дәрәҗәсендә уйлавы, бигрәк тә эндшпильдә оста уйнавы белән ул күпләрне гаҗәпкә калдыра... Безнең әле мондый яшь уенчыны дөнья күләмендәге бәйгегә чыгара алганыбыз юк иде». (М. Таль)*

*«Уенын күргәннәрнең фикеренчә, ул уникаль шахмат талантына ия». (А. Суэтин)*

*«Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, бу малай... өлкән яшьтәге Ботвинникны хәтерләтә». (А. Быховский).*

Болар бар да Ленинградта яшәүче Гата Камский хакында әйтелгән. «Советский спорт» газетасы аның турында «Бу исемне хәтерләп калыгыз» дигән рубрика астында «XXI гасырда ул кем булыр икән?» — исемле мәкалә дә бастырып чыгарды.

Күпне күргән журналистларны, данлы шахматчыларны ни белән гаҗәпкә калдыра соң әле Камский?

Иң әүвәл — яше белән. Уникесе тулуга яшьләр арасында СССР чемпионы булу, ягъни, унсигезгә кадәргеләр арасында иң көчле булып танылу дөнья чемпионнарының иң яше Гарри Каспаровка да тәтемәгән.

Нинди хикмәтле шартларда үсте икән мондый талант иясе? Бу «өлкәннәр акылына ия» малай үзен ничегрәк тота икән? Нәсел-нәсәбе нинди аның?— шуның ише сораулар мине Нева буендагы калага дәште.

Ленинградка килеп төшеп, кунакханәгә урнашу белән, М. И. Чигорин исемендәге шахмат клубы телефонын җыйдым. Клубның директоры кырт кисте:

— Камский белән очрашу мөмкин түгел. Иртәгә иртүк Балтик буена китеп бара ул.

Зинһарлап сорагач, «Хәзер, Камскийның тренерын дәшәм».— диде.

Халыкара класслы мастер М. Цейтлин ситуацияне аңлатып бирде. Майда Амстердамда уналты яшькә кадәрге шахматчыларның дөнья чемпионаты узачак икән. СССРдан берәү барасы. Аның кемлеге Гата Камский белән Ригада яшәүче 14 яшьлек Алексей Широв арасындагы көрәштә хәл ителәчәк. Очрашу Клайпедада үткәрелә.

Эмма Марк Давидович та сөйләшүне үтә кырыс тәгалләде:

— Телевидениедән арып кайтты, иртә таңнан юлга чыга.

Шулай да, Камскийларның телефон номерын ала алдым.

Трубкада хатын-кыз тавышы. Аптырый төшеп (әтиле-уллы яшиләр, дип язганнар иде бит) Рөстәм Камскийны сорыйм. «Ул өйдә юк,— диләр миңа.— Хәер, сабыр итегез...»

Трубкада бала тавышы. Гата, ахрысы. Сүзне ул да кыска тотты: «Әти囚 эштә, безнең вакыт юк — юлга җыенабыз».

Өмет өзелде. Иң гаҗәбе — берәүгә дә үпкәләрлек түгел. Шундый мөһим очрашуга барырга торганда минуты да дөнья бәһасе буладыр шул. Ә журналистлар... Алар бу өйдән өзелмәячәк хәзер... Вакыт та соң инде — сигез тулып килә. Шулай да, атып калганчы атып кал, дигәндәй, номерымны әйтәм: өлкән Камскийдан бер-ике сорауга, телефон аша гына булса да, җавап алалмаммы?

Вакыт төнге унга якынлашып килә иде инде. Беренче битенә берничә генә сүз сырланган блокнотымны кире портфельгә салырга дип кенә торганда, телефон шылтырады.

— Сез Казаннан түгелме?

— Әйе...

— Шулайдыр дип уйлаган идем аны! Хәзер безгә килә алмыйсызмы?

Рөстәм Гатович мине үзләре янындагы метро станциясендә көтәчәген әйтте.

Юлда Гатага нинди акыллы сораулар табарга дип баш ватам. Журналистлык практикамда вундеркинд белән беренче очрашу бу.

Урта зурлыктагы бүлмә икегә бүленгән. Ишек ягында — ике урынлы карават. Түр якта өстәл, берничә урындык, китап шкафы. Уң стенада скрипка, Гатаның фотолары, «Артек чемпионы» дип язылган ал тасма...

Кухня бишме-алтымы гаиләгә бер. Телефонны хатын-кыз алуның да сере ачылды— уртак икән ул.

Без кергәндә Гата кухняда бәрәңге җылытып йөри иде.

«Күчтәнәч»не тапшырам. Рәшит Нәҗметдиновның «Сайланма партияләре» дигән китабы үзләрендә дә бар икән. «Социа-

листик Татарстан»да «Советский спорт»тан күчереп басылган мәкаләне күрсәтәм. Аның башы үзгәртелеп, «Тарихта бер Гата» дип тәрҗемә ителгәнен белгәч, малайның авызы колагына җитте!..

Бәрәңге янына атланмай, кура җиләге вареньесы килә.

— Ашарга ипи булса — канәгатьбез, артык тәм-том эзләмибез,— ди Рөстәм.— Гата тормышны булганынча белә. Шатлыгы да, кайгысы да уртак... Моның өчен улым мине битәрләмәс дип уйлыйм.

Менә алар аталы-уллы чемодан тутыралар. Журналистлар язган «спартаннарча тормыш»ның эти кешенең сак, җылы мөгамәләсе белән йомшартылуын искәртми булдыра алмыйм.

— Гата, витаминнарны табып китерче... Гостиницада кияргә спорт форманң кирәк булыр бит, алыйкмы?

— Алыйк.

— Тыңлыйм һәм буйсынам!..

Гатаның йөзеннән елмаю китми. Бәләкәй генә, ябык кына үзе.

— Мәктәптә кыерсытмыйлармы соң? Сигезенче класста инде шактый гәүдәле малайлар да була бит.

— Әти хәтләләре бар... Юк, кыерсытмыйлар.

— Яраталар аны,— дип сүзгә кушыла әтисе.— Аннан, үзен яклый да белә әле ул. Гимнастика, бокс, каратэ белән шөгыльләнгәләдек... Мәктәпкә йөри башлаган чакларда вак-төяк «ЧП»лар була иде анысы...

Унике яшьлек малайның сигезенче класста укуына гаҗәпләнгәнсездер инде. Моның үзенә күрә тарихы бар.

Малаен Рөстәм күкрәк баласы чагыннан ук берүзе тәрбияләп үстерә. «Тату гына аерылыштык»,— дип көрсенгән сыман әйтеп куйды ул. Яше тулганда да малайның теле ачылмавы аны бөтенләй куркуга сала. Врачлар белән киңәшә һәм ныгытып шөгыльләнә башлый.

Рөстәм, уенын-чынын бергә кушып сөйли:

— Мин улыма «гувернер» булдым,— ди.

Әйбәт гувернер булып чыга ул! Ике яше тулыр-тулмас Гата укырга өйрәнә. Алты яшендә шактый катлаулы музыкаль әсәрләрне, нотага карап, яисә радио-телевидениедән ишеткәнне хәтерләп, пианинода уйный башлый. Баланы музыка дөньясына тизрәк кертү өчен Новокузнецкидан Ленинградка күчәләр. Өч бүлмәле квартира шушы бүлмәгә алыштырыла. Менә шунда «музыкант язмышы»ның аның белән кавышырга бик атлыгып тормавы ачыклана. Дөрес, музыка белгечләре «Каян килгән мондый талант!» дип, Шәүкәт Галиевчә әйтсәк, «шаккатта, тел шартлата». Әмма консерваториянең махсус мәктәбе ишекләрен ачарга ашыкмыйлар...

Ә «каян килгән мондый талант» дигән сорауга килгәндә, Рөстәмнең җавабы әзер. Чишмә башы — Гатаның бабасы. Күп уен коралларында сыздырып уйнаган ул...

Музыка капусы ачылганны көтеп ятып булмый. «Кыңгыраулы мәктәп еллары» якынлаша. Башка күп әти-әниләрдән аермалы буларак, Гатаның әтисе хәзерге мәктәпнең кимчелекле якларын да өйрәнеп өлгергән була: һәр балага, кем әйтмешли, «уравниловка» күзлегеннән карау, яңага омтылышны үтерә торган уку, күңелсез үгет-нәсихәт, ялыктыргыч «озынайтылган көн».

— Кызгандым улымны. «Утыр өйдә, укы! Билгеләрне үзем куярмын»,— дидем.

«Гувернер»лыкка укытучылык вазифалары өстәлә. Бу «укытучы» әтинең укыту ысулларын белсәләр, мәгариф инспекторлары, мөгаен, һуштан язарлар иде. Кайбер математика дәресләре, мәсәлән... карта уйнаудан гыйбарәт була. Әмма алар, рәсми мәгарифчеләр, бәхеткә каршы, Гатаны тәрбияләүнең ахыр нәтиҗәсен генә күрәләр. Дүрт сәгать тоташ барган имтиханнан соң малайның мәктәптәге укуын өченче класстан башларга рөхсәт алына. Әле өченче класста да Гата контроль эшләргә генә йөри. Мәктәптә уку, асылда, дүртенче класстан башлана.

Шахмат күәсе дә малайга бабасыннан күчкән, диярго була. Гатаны әтисе өйрәтә. Ә анысы үзе абыйларыннан откан. Аларны исә этиләре өйрәткән була.

Гатага исем дә бабасыннан күчә: Оренбург татар театрында эшләгән Гата һәм Фатиха Камскийлар оныгы ул.

— Минем үземнең чама өченче разрядка гына тарта,— ди Рөстәм.— Ә Гата мине уйның башлау белән диярлек ота да башлады.

Малай шахмат белән чын-чынлап дүртенче класска күчкәч — сигез яшендә мавыгып китә. Камскийлар су коеныргa, өстәл теннисы уйнарга Җиңү паркына йөри торган булалар. Ә анда «шахмат җене» кагылганнар җыела торган урын бар. Әнә шул «базар»дагы ярсу дауларда шахмат комары йокгыра да инде Гата, шул һәвәскәрләрдән (арада мастерлыкка кандидатлар да була) «практик» дәресләр ала. Ә теория ягы?

— Сулдан һөҗүм ит!

— Уңнан ябырыл!

— Пешканы ку! — теория әнә шул дәрәҗәдә була.

Чын шахматка Артур Юсупов партияләреннән өйрәнәләр. Гроссмейстер турнирларда уйнаганда, матчлары барганда, аның өчен уҭ йоталар. Юсуповча уйнап, көчле генә шахматчыларны да җиңә башлыйлар. Соңрак Нәҗметдиновның «иҗат бакчасына» керәләр. Аннан чират Каспаровка җитә.

«Өйрәнәләр», «җиңәләр», дип күплектә язуның хикмәтен аңлыйсыздыр. Тренер булырга күәсе җитмәсә дә, Гатаның әтисе оештыручы, рухландыручы җитәкче булып кала бирә. Хәер, янда бүтәне булмый да.

Тәрбияче, укытучы, тренер. Бер кешегә болай да аз түгел бу. Ә инде һәр «тармак»та шаккаткыч нәтиҗәгә ирешелгәнен дә исәпкә алсаң, сорау туарга мөмкин: «Үзе кайда укыды икән бу кеше?»

Академияләр тәтеми аңа. Әти-әни тәрбиясен дә алып җиткермичә, балалар йортына эләгә. Һөнәре — фотограф. Үзенә ул талантлы әтисе белән талантлы малаен тоташтырып торучы гап-гади бау дип кенә карый.

Хәер, алкышлар тәмен дә татырга туры килә әле Рөстәмгә. Орск шәһәренең пионерлар сарае драма түгәрәгенә йөргән чагы була. А. П. Чеховның бер пьесасында уйнап, үзешчән сәнгать смотрында уңыш каза-

на. Чираттагы турга Мәскәүгә җибәрүләрен сорап, түгәрәк җитәкчесе Камскийларга килә. Гата абзый ризалык бирми.

— Гомерем буена артист йөген тарттым, балаларымның бу юлда йөрүен теләмим,— ди.

Тормышлары җиңелдән булмый шул. Театрдагы ике сменага өченчесе — өй-бакча мәшәкатьләре ялгана. Акча кытлыгы гел сиздереп тора. Балалар да, бәп-бәләкәй чаклардан ук, тормыш көтүнең ни икәнен белеп үсәләр.

Юк, Рөстәмнең балачагы иптәшләренең берсенекенә дә охшамаган. Я, әйтегез: Африкада колонизаторларга каршы восстание күтәрү турында кайсыгызның хыялланганы бар? Ә Рөстәм хыялланып кына калмый, җыенып юлга чыга. Бер тапкыр Оренбургтан, икенчесендә хәтта Астраханьнан тотып алып кайталар үзен.

Я, әйтегез тагын: кемнең бала чакта ук: «Их, гомер үтә, кире кайтмаска үтә бит!» дип өзгәләнгәне бар? Вакытны «тыгызлау» турындагы хыялын Гатаны тәрбияләгәндә тормышка ашыра Рөстәм. Моның авырлыгы башлыча үз җилкәсенә төшә. Акча табудан алып төймә тагуга кадәр бөтен мәшәкать — аның өстендә.

Гатаны йокларга яткыргач, Рөстәм бер чемодан тотып килде. Әти-әнисенең фоторәсемнәре, документлары икән анда. Берәмберәм алып күрсәтә, аңлатып бара. Бервакыт Гата, инде күптән йокларга тиешле Гата, бабасының фотосын тотып килеп җитмәсенме! Ул анда икенче чемоданны актарып ята икән! Рөстәм, фотоны алып, ачуланып куып җибәрде үзен.

Гата абзыйның хезмәт кенәгәсен тапмыйбыз гына бит. Шулвакыт тагын, кояш кебек балкып, Кече Гата килеп җитте. Кулында — кенәгә.

Гата Сабиров («Гата Камский» аның театрдагы исеме) үзенең хезмәт юлын 1906 елның 1 маенда, малайлыкта башлап җибәргән икән. 1918 елга кадәрге гомере приказчиклыкта үтә. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армиядә хезмәт итә: культура хезмәткәре, артист була. Соңыннан төрле клуб һәм театрларда режиссер, артист булып эшли. Театр эшчәнлегенең төп өлеше Оренбург татар театрына туры килә. Рокыя Кушловская, Фатыйма Камалова кебек сәхнә йолдызлары белән янәшә төп рольләрдә уйнаган бу артистның исеме «Татар совет театры» дигән китапта (Казан, 1975) зурлап телгә алына. «Чик сакчылары» спектаклендә отряд башлыгы Хитров ролен уйнарга ничек әзерләнүе турында исә Г. Камский «Коммунист» газетасында үзе язып чыккан (1938, 20 апрель).

Ул арада Гата татар пластинкалары тартып чыгарды.

— Әни исталеге,— диде Рөстәм.— Әни этидән соңрак үлде безнең. Ташкентта Ямансулаган чакларда тыңлыйбыз. Илһам Шакиров, Әлфия Афзаловаларның җырлавын яратабыз. Яңа пластинкалар гына юк менә...

— Гатага гел әйтәм мин: Үзең өчен генә тырышмыйсың, синең уйнавыңны халкыбыз күзәтеп тора, дим.

Рөстәм әле сәгатенә, әле телефон тавышы ишетелсен дип ачып куелган ишеккә карап ала. Билет турында хәбәр итәргә тиешләр икән. Менә ул, күршеләрен борчымас өчен (вакыт соң) коридорга ук чыгып китте. Йөзен стена ягына куеп яткан Гатабыз шул секундта ук гәүдәсен 180 градуска борды, шуклык катыш кызыксыну ташып торган күзләрен миңа төбәде. Безнең арада менә мондый сөйләшү булып алды.

— Бүредән курыкмый идеңме? Бәләкәй чакта? — Түр стенага, тешләрен ыржайтып торган башы-ние белән, бүре тиресе эленгән. Шул турыда әйтүем.

— Юк. Аны бит әтием аткан!

— Син... нинди<u>рәк</u> бүләкләр яратасың?

Бу юлы тавыш алай көр чыкмады.

— Ни бирсәләр шуны инде.

— Даннан башың әйләнеп китмәсме?

— Алай булырга тиеш түгел.— Гатаның йөзе беразга гына җитдиләнеп ала.

Минем исә аны чәчләреннән сыйпап сөясем килә. Тыелып калуыма әле дә үкенәм.

Элек күз алдыма китергән вундеркинд сурәте өйгә килеп керү белән эреп юкка чыккан иде инде. Менә хәзер дә, Гатаның партияләрен уйнап карап, аерым йөрешләргә үзе биргән акыллы-акыллы аңлатмаларны укыгач та, бу ике образ — мин күргән малай белән көчле генә мастерларны да куркуга салган, ай үсәсен көн үскән Гата батыр — күңелемдә кушылмыйча, икесе ике кеше булып саклана...

Будильникның 5 кә төбәлгән угы калган сорауларымны онытырга мәҗбүр итә.

Һаман әле анык хәбәр ала алмаган Рөстәм бераз гына озата барды.

— Поезд белән генә китик дигән идем дә... Көн бозылып тора бит. Килешмәделәр, озак була, диләр.— М. Цейтлин һәм Ленинградтан барачак тагын бер шахмат әһеле турында икән сүз. Цейтлин да даими тренер итеп түгел, өч көн элек кенә шушы матчка гына билгеләнгән...

Казанга кайтуга, хәбәр көтә башладым. Широв көчле көндәш булса кирәк. Яшьләр чемпионатында Гата бер генә партияне оттырган. Шировка.

Ниһаять, Ленинградтан хат килеп төште. Юл мәҗараларын тасвирлаудан башлана ул. Аэропортта бер тәүлек көн рәтләнгәнне көткәч, Мәскәүгә — СССР яшьләр җыелма командасы өлкән тренеры, матчны оештыручы А. Быховскийга шалтыраталар. Ул матчны Ригада үткәрергә тәкъдим итә. Ленинградлылар ризалык бирәләр һәм икенче көнгә поездга билет алалар. Кичкә исә бүтән төрле фәрман килә: Клайпедага барырга, югыйсә Камскийга җиңелү язылачак.

Күтәренеп, матч үтәчәк бүлмәгә килеп керүгә, шахмат сәгате текелди башлый. Гата оттыра... Бер сүз дә әйтмичә, кунакханәгә урнашырга китәләр. Улын тынычландыра Рөстәм: «Иртәгә партияне ничек булса да ничьяга төгәллә, ә аннан... уйнап күрсәтербез!» ди. Шулай булып чыга да. Икенче партиядә — ничья, аннан рәттән өч отыш! Соңгы, алтынчы партияне уйнап торуның кирәге калмый.

Нинди перспективалар көтә соң Гатаны? Моны аңлау өчен башта казанышларына күз төшерик.

Ун яшьтә спорт мастерлыгына кандидат нормасын 1,5 очкога арттырып үти. Унбере

тулгач, яшьләр арасында «Спартак»ның бөтенсоюз беренчелегендә ота — 10 мөмкинлектән 9,5 очко. Узган ел азагында Эстониядә үткәрелгән шахмат фестивалендә катнаша һәм, 35 спорт мастерын артта калдырып, беренче урынга чыга. Быел Ленинград динамочылары җыелма командасы составында бу җәмгыятьнең бөтенсоюз беренчелегендә катнаша, беренче тактада уйнап, 9 мөмкинлектән 5,5 очко ала. Биредә ул беренче мәртәбә гроссмейстерлар белән очраша. Хәзер менә Ленинград беренчелеге бара, анда 18 мастер һәм гроссмейстер М. Тайманов катнаша. Гата беренче турда откан, шәһәр чемпионы, халыкара класслы мастер А. Лукин белән очрашулары ничьяга тәгәлләнгән.

Г. Камский феномены турында уйланган кеше аның киләчәк язмышын юрап караудан тыелып кала алмый. Белгечләрнең фикеренчә, бу язмыш бик-бик матур була ала. «Огонек» журналында М. Тайманов, мәсәләнн, менә болай дип язды: «Брюссельдә чыга торган «Суар» газетасы шахмат экспертының менә бу фикере белән килешергә кирәктер, күрәсең: «Ике К (Каспаров белән Карпов) шахмат Олимпында бу меңьеллыкның азагына кадәр хакимлек итәрләр кебек тоела миңа». Шуннан соң бик кызыклы өстәмә бирелә: әгәр дә аларга өченче К — күптән түгел Советлар Союзының яшьләр чемпионатында сенсацион җиңү яулаган уникe яшьлек Ленинград вундеркинды Гата Камский өстәлмәсә. Мин үзем дә совет шахмат сөючеләренә бу исемне игътибарга алырга киңәш итәм. Ышаныгыз, тиздән бөтен кешенең телендә булачак ул».

Безгә: «Хуш, раска чыксын!» диясе генә кала. Әмма... реаль чынбарлык сызган графикның логика күрсәткән текә туры сызык белән тәңгәл килмәве дә мөмкин шул.

Шахматта «гамбит» дигән нәрсә бар. Тизрәк һөҗүмгә күчү өчен уен башында пешканы яисә берәр фигураны корбан итү дигән сүз бу.

Камскийлар шәп башладылар. Әмма корбан да бәләкәйләрдән түгел.

Ленинград беренчелеге турында Рөстәм менә ни дип яза: «Турнир бик авыр, көн саен алтышар сәгать уйныйлар». Ә бу бит инде соңгы дүрт-биш айдагы алтынчы ярыш! Тагын бер-ике атнадан алар егерме яшькә кадәрге мастерларның сайлап алу турнирында катнашырга телиләр. Ул бетеп, унөч көн үтүгә — дөнья чемпионаты. Яшь организм моңа түзәрме? Һәм... түзәргә кирәкме әле?..»

«Синең өчен иң кызыклы ял нәрсә?» дигән соравыма Гата урынына әтисе җавап бирде: урам белән китап. Әмма бу рәхәтләр аңа бик тәтеми икән шул.

Мәктәп тә бар бит әле. Вундеркинд хәзер — өчлегә укучылар рәтендә...

Инде хатын тәгәлләгәч, числосын куйгач. Рөстәм ничек кенә булса да Гатага егерме яшьлекләр турнирына әләгергә кирәклеген әйткән. Һәм... өч өндәү билгесе тезгән. Мин исә аңа бу турнирдан баш тартырга һәм, гомумән, турнирлар санын киметергә киңәш итеп яздым. Аннан үзем үк икеләнеп калдым. Читтән күзәтеп кенә, белгеч булмаган килеш, мондый киңәшләр бирергә хакым бармы соң минем?

Тренерсыз интекәндә турнирларда еш уйнау, бәлкем, осталыкны чарлауның бердәнбер чарасыдыр? Рөстәм үз улының мөмкинлекләрен чамаламый булмас. Бәләкәй чактан ук киеренке хезмәткә күнегеп үскән ләбаса ул. «Тырышкан табар...» дигән мәкальне инде укырга керергә әзерләнгәндә — вакланмалар белән кайнашкан чакта ук тормыш законы иткән бит алар.

Алдагы дауларда ярдәмгә киләчәк тагын бер сыйфат тәрбияләнә Гатада: катлаулы шартларда да тыныч калу, игътибарны туплый белү. Каршы якның тренерлары кайчак ым-ишарәләр белән үз шәкертләренә әйтеп торудан да тайчанмыйлар икән. Кайберләре тагын малайның күзенә карый — тынычлап уйлый алмасын, янәсе. Гата исә тактадагы позицияне генә күрә.

Тик... бу игътибарлы-тыныч халәткә чумуның бер шарты бар. Янда әтисе булу кирәк моның өчен. Гатаның соклангыч уңышлар чоры да (соңгы ике ел) Рөстәм эшеннән чыгып торып, үзен тулаем улына багышлаган вакытка туры килә. Тик менә... акча дигәне генә...

Бу җәһәттән, шуны искәртеп үтәсе килә. Илебезнең хәзер Г. Каспаров кебек даһи шахматчы белән горурлана алуында менә мондый «нюанс» та чагылыш тапмады микән: Гата кебек чакта Гарри үзе — махсус стипендия, ә тренеры белән әнисе хезмәт хакы алып торганнар.

Талантларның йолдыз булып кабынып китә алмау очраклары сагайта. Аларның берсе — якташыбыз Р. Габдрахманов язмышы. Яшьләр арасындагы СССР чемпионатында бик озак лидер булды ул. Соңгы турда Баку малаена оттыруы гына (чемпионат Бакуда уза) Рафаэльне чемпион медаленнән мәхрүм итте (Г. Каспаровка эләкте ул). Ә хәзер, ун ел узгач, бу ике спортчыны шахмат тактасының ике ягында күрү ихтималы да аз инде...

Шулай да Камскийларның шахмат күгенә юл ярачакларына ышанам мин. «Набер. Фонтанки, 110 йорт, 48 фатир»— бу адреска котлау хатлары явачак әле!..

— Каспаровка да барып җитәрбез. Ничек, Гата, барып җитәрбезме Каспаровка?

Кече Камский баш кага:

— Аһа.

Редакциядән: Гата Камский, Рига шахматчысы А. Шировны җиңеп, дөнья чемпионатында катнашты һәм кырыкка якын уналты яшьлек дәгъвачылар арасында 13 нче урынга чыкты.

библиография

## Мөхәммәт Мәһдиев

# КИТАП ҺӘМ ТАРИХ

Фәннәр докторы Ә. Кәримуллинның 1985 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган китабы «Китаплар һәм кешеләр» дип исемләнгән[1]. Тирән мәгънәле исем бирелгән бу китапка. Китаплар һәм кешеләр... Мин исә бу хезмәт турындагы уйларымны китап һәм... тарих дип исемләргә булдым. Китап һәм тарих... Ул — ни? Китап,— чыннан да, тарих. Тере тарих. Төрле заманнарда, төрле кануннарга нигезләнеп фиргавеннәр, патшалар, шаһлар, корольләр, папалар, императорлар, президентлар, дәүләт башына менеп утырган авантюристлар иң беренче эш итеп китапка каршы көрәш башлаганнар. Радищев, Пушкин, Лермонтов, Герцен әсәрләре, алар язган китаплар империяне дер селкеткәннәр. Г. Коләхметов, Г. Тукай язган әсәрләр жандармерия папкаларында йөри-йөри таушалып беткәннәр. Китапка каршы көрәшмәгән бер генә монарх та булмаган. Әмма, А. И. Герцен әйткәнчә, «кабиләләр, кешеләр, дәүләтләр юкка чыкканнар, ә китап кала биргән. Ул кешелек җәмгыяте белән бергә үскән, кеше акылын тетрәткән бөтен тәгълиматлар, йөрәкләрне ашкындырган бөтен омтылышлар анда кристаллашкан».

Ә. Кәримуллинның татар китабы үткән юл турындагы әлеге хезмәтен укыганда, бу өземтә мәкаләгә керәм, керәм дип, миңа мөлдерәп карап тора сыман иде. Татар китабы... Катлаулы, авыр юл үткән, илгә, халыкка игелек китергән китап. Аның язмышы, ничектер, бөек рус, немец, испан, француз, инглиз, фарсы-гарәп, төрек китаплары үткән юл белән бик охшаш. Татар китабы гомер-гомергә тарихта актив булган, үз халкын гына түгел, тугандаш төрки халыкларны да агартуга хезмәт иткән. Утызынчы еллардагы кайбер вульгар социологлар «Казан шәһәре шәрык өчен дин китабы тараткан» дигән эчтәлекле ямьсез гайбәт язгаладылар. Әмма, Ә. Кәримуллин китабының бер генә бүлеген — «Гасыр» һәм «Яңа китап» нәшриятларының эшчәнлеген генә күзәтегез. «Гасыр» нәшрияты,— ди автор,— табыш артыннан кумаган. Бу турыда китаплар, аларның оформлениесенә киткән өстәмә материаль чыгымнар сөйли». Прогрессив нәшрият булмаса, «Гасыр» компаниясенең хуҗалары Әхмәтгәрәй һәм Зәйнәп Хәсәниләр янына Тукай, Коләхметов, Әмирхан, С. Рахманколый, Г. Кәрәм кебек алдынгы яшьләр тартылыр идеме? Татар халкына нур чәчүче мәгърифәт учагы булып исәпләнмәсә, «Гасыр»га большевик Хөсәен Ямашев кереп йөрер идеме?

«Гасыр» нәшриятының бу мактаулы эшчәнлеге Ә. Кәримуллин китабында бик тәфсилле рәвештә сөйләнгән, ышанычлы саннар, таблицалар белән беркетелгән. Бу хезмәтнең зур әдәби юбилейлар — Ф. Әмирхан һәм Тукайның тууына йөз ел тулулары алдыннан дөньяга чыгуы символик мәгънәгә ия: китапчылык тарихында Әхмәтгәрәй Хәсәни нәшриятын Тукайдан, Ф. Әмирханнан башка, Пушкинның, Лермонтовның татарчага тәрҗемәләреннән, халык өчен бик тә кирәкле русча-татарча, татарча-русча сүзлекләрдән, татарча беренче медицина китапларыннан, аш-су китапларыннан башка күз алдына китерү мөмкин дә түгел. Әхмәтгәрәй Хәсәни нәшриятының Россия империясе укымышлы татарлары арасында нинди әһәмияткә ия булганлыгын башка китапчы-календарьчы сәүдәгәр дә аңлаган. Шундыйлардан берсе — Шәрәфетдин Шаһидуллин, календарьчы, игъланчы. 1908 елда ул сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр өчен... «Идел нәһерендә (елгасында — М. М.) юлдаш» исемле бер альбом (юл күрсәткеч) чыгара. Идел буена урнашкан бөтен шәһәрләрнең социаль-экономик хәлләре, уку йортлары, халык һөнәре, сәламәтлек саклау эшенең куелышы белән таныштырган бу альбомда Казан шәһәренә аеруча зур урын бирелә. Шунысы характерлы, Казан нәшриятлары турында сүз чыгуга, Ш. Шаһидуллин альбомның тулы бер битендә «Гасыр» нәш-

[1] Каримуллин А. Книги и люди. Казань, 1985 (Предисловие М. А. Усманова).

шриятының ике ел эчендә бастырып чыгарган китаплар исемлеген бирә. Бөтен бер альбомда — бары тик «Гасыр» нәшрияты гына! Нигә алай? Җавап гади: Ш. Шәһидуллин биргән бу исемлектә бер генә дин китабы да юк. «Гасыр», шулай итеп, Ш. Шәһидуллин исәпләгән ике елында (1907, 1908) бары тик матур әдәбият («Беренче театр», «Хат болгатты», «Яшь гомер», һ. б.), фәнни әдәбият («Күк һәм йолдызлар», «Җир»), педагогика («Яшь балаларны ничек тәрбияләргә?»), медицина («Дифтерит», «Скарлатина», «Файдалы киңәшләр (корсаклы хатыннарга)») китаплары гына бастырган. Бу нәшриятның алга таба эшчәнлеге дә гел шулай, һәм мондый эшчәнлек Әхмәтгәрәй Хәсәни компаниясен туп-туры Октябрь революциясенә китереп тоташтыра. Ә. Кәримуллин бу нәшриятның тәҗрибәсе Октябрь революциясеннән соң «Яңа китап» нәшрияты эшчәнлегенә органик рәвештә кушылып китүен документлар белән исбатлый. Ә. Хәсәнинең зур тәҗрибәле китапчы булуын истә тотып, Татарстан партия-совет хезмәткәрләре, язучылар, журналистлар, галимнәр аннан яңа кооператив нәшрият төзүен үтенәләр. Бу кооперативка Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, К. Нәҗми, Ш. Байчура, М. Бәдәйли һ. б. яшь әдәби көчләр туплана.

Әхмәтгәрәй Хәсәни дөньяда нибары илле ел яшәгән. Әмма никадәр мактаулы эш, хезмәт җимешләре калдырган ул киләчәк буыннарга...

Ә. Кәримуллинның бу энциклопедик хезмәтен кат-кат укыйм һәм бер аяныч уйдан һич тә аерыла алмыйм. Әхмәтгәрәй Хәсәнинең хатыны — «Гасыр» нәшрияты буенча «компаньоны» Зәйнәп апа алтмышынчы еллар башында исән иде әле. Аның иреннән калган гаҗәеп бай китапханәсе, күпләгән альбомнары, истәлек дәфтәрләре бар иде. Болар барысы да биек, пыялалы мәһабәт, затлы шкафларда бик астында саклана иде. Мин Зәйнәп апа янында икеме-өчме мәртәбә булдым, шул вакытта язып алган истәлекләр, мәгълүматларга әле дә рәхәтләнәм. Дөрес, аларны язганда, минем күзем гел теге шкафларда, җиз йозаклы, калын-каты тышлы альбомнарда була иде, әмма, Зәйнәп апа, күпме генә үтенсәм дә, шкафларын ачмады: ачы тәҗрибә авазын ишетә иде әле ул. Андый бай китапханәләрдәге кыйммәтле китапларны гыйлем юлындагы очраклы кешеләр азмы таладылар... Бу китапханә, андагы китаплар, альбомнар ахырдан ничектер, эзсез югалдылар. Бик кызганыч. Бу — Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов, Г. Ибраһимовларга кагылышлы бик күп хатлар, фоторәсемнәр, истәлек-автографларны югалту дигән сүз...

Татар китабы югалтуларны күп күрде. Тарихта билгеле: Казан нәшриятларында басылган китапны халыкка җиткерү өчен, китапчылар төрле юллар, әмәл-ысуллар уйлап тапканнар. Арадан берсе — китапчылар Казанга бәхет эзләп килгән Арча, Тау ягы егетләренә китап төяп, аларны Малмыж, Әгерҗе, Кукмара, Сарапул якларына озатканнар. Теге егетләр исә кул яки ат чанасына төялгән ул китапларны авылдан-авылга йөреп сатканнар. Арада, әлбәттә, дин китаплары да булган. Әмма самодержавие ялчыларында бу хәл шик уяткан: 1910 елларда китап сатып йөрүче егетләрне Вятка губернасының Сарапулдагы жандарм ротмистры кулга алдырган һәм төрмәләргә озаттырган. Бик озак тикшеренүләрдән соң гына егетләр азат ителгәннәр, тик китаплар гына кайтарылмаган. Бу турыда архивта материал байтак. 1911 елгы Иж-Буби вакыйгаларында жандармнар отряды погром белән юлга чыккач, Буби шәкертләре, куркып калып, төне буе китап, кульязма яндыралар, аларда Тукай, Гафури шигырьләре була, «Марсельеза» тәрҗемәсе була. Ә жандармерия боларның берсен дә яратмый. Китапка кадерсез караш марксизм-ленинизм тәгълиматын үзләштермәгән кәе идеология фронтында эш йөрткән кайбер шәхесләр тарафыннан яңа заманда да үткәрелде. Утызынчы елларда, иске хәреф белән язылган китап безгә азык була алмый дигән ялган караш нигезендә шәхси кулларда, китапханәләрдә сакланган бик күп китап кадерсез калды. Хәлбуки, ул китаплар арасында В. И. Ленин хезмәтләренең татарчага беренче тәрҗемәләре, Коммунистик интернационал, Париж коммунасы турындагы хезмәтләр, Л. Н. Толстойдан, Пушкиннан, Лермонтовтан тәрҗемәләр, ниһаять, Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Коләхметов, М. Гафури китаплары бар иде. Вульгар социологларның ул шаукымына утыз җиденче елның, КПСС Үзәк Комитеты карарлары белән инде нигезле тәнкыйть ителгән хаталары килеп кушылды, ул чорда байтак китап зарар күрде.

Заманнар үтте, КПССның XX съезды идеология өлкәсендә тарихи әһәмиятле мәгълүм карар кабул итте. Гыйлем, тарих өлкәсендә яңа эзләнүләр, яңача критерийлар күренә башлады, бөек Ленинның бөтен тәгълиматларын тирәннәнрәк өйрәнеп коралланy кирәклеге аңлашылды. Ә. Кәримуллинның татар китабы тарихын өйрәнергә керешүе әнә шул — XX съездның тарихи-тирән мәгънәле карарлары атмосферасында башланды. Бәхеткә каршы, китап, документ, кульязма җыю, туплау, барлау өлкәсендә Ә. Кәримуллин ялгыз булмады. Бу мәсьәләдә тарих фәннәре докторы Р. И. Нәфиков, язучы һәм галим Н. Исәнбәт (ул чакта әле яшь аспирант, хәзер инде танылган галим), тарих фәннәре докторы М. Г. Госманов Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге гыйльми китапханә хезмәткәре, кульязмалар өйрәнү буенча танылган белгеч А. Фәтхиев менә күп еллар буе инде фидакарь хезмәт күрсәтәләр. Әле

соң түгел! Җыярга, тупларга, өйрәнергә!— дип, даими рәвештә набат сугып торалар алар. Алар мең кабат хаклы: Ә. Кәримуллинның әлеге хезмәтендәге беренче бүлекне — «Мәскәү шәһәрендәге беренче татар китаплары» дигән бүлекне генә карап чыгыгыз: Мәскәүдә татар телендә Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты, Үзәк Мөселман комитеты, Милләтләр эше буенча Халык комиссариаты чыгарган татар китаплары бөтен Шәрыкка революцияне алга таба үстерергә хезмәт иткән. Революция тарихында татар китабының мактаулы урыны бар. Үзәк Шәрык нәшриятында эшләгән, яки китапларын чыгарган бүгенге яшьләр өчен исемнәре аз таныш булган Самат Шәрәфетдинов, Мөхәммәт Парсин, Мәхмүд Максуд һ. б.— ихлас күңелдән, аскетларча бирелеп Шәрыкта барган революцион үзгәрешләргә китап белән ярдәм иткәннәр. Мәскәүдәге «Нәшрият» (пайщиклар җәмгыяте) исемле оешманың тарихы да бик кызыклы. Ә. Кәримуллинга кадәр моны әле җентекләп өйрәнгән кеше юк иде. Эченә керсәң — монда Г. Ибраһимов, С. Атнагулов, Г. Нигъмәти, Ш. Усманов, Ф. Агиев, Г. Ходаяров, Г. Афзал һ. б. язучыларның хезмәтләре, эзләре бар икән.

Монографиядә аерым бүлек итеп СССР халыкларының Үзәк нәшриятында басылган татар китаплары тарихы бирелгән. Үзәк Нәшриятның отчетын 1928 елның февралендә СССР УБК каршындагы Милләтләр Советы Президиумы тыңлый. Кабул ителгән карарда матур әдәбияттан оригинал әйберләр чыгару кирәклеген әйтү белән бергә «авыл хуҗалыгы турында һәм политик әдәбият чыгаруны көчәйтү» кирәклеге турында да әйтелә. Бу пунктның үзенчәлекле әһәмияте бар. Утызынчы еллар — илебездә, аеруча милли төбәкләрдә, атеистик пропаганданың бик нык сугышчан формада алып барылган чоры. Кызганычка каршы, урындагы кайбер җитәкчеләр атеистик пропаганданы үзләренчә аңлыйлар һәм дингә ышанучылар арасында системалы, сабыр аңлату эше алып барасы урында аларның дини хисләрен мәсхәрә итүгә юл куялар, мәчетләрне — халык сәнгате әсәрләрен — җимерәләр һ. б. Болар марксизм-ленинизм тәгълиматын өйрәнмәгән, үзләренең эшгамәлләренә шуны корал итә алмаган кешеләр иде, әйтергә кирәк, чын мәгънәсендә коммунист, белемле, ленинчы җитәкчеләр булган урыннарда мәчет тә, чиркәү дә җимерелмәде — ләкин теге «перегибщиклар» байтак зарар салып өлгерделәр. Әйтик, атеистик пропаганданың үзенә. Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының, партия документларының асыл нигезе исә атеистик пропаганда алып баруда фәннигыйльми әдәбиятны мөмкин кадәр күбрәк бастырып, авылларга, крестьяннар арасына күбрәк таратуны таләп итә иде. Крестьян, аз сөтле сыерын мулладан яки мәзиннән өшкертеп, күп сөт көтмәсен, авылда яңа населле сыер үрчетергә кирәк, крестьян моны китаптан укысын. Җиренә чәчкән перспективасыз орлыктан зур уңыш алу турында хыялланып, язмыштан көтеп ятмасын, крестьянны яхшы сортлы орлык чәчәргә өйрәтергә, аны шул орлык белән тәэмин итәргә, авыл хуҗалыгы буенча китап укырга өйрәтергә кирәк. Яшен яшьнәгәндә дә култык астын сыпырып кына утырмасын: яшен нәрсә ул, каян килеп чыга — китап аркылы шуны өйрәтергә кирәк. Берәм-берәм әнә шулай табигать көчләренең серен, игенчелек, терлекчелек нигезләрен фәнни аңлату — атеистик пропаганданың иң көчлесе шул түгелмени? Мәскәүдәге Үзәк нәшриятның татар секциясе нәкъ әнә шул нәрсәгә игътибар иткән. Монда татар телендә В. И. Ленинның тарихи хезмәтләре, кооперация турында, коммунистик хәрәкәт турында күп кенә китаплар басылган. Болар арасында «Кешенең табигать белән көрәше», «Политграмота китабы», «СССР экономикасы», «Үсемлекләр тормышы», «Экономик география» һ. б. бик күп әһәмиятле китаплар бар.

Мәскәүдә чыккан татар китаплары тарихы — Ә. Кәримуллинның зур энергия сарыф итеп ирешкән хезмәте.

Ә. Кәримуллинның бу монографиясе — интернациональ характерда. Китаптагы татар-казакъ нәшриятлары мөнәсәбәтләре, типограф М. Идрисов эшчәнлеге, Н. Ф. Катанов, И. Н. Харитонов һ. б. турындагы мәгълүматлар татар шрифтының, татар китабының заманында Россия төркиләре арасында мәгърифәткә таба барышта искиткеч зур роль уйнаганын исбатлый. Моның шулай икәнен профессор Н. Ф. Катанов, татарны ихтирам итә, ярата белгән Иван бабай Харитонов аңлаганнар. Харитоновның татар халкына иткән игелекле хезмәте турында киләчәктә монографияләр языла. «Рус белән тормыш кичердек сайрашып» дигәндә, минем күз алдына иң беренче чиратта ул — Тукай китапларына юл ачкан Харитон абзый килә... Татар журналистлары, китапчылары Харитоновның безнең культура тарихындагы урынын үз заманында билгели белгәннәр. 1909 елда И. Н. Харитоновның матбугатта эшли башлавына 40 ел тулуны бәйрәм иткәндә, татар прогрессив интеллигенциясенең рус прогрессив интеллигенциясенә ихтирамлы мөнәсәбәтен, шул чорның газета-журнал мәкаләләрендә укыганнан соң бу мөнәсәбәтләргә сокланмый калу мөмкин түгел.

Тарихи сәбәпләр аркасында китапларыбыз, кульязмаларыбыз таралган. Кайберләре план буенча, кайберләре язмыш буенча. Татар китаплары илебезнең иң зур китапханәләре булган Мәскәүдә Ленин исемендәге үзәк, Ленинградның Салтыков-Щедрин исе-

мендәге публичный китапханәләрендә саклана. Революциягә кадәр чыккан татар китабының мәҗбүри данәләрен Хельсинки китапханәсе дә алып барган. Хельсинки шәһәрендә татар китаплары университет китапханәсендә һәм Милли китапханәдә саклана. Болар белән миңа кыска гына вакыт эчендә бераз танышу бәхете эләкте. Татар китаплары Һиндстанның зур-зур китапханәләрендә дә очрады. Татар халык җырлары, Тукай әсәрләре тупланган китаплар төрле шрифтта, татар телендә Көнбатыш илләрендә дә, Япониядә дә басылган. Юл йөргәндә, боларны да тотып карарга, танышырга туры килде. Әмма Ватикан музеенда ук татар әсәре очрар дип башыма да килгәне юк иде. Пыяла астында кулъязма татар китабы: яхшы кәгазьдә, таза җеп белән төптән тегелгән. „Racconti turcomanni" («Төрки хикәяләре, XVI гасыр» итальянча) дип куелган.

Беренче битен үк иркенләп укып киттем. Татарча, бездә күп очрый торган хикәяләр. Безнең матбугатта проф. Н. Ф. Катанов китапханәсенең аянычлы язмышы турында язылган иде инде. Бу мәсьәләнең тарихи аспектын Ә. Кәримуллин тагы да җентекләбрәк тикшерә. Әйе, Катанов китапханәсенең чит илгә китүе — бу инде, русча әйткәндә, «утечка мозгов». Бу китапханәнең эчтәлеген 1913 елда «Вакыт» газетасы болай язып чыга: китапханәдә күпчелеге — төрки китаплар. Күп китаплар букинистлардан җыелган. Кайберләрен Катанов үзе күчереп язган. Мәсәлән, Рычковның «Оренбург тарихы» шундый. Моннан тыш, китапханәдә бөтендөнья ориенталистларының иң сирәк очрый торган китаплары бар. Алар Европа, Һинд, гарәп, фарсы телләрендә. Китапханәдә атласлар, рәсемнәр, энциклопедияләр тупланган. Барлыгы 24 шкаф, һәр шкафта 6 шар шүрлек, барлыгы 10 мең том чамасы (1913, 1213 сан). Катановның китапханәсен сатып алу турында матбугатта күп сүз алып барылса да, Казан-Оренбург байларыннан бер генә кеше дә бер генә сум да акча кертми. Тукай искә төшә. Халыкның заманында бәрәңгегә каршы көрәшкәнен искә алып, шагыйрь болай дип язган иде:

*Күп җәфа күрдең бу җиргә син килеп*
*Америкадан,*
*Нишлисең, тәкъдир шулайдыр, халкыбыз шул*
*бик надан.*

Тукай ачуы килгәнлектән, ачынып, бөтен бер халыкны «надан» дип атаган. Ләкин, Тукайны гаепләргә ашыкмыйк. Халкыбыз гыйлемгә, китапка Болгар заманнарыннан ук ихтирам саклап килгән. Әмма зур китапханәне «абстракт халык» сатып ала алмый. Моңа — сәүдәгәрләр, эшкуарларның гына көче җитә. Алар исә — надан.

Мондый зур байлык кая китә соң? 1914 елда ул Төркиянең «Вәкыфлар назарәте» тарафыннан сатып алына, аны Алтын Мөгез ярына махсус бер бина салып урнаштыралар. Төркия хөкүмәте аның җитәкчесе итеп шунда яшәгән татар язучысы Муса Акъегетзадәне билгели. Муса китапханәне тәртипкә китерү эшенә Төркиядә белем алучы татар егетләрен тарта. Китапханәдә рус китаплары да байтак була. Аларның кайберләрен Муса төрек теленә тәрҗемә итә.

Менә шулай, милли байлыгыбыз (барлыгы 22 телдә басылган китаплар) читтә яшәп ята... Ә шул фондта испан телендә язылган «Болгар тарихы» да бар.

Татар китаплары үз илебезнең дә әллә кайдагы ерак китапханәләрендә, музейларда саклана. Бу җәһәттән Себер ягы китапханәләре, музейлары кызык. Ул якта хакимлек иткән Строгановлар нинди генә сәнгать әсәре, китап, кулъязма җыймаган! Әйтик, Томск дәүләт университетының китапханәсендә шундый бер фонд бар. Анда уйгур, татартөрки һ. б. көнчыгыш халыклары телендә китаплар тупланган. Әлбәттә, Томск университетында аларга ихтыяҗ юк...

Ә. Кәримуллинның бу хезмәтен укыгач, үзебезнең Казандагы китаплар язмышы турында да уйланасың. Археографик экспедицияләрдә табылган иске китапларны университет китапханәсе хәзер, «стандарт түгел» дип, кабул итми. Табылган китаплар, әлбәттә инде, тузган, почмаклары ашалган, ертылган. Кая инде стандарт! Гыйльми байлыгыбыз булган элеккеге татар китаплары бер-береннән илле адым ераклыкта урнашкан өч үзәккә таралган: университет, В. И. Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәләре һәм СССР Фәннәре Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты китапханәсе. Кайвакытта бер чыганакны эзләп, шул өч үзәк арасында йөгереп йөрисең. Киләчәктә, бәлки, борынгы китапларны, кулъязмаларны бер ноктага туплау турында уйларга кирәктер? Табылган китапларны, бөтен республикабыз каршында галимнәрдән торган бер комиссия төзеп, мәгълүм бер урынга гына кабул итү турында уйларга кирәктер? Мәсәлән, 1983-84 елларда мин үзебезнең гаиләдәге иске китапханәне кая тапшырырга белмичә йөрдем. Анда бик иске кулъязмалар, XIX йөз татар китаплары, чит ил басмалары, XX йөз башына караган 200 дән артык китапкулъязма бар иде. «Стандарт түгел» дип кабул итмиләр. Китапларда еллар эзе — чорма тузаннары, яңгыр тәэсире, келәт асты «халкы»ның теш эзләре диссертация язган яшь галим әрсезлеге белән китапны аркылы тишеп йөргән көя юллары... Бу китаплар ни генә күрмәгән, кайда гына аунамаган... Ярый инде, шуның кадерен белүче табылды: Г. Ибраһимов исемендәге институт — моны алырга риза булды һәм өемә машина җибәрде. Атабабадан калган китапханә белән аерылу авыр булды, әмма күңелем тыныч иде: китапханәне институт исеменнән фидаи җанлы, гыйлемнең фанатигы Марсель Әхмәтҗанов кабул итеп алды.

Татар китабы, кульъязмасы дигәндә, минем күз алдыма зур галим Әбрар Кәримуллин белән бергә китап-кульъязма җыю буенча халкыбызга игелекле хезмәт күрсәткән Миркасыйм Госманов (әлеге китапка сүз башы аның тарафыннан язылуы һич тә очраклы түгел), китап-кульъязмадан башка бер генә көн дә яши алмый торган, фәнгә аскетларча бирелгән Альберт Фәтхиев, Марсель Әхмәтҗановлар килә. Заманында «Шура» журналында Н. Ф. Катанов турында бер мәкалә басылган. Анда мондый юллар бар: «Берәү әйткән иде: Катановны чиртсәң, гыйлем чыга, дип» («Шура», 1910, 2-3 сан, 813 б.).

Бу сүзләр безнең китапчы, кульъязмачы галимнәребезгә дә туры килә. Әйе, безнең гыйлем дөньясында Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, И. Готвальд, Н. Ф. Катанов, В. В. Бартольдлардан килгән матур традиция дәвам итә. Ә. Кәримуллинның соңгы китабы әнә шуның ышанычлы бер дәлиле.

...XVI гасыр француз философы Мишель Монтень «Тәҗрибәләр» дигән хезмәтендә антик заманнан кызыклы бер факт китерә: Александр Македонский поход сумкасында «Илиада» һәм «Одиссея» китапларын йөртә икән. Көннәрдән бер көнне, сумкасы обозда артта калгач, ул үзенең бер полководецыннан укып торырга дип шул китапларны сораган. Полководец исә походка үзе белән боларны алмаган икән.

— Ничек?— дип җикеренгән аңа Македонский.— Ничек? Шул китаплардан башка син походка чыктыңмы?— һәм ул үзенең сугышчан полководецының яңагына суккан.

В. И. Ленин, галимнәрнең исәпләве буенча үз гомерендә 300 мең данә китап караган; укыган, өйрәнгән, күчереп алган, кабат-кабат актарган. Китапка ул кешегә караган кебек караган. Октябрь революциясе булып, совет хөкүмәте яши башлауның беренче сәгатьләрендә үк В. И. Ленин, Мәгариф эшләре халык комиссары А. В. Луначарский белән сөйләшкәндә, нәшрият, китапханә мәсьәләләренә килеп чыккач, болай дигән: «Китап— зур көч. Революция нәтиҗәсендә китапка ихтыяҗ бик тә нык артачак».

Чыннан да, китап язмышы белән кеше язмышы бер үк бит! Шуңа күрә бит монархлар, тәхеткә килү белән, иң беренче нәфрәтләрен китапка күчергәннәр. Хәлиф Гомәр үз заманында мәшһүр Искәндәрия китапханәсен яндырган. Гарәпләрнең китап кадерен белгәннәрен яратмаган ул. Гарәпләр Испаниядә вакытта Кордовада 600 мең китаплы китапханә булдырганнар. Андалузиядә исә зурзур 18 китапханә булган. Гарәпләрдә ул заманнарда байлык китап саны белән үлчәнгән.

...Испанияне гарәпләр кул астыннан азат итү өчен көрәш вакытында испан монархлары бу көрәшкә дини төсмер биреп Андалузиядәге гарәп китапханәләрен яндыралар. Бу зур тарихи җинаять була. Өч гасырдан артык вакыт узгач, бөек немец шагыйре Генрих Гейне «Әлмансур» дигән әсәрен шул вакыйгаларга багышлый. Әсәрнең төп геройлары Әлмансур белән Хәсән менә болай сөйләшәләр:

Әлмансур: Без Гренадада китапларны утка ташлыйлар, дип ишеттек.

Хәсән: Бу әле уенның башы гына булган: китапларны яндырган җирдә ахырдан, ниһаять, кешеләрне дә яндыра башлыйлар...

Бөек Гейненың бу әсәре (1820) немец реакционерларына ошамый, бу әсәргә каршы әшәке кампания башлана. 1914 елда шагыйрь С. Сүнчәләй «Әлмансур»ны немецчәдән турыдан-туры татарчага тәрҗемә итә. «Китапларны яндыру» турындагы фикерләр жандармериягә ошамый, Сүнчәләйне эзәрлекли башлыйлар. Гейненың фикере исә — саф хакыйкать! Властька килүгә, Гитлер иң беренче эш итеп шәһәр урамнарында китапларга аутодафе оештыра. Карл Маркс, Фридрих Энгельс китапларыннан торган учакларга, сүнмәсен өчен, Гейне томнарын ташлыйлар. Шуннан соң ун ел да үтми, Освенцим, Дахау, Маутхаузенда кешеләрне яндыра башлыйлар. Йә, Гейнемы алдан күрмәгән?

Ләкин китапларны яндырып бетереп булмый. Җир шарының ниндидер бер почмагында аның берәр экземплярлы сакланмыйча калмый. Һәм шуннан ул яңадан терелә, яши башлый. Тик кеше гомере генә кабат кайтмый. Кешегә гомер бер генә тапкыр бирелә.

Китап гомере, кеше гомере...

1986 ел — Тынычлык елы. СССР тәкъдиме белән ЮНЕСКОның XVI Генераль Ассамблеясе 1972 елның Халыкара китап елы дип белдергән иде. Тынычлык елы белән Китап елы арасында турыдан-туры бәйләнеш бар. Китап — тынычлыкны саклауда һәрвакыт зур көч булып килгән.

Фәннәр докторы Ә. Кәримуллинның «Китаплар һәм кешеләр» дигән монографиясен укыганда туган уйлар әнә шундый.

# БӨРЕНЕ ТАМЫР УЯТА

Яшь шагыйрьнең беренче китабын укыйм. Яратып, куанып укыйм — сәләтен, мөмкинлекләрен тоеп сөенәм. Аптырап, ачуым чыгып укыйм — менә дигән шигырьне юктан гына харап итеп куюына җаным кыза.

*Бу чыбыклар — күңел кыллары,*
*Кунган чыпчыклары — тоеннәр...*

«Телефон чыбыклары» исемле әсәрнең шушы беренче юлларын күздән кичерүгә сәерсенеп тукталам. Кабат укып карыйм. Тукта әле, нәрсә була соң бу? Егерменче еллар шагыйре язса, мин, бәлки, гаҗәпләнмәс тә идем. Болай «шаккатыризм»га тартым образлар белән язу ул чорга хас:

*Безнең лирабыз — тимер юл зигзагы,*
*Ә байрак — болытка кадалган ялкынлы торбалар...*

Монда да сәерлек җитәрлек бит, лакин яшь Туфанның бу образларында зәвыксызлык юк. Өстәвенә, алардан шул дәвер колориты, оптимистик сулыш бөркелеп тора, шуңа күрә табигый тоела. Әмма да инде «чыпчыклы күңелләр»?! Бр-р! Күз алдына китерү имәнеч.

Дөрес, шагыйрь теләсә нәрсә турында һәм теләсә ничек язарга хаклы. Ләкин — бер шарт белән — табигый килеп чыкса гына, ышандыра алса гына.

Шулай да шигырьне укып бетерик әле:

*Кемнең җаны чыңлый чыбыкларда,*
*Кем язмышы җилдә тирбәлә,*
*Кем ядкяре җир-күк арасында*
*Йомры чыпчык булып төйнәлгән?*

Ахыргы өлеше алай ук сәер түгел икән. Хәтта чыпчык та ярыйсы ук сөйкемле образга әйләнгән. Метафора, үстерелеп, шулай ук матур гына тәгәлләнеш таба. Башлый белмәсә дә, тәгәлли алды шагыйрь.

Студент чаклардан бер вакыйга искә төшә: шулай кичен тулай торакта чәй эчәргә әзерләнеп йөрибез, күршеләрнең берсе килеп керде. Гадәттәгечә конспект-мазар, янсә чәй-шикәр кирәктер инде моңа дип уйларга өлгермәдек.

— Егетләр, илле сумлап акча биреп тора алмассыз микән? — дип сорады.

Аена кырык сум стипендиягә генә яшәгән студентка мондый сүзләр башка суккан кебек тәэсир итә. Стипендия аласы көнгә кадәр әле ерак икәне, таушалып беткән ике бишлектән гайре кесәсендә ни дә булмавы исенә төшеп, әче сызып куя аның... Дөрес, гозер белән керүченең күзләрендә ниндидер шаян чаткы чагылып узды бугай, ләкин ул безнең аңыбызга барып җитми калды.

Су капкан сыман тын утыруыбызны күргәч, әрсез күрше:

— Алайса, бер пешереплек чәй генә булса да бирегез инде,— диде һәм... авызын ерып җибәрде. Фәкать шуннан соң гына безгә барып җитте: юри безнең ушны алуы икән!

Актыкны чәйне булса да кулына тоттырдык. Хәтта шатланып биреп чыгардык бугай әле, чөнки акча табу янында ул бөтенләй чагыштыргысыз кечкенә булып тоелды.

Әлеге шигырьдә дә менә шундый эффект. «Шаккатыризм»лы беренче строфаны укып уза алсаң, гади генә язылган юллар да матур, тирән мәгънәле сыман тоела, җанга якын булып китә. Аннан соң, монда инде контекст бар, образны кабул итүгә укучыны азмы-күпме әзерләү бар. Ә шигырь башланып кына киткән чакта андый контекст каян килсен ди. Шуңа күрә дә күңел кыллары урынында алай ансат кына телефон чыбыкларын күрәсе килеп тормый. Ул чыбыкка әле чыпчык та кунган булса — бигрәк тә. Шигырь түгелдер, шигырьгә пародия генәдер бу дигән шөбһәле уй уяна.

Кыскасы, ап-ачык: автор гади генә тормыш күренешеннән дә үзенчә мәгънә чыгарырга, образлы фикерләргә омтыла. Ә менә чама хисе, зәвык сизгерлеге, күрәсең, җитеп бетми.

Сүз Рафаил Газизов, аның «Бөре керфекләре» исемле шигырьләр җыентыгы турында бара. Дөньяга чыгуына елдан артык вакыт узса да, китапның матбугатта булсын, бүтән урыннарда булсын телгә алынганы юк әле. Әйе, бездә анализлы бәя, рецензия күрмичә, шыпыртын гына күздән югала, җиңел генә онытыла торган китаплар чыккалый. Әллә бу да (яшь шагыйрьнең беренче китабы!) шундыйларданмы? Бөтенләй үк тәнкыйтьтән түбән әйберме әллә ул? Поэзиянең канатлы тул-

---

Газизов Рафаил. Бөре керфекләре: Шигырьләр.— Казан, 1985 («Яшь шагыйрьнең беренче китабы»).

пары — Пегас ялына Р. Газизовның үрелүе юкка гына микәнни? Әгәр чыннан да шулай булса, әлбәттә, бу китап турында сүз озайтып торуда мәгънә юк.

Кемгә ничектер, әмма минем күңелгә юл тапты бу иҗат. Шагыйрьлек нуры бар Рафаилдә. Шуңа күрә дә мин аның әсәрләре — хәтта камиллектән шактый ерак торганнары да — нинди дә булса анализ, бәя күрергә тиештер дип уйлыйм.

Әле телгә алынган шигыреннән үк күренде: Р. Газизов метафоралар белән фикерли. Бу аның образлы фикерләвендәге төп хасият. Аңлап эш иткәнме ул, аңламыйчамы, анысы караңгы, әмма яшь шагыйрьнең уңышлары да, уңышсызлыклары да метафорада, метафора белән эш итә белү дәрәҗәсенә бәйле.

*Бәхет орлыклары чәчә кеше,*
*Чәчкеч яза җиргә яңа җыр,*
*Башакларның алтын мыегында*
*Кубыз уйнар әле көзен кыр.*

Сигез генә юллы әсәрнең беренче строфасы бу, нибарысы дүрт юл, өч җөмлә. Һәм шунда — алты метафора: «бәхет орлыклары», «чәчкеч җыр яза», «башаклар мыегы», «Мыек — кубыз», «кубыз уйный кыр». Дүрт юл өчен алты метафора азмы, күпме — анысы хакында сүз куертып тормыйча, шуңа гына игътибар итик: боларның соңгы икесе шагыйрьнең үзенеке булып, калганнары — шактый таушалган, тоныкланган метафоралар. Ягъни эмоциональ тәэсир көченә әнә шул автор метафоралары гына ия. Фикер формалаштыруда катнашсалар да, калганнары тәэсирне тоныкландыруга, шигырьне авырайтуга күбрәк хезмәт итәләр. Җитмәсә, «Бәхет орлыклары» дигәне, строфадагы төп фикергә бәйләнмичә, образ тукымасыннан читтә кала, ул монда — «эшсез», артык. Шигъри фикер исә болай: язын чәчкеч язган көйне кыр, көз җиткәч, башаклар кубызында уйный. Метафоралар чылбыры — җәенке метафора бу.

Шигырьне укуны дәвам итик:

*Язгы көннең таңге нурларычнан*
*Иртә торып эшли кешеләр...*

Шагыйрь, әлеге җәенке метафорадагы фикерне калдырып, бөтенләй икенче нәрсә турында сөйли башлады. Бәлки, ул шигырьнең ахыргы юлларында аңа әйләнеп кайтып, шигырьне түгәрәкләп куяр?

*Бу иртәдә алар чәчкечләргә*
*Килеп кунган кошлар төсләләр.*

Юк, булмады. Аерым алганда матур тоелуларына да карамастан, бу юллар да шигырьгә бернәрсә өстәмәде. Хәтта боларында шигырьнең характерына һич туры килми торган комик мәгънә төсмере калкып чыга. Бу «кошлар» алда телгә алынып онытылган «бәхет орлыкларын» чүпләргә дип кунганмы әллә? Шулай уйламасаң булмый да, беренче строфа белән ул башкача берничек тә бәйләнә алмый. Әсәр, шулай итеп, таралып төште, шигырь юкка чыкты.

Образлар да бар иде бит югыйсә. Аерымаерым караганда матур да, мәгънәле дә кебек иде үзләре. Ә шигырь барыбер юк. Чөнки монда ул образларга эш юк. Нәрсә әйтергә теле автор — моны ул үзе дә белми кебек.

Әлеге ике әсәргә җентекләп тукталуның сәбәбе шул: алардагы җитешсезлекләр Р. Газизов өчен бик характерлы. Гомумән, фикер ачыклыгы җитмәү, образлар логикасындагы чатаклыклар аның әсәрләрендә еш очрый. Мәсәлән, «Кыйблаларга борыла җан», «Күз — карт кияү...», «Кояш. Яңгыр. Буран» дигән шигырьләре дә шулай ук логик яктан бер-берсенә бәйләнми торган ике өлешкә аерылганнар. Шагыйрь гадәти тасвирый стильдә язып килә-килә дә, мавыгып китеп, гади метафораны киңәйтә, җәя башлый. Ә метафора, җөмлә эченнән чыктымы инде, ахырга тиклем үстерүне таләп итә. Р. Газизов исә аны җөмлә эченнән сөйрәп чыгара да, ташлап, икенче метафора белән «уйнарга» керешә. Нәтиҗәдә, әсәр эчендә логик каршылыклар, төгәлсезлекләр пәйда булып, сәнгатьчә бөтенлек югала.

Метафора ясауда чама онытып җибәрүнең бүтән төрле мисаллары да очрый. Әйтик, «Кош канаты — скрипка кылы» ди ул. «Кош канаты — скрипка», дисә дә, мин риза әле, әмма инде канатны һич кенә дә кыл рәвешендә күз алдына китерә алмыйм.

*Болытлар — боз, кошлар саллар булып*
*Ага кукта — төпсез елгада.*

Моны күз алдына китерү шулай ук кыен. «Саллар» «бозлар»га караганда артык кечкенә булып чыга ич. Мондый салны ул бозлар шундук эштән чыгарачак. Р. Газизов язганча ага алмаячак алар.

Вак кына төгәлсезлекләр кебек инде үзләре, ләкин шигырь юлларын ышандыру сәләтеннән мәхрүм итәләр.

*Тәрәзәгә*
*Тамчы әнисенең*
*Йөрәк тибешләрен язып бара.*

Бу мисалда исә сүз тәртибен бозу, юлларны дөрес бүлмәү метафораны гына түгел, җөмләне дә аңлашылмаслык хәлгә китергән. Сүзләрнең үзара кирәксез бәйләнешләргә керүе аркасында, җөмләнең иясе югалган.

Менә бу юллар Г. Тукайга багышланган бер әсәрдән:

*Шагыйрь һәр көн баррикадаларда*
*Байрак итеп үзен яндырган.*

Яңгырашы матур, сүз дә юк. Образлары да эчтәлекле сыман: автор Тукайны баррикадада ялкын телләрен хәтерләтеп җилфердәгән байракка тиңләмәкче. Ләкин бу — ният кенә булып калган. Чөнки монда яңу — туры мәгънәсендә. Баррикадада Тукай үзен яндыра икән бит! Менә шушы

күренеш байракка, байрак җилфердәвенә тыңләнә икән. «Баррикада» сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылса, әлбәттә, әйбәт әйтелгән дияр идек. Ләкин әсәрдән алай аңлашылмый бит. Беренче юлны укуга ук Тукайны чын баррикадада итеп күз алдына бастырасың. Кыскасы, образ шактый катлаулана, анда каршылыклар хасил була. «Баррикада» сүзенең туры мәгънәсе өскә калкып чыгуы исә эшне бөтенләй бозып ташлый. Чөнки монысы инде Тукайга бөтенләй туры килми, тарихи дөреслекне бозу була.

Шул ук самимилеге аның фикер әйтү формасындагы шигырьләрендә кимчелекләр рәвешендә чагылса, кичерешләрен тасвирлаганда, балалар шигырьләрен язганда алыштыргысыз казанышка әйләнә.

## Кояшлы яңгыр

*Җил кызлары куктә керләр чайкый —*
*Керләр сыга, тамчы коела.*
*Кисәк селкеп ала, аннан элә*
*Алтын бауга — кояш нурына.*
*Шалтырап ала бәләк-чиләкләре,*
*Көянтәдә — җиде төс кенә...*
*Шул җиде төс — төсле музыкадай,*
*Моңнар ява явыл өстенә...*
*Җилләр, тынып, ял итәргә ятты*
*Көмеш нурдан чиккән үзәнгә...*
*...Балак сызганып, мин чаба яздым*
*Изге балачакның*
*Җиде төсле*
*Яңгыр тамчыларын эзләргә!*

Шигырьне хис ягыннан да, фикер ягыннан да төзек, бөтен дип ышанып әйтергә ярый. Иң мөһиме: шагыйрь якты бер күңел халәтен — туган як табигатенә булган самими мөнәсәбәт-хисен тәэсирле итеп бирә алган. Шигырь авазлар оештырылышы, аһәңлелек тарафыннан да камил. Соңгы строфада бик оригиналь яңгырый торган матур бер катлаулы эчке рифма (БАЛАК + ЧАБА — БАЛАЧАК) да бар. Ул, мәгънәви бәйләнешләрне көчәйтеп, строфадагы тасвирның укучы күңеленә уелып калуына булыша.

Шушындый характердагы әсәрләрне җыентыктан тагын да табып булыр иде. «Суык», «Кышкы авыл», «Болыннарга чыктым», «Кирмән буйларының һәрбер киче...», «Сөйләшәсе килә» — менә аларның иң истә кала торганнары.

Шулай итеп Р. Газизовның шагыйрь булуына шик калдырмый торган сыйфатлары хакында язарга да нәүбәт җитте шикелле.

Туган йортына карап, мәрхүм әтисе турында ул менә ничек уйлый:

*Әнкәйнең күз карашыннан*
*Өлге алып тәрәз куйган.*

Бер генә шигъри деталь, әмма никадәрле мәгънәви тирәнлек, ата-анага булган олы, самими мәхәббәт!

*Чиләк өшетерлек чишмәләр бар бездә...*
*Сабан туйлары көзгесендә*
*Гасырларны җыңгән таңнар ата...*
*Салам эскертләре төлке кебек*
*Бөгәрләнеп яткан кырларга...*
*Беләм, яшәвемнең мәгънәсе дә*
*Әни күзләрендә...*

Поэтик табыш дәрәҗәсендәге мондый юллар да шагыйрь файдасына сөйли. Болар аның художник-иҗатчы буларак потенциаль мөмкинлекләре кечкенә түгел икәненә ышандыра.

Соңгы елларда илебез картасында авыл исемнәре кими башлады — кечкенә авыллар бетә, тарала. Җыентыкта «Монда авыл булган» дип исемләнгән бер шигырь бар, ул кешеләре ташлап киткән әнә шундый авыл турында сөйли. Туган җирен, туган халкын өзелеп яратучы, шулар язмышы өчен борчылучы, гражданин-шагыйрьнең йөрәк авазы дияр идем мин бу әсәрне. Шагыйрь халкыбызның яшәү тамыры авылда икәнен бик ачык аңлый. Аның әлеге социаль күренешне фаҗига дәрәҗәсенә күтәреп тасвирлавы да тикмәгә түгел. Кисәтү яңгырый шигырь юлларыннан:

*Ә кешеләр өзә тамырларны,*
*Ялганмаслык итеп өзәләр...*

Шагыйрь бу фаҗиганең сәбәпләре турында да уйлана. Шуларның иң куркынычын атый. Ул — рухи гариплек:

*Шайтан таяклары, тигәнәкләр*
*Баскан ил картлары каберен,—*
*Бу авылдан качкан кешеләрнең*
*Тигәнәкләр баскан бәгырен.*

Тарихи хәтерне югалту бу. Ә тарихи хәтерне югалту ул һәрвакыт тарихи оптимизмның — киләчәккә ышанычның да җуелуына китерә. Шуңа да «тамырсыз» кешеләргә шагыйрьнең хөкеме каты: «Бу ташландык авыл — сезнең зират»,— ди ул.

*Исән килеш сез күмелгән монда,*
*Тигәнәкләр сезнең каберда.*

Миңа иң нык тәэсир иткәне гади генә менә бу ике юл булды:

*Дөньяда иң кызганыч җирләр —*
*Кеше ташлап киткән авыллар...*

Чыннан да, кызганыч, үгигә әвереләдерелгән тарих, ата-бабаларның киселгән өмете кызганыч... Тамырсыз дүңгәләкләрне, гадәттә, җил куып ышык урыннарга җыя, алар шунда өелә, ахырда басылып туфракка иңә. Тынчу шәһәрләрдәге нәсел-нәсәбен оныткан күпләрнең берсе булып көн күрүче «дүңгәләкләргә» карата шуңадыр микән күңелдә җылы хис юк.

Бу әсәр — әлеге Р. Газизов иҗатының иң югары ноктасы.

Чагыштырмача зур гына күләмле бу шигырьнең бер сулыш, бер күңел омтылышы белән язылганлыгы сизелеп тора. Сәнгатьлелек ягы да ярыйсы гына, әсәр тәэсирле. Һәр юлыннан, һәр сүзеннән шагыйрьнең йөрәк кайнарлыгы бөркелә.

Күңелендәге әрнеш, иң изге хисләр өскә калкып чыкканда, Р. Газизов, чыннан да,

шагыйрь икән.

Кызык: шигырьләрдә еш кына төгәлсезлекләр, хаталар очрап тора, әмма шуңа да карамастан, авторына карата күңелдә җылы бер хис уяна, зурая, көчәя бара. Вакыт-вакыт, әсәрләрнең ясалганлыгы яисә ясалып бетмәгәнлеге сизелеп-сизелеп китсә дә, ул үзе бервакытта да ясалма түгел, ул — эчкерсез, туры. Шуның белән күңелне яулый да.

Урман ешлыгын ерып чыккан кебек, әсәрләрендәге төгәлсезлекләр, җитешсезлекләр арасыннан шигърият, шагыйрь килеп чыга.

Әйе, фикерләве — шигъри; оригинальлек тә ят түгел аңа. Аерым юллары, образлары истә кала. Һәм, ниһаять, әйбәт кенә шигырьләре бар. Ягъни иҗади мөмкинлекләренә ышандыра Р. Газизов. Ләкин еш кына, образ уйлап табу белән мавыгып, шигырьнең төгәллек чиген үтеп киткәнен сизмичәрәк кала.

Шагыйрьне чынлап торып шагыйрь итә торган бер мөһим сыйфат бар. Ул — әрнү. Шигъри шалтыравыклар белән юанырга теләк тә, мөмкинлек тә калдырмыйча бөтен барлыгыңны, эчке-тышкы дөньяны үзенә буйсындырып, һәрвакыт киеренке бер халәттә тота торган күңел әрнешең, шуның чагылышы рәвешендәге темаң булу кирәк. Иҗатка шул табигыйлек, бөтенлек, зурлык бирә. Шул фикер бирә. Ни әйтергә теләвеңне үзең дә тәгаен белмәгәч, әлбәттә, шигырь таркау килеп чыгачак: ул образлы җөмләләр тезмәсенә әйләнә. Чөнки фикерсезлек образлар ясауны үзмаксатка әверелдерә, алар күпләп ясала, һәрберсе шәп, искитмәле. Берсен генә дә ташлап калдырасы килми — жәл! Автор аларны бергә өя дә өя, тик шигырь генә тумый.

Ә бит ул теманы Р. Газизов иҗатында бөтенләй юк дип булмый. «Монда авыл булган» шигыре, мәсәлән, шуңа мисал. Бар ул, тик шагыйрь аңа тиешле игътибар гына бирми, әһәмиятен аңлап бетерми кебек әле. Ул аның авыл кешесе булуыннан, авылда яшәвеннән килеп чыга. Хәзерге катлаулы экономик, социаль үзгәрешләр эчендәге киеренке тормышлы авыл турында әйтүем.

Бу китапка язган кереш сүзендә шагыйрь Зөлфәт менә нәрсә ди: «Кызык өчен генә язган юллар беркайчан да шигырь була алмый. Бу шигырьләрдән Мамадыш якларының тарихы, анда яшәүче кешеләрнең гадәт-холкы калкып чыга икән — моның өчен шагыйрьне мактарга гына кирәк.

Ни генә дисәң дә, чорның, туган ягыңның, туган халкыңның чагылышы бит ул шигырь!»

Зөлфәт дөрес тотып алган: менә шушы сыйфатны үстерергә иде. Әлеге бу сыйфат, бу бәйләнеш Р. Газизов иҗатында стихияле рәвештә генә калкып чыккалый.

Авыл язарга материал бирә. Ләкин шуннан артыгын түгел. Тема... Аңысы, материал белән очрашкач, шагыйрь күңелендә туа, кабына. Аны кабызу өчен, әлбәттә, күңелеңдә шигырь уты — үз фәлсәфәң булу зарур. Гади, беркатлы булсын, әйдә. Әмма булсын. Фәлсәфәсез — шагыйрь юк.

Карлар-яңгырлар, көз-яз, кояш-йолдыз поэзиясен аны һәркем яза. Ләкин гомер буена аны гына язу кызык түгел бит. Шагыйрь фәкать үзен, үз язмышын, халкы язмышын гына гомере буена яза ала. Чөнки шәхес, язмыш — ул үзе фәлсәфә...

Иң мөһиме — шушы.

Шигырь текстындагы вак-төяк кимчелекләр, кемнеңдер китабың турында уңаймы-тискәреме сүз әйтеп куюы моның янында бик кечерәеп, югалып кала.

Фәиз ЗӨЛКАРНӘЕВ

# АЧЫК ЙӨЗ

Шагыйрәнең беренче җыентыгында күңелгә ятышсызрак, йомшаграк чыккан урыннар да бар. Ләкин бу кимчелекләр шигырьләрнең төп яңгырашына зур зыян китермиләр. Чөнки авторның җитешеп, өлгереп бетмәгән әсәрләрендә дә чын шигъри авазлар бар.

«Биеклектә очрашу»... А. Минһаҗева, тыйнак булырга тырышып, куркып тормаган — чын шагыйрьләргә хас кыюлык белән үзенә дә, башкаларга да зур таләп куйган, югары бурыч йөкләгән. Һәм билгеләп үтәргә кирәк: очрашу буласы биеклеккә таба ул шушы җыентыгы белән беренче ныклы баскычны ясаган. Хәзер инде биеклекнең икенче ягында торучы күп санлы укучылар чираты, чөнки бу бер яклы гына хәрәкәт түгел.

Биеклеккә ашкынсак та, без җирдә яшибез, аннан беркая да китеп булмый:

*Булам күп чак*
*үз ярасын үзе ялап*
*дәваланган киек кук.*

Бусы инде көнкүреш чынбарлыгы тоткынлыгындагы яралы кош авазы. Хәер, кү-

Минһаҗева Асия. «Биеклектә очрашу». Казан, 1985.

ңеле ярасыз шагыйрьләр бар микән ул дөньяда? Билгесез берәүнең: «шагыйрь ул сызланудан кычкыра, ә аның авызыннан гүзәл музыка агыла» дигән сүзләре бар. Бу — камиллектән әле бик ерак булган дөньяны ямьләндерергә тырышып сызлану, гүзәллекне калку күрсәтеп, аны ямьсез явызлыкка каршы кую:

*Шагыйрь — мәңгелек дежурда,*
*Шагыйрь — мәңгелек табип.*

Бу принциптан читкә тайпылучылар, шигърияттә үзләрен күбрәк яратучылар, яшь шагыйрәнең күңелен рәнҗетәләр, ул моның белән һич тә килешә алмый. Менә «Бер шагыйрьгә үпкә» шигыре. Кыю, аяусыз, ләкин, әдәп белән һәм хәтер саклап язылган иң уңышлы шигырьләрнең берсе дип әйтер идем. Кемгә атап язылганлыгы безгә билгесез, хәер бу әллә ни мөһим дә түгел. Сүз кайчандыр үзенең шигырьләре белән яшь күңелне дулкынландырган, тик еллар үткән саен язган шигырьләренә туры килмәслек битараф, тук җанга әйләнгән шагыйрь турында бара.

...*Кичер мине, аямыйча әйтәм туры*
*Әйтми калсам, үз җанымны*
*Тырнап торыр...*

Әйе, күпләрнең күңелендә бардыр ул «аямыйча туры» әйтәсе килгән хакыйкать. Як-ягына каранмыйча әйтүчеләр генә күренми. Куркыныч та юк әллә ни, ничектер уңайсыз. Уңайсызлыклар куркыта. Бүгенге җанлы тормышта ялганга түзеп тормаучылыкны — әдәпсезлек, вакчыллык кебек итеп кабул итә башладылар бит бервакыт. Бу күренеш әдәбиятны да читләтеп узмады, һәм, дөресен әйтик, кайбер очракларны исәпкә алмаганда, без һаман да уңайлы, тыныч тормышыбызга ябышып ятабыз. А. Минһаҗеваның әлеге шигыре чаң авазы ук булмаса да, тынлыкны бозарлык тавыш.

...*Куркыта шул: әгәр дә син*
*Кешелектә мираж булсаң,*
*Ә шигырьдә меңәрләгән*
*Тираж булсаң.*

Шигъри сүзләр белән кысылган фикерләрнең тыгызлыгы, тәгәллеге белән күңелгә уелып керәләр бу юллар. Әйе, бар алар. Пегаска атланып, дөньяны ямьләндерергә сөрән салып килеп кергәннәр. Ләкин шигърият аргамагында утыру җиңел түгел. Ә тирә-якта чуар тормыш, муллык, кызыктырырлык мөмкинлекләр... Күпләргә я батырлык җитми, я ялкаулык баса... Кемдер тына, кемдер сына, кемдер аңлашылмаслык шома һәм баш әйләндергеч эзоп теленә күчә, кемдер тел тегермәннәре белән сугыша, ә кемдер илһамы орлыгыннан үсеп чыккан сыек куаклык күләгәсендә кулындагы «ромашка» темасының таҗ яфракларын өзә: «ярата... яратмый»... Күгәргән кылыч янында тышауланган Пегас утлап йөри...

Күңел байлыгын ярты юлда түгеп бетергән талантлы шәхес турындагы уйларның дәвамы «Афәрин» исемле шигырьдә дә бар. Дөрес, «Афәрин», алдагы шигырьгә караганда таркаурак, йомшаграк эшләнгән, ләкин монда да шул ук аваздаш мотивлар:

*Нәрсә кирәк тагын:*
*Ул үз-үзе булып*
*яшәп караган!*
*Тик ярты гомергә дә җитмәгән*
*запасы!*
*Менә*
*яшәп карасын әле*
*кеше,*
*азакка тиклем*
*үзе булып*
*яшәп карасын!*

Нинди упкыннар, нинди чоңгыллар суыра безнең күңел мәрҗәннәребезне, фидакарь хыялларыбызны? Автор әле моның нәтиҗәләрен генә күрә. Сәбәпләрен, барышын «туры» сөйләргә ул әле әзер түгел — «башы яшь»... Тик, кем әйтмешли, «яшьлек» дигән «кимчелек» озакка сузылмый. Ә хәзергә шул бер аяныч кына:

*Йолдыз булып*
*атылырга туган*
*гомер үтә!..*

Гомер үтә... Гомер үткән саен яшь шагыйрә дә, бәлки, бераз үзгәрер, ләкин, тынмасын иде, сынмасын иде бу тынгысыз тавыш. Ни әйтсәң дә, шигърият бит ул беренче чиратта — көрәш! Көрәш уты сүнгән, тынычланган, тере дөньяның көйсезләнеп сызлануын тоймый башлаган шагыйрь — инде үле шагыйрь. Шушы уңайдан Нәҗип Думави шигырьләренең ике юлы искә төшә:

*Кычкырыйм бер утлы сүз,— калсын*
*явызлар шаккатып,*
*Кычкырыйм, яшьним, сугыйм, каткан*
*күңелне шартлатып!*

Көндәлек әдәби тормышта без шигъриятнең асылы, бәйләнеше турында оныта башлыйбыз шикелле. Шигырьләр күп языла, аларда заманга ярарга тырышкан ясалма пафос та, буш дидактика да, вак-төяк кичерешләр дә тулып ята... Безнең күзләр дә «буш токым»га күнегәләр. Дөрес, алтын алтын булып күренсен өчен ком да кирәктер. Ләкин, «ирешеп булмаслык максатларга омтылу юлларында гына шедеврлар туа», дип язган иде Б. Кремнев үзенең «Бетховен» исемле китабында.

Әйткәнемчә, авторның беренче җыентыгында кытыршырак урыннар да очрый. Бер шигыре аның шулай башлана:

*Җир — йөреп торган сәгать күк,*
*Кем күтәрер герен?*

Минемчә, бу уңышлы чагыштыру түгел, фантазия өчен дә буталчык булган катлаулы мәсьәлә. Акыл белән генә язылган шигырь югары максатка ирешмәгән. Менә икенче шигырьдән юллар:

*Бит Җиребез безнең*
*Мичкә түгел,*

*Кыршау кидерәлмәбез,*
*кул да тидерәлмәбез,*
*ярылса!..*

Бусы битараф калдырмаслык, күз алдына китерерлек, аянычлы, тәэсирле табыш. Гомумән, бу темага А. Минһаҗева аз язмаган, ләкин, кызганыч, ядрәләрнең барысы да мишеньга барып җитәрлек түгел. Аларның эшләнеше төрле «авырлык»та, төрле кайнарлыкта. Ә зур темаларга кагылганда үз-үзеңә аеруча таләпчән булырга кирәктер, чөнки, үтемсез, йомшак шигырьләрнең җитди проблемаларга зыян гына китерүе бар. Авторның хәтергә кереп кала торган табышлары бу өлкәдә аз түгел. Димәк, яуланган биеклекләрдән түбән төшмәскә тырышып эшләргә, кабатланмаган, яңа тәэсир итү көчләрен эзләргә кирәк.

Илһамсыз язылган «җитди» шигырьләр безнең матбугатта киң таралган. Теманың мөһимлеге, коньюнктура аларга «җиңел юл» ача, ә нәтиҗәдә бу «җиңел юл» шигъриятебезнең дәрәҗәсен төшерә генә. Ә бит һәр шигырьдә кечкенә генә булса да ачыш, табыш, шигърият тылсымы булырга тиеш! Аның моңы да, көе дә, фикере дә, кичереше дә, хисләре дә, хәтта, рәвеше дә ниндидер яңалык алып килергә тиеш! Менә шушы табышларның бердәмлегенә ирешкәндә, шигърият могҗизасы туа.

Асия Минһаҗеваның бу җыентыгын укып чыккач, барлык уңышларына карамастан, нәрсә җитми соң бу шигырьләргә дигән бер сәер тәэсир дә кала. Озаграк уйлаганнан соң сәбәбе дә табыла кебек — хикмәт монда иҗади процессның тарихтан, халык иҗатыннан, авыл моңнарыннан, табигатьтән, илаһи моңлы көйләрдән читтәрәк булуында. Ниндидер салкын, коры хакыйкать, төгәл белемле акыл кайбер шигырьләрдә өстенлек итә. «Вакыт», «Дөнья», «Кызыл кенәгә» әсәрләренең ахыргы дүртьюллыклары гына да шушы шигырьләрнең мәгънәви йөген күтәреп чыга алалар.

Җыентыкның баш өлешендә шундый юллар бар:

*...Үзем бер ил, дәүләт булып,*
*Тарихыма кереп барам...*

Шик юк, әйбәт әйтелгән, һәр кеше — үзе бер зур дөнья. Шунда ук янәшә икенче шигырь башланып китә:

*Кайда үзем салган сукмак,*
*Кайда димен юл башым?*
*Уйлар урманында калып,*
*Аваз салам бер башым...*

Автор монда борылып кына карады да, «юл башын» күрмичә «уйлар урманы»на кереп югалды, адашты кебек. Әйтергә кирәк, бу сорау безне дә кызыксындыра. Шагыйрә адашмасын иде, югалмасын иде катлаулы замана юлларында.

*Мәҗнүндәй чыгып йөгерәм*
*ымнар-шомнар даласына.*
*Үзе җитә. Дөнья кирәк*
*Бу табигать баласына!..*

Шушы юлларның моңына сөенеп, алга таба укыйбыз.

*Шаулый миндә кәефханә,*
*Мин — барменьы.*
*Үземнән дә күп белүче*
*Кем бар мине?*

Шәп рифма табылган, оригиналь рәвеш, интонация! Ләкин, шушы отыш өчен, автор шигырьнең күңел кузгатырлык моңын алмаштырган түгелме?

Шагыйрьләрнең күп өлеше кебек, А. Минһаҗева да авылда туып үскән. Ләкин, җыентыктагы шигырьләрнең кайберләрен бүгенге шәһәр кызы яза дип уйларлык. Бәлки аңа хәрәкәтне кире яктан башларгадыр? Тормышның нигезләреннән күтәрелеп һәм халык зирәклегенә таянып, көннең биографиясенә лаеклы бәя бирү кирәктер? Ныклы, ышанычлы тарихи һәм рухи җирлектә генә без авторның тыгыз, борчулы һәм эзләнүчән хисләренең тулы илһамлы куәтен сизәрбез кебек.

Шигъриятә яңа сүзләр белән тәҗрибәләр ясауга каршы килергә ярамый. Ләкин, бу тәҗрибәләрдә яңа сүзләрне шигырь тукымасы белән аерылмаслык табигый итеп бәйләү аеруча зур осталык һәм саклык таләп итә. Әгәр дә бу эш барып чыкмаса, калкып торган чит атамалар уңышсыз чыккан шигырьне каты тәнкыйть уты астына куялар.

*Үзем уйлап таптым*
*Перпетуум мобилен!*
*Ләкин менә күргәзмәгә*
*Куеп булмас моделен...*


Рус теленнән начар тәрҗемә ителгән шигырьгә охшый башлый инде бу. Русча әйбәт яңгырар иде әлеге юллар дип тә уйлап куясың... Ләкин, бай бит безнең үз туган телебез дә! Без аны аңлап кына, иңләп кенә бетерә алмыйбыз. Билгеле, яңа атамалардан беркая да качып булмый, аларга һәрвакыт төгәл тәрҗемәләр табу да мөмкин түгел. Ләкин төп омтылыш үз телебезнең барлык яшерен куәтләрен күрсәтү юнәлешендә булсын иде. Кулына каләм алган һәркемнең бу изге бурычы!

А. Минһаҗеваның беренче җыентыгы уйландыра, капма-каршылыклы фикерләр дә тудыра. Бу күренешкә бертөрле генә бәя биреп булмый. Шунысы ачык — шигырьләрдә тынгысыз, ихлас күңелле шәхес күренә. Ә бәхәс тудырырлык әсәрләр әдәбиятта беркайчан да артык түгел.

*Өйрәнәм көннең биографиясен,*
*Аның ничек яшәгәнен*
*Башка илләрдәге,*
*Башка еллардагы*
*көннәргә дә*
*сөйләр өчен.*

Зур бурыч, авыр йөк алган автор, вакланып, икеләнеп тормаган. Мондый тәвәккәллек инде үзе үк мактауга лаек.

**Рәниф ШӘРИПОВ**



Ш. Мөхәммәдев йорты

Париж Коммунасы урамы, 106 йорт.

# ДАЛАДАГЫ КАЛАДА

«Кеше өчен сәяхәт шундый кирәкле, шундый файдалы бер эш, аның кадерен фәкать сәяхәт итүчеләр генә тиешенчә аңлый алалар. Сәяхәт кешенең фикерен ача, күңелен нурландыра, белмәгәнен өйрәтә»,— дип яза үзенең бер әсәрендә күренекле татар әдибе Шакир Мөхәммәдев. Әлеге сүзләрне ул гүяки үзен күздә тотып язган. Кайда гына булмаган ул, кайда гына йөртмәгән аны язмыш егәй?!

Туган шәһәре Буадан 14 яшендә чыгып киткән Шакир Мөхәммәдев 1879 елда Оренбургның бер баена самавырчы булып эшкә керә. Бара-тора ул, төрле хуҗаларда эшләп, приказчик «дәрәҗәсе»нә ирешә һәм миллионер Хөсәеновлар конторасында хисапчы хезмәтен башкара. Аннан ул, бәхет эзләп, Мәскәүгә юнәлә һәм бер рус сәүдәгәренең конторасында эшли башлый. Озакламый бухгалтерия курсларына йөреп белемен күтәргән егетне хуҗасы Маньчжуриягә җибәрә. Ике еллап ул Харбин шәһәрендә яши. Шунда аның беренче хикәяләре иҗат ителә. 1901 елда аның ике әсәре басылып чыга: берсе Казанда, ә икенчесе Оренбургта.

Ш. Мөхәммәдев 1903 елда яңадан Оренбургка килеп Гани бай Хөсәенов конторасында эшли башлый, шунда төпләнеп кала.

Инде сәяхәткә аның әсәрләре чыга һәм татарлар яшәгән төрле төбәкләргә тарала. Оренбургта аның журналистлык таланты да ачылып китә. 1903 елдан башлап Ш. Мөхәммәдевнең «Татар угылы» псевдонимы астында прогресска каршы чыгучы һәртөрле карагруһчыларны тәнкыйть утына алган мәкалә, хикәяләре, фельетоннары, хатлары бер-бер артлы Тбилиси шәһәрендә әзербайҗан телендә чыгып килгән «Шәркый рус» газетасы битләрендә дөнья күрә башлый.

Бишенче ел революциясен дә Ш. Мөхәммәдев Оренбургта каршылый һәм революция тудырган шартларны халык арасында яңа фикерләр таратуга файдалана, халык мәнфәгатьләрен кайгыртып матбугатта чыгыш ясый.

1906 елның сентябреннән инде башка газета-журналларга язышу белән генә канәгатьләнмәгән Ш. Мөхәммәдев үзе журнал чыгара башлый: «залим байларга каршы каләм йөртүче» «Карчыга» исемле сатирик журнал. Мәгълүм ки, кыска гомерле булса да, «Карчыга»— татар вакытлы матбугаты үсешендә һәм, гомумән, мәдәниятебез тарихында сизелерлек эз калдырган журнал. Аның сәхифәләрендә дөнья күргән хикәя, фельетон, хатлар һәм революцион рухлы шигырьләрдә үз заманының актуаль мәсьәләләре күтәрелә. Күпме эреле-вaклы «ач күзле капиталистлар», надан, тәкәббер, залим муллалар, «доброволец Батыргали агай» ише шарлатан милләт каһарманнары, журнал битләрендәге язмалардан үзләрен танып, язучыны сүкмәгән, аңа теш кайрамаган?! «Казаннан Батыргали Шалканов имзасы илә бер хат алдым. Менә сүгеп яза дыр. Чамасы — Батыргалидәге сыйфат бу адәмдә булырга кирәк, югыйсә Батыргали дигән Казанда бер юан кеше бармы? Әмма соң бик ачуланган. Ну кызык тә соң шундый кешенең хатын уку»,— дип язарга тулы нигезе булган Ш. Мөхәммәдевнең. Чөнки үзенең үткен сатирасы белән бик күп байгураның ярасына тоз салган ул. Әйе, ничәмә-ничә буын әдәбият сөючеләр тарафыннан яратып укылган, Ш. Мөхәммәдев исемен киң катлау укучыларга таныткан атаклы сатирик повесть— «Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай» да мәдәниятебез тарихында күренекле урын алган Оренбургта иҗат ителгән, әнә шуннан күпсанлы татар укучылары күңеленә юл алган.

*З. Мөхәммәтҗанова рәсеме.*

*Ж. Миңнуллин тексты.*

# АБРУЙЛЫ ТӘНКЫЙТЬЧЕ

## Г. НИГЪМӘТИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Егерменче еллар татар әдәбияты тарихында исемнәрен горурланып телгә алырлык шәхесләр бар. Аларның берсе — әлбәттә, Галимҗан Нигъмәти. Бик кыска, ләкин эчтәлекле һәм игелекле иҗат гомере кичергән бу күренекле тәнкыйтьче һәм әдәбият галименең тууына быел 90 ел тулды.

Галимҗан Нигъмәтинең исеме марксистик-ленинчыл әдәбият тәнкыйтен һәм гыйлемен үстерү, марксистик-ленинчыл эстетиканы нигезләү эшенә бөтен иҗат ялкынын, яшьлек дәртен, акыл энергиясен биреп хезмәт итүнең кабатланмас үрнәге, гүзәл өлгесе булып тора.

Ул әдәбият мәйданына катлаулы һәм каршылыклы чорда — иске тормыш белән яңа тормыш алышынган елларда, яңа идеяләр, карашлар, эстетик принциплар белән искеләре арасында килешмәүчән кискен көрәш барган вакытта килде. Әдәби тәнкыйтьне, әдәбият фәнен яңа нигезгә утырту — марксистик-ленинчыл платформага кору эше бөтен актуальлелеге белән көн тәртибенә баскан чор иде бу. Әдәбиятның киләчәге, алдагы язмышы белән бәйле булган бу гаять җаваплы, авыр, масштаблы эшне Г. Нигъмәти Галимҗан Ибраһимов, Габдрахман Сәгъди, Гомәр Гали һәм башка танылган марксист тәнкыйтьчеләр белән бергә күтәрде, алар белән бер сафта торып башкарды, әдәби процесска тон бирүче, аны әйдәп баручы көчле һәм абруйлы тәнкыйтьче булды. Каләмдәшләре арасында Галимҗан Нигъмәти тирән эрудицияле, яхшы теоретик әзерлекле, принципиаль һәм объектив тәнкыйтьче булуы белән аерылып торды.

Г. Нигъмәти, әдәби тәнкыйть хәрәкәтенә килеп кушылганчы, зур мәктәп — иҗтимагый тормыш мәктәбе узды. Ул бик яшьли матбугат, совет, партия органнарына эшкә тартылды, К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әсәрләрен өйрәнү, тәрҗемә итү, пропагандалау эшенә актив керешеп китте. Аның «Октябрь һәм әдәбият» (1922), «Карл Маркс безгә нәрсәләр калдырды» (1922), «Ленин һәм пролетариат революциясе» (1924), «Адәмнәр ничек яратылган» (1924) һ. б. мәкаләләре, «Коммунизм турында» (1924), башка авторлар белән берлектә чыгарылган «Сәяси лөгать» (1925), «Иҗтимагыять дәреслеге» (1925), «1905 нче ел» (1926), «Көнбатышта сыйныфлар көрәше тарихы» (1928) һ. б. хезмәтләре марксизм-ленинизм нигезләрен нык үзләштергән, яхшы политик калыплы кеше булуы турында сөйлиләр.

Марксизм-ленинизм классикларының фәнни-теоретик мирасын өйрәнү барышында Галимҗан Нигъмәти марксистик эстетика мәсьәләләренә дә җитди әһәмият бирде. Маркс, Энгельс, Ленинның әдәбиятка, сәнгатькә мөнәсәбәттә әйткән тирән методологик фикерләрен үз тәнкыйть арсеналына алырга, аерым әдәби күренешләргә бәя биргәндә, аларны нигез принциплар буларак кулланырга тырышты.

Галимҗан Нигъмәтинең әдәбият белеме буенча язылган хезмәтләрендә, әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә сәнгатьнең үзенчәлекле бер төре буларак әдәбиятның спецификасы, социологиясе, әдәби әсәрләрдә тормышны чагылдыру принциплары, сыйнфыйлык, халыкчанлык, партиялелек кебек һ. б. гаять әһәмиятле методологик проблемалар күтәрелде һәм теоретик яктыртылыш тапты.

20 нче елларда әдәбиятны иҗтимагый нигезләре буенча тикшерү, ягъни сыйнфыйсоциаль күренеш буларак өйрәнү мәсьәләсе беренче планга чыкты. Әдәби тәнкыйтьтә Плеханов ортодоксиясе нигезендә һәр әдәби күренеш шул чорның материаль җирлегеннән үсеп чыга дигән вульгар карашка таянып, һәр чорның әдәбияты һәм язучысы шул чорның хаким идеологиясенә хезмәт итә дигән ялгыш караш яшәде. Нәтиҗәдә, үткәндәге әдәби мираска тулаем ялгыш бәя бирелде, әсәрнең социологиясен тикшерү, язучының социаль чыгышы мәсьәләсен ачыклау үзмаксатка әйләнеп китте. Әдәби-эстетик күренешләрне барлыкка китерүче төрле идея тенденцияләре, һәр дәвернең үз эчендәге социаль-сыйнфый каршылыклар исәпкә алынмады, әдәби үсеш үзенчәлекләре тулысынча һәм туп-туры иҗтимагый үсеш үзенчәлекләренә буйсындырылды.

Галимҗан Нигъмәтинең тирән теоретик әзерлеге, әдәбиятны бик нечкәләп аңлавы, эстетик сиземләү көче, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме үсешенең ерак күзалласын ачык итеп күрүе мондый катлаулы шартларда аны вульгар социологизм чирена бирешүдән саклады, дөрес методологик юнәлешнең үсүенә һәм ныгуына китергән сәбәпләрнең бик әһәмиятлесе булды. Аның «Әдәбият мәйданында» (1925), «Революция елларында әдәбиятыбыз» (1929), «Татар совет әдәбияты күтәрелештә» (1934) кебек күләмле хезмәтләре, «Әдәбиятта формализм — буржуа карашы» (1930), «Әдәбият фәненең үсеш юлы нинди булырга тиеш» (1930), «Әдәби тәнкыйтьтә механистлык һәм эклектик чыгышларына каршы» (1931), «Әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеменең үсеш юллары» (1930), «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1933) һәм башка мәкаләләре әдәбият тарихы материалларына һәм җанлы әдәби процесска таянып, марксистик-ленинчыл эстетиканың актуаль мәсьәләләрен теоретик хәл итүгә, әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть методологиясен нигезләүгә кыйммәтле өлеш булып керде.

Әдәбият социологиясе буенча теоретик карашларына килгәндә, галим һәм тәнкыйтьченең асылда дөрес позициядә торганлыгын билгеләп үтәргә кирәк. Әдәбиятның үсеш динамикасын әйдәүче көчне, бу катлаулы структураның төрле элементларын хәрәкәткә китерүче төп моментны Нигъмәти тормышның социаль-экономик шартлары җыелмасында күрде. Ул әдәбиятны җәмгыять тормышына бәйле өйрәнү белән бергә, аны үзенең эчке үсеш кануннарына ия булган мөстәкыйль организм итеп карау кирәклеген әйтеп чыкты. «Әдәбият идеологиянең бер тармагы булу белән,— дип язды Г. Нигъмәти,— идеологиянең башка тармаклары рәтеннән җәмгыять үсеше законнарына бер үк нигездә баш игән кебек, аның тагын үзенә генә караган аерымлыклары да бар»[1]. Вульгар социологларның һәм формалистларның төп ялгышын галим һәм тәнкыйтьче әдәбиятның нәкъ шушы ике яклы үсеш үзенчәлеген аңлый алмауларында күрде. Әдәбият — «идеологиянең үзенә хас сыйфатларга да ия булган тармагы», ләкин ул аерымланган, изоляцияләнгән организм түгел. «Әдәбиятны, сәнгатьне марксистча тикшерү,— дип аңлата Нигъмәти,— аны идеологиянең башка тармакларына һич бәйләнмәгән, фәкать үзенә генә махсус кануннарга ия булган күренеш итеп механик рәвештә аны аерып йөртүнең дә дөрес түгеллеген күрсәтә»[2].

Нигъмәти әдәбиятның башка идеологик формалардан аермасын аның образлылыгында күрде. «Сурәтлелек — әдәбиятның спецификасы»,— дип язды ул.

Шул рәвешле, Галимҗан Нигъмәти татар тәнкыйтендә марксистик әдәбият социологиясе принципларын кыю рәвештә формалаштырган дип әйтергә мөмкин.

Нигъмәтинең тәнкыйть методологиясендә отышлы фикерләр, уңай табыш-казанышлар белән бергә кайбер кимчелекле яклар да бар иде. Әдәби әсәрләргә бәя бирүдә сыйнфыйлыкны төп критерий итеп карау кирәклеген таныса да, тәнкыйтьче, бу мәсьәләне теоретик планда хәл иткәндә, вульгар социологик хаталар да җибәргәләде. Хәтта «Әдәбият мәйданында» кебек җитди хезмәтендә дә «сәнигъ, шагыйрь нинди иҗтимагый халәттә, кайсы сыйныфтан булса, аның ясаган, язган әсәре шул мохитның сыйныфының фикер-карашларын белдерә»[3] дигән ялгыш фикер үткәрелде. Мондый хаталар тегe яки бу дәрәҗәдә аның башка хезмәтләрендә дә чагылды. Әдәби мираска, язучылар иҗатына бәя куйганда да ул аерым очракларда вульгар социологик методологиягә нигезләнеп эш йөртә. Мәсәлән, шагыйрь Габдулла Тукайның үлеменә ун ел тулу уңаеннан язылган бер мәкаләсендә («Кызыл Татарстан», 1928, 15 апрель) Нигъмәти аның «бөек шагыйрь» икәнлеген таныса да, «иҗтимагый мотивлары ягыннан революцичел вак буржуа әдибе» булуын исбатларга тырышты.

Ләкин шунысы характерлы, Г. Нигъмәти үзенең хата карашларында катып калмады, художество күренешләренең катлаулы сыйнфый табигатен аңлау юнәлешендә үсте, тикшерү методологиясен туктаусыз камилләштерү өстендә эшләде. Аның язучы иҗаты һәм шәхесенә мөнәсәбәттәге абстракт-сыйнфый карашны кискен тәнкыйть итеп язган мәкаләләре, Переверзевның әдәби образны язучының икенче төрле яшәеш формасы дип тануына капма-каршы юнәлештә әйтелгән теоретик фикерләре татар тәнкыйтендә сыйнфыйлык мәсьәләсенең марксистик хәл ителә башлавына китерде. «Сурәт — иҗтимагый характерны күрсәтә, аның аша иҗтимагый характер эшләнеп күрсәтелгән була дип алу,— дип язды Г. Нигъмәти,— сәнгать сыйныфның үз портретын бирүче дип аңлауга илтеп чыгара. Ләкин бу караш дөрес түгел. Бу — тар караш. Чөнки нинди генә сыйныф художнигы булмасын, ул үз сыйныфы типларын бирү белән чикләнүгә зарур түгел, художник сурәтләрне теләсә нинди катлау эченнән алуы мөмкин»[4]. Күренә ки, тәнкыйтьче иҗат шәхесенең аңлы социаль позиция алу мөмкинлеген яклады, үз иҗатында җәмгыятьнең социаль практикасы тудырган бик күп башка якларны да чагылдыра алу мөмкинлегенә төшенде,

[1] Нигъмәти Г. Әдәбият фәненең үсеш юлы нинди булырга тиеш! — «Яңалиф», 1930, 1 сан.
[2] Нигъмәти Г. Әдәби тәнкыйтьтә механистлык һәм эклектик чыгышларына каршы.— «Яңалиф», 1931, 11 сан.
[3] Нигъмәти Г. Әдәбият мәйданында. М., 1925, 18 б.
[4] Нигъмәти Г. Әдәбият фәненең үсеш юлы нинди булырга тиеш! — «Яңалиф», 1930, 1 сан.

сүз художнигының дөньяга карашы аның социаль симпатияләреннән киңрәк булуын аңлады. Теоретик карашларындагы мондый югарылыкка ул туктаусыз актив иҗади эзләнүләр, киеренке практик эшчәнлек нәтиҗәсендә, партия карарлары, марксизм классикларының эстетикага кагылышлы фикерләрен тирән үзләштерү нәтиҗәсендә иреште.

20 нче еллар тәнкыйтендә Плеханов концепциясе нигезендә әдәби әсәрнең социаль эквивалентын билгеләү һәм художество ягын тикшерү аерым ике акт итеп карау гадәте кергән иде. Галимҗан Нигъмәти моның белән нигездә килешмәде: «Әдәби тәнкыйтьнең бер-береннән аерым ике акты юк»,— дип белдерде ул, әдәби-эстетик анализ берлеген яклап. Художество иҗатында идея югарылыгы белән эстетик камиллек мәсьәләсен ул бер нәрсәнең аерылгысыз ике ягы итеп карады. Революциядән соң әдәбият мәйданына килеп кергән яшь язучылар иҗатын югары идеяләрне сәнгатьчә оста сурәтләп бирү куәтеннән чыгып бәяләде, әдәби әсәрләрне коры идеяләр схемасына, политик тезислар иллюстрациясенә кайтарып калдырудан сакланырга чакырды, «әдәбият партияле булырга тиеш» дигән лозунгны әдәбияттагы художество үзенчәлекләрен агитка белән алмаштырудан гыйбарәт булмаганын[1] раслауга күп көч куйды. Ул В. И. Ленинның «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле мәкаләсеннән үз карашларын нигезләү өчен методологик әһәмиятле тезислар китерде.

20 нче еллар татар әдәби тәнкыйте методологиясендә халыкчанлык мәсьәләсенә дә гаять җитди әһәмият бирде. Әлбәттә, аның куелышы һәм хәл ителеше әдәбиятның социологиясе, сыйнфыйлыгы, партиялелеге проблемалары белән тыгыз бәйләнештә барды. Марксистик тәнкыйть матур әдәбиятның эчтәлеге ягыннан да, художество эшләнеше белән дә халыкның эстетик зәвыгына туры килерлек булуын таләп итте. Галимҗан Нигъмәти К. Нәҗми, Г. Кутуй, Сирин һ. б. шагыйрьләр иҗатындагы формалистик мавыгуларны бер яктан да хупламады, «төрле «-изм»нар юлы белән язылган әсәрләр язуга бирелеп китү революция әдәбиятына күп кыйммәт өсти алмас», дип кисәтте. Бу мөнәсәбәттә дә тәнкыйтьче В. И. Ленин позициясен үзенә төп ориентир итеп сайлады, Ленинның «сәнгать халыкныкы» дигән сүзләрен мисал итеп китерде. «Изм»нар юлы белән язылган әсәрләрне мин сәнәиг нәфисәнең югары дәрәҗәдәге әсәрләре дип хисаплый алмыйм,— диде В. И. Ленин (*тәрҗемә Г. Нигъмәтинеке*).— Мин алардан берниндә дә ләззәт таба алмыйм. Сәнгатьнең миллионнарча саналган халык арасыннан берничә йөз яки берничә мең кешегә генә кызыклы булган нәрсә бирүе әһәмиятле түгел, сәнгать бөтен халыкка булырга тиеш. Ул массага аңлаешлы, масса тарафыннан сөелерлек булсын. Ул шул массаның уе, тойгы һәм ихтыярын бергә җыйсын, аның күңелен күтәрсен. Без һәрвакыт эшче-крестьяннарны күз алдында тотарга тиешбез»[2]. Галимҗан Нигъмәтинең тәнкыйть мәкаләләре һәм хезмәтләрендә формализм, футуризм һәм башка -измнарга каршы көрәш әдәбиятның-сәнгатьнең халыкчанлыгы өчен, һәм, димәк, тормыш чынбарлыгын сурәтләүнең дереслеге — реализм өчен көрәшкә кайтып калды, партиянең «массовый укучыга исәп тотучы матур әдәбият тудыруга, әдәби иҗатта тәкәбберлек хорафатлары белән араны кыюрак өзәргә, иске мирасның бөтен техник казанышларыннан файдаланып, миллионнарга аңлаешлы яңа форма эшләп чыгаруга» чакыруына авазадаш булды. Биредә шунысын да билгеләп үтәргә кирәк ки, Г. Нигъмәти татар әдәби тәнкыйтендә «иске мирастан, аның художество, нәфислек ягыннан ирешкән җиңешләрен үрнәк итеп алу, өйрәнүгә» кыю рәвештә чакырып чыгучыларның берсе булды. Аның «Иске мирастан файдаланырга кирәкме» (1928), «Дәрдмәнд турында» (1929), «Дәрдмәнд әсәрләре» (1929) кебек һ. б. мәкаләләре — моның ачык мисалы.

Нигъмәти татар әдәбиятының революциягә кадәрге үсеш этабында булган реалистик юнәлешне яңа чорда да дәвам иттерергә кирәклекне әйтте, яңа иҗат методының асылын яктырту, аны теоретик яктан нигезләү эшенә үзеннән зур өлеш кертте, татар тәнкыйтьчеләре арасында беренчеләрдән булып, романтизмның милли әдәбиятыбыздагы идея-эстетик катлауланучын аңларга омтылыш ясады. Аның «Революция елларында әдәбиятыбыз» дигән хезмәте, «Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгә ниләр биргән?» (1929), «Ун ел эчендә әдәбиятыбыз» (1927), «Максим Горький ни белән зур?» (1928) һ. б. мәкаләләре татар әдәбиятында романтизмның прогрессив канатын күрү, «кызыл», «революцион» романтизм күренешләренә бәя бирү ягыннан характерлы. Әдәбиятчы прогрессив романтизмның реалистик әдәбиятны, юнәлешне үстерүдәге роленә игътибар итте.

Кыскасы, Галимҗан Нигъмәти үзенең кыю, сугышчан, ару-талу белмәс, ялкынлы эшчәнлеге белән татар совет әдәби тәнкыйтенең нигезләрен салуга булышты. Аның теория һәм методология өлкәсендә авыр көрәш белән яулап алынган прогрессив мирасы әдәбиятыбызның алга таба үсешенә юл ярды.

**Эльмира ГАЛИЕВА**

---

[1] Нигъмәти Г. Әдәбият һәм тормыш. Казан, 1931, 3 б.
[2] Нигъмәти Г. Әдәбият мәйданында. М., 1925.

# АНАЛАР БӘХЕТЕ

## РӘИСӘ ИШМОРАТОВАГА — 70 ЯШЬ



Ничәмә-ничә тапкыр сынаганым бар: язучы язган әсәрләрнең һәммәсе дә бердәй тигез тәэсир итә алмый укучыга. Арадан кайберләре аеруча бер җылылык белән хәтердә кала торган була. Рәисә ханым Ишморатованың минем күңелгә аеруча ошаган әсәре — тәүге әсәре дип әйтим, «Килен кайткач» дигән хикәясе булды. Мин аны беренче тапкыр китап битләреннән түгел, ә радиодан артистлар укуында ишеттем. Бик авыр хәлләрдә улы Илдарны тәрбияләгән, аны, әтисе үлгәннән соң, күз карасы кебек итеп баккан Фагыйлә карчыкның образы, аның явыз табигатьле килене, ирен гел әнисенә каршы котыртып, агулы елан кебек чагып торуы, ә Илдарның, Ленинград Хәрби Академиясен тәмамлап чыккан егетнең, әнисенә карата булган күңел җылылыгы, ахыр чиктә хатыны Рәмзияне үз ягына бора алуы, әнисен хөрмәтләргә мәҗбүр итүе бик тә ышандыргыч итеп бирелгән иде.

Хикәяне мин алтмышынчы елларны, Әлмәттә яшәгән чакта, тыңлаган идем. Инде менә егерме елдан соң, «Аналар» исеме белән басылып чыккан хикәяләр һәм очерклар җыентыгыннан кабат укыдым, тәэсирем кимемәде. Хатын-кыз әдибә кулы белән язылганлыгы, аналар бәхетенең кайчакларда нинди фаҗигаләргә юлыгуы нечкәләп ачып бирелгән. Әллә ни зур булмаган бу китапка алты хикәя һәм бер очерк урнаштырылган, аларның барысы да нигездә аналар һәм аларның кызлары турында, хатын-кыз психологиясен, аның күңел тибрәнешләрен яхшы белеп язылган әсәрләр. Бу бәләкәй генә китаптагы хикәя-очеркларның тормышчанлыгы очраклы бер хәл түгел, Рәисә ханымның проза әсәрләре белән азмы-күпме таныш кешеләр беләләр, бу әсәрләр аның озак еллар буена республикабызның газета-журналларында өзлексез язып килгән күп санлы очеркларының һәм хикәяләренең әйбәт сөземтәсе. 1965 елны басылып чыккан китаптагы кече күләмле әсәрләрнең — хикәяләрнең күтәргән проблемалары бүген дә искермәгән булуы мине шатландырды. Искермәгән булуының сәбәбен уйладым. Ә ул, бактың исә, бик гади: болар гаилә мөнәсәбәтләрен ачып биргән әсәрләр икән. Гыйбрәтле хәл. Әле күптән түгел генә гаилә язмышы әдәби әсәрләрнең үзәгенә куелмый иде. Гаилә проблемаларына төрле оешмалар да, социологлар да кечерәк бер нәрсә итеп карап килделәр. Ә менә партиябезнең XXVII съезды кискен борылыш, үзгәреш һәм тизләнеш мәсьәләләрен көн тәртибенә китереп куйгач, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсе беренче планга килеп чыккач, җәмгыятьнең бер ячейкасы булган гаилә үзенә игътибарны бик нык таләп итә башлады. Үз гомерендә байтак балалар тәрбияләп үстергән, аларга акыл һәм күңел җылысын биргән ана — Рәисә ханым гаилә проблемасын беркайчан да исеннән чыгарып тормаган икән. Бу — язучыны бизи торган сыйфат.

Соңгы елларда язучының «Рәйхана» исемле повесте бәхетле язмышка очрады. Аның хакында авторга хатлар яздылар, әсәр «Казан утлары»нда 1985 елны дөнья күргәч, шул ук елны аерым китап та булып басылып чыкканнан соң, күп санлы укучылар да, язучылар җәмәгатьчелеге дә бу әсәрне авторның җитди уңышы дип бәяләде. Шәфкать туташы, эвакуацион госпитальдә эшләгән япь-яшь кенә кыз Рәйхананың тормышчанлыгы, татар хатын-кызларында элек-электән килгән шәфкатьлелек, ярдәмчеллек, авыруларны сабыр гына бага белү сыйфатлары Рәйхананы сөйкемле иткән. Шуның өстәвенә аның ата-анасы белән булган туганлык мөнәсәбәтләре дә күзгә бәрелеп торган аерым детальләрдә ачылып бирелә. Мөлаем-сабырлык белән генә кешеләр ихтирамын казанмый Рәйхана, тормыштагы ныклыгы, гүзәллеге, һәм шул гүзәллеген гүзәл килеш саклый белүе, үз дигәненә ирешкәндә авырлыклардан курыкмавы белән дә күңелгә кереп кала.

Бу уңыш шулай ук күктән төшмәгән. Без Рәисә ханымның Арча госпиталендә эшләгәнен беләбез. Фронтларда чыныгу алган Бөек Ватан сугышы ветераны булуы да исебез дә. Тормыш биргән тәҗрибәсен аның үз әсәрләрендә уңышлы файдалана белүе — шулай ук игътибарга лаеклы матур сыйфаты.

«Рәйхана»ны уңышка китергән тагын бер шартны әйтмәсәк, бигүк дөрес булмастыр. «Рәйхана» повесте басылып чыкканчы, Рәисә ханым Ишморатова инде берничә повестьның авторы иде. Аның «Милиция лейтенанты» повесте — яшь буынны тәрбияләүгә багышланган, милиция органнарында эшләүчеләрне калку итеп сурәтләгән әсәр, әле җит-

мешенче еллар башында ук «Казан утлары» журналында басылып, СССР Эчке эшләр министрлыгы уздырган әдәби конкурста бүләк алуга ирешкән иде. Бу әсәрне иҗат итүгә аның тормыш тәҗрибәсе дә булышкандыр. Бөек Ватан сугышы чорында яшь Рәйсә Совет Армиясе сафларында хезмәт итә: ул солдат, сержант, кече лейтенант. Армиядә чакта, авыр сугыш елларында ул партиягә керә. Күренәдер ки, аның каләмгә тотынуы юкка түгел — кешеләргә әйтер сүзе бар. Ләкин ул, башкалар кебек, уналты-унҗиде яшендә яза башламый, утыз яшендә керешә иҗат эшенә. Аңа үзлегеннән күп өйрәнергә, юлында очраган байтак кына киенлыкларны җиңеп чыгарга туры килә. Ихтимал моңа холкындагы ныклык та, ихласлык та ярдәм иткәндер. Бер тотынгач, инде ул туктап калмый, гел алга бара, укучының ихтирамын яулый бара. «Милиция лейтенанты» повесте — моның ачык мисалы. Хәтерлим, повестьны укучылар мавыгып укыды. Аның дәвамын таләп иттеләр. Һәм ул язылды. «Аналар» китабыннан соң бу әсәр бер адым алга киту иде. Тел-стиль ягыннан, сюжетны оештыра белү ягыннан, кыскарак, тыгызрак итеп язу ягыннан! Шулай да әле бу повестьта персонажларның тышкы физик портреты эчке психологик портрет белән кушылып җитми иде. 1980 елны басылып чыккан «Чәчәкләр» китабында моңа ирешүне раслый торган хикәя бар. Автор әлеге «Чәчәкләр» хикәясен Чистайда Ярлылар комитеты председателе булып эшләгән әтисе Гыйниятулла Чебдаровка һәм әнисе Гыйшкыйҗамалга багышлый. Җир йөзендәге иң кадерле кешеләргә — әтиең белән әниеңә багышлана торган әсәрнең камил булуы һәм синең үзеңнең аңа ышанган булуың кирәк. Чөнки бу адым сиңа бик зур җаваплылык өсти. Бу, фронтовиклар термины белән әйткәндә, «Үз өстеңә ут алу» белән бер. Әсәрне укып чыккач, авторның моңа хаклы икәнենә ышанасың. Бу бәләкәй генә хикәядә ниндидер сабыр моң, эчке мөлаемлык һәм олы язмышлар бар. Әсәр беренче юллардан ук безнең яңа тормышыбызга авторның җылы-лирик мөнәсәбәте белән ачылып китә:

«Ничә еллар инде менә дүрт катлы йортның икенче каттагы тәрәзәләренә карап узам. Кышкы суык, ул тәрәзәләргә оста рәссамнар көнләшердәй бизәкләр төшереп, ак пәрдә яба. Яз җитеп, кояш көлеп карый башлау белән, тәрәзә төбендә яран, кына, роза гөлләре шау чәчәккә күмеләләр. Чүлмәккә утыртылган өй гөлләре янында, кечкенә генә пыяла вазада беренче чәчәкләр умырзая, энҗе чәчәк, шомырт чәчәкләре, аннан канәфер чәчәге күренә. Көзгә кадәр шулай, бер-берсен алмаштырып, төрле төстәге чәчәкләр тәрәзә төбен матурлап торалар. Алар беркайчан да шиңми...»

Мин дип сөйләүче лирик герой бу йортта көннәрдән бер көнне тәрәзә төбендәге вазада чәчәкләр юклыгын күрә. Шомланып, өйгә керә һәм гаҗәеп бер драматик күренешкә тап була. Чәчәкләр яратучы абзый вафат, ак чәчле әби ялгыз калган, авырып ята.

Һәм аларның өендә лирик герой революция көннәре белән, бөек мәхәббәт тойгылары белән бәйле тарихны ишетә. Гражданнар сугышын һәм Бөек Ватан сугышы фронтларын узган, үзен коткарып калган Зөләйхага чәчәкләр алып кайтып торган, илле биш ел буе шушы гүзәл Зөләйха белән гомер кичергән Вәли Сәфәровның — инде дөнья куйган батырның гомер юлы ачыла.

Гүзәл Зөләйханың тышкы портреты һәм рухи дөньясы, батыр Вәлинең тышкы портреты һәм кылган гамәлләре бер бөтен булып кушыла бу хикәядә һәм ул бер укуда хәтергә уелып кала.

Менә мин Рәйсә ханым Ишморатованың проза жанрында ничек үсүен сөйләп бирдем. Ләкин бит ул әдәбият мәйданына прозаик булып килгән кеше түгел.

Ул әдәбиятка бер пәрдәле пьесалар язып килде. Аның «Директор хатыны», «Бай кияү», «Куркыныч авыру», «Омтылыш» кебек бер пәрдәле пьесалары — моның мисалы. Шунысы гыйбрәтле, безнең әдәбиятта яшь каләмнәрне танучы, аларга ярдәм кулын сузучы олы җанлы әдипләр һәрвакыт булып торды. Рәйсә Ишморатованың «Бай кияү» әсәрен беренче башлап күренекле татар совет драматургы Таҗи ага Гыйззәт укый һәм, авторыннан кат-кат эшләтеп, сәхнәгә куйганчы ярдәм итә. Гамир Насрый исә яшь авторның беренче пьесаларына уңай бәя биреп, «Яшь сталинчы» газетасында (1954 ел, 12 декабрь саны) «Осталар сафына омтылу» дигән махсус мәкалә язып чыга. Әлеге бер пәрдәле комедияләр үзешчән сәнгать театрлары өчен бик тә кирәкле әсәрләр булып чыгалар. Безнең тормыштагы тискәре күренешләрне усал тел белән, кискен вакыйгалар аша камчылап, тамашачының аңын уяулыкка юнәлтәләр.

Миңа калса, Р. Ишморатовага драматургия жанрында уңыш алып килгән беренче зур әсәре «Тормыш юлында» исемле драмасы булды. Мин аның драмсекциядә укылган көннән башлап зур язмышка очравына шаһит. Секциядә катнашкан драматурглар, әсәргә ул чакта ук уңай бәя биреп, студент яшьләрнең рухи дөньяларын ачуда авторның уңышка ирешүен әйткәннәр иде. Әсәр Уфада, Академия театрында, Башкортстанның Салават, Баймак, Ауыргазы колхоз-совхоз театрларында, республикабыз күчмә театрында (хәзерге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) уйналды. Озак уйналды. Аңа

әдәбиятның күренекле вәкилләреннән Мостай Кәрим, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази уңай бәя бирделәр. «Совет Башкортстаны» газетасында (1955 ел, 28 декабрь саны) галим Әхәт Нигъмәтуллинның күләмле мәкаләсе басылды. Галим бу драманың моңарчы билгеле булган сюжетка, әйтик, Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте сюжетына якын торуын әйтә, ләкин шуңа да карамастан, яшь авторның геройлар дөньясын ачып бирүдә үз алымнарын куллануын билгеләп уза.

«Автор Зөфәр образында совет җәмгыятенә чит булган күренешләрне хөкем итә, мораль таркалуның, эшкә җавапсыз карауның, укып алган профессиядән читләшүнең гомуми эшкә, семья мөнәсәбәтләренә зарарлы булуын күрсәтә.

Авторның оригинальлеге һәм уңышы — Гөлнар образы аша көчле ихтыярлы характерны, хезмәткә яңача караучы уңай героиня образын тудыруда, авыл интеллигенциясе вәкилләренең фидакарь хезмәтен күрсәтергә омтылуда».

Димәк, бу беренче зур җитди пьесада ук «Семья мөнәсәбәтләре» дигән төшенчә килеп керә. Моны без исебездә калдырыйк. Төрле елларда Р. Ишморатова иҗат иткән күп санлы очеркларда һәм хикәяләрдә акчага табынучы, байлык артыннан куып, намусларын югалткан комсызлар, түбән зәвыклы бистә мещаннары, дан-шөһрәт артыннан чабып егылып калган саламторханнар күрсәтелә һәм шуларның антиподлары булган укытучылар, халкыбызның данлы артистлары (Гөлсем Болгарская, Галия Булатова), савымчы кызлар, терлек караучылар, колхоз председательләре, үзешчән сәнгатьтә катнашып, сәхнәгә нур өстәүче булдыклы яшьләр, завод эшчеләре мактала — нинди генә һөнәр ияләре, нинди генә проблемалар юк боларда!

Ә инде ахырга табан Рәйсә ханымның бер темага төплерәк ысуллар белән, җитдирәк сәнгать чаралары белән якынаюын күрү кыен түгел. Ул да булса — яшьләрне тәрбияләү, яңа буынны аякка бастырып, илнең патриотлары, булачак хуҗалары итеп үстереп җиткерү. Бу — аналарча кайгырту, бу аналар бәхете хакына армый-талмый эшләү. «Тормыш юлында» драмасыннан башлап, «Яшьлек канат җәйгәндә» пьесасы аша, «Милиция лейтенанты» һәм «Рәйхана» повестьлары аша үзе белгән, күңеле тарткан шушы өлкәгә кат-кат кайтып, гел уңышка ирешә бара язучы. Күрәсең, аны иҗатындагы бу олы юлга тормышта башкарган җәмәгать эшләренең профиле дә алып килгәндер. 1951—1963 елларда, уникe ел буена, ул Казан шәһәре Бауман районының халык суды утырышчысы була. 1971 елны Актаныш районы «Коммунизмга» колхозы игенчеләре аны үз колхозларының почетлы члены итеп сайлыйлар. Татарстан Язучылар оешмасында ул местком председателе булып эшли, менә хәзер, байтак еллардан бирле, Татарстан Язучылар союзы каршындагы көнкүреш комиссиясенең председателе ул.

Күрәбез, гаиләләр белән, үсмерләр язмышы белән бәйле өлкәләрдә эшләп килә Рәйсә ханым. Нәкъ менә шулар аның иҗатының профилен соңгы елларда аеруча ачык итеп билгеләделәр дә.

Рәйсә ханымның гел үсә барган иҗади тәҗрибәсе аңа уңышлар китерер дип ышанып калабыз. Әлеге ышанычны белдерергә безгә, мәсәлән, Рәйсә ханымның бер автобиографик язмасындагы акыллы һәм тыйнак юллар да булыша:

«Гомер юлындагы чакрымнарның җитмешенче баганасы күренә башлагач, гәрчә ул бик шартлы билге булса да, артта калган еллар хакында моңарчы булганга караганда бөтенчәрәк уй йөртә башлыйсың икән. Үткәндәге хәлләрне, вакыйгаларны, кешеләр белән үзара мөнәсәбәтләрне, кылган гамәлләрне, ирешкән казанышларны, эрерәк иләктән иләгәндәй буласың.

Көнендә-сәгатендә бик мөһим булып күренгән уңыш та, үз вакытында күңелне нык кына тырнап киткән тискәре күренеш тә бу иләктән коелып кала, төссезләнә, әһәмиятен югалта. Хәтер исемлегенә теркәлердәйләре исә коелмый да, төсен дә җуймый. Алары йөрәккә якын, алары дөньядан кешенең үзе белән бергә генә китәләрдер...»

Әйе, аның зур тормыш юлы узып, гомер чакрымнарына килеп җиткән фәлсәфәсе акыллы һәм халыкчан. Рәйсә ханым Ишморатова хәтер күгеннән җуелмый торган халык хакыйкатенә — яңа буыннарны лаеклы итеп тәрбияләү уена килгән икән, бу аның язучы буларак та, әни кеше буларак та бәхете.

**Гариф АХУНОВ**

*«Казан утлары» — 1988 елда*

# КАБАН КҮЛЕНЕҢ СЕРЛӘРЕ

Ничә еллар инде мин үземне гаепле хис итеп яшим. Шул чагында ул картка тиешле хөрмәт һәм игътибар күрсәтсәм, бәлки бөтенесе дә башкача булыр иде... Хәер, бөтенесен дә тәртибе буенча сөйлик...

...Карт сүзне ерактан башлады. Кабан күленә мөнәсәбәтем турында сорашырга кереште. Дөресен әйткәндә, үз мәшәкатьләрем дә житәрлек иде, шунлыктан артык кызыксыну күрсәтмичә, икеле-микеле генә җавап кайтардым.

Әйе, Кабан, әлбәттә, Казанның горурлыгы һәм бизәге, үзенә күрә тарихи истәлеге дә... Әйе, күл элеккеге данын югалта бара. («Югалту гынамы? Күз алдында чери, һәлак була»,— дип бүлдерде мине карт). Ләкин... Ни эшләмәк кирәк — прогресс өчен бәһане зурдан түләргә туры килә шул... Күлне чистартасы бар, анысы... Ләкин бу эш миллион чыгымнар сорый. Аларны каян табарга?

Менә шунда инде карт җеп очын «чыгарды» да. Хәйләкәр елмаеп, әле бер, әле икенче күзен кыскалап, әйтеп салмасынмы:

— Шул ук вакытта миллионнар тыныч кына күл төбендә ята бирә...

— Сез Казан ханлыгы хәзинәләре турындагы риваятьне күздә тотасызмы?

Карт тантаналы кыяфәттә елмаеп җибәрде:

— Кемгәдер, бәлки, риваять тәдер... Миңа килсәк, мин аңа үземә ышанган кебек ышанам. Ул гына да түгел, алдыгызда чын дөреслекне белүче бердәнбер кеше басып тора... Нигездә, мин шуны әйтергә килдем дә.

«Юкәдә икән чикләвек!»— дип эчтән генә көлемсерәп куйдым. Димәк, алдымда язу-сызу чире кагылган кеше түгел, ә борынгы хәзинәләр белән саташканнардан берәү тора. Редакцияләргә андыйлар да күп йөри иде.

— Мин Әҗемнәрдән, ягъни Азимовлардан булам,— дип дәвам итте карт.— Бу исем сезгә нәрсә турында булса да сөйлиме?

Казанлылардан кемнең генә кайчандыр зур нәсел башында торган бу борынгы исемне ишеткәне юк икән!.. Алар акчасына Болак артында төзелгән данлыклы Әҗем мәчете архитектура формалары белән, бизәлешенең камиллеге белән иң матур һәм үзенчәлекле санала.

— Шул, шул,— диде карт һәм авыз ачарга да ирек бирмичә исемнәр, фамилияләр тезеп китте.

Буынланып торган тыңлаусыз бармаклары белән кулындагы төенчекне чишәргә кереште. Аннан саргаеп инде көрән төскә керә башлаган, почмаклары кителеп-кителеп торган, кайберләренең читләре янып күмерләнгән сыман кәгазьләр килеп чыкты. Аңлавымча, монда теге яки бу дәрәҗәдә хәзинә турында әйтелгән язмалар һәм Әҗемнәр нәселенең истәлекләре иде.

Карт саклык белән зур кәгазь кисәген җәеп салды. Дөресрәге, кисәкләре белән тезеп чыкты дияргә була. Чөнки кәгазь бөгелгән урыннарыннан тәмам ертылып беткән иде. Бу — бик иске татар шәҗәрәсе иде. Аларны элек тә күргәләгәнем бар иде барлыгын, әмма мондый борынгы һәм бөртекләп эшләнгәне белән беренче тапкыр очрашуым.

— Менә монысы Казанның соңгы ханы Ядкәрнең якын кешеләреннән берсе булган,— дип карт сөякчел бармагы белән өстәге түгәрәкләрнең берсенә төртеп күрсәтте.— Бөтенесе дә шуннан башлана...

***Хөрмәтле укучыларыбыз!***

*Язучы Рафаэль Мостафинның «Кабан күле серләре» дигән яңа әсәре Кабан күле, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгенә багышлана. Автор күлнең шәһәр өчен әһәмиятенә генә тукталып калмый, ә бәлки зур борчылу белән яңа төр экологик фикерләү, табигать белән кеше мөнәсәбәтләренә яңача караш булдыру проблемаларын күтәрә.*

*Әсәр тукымасында борынгы риваятьләр, тарихи истәлекләр, Октябрь революциясенә кадәрге һәм бүгенге фәнни тикшеренүләр зур осталык белән файдаланылган.*

*Язучы Рафаэль Мостафинның бу документаль повесте журнал битләрендә сезгә 1988 елда тәкъдим ителәчәк.*

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

14 майда Татарстан Язучылар союзының ачык партия җыелышы булды. Ул СССР Язучылар союзы идарәсенең 27—28 апрельдә узган пленумы йомгаклары турында сөйләшүгә багышланган иде.

Пленумның эше, анда күтәрелгән мәсьәләләр турындагы доклад белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Туфан Миңнуллин чыкты.

Фикер алышуларда язучылар Г. Бәширов, Ж. Тәрҗеманов, Р. Мостафин, И. Юзеев, Р. Батулла, Р. Харис, А. Шәрәфи, Р. Хафизова, Ж. Дәрзаман, Л. Шакирҗанова һ. б. чыгыш ясады.

### ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

15 апрельдә Казанның Актерлар йортында Татарстан язучыларының узган елгы әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышы булды. Анда әдәбиятның төрле жанрлары буенча М. Галиев (проза), Р. Гатауллин (поэзия), Ә. Мушинский (рус язучылары иҗаты), Р. Батулла (драматургия), Р. Миңнуллин (балалар әдәбияты), К. Миңлебаев (тәрҗемә), Р. Юнысов (очерк һәм публицистика), Ф. Мусин (тәнкыйть) докладлары тыңланды.

Соңыннан фикер алышулар, әдәбиятыбызның иң актуаль мәсьәләләрен колачлаган зур сөйләшү булды.

### ДУСЛЫК БӘЙРӘМЕНДӘ

Апрель ахырында Украинада Совет әдәбияты көннәре булып узды. Күпмилләтле совет әдәбияты вәкилләре арасында бу зур әдәби бәйрәмдә шагыйрь Р. Фәйзуллин катнашты. Киевта тантаналы ачу кичәсендә чыгыш ясады.

Әдәбиятны пропагандалау буенча Бөтенсоюз Бюросы Советы члены буларак, Бюроның шул көннәрдә узган пленумы эшендә катнашты. Украинаның Чернигов өлкәсе хезмәт ияләре белән очрашты.

### УДМУРТ ЯЗУЧЫЛАРЫ БЕЗДӘ КУНАКТА

18—20 майда Удмурт язучылары Евгений Самсонов белән Александр Шкляев Балтач районында булдылар. Алар районның «Дружба», «Труд», Ленин исемендәге колхоз членнары, шушы колхозларга кергән авыллардагы мәктәп укучылары белән очраштылар, удмурт әдәбияты, удмурт һәм татар әдәбиятларының дуслыгы турында сөйләделәр, үз әсәрләрен укыдылар. Кунакларны язучы Р. Кәрами озатып йөрде.

### ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИН ЮБИЛЕЕ

Әзербайҗан ССРның Югары һәм Урта махсус белем министрлыгының карары буенча Бакуда 19 майда татар совет язучысы, тарих галиме Газиз Гобәйдуллинның тууына 100 ел тулуга багышланган югары уку йортларының арадаш Фәнни сессиясе үткәрелде.

Фәнни сессияне Әзербайҗан дәүләт университеты ректоры, академик Ф. М. Багир-Заде ачты һәм алып барды. Сессиядә Мәскәүдән Ш. Ф. Мөхәммәдъяров, Казаннан С. Х. Алишев һәм Әзербайҗан галимнәре Г. Гобәйдуллинның тормыш һәм иҗат юлын яктырткан докладлар белән чыктылар.

### ТАТАРСТАН КОМПОЗИТОРЫНА — БЕРЕНЧЕ ПРЕМИЯ

ГДРның Дрезден шәһәрендә яшь композиторларның квартет музыкасы буенча халыкара конкурсы үткәрелде. Анда Татарстаннан яшь композитор Рәшит Кәлимуллин да катнашкан иде. Әлеге конкурста безнең якташыбыз җиңеп чыкты — аңа Габдулла Тукай истәлегенә багышланган Кыллы квартеты өчен беренче премия бирелде.

### БӨТЕНРОССИЯ СЕМИНАРЫНДА

23 марттан 3 апрельгә кадәр СССР Язучыларының Пицунда иҗат йортында яшь очеркистларның Бөтенроссия семинары булды. Анда Татарстаннан журналист Хәмзә Бәдретдинов катнашты. Семинарда авторның «Казан утлары»нда басылган әсәрләре тикшерелде. Яшь очеркистның портрет-очерк жанрында эшләве билгеләп үтелде.

# БЕЛӘЗЕГЕМ, ЙӨЗЕГЕМ...

Татарстан сынлы сәнгать музеенда тупланган беләзек, йөзек һәм балдаклар коллекциясе нигездә XVIII һәм XIX гасырларга карый. Ул чорда бу зиннәтләрне йөртү милли киенүдә тотрыклы үзенчәлекләрнең берсен тәшкил иткән. Хәер, борынгы болгар традицияләренең дәвамы булган шушы үзенчәлекне әле бүгенге көндә дә еш очратырга туры килә. Юк-юк та, хатын-кызлар кулында милли беләзеккә тап буласың яисә аны гаилә ядкаре итеп саклыйлар, гүзәллегенә, эшләнеш техникасына, камиллегенә сокланалар.

Беләзек, гадәттә, ике кулда да йөртелгән һәм ир белән хатын арасындагы тигезлекне гәүдәләндергән. Өлкәнрәк яшьтәгеләр өчен киң, яшь кызлар өчен таррак беләзекләр эшләнгән. Кайберләренең киңлеге, мәсәлән, 7-8 сантиметрга җитә. Эшләнеш дәрәҗәсе дә төрлечә. Алтын йөгертелгән көмештән нечкәләп, зиннәтләп, бик купшы ясалганнары да, төсле металл кушылмаларыннан коелган гадирәк бизәклеләре дә очрый. Аларның төрле сыйныф кешеләре өчен эшләнүен аңлау кыен түгел. Әмма аларның һәркайсы, сәнгать әсәре буларак, бүген дә зур эстетик һәм тарихи кыйммәткә ия.

Белгечләр татар беләзеген ике зур төркемгә — тоташ һәм буынлап эшләнгәнгә бүлеп карый. Бу ике төркем эчендә исә тагын дистәләрчә төрле вариантлар бар. Тоташлары, мәсәлән, металл коелмасын яки тәңкәне ялпаклау юлы белән, бизәкләп, бөрчекләп ясала. Бизәк арасына каллиграфик хәрефләр белән беләзек иясенең исеме яки коръән аятьләре урнаштырыла. Язма чәчәкле-үсемлекле орнаментка шулкадәр органик берләктә кушыла ки, ул аерылгысыз бербөтен булып тоела башлый. Ә буынлы беләзекләрдә бер яки берничә асылташ кулланыла, бизәкләү рәвеше дә үзгәрә төшә. Металл чыбыклардан үреп, очочларын тамчы, еш кына арслан башы сурәтенә кертеп, асылташлар утыртып эшләнгәннәре игътибарны аеруча җәлеп итә. Идел-Кама буйларында яшәгән бүтән бер генә халык сәнгатендә дә мондый үзенчәлекле форма очрамый. Челтәрсыман буыннардан, шарнирлы тоташтыргычлар ярдәмендә кушып ясалган, өч яки биш буынлы беләзекләр тагын да зуррак осталык таләп итә. Бөтеркәләп бизәкләнгән, фирүзә, сердолик, аметист, бәллүр һәм башка асылташлар куелган бу беләзекләр гаҗәеп төсләр балкышы тудыралар.

Йөзек һәм балдакларда да, беләзекләрдәге кебек үк, болгар сәнгате традицияләренең дәвамчанлыгы ачык чагыла. Алар да металл эшкәртүнең һәм зиннәтләүнең шул ук ысуллары белән әзерләнгән. Кулланыш ягыннан исә, үзенә хас кайбер үзенчәлекләр күзәтелә. Әйтик, ирләр өчен ясалганнары саллырак һәм бизәүдә гадирәк. Хатын-кызлар өчен исә алар бизәкләп, бөрчекләп, төрле асылташлар куеп — нечкәләп эшләнгән. Татар ювелирлары ташны кисеп бизәкләү ысулын да яхшы белгән. Фирүзә, гәрәбә, агат яки бүтән төрле ташның шомартылган өслегенә гарәп хәрефләреннән аерым сүзләр һәм аятьләр төшерелгән, алар алтын белән йөгертелгән булган.

Беләзекләр һәм йөзекләрнең бар төрләрен дә санап яки сурәтләп чыгу мөмкин түгел. Биредә аларның кайберләре генә әйтеп үтелде. Бүгенге көндә ювелир сәнгате истәлекләрен галимнәр генә түгел, рәссам-осталар да җентекләп өйрәнә. Халык сәнгате традицияләре алар иҗатына илһам һәм рухландыргыч көч өсти.

**Людмила КОРОБЦОВА**,
Татарстан сынлы сәнгать музее
фәнни хезмәткәре.


**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Шәһәребезнең Лобачевский урамында Н. И. Лобачевский һәйкәле.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210




**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)